

# Гафур Каюмов

# *Упкын өстендә уен*

Пьесалар

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2003

УДК 820/89 (470)
ББК 84(2Рос=Тат)–6
К35

**Каюмов Гафур**

К 35 Упкын өстендә уен: Пьесалар.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.— 384 бит.

Бу китапта драматургның төрле театрларда уңышлы уйналып килгән сәхнә әсәрләре тупланды.

ISBN 5-298-01219-1 © Татарстан китап нәшрияты, 2003

# Керәш урынына

Тормыш, гомер, яшәеш...
Бик кызыклы һәм серле төшенчәләр...
Бигрәк тә кеше язмышын читтән күзәткәндә...
Ә минем гомер юлым бик гади...

Мәктәп, «бөек» совет армиясе сафлары, театр училищесы, актер, Тинчурин театры, Камал театры, Мәдәният министрлыгы, институт, телевидение һ.б. дип, тормыш баскычларын, аның әллә нинди бусагаларын бөртекләп санап тору кирәкме икән?.. Без барыбыз да шулайрак «яшәп» маташабыз...

Яшәү микән соң ул? Кем белә... Күп сүз... «Сүзләр, сүзләр, сүзләр»,— дигән бер акыллы драматург.

Ә бу җыентыктагы пьесаларга килгәндә, минем башка язмаска да тырышкан чагым булды... Болай да бит «сүз тутырган кәгазьләр» бик күп...

Кайберләре минем каршылыкны җиңеп чыккан кебек булды... Шуңа да бу дөньяны артык бер китап белән тутыруымны, бәлки, кичерерсез...

Ә драма әсәрләренә килгәндә... Теләгем, гомумән, драма гына түгел, әдәбиятның бүтән төрләрендә дә, сәнгатьнең башка юнәлешендә дә — Мәңгелек (Ходай Тәгалә, Абсолют) биргән күңел, йөрәк кенә тоемлаган дөнья, кеше төзелешен, аның язмышын, яшәеш мәгънәсен, тирәнлеген аңлата торган фәлсәфәгә, психологиягә омтылган әсәрләр, иҗат җимешләре күрәсе килә.

Ә җиһанның корылышына, әлбәттә, иң якын торган иҗат урыны, ул — театр.

Театрның мөмкинлекләре бик зур... Ләкин без аны әлегә бик аз һәм мескен хәлдә кулланабыз...

Әлбәттә, хыял киң колачлап, иңләп йөзәргә ярата... Тырышсак, бәлки, тирән фикерле, нечкә зәвыклы театрга табан йөз тотарбыз... Әле берничә Камера театрларыбыз да, «бәлки», дөнья күрерләр... Бәлки, татар халкы бөек булып киләчәктә тагын да үсәр, чәчәк атар... Бәлки...

Шушы өметләр белән яшәп ятмыш ошбу көндә...

*Г.Каюмов*
2002

# *Упкын өстендә өен...*

*Ике пәрдәле трагифарс*

КАТНАШАЛАР:

Хәким — 64 яшьтә.
Гөлсем — аның хатыны, 43 яшьтә.
Рәшидә — Хәкимнең беренче хатыныннан туган олы кызы, врач, 38 яшьтә.
Валера — автомеханик, аның ире, 36 яшьтә.
Сәкинә — Хәкимнең беренче хатыныннан туган икенче кызы, депутат, 36 яшьтә.
Хафиз — аның ире, милиционер, 40 яшьтә.
Ногман — Хәкимнең беренче хатыныннан туган беренче малае, «кооператор», «банкир», 35 яшьтә.
Гайшә — аның хатыны, 34 яшьтә.
Ирек — Хәкимнең беренче хатыныннан туган төпчек улы, төрмәдә утырып чыккан егет, 27 яшьтә.
Чәчкә — төпчек кызлары, 17 яшьтә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бик бай җиһазландырылган өй. Коттедж булуы да мөмкин. Көзгеләр, картиналар сөлге-тастымаллар белән каплап куелган. Уртада — өстәл. Нindидер мәҗлес көтелә. Гөлсем кухня белән өстәл арасында бөтерелә. Кыңгырау тавышы. Ишек ача. Аннан уфылдап Чәчкә килеп керә.

Чәчкә. Уф, чаба-чаба җаным чыга язды.

Гөлсем. Ярый, вакытында кайтып җиттең әле. Йә, нәрсә булды соң?

Чәчкә. Халисә апада да, Шакир абыйларда да, тет Марусяларда да булмады. Тет Маруся бер танышыннан табып бирде. Уф, боже мой, үләм дип торам.

Гөлсем. Унны алдыңмы?

Чәчкә. Ты что, мам? Көчкә-көчкә дүртне таптык. Ун еще... Ярый әле...

Гөлсем. Ярар, ярар, яхшы булган. Әйдә чишен. Кем уйлаган аны. Серафим Халисәсе, аракысыз ничек үткәрәсең, дип коткы салгач, аптырап калдым. Ярый,

булды әле. Тәк, өчесен кухняга яшер. Берсен үз бүлмәңә куеп тор.

Чәчкә. Зачем?

Гөлсем. Сиңа әйттеләр бит инде! Аңлатам. Безнең татар гадәте буенча, мәрхүмне искә алганда, борын заманнарда эчмәгәннәр.

Чәчкә. Ә хәзер?

Гөлсем. Нәрсә хәзер?

Чәчкә. Хәзер эчәләрме?

Гөлсем. Хәзер дә ярамый.

Чәчкә. А что такое мәрхүм?

Гөлсем. Бүлдермә инде. Мәрхүм? Ничек дип әйтим, үлгән кеше, покойник.

Чәчкә. Понятно!

Гөлсем. Шуңа күрә туганнарың җыелгач...

Чәчкә. Сама эчәргә ярамый, дисең...

Гөлсем. Өстәлгә куярга ярамый, яшереп кенә. (*Тамак төбенә чиертә.*) Тыңла. Син...

Чәчкә. Ни өчен мин?

Гөлсем. Чөнки син минем бердәнберем, иң акыллы кызым. Минем иң ышанычлы булышчым. (*Елый.*) Безне өзелеп яраткан кадерле әтиеңне искә алганда, синнән башка кем булышсын инде миңа. (*Мышкылдый, танавын сөртә.*) Аннан сиңа да варенка костюм, алтын цепочка кирәк бит әле. Минем бердәнбер кызым матур киенеп йөрергә тиеш.

Чәчкә. Мин болай да матур, ә варенканы син болай да аласың... Әгәр алмасаң?..

Гөлсем. Ярый, кызым, бар да әйбәт кенә, без теләгәнчә генә бетсә, бар да булыр.

Чәчкә. Без түгел, син теләгәнчә.

Гөлсем. Бигрәкләр дә акыллы инде син, кызым, нәкъ әтиең.

Чәчкә. О, комплимент, давай, мам, давай!

Гөлсем. Ник алай дисең, кызым?

Чәчкә. Что-то бик куе китте әле бу, кызым да кызым! Ладно, все. Что от меня требуется, мамуся?

Гөлсем. И-и-и, юк кына әйбер инде, кызым. Менә абыйларың, җизнәләрең, апаларың, алар да каршы килмәс, эчүгә хәзер кем каршы, кухняга яисә синең бүлмәгә кергән арада, салгалап бирерсең. Бетсә, шинкарлардан тагын алырбыз. Миңа, үзең аңлыйсыңдыр, аны эшләргә ярамас.

Чәчкә. Ярар, эшләрмен. Но, үзем дә бераз кабам, все?!

Гөлсем. Анысын үзең беләсеңдер инде, зур кыз бит

инде син хәзер. Тагын шул, кызым. (*Конверт чыгара.*) Менә бу әтиең язып калдырган васыять. Ул аны барлык балаларның кулы булганда гына дөрес дигән. Болай була инде... Ничек диим...

Чәчкә. Ладно, боргалама, вали прямо.

Гөлсем. Аракы белән генә йомшартып булмаса, кул куймасалар... Ни, үзең беләсең, алар бик кире. Ничек диим... Ярар, кызым, бар алайса.

Чәчкә. Да, әни, что-то син мине бик нык ярата башладың әле.

Гөлсем. Мин сине гел яратам. Көлмә. Болай эшләвем дә сине кайгыртканга, синең киләчәгеңне дә уйлыйм. Аннан мин дә бит әле карт хатынга охшамаган, шулаймы, ә?! (*Көлә.*)

Чәчкә. Женщина — экстра класс!

Гөлсем (*еламсырап*). Менә мәрхүм әтиеңне генә кызганам, нишләп кенә ташлап китте микән без месскеннәрне.

Чәчкә. Ладно, невтерпеж, замуж, уж пишутся без мягкого знака.

Гөлсем. Ни дидең, аңламадым?

Чәчкә. Юк, шундый правила бар урыс телендә.

Гөлсем. Әй, минем урысчам чамалы шул.

Чәчкә. Урысча дигәннән, әни, Отчизнаның татарчасы ничек була?

Гөлсем. Нәрсә, нәрсә?

Чәчкә. Трамвайда кайтканда, ике абый так говорили, Отчизнаның татарчасы ничек була, дип. Интересно, а как, мам, а?

Гөлсем. Баш катырма әле, мин каян белим.

Чәчкә. Шулай да, очень даже интересно, татарча ничек була? Ярый, мин урнаштыра торам. Все будет о' кей! Мин бит дура түгел. «Миллионы, миллионы алых роз...» (*Кухняга кереп китә.*)

Гөлсем. Ни сөйли бит. Ничава. Йа Аллам, гөнаһларымнан үзең ярлыка. Ниләр эшләргә туры килә бит... Ярый, бусы җайланды. (*Ишектә звонок.*) Ай Аллам, килеп тә җиттеләр. (*Ишек ача.*)

Ирек керә.

Гөлсем. Апаларың дип торам, син икәнсең.

Ирек. Нәрсә, мин булгач, ярамыймы? Иң әүвәл, исәнме, әни. Во-вторых, барыбер китмим, әти хөрмәте, өченчедән, баш авырта.

Гөлсем. Саумы, улым. Ачуланма, кайгыдан, борчылудан баш каткан. Кем уйлаган бит шулай булыр дип...

Ирек. Аңлашылды... Ну, нәрсә, әнкәй, баш чатный.

Гөлсем. Син нәрсә инде, Ирек, шундый көндә. Аннан каян килсен ди миндә...

Ирек (*катгый рәвештә*). Ярар, ярар, месскенләнмә, әнкәй, бар икәнен беләм бит.

Гөлсем. Синнән котылып булмас, бар әнә кухняга, Чәчкәдән сора. Кара аны, артыгын тыгынма.

Ирек. Син что инде, әнкәй, бәгърем. Чуточку и все! Чәчкә! Чәчәк тотып из Воркуты. (*Кухняга кереп китә.*)

Гөлсем. Үз балаңнан котың чыгып, аның өчен оялып йөр инде. Алма кебек бала булып үскән иде бит. Туктале, үзем дә керим әле. (*Кухняга китә.*)

Тышкы ишектән песи кебек йомшак кына атлап Ногман керә. Кулында пакет. Як-ягына карана, эзләнә, капланган әйберләрне күтәреп карый. Ул моны, кызыксынудан бигрәк, күнегелгән гадәт буенча эшли. Аның артыннан, дөбер-шатыр килеп, Гайшә килеп керә. Ул мишәрчә сөйләшә.

Гайшә. Нәрсә актарынасың инде тагын, карак мәче кебек?

Ногман. Тс-с... Нәрсә акырасың, базарга чыктың мәллә?

Гайшә. Шул җүләр гадәтеңне сөймим, эзләнәсең дә эзләнәсең. Төнлә белән йоклаганда кисәк капшап котымны аласың. Капшаганга карап, рәтең булса иде, ичмасам. Ха-ха-ха!..

Ногман. Но-но! Узынма! Минем кебек май эчендә йөздереп яшәтә торган мужик булса, күпләр түшәмгә сикерер иде. (*Һаман эзләнә.*)

Гайшә. Анысы бар инде. Әй, җанашым, алай гына, май эчендә генә яшәп күңел тынычлансын иде ул. Булмый шул. Уф, кысталып үлә яздым. Каяле, әнинең бәдрәфе үз урынында микән? (*Көлә-көлә кереп китә.*)

Ногман. Чамалап анда, бу гәүдәң белән кысылып кала күрмә. Кайда соң бу халык? (*Стенка тартмаларын актара.*)

Гөлсем килеп чыга. Ул аптырап Ногманга карап тора. Ногман аны күрми.

Гөлсем. Нишлисең, Ногман?

Ногман (*шып туктап кала, селкенми*). Ә, нәрсә?.. (*Акрын гына борыла, нишләргә дә белми аптырап кала.*)

Гөлсем. Нишлисең дим?

Ногман (*ни әйтергә белмичә*). Ни... хе-хе, ну инде... теге... Әйе, безнең шеф стенка кирәк дигән иде, ни, бу ничава бит, әни, ә?

Гөлсем. Ничава, ничава... (*Аптырап.*) Исәнләшик димме соң? Ни хәлләрең бар?

Ногман. Әй, бу эш белән дә баш катказн, яңа эш бит. Ирек әйтмешли, кооперация күселәре бит без, хи-хи-хи!.. Исәнме-саумы, әнкәй, җаныем-бәгърем! Әни, менә монда (*пакетны бирел*) кирәк булса дип, алмалар, лимоннар алган идем... Бер булса да сервилат.

Гөлсем. Рәхмәт, Ногман улым. Борчыласың калмаган, бәйрәм түгел ич... Атагыз мәрхүмнең... (*Мышкылдый башлый.*)

Ногман. Йә, йә, әни, хәзер елап берни эшләп булмый. Нишлисең инде. Үлгән артыннан үлеп булмый. Үзеңне генә бетерәсең.

Су шаулаган тавыш ишетелә.

Гайшә. Мондый бәдрәфтә көне буе утырсаң да ярый, ә. Әнигә килгән саен эшем булмаса да кереп чыгам. Мировой стандарт.

Ногман. Шаулама инде, күрәсең ич...

Гайшә. Кичер, әни. (*Еламсырап.*) Нишлисең инде, дөнья шулай барадыр. Үзең таза-саумы соң?

Гөлсем. Аллага шөкер, килен. Менә соңгы вакытта гына йөрәк сыкрап тора.

Гайшә. Үзеңне бетермә. Елап берни эшләп булмый. Нишлисең бит... Уф, үзем дә тетрәнеп калдым. Язмыштан узмыш юктыр инде ул...

Ногман. Әни, әйдә, син бераз ятып тор, без үзебез монда карарбыз.

Гайшә. Әйе, әни, син ял итеп ал. Без монда үзебез... Минем Ногман уңган ул, өйдә дә ялт итеп өстәл әзерләп ата.

Гөлсем. Өстәл дип, әллә ни шауларга ярамас...

Гайшә. Әй, шул татар, татар, дия-дия, кешене юньләп (*тамак төбенә чиертеп*) искә алып та булмый. Әйдә, әни, икенче бүлмәгә. Әллә бездән башка беркем дә юк инде?

Гөлсем. Бар. Ирек килде, Чәчкә белән кухняда.

Гайшә. Ул каламы соң... Сугыш чукмары!

Гөлсем. Әйбер-мазар кирәксә, Чәчкәдән сорагыз.

Ногман. Яхшы, тик борчылма гына. (*Әниләрен бүлмәгә кертеп чыгалар.*)

Гайшә. Боларның берәр рәтләре бар микән?! Әни бик шикле сөйләнде.

Ногман. Сиңа эчәргә ярамый, тагын кычкыра башлыйсың, тавышың тавыш булса иде, мацы куригы!

Гайшә. Мыскыллама, мишәр хәтле булырга кирәк әле. «Татарин со знаком качества» дип ничә тапкыр әйттем.

Н о г м а н. Шуңа мине атланып изәсеңме, «со знаком качества» булганга?!

Г а й ш ә. Издермә, ха-ха-ха!..

Н о г м а н. Бар, төшереп кара өстеңнән синең кебек әвенне.

Г а й ш ә. Үзең менә алмагач, ятасың инде аста мышнап, яланып, хи-хи-хи!

Кыңгырау тавышы.

Әһә, бер ач күзе килеп җитте, бар ач әле.

Н о г м а н. Менә нәрсә, болай теләсә нәрсә кычкырып утырасы булсаң, коры калачакбыз, сукыр тиен дә эләкмәс.

Г а й ш ә. Ярар, ярар, ул кадәр ахмак мишәр дигәч тә... Дәшмәм. Ну, әгәр дә безне кыса башласалар...

Тагын кыңгырау тавышы.

Бар инде, ач, дәшмәм, дидем бит, май каптым. Гайшә акча кадерен белми, шпана Ирек түгел ич мин.

Ногманга ияреп, Р ә ш и д ә, В а л е р а, С ә к и н ә, Х а ф и з керәләр. Валераның кулында авыр гына төргәк. Рәшидәдә кул сумкасы. Сәкинәнең күкрәгендә депутат значогы. Хафиз милиция лейтенанты формасыннан.

Г а й ш ә (*тыңлап утыралмыйча*). У-у-у, казанские сироты. Көтүегез белән генә йөрисез.

В а л е р а. Общий привет! Асса-ла-муляйкум! Что в переводе означает — маленько салам.

Р ә ш и д ә. Бик җәелмә, нинди көн икәнен беләсең. Саумы, Гайшә! Гөлсем апа кайда?

Н о г м а н (*Гайшәгә төртеп*). Гайшә, үзең күргәнчә, айгыр кебек таза. Ә әни теге бүлмәдә, хәле начарланыбрак тора.

Р ә ш и д ә. Ни булды?

Г а й ш ә. Син минем башыма сукма. Ни булды? Башта әни, дип әйтергә өйрәнегез. (*Еламсырап.*) Берәр нәрсә кирәк булса гына килеп җитәсез шул сез, хәл белергә калса — без!

Рәшидә сүз дәшми, сумкасын алып күрше бүлмәгә кереп китә. Хафиз, тирә-якны күзәтеп, уртада кала.

С ә к и н ә. Исәнмесез, саумысез, әнинең хәле ничек?

Г а й ш ә. Менә яңа совет власте исәнләшә дә белә, әни, дип тә әйтә һәм берни дә соранмый, шулаймы?

С ә к и н ә. Шулай, шулай. Әнигә ни булды?

Г а й ш ә. Совет власте булсаң, кереп кара. (*Сәкинә бүлмәгә кереп китә.*)

Х а ф и з. Ник совет властена берни дә кирәкмәсен?

Ничек итеп ул шулкадәр аппаратны, мәсәлән, хотя бы мине асрасын?!

Гайшә. Анысы дөрес, синең кебек әзмәвердәй кешене асравы авырдыр. Минем кулда булсаң, малны җәлләмәс идем дә, борының гына ни тора, их! Хи-хи-хи! Эшләп аша!

Ногман. Гайшә, җитте диләр, сөйләштек бит.

Гайшә. А! Минем мужик җикеренә башлады, кая качып котылыйм. Курыкма, бирми карасыннар, бөтен козгын оясын туздырырмын, милиция белән советтан курыккан заманнар үткән инде. Әнә калхуз базары тирәсендә тәртип сакласыннар! Шулаймы, Хафиз кияү?!

Ногман (*чәрелдәп*). Гайшә дим! (*Хафиз дәшми.*)

Валера. Ты, Гайша, кому угодно приставай, но Рашиду оставь в покое. Думаешь, она умолчит, а ты все загребешь. Как бы не так. Здесь еще я есть, богатырская наша сила...

Гайшә. Ой, үләм, ха-ха-ха, урыс богатыре, ой, тотыгыз. Күшеккән чучка, хи-хи-хи.

Савыт-саба күтәреп Чәчкә килеп чыга.

Чәчкә. Гайшә апа, у тебя часто заскоки бывают?..

Гайшә. Нәчтә?..

Чәчкә. Ну, вакыты җиттеме әллә, диюем?

Гайшә. Әй, маңка тәре, нәрсә сөйли дип торам. (*Кычкырып.*) Әдәпсез, анаңнан да юк, атаңнан да, үзең ни урыс, ни татар, тфү! Хи-хи-хи!..

Чәчкә. Ты, эти белән әнине не трожь!

Хафиз. Ногман, тый хатыныңны! Урыны түгел, вакыты да, хихылдап утырырга.

Гайшә. Ярар, ярар, өйрәтмәсәгез дә беләм. Барыгыз да күзегезне алартып килгәнсез, үтәли күрәм бит мин сезне. Карагыз аны, мишәр — эчеңне тишәр!..

Ногман. Гайшә бәгърем, ну, пожалуйста!

Гайшә. Ай, бәгырь кисәгем, нинди җөмләләр белә бит ул. Юкка гына чәче коелмаган. Бетте, май каптым. Кая соң болар? (*Бүлмәгә кереп китә.*)

Ногман (*Хафизга*). Син бүген эшләмисеңмени?

Хафиз. Төнгедән. Ә нәрсә, берәр эш бармы?

Ногман. Юк, болай гына. Ни, миңа права эшләп атырга иде бит инде. Буш итмәм.

Хафиз. Сөйләшербез әле. Байыйсыз, ә?! Машинасын алдыңмы әле?

Ногман. Юк пока. Үзең беләсең, безнең кооперативта машина юк. Ә базарда кыйбатрак. Менә әни булышса... берәр «мерс»ка...

Х а ф и з. Әни булышса? Акылың алтын икән! Белмим, бар кешегә булышып бетә алыр микән? Вообще, булышса әле...

В а л е р а. А почему нет? Вот же, я помогаю. Всегда помогал. А сейчас на ихнюю «Волгу» карбюратор принес.

Н о г м а н. Нәрсә ул?

В а л е р а. Ну батя три года назад говорил, что машина не тянет. Вот сменит.

Х а ф и з. Әле генә эти двигатель алмаштырган иде бит.

В а л е р а. Ну я не знал, я думал...

Н о г м а н. Кайгырма, «Мерседес»ка ярaса, миңа бирерсең.

В а л е р а. Еще чего. Фигу. Только бабке.

Х а ф и з. «Мерседес» аласыңмыни? Ни... ялгышма...

Н о г м а н. Йә, йә... борчылма артык... Безнең егетләр рәтен беләләр, һәрберсендә — машина.

Х а ф и з. Да, синең тормыш көйләнгән. Элитный йортта фатир, өчегезгә машиналар, шикарный дача...

Н о г м а н. Юк шул, барысы да көйләнмәгән. Әйтәм бит, әни азрак булышса, хотя бы яртысын...

Х а ф и з. Ә безнең!.. Хатынга әйтеп караган идем дә, шабашкага китим дип, курыкты. Хәзер бөтенләй депутат булып китте. Шул, әни ни дияр.

Н о г м а н. Юләр син, шабашка белән хәзер баеп буламы? Спекуляция, фарцовщиклар өчен иң кулай вакыт килде. Сине өйрәтәсе юк, үзең милициядә эшлисең, беләсеңдер. Бөтен дөньясында дефицит өстенә дефицит. Шул ук шикәр белән дөнья акча эшләргә була. Аракы белән әйткән дә юк. Йоклап ятма. Бүген права үз кулыңда.

В а л е р а. Да, умеют они наших водителей зажимать да баб разведенных. Я знаю участкового, регистрирует одиноких и симпатичных женщин отдельно и защищает их от одиночества, и якобы от другого. Тянет их потихоньку, сволочь. А шинкарям в винном достает ящиками вина. Да, что там говорить. И ты тоже...

Х а ф и з. Нәрсә син, күрдеңме? Үзең син запчасть сатып, бензин сатып...

В а л е р а. Но, но, а ну вас. Все вы на одно лицо...

Н о г м а н. Ярый, ярый, талашмагыз, әни чыгар. Нишләп сузалар инде, кая китеп беттеләр.

В а л е р а. Мужики, пошли, пока покурим.

Ч ә ч к ә әйберләр белән чыга.

Н о г м а н. Киттек. Чәчкә, без монда, тартабыз гына! Хафиз, әйдә.

Хафиз. Мин тартмыйм. (*Диванга утыра. Сигарет алып каба.*)

Чәчкә. Нәрсә, җизни, душа не спокойна? (*Аның янына диванга утыра.*)

Хафиз. Нигә алай дисең?

Чәчкә. Предчувствие тынгы бирмидер дим.

Хафиз. Ниткән предчувствие?

Чәчкә. Ну ладно, ладно! (*Пышылдап.*) Неужели минем сине ничек якын итүне сизмисең? (*Якынрак килеп утыра.*) Ә?

Хафиз. Хе, ни, ничек диим, сизәм шикелле...

Чәчкә. Ну, сизгәч, азрак миңа внимание да кирәк бит инде. (*Итәген күтәребрәк куя.*) Мин бит тоже не железная, сине көттем.

Хафиз (*каушап*). Ни дип әйтим, мин курыктым.

Чәчкә. Нәрсәдән? Миннәнме?

Хафиз. Ну, ни диим... Син бит фырт кыз. Үзең чибәр, үзең шикарная. Сиңа якын килүе — утка кергән күбәләк язмышы күк. Рэкет малайларын да җыеп килсәң...

Чәчкә. Ха-ха-ха... Ну, сказанул, җизни! Ну и что фырт! Может миңа син күбрәк ошыйсыңдыр, чем мафия егетләре, ә? (*Иягеннән сыйпап китә.*) Ха-ха-ха!.. Ничек инде ты, милиция лейтенанты була торып, малайлардан куркасың.

Хафиз. Хе, курыкмый кара, алар сине хәзер милиция дип тормыйлар. Милиция тагын да ныграк качып йөрергә тиеш әле.

Чәчкә. Ну, ярар алайса, ладно, мин сине үзем алардан саклармын, яме? Ха-ха-ха!.. Ә син аның өчен миңа...

Хафиз. Ә юк, сиңа бүләк бирә алмыйм. Сиңа бүләк бирерлек минем валюта юк.

Чәчкә. Ты что уж, җизни, какая синнән валюта? Юк, юк, миңа синнән берни дә кирәкми.

Хафиз. Кәнишне, синдәге байлык...

Чәчкә. Җизни, неужели син не можешь, хотя бы государственный машина белән булса да, мине берәр пикникка чакырырга, ха-ха-ха...

Хафиз. Пикникка, дисеңме?.. А почему... мөмкин. Әйдә, болай итәбез: бер әйбәт дача бар... Шунда барабыз.

Чәчкә. Кайчан?

Хафиз. Кайчан, дип, хет бүген. (*Коча.*) Син тик беркемгә дә сиздермә, яме?

Чәчкә. Гарантия 200 процент.

Хафиз. Безнең барудан файда булырмы икән? Бушка гына йөрисе килми бит. Аннан мин синнән өлкәнрәк.

Чәчкә. Нинди карт?! Сыйлый белсәң, все о' кей будет. Потом, үзеңнән старше кеше белән очень даже за-

манчиво. Ә калганын я обеспечу. Без бит бик «яхшы» видиклар карыйбыз.

Хафиз. Ярар, матурым! (*Үбеп ала.*) Килештек! Кайчан икәнен мин үзем хәбәр итәрмен!

Чәчкә. Ферштейн! Тик менә что, җизни: все это будет, если баш тартсаң от своей доли, и кул куйсаң, а? Что сиңа стоит, әйеме?

Хафиз (*этеп җибәрә*). Чего?! Кара син аны, акыллы баш, үзең белдеңме, әллә анаң өйрәттеме? Кара син аны, мин а то хатын тапмыйм. Извини, сине бер үбү өчен байлыктан баш тартырга минем башка тай типмәгән. Кая, бер үбим дә...

Чәчкә. Пошел ты... (*Тәмәкечеләрнең кергәне ишетелә. Чәчкә кухняга кереп китә.*)

Хафиз. Ярар, соңрак сөйләшербез әле...

Валера, Ногман керәләр. Ирек чыга, ул кызып алган.

Ирек. «Яшисе килә, яшисе килә, яшисе килә, дуслар...» О-о-о, барысы да җыелган, җыелышны ачык дип белдерик. Саумы, иптәш, товарищ мент? Привет, Валера, нихәл, кооперация күсесе?

Ногман. Яхшы. Фу, сасыган! (*Борынын каплый.*)

Ирек. Но, но, ирләр исен яратмыйсың. Син нәрсә генә яратасың соң, ә? Ирләр исен юк, хатын-кызны тем более, кхм, сәер... Ә акча исен яратасың. Гафу ит, мин сине кайвакыт кешегә санап атам, син күсе бит әле.

Хафиз. Өлгердең дә, ә?

Ирек. Иснәмә дә, тикшеренмә дә. Хет монда кеше бул. Кара әле, мине тыңласаң, адәм ясыйм мин синнән. Ә юк, сине үзгәртеп булмас. Синең йөрәгең кызыл лента белән кысып бәйләнгән инде. Октябренок, пионер, комсомол, коммунист, пенсионер — хенде хох, ха-ха-ха... Вот Валеру еще можно, а?

Валера. О чем поешь?

Ирек. Пить будешь?

Валера. Всегда готов! Что у вас за традиции, по-человечески человека не помянешь.

Ногман (*чәрелдәп*). Диваналанма, Ирек! Әти хакында уйла. Шундый көндә!

Хафиз. Артыгын кыланма!

Ирек. Кыланам? Минме кыланам?! Әйе, кыланам, ни өченме? Чөнки әти минем өчен мәңге үлмәс, ә сез аның үлемен көтеп йөрдегез.

Ногман. Син ни сөйлисең? Ничек оялмыйсың, оятсыз!

Ирек. Оялырга, хы-хы... Мин бит оятсыз. Ә, юк, менә оялдым, кызардым хәтта, мерси!

Х а ф и з. Җитте, маймылланма!

И р е к. Алайса, менә нәрсә: алай бик ирләрчә сөйләшәсегез килсә, әйдә, кухняга чыгып керик!

Н о г м а н. Җибәр, мин чыкмыйм.

И р е к. Курыкма, бүген беркемне дә кыйнамыйм. Только, только тыңласагыз гына.

В а л е р а. Нугман, слушайся старших!

И р е к. Валера, айда.

Ирләр җыйнаулашып кухняга чыгып китәләр.

И р е к (*шаярып Чәчкәне кухнядан төртеп чыгара*). Бар тизрәк, табынны әзерләп бетерегез дә, башлыйк.

Ч ә ч к ә. Абыйка, пожалуйста, исермә инде?..

И р е к. Курыкма, матурым. Бүген миңа исерергә ярамый. Нәрсә мине бик кайгыртасың әле син?

Ч ә ч к ә. Мин бит сине яратам, абый.

И р е к. Чәчкә дим!

Ч ә ч к ә. Мин гомерем буе чәчкә инде.

И р е к. Сезгә анатомия укыттылармы?

Ч ә ч к ә. Укытсалар соң.

И р е к. Киреләнмә әле, карале син моны. Яле менә миңа кара әле. Шулай. Анда нәрсә диелгән? Бертуганнар яратыша алмый.

Ч ә ч к ә. Без бертуганнар түгел.

И р е к. Без — бер ата балалары.

Ч ә ч к ә. Миңа физиология мөһим түгел, о душе предмет интересней.

И р е к. Йә, йә, бик укымышлы икән син. Йә инде, булды инде... Мин дә бит... сине... яратам.

Ч ә ч к ә. Яратмыйсың.

И р е к. Йә, шундый елак булмыйлар, булды. Син миңа бик кадерле. Сүз бирәм, бар да яхшы булыр.

Ч ә ч к ә. Мин дә бит ул турыда түгел.

И р е к. Ярый, ярый, бар да яхшы булыр.

Керел китә.

Ч ә ч к ә. Апа, апа!

Г а й ш ә. Нәрсә чыйныйсың, коерыгы кысылган чучка кебек.

Ч ә ч к ә. Җыелырга иде. Өстәл әзерләргә.

Г а й ш ә. Хәзер, җаным. (*Бүлмәгә кереп китә.*) Сәкинә, әйдә, Рәшидә, син дә калма!

С ә к и н ә чыга.

С ә к и н ә (*Чәчкәгә*). Исәнме, сеңлем? Нәрсәләр кирәк?

Ч ә ч к ә. Чашкалар да ложечки. А, нет, кухняга үзем

кереп чыгам, таба алмассың. Менә, апа, пирогны кисә тор.

Кухняга кереп китә.

Г а й ш ә (*бүлмәдән чыгып*). Йоклап тормагыз, өйдә чабып йөрергә кирәк.

С ә к и н ә. Гайшә, алай ук гөрләмә инде, килешмәс.

Г а й ш ә. У-у-уф, нишлисез сез, ә? Үзем белмим мәллә? Әтинең иң уңган, иң яраткан килене идем мин, беләсегез килсә!

С ә к и н ә. Ачуланма. Тормышларыгыз ничек соң? Күргән дә юк — дөнья куып.

Г а й ш ә. Сөйләмә инде, кооперативка күчкән булып акчасын да күргән юк. Эчә башлады.

С ә к и н ә. Ничек, Ногман эчми иде бит?

Г а й ш ә (*елап*). Җаным, хәзер сала. Тавыш та күтәрә башлады, кулы да тик тормый. Акча җиткереп булмый.

С ә к и н ә. Кит әле, кул саламы? Мин үзем сөйләшеп карармын әле. Акчаны да әйбәт кенә эшлим дигән иде бит.

Г а й ш ә (*айнып китеп*). Кирәкми. Гаилә эшенә катышма. Гаилә бозарга. Хе, кеше тормышын болгату ансат ул. Совет булдым дигәч тә. Акча эшлим дип алдый икән әле тагын, Ходаем. (*Чәчкә, чыгып, кашыклар тезә башлый.*) Шул тиеннәрен, оятсыз.

С ә к и н ә. Кысылмыйм, кысылмыйм, шаулама гына. Бар, әнә чәй алып чык.

Гайшә китә. Эчтән Валераның «Гайшә, айда, стопку» дигәне, Гайшәнең «Ә кәкже» дигәне ишетелә.

Чәчкә, син укырга керергә уйламадыңмы?

Ч ә ч к ә. Зачем? Миңа и так әйбәт!

С ә к и н ә. Эшләмисең дә, гомер буе әни җилкәсендә ятарсыңмы?

Ч ә ч к ә. И не думаю. Кызыгы юк. Ай, әтидән калган байлык бар. Менә син совет власте буларак (*юри мескенләнеп*), бәләкәй, төпчек кыз туганыгызга ул акчаларны калдырсагыз, все о’ кей будет. Немножко типтереп яшәрмен дә, берәр банкирга кияүгә чыгармын. Чибәрлегем бар, ә! Хи-хи-хи!..

С ә к и н ә. Кыланма, акыллы гына сөйләш.

Ч ә ч к ә. Мин кыланмыйм, менә сез кыланасыз, мин уйлаганымны әйтәм! Ә что толку, в самом то деле син...

С ә к и н ә. Ә нишләп банкирга, профессорга түгел?

Ч ә ч к ә. Как не понимаешь? Профессорның престижы юк хәзер. Карт булалар тем более. Ә «яңа татарлар» бешеный акча алалар.

Сәкинә. Озак шулай акча сугар дип уйлыйсыңмы?

Чәчкә. Минем гомергә җитәр. Озак яшәргә җыенмыйм.

Сәкинә. Ни сөйлисең, ә?

Чәчкә. А что? Дөньяның бөтен рәхәтен күреп бетерәм дә — а потом что? Искать смысла жизни? Не хо-чу! Сезнең кебек яртышар ел в Верховном Совете акыллы фикергә килә алмыйча чокчынnetworkыргамы? И вообще, калдырыгыз мине, я не ребенок!

Кухняга китә, анда Гайшәнең шаркылдаганы ишетелә.
Гайшә чәйнекләр күтәреп чыга, кәефе күтәрелгән.

Гайшә. Чәй әзер, иптәш депутат. Адәмнәр, җыелыгыз!

Рәшидә чыга.

Сәкинә. Йә, ничек?

Рәшидә. Әйбәтләнә, укол кададым.

Гайшә. Әй, берни дә булмагандыр әле, без хатынкыз халкы хәйләкәр инде ул.

Сәкинә. Гайшә, җитте инде сиңа. (*Рәшидәгә.*) Сезнең малай ничәнчедә инде хәзер?

Гайшә китә.

Рәшидә. Унда. Кая гына юл алыр инде. Физикасыннан аерыла алмый.

Сәкинә. Акыллы малай ул. Галим булып китәр әле.

Рәшидә. Сөйләмә булмаганны. Кая инде ул?!

Сәкинә. Алай димә, әллә кемнәр булмый инде аны.

Рәшидә. Шулай булсын. Бөтен юанычым шул. Син кайчан Мәскәүгә китәсең?

Сәкинә. Тагын ике атнадан сессия башланырга тиеш. Үзем дә туйдым инде. Эх, Рәшидә, синең, ичмасам, юанычың бар, малаең.

Рәшидә. Соң, сез дә алып кайтыгыз тупылдатып.

Сәкинә. Булмый бит. Хафиз башта үзе төшертте, безгә әле бала кирәк түгел дип, ә хәзер үзе китәм дип тә янап ала. Мин аннан башка яшәүне күз алдына да китерә алмыйм.

Рәшидә. Ярар, булды, булды, җебемә.

Сәкинә. Соңгы вакытта акчага хирысланып китте. Эшен ташлап, шабашкага китмәкче иде, көчкә үгетләп калдым. Монда килгәндә дә... (*Туктап кала.*)

Рәшидә. Нәрсә дисең, аңламадым.

Сәкинә. Ә юк, ни, әнине чакырыйк.

Рәшидә. Әйе, җыелырга вакыт.

Кухнядан Г а й ш ә белән Ч ә ч к ә чыга.

Г а й ш ә. Үзем, әнине үзем алып чыгам. (*Керен китә.*)

Р ә ш и д ә. Чәчкә, бар, акыллым, абыйларыңны чакыр.

Чәчкә китә.

Г а й ш ә (*Гөлсемне алып чыга*). Әйдә, әни җаным, үзем генә карап йөртим әле.

Г ө л с е м. Кирәкми, минем хәлем яхшырды.

Г а й ш ә. Юк-юк, тап-таза киленең була торып, шту син...

Р ә ш и д ә. Гөлсем апа, сез тынычрак булырга тырышыгыз.

Г а й ш ә. Уф, тагын апа.

С ә к и н ә. Гайшә!

Гөлсем өстәл янына утыра, Гайшә аның янына чума.

Г а й ш ә. Әнине үзем саклап утырам. (*Рәшидәгә.*) Бар, бар, ераграк йөр, хәзерге медицинага ышаныч юк. Әнә, дөньяда иң артта калганбыз диме?

И р л ә р чыга, барысы да кызмача.

Хәзер Кашпировский бөтенегезне алмаштыра. Каяле, картым, утыр әле яныма.

Х а ф и з. Саумысез, Гөлсем апа!

Г ө л с е м. Исәнме, улым!

В а л е р а. Здравствуй, бабуля!

Г ө л с е м. Исәнме, кияү, ярый, балалар, утырышыгыз. Чәчкә кайда соң әле?

И р е к. Ул хәзер чыга. Духовкадан ашамлыклар алып калды.

Г ө л с е м. Барыгызга да мәгълүм, балалар, өч көн элек, һич көтмәгәндә, безнең иң кадерле кешебез, безне ачялангач итмәгән, яраткан, киләчәктә дә матур итеп безнең белән яшәргә теләгән изге күңелле кеше — этиегез вафат булды. (*Өстәлгә капланып елый.*)

С ә к и н ә. Кирәкми, әни.

Г ө л с е м. Нишлисең бит, язмыштыр инде. Авыр миңа, балалар.

Х а ф и з. Аңлыйбыз, әни. Син бик борчылма инде...

Н о г м а н. Әйе, әни, син үзеңне бетермә. Эти безгә бик кадерле кеше иде.

Г ө л с е м. Әй балалар, яраткан кешеңне югалту бик читен ул, аңларсыз әле.

Г а й ш ә. Әй әни, уф, йөрәгем. Эти минем өчен үлеп тора иде, акыллым, киленем, дип, сөя иде. (*Елый.*)

Н о г м а н. Тынычлан, карчык, тынычлан.

Г а й ш ә. Шту, нинди карчык булыйм ди мин сиңа?!

Н о г м а н. Ярар инде, девочка, алайса.

Г ө л с е м. Беләм, балалар, барыбыз өчен дә бу югалту бик авыр. Җитмәсә, шулкадәр көтелмәгән... (*Шыңшып ала.*) Белгәнегезчә, этиегез кайтырга тиешле самолет шартлаган. Берни дә таба алмаганнар. Туганнар каберлегендә ята, мескенем. (*Шыңшый.*) Күмүчеләр, соңгы юлга озатучылар булмагач, өчесен туганнар гына җыелып үткәрергә туры килә.

Н о г м а н (*кисәк кенә елап*). А-а-а-у-а... Әтием бәгырем, ник ташлап киттең безне? Ничек ярата идем мин сине? Син бит мине булдыклы улым, дип, сөя идең, нигезнең тоткасы син, дип!

С ә к и н ә. Тынычлан, Ногман. Елама. Нишлисең бит инде, елап кайтарып булса икән...

Г ө л с е м. Әйе, кызым, елап кайтарып булса икән, көнетөне баш күтәрмәс идем.

Х а ф и з. Эх, эткәй! Бигрәк яхшы кеше иде инде, мәрхүм. Балыкка гел минем белән йөрер иде. Син милиция, синең белән ышанычлы, дия торган иде. Зур балык тотып биреп, үзем тоттым, дип әйтерсең дисәң, шаярып кына сүгә торган иде. Кияү, син минем иң якыным, иң тотнаклы, акыллы булышчым, киләчәктә бердәнбер таянычым, дия иде. (*Шыңшый башлый. Шундый гәүдәле милициянең шыңшуы сәер булырга тиеш.*)

Г а й ш ә. Хе, бердәнбер таяныч!..

Г ө л с е м. Сабыр, кияү, тынычлан. Менә, балалар, шушы чәй өстәле янында этиегезнең якты рухын искә алып үтәрбез бергәләп. Аннан... (*Барысы да сагаеп калалар.*) Атагызның калдырган бер әманәте бар, ул турыда да сөйләшеп аласы булыр.

В а л е р а (*сикереп тора*). Мам, ой мам... Как тяжко мне! Знаете же, он мне как родной отец был! Я всегда ему помогал, всегда вместе машину ремонтировали! (*Елап.*) Вот ведь как получается? 3—4 дня назад я для его машины карбюратор приготовил, вот принес... а... его... уже нет... Ой, горе мне! Он же любил, когда я ему помогал, и сам всегда говорил: Валера, если надо будет, я тебе всегда помогу, хочь финансом, хочь так!

Ч ә ч к ә чыга.

Г ө л с е м. Кызым, әнә шул тартмадан конвертны гына алып бир әле! Ирек, син нигә читтә утырасың?

И р е к. Миңа монда да әйбәт. Нигәдер эсселәдем.

Ч ә ч к ә. Мә, әни. (*Китә башлый.*)

Г ө л с е м. Син кая?

Ч ә ч к ә. Мин кухняда булырмын.

Г ө л с е м. Юк, юк, балам, бу барыгызга да кагыла.

С ә к и н ә. Әни, бәлки, чәйләр суынганчы, бераз тынычланып чәй эчеп алырбыз.

В а л е р а. А почему чай, мәй надо?

Х а ф и з. Заткнись...

В а л е р а. Не понимаю?..

Пауза.

Г ө л с е м. Шулай дисеңме? Әйе шул, чәй эчеп алыйк.

Ч ә ч к ә (*чәй агыза башлый*). Ирек абый, әйдә.

Г ө л с е м. Ә, әйдә, Ирек.

И р е к. Юк, эчәсем килми.

Пауза.

Г ө л с е м. Менә, кызым, бу чынаякка да сал, әтиегез утыра дип уйлагыз, балалар.

И р е к. Булды инде, әни.

Ч ә ч к ә. Ә әти чәй яратмый иде...

Г ө л с е м. Ә нәрсә?

Пауза.

Шулай бугай шул... Мин барыбер аны үземнең янымда итеп сизәм.

Х а ф и з. Сеңлем! Эш ярату-яратмауда түгел, ә искә алуда, якын итүдә.

Ч ә ч к ә. Ә син монда причем?..

Х а ф и з. Ничек причем? Мин әтине бик якын итә идем. Мин аның яраткан кияве... Аннан...

Г ө л с е м. Чәчкә!

Пауза.

В а л е р а. А я тоже чай не люблю. Я...

Р ә ш и д ә. Валера, җитте!

В а л е р а. Жена, молчи! Будешь говорить, когда спирту напасешься.

Пауза.

Г ө л с е м. Тукта әле, кияү. (*Пауза.*) Ярый, балалар. Менә бу кәгазьне әтиегез, нәрсәдер сизенепме, бүтәннәнме, васыять итеп язып калдырган. Мин сезне шуның белән таныштырып китәм. Үзегез беләсез, атагыз сезнең барыгызны да тигез күреп, сезне тәрбияләү өчен, өстегез бөтен, ни теләсәгез, шуны ашасыннар өчен гомер буе тырышып эшләде. Алган грамоталары, хәтта медале дә бар! Кадерле, сөйгән хатыны сезне тәрбияләүдә

мохтаҗлык күрмәсен дип, төнне көнгә ялгап эшләде. Завхоз гына булса да, шактый мал туплап калдырды.

Валера. Батя был мировым мужиком!

Хафиз. Утыр, синсез дә беләбез без әтине.

Валера. А ты мне глотку не затыкай. Сказал мировой, и баста.

Рәшидә. Валера дим, тукта инде.

Гөлсем. Һәм менә әманәткә язылганнарны бергәләп киңәшеп бүләргә кушкан.

Сәкинә. Ирек, кил, монда урын бар бит.

Ирек. Юк!

Гөлсем. Чәчкә, кая киттең?

Чәчкә. Бәлешем яна.

Гөлсем. Ай, балалар, хет бүген карышмагыз инде. (*Пауза.*) Утыр әле.

Гайшә. Тыңлыйбыз, әни җаным, әти минем өчен изге кеше иде.

Ногман. Әйе, әни, укы. Әти безнең иң кадерле кешебез.

Гөлсем. Монда язылганча, әтиегез «Волга» машинасы, Идел буендагы дача, менә бу йортны һәм өч книжкада 67 мең акча калдыруы турында яза. Мин, әлбәттә, сезгә күрсәтмичә, үземчә генә дә эшли ала идем. Ләкин сез минем балаларым. Минем өчен сез һәрберегез кадерле. Дөрес, берәрегез мине әни дип тә танымыйдыр.

Гайшә (*Рәшидәгә янап*). Бар андый агач авызлар.

Сәкинә. Гайшә, бүлдермә.

Гөлсем. Юк, минем алай дип әйтәсем килмәде. Чынбарлыкны күздә тотканда, дөрестән дә син менә, Рәшидә, син Ногман, син Сәкинә һәм Ирек — барыгыз да әтиегез җилкәсендә хатыны үлгәннән соң калган балалар. Чәчкә генә минем кызым булып чыга. Шуңа карамастан сез барыгыз да миңа бик якын, бик кадерле. Мине дә шулай якын итәсездер дип уйлыйм.

Сәкинә. Син безгә бик кадерле, әни.

Гайшә. Әйтәсең бармы?..

Ногман. Без сине, әни, беркайчан да ташламабыз.

Валера. Да я, да мы!..

Рәшидә. Син ачуланма инде, Гөлсем апа, мин үз әниемне артык яхшы беләм, оныта алмыйм.

Гөлсем. Юк, юк, кызым, нинди ачулану ди. Мин сине бик аңлыйм. Менә шулай, балалар, сез дә, димәк, мине якын итәсез. Мин дә шулайдыр дип уйлаган идем. Үзегез беләсез, хәзерге көндә мин беркайда да эшләмим. (*Елый.*) Әтиегез мәрхүм исән чакта, бер кайгым да юк иде. Менә төпчек сеңлегез Чәчкәне, баланы да үстереп кеше итәсе бар.

Г а й ш ә. Һе, бала — айгыр!

Н о г м а н (*аяк тибеп*). Гайшә, тик утыр.

Г а й ш ә. Май каптым.

С ә к и н ә. Укып кара, әни.

Г ө л с е м. Мәле, кызым, үзең укы.

С ә к и н ә. Приамбуласын укып тормыйм, ярыймы?

Н о г м а н. Нәрсәсен, нәрсәсен?

С ә к и н ә. Ну, приамбуласын. Башын укып тормыйм, васыять шартларыннан гына башлыйм, ризамы?

Х а ф и з. Укы инде тизрәк.

В а л е р а. Че тянешь, а?

С ә к и н ә. Янмагыз. «Әгәр көтелмәгән хәл булып, аңымда булмаган килеш гомерем өзелгән очракта,— эх, эти, эти,— миннән калган «Волга» машинасын, йортны, дачаны, кассадагы алтмыш җиде мең акчаны барлык балалар һәм әниләре — Булгарова Гөлсем Халиковна белән бергәләп бүлешеп, риза булып кул куйганнан соң гына, нотариус карамагына тапшырырга. Балалар, әнисе сезнең саф акылыгызга, татулыгыгызга таянам. Бу язуның төп нөсхәсе адвокат Нуруллин А.Г.да. Аның белән киңәшегез. Бу эшләрне үзем эшләп калдырырмын дип уйлыйм. Шулай да дөнья хәлен белеп булмый. Тату булыгыз».

Г ө л с е м. Менә, балалар, шундый хәлләр. Мондый көнне кузгатып тору кирәкми дә иде. Ләкин безнең сузарга вакытыбыз юк, аннан барыгызны да тиз генә җыеп та булмый.

Р ә ш и д ә. Акча дигәндә, җыелалар...

Х а ф и з. Җыелабыз, диген...

С ә к и н ә. Шауламагыз әле, культурно гына булыйк, тәртип кирәк. Сөйлә, әни!

Г ө л с е м. Балалар, сез мине һәрвакыт тыңлап килдегез. Мин гел яхшылыкка гына өндәдем. Хәзер дә тыңлагыз әле. Ни әйтмәкче булам... Әтиегез бу эшне миңа ышанып тапшырган икән, юкка гына түгел инде ул.

Г а й ш ә. Адвокатка әйтергә дә онытмаган шул.

В а л е р а. Доверяй, но проверяй...

Р ә ш и д ә. Шауламагыз әле...

Г ө л с е м. Минемчә, иң уңайлысы, иң акыллысы: бөтен булган акчаларны минем исемгә калдырып торырга.

В а л е р а. Охо, губа ни дура!

Р ә ш и д ә. Валера!

Г ө л с е м. Аңлагыз әле башта, кияү, менә хәзер бүлешә башласак, бөтен әйбер таралып бетәчәк. Беркемдә дә капитал тупланып калмаячак, аз-азлап сез аларны таратып бетерерсез. Ә болай бары да миндә булганда, мин сезгә

һәрвакыт булышырмын. Мин бит сезнең һәрберегезне якын, тигез күрәм. Мин бит ана!

Валера. А ты, теща, и русского зятя так же уважаешь, а?

Гөлсем. Рус кешесе яхшырак та әле ул.

Валера. Вот какой я дурак оказывается, даже не догадывался, что теща меня так любит!

Рәшидә. Валера, кыланма инде.

Гөлсем. Йә, балалар, ни дисез? Шулай әйбәтрәк була бит, әйеме?

Хафиз. Ярый, Гөлсем апа. Шулай да булсын ди, ә кем гарантия бирә, син, например, мине алдамассың дип. Мин хәзер кул куярмын, ә соңыннан сез минем белән сөйләшеп тә тормассыз.

Гөлсем. Син нәрсә инде, кияү, минем хакта, ә?!

Сәкинә. Аптыраганнан әйтә торгандыр инде, әни, аптыраганнан...

Хафиз. Юк, нигә аптырыйм, менә, мәсәлән, миңа бары-югы утыз биш мең җитә ди. Бүген расписка биреп җибәрәсеңме?

Валера сызгырып куя.

Валера. Абиең сизгира биламы?

Гөлсем (*көлеп*). Кияү, ашыкма әле син, берсен хәл итик, сөйләшербез, килешербез, уйлашырбыз. Безгә әлегә бу кәгазьне хәл итәргә кирәк.

Хафиз. Менә шул шул, конкретно алгач — килеп терәлә.

Гайшә. Тукта әле, син нәрсә, милиция булгач та... Сразу 35 мең даулый башладың. Артык комсызланып, эчең күпереп, шартламасын.

Ногман (*чинап*). Хатын, утыр. Әйттеләр бит сиңа. (*Торып баса.*) Җәмәгать! Минемчә, әнинең сүзләрендә дөреслек күп, бик күп. Әни безнең һәрберебез өчен дә борчыла, һәрберебезгә ярдәм итәргә тырыша, татулык булсын дип тә уйлый.

Сәкинә. Ярый, сузма, төп сүзеңне әйт.

Гөлсем. Бүлдермә, кызым, абыең сөйли бит, әдәпле бул.

Гайшә. Әйе, абыеңны узып, әй кешеләр!

Ногман аның башына чиртә.

Ногман. Шуңа мин тулысынча әнинең сүзләре белән килешәм, ике куллап. Бу дөньяда әни сүзен тыңлап, балаларның хурлыкка калганы юк әле. Дөрес, ул безнең үги әниебез, ләкин миңа ул туган әниемнән дә кадерлерәк.

Г а й ш ә. Кадерле генәме соң, изге кеше ул.

Н о г м а н. Тик монда тагын бер ягы бар әле, әни. (*Бар да сагая.*) Юк, алай куркыныч түгел, сагаймагыз. Мин үзем өчен уйламыйм. Гомумән, үзем турында уйлаганым да юк.

Х а ф и з. Гел безнең турыда гына уйлыйсың шул. Машина алгач, аны да безгә бирерсең әле син.

Г а й ш ә. Әй, оятсыз, ни ди бит... ни ди бит...

Н о г м а н. Көлмә, көлмә... Нәкъ сезнең турыда... Минем акчага кызыкканчы, үзең эшләргә өйрән.

Г а й ш ә. Әйе, болай да юк акчабызны, тиеннәребезне санап, без мескеннәрне талап үтерәсез инде...

Х а ф и з. Син миңа акыл өйрәтмә, әйтәсеңне әйт тә...

В а л е р а. Ну и не подеретесь...

Г ө л с е м. Сабыр инде, балалар.

С ә к и н ә. Җитте сиңа, Ногман.

Г а й ш ә. Син нигә аңа бәйләнәсең, милициянне тый?!

Х а ф и з. Лыгырдама, җуан марҗа!

В а л е р а. Все братцы, хватит, пусть Нугман доскажет.

Г а й ш ә. Сөйлә, картым, сөйлә.

Н о г м а н. Нидә калдым соң әле?

Г а й ш ә. Үзең эшлә, диден тегеңә. (*Хафизга күрсәтә.*)

Н о г м а н. Ә, әйе, эшләү мәсьәләсендә. Шулай, җәмәгать, минем алда хәзерге көндә бик зур бер эш тора. Үзегез беләсез, әти миндә сату-алу эшенә осталыгың бар, дип, кечкенәдән әйтә килде. Андый талантны югалту безнең гаиләгә берниндди файда да китермәячәк.

Х а ф и з. Талант, хе!

Г а й ш ә. Бүлдермә, кеше сөйләгәндә.

Н о г м а н. Менә шул. Мин әти калдырган акчаның илле меңен алып, шул эшкә кертмәкче булам. Эшләгәч, акрынлап кайтарырмын.

Ирләр сызгырып куялар.

Г а й ш ә. Ногман эшли ул, эшли. Көне-төне эшли.

В а л е р а. Ну, у тебя и дети, теща, один хлеще другого, с ними не пропадешь.

Ч ә ч к ә. Әнинеке түгел алар.

Г ө л с е м. Чәчкә!

Х а ф и з. Син хәйләкәр, анысын беләбез. Ә нинди гарантия, что син аларны кире кайтарасың?.. Яз расписка.

Н о г м а н. Ну... яз дип... килешербез, сөйләшербез соңыннан. Башта менә бу кәгазьгә кертергә кирәк, шул сумма миңа бирелә дип. Ана кеше улына ничек ышанмасын инде?

Ч ә ч к ә. Тоже мне, ул...

Г а й ш ә. Сез минем картлачыма ташланмагыз, болай да куркытылган, йомшак ул. Кара син аларны, кагарга гына торалар.

Г ө л с е м. Мин чын күңелемнән синең яклы, улым. Әмма миңа алай эшләргә ярамый. Син бит минем бердәнберем генә түгел, сез бит күп.

С ә к и н ә. Әйе...

Г ө л с е м. Мин барыгыз өчен дә җавап бирәм. Җитмәсә, бөтен акчаны сорыйсың.

Н о г м а н. Калган акча, «Волга» белән дача, өй бар бит әле.

В а л е р а. Иш ты, чего захотел?!

Г а й ш ә (*елап*). Без хәерчеләргә күп кирәкми бит...

Р ә ш и д ә. Ай, мескеннәр.

С ә к и н ә. Ачка үлә күрмәгез тагын.

Г а й ш ә. Һай, әни җаным, нигә гел безнең белән булышалар инде. Хәерче без, ярлы.

Ч ә ч к ә. Ладно, не ной, Гайшә апа. Какие вы все җансызлар. Барыгызга да кирәк, барыгыз да ачлар. Юк, сез комсызлар, и еще оятсызлар! Здесь бичара карт әни белән мин...

Г а й ш ә. Ха-ха, карт әни диме?

Ч ә ч к ә. Заткнись, сука!

Г ө л с е м. Чү, кызым?

Ч ә ч к ә. Ә алар что, карт мама һәм девченка бернәрсәсез кала, ә алар тарткалаша. Бир, әни, барысына да, а мы по миру пойдем. Отдай все, если у них совести нету.

Г ө л с е м. Чәчкә, кызым, ярамый. Шаулама, алар да алабыз дими бит әле.

Ч ә ч к ә. Если возьмут, я на себя руки наложу!

Г а й ш ә. Әй, галәмәт була икән, тагын мал бүлешәсе була!

Ч ә ч к ә (*итәген күтәреп селки*). Вот тебе, жаба! (*Кухняга кереп китә.*)

Х а ф и з (*аның артыннан кычкырып*). Әрәм булма, яшь килеш, чибәр килеш. Йөрәкләрне яндырып калдырасың.

С ә к и н ә. Оятсызланмагыз әле.

Г ө л с е м. Бар, кызым, бар, яңадан чәй куеп җибәр әле. Ягез, тагын кем нәрсә ди?

Р ә ш и д ә. Менә нәрсә: туйдым мин бу тарткалашуны тыңлап. Икенең берсе булсын: йә Гөлсем апа әйткәнчә, йә тигезләп бүлсеннәр. Мине кыстырмасагыз да ярый, аның өчен килмәдем.

В а л е р а. Чего?! Ты что, дура! Спятила что ли? Я не собираюсь всю жизнь тащить тебя и твоих детей на сво-

ем горбу. (*Бугазына сызып.*) На-до-ело. Грабежь средь белого дня.

Р ә ш и д ә. Кычкырма! Беренчедән, синең тиенеңне дә күргәнем юк, эчеп бетереп барасың. Икенчедән, әнә ал да акчаңны, күземә күренмәсәң дә була.

Ярсып чыгып китмәкче була, Валера белән Сәкинә туктата.

В а л е р а. Извини, жена, погорячился, я же без тебя не могу. Умру потом. Без тебя мне и медного гроша не будет.

С ә к и н ә. Син нәрсә инде, апа, алай итмә. Дөрес әйттең. Барыбызга да тигез булырга тиеш. Сиңа да...

Р ә ш и д ә. Уф Алла, ярар, бары тик тизрәк хәл итегез.

Г ө л с е м. Ничек инде тигез, балалар?

С ә к и н ә. Ничек дип, семья башы буенча инде. Ирекә дә.

Г ө л с е м. Алай... Сезгә дә, миңа да, Чәчкәгә дә бертигез. Без — өчәү.

Х а ф и з. Каян килеп?

Г ө л с е м. Җансызлар, мәрхүм әтиегезне онытып та бетердегез, ә ул минем күңелемдә мәңге яшәр. Ә сез... Алай, улым, Ирек, син нигә дәшмисең?

И р е к. Әй! (*Кул селки.*)

Г ө л с е м. Ник дәшмисең дим? (*Елый.*) Минем яраткан улымны өлешсез калдырырга уйлыйлар.

И р е к. Ярар инде, әни, арттырма.

Г ө л с е м (*боерып*). Әйт үз сүзеңне!

И р е к. Миңа берни дә кирәкми, барыбер эчеп бетерәм.

С ә к и н ә. Алай булмый, тигез булырга тиеш, син дә бит эти малае.

И р е к (*көлеп*). Алай бик бирәсегез килгәч, барысын да бирегез, минем бергә утырган егетләр күп, ул безгә җитми дә калачак.

Х а ф и з. Сиңа артыкка китмәсен, нәфесләнмә, тыгылмасын.

И р е к. Мент, барын да ал алайса.

Х а ф и з. Миңа бары да кирәкми, бары 35 мең.

Г а й ш ә. Тотып тор иснәп, яме.

Х а ф и з. Ногман, тый хатыныңны, юкса...

Г а й ш ә. Әй, куркытмасана, хөрәсән, начальство ләббәйкәсе...

Н о г м а н. Гайшә, әнисе...

Г а й ш ә. Әнисе-е, әйттем бит мин сиңа, алырсың алардан, дип. Карагыз аны, мин Ногманише генә түгел: мишәр диләр безне, әбиҗәйт итеп кенә карагыз!

Сәкинә. Нишлисез инде, туктагыз. Рәшидә әйткәнчә, аның альтернативасы бик дөрес була.

Гөлсем. Балалар, ашыкмагыз әле, уйлап эш итегез.

Гайшә. Әни, кысылып торма, карт башың белән. Йә харап булырсың, весым белән генә дә сытам бит мин сине, бүлдермә.

Сәкинә. Гайшә, нишлисең, акылыңа кил.

Гайшә. Лыгырдап кына торма әле, депутат калдыгы! Әнә үзең дә бер дә отказ бирмисең, авызың чәпелдәп тора. Оят та юк кешедә. Депутат башы белән акча сорап маташа!

Валера. Да!!!

Хафиз. Нигә оялырга тиеш әле ул, ә? Аның, депутат дигәч тә, тамагы юк мәллә? Балалары юк дигәч тә... Менә мин иртәгә үк детдомнан ун бала ияртеп алып кайтам. Великий почин булачак.

Сәкинә. Хафиз...

Хафиз. Сабыр, хатын. Безне — гүзәл совет семьясын кысмакчы булалар. Не позволю! Син, Гайшә, артыгын узына башладың. Беләсең килсә, сиңа не положено да әле.

Гайшә. Ничек инде ул — не положено?! Карак милиция булмагач, не положено ук мыни, ач күз!

Хафиз. Син бит каенатаның кызы түгел, килене генә, анысы да пешмәгән.

Гайшә. Булса соң? Мин әтинең иң яраткан килене идем, мәрхүмнең. Үзең кем соң? Хәерче кияү кисәге генә. Җитмәсә, милиция кисәге!

Валера. Че вы мелите, дураки?

Гайшә. Мин мыйламыйм, әнә теге пешмәгән.

Ногман (*кычкыра*). Гайшә, дим!

Гайшә. Болганма әле! (*Елый*.) Хатыныңны кешегә дә санамыйлар хәзер.

Рәшидә. Туктагыз дим, талашмагыз, шундый көндә?!

Сәкинә. Җәмәгать, тәртип кирәк, культурно гына. Консолидация!

Гайшә. Талагыз, тала. Без талауга өйрәнгән инде. Безгә килеп тыгынып кына китә беләсез шул сез, рәхмәтегез шулдыр.

Ногман. Нишлисең инде?

Валера. Ну и баба!

Хафиз. Син, марҗа, мине кияү генә дип кимсетмәкче булдың. Әйе, мин кияү. Әмма — нинди! Беләсезме, әти мине ничек ярата иде. Ул мине, ул... мине... улыннан да якын күрә иде.

Ирек. Мент, шапырын, но не загибай.

Х а ф и з. Ышанмыйсызмы? (*Елардай булып.*) Шулай берчак балыкка баргач...

Г ө л с е м. Туктап тор әле, кияү, җитәр. Ярар, балалар, минем киңәшне тыңламадыгыз. Мин бөтен җанымтәнемне биреп сезне үстердем. Яшьлегемне, көчемне кызганмадым. Шуңа күрә безгә дача, «Волга» машинасы, илле мең кала, калганын теләсә нишләтәсез.

В а л е р а (*сызгырып җибәрә*). Смотрите, как свистеть научился.

Г а й ш ә. Шул шул. Күбрәк сызгырып утырсаң, сызгырып калырсың әле. (*Иренә.*) Син дә утыр сызгырып.

Н о г м а н. Нишлим, суелып аңлата алмыйм бит инде мин...

Г а й ш ә. Бушны учлап калсаң, суелмый кая барырсың. Балаларыңны кочаклап ачка үлим что ли? (*Ногманны чеметеп ала.*)

Н о г м а н. Әйе шул... Сез, сез — җансызлар. Мин сезне баетырга уйлыйм, ә сез кире тәреләр. (*Елый.*) Бирегез акчаны, бирегез дим! Бирәсезме, юкмы? (*Киемен умыра башлый.*)

Г а й ш ә. Асылына күрмә инде, картым. Оятсызлар, кешене нинди хәлгә китереп җиткердегез?! Бирегез!

Х а ф и з. Асылынсын, безгә күбрәк тияр.

С ә к и н ә. Җүләр сатма әле, Ногман. Хатын колы булып яшәмә.

Н о г м а н (*әтәчләнеп*). Минем хатынга тел тидермә! Ул алтын хатын!

Г а й ш ә. Дөрес, картым, дөрес! Тынычлан, җаным. (*Су бирә.*)

Р ә ш и д ә. Уф Аллам, нишлисез инде?

В а л е р а. Жена, успокойся, тебе нельзя волноваться. Теперь я начну. До сих пор молчал. Бабуля, в соседях русские живут?

Г ө л с е м. Яшиләр.

В а л е р а. Очень хорошо! Во-первых, дверь открою, пусть братья по крови услышат. Да, вижу. Здесь мне не выжить! Полнейший национализм. Меня, русского зажали.

Х а ф и з. Акырмасана, сезне инде Чыңгыз хан заманында ук зажали. Юкны бутама.

В а л е р а. Зажали да?! (*Изүләрен ача.*)

Р ә ш и д ә. Валера, нишлисең, акылыңа кил.

В а л е р а. Уйди! Вы нацисты! Нет, вы фашисты! Хотят меня убить?! Люди!

Г ө л с е м. Ай Аллам, кияү, нишлисең?

В а л е р а. По среди России русского человека убивают. Меня, честного человека обделили, грабят! С голоду

помру! Голый буду ходить! (*Күлмәген салып ыргыта.*) А-а!..

Рәшидә. Валера, дим, зинһар өчен...

Гайшә. Вәт тамаша, чистый шашкан татар булды бу, хи-хи-хи... Шаш, шаш, котылырбыз!

Хафиз. Урыс котырса, чучкадан ким түгел икән.

Ирек. Житте сезгә!

Хафиз. Син, тюремщик, кысылма. Бу урыс, безне басып алганнары җитмәгән, безне ата малыннан мәхрүм итмәкче була.

Ногман. Талашмагыз, 50 меңне бирегез дә, мин кулымны куеп китәм, соңыннан талашырсыз.

Гайшә. Әйе, без мескен кешеләрне бутамагыз. Татулык белән бирегез.

Валера. Вот вам, пососите!

Гайшә. Ах, хайван, бәбәгеңне цокып цыгарып, форточкадан икесен ике якка томырырмын.

Валера. Не подходи! А ты, мент, 35 тысяч захотел, зарежу!

Рәшидә. Валера, дим, тукта, зинһар!

Хафиз. Ах, әле син шулаймыни?! Эчәгеләреңне актарып, койма башына элгәнне көтәсеңме? Мә алайса! (*Валерага суга.*)

Валера. Ах так. Убью!

Рәшидә. Нәрсә карап торасыз, үтерешәләр бит?!

Гомум буталыш, кычкырыш.

Ирек. Үтерешмәс, куркак алар, кычкыра гына беләләр. Һе, ата малын бүлешү шулай була микәнни инде?

Сәкинә. Тәртип, җәмәгать, тәртип, культура кирәк.

Хафиз белән Валера рәхәтләнеп якалашканда, зал ягыннан Хәким килеп керә. Кулында чемодан, өстендә ак плащ, ак костюм, туфли, ак эшләпә. Аптырап кала.

Хәким. Саумысыз, туганнар, нишлисез?

Бөтенесенең күзләре шакмак була, тораташ булып басып калалар. Озак кына селкенми торалар.

Ни булды? (*Хатынын кочмакчы була.*) Нихәл, карчык?

Гөлсем ачыргаланып кычкырып егыла. Ирек кенә этисе белән күрешә.

Ирек. Син исән... Исәнме, эти!

Барысы да (*пышылдашып*). Исән, исән...

Хәким Гөлсем янына иелә.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәхнә ачылганда шау-шу, гармун тавышы, биюләр. Кыскасы, пәри туен хәтерләтә. Картина, көзгеләрне каплаган тастымаллар шул килеш калган. Шул ук бүлмәдә, уртада Ата утыра, көлә, кул чаба. Кемнәрдер сикерә. Валера сызгыра, Чәчкә атасы янында утыра. Гөлсем өстәл белән кухня тирәсендә бөтерелә. Хафиз гына күренми.

Хәким. Җәмәгать, туктагыз, җәмәгать! (*Кабер тавышы чыгарып.*) Мәет сүз сорый. Ха-ха-ха!.. Теге дөньядан килгән кунак сүз сорый!!!

Барысы да тәгәри-тәгәри көлешәләр.

Гөлсем. Әтисе, алай ук шаярма инде. (*Көлә.*)

Чәчкә. Пап, пап, шулай, шулай, так держать!

Гайшә. Әткәй сүз сорый бит, туктагыз инде, хәшәпләр!

Валера. Тс-с-с-с, братцы, Христос воскрес! (*Чукына.*) Амин.

Хәким. О, рәхмәт, фани дөнья мәхлуклары. Ирек улым, тутыр бокалларны!

Ирек. Монда бетеп килә.

Хәким (*үз тавышы белән*). Ничава, булганын тамыз. Хафиз кияү, Хафиз кияү! Кайда ул?!

Ногман. Кайтып җитмәгән, әткәй.

Хәким. Хәзер, ул кайткач бар да булыр. Тәк, булдымы, тотыгыз бокалларны, (*чит тавыш белән*) теге дөньядан бер тост тәкъдим итәм. Кызык бит әй, ике дә уйламый күмеп куйганнар. Шәп бит, ә?! (*Шаркылдап көлә.*) Ну, мин уйладым, уйладым да чыгып карарга булдым. Мәйтәм, миннән башка болар нишләр? (*Көлә.*)

Гөлсем. Синсез без ничек яшик инде, әтисе...

Хәким. Җ-ә-ә, анасы, бүлдермә. Тыңлап бетер. Мине тыңламыйча, хәзер сез берни дә эшли алмыйсыз. Үлми калдым.

Гөлсем. Хәким, дим!..

Ирек. Дөрес, әти, һәм бу бик әйбәт!

Хәким. Во! Әйтәм бит. (*Җир астына күрсәтеп.*) Миңа анда калырга ярамый инде. Кәнишне, җаным очып йөрде инде.

Рәшидә. Әти, шулай да, ничек алай килеп чыкты соң ул?

Валера. Да, батя?

Хәким. Ничек дип, бик гади.

Күтәрүләр күңелле икән,
Бокалларны «чек» итеп...
Самолет очкан да киткән —
Тормаган мине көтеп.

Мин исән-сау яшим, бәйрәм итәм. Ура!

Барысы да. Ура!

Хәким. Бары тик теге самолеттагы кешеләр кызганыч. Анда нинди генә яхшы кешеләр булмагандыр.

Гайшә. Әй, яхшы кеше бармы инде ул хәзер?

Хәким. Юк, килен, миңа бу дөньяның иң яхшы кешеләре шундый юк-бар җирдә кырылып бетә төсле тоела. Без аларны сакларга тиеш, ә саклый алмыйбыз. Җыен пешмәгәннәре бу якта кала. Ә бит ул рейста мин һәм берничә кешедән кала барысы да акыл ияләре, язучылар. Нindидер симпозиумнан кайталар иде. Менә шул.

Сәкинә. Ничек, әти, син үзеңне пешмәгән димәкче буласыңмы?

Гайшә. Шулай булып чыга инде, алайса...

Хәким. Алайса гына түгел, килен, нәкъ шулай.

Ногман. Что син, әти, син бит изге кеше.

Валера. Да, батя!

Хәким. Менә, балалар, мин шул изге җаннар өчен күтәрәсем килә бу бокалны. (*Тын гына барысы да эчеп куя.*) Ходай Тәгалә мине саклап калган икән, бу фани дөньяның кадерен белергә тиешле мин: һәр сәгатен, һәр минутын. Хәер, мин генә түгел, без барыбыз да. Бу вакыйгадан соң шундый уй керде минем башка.

Валера. Правильно, тесть, не теряй ни минуты, пей да пой. (*Эчә.*)

Хафиз кайтып керә.

Хафиз. Бу нинди бардак биредә? Барысын да кулга алырга, бокалларны, дим!..

Валера. Сдаемся. Ура, помощь пришла. Как говорится, моя милиция меня бережет и поит!

Хәким. Маладис, кияү, күпме алдың?

Хафиз. Артыгы белән җитә. Әй, алганда кызык булды. Чулак Хөсәен белән килеп кердек бер шинкарга. Монда ул белә инде бөтен точкаларны. Хөсәен, тегеңә аракы кирәк, ди. Теге мескен хатын ни ык, ни мык... Мине күргәч, куркып калды. Әйтеп карыйм, мин әйтәм, мин просто гына, тикшереп йөрмим, дим. Юк. Кычкырмыйча, тавыш күтәрмичә рәткә килә алмады. Обыск ясыйбыз, дигәч, шиңде... (*Барысы да көлешә.*)

Сәкинә. Синең иләк авызың кычкыруга гына көйләнгән дә инде.

Хафиз. Ә кәк же...

Гайшә. Ә минем карт миңа бер дә кычкырмый, әйеме?

Ногман. Шулай булмыйча. Хатынга кычкырырга кирәкми, хатынны хөрмәт итәргә кирәк!

Сәкинә. Сезнең гаиләне инде күргәзмәгә куярлык.

Валера. Хурмат итарга. Если ты ее не хурма, то она тебя бора. (*Көлә.*)

Гайшә. Чукынмагыз әле, әнә әти исән-сау кайткан, аны тыңлыйк.

Сәкинә. Әйе, син, әти, хәзер яңадан туган кебек булдың, ә?

Хәким. Кәнишне, кызым, нәкъ үзе. Лев Николаевич Толстой, «Яңадан туу», прәме өр-яңадан килеп чыккандай булдым.

Гөлсем. Әтисе, син бигрәк инде, балалар алдында.

Хәким. Стоп, хатын, бүген көн минеке. Мин командалык итәм. Нинди бала инде алар хәзер, гәүдәләренә генә кара. Чәчләре агарып килә.

Валера. Правильно, батя, вали все подряд.

Рәшидә. Җитеп тормасмы сиңа?

Валера. Ты что, жена, батя воскрес! (*Эчә.*) Амин. (*Көлә.*)

Гөлсем. Әйдәгез, ашагыз-эчегез әле. Чыннан да күңелле бәйрәмгә әйләнде бит әле бу.

Гайшә. Һай, эткәй җаным, бигрәк ямь керттең өйгә, син булмасаң, ямь югала икән.

Ногман. Шулай булмыйча, карчык, эти бит ул, нур иясе!

Хафиз. Әти ул — алтын балык кебек ялтырый. Эх, әти! Балыкка барабызмы?

Хәким. Барырбыз, кияү, һичшиксез...

Чәчкә. Пап, ялагайларга не поддавайся.

Гайшә. Син нәрсә бутап утырасың. Кычыткан чыпчыгы! Белмәгәнеңә?! Ниткән ялагай?

Хәким. Шулай да кызык, минем калдык-постыкны ничегрәк бүлгәләдегез инде, ә?

Гөлсем. Бүлмәдек.

Хәким. Ничек инде? Ничек түзеп тора алдыгыз? Мин үзем менә акча дигән нәрсәне бик яратам.

Валера. Хафиз, поделись богатством, одолжи тысяч 5, а?! (*Көлә.*)

Гайшә. Жәлләмә, жәлләмә, синдә 35 бит әле. Хи-хи-хи...

Хафиз. Нишлисез, ычкындыгыз мәллә? (*Ни эшләргә белмичә, көлгән булып карый.*) Әйе, теге, юаш дигәч тә... Тыңлама син аларны, каенатай, шаяра алар. Әни барыбер беркемгә дә, бернәрсә дә бирми иде.

Чәчкә. Син нәрсә лыгырдыйсың?

Хәким. Маладис, кияү, вакланып маташмаган, сразу 35 мең, ә?! (*Көлә.*)

Х а ф и з. Алмадым, Хәким абзый.

Х ә к и м. Да, син каушама, кыю бул. Ә нәрсә? Һәркемгә дә матур яшәү кирәк.

Х а ф и з. Син нәрсә, әткәй, мин юри генә әйтеп карадым, шту син! Әнә Ногман илле меңне сразу эләктермәкче иде.

Х ә к и м. Охо! Минем улым үземә охшаган.

Г а й ш ә. Оятсыз! Күзен дә йоммый бит, ни ди?! Нәрсә, прокурор булдың мәллә безне тикшерергә? Маташма, милиция калдыгы гына әле син.

Х а ф и з. Дөрес түгел мәллә?

Р ә ш и д ә. Гайшә, шашма инде.

Н о г м а н. Син, Хафиз, милициядә эшләп, кешегә юк гаепне тагарга өйрәнеп беткәнсең. Монда азрак онытып тор инде ул гадәтеңне.

Х ә к и м. Оялма, улым, маладис. Синең кебек кешегә чүп кенә бит ул 50 мең. Үзең эшләп тапмасаң, бигрәк тә.

Н о г м а н. Юк, әткәй, мин безнең семья өчен файдалы эш оештырмакчы идем.

Г а й ш ә. Әй, әти җаным, нишлик соң? Бөлгенлеккә төштек бит без, хәерче хәлендә. Менә бу шайтан кооперативка кергән булып...

Н о г м а н. Хатын, шашма!..

Г а й ш ә (*Ногманны чеметә*). Шул, аптыраганнан инде. Ул балаларны ничек үстерер идек синең ярдәмең булмаса? Син үлгәч, әй, тфү лә, ни, син юк, дигәч, ай кайгырдык та инде, әти җаным.

Х ә к и м. Рәхмәт инде, килен, бигрәкләр дә яратасың икән.

Г а й ш ә. Яратмаган кая ул.

В а л е р а. Я, я, батя, «Волжанку» никому не отдал бы на истерзание, в ней же никто не разбирается.

Р ә ш и д ә. Нишлисең син, ни сөйләгәнеңне аңлыйсыңмы?

В а л е р а. А что? Чем мы хуже других? (*Җырлый.*)

Течет река Волга,
Издалека долго,
А Бате 17 лет...

Х ә к и м. Дөрес, кияү, сез кемнән ким?

Р ә ш и д ә. Юк, әти, безгә берни дә кирәкми!

В а л е р а. Жена!

Х ә к и м. Ышанам, кызым. Шулай да юкка, уйламыйча, беркайчан да баш тартма.

Г а й ш ә. Һе, кирәк түгел дигән була хәзер. Үзе тигез итеп булик диде дә. Әүлия.

В а л е р а. Әй верблюд, не обзывайся.

Гөлсем. Матур гына булыгыз инде, балалар. Әтиегез кайтты, нинди шатлык.

Гайшә. Әни, мескенләнмә инде син дә, пожалуйста. Үзең дә әле кайчан гына барын да потламакчы идең. Матур гына булыгыз, үләрсең...

Гөлсем. Ни сөйлисең, килен?!

Гайшә. Ни ишетәсең, шуны.

Хәким. Вәт минем хатын! Уңдым хатыннан! Аптырап калмаган.

Гөлсем (*бик гади генә*). Әйе, мин беркемгә дә таратырга җыенмадым атагыз җыйган малны. Күңелем аның кайтасын сиздe, бер дә тынычлана алмады. Ә хәзер мин нинди бәхетле. (*Хәкимне кочаклый.*)

Хәким. Ә син, Ирек улым, берни дә алмадыңмы?

Ирек. Миңа, әти, бу акчалар азрак тоелды. Минем масштаб башка бит.

Хафиз. Масштаб, дигән була, бер яртыга акча таба алсаң, бик шат инде син.

Ирек. Мин синең шикелле вытрезвительдәге исерекләрнең соңгы тиеннәрен җыймыйм, хәләл акчам. Шуңа шатлыклы да.

Хафиз. Син мине башта тот, аннан...

Сәкинә. Җитте инде сезгә, әнә, аракыңны сал.

Валера. Да, а то остынет.

Ногман. Әйдәгез әле, әти хөрмәтенә күтәрик әле.

Чәчкә. Әти, гомумән, у всех хочу спросить, можно?

Хәким. Сора, кызым, сора.

Чәчкә. Менә Отчизнаның татарчасы ничек будет?

Гайшә. Әй, берәр җүнле сүз әйтәме дисәң...

Хәким. Туктале, килен, тукта. Бик кызыклы әле бу. Каян башыңа керде әле ул?

Чәчкә. Шулай трамвайда ике абзый сөйләшеп кайттылар.

Хәким. Ничек диим, мин карт кеше, белеп тә бетермәм, йә, яшьләр, ничек була?

Ногман. Һе, аның татарчасы буламыни — Отчизна Отчизна инде.

Хафиз. Кызык әле, ничек инде ул, татарчасы бардыр аның, туктале, Отчизна, Отчизна, карале, искә төшми!

Гайшә. Нәрсә килсен синең калай башыңа. Отчизна Родина була ул!

Валера. Ха-ха-ха... Отчизна, Родина!

Гайшә. Нәрсә ыржаясың?

Валера. У вас, у татар нету Отчизны, поэтому и такого слова нет.

Хафиз. Но, но, Татарстанда яшисең!

В а л е р а. Ну и что, Татария называется, командуем мы.

Р ә ш и д ә. Ашыкмагыз әле, бар бит аның татарчасы, ничек соң әле?

С ә к и н ә. Ул турыда уйлап караган да юк иде, һе, ничек соң?

Г ө л с е м. Әй, юкка баш ватмагыз, минем башны да катырды инде ул. (*Чәчкәгә.*) Син дә вакытын таптың. Ашап-эчеп утырыгыз әле.

Х ә к и м. Ашыктырма, хатын, сез ул сүзне табарга тиеш. Бар иде андый мәгънәле сүз.

И р е к. Ялгышмасам, Ватан була бугай ул.

Х а ф и з. Ничек? Ватан? Туктале, Ватан — Родина була түгелме соң?

С ә к и н ә. Родина «род» сүзеннән алынган. Шулай булгач, туган ил була инде.

Х ә к и м. Ватан, дөрес, бар иде шул шундый матур сүз. Ватан! Карале, ә онытып бетергәнбез. Маладис, Ирек!

Г а й ш ә. Кара син аны, Себердә акыл гына җыеп яткансың икән.

Ч ә ч к ә. И в правду Ватан буламы инде, абый?

Х ә к и м. Әйе, кызым, ул изге сүз Ватан була. Ә без... онытып бетергәнбез.

Г а й ш ә. Әй, нәрсәгә соң ул җыен килде-китте сүз. Аннан башка да баш каткан.

Х а ф и з. Әйе, каян казып чыгардың, тузга язмаганны. Әйдә, салганны суытмагыз, градусы бетә.

В а л е р а. Да, придумали чушь какую, давай пить, за твое здоровье, батя.

Ч ә ч к ә (*Ирекkә*). Рәхмәт сиңа, абый.

Ирек кулын селки.

Р ә ш и д ә. Әти, син чыннан да бәхетле кеше икән.

Х ә к и м. Ник, кызым?

Р ә ш и д ә. Беренчедән, самолетка эләкмәвең белән, икенчедән...

Х ә к и м. Әйе, минем иң олы бәхетем сез, кызым. Шуны белегез, акчада да, дәрәҗәдә дә бәхет була алмый. Бердәнбер юанычым сез каласыз, сез мине искә алырсыз, сез мине хөрмәтләрсез. Сез минем иң зур куанычым, иң зур бәхетем! Бу бокалны сезнең өчен күтәрәсем килә. Кызларым, улларым, сезнең өчен!

Х а ф и з. Ә без?

Г а й ш ә. Әйе...

В а л е р а. А я?

Х ә к и м. Сезнең өчен дә.

Г ө л с е м. Ә минем өчен?
Х ә к и м. Ә синең өчен особо!
Р ә ш и д ә. Рәхмәт, эткәй.
Н о г м а н. Вот әйтте эти.
Г а й ш ә. Безнең эти кебек кеше дөньяда юк.
Х а ф и з. Юк кынамы! Иң олы балык та аңа гына эләгә.
С ә к и н ә. Мәңге яшә, эти!
В а л е р а. Да здравствует 1 Мая! Тфү, батя!
Х ә к и м. Ә сез, Чәчкә, Ирек, кушылмыйсызмыни?
И р е к. Без гел синең белән, эти, беләсең бит.
Г а й ш ә. Кешедән аерылмаса, Ирек Ирек буламы соң инде?..
Х ә к и м. Ярый, сезнең өчен, балалар.
Х а ф и з. Төбенә кадәр. Туганнар, кардәшләр хакы. Мәңге тату яшик!

Эчәләр.

Н о г м а н. Әти булганда, без гел тату булырбыз.
В а л е р а. Одна единая семья, как хорошо, когда все добры и дружны.
Г а й ш ә. Яшәсен безнең тату семья!
Х ә к и м (*бик моңсу*). Бергә җыелып утыру ничек күңелле, эчкә дә җылы кереп китте. Каяле минем гармун?
Х а ф и з. Туй итәбез. Әтинең яңадан туу туе!
Б а р ы с ы  д а. Туй! Туй! Әйдәгез, ишегалдына!
Х ә к и м. Кияү, бер урындык гармонистка.
Х а ф и з. Есть, бер урындык алырга! (*Җырлашып чыгып китәләр.*)

Ирек утырып кала, аның янына Сәкинә килә.

С ә к и н ә. Ни булды сиңа, Ирек?
И р е к. Нигә алай дисең?
С ә к и н ә. Бер дә сөйләшмисең дә...
И р е к. Исердем. (*Кылана.*)
С ә к и н ә. Кыланма инде, ни булды?
И р е к. Берни дә...
С ә к и н ә. Мин сине аңлыйм да кебек.
И р е к. Нәрсә аңлыйсың?
С ә к и н ә. Синең Хафизны ошатмавыңны да, хәтта күрә алмыйсың, нигә?
И р е к. Бар әле, апа, ирең янына чык әле, бие, уйна. (*Пауза.*)
С ә к и н ә. Шулай да?.. Без бит туганнар, болай дошманлашып яшәп булмый бит инде.
И р е к. Кем әле дошманлаша?
С ә к и н ә. Кирегә борма инде, Ирек.
И р е к. Синең барысын да тигезлисең килә инде. Тор-

мышта алай була алмый бит, апа. Син мине дә утырып чыккан, шуңа синең мужигыңны яратмый, дип уйлыйсың. Юк, була бит шундый кешеләр, ничек диим, үзләре тирәсендә түзеп булмаслык авыр атмосфера тудыралар, чыдап булмый. Карале, апа, син аңа нигә кияүгә чыктың?

Сәкинә. Ничек инде, менә кызык, ратканга...

Ирек. Син ярата да беләсеңмени? Бер-берегезне шулкадәр яраткач, нигә сезгә акча?

Сәкинә. Көлмә, мин бит ул ярата, димәдем, мин яратам, дидем. Аннан, үзең беләсең, хәзерге заманда кем акчасыз яши алсын.

Ирек. Менә мин.

Сәкинә. Һе, син ич ул.

Ирек. Мин кеше түгелмени?

Сәкинә. Кеше, әлбәттә, ләкин син ялгыз, бер кайгың да юк.

Ирек. Анысы дөрес... бер... кайгым... да... юк?! Апа, синең ишеткәнең юкмы, Рәмзия кайда микән хәзер?

Сәкинә. Тәки оныта алмадыңмы?

Ирек. Юк, эш анда түгел, бары иң матур чаклар, иң гүзәл мизгелләр искә төшә кайчак. Ахыры ни белән беткәнен дә беләсе килә.

Сәкинә. Син аны озата барган егетне кыйнап утыргач, син кайтканчы, өч тапкыр кияүгә чыккан бугай инде, тагын үзе генә диме. Ул да үзенә урын таба алмый. Яшь чагында кеше ни өчен шулкадәр юләр була икән, әйеме?

Ирек. Бәхетле була чөнки.

Сәкинә. Бәлки. Син хәзер бәхетсезмени?

Ирек. Нәрсә соң ул бәхет?

Сәкинә (*җилкәсен селки*). Кем белә инде аны... Кем балалары белән, кемдер ярату белән, кем эше беләндер инде, кем белә...

Ирек. Әгәр боларның барысы да бергә килсә?

Сәкинә. О, ул чагында ул иң бәхетле кешедер инде. Тик кайда гына яши икән ул андый кеше?

Ирек. Алайса, синнән дә бәхетле кеше юк инде.

Сәкинә. Зарланмыйм, нигә алай дисең?

Ирек. Иреңне яратасың, яраткан эшең бар. Кстати, син бит хәзер эшләмисең дә бугай.

Сәкинә. Ни сөйлисең, нишләп эшләмәсен. Ул депутат эше белән баш каткан. Заводта рәхәт иде. Үз эшеңне беләсең, сигез сәгатеңне эшлисең дә, вәссәлам, ә монда...

Ирек. Ник, ошамыймыни?

Сәкинә. Бик ошый. Зур җаваплылык, зур эшләр башкарабыз!

Ирек. Зур эшләр... Зур трибунадан торып буш сүзләр болгатабыз диген.

Сәкинә. Юк, ялгышасың, зур эшләр эшлибез. Ул безнең эшебез.

Ирек. Шулай укмыни?.. Берсен булса да атап күрсәтегез, пожалуйста, апакай, алай булгач...

Сәкинә. Иронияң юкка... Мәсәлән, теге ни... законнар кабул иттек.

Ирек. Аннан кемгә файда? Менә миңамы? Кайда ул файда, мин күрмим аны, тота алмыйм. Ау?! Кайда син — файда?!

Сәкинә. Нигә үзеңә аласың әле?

Ирек. Мин үз исемемнән сөйләргә яратам. Бу дөньяда һәрбер кеше үзе сөйләгән сүзләргә генә җавап бирә алса иде әле...

Сәкинә. Миңа төрттерүңме?

Ирек. Юк инде. Менә кибетләрдә ашарга ризык юк, аны күрәм, кияргә кием юк, аны да күрәм, сабын, паста, радио-телеаппаратураны санап тормыйм, алар күптән юк — анысын да күрәм. Ә закон чykканга карап үзгәреш булмагач, какой толк?

Сәкинә. Кызык син, тиз генә була торган булса.

Ирек. Ничек инде?! Илнең «иң акыллы» меңләгән кешеләре, бергә җыелып, ярты елдан артык акыл саттыгыз, берни дә үзгәрмәде. Ә юк, ялгышам, үзгәргән икән, тагын да артка киткәнбез.

Сәкинә. Моның белән ни әйтмәкче буласың? Без анда көне-төне тырышабыз, тормыш матур булсын дип, ә алар...

Ирек. Ой, ой, ой! Шуны гына әйтмәкче булам. Димәк, анда акыллы кешеләр җыелмаган. Кулыгызга көрәк тоттырып, барыгызны да бәрәңге казырга җибәргән булсалар, әйбәтрәк булыр иде, файдасы күбрәк... Елмайма, мин үземнең примитив аңлатканымны да аңлыйм. Ләкин сезнең эш практикада шулай чагыла, нишлим...

Сәкинә. Хәзер демократия, шулай да син сүзләреңне чамалабрак сөйлә инде...

Ирек. Оһо, куркыта да башладылар.

Сәкинә. Хәер, ул демократияне дә без бирдек.

Ирек. Нәрсә соң ул демократия? Минем белән бер язучы кисәге утырган иде. Аның сөйләвенә караганда, Байрон исемле инглиз шагыйре булган. Менә ул демократияне «анархия головорезов» дип атаган. Һәм мин аның белән килешәм.

Сәкинә. Ни өчен?

Ирек. Күз алдында ич... Бөтен нәрсә дә бар кебек...

Ирек тә, сөйләргә дә була, бүтәне дә. Шул ук вакытта юк та кебек. Бары да ниндидер рамка эчендә. Ә урамнарда кем ни тели, шуны эшли. Төп-төгәл анархия. Башкисәрләр башка утырып та алсалар, сезнең ярдәм белән.

Сәкинә. Димәк, депутатлар барысы да начар кешеләр.

Ирек. Начар кешеләр димим. Анда кешелекле генә түгел, ә шаккаткыч итеп эш эшли ала торган кешеләр кирәк. Бардыр андыйлар да. Ләкин алар да гомум көтү эчендә калалар.

Сәкинә. Кызык, кызык. Ә син ни эшләр идең?

Ирек. Мин нишлим, мин гади кеше, җитмәсә, тюремщик...

Сәкинә. Ирек, үзеңне алай кимсетмә.

Ирек. Ярар, бетте... Сез бит анда сарык көтүе кебек, беркем дә аерылып чыга алмый. Берәрсе аерыла башласа, «көтүчеләр» хәзер тәртипкә кертәләр. Нәкъ көтүдәге кебек, бар да кычкыра, беркемне дә аңлап булмый. Кемнең дә булса берәүнең сүзен тыңларга кирәктер инде, шулаймы?

Сәкинә. Шулай да булсын ди. Тыңлыйм, тыңлыйм...

Ирек. Бөтен бер көтү берәр җаваплылыкны үз өстенә алса, димәк, аны шәхсән беркем дә алмаган була, беркем дә җавап бирми. Менә ни өчен сезнең законнарның да, сүзләрегезнең дә результаты юк.

Сәкинә. Кара, син ничек фикер йөртәсең. Хәтта минем баш та көчкә эшкәртеп өлгерә.

Ирек. Бик сәерме? Уголовник нинди буй җитмәслек кешеләр хакында сөйләшә, ә?

Сәкинә. Ирек, дим, үзеңне кимсетмә, дип әйттем бит инде. Син кечкенәдән башлы малай идең, ә төрмә... Нишлисең, анысы язмыш эше инде...

Ирек. Сез беләсезме, минемчә, нәрсәне тоя, аңлый алмыйсыз?

Сәкинә. Нәрсәне?

Ирек. Без башта нәрсә икән ул бәхет дип сөйләшә башлаган идек. Хәтерлисеңме?

Сәкинә. Әйе...

Ирек. Син барын да санап чыктың, тик бернәрсәне генә оныттың.

Сәкинә. Нәрсәне?

Ирек. Иң кирәклесен. Иректе. Юк, мине түгел, чын иректе. Минемчә, кеше үзен иректе булганда гына бәхетле итеп тоя ала. Юк, бәхетле үк тә түгел, бәхет әллә нинди сүз ул шунда, ничек диим, үзен кеше итеп, табигать баласы итеп тоя ала.

Сәкинә. Синеңчә, без ирекле түгелмени? Минемчә, без ирекле илдә яшибез.

Ирек. Әйе, без, ияләшкән аңлатмалар буенча исәпләгәндә, үзебезне ирекле итеп саныйбыз, ахыр чиктә, санарга тиешбез, или...

Сәкинә. Нәрсә или?

Ирек. Ну, неважно. Үзең теләгәнчә яши дә алмагач, нинди ирек була инде ул... Димәк, бу чын ирек түгел, безне алдыйлар булып чыга.

Сәкинә. Ә менә синеңчә нәрсә инде ул бәхет?

Ирек. Минемчәме? Минемчә, ялгышмасам, ул — көннәреңне, сәгатьләреңне санап үткәрмәгән һәм бәхет дигән уй бер дә башыңда булмаган чактыр.

Сәкинә. Бик кызык...

Ирек. Ирек дигәннән, чын ирекле кешенең җаны кош кебек рәхәтләнеп очып йөри торгандыр ул...

Сәкинә. Син хыялый...

Ирек. Менә шул шул... Чын ирек турында уйлаган кеше сезгә хыялый, җүләр булып күренә.

Сәкинә. Мин алай димәдем.

Ирек. Күпме шундый хыялыйларны җүләр дип, психбольницаларга яптылар, күпмесен төрмәгә утырттылар. Күпмесе Себердә череде. Күпмесе чит илдә? Бары арканланган «иреккә» шатланган мәхлуклар гына исән калды.

Сәкинә. Минем кебекләрме инде ул?

Ирек. Син дә.

Сәкинә. Шунысы кызык, син миңа шундый сүзләр әйтәсең, ә мин сиңа бер грамм да үпкәләмим, нигә?

Ирек. Чөнки мин чын дөресен генә әйтәм. Менә шул, апа, чын ирек даулаган кешеләрне сез аңлый алмыйсыз. Мин үзем дә аңламый идем, утырып чыккач кына аңлый башладым.

Сәкинә. Менә бит, син дә безнең янга чыккач кына үзеңне ирекле итеп сизгәнсең.

Ирек. Юк, аннан гына түгел, ирекле итеп үзеңне анда да тоярга була. Ничек аңлатырга инде аны... Күңелем ирекле хәзер минем. Ни өчен мин сез акча бүлгәндә кысылмыйм?

Сәкинә. Ни өчен?

Ирек. Чөнки ул өлеш мине ирексезләр иде. Уйлап кара, ни өчен без газиз әтиебезнең акчасы өчен талашырга, ызгышырга тиеш идек?

Сәкинә. Син бит талашмадың.

Ирек. Неважно. Без ул — бергә инде барыбер. Чөнки кеше, саф намус белән генә эшләп, үзенең яшәеше өчен кирәк булган нормальный условиеләрне тудыра алмый.

һәркемнең дә бит әйбәт яшисе килә. Гомер һәркемгә бер генә бирелә. Кеше өчен иң кирәкле әйбер байлык димим. Мин бик укымышлы түгел, төп дөресен белмим, шулай да элеккеге талант иярәренең күпчелегенә финанс турында уйларга да туры килмәгән. Ә хәзерге кеше, беренче чиратта, бигрәк тә бездә, үзен ничек туйдыру турында, яшәтү өчен кайгыртырга тиеш. Аннан соң гына иҗат мәсьәләсен хәл итү планга куела...

Сәкинә. Кызык, бик кызык.

Ирек. Кызык түгел бу, апа, аяныч.

Сәкинә. Юк, синең хакта уйлап әйтүем, әрәм булып йөрисең икән.

Ирек. Көлмә.

Сәкинә. Көлмим, чын күңелдән.

Ирек. Әгәр менә мондый ирләр җитәрлек дәрәҗәдә хезмәт хакы ала алсалар, шул ата акчасы өчен сугышып ятарлар идеме? Ногман абый гына үрсәләнсә инде. Аны аңларга була, ул анда чир инде. Алар бит берсе дә начарлык теләми. Бары тик һәркемнең кешечә яшисе килә.

Сәкинә. Синеңчә күпме тора инде ул кешечә яшәү?

Ирек. Тагын көләсең? Һәркемнең үзенең үлчәве бар. Ә инде бик зур күпчелек хәерче хәлендә яши башлагач... Билгеле инде, нинди рух турында уйлыйсың? Җан саклау турында, тамак турында уйларга вакыт җитсә... Әйе, миңа да акча бик кирәк. Ләкин мин шундый авырлыклар белән тапкан ирек тойгысын югалтасым килми. Ул миңа кадерлерәк. Шулай, апа җаным, финанс ягыннан мескенлек үзебезне дә мескен, булдыксыз итеп калдыра. Халыкның акча эшләргә тырышуы шуннан килеп чыгадыр да...

Пауза.

Сәкинә. Һе, синеңчә, без анда, суелырга тиешле сарыклар шикелле, баш иеп утырабыз, шулаймы?

Ирек. Алай ук димим, шулай да артка шикле караш ташламыйча, алга да атламыйсыз.

Сәкинә. Атлаучылар да бар бит.

Ирек. Билгеле, бардыр, булачак. Ләкин сез аларның башына басып тигезли барачаксыз. Төрмәдәге кешенең өстенлеге нәрсәдә?

Сәкинә. Кем белә инде аны?..

Ирек. Ә-ә-ә, бездә мәктәп белемен бутамаска, Чарльз Дарвин әйтмешли, «Естественный отбор». Әйе, әйе... Кем көчле, акыллы, шул ала. Һәркем үз урынын таба. Сатлык үз урынын, пидираслар үз урынын... Дәүләттә дә ниндидер табигать законнары өскә калкырга тиештер, мөгаен.

Сәкинә. Ничек итеп, ни рәвешле?

Ирек. Ничек итеп? Мин үз фикеремне генә әйтәм. Ни өчен сезнең политикада фахишәлек, пычраклык?! Чөнки кабахәтне сугып очыру түгел, кабахәт дип тә булмый, аны үзе үк чыгарган закон яклый. Шул параша төбендә утырасы сатлык белән петух, өскә үк менеп, закон чыгарып, синең өстеңнән җитәкчелек итә, параша чистарттыра. Противно.

Сәкинә. Естественный отбор булса, сугып очырырлар идеме аларны?

Ирек. Әйтеп бетер, әйе, нәкъ син уйлаганча, сезнеңчә бюрократлар, ә безнеңчә... әлбәттә, алай булганда, алар иләк аша үтәр иделәр. Югары үрмәләргә дә куркырлар иде. Менгән очракта да, чамалап сикерерләр иде. Минем уйлавымча, властька менгән начар кешегә властьның бөтен начар ягы даябыша, алар үрелеп үсеп, тагын да көчәя. Дәүләт тә, милләт тә изге түгел дөньяда — ә кеше! Шушы формулировкада алга куелганда гына дөрескә якын дәүләт килеп чыга аладыр.

Сәкинә. Син бик гади генә, җайлы гына хәл итәсең. Ә бит анда алай җиңел түгел, бик болганчык.

Ирек. Юк инде, апа, нинди хәл итү, гади, кытыршы үз уйларым гына.

Сәкинә. Ничек итеп кертергә соң ул табигать законнарын?

Ирек. Анысын сез уйлагыз инде. Һич югында, һәр халыкка ирек бирүдән башлап карагыз.

Сәкинә. Ничек?

Ирек. Ну, һәр халык үз язмышын үзе хәл итәрлек булсын.

Сәкинә. Бутама. Бездә бар халыклар да ирекле, тату.

Ирек. Ирекле... Алай булгач, без нигә, халык теләге була торып, аерым республика ясый алмыйбыз? Ирекле халык булгач, нигә без аны Мәскәүдән ялына-ялына сорарга тиеш? Нигә без үзебез теләгәнчә яши алмыйбыз? Ә бит теләгебез бар, бик бар.

Сәкинә. Йә, йә, ярсыма. Менә син ничек китереп чыгардың. Сорамый гына булмый. Без Россия белән ничә гасырлар буе кулга-кул тотышып...

Ирек. Әй, ташлале, шул... Аңлаттым, аңлаттым. Ничә гасырлар изелеп яшәдек, диген.

Сәкинә. Ирек, син ни сөйлисең, минем алда, җитмәсә?

Ирек. Юк, син төзәлерлек түгел икән.

Сәкинә. Карале, кара...

Ирек. Карале, апа, сине ялгыш депутат итеп сайла-

мадылар микән? Син анда, һич югы, безгә статус кирәк, дип әйтә алдыңмы, пышылдап булса да?..

Сәкинә. Әйтә алдыңмы, дип, ни... Анда чират җитми.

Ирек. Чират җитми? Күз алдына китер, нинди бай без яшәгән җир. Идел, Кама һәм башкалар... Күпме урманнар, нефть, газ. Әле болары ярылып ятканы гына. Шушы байлыкларның күпмесе безнең халыкка хезмәт күрсәтә алмыйча бушка китте, ә бит болар барысы да безнең халыкның борынгыдан килгән байлыгы. Россиянең бер катнашы да юк анда. Ә иң куркынычы: тел югалу, милләтнең бетүгә баруы түгелме? Статусны без сорап торырга тиеш тә түгел, үзебез урнаштырырга тиеш. Нишлисең бит, халык әле аны аңлап бетермәгән чорда сорап йөрергә туры килә. 1552 елда бабалар үз ирке белән бирелмәгән кебек, безгә дә ирекле рәвештә ирек бирмәсләр.

Сәкинә. Бирмәсәләр, моңарчы яшәгән, миңа анын бернигә дә кирәге юк.

Ирек. Менә ничек! Шул сорау өчен дә көрәшмәгәч, нәрсәгә соң син халыкка? Болай да, депутатлар ярдәменнән башка да юкка чыгарбыз. Аның өчен тырышучылар синнән башка да җитәрлек.

Сәкинә. Менә нәрсә, энем. Син мине сайламадың, сиңа тикшерергә дә түгел. Үз сүземдә калам, руслар яхшы халык.

Ирек. Ярый, ярый, кызма. Мин дә аларны хурламыйм, киресенчә. Тегендә минем дустым рус иде.

Сәкинә. Шулай булгач...

Ирек. Без үзебез горур, ирекле халык булып яши алсак, аларны тагын да ныграк хөрмәт итәр идек. Изелүче халык булып түгел, ә тату күршеләр булып. Йөрәк әрни, гомер уза, ә берни дә эшләп булмый.

Сәкинә. Да, брат, мин сине бөтенләй белмәгәнмен икән.

Ирек. Менә шундый әшәке кеше инде мин...

Сәкинә. Ирек, син нигә университетыңда укуыңны дәвам итәргә уйламадың?

Ирек. Утырып кайткачмы? Беренчедән, алмаслар иде, икенчедән, мин үземә кирәкне алдым бугай инде. Аннан «Научный коммунизм»ны яттан беләм! (*Бармаклары белән рәшәткә ясап күрсәтә.*)

Сәкинә. Көлмә, юк, син уйла әле ул турыда.

Хәким керә.

Хәким. Ә-ә-ә, менә кая качканнар, сезгә штраф.

Ирек. Качмадык, әти, сөйләшеп утырдык.

Хәким. Ни турында?

Ирек. Шул, синең байлыкны бүлешә алмыйбыз.
Сәкинә. Шаяра ул, әти.
Хәким. Шаярма, син андый малай түгел.
Ирек. Урлап кына китәргә оста дисеңме?
Хәким. Юк, улым, алай уйламыйм. Сәкинә, бар, әниеңне чакыр әле. Бире керсен.
Сәкинә. Хәзер, әти. (*Чыга.*)
Ирек. Син нигә күңелсез, әткәй? Шатлан, бәйрәм бит бүген, икенче тапкыр тудың?
Хәким. Анысы дөрес, улым. Бәхетле булырга, шатланырга тиеш идем мин. Әмма шатланасы килми.
Ирек. Син нәрсә инде, әти, булды инде, булды...
Хәким. Менә монда, эчтә, нидер әйләнгән кебек булды...
Ирек. Борчылма, әти. Син бераз исереп киткәнсең...
Хәким. Юк, улым, мин исерек түгел. Күзләр кысылса да, акыл саф... Тыңла әле син мине, бүтән сөйләшер кеше дә юк бит.
Ирек. Сөйлә, әти, сөйлә.
Хәким. Менә шулай, бөтен күңелем, акылым алмашкандай булды. Уйлап куйдым, ни өчен гомерем буе акча җыйдым мин, нигә бөтен гомеремне шуңа багышладым?
Ирек. Ник, дип...
Хәким. Тукта, улым, бүлдермә, фикеремне чуалтасың. Карт кешенең фикере тиз чуала.
Ирек. Нинди картаю ди әле ул...
Хәким. Юк, улым, соңгы ике көндә мин бик нык картайдым. Күңелем нindидер афәт сизгән шикелле. Шуңа сөйләшеп каласым килә.
Ирек. Юк-барны уйлама, тыңлыйм, әти.
Хәким. Шулай менә. Гомерем буе акчага чукындым. Урлый алганда, урладым, алдардаен алдадым — җыйдым да җыйдым. Элек ул миңа нindидер ләззәт, рәхәтлек бирә иде. Ә бу самолет белән булган вакыйгадан соң, косасым килә...
Ирек. Син тынычлан әле, әти...
Хәким. Юк, улым, син тынычландырма мине. Сиңа мин шуңа күрә дә сөйлим, син ирләрчә мине тыңлый аласың — һәм шундый булып кал да...
Ирек. Ярый, әти.
Хәким. Борылып карасам, гомер бушка үткән, артта берни дә калмый. Ә бит мин заманында булдыклы бала идем. Гармуным бар иде минем, теләсә нинди көйне бер ишетүдә уйный идем, сәхнәдән төшмәдем. Белгечләр ничек ди әле, теге, ә... әйе, слухың әйбәт, киләчәгең өметле, диләр иде. Ә чынында менә ничек килеп чыкты. Хәер,

бала чакта ук акча җыярга ярата идем. Шулай шул, чирне вакытында дәваламасаң, аза икән. Кем инде мин хәзер, нәрсәгә ирештем?

Ирек. Чынын әйткәндә, эти, әйе, акча да бик кирәк. Ләкин син акча артыннан куып, безне күп вакыт күрми дә идең. Шулай да борчылма, эти, синең горурланырлыгың бар. Без бар ич, эти.

Хәким. Рәхмәт, улым, яхшы сүзеңә. Сиңа ышанам, ә тагын? Мин үлмәс борын, минем тиеннәремне бүлешүче балаларым? Дөрес, анысы,— ни чәчсәң, шуны урырсың, ди.

Ирек. Юк, эти, барыбыз да бүлешмибез ич. Син ачуланма, эти. Без, чыннан да, сине искә алырга җыенган идек.

Хәким. Ник ачуланыйм, сез гаепле түгел ич.

Гөлсем керә. Аның артыннан Хафизның көлгәне ишетелеп кала.

Гөлсем. Уф Аллам, биетеп үтерә яздылар. Абау, сез нигә бик болытлы. Тышта да яңгыр җыена бугай.

Хәким. Ярый, улым, син ял ит, бар.

Ирек. Юк, эти, мин китәрмен инде.

Гөлсем. Юк, юк, нинди китү, атаң исән-сау әйләнеп кайткан.

Хәким. Шаулама әле, хатын.

Гөлсем. Шаулама... Синең өчен тырышам.

Хәким. Моңарчы тырышканнарың да бик җиткән.

Ирек. Ярый, мин китим, бер ашыгыч эш бар иде, сау булыгыз.

Хәким. Сау бул, улым.

Ирек китә.

Гөлсем. Озакка югалма. Нәрсәгә чакырдың?

Хәким. Утыр әле яныма.

Гөлсем. Миңа монда да әйбәт.

Хәким. Йә, ничек соң, әнисе, күңеллеме?

Гөлсем. Нигә алай дисең?

Хәким. Тыштан көлсәң дә, эчтән яна кебек...

Гөлсем. Менә әйттең, нигә яныйм ди мин...

Хәким. Ярый, үпкәләмә. Мин үлгәч, ни эшләргә иде инде синең исәп?

Гөлсем. Әй, юк сүз сөйләп утырма әле. Исән-сау ич син! (*Кочаклый.*) Рәхәтләнеп яшибез әле, Алла боерса.

Хәким. Тукта әле, соңыннан. Әйт әле менә яшермичә. Син нигә миңа кияүгә чыктың?

Гөлсем (*аның яныннан тайпылып*). Син нәрсә?! Артыграк эчеп ташладыңмы карт башың белән? Ни сөйлисең?

Х ә к и м. Юк, мин аек, карчык...

Г ө л с е м. Нинди карчык булыйм ди мин сиңа.

Х ә к и м. Гөлсем, ачыктан-ачык сөйләшик әле. Курыкма, мин сине гаепләргә җыенмыйм. Әллә ничек шунда, күңел тыныч түгел.

Г ө л с е м. Күбрәк эч...

Х ә к и м. Син нигә миңа кияүгә чыктың?!

Г ө л с е м. Нигә дип, ошаткан булганмындыр инде. Кыяфәтең дә яшь иде ул чакта. Мин дә аерылып кайткан хатын идем. Аннан, барыбер бер чыгасы бар иде бит.

Х ә к и м. Яратмадыңмы?

Г ө л с е м. Шаярма инде, бу яшьтә нинди ярату ди.

Х ә к и м (*кычкырып*). Менә нәрсә! Җитте! Минем синең белән мәчеле-тычканлы уйнарга вакытым да, теләгем дә юк. Яраттым мин сине, шайтан хатынын. Хәзер дә...

Г ө л с е м. Яратсаң соң! Кычкырма миңа. Синнән курыккан туннар тузган! Әйе! Әйе! Әйе! Бай булганга чыктым, рәхәт яшисем килде. Яшәдем...

Х ә к и м. Рәхәт яшисең килгәнгә гуляйть иттеңме?

Г ө л с е м. Менә нәрсә, карт пәри, анда синең эшең булмасын. Менә үзеңнән егерме бер яшькә карт убырга өйләнеп кара, нишләр идең икән? Алай гына гуляйть итәр идең микән? Кая соң рәтең? Әйдә, киттек алайса! Әйдә дим! Ник бармыйсың?

Х ә к и м. Кит әле дим, җибәр, авырттырасың.

Г ө л с е м. Ә-ә-ә, булмыймыни? Ә мин нишлим? Болай да алма кебек яшь чагым әрәмгә узды, син карт җен белән...

Х ә к и м. Әле дә соң түгел, бик ясангансың...

Г ө л с е м. Ясандым шул, бәлки, берәр киявем карап куяр. Алар бит миннән дүрт-биш яшькә генә яшь. Җитмәсә, балаларың да минеке түгел, Чәчкәдән кала. Чукынышып китсеннәр.

Х ә к и м. Җитте, кабахәт, үтерәм!

Г ө л с е м. Үтерермен мин сиңа, өзеп алырмын. Никләр генә кайткансыңдыр инде, башым котылды гына дигәндә, акаеп кайтып кердең бит... Йа Ходаем, (*елап*) никләр тилмертәсең бу бичара хатынны?..

Х ә к и м. Каргамасаң да үләрмен, борчылма.

Г ө л с е м. Кат шунда, сәдака бирер идем.

Х ә к и м. Оятсыз ук икәнсең. Үз башыңа килмәсен. (*Чыгып китә.*)

Г ө л с е м. Бар, бар, эзлә әҗәлеңне. (*Капланып елый.*) Әй Аллам.

Җырлый-җырлый Х а ф и з килеп керә.

Х а ф и з. Әссәламәгаләйкем! (*Гөлсем дәшми.*) Ишет-

миләрме, әллә ишетергә теләмиләрме закон әһелен... (*Гөлсем дәшми.*) Әллә йоклый инде.

Гөлсем. Юк, йокламыйм.

Хафиз. Елыйсыз, ни булды?

Гөлсем. Юк, берни дә...

Хафиз. Ничек инде, тик торганда елыйсың алайса... Әйтегез генә, мин ул шакалны... Ирекме?

Гөлсем. Юк, юк, ни сөйлисең?

Хафиз. Белмичә минем күңелем тынычланмаячак.

Гөлсем. Болай гына, Хәким белән үзебез.

Хафиз. Хәким абзый? Ул куркуль әле кул күтәрә башладымы минем каенанага... Түзеп-түзеп торырмын да... Кара син аны...

Гөлсем. Кирәкми, зинһар өчен, тавыш чыгара күрмәгез.

Хафиз. Ярар, ярар, каенанам.

Гөлсем. Хафиз, шул каенана сүзен әйтмә әле, әллә ничек.

Хафиз. Ник, әби, дииммени?

Гөлсем. Анысын бигрәк тә. Мин бит синнән нибары берничә яшькә генә өлкән.

Хафиз. Ай, гафу итегез, мин иярәшкән буенча инде, сарык диген.

Гөлсем. Гади генә, Гөлсем апа, диген.

Хафиз. Гөлсем, һе, иярәнмәгән, әллә ничек. Ә шулай да бик ягымлы килеп чыга. (*Колагына нидер әйтә.*)

Чәчкә килеп керә. Аптырап катып кала.

Чәчкә. Мам!

Гөлсем. Әй, оятсыз. (*Хафизның аркасына җиңелчә сугып.*) Исерек.

Чәчкә. Мам, анда сине сорыйлар.

Гөлсем. Нәрсә кирәк булган тагын, чәнчелгерләргә. (*Чыгып китә.*)

Чәчкә бүлмәсенә узмакчы була, Хафиз туктата.

Чәчкә. Ты чего?

Хафиз. Оныттыңмыни?

Чәчкә. Нәрсәне?

Хафиз. Чәчкә! Сөйләшкән идек бит инде. Мин сине бик күптәннән яратып йөрим. Синсез яши алмыйм. Әйдә, монда, мин сине бик...

Чәчкә аның кулын тешли, Хафиз аны ычкындырып җибәрә. Чәчкә елый.

Син! Тварь! Чего захотел! (*Өстәлдәге пычакны алып.*) Кит моннан, зараза, үтерәм хәзер!

Хафиз. Чү, чү, син нәрсә, китәм!

Чәчкә. Ычкын, мент калдыгы! Все вы твари! Ничек котылырга сездән, кая качарга, куда провалиться? Чәнчелимме соң әллә?!

Хафиз аның пычагын бәреп төшерә. Чәчкә капланып елый. Рәшидә керә.

Хафиз. Син нәрсә, мин шаярдым гына, үзе әйтте дә... Мин нәрсә... Мин болай гына...

Рәшидә. Чәчкә, ни булды?

Чәчкә. Ничек яшәргә инде бу дөньяда, Рәшидә апа?! Берсенә акча надо, одному хатын-кыз, другим еще что-то!.. Неужели просто гына, тынычлап кына яши алмам микәнни?

Рәшидә. Тынычлан, акыллым, тынычлан. Син әле яшь, бары да яхшы булыр. Синең әле киләчәгең алда... Менә укырсың...

Чәчкә. Что син, апа. Нинди алда, нәрсә алда? Минем менә шушы яшьтән уже жить не хочется, ә син әйтәсең...

Рәшидә. Үтә ул, сеңлем, тынычлан.

Чәчкә. Үтә! А мин не хочу үткәрергә! Үткәч, менә сезнең кебек бөтен нәрсәгә битараф калгач, нәрсәгә яшәп торырга?! Ә бәлки, апа, наши предки яшәгәннәр бесмысленной жизнью? Бәлки, шуңа күрә безнең тормышның да мәгънәсе юктыр? Бәлки, без дә обреченные люди?

Рәшидә. Кем белә инде, сеңлем. Шулай да ныграк бул, яшәргә кирәк. Бу тормышның пычраклыклары күп очрар әле.

Чәчкә. Ни өчен?

Рәшидә. Нәрсә ни өчен?

Чәчкә. Яшәргә кирәк?

Рәшидә. Турысын гына әйткәндә, үзең ана булганчы, ашыкма, сеңлем. Үзеңнең балаң, буының барлыкка килгәч, үзеннән-үзе тормышка омтылыш уяна ул, алар өчен яшисе килә. Йә, йә, булды... Акыллы булырга сүз бирәсеңме?

Чәчкә. Ладно... Попробуем.

Көчәя башлаган гармун тавышы.

Апа, ведь нет бернинди надежда да алга таба. Такая тоска. Не знаю ничек яшәргә? Бернәрсә дә не хочется, уйлыйсы килми. Беләм, мин үзем дә бик гаепле... Ләкин бит я хочу, чтоб яхшырак булсын, а не получается. Шагаю, ә алда әйтерсең бездна... упкын...

Р ә ш и д ә. Тынычлан, сеңлем, кая, бер елмай әле. Елмай инде, менә шулай. Ә без синең белән соңыннан сөйләшербез. Бар, бераз йөреп кер, бар, сеңлем.

Хәкимне Хафиз белән Валера җилкәләренә утыртып, самолет тавышы чыгарып үкереп керәләр. Хәким гармун тарта. Көлү, шау-шу.

Х ә к и м. Чү, кияүләр, төшереп җибәрә күрмәгез. Ватарсыз карт савытны. Сезнең самолет куркынычрак икән.

Н о г м а н. Куегыз инде этине, тәрбиясезләр.

Х а ф и з. Курыкма, каенагай, бер төшүдән берни булмас.

В а л е р а. Если мы бросим, так повыше, с высоты.

Көләләр. Хәкимне утырталар.

С ә к и н ә. Тәртип белән, культурно гына, җәмәгать! Вәт, эти, үзеңне күтәреп кенә йөртәләр!

Х ә к и м. Әйтмә инде, кызым. Аллага шөкер, уңдым кияүләрдән.

Г а й ш ә. Ә киленнәрдән уңмадыңмыни, эткәй?

Х ә к и м. Сине, килен, әйтеп тә тормыйм инде, чәчрәп торасың. (*Хафиз көлә.*)

Г а й ш ә. Ник көләсең? Уңган хатын чәчрәп торырга тиеш инде ул. Әйеме, эткәй?

Х ә к и м. Нәкъ үзе, килен!

Н о г м а н. Эти, әгәр берәр нәрсә эшләтәсегез булса, миңа гына әйт. Сүз белән ул кияүләр барысы да бик яхшы. Менә эшләп күрсәтегез сез. Эти безнең кооператив, ни кирәк, шуны эшли.

Х ә к и м. Алайса, улым, мин үлгән булсам, табут та ясаткан булыр идеңме?

Н о г м а н. Әй, эти, айн момент. Без аны хәзер эшләп атабыз.

Х ә к и м. Үл генә диген, ә?

Н о г м а н. Юк инде, эти. Просто шулай килеп чыкса, дим. Син әле озак яшәрсең.

Г ө л с е м. Тагын үзенекен башлады инде. Туймадыңмыни әле? Үләсе кеше кешегә әйтеп тормый ул...

Х а ф и з. Син, Ногман, этине күмеп тә куйдың инде, ә, өлгер...

В а л е р а. Да, шустрый какой...

Г а й ш ә. Берегез дә артык түгел, боргаланмагыз. Карале, эткәй, нигәдер тамак кибеп китте, бии-бииме шунда...

Х ә к и м. Чыннан да, кардәшләр, без ник болай утырабыз соң әле? Мин исән, мин үлмәм! Кияү, давай, буш тотма бокалларны! Ягез әле, салыйк әле туганнарның туганлыгы өчен!

Г а й ш ә. Ничек инде?

Х ә к и м. Ничекме? Менә бер-берегезне якын итеп, бер-берегездән берни дә жәлләмичә яшәү өчен.

Г а й ш ә. Әй, алай яшәп булмыйдыр ул.

Х ә к и м. Нигә булмасын, теләк булсын.

Н о г м а н. Алай яшәү өчен һәркемнең бай булуы кирәк.

Р ә ш и д ә. Ә синеңчә нәрсә соң ул байлык?

Г а й ш ә. Хе-хе-хе... (*Көлә.*) Белми... Нәрсә булсын ди инде байлык. Акча, билгеле... Акчаң булса, бар да була.

Н о г м а н. Кәнишне.

Х а ф и з. Бик дөрес.

В а л е р а. Но ведь «Волгу» можно и украсть.

С ә к и н ә. Аңа китсә, акчаны да урлап була.

Х а ф и з. Һе, андый байлык өчен Уголовный кодексның бик әйбәт статьялары бар. (*Бармакларын рәшәткәләп күрсәтә.*) Әнә Иректән сорагыз.

Р ә ш и д ә. Ә Ирек кайда соң әле?

Г ө л с е м. Китте ул.

Х ә к и м. Эше килеп чыкты аның.

Х а ф и з. Эше... Күрә алмый ул безне, шуңа китте. Нигә күрә алмый, аңламыйм. Без бит аңа яхшылык кына телибез.

Ч ә ч к ә. Не трожьте абыйны! Сезнең эшегез түгел...

Р ә ш и д ә. Йә, йә, сеңлем. Чыннан да, кагылмагыз аңа. Ул болай да...

Г а й ш ә. Мескен. Үзе гаепле.

Х ә к и м. Җитте, килен! Синең башың җитәрлек эш түгел бу. Әйдәгез, нәрсәгә тукталдык? Ә, әйе, туганнарның туганлыгы өчен.

С ә к и н ә. Шулай итеп, акча дип исәплибез инде байлыкны...

Н о г м а н. Соң, нәрсә кабат сорап торасың. Вәт кызык, тагын нәрсә булсын инде байлык?

С ә к и н ә. Ә син нәрсә әйтмәкче идең, Рәшидә?

Р ә ш и д ә. Әйе, акчасыз яшәве кыен.

Г а й ш ә. Кыен гына түгел, үлем...

Р ә ш и д ә. Кем акча белән бай, кем җаны белән, кем балалары белән. Рух дигән әйбер, рухи байлык та бар бит әле.

Г а й ш ә. Хе-хе-хе... Бар, чыгарып сатып кара син ул байлыгыңны базарга, кем сукыр тиен бирер икән...

Х а ф и з. Көлкегә калдырып йә типкәләп ташламасалар ярар.

В а л е р а. Что-то ты не ту тему завела, жена.

С ә к и н ә. Культура кирәк, җәмәгать.

Рәшидә. Бөтен кеше дә акча гына җыеп ятмый бит. Менә безнең отделениедә бер карт ятты. Ак сакаллы, чәче дә кардай ак. Ә күзләре чем-кара. Эчендә ниндидер аңлап бетермәслек сагыш, моң. Үзләре шундый бәхетле ялтырыйлар. Ә бит ул үзенең озакламый үләсен белеп, сизеп ятты. Кемнәр генә килми иде аның янына — балалары, оныклары, туганнары, кияү-киленнәре, әллә кайчан бергә эшләгән кешеләр, шәкертләре, тагын әллә кемнәр. Санап бетерерлек түгел. Көн дә киләсе кешеләргә исемлек төзергә туры килә башлады. Режим керттек. Югыйсә картны алҗытып бетерәләр. Юк, ул үзе тыштан берни дә күрсәтми. Киресенчә, һәркемне күргән саен талпынып, канатланып китә. Минемчә, ул бик бәхетле кеше иде. Үлгәндә дә елмаеп үлде.

Гайшә. Һе, аңа калса, безнең эти иң бай, иң бәхетле кеше. Әнә күпме акчасы, күпме балалары, җаны да үз урынында.

Хафиз. Чыннан да шулай бит, әй.

Валера. Сказал же я вам, что он Христос.

Гайшә. Бутама, керәшен түгел, мөселман ул.

Хәким. Карале, кызым, кем булып эшләгән ул?

Рәшидә. Музыкант шикелле...

Хәким. Музыкант? Исемен белмисеңме?

Рәшидә. Заһид абый бугай.

Хәким. Заһид, Заһид... Юк, белмим шул, белмим. Завскладларны, директор урынбасарларын, спекулянтларны беләм, хәтта замминистр торговлины да. Ә аны белмим, кызганыч...

Гайшә. Нәрсәсен кызганырга, әткәй. Ул инде картаеп киткән, беткән. Ә без әле синең белән яшь, бергәләп дөньясын дер селкетеп яшәрбез.

Хәким. Сүз ул турыда түгел шул, килен.

Гайшә. Син пешмәгән духтыр, әллә ниләр бутап, этине борчыма, яме. Матур гына утырганда...

Хәким. Рәшидә кызым дөрес әйтә, акча белән генә яшәп булмый.

Ногман. Шулайдыр анысы, эти. Үзең дә бит шактый туплагансың. Аны ничек аңларга?

Хәким. Шуңа күрә мин артык куанмыйм да. Элек булдырам дип яши идем, ә хәзер...

Хафиз. Сез нәрсә инде, бала-чагалар кебек? Эти шаяра гына. Ә сез авызыгызны ачып тыңлыйсыз! Тост!

Ногман. Әйе, җәмәгать, Хафиз дөрес әйтә, нигә болай утырабыз әле, эти, тот бокалларны.

Хәким. Туктале, хәзер, балалар. Минемчә, сезгә бөтен булганыгызны берләштереп яшәргә кирәк.

Г ө л с е м. Менә әйттем бит мин сезгә.

Х ә к и м. Туктале, хатын, Рәшидә әйткәнне дә, акча мәсьәләсендә дә, бүтәнне дә. Кем нәрсәгә мохтаҗ, шуны ала алсын.

Х а ф и з. Нәрсә хәзер, Рәшидәнең күңеле бай, акчасы да юк дип, акча җыеп бирикме, хе-хе-хе!.. Бик кызык әле бу.

Г а й ш ә. Менә сиңа йомыкый Рәшидә?! Вәт бирде бу! Шыпырт кына утырды да, барын да үзенә җыеп алды. Вәт маладис!

Х ә к и м. Аңа гына түгел, барыгызга да. Аңа, мәсәлән, күпмедер процентта финанс белән, ә сиңа җан азыгы, бүтәнгә...

Г а й ш ә. Туктале, әткәй, син мине җансыз димәкче буласыңмы? Без акчабызга җан сатып алырга тиешме? То есть, әй юк ла, сатып ала алмыйбыз, кәнишне, безнең бит акча юк.

Х ә к и м. Юк инде, алай димим. Бары бөтен булганыгыз белән уртаклашып, ярдәмләшеп яшәгез. Чын кардәшләр булып. Соңыннан соң була ул.

Х а ф и з. Син соңардыңмыни?

Х ә к и м. Соңардым шул...

В а л е р а. И твои сбережения тоже сюда, и «Волгу»?

Х ә к и м. Әй балалар, сбережениеда гына мыни хикмәт?

Н о г м а н. Шулай да кирәкме?

Х ә к и м. Керер, ник кермәсен.

Г ө л с е м. Атагызга һәм аның хезмәтенә кагылмагыз! Тынычлыкта калдырыгыз олы кешене. Оялмыйлар да...

Г а й ш ә. Хезмәте... Үзеңә потламакчы буласың барысын да?

С ә к и н ә. Гайшә! Әни! Тәртип кирәк, культура! Консенсус...

Г ө л с е м. Соң, кызым, атагыз исән бит әле, тагын бүлешә башладыгыз.

Г а й ш ә. Ачка үлә күрмәгез тагын. Мескеннәр.

Х а ф и з. Менә нәрсә, әти дөрес сүз башлады. Тигезләргә кирәк дөньяны. Мәгәр әгәр дә мин теләгәнне ала алсам, бер дигән дөнья корып җибәрер идем. Кызың да бәхетле булыр иде.

Х ә к и м. Күпме инде ул, сине бәхетле итә торган сумма?

Х а ф и з. Күп түгел, шул бер 40 мең җитә безгә.

В а л е р а. Охо!..

Г а й ш ә. Син нәрсә? Ычкына башладың мәллә? Безне коры калдырмакчы буласыңмы?

С ә к и н ә. Җәмәгать, шауламагыз, тәртип...

Н о г м а н. Туганнар, сөйләшкән идек бит, 50 мең ча-

масы алсам, мин аны эшкә кертәм, ул безгә файда китерәчәк, дип. Шулай хәл итик әле без.

Хафиз. Син, «кооп», бик остарма әле, яме? 50 мең бирсәгез, имеш. 50 мең кулга керсә, мин аны үзем дә бик һәйбәтләп эшкә кертәм.

Гайшә. Син нәрсә Ногманның бугазын буасың? Нигә дип эти сиңа кырык мең бирергә тиеш әле, милиция булганың өченме?

Хафиз. Шуның өчен булса да... Менә монда кычкырышып, эчеп, бәйрәм итеп утырасыз, ә кем сезнең тынычлыгыгызны саклый? Кем сезне хулиганнардан яклап кала? Кем сезнең өчен гомерен дә җәлләми?

Валера. Не смеши, Хафиз. Будь мужиком, все знают, как вы защищаете...

Хафиз. Син кагыласы булма...

Ногман. Кай арада кырык меңгә күтәрелде әле ул?

Хафиз. Нәрсә, сиңа ярый, безгә ярамый? Сез болай да бай...

Валера. Про другое не знаю. Батя, как с «Волгой» поступишь? Не забудь, я твой главный механик.

Хәким. Туктагыз әле, балалар, мин исән бит әле.

Гөлсем. Ояла да белмисез инде, атагыз сезнең өчен үлеп тора.

Хафиз. Ничек? Бу синең, чыннан да, шаяру гына булдымыни?

Гайшә. Безне шул хәерчелектә калдырасыңмы?

Валера. Как же я без «Волги» проживу, не представляю.

Рәшидә. Шашмагыз инде, исерешеп беттегез.

Сәкинә. Юк, эти, син дөреслек белән бар, тигез итеп бүл дә бир. Тавыш та чыкмас. Дөрес булыр.

Гөлсем. Нишлисез, балалар? Атагызны көпә-көндез талыйсыз түгелме?

Гайшә. Юк инде, әни, син үзең башлап җибәрдең дә, хәзер без гаеплеме? Эткә сөяк күрсәтмәскә иде аны, хәзер тыеп кара әнә.

Сәкинә. Тәртип, җәмәгать, культурно гына...

Ногман. Туктагыз әле, туганнар. Менә мин нәрсә тәкъдим итәм: әйдәгез, тынычлану өчен берәр чәркә күтәреп, капкалап алыйк, аннан барын да аек акыл белән хәл итәрбез.

Рәшидә. Ногман, нишлисез, болай да исерешкәнсез бит инде.

Валера. Жена, молчи.

Хафиз. Ярый, көтеп карыйк.

Ногман. Менә бу юлы кадерле әтиебезнең акылы, зирәклеге өчен эчәсем килә.

Г а й ш ә. Әйтәсе юк. Әбзәтелни әти өчен!

Х ә к и м. Рәхмәт, улым. (*Эчәләр.*) Ләкин хәзер күпме генә сөйләсәгез дә, бер тиен дә ала алмассыз.

Г ө л с е м. Дөрес, этисе.

Х ә к и м. Кысылма, сихерче! Сиңа да эләкмәячәк. Барыгыз да минем алда акча өчен генә юхаланасыз.

С ә к и н ә. Әти, син ни сөйлисең, тынычлан.

Х ә к и м. Юк, тынычландырма мине, мин үлде дигәч, ничек куанганыгызны аңлыйм мин хәзер...

Г ө л с е м. Син исерден, атасы.

Х ә к и м. Ю-у-ук-ук! Мин исерек түгел! Киресенчә, айнып киттем. Ә син (*Гөлсемгә*), миннән котылгач, рәхәтләнеп типтереп яшәмәкче идеңме? Кияүләреңнең берәрсен эләктерергә дә не прочь. Мә, тот!

Г ө л с е м. Кит, оятсыз! Ни сөйлисең, балалардан оял!

Х а ф и з. Ә кияүләргә ни булган, ә? Бар яктан килгән.

С ә к и н ә. Хафиз!

Х а ф и з. Менә нәрсә, папаша! Юләрләнмә, үзеңә дә тими ул акча, безгә дә...

Х ә к и м. Һәм тимәс тә, яндырам.

Г ө л с е м. Котырган!..

Н о г м а н. Туктале, әти, нигә бирмәскә булдың инде?

Х ә к и м. Чөнки сез барыгыз да — ничтожество! Булдыксызлар сез, юк сез, юк! Нуль! Сез, берегездән-берегез таза ирләр, шул хәерче берничә меңгә карап талаша башладыгыз. Тфү! Мин үз гомеремдә, аз гына булса да, эшләп кала алганмын. Ә сез аны да булдыра алмыйсыз. Үзегезне муллыкта яшәтә торган итеп эшләр әйләндерә белсәгез, мин чәчәр идем ул акчаларны сезгә. Сез булдыра алмыйсыз. Ә фактически сез үзегез җир җимертеп таба алырга тиеш. Булмагач, тамагың да ач! Һәркем үзенә тиешлене ала инде. Сезгә тиешлесе шул — хәерчелек. Хе-хе-хе!..

Х а ф и з. Ул безне мыскыл итә!

В а л е р а. Әй мужик!

Х ә к и м. Әйе, мужик! Әйе, көләм... Чөнки сез көлке, мескен хәлдә. Үзегез гаепле. Кайсыгыз ул акчадан файда эшләр иде? Кайсыгыз берәр мохтаҗ кешегә ярдәм итмәкче булды? Берегез дә! Ә син, Рәшидә кызым! Бөтенләй баш тарттың! Иң ансаты ул — баш тарту! Ач корсагыңны сыйпап яту.

Н о г м а н. Әти, мин әйттем бит, файдалы эшкә кертәм, дип.

Г а й ш ә. Әйе, эткәй. Ногман бик файдалы эш эшләмәкче иде.

Х ә к и м. Беләм мин синең файдалы эшеңне. Кесәңне

калынайтырга да бикләнеп, башкаларга төкереп яшәргә, шиш!

Хафиз. Ярдәмгә мохтаҗлар турында уйларга? Үзебезнең хакта кем уйлар?

Гайшә. Бу кадәр кире булырсың икән.

Хәким. Барыбер юкка чыгарам.

Сәкинә. Әти, нигә алай итәргә? Тигезләп бүләргә дә бетте китте...

Хәким. Тигезләп... Соң, әзрәк уйлап карагыз. Булмый аның белән генә бәхетле яшәп, булмый. Кеше хакы барыбер бер килеп чыгачак. Моны мин әйтәм, мин беләм. Киресенчә, йөрәкне генә май баса. Рәшидә әйткән кеше хакында уйлагыз, гомерегез бушка уза бит.

Хафиз. Син безгә ничек яшәргә икәнен өйрәтмә. Акчаңны тарат та, калганын без үзебез белербез.

Гайшә. Әйе, акыл сатарга мин үзем дә мәчтер.

Хәким. Китегез, күз алдымнан югалыгыз!

Хафиз. Нәрсә?! Миңа кычкырасың? Ярый, аңламадың. Хәзер дусларны чакырып...

Хәким. Шунсыз булдыра алмассыңмы? Үз кулың белән буа алмыйсың. Куркак шул син!

Сәкинә. Тәртип, җәмәгать! Хафиз, нишлисең инде?

Хафиз. Атаңны тый әнә, үз кызыннан барлы-юклы акчасын җәлли. Әйе, куандык. Синең үлү хәбәреңне ишеткәч, куандык. Азрак булса да файдаң тигән булыр иде. Нигә кайттың?

Рәшидә. Ни сөйлисең, Хафиз?

Хәким. Ха-ха, барыбер эләкмәс!

Хафиз. Котыртма минем җанымны!

Хәким. Җаның? Кайда соң ул, табан астындамы?

Сәкинә. Әти, мыскыллама син аны, исердем дигәч тә.

Хәким. Бар, бар, сат атаңны шуның танавына.

Гайшә. Бу ни була инде бу, Ногман? Без бередән бер тиенсез китәбезмени?

Ногман. Әти, юләрләнмә, вакытында акылыңа кил.

Валера. Как это, значит, папаша, я «Волгу» больше не увижу. А если я умру. Ведь я без «Волги» ни дня проживу. Понятненькое дело, как всегда честного русского человека давят.

Гайшә. Әй, сине түгел, безне дә кимсетәләр әле монда.

Гөлсем. Менә күрәсезме, балалар, ничек яшәдем мин? Гел кимсетелү, гел орыш.

Хәким. Месkenләнмә, барыбер эләкмәс.

Гөлсем. Эләкмәсә! Никләр генә кайттың?! Кайтмый калсаң, эләктерә белер идем. Җүнле кеше булса, кайтмас иде әле, җүнсез.

Г а й ш ә. Шулай итеп, әти, Ногманны, булдыклы улыңны өлешсез калдырасың? Сытып бетерәм! (*Ябыша.*)

Н о г м а н. Шундый ул, әти, уйла.

Р ә ш и д ә. Нишлисең, Гайшә?

Гайшә Рәшидәне этеп җибәрә.

Г а й ш ә. Кит әле. Бирәсеңме, юкмы?

Ногман Гайшәне аера.

Х ә к и м. Берни эләкмәс.

Г ө л с е м. Әнә шундый ул, кире. Анагызны гел мыскыл итә, сез түзәсез. (*Шыңшый.*)

Х а ф и з. Т-ә-к-к, шулай итеп, аңлаша алмадык. Бирәсеңме, каенатай, юкмы?

Х ә к и м. Юк!

Х а ф и з. Юкмы?! (*Хәкимне сугып ега.*)

Р ә ш и д ә (*елап*). Нишлисез, җир битләр!

Х а ф и з. Кысылмагыз!

Н о г м а н. Әти, акылыңа кил, юньлегә түгел бу, үзеңә яхшы булмас.

Г а й ш ә. Нәрсә аның белән сөйләшеп торасыз. Әйткәнне аңлыймыни ул? (*Егылган Хәкимгә атланып, аның башына суга башлый.*) Мә, мә, куркуль!

С ә к и н ә. Гайшә, юләрләндең мәллә?

Г а й ш ә. Кит әле. Акылыңнан шашарсың монда. Көпәкөндез чишендерәләр.

Сәкинә белән Рәшидә Гайшәне тартып төшерәләр.

Г а й ш ә. Үтерәләр, карт шайтан. Үтерә!

Х ә к и м. Туктагыз, балалар, нишлисез?

Х а ф и з. Туктарбыз, бирәсеңме, юкмы?

Х ә к и м. Нәрсәне?

В а л е р а. «Волгу»!

Х ә к и м. Юк, дидем бит инде! Сезгә файда бирмәячәк ул акчалар.

В а л е р а. Ах, нет. Ну и получай! (*Сугып җибәрә.*)

Х а ф и з. Күп сөйләшеп тор әле.

Валера белән Хафиз Хәкимне типкәли башлыйлар. Гайшә өстендә сикерә.

Г ө л с е м. Менә алма кебек хатыныңны тыңлый белмәсәң.

Р ә ш и д ә (*аралап*). Нишлисез, үтерәсез бит! (*Елый.*)

Г а й ш ә. Катсын, бер файдасы да юк.

С ә к и н ә. Шашмагыз, булды. Әти, әллә... Экономик яктан караганда... әллә...

Н о г м а н. Ник җәлләргә инде шул акчаларны.

Х а ф и з. Бирсә, әйбәт була бит. Хәзер сине келәткә бикләп торабыз, уйла, акылыңа килмәсәң, тагын әләгер.

Хафиз белән Валера Хәкимне алып чыгып китәләр.

Р ә ш и д ә. Туктагыз, нишлисез, милициягә чакыртам...

Н о г м а н. Кая барасың? (*Аны туктата.*) Милиция (*килеп керүче Хафизга*), сиңа минем апа нидер әйтмәкче була. Хи-хи-хи.

Р ә ш и д ә. Ничек оялмыйсыз?

С ә к и н ә. Җиттеме сезгә? Ни кыланганыгызны аңламыйсызмы сез, ә? Барыбер бирмәячәк.

Х а ф и з. Әйе шул. Артык кызып киттек бугай. Ногман, кая, бармы анда, сал әле?..

Н о г м а н. Мә!

Х а ф и з. Сәкинә дөрес әйтә, бирмәячәк. Ярый, җәмәгать, берни дә барып чыкмады. Әйдә, Валера, эчик! (*Эчәләр.*) Ногман, бар, алып чык атаңны, начаррак килеп чыкты.

Г а й ш ә. Әй, берни дә булмады әле ул кадәр.

Г ө л с е м. Ни булсын аңа, кешеләр шартлаганда да үлмәгәнне. Җен кебек таза.

Х а ф и з. Ярый, булды. Ногман, бар, алып чык, син җаен беләсең.

Н о г м а н. Хәзер. (*Китә.*)

Г а й ш ә. Тапкан җәлләр кеше. Безне җәлләми бит әле.

В а л е р а. Ты и в правду отказываешься, Хафиз? ( *Җырлый.*)

Автомобиль гаражы,
Син дә безне җәлләмәдең,
Җәлләмибез, заразы...

Тышта Ногман чәрелдәгәне ишетелә. Ул йөгереп керә. Күзе-башы акайган, ни әйтергә белми.

Х а ф и з. Ни булды?

Ногман дәшми.

Г а й ш ә. Нәрсә акайдың, сөйлә!

Н о г м а н (*үкереп җибәрә*). Сволочь, карт тәре... дуңгыз... чучка... (*Аракы эчеп ала.*) Вәт дуңгыз... ә...

Х а ф и з. Ни булды?

Н о г м а н. Асылынган...

Р ә ш и д ә. Әти! (*Чыгып йөгерә.*)

С ә к и н ә. Әткәй! (*Аның артыннан ташлана.*)

Барысы да катып калалар. Утлар сүнә, арттан гына прожектор яна. Һәр персонаж кара шәүлә генә булып күренә. Тынлык. Фонограмма яңгырый: кайдадыр кабердән чыккан авазлар ишетелә.

Гөлсем. Яраткан кешеңне югалту бик кыен ул, аңларсыз әле...

Ногман. Әтием, бәгърем, ник ташлап киттең безне?! Ничек ярата идем мин сине.

Гайшә. Уф, йөрәгем. Әти минем өчен үлеп тора иде. Акыллы киленем, диеп сөя иде...

Хафиз. Эх, әткәй, бигрәк яхшы кеше иде инде. Нинди балыклар тота идек...

Валера. Ой, как тяжко мне... А я карбюратор к «Волге» принес...

Сәкинә. Әти! Балаларың, туган ил, партия — сине беркайчан да онытмас!

Чәчкә. Әтием, ә как була Отчизнаның татарчасы?

Пәрдә

# Юбилей

*Ике пәрдәле драма*

КАТНАШАЛАР:

Лилия — 50 яшьтә.
Марсельеза — 78 яшьтә.
Рәфидә — 20 яшьтә.
Шаһия — 37—38 яшьләрдә.
Шакир Нигъмәтович — 42—43 яшьләрдә.
Хыял — 52 яшьтә.
Әхмәтгәрәй — 60—65 яшьләрдә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәхнәдә — Идел аръягындагы дача. Аның торак йорт сыман корылмасы төзелеп бетмәгән. Ничектер, менә-менә «җимереләм» дип торган кебек, күңелдә ныклы булуына ышаныч уятмый. Идел буеннан күтәрелүче сөзәк тау һәм бакча кисәк ачылып китә. Уртада — өстәл. Таң атып килә. Сәхнә ниндидер төшкә керә торган матурлыкны, хыялны хәтерләтә. Шул моңсу гүзәллек эчендә Марсельеза әби чебиләрен эзләп йөри. Ул очып йөргән фәрештәне хәтерләтә.

Марсельеза. Чеп-чеп-чеп-чеп-чеп-чеп-чеп... кая югалалар болар?.. Матуркайларым, чеп-чеп-чеп... йомшакларым... кая качтыгыз... наяннар?.. Чеп-чеп-чеп-чеп... Ярый, шук йомгаклар, карыныгыз ачкач, чыгарсыз әле... Чеп-чеп... Ә мин сезне тәмле ярма белән сыйлармын. (*Намазлык алып җәя.*) Бисмилләһир-рахмәнир-рахим..

Рәфидә кайта. Бер кулында — авыр сумка, икенчесендә — кош читлеге. Әбигә бераз карап тора да, сумкасын калдырып, өйгә кереп китә.

Марсельеза. Фани дөньядагы бу мәхлукларыңа сабырлык бир, Ходаем...

Тау астыннан аяк тавышлары, бүленеп-бүленеп җырлаган тавыш ишетелә. Бераздан зур сеткалар тоткан, алҗыган, әмма бик тере Шаһия күренә.

Шаһия. У-у-уф! Салют, түткәй! Уф Алла, тапканнар дача ясар урын. Үзе Иделнең икенче ягында, үзе тау

башында, үзе... (*Сумкаларын өстәл янына куя.*) Шулаймы, Марсельеза әби? Әйеме дим... Килсәң, килеп, менсәң, менеп җитеп булмый. Исе китте инде... Имеш, дачасы Идел ярында булсын... Шакир Нигъмәтович булмаса, шиш... әйеме... (*Өйгә кереп китә.*)

Марсельеза. Сабырлык бир, Ходаем. Шәһит киткәч, ярдәмеңнән ташлама... (*Догасын дәвам итә.*)

Шаһия чыга.

Шаһия (*киерелеп*). А-а-а-ах!.. Йокы килә... Хәлләр ничек, түтәй? Төне буе шаштык бит. Ха-ха, үзем дә җүләр инде. Барыбер беркем дә карамады. Исәнме, дим, әби... Әссәламәгаләйкем. (*Әби укына.*) Әллә?! (*Үзалдына.*) Әллә ычкынган инде... Әби, дим?.. (*Әби дәшми.*) Әби, дим, чукракландыңмы әллә?

Марсельеза (*егылып китеп*). Әстәгефирулла! Ләхәүле вә лә куәте!..

Шаһия. Аллага шөкер... Уф. Йә, тагын берәр сүз әйт әле! Яле...

Марсельеза (*сүзен әйтә алмыйча*). Ләх-ләх-ләх...

Шаһия. Йә инде, йә...

Марсельеза. Чу-чу-чукынган кызый, котымны алдың... Намазымны бүлдең...

Шаһия (*көлеп*). Хи-хи. Исәнме, дим, әбекәй, исәнме! Хәлләр ничек?

Марсельеза. Исәнме, исәнме?.. Исән... (*Китә.*) Чеп-чеп-чеп...

Шаһия. Үпкәләде... Марсельеза әби, кая монда чеби булсын инде, бакчада.

Марсельеза. Хе-хе, үзем беләм мин, кысылма... Чеп-чеп-чеп-чеп. (*Эзләп китә.*)

Шаһия. Уф, алҗыткан... Бу кортка әллә чыннан да ычкына башлаган инде. Көне-төне намаз укый, әллә ниткән, дөньяда булмаган чебиләр эзли. Картайган шул, картайган... Тәрбия дә юк бугай мескенгә. Әй дөньясы... без дә шушы көнгә калырбыз микәнни? Чеби эзләп, намаз укып йөрергә. Гомер үтә... шулай... Ходай үзе сакласын.

Марсельеза әйләнеп килә.

Марсельеза. Чеп-чеп-чеп-чеп, калганнарыгыз кая?

Шаһия. Хәзер кайтып җитәрләр. Аларның бит мәхәббәт. Яшьләр бераз шаярышалардыр...

Марсельеза. Шаяралар... Чеп-чеп-чеп-чеп...

Шаһия. Карале, Марсила апа, эзләмә син ул юк чебиләреңне. Көтеп йөр дә, берзаман үзләре килеп чыгарлар...

М а р с е л ь е з а. Шулай дисеңме?

Ш а һ и я. Билгеле, Рәфидә кайтмадымыни? Миннән алда чапкан иде бит.

М а р с е л ь е з а. Белмим, күрмәдем. Кайтмагандыр әле. Чеп-чеп-чеп.

Ш а һ и я. Фу-у, әби җаным, туйдырдың.

М а р с е л ь е з а. Соң, эзләми генә... Ни әйтсәң дә, кош бит! Очмаса да... Тавык кына булса да... Кошлар яратам мин...

Ш а һ и я. Алай булгач, эзләп кара инде әби, эзлә. Бәхетең чеби эзләргә калгач... Анысы, хәер, белеп булмый, бәлки, табып та куярсың. Хы-хы-хы! Бер картлыкта, бер яшьлектә, диләр бит...

М а р с е л ь е з а. Нәрсәне?

Ш а һ и я. Чебине түгел инде, һәрхәлдә. Вәт, Марсила апа, кичә мине чакырды ул берәү танцага... Эх! Высший сорт! Шундый кара мыеклы, зифа буйлы... Ха-ха-ха! Үзе капшана... Син бигрәк йомшак икәнсең, дигән була. Ишетәсеңме, симез икәнсең, дими, йомшак икәнсең, ди. Хи-хи-хи! Ну, Шакир Нигъмәтович булмаса, йомшак җәеп катыга утырта идем инде анысы...

М а р с е л ь е з а. Нәрсә сөйли дип торам... Чеп-чеп-чеп-чеп. Тәртипле генә үттеме соң?

Ш а һ и я. Ничава... Әллә ни кыландырмадылар. А-а-а-аһ... (*Авызын каплап.*) Карале, күз йомыла... Ярый, әбекәй, тегеләр кайтканчы, мин самавыр куеп, өстәл әзерли торыйм әле. (*Җырлый-җырлый китә.*)

Сандугачның балалары
Нигә сигез булмаган...

М а р с е л ь е з а. Кыланыгыз инде... Бу бала кая китте микән? Чеп-чеп-чеп-чеп.

Ш а һ и я самавыр күтәреп чыга.

Ш а һ и я. Рәфидәме? Монда икән, әнә йоклап ята.

М а р с е л ь е з а. Ничек күрми калдым соң? Арыгандыр, бәбекәем.

Ш а һ и я. Һе, бәбкәй. Алҗымый. Кичә төне буе маймыл кебек сикерде... йокласын. Сезнең күмер кайда соң, әби?

М а р с е л ь е з а. Нәрсә?

Ш а һ и я. Күмерегез кая, дим, самавыр куярга?!

М а р с е л ь е з а. Ниткән күмер? Юк күмерне каян аласың ди... Әнә электр чәйнеген тык...

Ш а һ и я. Юк, әби, монда килеп, самавырдан да чәй эчмәгәч...

М а р с е л ь е з а. Самавыр... Элеккеге заман түгел... Эх, элек иде ул. Бар иде күңелле чаклар... Шулай...

Ш а һ и я. Ни дисең? Кайда?

М а р с е л ь е з а. Бар иде күңелле чаклар...

Ш а һ и я. Берни дә аңламадым... (*Якынрак килә.*)

М а р с е л ь е з а (*хыялланып, үзалдына*). Без кыз чакта, кышын мич якканда, күмерен җыеп бара торганнар иде. Мин бит авылда үстем... Әй ул безнең авылның ямьлелекләре... Ишегаллары яшел чирәм... Ул су буйлары... Ә самавырны бер дигән күмер белән каената торган идек... Хе-хе-хе... Иң кызыгы, әтинең иске солдат итеге белән өрдереп... Хи-хи-хи. Иске иде, тишекләреннән төтен чыга... Безгә кызык... Шул итекне киеп революция ясап йөргән бит. Хе-хе. Бер ак әфисәр итеге, ди, имеш.

Ш а һ и я. Соң, әби, нәрсә белән каенатабыз?

М а р с е л ь е з а. Ә?.. Ә, әйе, өй артында йомычка бардыр шунда...

Шаһия өй артына китә.

Шулай... Ишетәсеңме, сиңа әйтәм... Ә самавыры җиз иде. Чын, ялтырап торган җиз... Әйе, бар иде күңелле чаклар! Әти мәрхүм Гитлер сугышында һәлак булды шул, бәгырькәем... Ә хәзер әнә нинди матур тормыш...

Ш а һ и я (*кире килеп*). Самавыр чыжлый, өстәлне карый торыйк, түтәй, вакыт үтте, тамак та ачты...

М а р с е л ь е з а. Шулай, шулай, балам, ашыгыйк.

Ш а һ и я. Син, әбекәй, яшергәннәреңне чыгар, ә мин монда рестораннан кайтканнарын бушатыйм.

М а р с е л ь е з а. Карале, кызым, каплабрак куй, чебен кермәсен. Мин хәзер, чеп-чеп-чеп-чеп...

Ш а һ и я. Ярый, бар, бар. Картайган карчык.

Әби китә.

Тегеләр кайда йөриләр инде?.. (*Шакир Нигъмәтович аның артына кача.*) Дөнья тигез булмаган шул, сандугач балалары...

Ш а к и р  Н и г ъ м ә т о в и ч (*куркытып*). Хайт! Ха-ха-ха!

Ш а һ и я. Аһ! (*Кисәк кенә аңа борыла. Шакир икәнен күргәч, һуштан язган сыман, аның кочагына егыла, муеныннан кысып кочаклый. Шакир көлеп, нишләргә белми тора.*) Аһ...

Л и л и я керә.

Л и л и я. Менә без дә... Сездә ни хәлләр? (*Шаһия һаман да Шакирны җибәрми.*) О-о, картина Репина. Не ждали... Бигрәкләр дә матур торасыз...

Ш а к и р. Лилька, нишлим, җибәрми...

Ш а һ и я. Мин бик курыктым. Аһ! (*Кыланып, башын Шакирның күкрәгенә сала.*)

Ш а к и р. Җибәр инде, Шаһия... Шаярдык.

Л и л и я (*кыланып*). Их, ахирәт, менә син нинди икән, подружкаңның егетен, әй лә, дустын әләктерәсең, ә?

Ш а к и р. Ну, Шаһия, в конце концов...

Ш а һ и я. Юк, юк, мин түгел, ул үзе мине әләктерде, ахирәт. (*Шакирга.*) Җибәр дим, җибәр. (*Тагын да ныграк коча.*) Ха-ха-ха! Ярый инде, Лилия, бир аны миңа, син чибәр, бүтәнен хәзер табарсың. Шакир Нигъмәтович миңа булсын, миңа ярап торыр...

Л и л и я. Сиңа ярарлыкмы? Ал алайса... Тик синнән мәгәрич...

Ш а к и р. Лилия, Шаһия шаяра ул... Шаһия, дим!

Ш а һ и я. Мин чынлап әйтәм. Мәгәрич кенә түгел, миннән бер ящик... Шакир Нигъмәтович өчен җәлләп торып буламыни... (*Чын-чынлап Шакирга ябыша, кисәк кенә анда ниндидер тынгысыз дәрт уянганы сизелә.*) Шакир, җаным... бәгърем... кая, бер үбим инде...

Ш а к и р. Нәрсә?! Карале дим...

Ш а һ и я. Бер генә. (*Тарткалашканда икесе дә егылып китәләр.*)

Л и л и я. Ха-ха-ха! Шакир Нигъмәтович, әйдә, бирешмә.

Ш а к и р (*сикереп торып*). Мин түгел, ул үзе, Лилиям.

Л и л и я (*көлеп*). Гәҗитебездәге бердәнбер Шакирны бетерә яздың бит, Шаһия...

Ш а һ и я. Бетерерсең, бар... Башка хатын-кыз күзенә күренми аның. Бәйләнчек урман бете кебек сиңа кадалып каткан.

Ш а к и р. Менә монысы дөрес. Валлаһи, шулай. Лилиямнән башка кеше... (*Лилияне үбеп ала.*)

Л и л и я. Бусы ни тагын?

Ш а к и р. Ә ни булды, бәгърем?

Л и л и я. Ни булды? Тик торганда, лач-лоч килеп, үбешеп йөрмиләр инде...

Ш а к и р. Тагын мин гаепле.

Л и л и я. Без бит яшьләр түгел. Кичә илле тулды.

Ш а к и р. Сине әле унсигез яшьлек кызларга да биргесез. (*Кочмакчы була.*)

Л и л и я. Булды дим... Ачуымны чыгарма...

Ш а һ и я. Шакир, менә мине үп рәхәтләнеп, мин оялмыйм.

Ш а к и р. Син ул сузылып та ятарсың...

Ш а һ и я (*үпкәләп*). Менә анысы булмас!

Л и л и я. Шаһия, Шакир шаяра ул. Шаян бит ул. (*Шакирны чеметеп ала.*)

Ш а к и р. Ой, авырта.

Л и л и я. Әнә бит, нинди шаян! Шырык-шырык көлә... (*Шакирны кытыклап көлдертә.*)

Ш а к и р. Ха-ха-ха, җәмәгать, туташлар! Шакир абзагызның ашказаны шәрифләрендә бүреләр Сабантуй ясый, нишлибез... Баш та үз урынында түгел.

Ә х м ә т г ә р ә й керә. Алыптай олы гәүдәле, шаян кеше.

Ә х м ә т г ә р ә й. Что за шум, а драки нет.

Ш а һ и я. О-о, Әхмәтгәрәй абзый. Син ничек биредә?

Ә х м ә т г ә р ә й. Менә Вашингтоннан Токиога очышлый, туган якны (*елаган булып*) сагынуга түзә алмыйча, самолеттан сикереп төшеп калдым.

Ш а һ и я. Ха-ха-ха. Аяк сынмадымы?

Ә х м ә т г ә р ә й (*тамак астына чиертеп*). Тәнне бик яхшылап йомшарткан идем, ул-бу булмады...

Л и л и я. Әхмәтгәрәй җизни, ничек син биредә? Кайчан килдең?

Ә х м ә т г ә р ә й. Әйттем бит инде, очып барышлый...

Л и л и я. Җизни, кыланма...

Ә х м ә т г ә р ә й. Бетте, бетте. (*Кулларын күтәрә.*) Биреләм.

Л и л и я. Фу-у, перегар үзеңнән! Төне буе эчтеңме?

Ә х м ә т г ә р ә й. Юк, бераз гына...

Л и л и я. Бераз чамасын бел инде.

Ә х м ә т г ә р ә й. Чамасы дип, балдыз... бу гәүдәгә ул баш төзәтерлек кенә булды инде.

Ш а к и р. Сез, килгәнсез икән, теләсә ни сөйләп, кыланып йөрисе булмагыз. Бүген Лилия Газизовнаның шундый көне.

Ә х м ә т г ә р ә й. Бетте, туган, тимә генә. Минем бит килүем дә шуның өчен генә. Балдызны чын күңелдән котларга иде исәп. Менә бер литр күчтәнәчем дә бар иде. Бигайбә, төне буе көттем, кайтмадыгыз.

Л и л и я. Сиңа шул эчәргә генә булсын.

Ә х м ә т г ә р ә й. Ялгышасың, балдыз. Эчәргә түгел, тормышның тәмен белергә. Мин менә йөз грамм салсам, аның тәмен белеп, тәнгә сеңдерәм. Гәүдәм ләззәткә чума, ә җаным әллә кайларга оча.

Л и л и я. Ярый, җизни, шамакайланма, төне буе йокламаган.

Ә х м ә т г ә р ә й. Бетте генә, үзегез сорашканга гына әйтүем. Аннан, Лилия сеңлем, шамакайлану ул чагыш-

тырмача әйбер. Менә мин сезгә шамакай булып тоелсам, ә сез миңа...

Л и л и я. Чыннан да, Шаһия ахирәт, карын ачты, ничек соң синең ул фронтта хәлләр?

Ш а һ и я. Хәзер, дустым. Самавыр кайнагандыр, менә өстәлне әзерләп бетерик тә...

Ә х м ә т г ә р ә й. Менә бит... Син, Шаһия сеңлем, беркемгә алыштырмаслык хатын, үзең уңган, үзең, гүпчем, сүз табарлык та түгел. Эх, менә синең кебек домохозяйкаң булса...

Ш а һ и я. Нигә домохозяйка гына, хатын түгел?..

Ә х м ә т г ә р ә й. Ә, юк! Хатын булмасын. Хәзерге заман хатыннарының мәшәкате күп. Үзен-үзе дә карый алмый, ирекне дә чикли... Ә миңа ирек булмаса...

Ш а к и р. Ирек дигән була әле. Нинди хатын килсен синең янга!

Хатыннар өстәл әзерләп йөри.

Ә х м ә т г ә р ә й. Сүзеңдә хаклык бар. Килмиләр. Чөнки алар миңа хатын так таковой кирәк түгел икәнлеген аңлыйлар... Әгәр дә инде чын дус булырлык булса, ул чакта...

Ш а һ и я. Нәрсә, Әхмәтгәрәй абзый, чын дус булырлык хатын-кыз очрамадымы?

Ә х м ә т г ә р ә й. Юк. Дөрес, яхшы хатыннар күп очрады. Хе-хе. Яшь чагында ул халыкны мин бик ярата идем, алар да мине... (*Шаһияне коча.*)

Л и л и я. Җизни, оятсызланма, зинһар...

Ш а һ и я. Үтерәсең, Әхмәт абзый.

Ә х м ә т г ә р ә й. Әйе, күп күрдем мин сезнең халыкны. Ләкин дус булырлык булмады. Ул, Шаһия сеңлем, ирләр арасында да булмый дус булырлыгы...

Ш а һ и я. Синең дә дустың юкмы?

Ә х м ә т г ә р ә й. Юк. Гомумән, кеше дигән җанвар бу дөньяда бик ялгыздыр ул...

Ш а к и р. Акыл ияләре һәр кешене, ирме ул, хатынмы, барысы да яртышар була, дигәннәр. Һәркем үз яртысын гомер буе эзли, ди.

Ә х м ә т г ә р ә й. Син үзеңнекен таптыңмы соң?

Ш а к и р. Таптыңмы дип... (*Лилиягә карап.*) Миннән генә тормый шул...

Ә х м ә т г ә р ә й. Әй, аптыратма. Менә хәзер минем үземнең яртым булсын иде ул...

Ш а һ и я. Ну, Әхмәт абзый, хе-хе... Булыр, Алла боерса.

Ә х м ә т г ә р ә й. Булырмы? Менә бит. Юкка гына мактамыйм мин Шаһияне.

Лилия. Җизни! Шаһия, син дә котыртып торма.

Шаһия. Күңелле ич. Менә, Әхмәтгәрәй абый, сине бик мактамыйлар да, ә шулай да син булганда күңелле, яшисе килеп китә...

Әхмәтгәрәй. Миндә бит кан юк. Миндә — яшәү чишмәсе.

Шакир. Спирт диген.

Әхмәтгәрәй. Искә төшермә әле шул ярты, спирт дигән сүзләрне, йөрәгемә ярамый. Менә Шаһия уңган да инде безнең...

Лилия. Минем ахирәт шулай булырга тиеш...

Әхмәтгәрәй. Тиешен тиеш тә, син дә калышма...

Лилия. Ашыкма.

Шаһия. Мин, Әхмәтгәрәй абзый, берәр асыл егетне каратып булмасмы дип тырышуым иде. Тырыша торгач, остарып киттем, гадәткә кереп калды. Халык әйтә бит, ирләрнең мәхәббәте корсак аша, дип. (*Шакирның корсагына төртә.*)

Әхмәтгәрәй. Иң мөһиме — корсак. Менә монысы хак! Аннан — тамак. (*Тамагына чиртә. Шакирга күрсәтеп.*) Моңа кызыкма, моның корсак болай да зур, эшең барып чыкмас... Белмим тагын, тырышкан табар дигәннән...

Шакир. Ай-яй, кешедән көләргә яратасыз да инде. Культура булырга тиеш азрак кешедә.

Әхмәтгәрәй. Ә нәрсә соң ул культура?

Шаһия. Кешене мыскыл итмәү, беренче очракта.

Әхмәтгәрәй. Бәлки. Минемчә, иң әүвәл кешенең эче кортлы булмасын...

Лилия. Ярый, җизни, җитте...

Шаһия. Белмим инде, Әхмәтгәрәй абзый, тырышып карыйм микән, хи-хи-хи.

Лилия. Шаһия, дим!

Шаһия. Булды, акыл керде. Ичмасам, самавырны алып килегез берәрегез...

Лилия. Шакир Нигъмәтович...

Шакир. Тыңлыйм.

Лилия. Марш, самавырга!

Шакир. Есть, Лилиям!

Әхмәтгәрәй. Айт-два, айт-два.

Шаһия. Ха-ха-ха.

Лилия. Җизни, в конце концов...

Әхмәтгәрәй. Соң, балдыз, кызык бит.

Марсельеза самавыр күтәреп килә.

Марсельеза. Самавырыгыз шартлый бит инде...

Ә х м ә т г ә р ә й. Хәерле иртә, түтәй!

М а р с е л ь е з а (*Әхмәтгәрәйгә*). У-у-у, мөртәт, син мондамыни әле?! Хәерле иртә, дигән буласың тагын.

Л и л и я. Нишләде, түтәй?

М а р с е л ь е з а. Төне буе үкереп чыкты, йокы бирмәде.

Л и л и я. Куасың калган.

М а р с е л ь е з а. Куарсың ул аюны.

Ә х м ә т г ә р ә й. Менә, Шакир дус, бер хатын-кыз яратмый мине шушында. Ә минем тамчы да исем китми. Миңа тормыш матур булсын, ә калганы... Хатын-кызга хәзер... исем дә китми минем.

Ш а к и р. Сез дөрес әйтмисез. Хатын-кызны олыларга, яратырга кирәк.

Ә х м ә т г ә р ә й. Җәллим мин аларны, бик җәллим. Алар бик тырышалар, без яшибез, дигән булалар. Ә чынында...

Л и л и я. Җизни, җитте. Йә яхшы гына буласың, йә...

Ә х м ә т г ә р ә й. Бетте, бүтән бер сүз дә дәшмим. Бигайбә, баш төзәтми дә китә алмыйм... (*Читкәрәк китеп, трубка кабыза.*)

Л и л и я. Ни хәлләр соң монда, түтәй?

М а р с е л ь е з а. Аллага шөкер, бүгенгә исән-сау әле. Менә чебиләрем генә югалды.

Ш а к и р. Исәнме, Марсельеза түти!

М а р с е л ь е з а. Әйбәт әле. Чеп-чеп-чеп-чеп.

Л и л и я. Тукта әле, түтәй, нинди чеби тагын?

М а р с е л ь е з а. Ә-ә, бик матур, бик йомшак ике чеби...

Ш а һ и я. Тыңламагыз аны, минем башны да катырды. Карале, Лилия, синең ул... (*Чигәсен бармагы белән борып күрсәтә.*)

М а р с е л ь е з а. Кичә бер салмыш ир кәртүзен тотып үтеп бара... Чыр-чыр килә кәртүзе... Нәрсә ул, нигә газаплыйсың, дим? Чебиләр, ди. Бишәү иде, ди, өчесе берәр артлы үлде, атып бәрдем, ди, мөртәт.

Ш а к и р. Аңа каян килгән ул чебиләр?

М а р с е л ь е з а. Алла белсен. Мин әйтәм, боларын да харап итәсең, калдыр, дим. Аракы бирсәң, ди, юньсез... Хе-хе. (*Лилиягә.*) Кызым, синең теге мәтәштергән әйбереңне литрлы банкы белән чыгарып бирдем инде, ачуланма.

Ш а һ и я (*ерактан*). Нинди әйбер?

М а р с е л ь е з а. Соң, теге, нәрсә әле?..

Ә х м ә т г ә р ә й. Брашка!

М а р с е л ь е з а. Әйе, брашкамы, нәрсә әле?..

Л и л и я (*көлгән булып*). Хе-хе, әби, син нәрсә, хе-хе! Әби белми сөйли...

Марсельеза. Белмим тагын, шуны биргәч, калдырып китте. Менә көне буе таба алмый йөрим. Ачыкканнардыр инде, мескенкәйләрем. Чеп-чеп-чеп.

Әхмәтгәрәй. Эх, әбекәй, нигә кичә әйтмәдең аны?

Лилия. Җизни, валлаһи, дим...

Әхмәтгәрәй. Дәшмим бит, шаярам гына...

Лилия. Чеби дигәннән, кая әле безнең теге сайрар кош, кичә миңа бүләк иттеләр бит...

Шаһия. Рәфидә алып кайтып киткән иде.

Лилия. Шундый матур үзе, бәләкәй генә. Тик нигәдер сайрамый.

Әхмәтгәрәй. Очар кош та булсын, читлектә дә булсын, сайрасын да, хе... Кошны түгел, сөйрәлүчеләр семьялыгына кергән җанварны читлеккә япсаң да шиңә...

Шаһия. Шулай шул, читлек читлек инде...

Шакир. Тамагы ачтыр аның, ашатып-эчертеп карыйк.

Әхмәтгәрәй. Ашатуны белмим, әмма эчерсәгез, кош түгел, үзем дә сайрыйм.

Лилия. Ай Алла! Җизни?!

Әхмәтгәрәй. Җизни, җизни. Син, балдыз, әллә нишләдең әле. Мин бит сине чын күңелдән котларга дип килдем. Синең тормыш, хезмәт уңышларың минем өчен дә зур куаныч. Менә күчтәнәч тә алып килгән идем, тик кайтып кына җитмәдегез. Буш килеш кенә, тостсыз гына котлап булмый бит.

Лилия. Ярый, ярый. Мин бит каршы түгел. Матур гына да була бит.

Шаһия. Чыннан да, иптәшләр, әйдәгез, өстәлне чебен басканчы, аны без басыйк. Утырышыгыз.

Лилия. Түтәй! Кил монда. Ярый, түтәй, юләр сатып йөрмә, әйдә, өстәл янына... Рәфидә кайтмадымыни?

Шаһия. Өйдә, ял итә.

Лилия. Түтәй, чакыр әле!

Марсельеза. Хәзер, кызым. (*Китә.*)

Шакир. Бик кызык әби.

Лилия. Картайган инде, саташа...

Әби белән Рәфидә чыга.

Шаһия. Әйдә, күгәрченнәр, утырышыгыз.

Шакир. Безгә инде бу, пар күгәрченнәргә, әйеме, Лилия? Исәнме, кызым!

Лилия. Рәфидә, нигә исәнләшмисең?

Рәфидә. Сеңлегездер, бәлки.

Шакир. Исәнме, сеңлем.

Әхмәтгәрәй. Йокы туйдымы, кошчык?

Р ә ф и д ә. Исәнме, Әхмәтгәрәй абзый!

Ш а һ и я. Әйдә, әйдә, сузмагыз, утырышыгыз. Ашыйсы килә. Лилиягә аңа...

Ә х м ә т г ә р ә й. Баш та авырта инде анысы. (*Юри алга үтеп.*) Рәхмәт инде, рәхмәт, алай ук түргә кирәкмәс иде... Ярар инде, ул кадәр кадер-хөрмәт... кыстамагыз инде... (*Рәфидә көлә.*)

Ш а һ и я. Оялма инде, Әхмәтгәрәй абзый, алай тартынып торма. Үз өеңдәге кебек бул!

М а р с е л ь е з а. Әрсез алабай. Мөгезсез сыер кебек сөзә. Кит! Читкә утыр!

Ш а к и р. Лилия, кил, монда утыр...

Л и л и я. Юк, мин монда гына, бар да кул астында...

Ш а һ и я. Каяле, Шакир Нигъмәтович, үзем синең янга утырыйм әле. (*Аңа сыенып утыра.*)

Л и л и я. Бигрәкләр дә пар килгәнсез икән. (*Рәфидә белән Әхмәтгәрәй көлеп куялар.*)

Ш а һ и я. Ә кәк же. Ә табын кичәгедән дә матур булды түгелме, ә?! (*Аракылар чыгарып куя.*) Шакир иптәш, командуй.

Ә х м ә т г ә р ә й. Охо! Өстәл болай да матур иде, җитмәсә, аның өстенә ай белән кояшын да чыгарып куйдың.

Л и л и я. Юк, юк, кичәгегә тел тидермәгез. Кичә иң матур табын, иң матур көн булды.

Ә х м ә т г ә р ә й. Синең өчен.

Ш а к и р. Нигә алай булсын. Кичә барыбыз өчен дә искиткеч көн иде.

Ш а һ и я. Мин бит бүген дә матур дим.

Л и л и я. Ә кичә! Эх, кичә! Шакир Нигъмәтович, матур булды бит, ә?

Ш а к и р. Шаккаткыч!

Ә х м ә т г ә р ә й. А те вчера по пять, были очень большие... Но вчера... Мин дә кушылам. Искиткеч көн булган. Шуның хөрмәтенә... (*Шешәгә үрелмәкче була.*)

Л и л и я. Ашыкма әле, җизни, өлгерерсең. Юбилярны да тыңлагыз әле бераз.

Ш а к и р. Стоп! Тавыш, җәмәгать!

Л и л и я. Искиткеч бәйрәм булды ул кичә, әйеме, ахирәт? Әйеме, дусларым?!

Ә х м ә т г ә р ә й. Искиткеч. Менә шуның өчен...

Ш а к и р. Утырыгыз әле. Тыңлыйбыз, Лилия...

Л и л и я. Ул өстәлләр, ул халык, кемнәр генә юк иде, ә, Шакир Нигъмәтович?! Ул «Вечерка»дан еврейлар да, безнең газетадан да. Санап бетерерлек түгел...

Ә х м ә т г ә р ә й. Бушка ашарга, эчәргә җыелалар инде. Минем кебек.

Ш а һ и я. Каты капладың, Әхмәтгәрәй абзый.

Л и л и я. Син хаклы түгел, җизни. Үзең белән чагыштырма...

Ә х м ә т г ә р ә й. Аерма шунда: мин ачыктан-ачык эчәргә дип киләм... Алар изге кыяфәттә...

М а р с е л ь е з а. Тукта инде, карт шайтан...

Л и л и я. Юк, җизни, бу минем 50 еллык гомеремнең, хезмәтемнең җимеше, дип уйлыйм. Бүлдермә, җизни. Дусларым! Мин нинди бәхетле! Үзегез уйлап карагыз. Зур газетта җаваплы секретарь булдым. Мәкаләләрем басылып тора. Менә Шакир Нигъмәтович әле мәкаләләремне, очеркларымны җыйнап, китап итеп чыгарабыз, ди. Мин бит язучы булдым дигән сүз.

Ш а к и р. Мин синең өчен бик шат!

Л и л и я. Менә дигән булып кызым үсеп җитте. Куанычым. Ә кичәге мәҗлес тормыштагы минем бу уңышларыма өндәү билгесе булды дияргә була. Таң атканчы утырдык бит.

Ә х м ә т г ә р ә й. Ну инде, братва, моның өчен дә тост күтәрмәсәк... Сал, Шакир шәкерт...

Ш а к и р. Әйе, әйе. (*Аракы сала башлый.*)

Ш а һ и я. Шакирга рәхмәт инде.

Л и л и я. Әйе, әйе, Шакир Нигъмәтович, сезнең ярдәм күп булды. Рәхмәт. Шундый ресторанда, шундый кешеләр җыелды... Менә, ышанасызмы, күз алдына да китерә алмый идем...

Ш а к и р. Не стоит, пүчтәк ул, не стоит...

Л и л и я. Мин шат, мин бик шат. (*Күзләре дымлана.*)

Ш а һ и я. Ахирәт, син нәрсә инде...

Л и л и я. Юк, юк, шатлыктан, шатлыктан... кебек...

Ш а к и р. Җәмәгать, без монда барыбыз да Лилиянең дуслары.

Ә х м ә т г ә р ә й. Мин хәтта туганы да!

Ш а к и р. Кысылмагыз әле. Әйдәгез, аның уңышлары, аның ак бәхете өчен!

Ш а һ и я. Әйдәгез! Бәхетле бул, дустым, тагын да, әгәр мөмкинлек булса...

Ә х м ә т г ә р ә й. Яшә, Лилия... (*Эчәләр.*)

Л и л и я. Әйдәгез, ашагыз, капкалагыз, балалар, хәзер чәй ясыйм.

Р ә ф и д ә. Алай гына бәхетле булып булса икән ул...

Ш а к и р. Бәхет, кызым...

Р ә ф и д ә. Сеңлем.

Ш а к и р. Әйе, әйе, сеңлем, шулдыр инде ул... Эшеңдә уңышларга ирешсәң, тормышың түгәрәк булса. Аннан, мондый юбилей бик сирәк кешегә эләгә.

Әхмәтгәрәй. Каргаларга гына.

Рәфидә. Нигә каргаларга?

Әхмәтгәрәй. Чөнки карга карганың күзен чукымый.

Шаһия. Үтерәсең, Әхмәтгәрәй абзый.

Шакир. Нәрсә әйтмәкче буласың шуның белән, әйт, әйт?

Лилия. Шакир, игътибар итмә. Аллага шөкер. Ә нәрсә? Казан уртасында бер дигән ике бүлмәле фатирым бар. Дача салырга хыялландым. Анысы да булды. Идел ярында. Ну, өен генә корып бетерәсе бар. Шакир Нигъмәтович булышса, анысы да... Нинди матур җирдә, җитмәсә...

Шакир. Юкка борчылма, Лилия. Моның урынына бер дигән йорт корырбыз.

Әхмәтгәрәй. Торыйк, торыйк, торналар, корыйк, корыйк, кодалар... Менә бу тост, ичмасам. Маладис, Шакир брат, әйдәгез, шуның өчен.

Лилия. Җизни!..

Шакир. Ә урыны искиткеч. Тау башына урнашкан оҗмах бакчасымыни! Тормыш түгел инде монда... просто мечта...

Рәфидә. Ә ярату?

Шакир. Нинди ярату?

Рәфидә. Китапча әйткәндә, мәхәббәт?

Әхмәтгәрәй. Менә терәде сезне бала...

Марсельеза. Кызым, булышма олылар белән...

Шакир. Мәхәббәт? Ярый, бераз гына сабыр ит, кызым... Әй лә, сеңлем, хәзер аңлатам.

Марсельеза. Ашап утырыгыз әле.

Әхмәтгәрәй. Син, Рәфидә, андый әйберләрне миннән генә сора.

Марсельеза. Башлады инде...

Әхмәтгәрәй. Шаулама, кортка. (*Рәфидәгә.*) Син яшь әле, мәхәббәте дә, чурты да, мурты да булыр. Иң мөһиме — тормышның кадерен белеп яшә. Гомер безнең бик кыска, аның һәр мизгеленең кадерен бел...

Лилия. Дурацкая философия.

Әхмәтгәрәй. Т-с-с-с, балдыз... Шуны бел, тормышның һәр мизгеленә куана алсаң — кеше буласың. Безнең тере килеш, исән-сау бу дөньяда йөрүебез үзе зур могҗиза.

Лилия. Булды, җизни. Әле син аракы да эч, диярсең.

Әхмәтгәрәй. Юк, әйтмим. Анысы кирәк түгел. Андый эшне һәркем үзе хәл итә.

Ш а к и р (*аракы салып*). Җәмәгать, мин дә бер сүз әйтим әле. Рөхсәтме?

Ә х м ә т г ә р ә й. Сорап торасың... Аракы салган кешегә һәрвакыт яшел ут.

Ш а һ и я. Рөхсәт, рөхсәт.

Ш а к и р. Менә, җәмәгать, без барыбыз дуслар, туганнар дияргә була. Менә кызымны да...

Р ә ф и д ә. Рәфидә...

Ш а к и р. Ничек Рәфидә?..

Р ә ф и д ә. Минем исем Рәфидә.

Ш а к и р. Әйе, Рәфидә кызым...

Р ә ф и д ә. Сеңлем...

Л и л и я. Кызым, олы кеше белән алай сөйләшмиләр.

Ш а к и р. Юк, юк. Миңа Рәфидә сеңлем кызым кебек якын, шуңа онытылып китәм. Белүегезчә, без Лилия белән күптәннән бергә эшлибез. Бер-беребезне беләбез. Мин редактор, ул җаваплы секретарь...

Ш а һ и я. Эчәбезме инде, юкмы, баш авырта.

Ә х м ә т г ә р ә й. Нинди эчү ди инде ул һаман?

Ш а к и р. Хәзер, хәзер, бүлдермәгез, зинһар өчен. Мин менә нәрсә әйтмәкче булам. Мин Лилия Газизовнаны бик ошатам, так-с, без бик якыннар... мин... мин аны... әйтик... яратам... һәм мин, Лилия Газизовна, сезнең кулыгызны сорыйм. Без бергә матур тормыш корыйк.

Ш а һ и я. Оһо, монда эш шаярудан узган.

Ә х м ә т г ә р ә й. Бәйрәм өстенә бәйрәм.

Ш а к и р. Ни дисең, Лилия?

Л и л и я. Минме... Мин... ничек инде... уйламаганда... Мин бит, Шакир Нигъмәтович, үзем генә түгел... Кызым Рәфидә бар... Марсельеза түтәй дигәндәй... Аннан соң син миннән яшьрәк тә бит әле...

Ш а к и р. Юк, Лилиям, мин синнән күпкә олырак күренәм... Ә Рәфидә... кызым, ни дисең?

Р ә ф и д ә. Миңа барыбер, миннән хәер дога. (*Читкәрәк китә.*)

Ш а к и р. Марсельеза әби, син?

М а р с е л ь е з а. Мин нәрсә, әй... бүген бар, иртәгә юк дигәндәй, бәхетле булыгыз... чебиләрем генә кая югалды...

Ә х м ә т г ә р ә й. Балдызны да кияүгә бирәм, Аллага шөкер, в конце де концов...

Ш а һ и я. Синең дөньяң бөтенләй түгәрәкләнә түгелме, ахирәт?! Язмыш бер бирсә, бирә ул...

Ш а к и р. Йә, Лилиям, ни дисең?..

Л и л и я. Ни диим... карап карыйк...

Ш а к и р. Рәхмәт... Лилиям! Мин бик шат.

Ә х м ә т г ә р ә й. Вәт театр. Тагын бәйрәм итәсе була. Яратам да инде туйларны (*аракы эчеп*) фу, ачы бит бу, җәмәгать! (*Лилияне Шакир янына алып килеп бастыра.*) Ачы-ачы-ачы!

Шулчак Х ы я л килеп керә. Лилия белән Шакир үбешә алмый калалар.

Х ы я л. Исәнмесез...

Л и л и я. Сез кем?

Ш а һ и я. Исәнмесез, саумысыз! О-хо-хо, менә кунак.

Ә х м ә т г ә р ә й. Эх, нинди мизгелне боздыгыз. Инде...

Ш а к и р. Юк, җәмәгать, нинди бозу! Нәкъ вакытында! Бик мактап йөрисез икән. Шушындый зур бәйрәмгә! Ә! Язмыш үзе җибәргәндер сезне...

Ш а һ и я. Минем көткәнне белеп...

Х ы я л. Гафу итегез, минем сезнең мәҗлесне бозасым килмәгән иде.

Ш а к и р. Нинди бозу ди ул.

Х ы я л. Әйтегез әле, Лилия Газизовна дачасы шушымы?

Ш а к и р. Нәкъ өстенә бастыгыз, мактап йөрисез икән, урыныгыз түрдән булыр...

Х ы я л. Юк, мин...

Ш а һ и я (*аны култыклап*). Кадерле кунакның урыны иң акыллы, иң гүзәл хатын янында, ягъни минем белән булырга тиеш. (*Үзе янына алып китереп утырта.*)

Ә х м ә т г ә р ә й. Димәк, миңа развод? Менә ышан хатын-кызга.

Ш а һ и я. Соң, Әхмәтгәрәй абзый, алтын барында бакыр җыеп булмый.

Ә х м ә т г ә р ә й. Алдана күрмә!..

Ш а һ и я. Соңгысы булмас. О, чәчәкләр! Әллә миңамы?

Х ы я л. Гафу, ханым, минем... Исәнме... Исәнмесез, Лилия... Газизовна...

Л и л и я. Исәнмесез... Сезне...

Х ы я л (*чәчәкләрне биреп*). Бу сезгә... Котлыйм.

Л и л и я. Рәхмәт... Сезне таныган кебек тә итәм дә...

Х ы я л. Мин сезне...

Ш а к и р. Аңлашулар соңыннан, ә хәзер...

Х ы я л. Мин бер генә сүз...

Ш а к и р. Юк, юк, сезгә сүз бирә алмыйбыз...

Ә х м ә т г ә р ә й. Ну, сөйләсен инде кеше, в конце концов! (*Читкә үк китеп утыра, тарта.*)

Ш а к и р. Юк, башта болай итәбез. Әхмәтгәрәй абзый, бүген үзең беләсең, минем көн, мин җитәкчелек итәм. Җәмәгать, соңга калган кунакка нәрсә?

Ш а к и р. Каткан сөяк.

Ш а һ и я. Юк, ну инде, ну...

Л и л и я. Штрафной, стакан тутырып...

Ә х м ә т г ә р ә й. Стакан?!

Ш а к и р. Өстенә бастың, Лилиям. (*Аракы сала.*) Штрафной! Мәле, туган, шушы күз яшедәй мөлдерәмә ризыкны әйләндереп, печатен күрсәтеп куй әле.

Х ы я л. Ничектер уңайсыз килеп чыкты әле...

Ш а һ и я. Бер дә әллә ничек түгел, бик матур килеп чыкты.

Х ы я л (*Лилиягә*). Сезнең исәнлеккә, бәхетле булыгыз!

Л и л и я. У-у, болай да ташып тора бүген.

Ш а к и р. Ә кеше тагын да күбрәк тели, то есть безгә, матур яшәсеннәр, ди.

Ш а һ и я. Бер Ходай беләдер инде анысын.

Х ы я л. Алайса, үзегезнең изге теләгегезгә ирешүегезне телим. (*Эчә, яртылаш калдыра.*)

Ш а к и р. Ә-ә-әй, туган, бу мыскыл итү. Яртылаш теләк как имгәк. Төбенә кадәр... җәмәгать, булышыгыз...

Б а р ы с ы  д а. Пей до дна, пей до дна... (*Хыял эчеп бетерә.*)

Л и л и я. Менә, ичмасам! (*Көлә.*) Мине чын күңелдән якын иткән, хөрмәтләгән кеше икәнсез.

Ш а к и р. Стаканыннан күренә.

Ш а һ и я. Шулай булмыйча. Ир-егет, егетләрнең егете. Каяле, шуның өчен. (*Битеннән үбеп ала.*)

Л и л и я. Чыннан да, мин сезне каядыр күргән кебек булам. Ә-ә, исемә төште. Вәт баш, үзем интервью алган, аның турында зур мәкалә язган кешене танымыйм бит, ә?! Исемә төште. Гафу итегез, мин сезне танымый торам.

Ш а к и р. Лилия, сине бүлдерәм...

Л и л и я. Туктап тор, Шакир Нигъмәтович... Дуслар, менә шулай көтмәгәндә, белеп тә бетермәгән кешенең сине котлап керүе... бу инде... Мин бит аның хакында бары язып кына чыкканмындыр. Бу инде...

Ә х м ә т г ә р ә й. Дөнья булгач, төрле хәлләр була.

Ш а к и р (*аңа кушылып*). Әйе, җәмәгать, бу, беләсезме, нәрсә?! Бу искиткеч хәл! Хөрмәтле Лилия Газизовнаның эшенә, аның бу бәйрәменә, җиңүенә өндәү билгесе! Бу, җәмәгать, халык тануы! Лилия — халык язучысы! Афәрин, иптәшләр!

Х ы я л. Сез... болай бит әле ул...

Ш а к и р. Стоп, тукта, туган. Синең тыйнак кеше икәнеңне аңладык. Гафу үтенеп вакланма. Монда бар да аңлый торган кешеләр, җәмәгать! Лилиянең тагын бер уңышы өчен тост. Урра!

Ә х м ә т г ә р ә й. Кара, Шакирҗан, син дә ничава егет икәнсең бит! Әйдәгез әле, тост!

Ш а һ и я (*Хыялга*). Әйдәгез, дускай! (*Аңа гына.*) Мин барыбер сезнең өчен эчәм, ярыймы?

М а р с е л ь е з а. Бигрәк күңелле дә инде, ашагыз инде, балалар. Тавыгыннан авыз итегез...

Ш а һ и я. Мин дә тел селкетеп карыйм әле. Җәмәгать, әйдәгез, Лилияне җырлатабыз!

Л и л и я. Сез нәрсә инде, кичә дә җырлый-җырлый...

Ш а к и р. Юк, юк, Лилия. Менә яңа кеше дә ишетсен әле сандугач тавышын...

Х ы я л. Минем Лилиянең җырлаганын ишеткәнем бар.

Ш а к и р. Оһо, менә ничек? Синең моңны хәтта халык белә. Браво! Болай булгач, бигрәк тә... җәмәгать, сорыйбыз...

Б а р ы с ы  д а. Сорыйбыз, сорыйбыз.

Х ы я л. Лилия, чынлап та, яшь чактагы шикелле...

Ш а к и р. Яшь чактагы шикелле? Син нәрсә, туган? Лилия хәзер дә унсигез яшьтәге шикелле...

Л и л и я. Кая инде ул... Кайтарып булса иде... Ярый, җырлап карыйк... (*Җырлый.*)

Алтынланып тулган ай сагышын
Иделкәйгә иелеп чайкады.
«Кояш, бәгърем, бер күрсәм дә бәхил»,—
Тик кояш юк, ялгыз ай калды.

Алтынланып тулган ай сагышын
Сөзеп эчте Акбүз байталым.
Йөрәгемә сыялмыйча, һай, сагышым,
Айлы күкне сызып айкады.

Алтынланып тулган ай сагышын
Күтәралмам аем, һай, сузма.
Күңелемдә ташый моң-сагышым,
Йөрәгемдә уйлар сыр сыза...

Х ы я л. Искиткеч! Рәхмәт, Лилия.

Ә х м ә т г ә р ә й. Эх, балдыз, үзәгемне өзәсең. Җырлаганда, нәкъ апаңны хәтерләтәсең. (*Күзе яшьләнә.*)

Р ә ф и д ә. Әхмәтгәрәй абзый, ягез инде... сез олы кеше бит...

Ш а к и р. Молодец, Лилиям. Афәрин!

М а р с е л ь е з а. Моңлы җырлыйсың шул син, кызым, моңлы... әй дөньясы, дөньясы...

Ш а к и р. Әби, яшь чагыңда әллә син дә яраткан иденме?

Л и л и я (*Хыялга*). Йөзегез шундый таныш, искә генә төшерә алмыйм.

Хыял. Сез мине дөрес кабул итмәдегез, сез мине бутыйсыз. Мин...

Шакир. Чыннан да, кайчаннан бирле утырабыз, танышкан да юк. Үзегез яхшы кешегә дә охшагансыз...

Әхмәтгәрәй. Өч көн үткәч, исәнме кодагый шушы буладыр инде...

Хыял. Зыян юк, зыян юк...

Лилия. Аңламадым, ничек инде... бутыйсыз, дисезме?

Хыял. Мин — Хыял... Гомәров Хыял...

Лилия. Хыял?

Шаһия. Бигрәк матур исем, хе-хе... Хыял... Ә менә мин — Шаһия...

Хыял. Әйе, Хыял... Хәтерли алмыйсызмыни?.. Бер егерме биш елга кире кайтып карагыз. Яшь чаклар... хехе. Әле мине гел Хыялый Хыял Хыялович дип үрти идең!

Лилия. Ә-ә-ә? Х-х-хыял?! Бу-бу... син?! Ышана алмыйм... Хыял... (*Хәлсезләнеп егыла башлый, Хыял аны тотып кала.*)

Хыял. Су, зинһар өчен.

Әхмәтгәрәй. Менә сиңа кирәк булса. (*Эчеп куя.*)

Шаһия. Нашатырь кирәк. Рәфидә, өйдән, тизрәк...

Рәфидә. Хәзер. (*Йөгерә.*)

Шакир. Менә сиңа... ни булды... аңламыйм. Әйбәт кенә утырганда... (*Лилия янына иелә.*)

Хыял. Лилия, Лилия. (*Көчләп су эчерә.*)

Рәфидә (*нашатырь биреп.*) Мәгез!

Шакир (*нашатырь иснәтеп*). Лилия!..

Лилия күзен ача.

Аллага шөкер.

Хыял. Гафу ит, Лилия...

Лилия (*көчкә*). Юк, юк, бар да әйбәт...

Хыял. Мә, тагын су кабып куй...

Лилия. Миңа әйбәт, әйбәт...

Шакир. Селкенмә, сиңа борчылырга ярамый...

Лилия (*торып*). Миңа әйбәт... Хыял... Менә син хәзер нинди... олыгайгансың... ә мин сине танымадым да... Хыял... Хыял...

Хыял. Егет үзе картаймаса...

Лилия. Әйе, аны дөнья картайта...

Шакир. Гафу ит, Лилия. Ә шулай да кем дип белик бу кешене?

Лилия. Син ачуланма, Шакир Нигъмәтович, соңыннан, яме, соңыннан. Хыял — минем яшьлек дустым.

Шакир. Юк, юк, син борчылма, мин аңлыйм...

Л и л и я. Берни дә юк, күптәнге вакыйга инде...

Ш а к и р. Ярый, ярый, таныш булыйк. (*Хыялга.*) Мин — Шакир Нигъмәтович, газетада редактор...

Х ы я л. Хыял.

Ә х м ә т г ә р ә й. Ә мин, понимаете ли, шушы тирә-якның җәнлеге, кушаматым — аю, хе-хе-хе.

Ш а һ и я. Ягез әле, ник карап каттың, яңа килгән кешене уңайсыз хәлгә куйдык.

Х ы я л. Зарар юк, борчылмагыз.

Л и л и я. Ә, әйе, әйдәгез, өстәл янына, минем җебегәнлеккә карамагыз... Бар да үтте. (*Ачылып китеп.*) Бииммe, җырлыйммы? Ә-әй! (*Биеп, сикергәләп ала.*)

Ш а к и р. Чыннан да, җәмәгать, утырышыгыз. Бәйрәм дәвам итә.

Ш а һ и я. Хыял Хыялович! Мечта! Прошу ко мне! (*Аны сөйрәп үз янына утырта.*) Сез хәзер минеке. Каптыгыз. Әле мин пешергән ризыкны да татып карасагыз, чумасыз, минем сазлык сезне үзенә ала.

Х ы я л. Минем, гафу итегез, бер генә сүзем бар иде.

Ш а к и р. Әйтерсең, дускай, әйтерсең. Син бит бу тантананың ике башлы икәнен белмисең. Бу безнең...

Л и л и я. Шакир, ярар инде...

Ш а к и р. Юк, Лилиям, белсен нинди олы мәҗлестә утырганын. Хыял дус, бу Лилия юбилееның дәвамы.

Ш а һ и я. Койрыгы, диген инде, ниткән дәвамы...

Ш а к и р. Бүлдермә, Шаһия. Бер үк вакытта Лилия белән безнең...

Х ы я л. Гафу итегез! Мин сезнең бу бәйрәмегезгә ялгыш эләккәнемне дә аңлыйм. Минем мәҗлесне бер дә бозасым килмәгән иде.

Ш а к и р. Ниткән бозу...

Х ы я л. Лилия, мин сине тагын бер кат чын күңелдән юбилееӊ белән котлыйм. Синең белән күзгә-күз генә сөйләшәсем килгән иде, булмады.

Л и л и я. Әйе, тыңлыйм, Хыял...

Х ы я л. Менә нәрсә: мин бик күпне күрдем, бик нык-лап иләндем бу тормышта. Беләм, синең алда минем гаебем чиксез зур. Кыскасы, ассаң — ас, киссәң — кис дигәндәй, мин сине алып китәргә кайттым, әгәр син риза булсаң.

Ш а к и р. Нәрсә?!

Л и л и я. Ничек?

Х ы я л. Зинһар өчен, Лилия, уйлап җавап бир... ашыкма. Бөтен кеше алдында әйтәм, миңа синсез авыр...

Ш а һ и я. Вот это да! Менә бу, ичмасам, тамаша! Бәхет килсә дә килә! Сайла, Лилюк.

Ә х м ә т г ә р ә й. Бик кызыклы факт. Кияүлеккә икенче кандидат. Чиратта кем...

М а р с е л ь е з а. Шамакайланма... Инде исергән...

Л и л и я. Мин... Ничек инде... Син... чынлапмы, Хыял?..

Х ы я л. Чын, ихластан, Лилиям!..

Л и л и я. Мин... ни диим... юк, син хыялый... (*Сулкылдап.*) Миңа авыр... Минем бит тормышым бар. Кызым... бүтәне... (*Өстәлгә каплана, елый.*)

Ш а к и р. Син ни сөйлисең, Лилия? Мине, мине соң, оныттыңмыни? Без бит килешкән идек?.. Шулай бит, әби? Рәфидә?.. Шаһия?..

М а р с е л ь е з а. Мин сезне белмим. Ай балалар, балалар! (*Рәфидәгә.*) Ник карап каттың? Әнә урыныңны җый. (*Куа. Рәфидә китә.*) Сезнең белән чебиләрем ачка үлә, чеп-чеп-чеп-чеп.

Ш а к и р. Тә-әк, гражданин. Сезнең монда рөхсәтсез килеп керүегез җитмәгән, бөтен дөньяны болгаттыгыз!

Х ы я л. Аңламыйм, монда сезнең ни катнашыгыз бар?

Ш а к и р. Ни катнашым бар? Ишеттегезме, ни ди? Минем ни катнашым бар?! Колагыңа киртләп куй, син, дөнья болгатучы килгәнче, без Лилия ханым белән ярәшелдек! Бу безнең кушылу мәҗлесе. Мин Лилияне яратам, аңлыйсызмы, яратам.

Х ы я л. Миңа да ул чит түгел. Ә ул үзе сезне яратамы?

Ә х м ә т г ә р ә й (*ромашка йолкып*). Любит, не любит. Йә болай, йә тегеләй. Тфү! Нинди мужиклар сез, бер хатын өчен талашасыз. Әй, чукынышып бетегез! (*Башланган шешәне эләктереп, тау астына китә.*)

Ш а һ и я. Шакир Нигъмәтович, әйдә, төкер барысына!

Ш а к и р. Кысылма! Алаймы? Алайса — вон моннан, хәзер үк извольте — вон!

Л и л и я. Шакир Нигъмәтович...

Ш а к и р. Юк, Лилия, әле ул килеп сине ушыңнан яздыруы җитмәгән, сине елата! Кайда диген? Безнең җирдә, безнең бакчада. Вон! (*Хыялны төртеп җибәрә.*) Хәзер мин сине яр астына ыргытам. (*Ул килеп ябышкач, Хыял аны әйләндереп сала*).

Л и л и я (*елап*). Туктагыз, зинһар өчен, дим...

Ш а к и р. Син, син мине... мин сине моның өчен...

Л и л и я. Шакир бәгърем, алтыным, бар кайт, зинһар өчен...

Ш а к и р. Ничек?.. Миңа?.. Кайтырга?..

Ш а һ и я. Шакир Нигъмәтович, әйдәгез китик.

Ш а к и р. Димәк, ул кала, мин китәм? Оригинально!

Ш а һ и я. Лилия, рөхсәт ит, мин аны үзем белән алып китәм.

Л и л и я. Алла хакына, зинһар өчен.

Хыял читтәрәк басып тора.

Ш а к и р (*Хыялга*). Син, син кабахәт, минем бөтен планнарымны боздың.

Шаһия белән Лилия аны тоталар.

Беләсеңме, мин сине моның өчен... Күрерсең күрмәгәнеңне...

Ш а һ и я. Күзлегегезне, күзлегегезне саклагыз, Шакир Нигъмәтович...

Л и л и я. Шакир Нигъмәтович, зинһар өчен... Йа Аллам...

Ш а к и р. Син мине куасың? Шушы килмешәк, әтрәкәләм хакына куасың...

Л и л и я. Шакир, дим!..

Ш а к и р. Яхшы... Тик белеп тор, мин моны болай гына калдырмыйм...

Л и л и я. Ярар, ярар, тик кит, зинһар өчен.

Ш а к и р. Ярармы? Яхшы. Минем кулдан ни килгәнен беләсең: иртәгә үк мин сине... менә күрерсең... Секретарь түгел, бөтенләй редакциядән үк... Вон...

Л и л и я. Яхшы, яхшы... (*Елый*.)

Ш а к и р. Яхшымы?! Син себерке, син... Бөтен планнарымны җимердең... Себерке... син...

Х ы я л (*ярсып*). Син сөйлән, ләкин чамаңны бел...

Ш а һ и я. Шакир Нигъмәтович, әйдәгез китик. (*Читкәрәк алып китеп*.) Безгә кайтырбыз. Минем общагам иркен, тәмле әйберләр пешерермен, коньяк та, ак та бар. Бар да бар, әйдәле!

Ш а к и р. Әй, кит әле моннан. (*Шаһияне этәреп җибәрә*.) Кит әле! (*Хыялга*.) Хәзергә син көчле, тик мактанма, без әле очрашырбыз.

Х ы я л (*Шакирга*). Хайт! (*Шакир чигенә*.) Ярый, бар, очрашкач сөйләшербез.

Л и л и я. Булды инде сезгә...

Ш а һ и я. Әйдә, Шакир Нигъмәтович...

Ш а к и р. Әй, кит әле моннан. (*Китә башлый*.) Ярый, Лилия Газизовна. (*Китә*.)

Ш а һ и я. Шакир Нигъмәтович, Шакир... (*Артыннан йөгерә*.)

Х ы я л. Гафу ит, Лилия, болай күңелсез очрашасы килмәгән иде.

Л и л и я. Гафу, гафу... Бер мизгелдә бөтен тормышымны җимердең, бер дигән, корылган тормышны...

Х ы я л. Ачуланма, алайса, мин дә китеп торыйм.

Л и л и я. Китүе ансат ул. (*Мышкылдый.*) Бары да кырылды... Син бит икенче тапкыр җимердең...

Х ы я л. Лилия.

Л и л и я. Ярый, дәшмә... Тыңлама минем шыңшуны... Телем генә сөйли аны, күңелем түгел... җимерелсен, язмыш эшедер... Мин бит син юньсезне гомерем буе...

Х ы я л. Лилиям. (*Кочаклап ала.*) Бәгърем...

Л и л и я. Хыялым! Минем Хыялым!.. Чыннан да синме бу?

Х ы я л. Әйе, Лилиям. Мин сиңа гомерем буе килдем. Без хәзер мәңге бергә...

Л и л и я. Рәфидә, кил әле.

Х ы я л. Син борчылма, ул минем үз кызым кебек булыр.

Л и л и я. Эх, син!.. Ул бит синең...

Х ы я л (*сискәнеп*). Ә-ә-ә? Ничек?

Р ә ф и д ә килә.

Л и л и я. Кызым, моңарчы яшереп йөрткәнгә гафу ит, бу кеше — синең әтиең.

Р ә ф и д ә. Ничек?

Л и л и я. Ягез, аптырап тормагыз, исәнләшегез...

Р ә ф и д ә. Ничек? Сез минем ә-ә-ә-ти-и?.. Ә-ә-әти?..

Караңгылык төшә.

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук күренеш. Кич. Сагышлы тынлык. Күктә ай йөзә, йолдызлар җемелди.

Х ы я л. Син миңа үпкә сакламыйсыңмы инде, кызым?..

Р ә ф и д ә. Юк, әткәй. Саклап ни файда. Син үзең дә белмәгәнсең бит. Просто, бераз, элеккеге балачак өчен, кимсетелүләр өчен күңел кителеп калган. Эх, минем дә әтием булсачы, дигән вакытлар күп булды.

Х ы я л. Син мине кичерергә тырыш инде, кызым.

Р ә ф и д ә. Юк, юк, әткәй. Мин сиңа бернинди дә үпкә сакламыйм. Синең гаебең юк. Соңлап булса да әтиле булу — үзе бер бәхет.

Хыял. Кызым минем... Аның урынына мин сине менә хәзер беркемнән дә кимсеттермәм...

Рәфидә (*көлеп*). Сез, олы кешеләр, бигрәк беркатлы инде. Әллә шулай күренәсез генәме? Мин бит инде үзем зур кеше.

Хыял (*Рәфидәне кочып*). Син минем өчен бала гына әле, бәбием. (*Сөя.*)

Рәфидә. Әйе, бәби, синең буе. Юк, әткәй, мин инде олы кеше... Минем үз уйларым, үз тормышым булырга тиеш.

Хыял. Анысы дөрес... Менә укып бетердең. Аспирантурага керергә теләк юкмы?

Рәфидә. Юк, әти. Укырга чакыралар, теләмим. Нәрсәгә икәнлеген үзең аңлыйсыңдыр. Хәзерге көндә нинди белем алыйм.

Хыял. Анысы шулай инде...

Рәфидә. Минем үз планнарым.

Хыял. Тартынмасаң, уртаклаш...

Рәфидә. Ачуланма, әти, әлегә сиңа әйтә алмыйм. Әни аша, яме?..

Хыял. Яхшы, кызым.

Арттан Лилиянең килгәне күренә.

Рәфидә. Әти, ә нигә синең исемең Хыял? Бик кызык бит, хыял, мечта...

Хыял. Үзем дә тинтерәдем инде ул исем белән. Әти эше ул. Мин туганчы өч кызлары булган. Әти гел малай турында хыялланган. Әни әйтүенә караганда, шуннан мин тугач, әти тоткан да Хыял исеме куйдырган. Менә шул.

Рәфидә. Нигә?.. Бик матур, романтичный исем.

Хыял. Шул шул, кызым, исемем генә Хыял, ә үзем — сазлык.

Рәфидә. Ярый, әти, мин керим.

Хыял. Рәхмәт, кызым.

Рәфидә. Ни өчен?

Хыял. Мине чит итмәвеңә...

Рәфидә. Юкка, әти... (*Кочып ала.*) Ничек чит итим инде. Тик, әти, без барыбер... ярый... Ә төн нинди матур, әти...

Хыял. Әйе, кызым.

Лилия. Нәрсә серләшәләр болар? (*Икесен дә арттан кочаклап ала.*)

Хыял. Төне искиткеч, әнисе. Эх, сез күз алдына да китерә алмыйсыз. Мин бүген шундый бәхетле. Бүген минем иң матур көнемдер.

Рәфидә. Төнем, диген.

Хыял (*аны иркәләп*). Төнем... Без бергә... Шундый бакча эчендә... Табигать бу очрашуны шәхсән үзе оештырган кебек. Ә төне... Әкияттәге кебек. Лилиям, чемет әле, төш түгелме икән?!

Лилия. Йом күзеңне. (*Үбеп ала.*) Каты чеметтемме? (*Көлә.*)

Хыял. Бик каты. Төш түгел икән. Күпме генә кирәк кешегә бу дөньяда, ә?..

Рәфидә. Миңа бик күп кирәк.

Лилия. Яшьләргә шулай. Яшь чагында шулай инде ул, тормыштан әллә нәрсәләр көтәсең...

Рәфидә. Көтмим, ә ирешәм, менә күрерсез. (*Хыял белән Лилия көлешәләр.*)

Хыял. Әлбәттә, ирешерсең...

Рәфидә (*каршыларына басып*). Ә сез шундый пар килгәнсез, абыйлы-сеңелле кебек.

Лилия. Ә син безгә охшамаганмы?

Рәфидә (*бәби булып*). Охшаган, ярты битем — әни, ярты битем — әти.

Лилия. Ярый, кызым, син кереп ят, вакыт соң.

Рәфидә. Ә сез?

Лилия. Без дә озакламабыз. Азрак сөйләшәбез дә. Чоланга керербез, урын җәеп куй, яме?

Рәфидә. Яхшы, тыныч йокы.

Хыял. Тыныч йокы, кызым.

Лилия Хыялны кочаклап, янына утыра.

Лилия. Менә миңа да чират җитте.

Хыял. Әйе, көне буе буталабыз, бергә утырып сөйләшә дә алган юк.

Лилия (*Хыялны капшап*). Синме соң бу, Хыялым?

Хыял. Мин, төнбоек чәчәгем.

Лилия. Яшь чакларда син мине гел төнбоек дип иркәли идең. Гүя яшь чагыма кайткандай булдым.

Хыял. Мин дә. Эх, кире кайтарып алып булса...

Лилия. Үкенмә, Хыял бәгърем. Мин хәзер бернигә дә ышана алмыйм. Менә хәзер дә сине югалтудан куркып утырам.

Хыял. Җүләрем. Курыкма. Мин сине беркемгә дә бирмим.

Лилия. Мин бигрәк үземнән куркам. Уйларым керәле дә чыгалы.

Хыял. Минем көчемә таянырсың, беләкләр бирешми әле.

Лилия. Күпме еллар үтте, күпме сулар акты.

Х ы я л. Лилия, нигә син миңа бала бар икәнен хәбәр итмәдең?

Л и л и я. Ничек әйтим?.. Баштарак синең юлыңа киртә буласым килмәде, аннан синең гаиләң булды...

Х ы я л. Гаилә, юл... Әйе, кем белә бит ничек килеп чыгасын.

Л и л и я. Син Мәскәүгә укырга киткәч, ничек дәвам итте соң синең тормыш? Мин синең хакта шулкадәр аз беләм...

Х ы я л. Мин синең алда бик тә гаепле, Лилия...

Л и л и я. Ташлале, Хыял. Булган — беткән, кире кайтарып булмый. Сөйлә инде...

Х ы я л. Шулай да... Әгәр син мине шул вакытта туктатып калган булсаң... Хет бала була, дип куркытсаң... Син дә инде... Синдә дә гаеп бар анысы.

Л и л и я. Бар, Хыялым, бар...

Х ы я л. Нигә туктатмадың, ә?

Л и л и я. Эх, бәгърем! Мин бит сиңа изгегә табынган кебек табындым. Бигрәкләр яратканмын инде мин сине.

Х ы я л. Лилиям!

Л и л и я. Баштарак гел бергә булырбыз, гаилә корырбыз кебек иде. Аннары синең бик яхшы укыганыңны күреп, укуыңны теләдем, зур кеше итеп, талант иясе итеп күрәсем, горурланасым килде, хәтта... мактанасым. (*Көлә.*)

Х ы я л. Әйе, миңа зур өметләр багладылар ул чакта...

Л и л и я. Син Мәскәүгә киткәч, синең белән горурланып яшәдем. Зур кеше булып миңа әйләнеп кайтырсың кебек тоелды... Ләкин...

Х ы я л. Эх, юлымны бүлгән булсаңчы шул чакта...

Л и л и я. Кем белгән бит. Бәхетеңне кулдан бер дә ычкындырып карарга ярамый икән ул... Аннан синең өйләнгәнеңне ишеткәч, эчтән генә, күңелемдә генә сөя башладым, хе-хе, төшләремдә еш күрә идем.

Х ы я л. Лилиям, мин мең тапкыр гаепле...

Л и л и я. Юк, Хыялым, язмышка шулай язылгандыр. Хе-хе. Газета битләрендә синең исем чалынганда, куанып бетә алмый идем. Үзем комачаулап, сине шул зур эшеңнән бүлмәвемә шатландым. Синең кызыңны үстерү горурлык бирде.

Х ы я л. Юкка, Лилиям...

Л и л и я. Нигә алай дисең?

Х ы я л. Әйе, киттем мин укырга. Әйбәт укыдым. Күрдем, укып кына бу дөньяда беркая да эләгеп булмаганын. Кызып китеп, профессор кызын да эләктердем.

Л и л и я. Чибәрлек бар иде инде анысы...

Хыял. Фәннәр кандидаты булдым. Профессор озак тормады, дөнья куйды. Ярдәм бетте. Профессор кызы акча яратты. Баштарак шабашкага йөрдем. Аннан үз эшемне ташлап, бөтенләй зур сәүдә эшләре йөртә башладым...

Лилия. Яраткан кеше өчен ниләр эшләмәссең.

Хыял. Юк, яратмый идем мин аны.

Лилия. Ник, алай булгач, ташлап китмәдең? Ә-ә, балалар...

Хыял. Юк, Лилиям, эш анда түгел... Балалар да булмады безнең. Баштарак, профессор гаиләсенә кергәч, баш идем, аннан хатын үзе иярләп алды, соңга таба кара эшләрем белән кысып алды, куркытып яшәде...

Лилия. Эх, Хыял, син бит элек бик кыю идең...

Хыял. Дөнья иманыңны өшкерсә, тез асты йомшара икән ул. Аннан узган ел хатын да үлеп китте...

Лилия. Ничек?

Хыял. Машинасы белән бәрелеп. Мин бит сине күптән күрергә хыялланып яшәдем.

Лилия. Мескенем...

Хыял. Көлмә, Лилиям...

Лилия. Көлмим, чыннан. Бигрәк мескен күренденң син хәзер миңа, Хыялым...

Хыял. Ул дөнья куйгач, ничек итеп сине күрергә, дигән уй баштан чыкмады. Актарына торгач, туган көнең белән котлап язган, әмма җибәрелмәгән открытка килеп чыкты. Шуннан соң юбилейга хәтле түзәргә, кисәк кенә килеп чыгарга уйладым.

Лилия. Эффектлырак булсын, әйеме?

Хыял. Анысы да булгандыр.

Лилия. Мин һуштан язарлык булгач инде. Куандыңмы?

Хыял. Нәрсәгә?

Лилия. Һуштан язгач... Үзеңне хәзер дә яраткан кешене күрү кызыктыр ул.

Хыял. Лилия!..

Лилия. Ярый, бетте, бетте, әй минем мескен хыялым. Ә дачаны ничек таптың?

Хыял. Мин кичә үк килгән идем инде... Тел Киевка кадәр җиткерә, диләр бит, эзли торгач, таптым...

Лилия. Рәхмәт!

Хыял. Ни өчен?

Лилия. Эзләп табуың өчен. (*Күңеле тулып.*) Сине күрми үлеп китәрмен, дип курка идем. Сине бер күрсәм дә, бөтен дөньям түгәрәкләнер кебек иде. Инде менә күрдем...

Хыял. Йә, йә, булды... Мин сине хәзер бер дә ташламам.

Лилия (*башын сыйпап*). Ә син бик таушалгансың...

Хыял. Син юк. Син һаман да элеккеге күл гүзәле — төнбоек.

Лилия. Рәхмәт. Мин сине таный да алмадым, ачуланма.

Хыял. Юк сүз. (*Пауза.*) Лилия, ә бу адәм чыннан да синең ирең булырга тиеш идеме?

Лилия. Әйе...

Хыял. Син аны яраттыңмы?

Лилия. Ярату дөньяда бер генә була диләр түгелме?

Хыял. Алай булгач, ник кияүгә чыгарга риза булдың?

Лилия. Әйтеп тә тормас идем, күңелеңдә шик калмасын. Мин аның белән күп тарткалаштым. Аннан (*көлеп*) илледә булса да, бер кияүгә чыгарга кирәктер бит.

Хыял. Ничек? Ул сиңа басым ясадымы?

Лилия. Ясады, дип, ялгыз хатынга авыр бит бу дөньяда, бигрәк тә дөресрәк яшим дисәң. Мин аңа ягымлырак булдым, ә ул миңа булышты...

Хыял. Бу бит... ничек син, Лилия...

Лилия. Ничек син? Син ничек яшәдең гомерең буе?.. Шулай шул, кешене гаепләү генә җиңел ул. Соңга табарак өйләнәм дә, ди башлады... Алай артык иркәләмәдем дә инде үзен...

Хыял. Ә гаиләсе?

Лилия. Аңа тагын. Күптән хатынсыз... безнеңчә — бабник.

Хыял. Син шуннан карышмадың инде...

Лилия. Ничек карышыйм. Анда көч. Ул редактор. Бер уйлаганда, миңа аның белән булу кулайрак та...

Хыял. Лилия...

Лилия. Тыңлап бетер. Мин үземнең урынымны, эшемне таптым, тора-бара дәрәҗәгә ирештем. (*Көлә.*) Менә китабымны чыгарабыз, дигән иде, инде булмастыр... Болар азмыни?..

Хыял. Аннан башка дуслар да булгаладымы?

Лилия. Дөнья бит, тормыш юллары катлаулы...

Хыял. Яратам, дисең. (*Ярсып китеп.*) Ничек итеп соң син... Күп нәрсәгә ирешкәнсең, алайса... Беләсеңме, болар барысы да чүп — дәрәҗә, гәҗит, тфу!

Лилия. Йә, йә, кызма... Бәлки. Ә шундый галәмәт юбилей оешуны ни дисең? Дөресен әйткәндә, болар минем төшемә дә керми иде...

Хыял (*тагын да кызып*). Юбилей... Анысы да... Ул

«очкарик» сине алдау, йомшарту өчен юри барын да күпертә. Дөнья кырдым дип яшәмә.

Л и л и я. Син кырдыңмы алайса?

Х ы я л. Мин... Сиңа бит болар берсе дә кирәкми. Сиңа бит мин кирәк идем. Күңелеңдә мин яшәдем. Нигә үзүзеңне алдыйсың?

Л и л и я. Ярый, ярый, кызма. Кара, нинди утка әйләнде, ә?! Егет! Мин синең фикерең белән риза түгел. Мин үз сүземдә калам. Мин күп нәрсәгә ирештем.

Х ы я л. Гафу, Лилиям, кызып киткәнмен. Бәлки, син дөрестердер дә...

Л и л и я. Хыялым! Син минем күңелемә гел яшь, чибәр, үз көченә нык ышанган, акыллы, батыр булып кереп калгансың. Мин еллар буе сине шул килеш яраттым. Сине гел шундый итеп күз алдына китерә идем, ә чынында...

Х ы я л. Нишлисең, тормыш...

Л и л и я. Барыбер... Мин бүген бик бәхетле...

Х ы я л. Лилиям! (*Кочаклап үбә. Озак кына шулай торалар.*) Әйдә, чарлакка. (*Лилияне күтәреп ала.*)

Л и л и я. Ай, төшерә күрмә... Мин авыр.

Х ы я л. Үлгәндә дә...

Л и л и я. Ничек рәхәт. Мин очам.

Х ы я л. Мин сине... (*Күтәреп артка китә.*)

Ут сүнә.

Кояшлы кызу көн. Сәгать уникеләр тирәсе. Бөтен тереклек эсселектән куырылган. Халат кигән, башына ак яулык бәйләгән Л и л и я ботакка эленгән читлектәге кошка җим биреп, аны сайратмакчы була. Бүген аның кыяфәтендә кичәге тантананың төсе дә юк.

Л и л и я. Йә инде... йә, берәр сайра инде... (*Сызгырып карый.*) Чут-чут-чут... Йә инде, кошчыгым... Ашатып та карадым инде үзеңне... Сайрамыйсың...

Идел ягыннан Р ә ф и д ә менеп килгәне күренә.

Л и л и я. Нигә үзең генә?

Р ә ф и д ә. Уф, арыдым. Әти пристаньда калды... Анда Әхмәтгәрәй абзый да йөри.

Л и л и я. Кайтып китмәгәнмени әле?

Р ә ф и д ә. Юк. Әни, кичә сөйләшеп булмады. Сиңа сүзем бар иде.

Л и л и я (*кош белән булышып*). Тыңлыйм...

Р ә ф и д ә. Куй инде шул чыпчыгыңны...

Л и л и я. Нишләп чыпчык булсын, кенәри бит ул, тик менә сайрамый гына.

Р ә ф и д ә. Читлектә сайрамас шул. Тыңла инде. (*Читлекне читкә алып куя.*)

Л и л и я. Йә, ни ишетербез икән?..

Р ә ф и д ә. Әни, мин кияүгә чыгам...

Л и л и я. О-о, кызым, ничек алай кисәк кенә...

Р ә ф и д ә. Әни, мин шаярмыйм.

Л и л и я. Тәк, ничек инде ул, ә?

Р ә ф и д ә. Шулай. Бу әле, әни, чәчәге.

Л и л и я. Җимеше дә бармыни?..

Р ә ф и д ә. Бар шул...

Л и л и я (*җитдиләнеп*). Тыңлыйм.

Р ә ф и д ә. Мин, әни, чит илгә китәргә тиеш булам.

Л и л и я. Ничек, кабатлале...

Р ә ф и д ә. Чит илгә...

Л и л и я. Ничек инде ул?

Р ә ф и д ә. Шулай. Ул Колумбия кешесе...

Л и л и я. Йа Алла, негр...

Р ә ф и д ә. Негр түгел, әни, португал канлы...

Л и л и я. Португал, негр... Син нәрсә сөйләгәнеңне аңлыйсыңмы, җүләр кызый?..

Р ә ф и д ә. Аңлыйм.

Л и л и я. Дәшмә, оятсыз. Миңа, әниеңә, шул турыда сүз катырга ничек батырчылык иттең? Беткәнме сиңа безнең татар егетләре. Һич югында, урыс булсын иде инде. Негр бит...

Р ә ф и д ә. Әни, син хаклы түгел, ул бик әйбәт.

Л и л и я. Әйбәт... Тагын яклап тора... Дәшмә! Хәзер үк әниеңнән гафу үтен, бүтән андый сүзне кабатламам, диген...

Р ә ф и д ә. Әни...

Л и л и я. Гафу үтен!..

Р ә ф и д ә. Гафу ит... Ләкин...

Л и л и я. Менә шулай. Бүтән миңа андый сүз ишеттерәсе булма. Нәрсә ләкин? Мин сине шул маймылга биреп җибәрер өчен үстердеммe? Оялмый да...

Р ә ф и д ә. Маймыл түгел, португал.

Л и л и я. Дәшмә дим...

Р ә ф и д ә. Тыңлап бетер инде, әни...

Л и л и я. Җүнле сүз булса гына сөйлә.

Р ә ф и д ә. Җүнле түгел.

Л и л и я. Алайса сөйләмә, бар, бар, өйгә кереп кит.

Р ә ф и д ә. Әни, минем аннан балам булачак.

Л и л и я. Нәр-сә?..

Р ә ф и д ә. Минем... аннан...

Л и л и я. Ах, оятсыз кыз... җир бит...

Р ә ф и д ә. Хәзер соң инде...

Л и л и я. Соң... Су, су бир... (*Рәфидә су алып килә.*) Ничек?

Р ә ф и д ә. Ул алты айлык...

Л и л и я. Негрмы?

Р ә ф и д ә. Португал малае...

Л и л и я. Ах, нишлим, уф, үтердең... Ай кызый...

Р ә ф и д ә. Юкка хәвефләнмә, әни, бар да әйбәт булыр...

Л и л и я. Дәшмә, ичмасам...

Р ә ф и д ә. Дәшмим, әни...

Л и л и я. Нәрсә тынып калдың, сөйлә...

Р ә ф и д ә. Ни сөйлим?

Л и л и я. Нинди кеше ул?

Р ә ф и д ә. Колумбиец, бездә укыды... Ну, таныштык. Әни, беләсеңме, ул искиткеч кеше. Ул бик күңелле, бик акыллы...

Л и л и я. Акыллыдыр шул...

Р ә ф и д ә. Менә үзең күрерсең әле...

Л и л и я. Негр да күрәсем бар икән әле...

Р ә ф и д ә. Португал.

Л и л и я. Шуны яраттың инде алайса?

Р ә ф и д ә. Белмим инде...

Л и л и я. Ничек: яратмадың да, китәсең дә... Ничек (*корсагына күрсәтеп*) булды соң бу, алайса?

Р ә ф и д ә. Булды инде, озак кирәкмени...

Л и л и я. Һай, оятсыз...

Р ә ф и д ә. Бүген ул мине алмага килеп җитәргә тиеш. Без монда кайтып китәрбез, әни. Аннан соң документларны эшләгәч, тегендә үк...

Л и л и я. Нәрсә? Син әле һаман да китәргә җыенасыңмы? Бетте, оныт... ул хыялыңны!

Р ә ф и д ә. Ә бала?

Л и л и я. Бер баладан үлмәбез...

Р ә ф и д ә. Әни, син мине бала-чагага санама, җитте.

Л и л и я (*елап*). Бала-чага... Син миңа гомер буе, үлгәнче бала... Мин сине берьялгызым, күкрәк сөтемне имезеп үстердем... Хәзер син мине, ялгыз анаңны ташлап китеп... Шул негрга алыштырасыңмы?!

Р ә ф и д ә. Португал.

Л и л и я. Бар, бар, сат газиз әниеңне...

Р ә ф и д ә. Әни, әнием... (*Еламсырап.*) Нигә алай итәсең инде? Мин бит сине яратам, әнием.

Л и л и я. Шушымы яратуың?..

Р ә ф и д ә (*әнисен кочаклап*). Әни, нишлим соң инде? Ул миңа ошый, балабыз да була. Үзең әйтәсең бит, ялгыз авыр, дип...

Л и л и я. Чит ил бит ул, чит ил.

Р ә ф и д ә. Булса соң. Монда калып, синең язмышыңны кабатлыйммы?

Л и л и я. Ни булган миңа?

Р ә ф и д ә. Булмаган, юкка куанып яшәгәнсең.

Л и л и я. Нигә юкка булсын? Зур газетада җаваплы секретарь, китабым чыгар, ә юбилей ничек узды... Дача салдым, фатирым бар...

Р ә ф и д ә. Тагын шул...

Л и л и я. Шул булмыйча. Әниеңне тикшереп утыр тагын, молокосос...

Р ә ф и д ә. Шуларга табынып, менә мин дә мескен булып яшимме? Ә бәлки, анда, читтә бүтәнчәрәк булыр. Монда мин ни эшли алам? Бу коллар җәмгыятендә? Минем ирекле буласым килә. Ә ярату... әгәр андый хис булса... бу илдә ул барыбер чын булмаячак. Колларның яратуы да колларча булачак.

Л и л и я. Тукта! Тукта... дим! Безнең хисләргә кагылма!

Р ә ф и д ә. Эх, әнкәй, әгәр колларча булмаса, берегез фән, дан өчен, дигән булып, икенчегез «башкача» изгелек саклап, шул яратуыгызга төкергән булыр идегезме? Ярату өчен көрәшергә кирәк!

Л и л и я. Тукта дим.

Р ә ф и д ә. Мин туктыйм... Ләкин бит, әни, тормыш элеккечә кала. Үзеңне алдама. Син аны үзгәртә алмыйсың. Ә минем бүтәнчә яшәп карыйсым килә. Кол булып түгел... бүтәнчә...

Л и л и я. Син аны яратасыңмы?

Р ә ф и д ә. Белмим, ләкин ул миңа ошый. Ә бүтәнчә мин бу үрмәкүч оясыннан чыга алмаячакмын.

Л и л и я. Мин нишләрмен? Минем турыда уйладыңмы?

Р ә ф и д ә. Син хәзер ялгыз түгел. Сайлый да аласың, теләсә кай...

Л и л и я. Кызым!

Р ә ф и д ә. Соң беренче мәхәббәтең кайтты бит.

Л и л и я. Сиңа эти ул.

Р ә ф и д ә. Әти... бик соңлап шул, әни, бик соңлап...

Л и л и я. Сине шулай итеп күрә дә алмам микәнни?

Р ә ф и д ә. Әни, йә, булды инде, елама. Язган булса, без кунакка кайтырбыз, ә сез безгә килерсез...

Л и л и я. Әй кызым, алай гына йөрешә торган җир түгел шул ул...

Р ә ф и д ә. Ярый, әни, калганы соңыннан. Мин шәһәргә, каршыларга барып кайтам. (*Керeп китә.*)

Л и л и я. Үстер инде бала дип...

Р ә ф и д ә (*чыгып*). Ярый, әни, пока.

Л и л и я (*аңа ябышып*). Җибәрмим, җибәрмим, кире кайтып китсен!

Р ә ф и д ә. Әни, шашма, хәзер берни эшләп булмый.

Л и л и я. Китсен, баланы да карарбыз, җибәрмим!..

Р ә ф и д ә. Әни, син мине тупас булырга мәҗбүр итәсең. (*Аны көчләп утырта, үзе кача.*)

Л и л и я. Китмә, мәңге хәер догам юк...

Рәфидә китә.

Әй бала... бала...

М а р с е л ь е з а чыга.

М а р с е л ь е з а. Чеп-чеп-чеп-чеп-чеп-чеп, нигә шаулашасыз, бөтен дөнья гөрли. Намазымны бүлдегез.

Л и л и я. Әй, йөрмә әле.

М а р с е л ь е з а. Ни дисең, кызым?

Л и л и я. Кит әле моннан дим, аяк астында буталып йөрмә.

М а р с е л ь е з а. Ни булды, кызым?

Л и л и я. Кара әле, ә?

М а р с е л ь е з а. Нигә ачуланасың, ачуланма... Тырышып йөрим бит...

Л и л и я. Җиттеме сиңа, юкмы? Тиле. Сине карап, синең көеңне көйләп гомерем үтте. Җүләрләнеп, башны катырып йөрисең... Үлмисең дә, ичмасам...

М а р с е л ь е з а. Ярый, ярый, кызым, китәм, ачуланма гына... күп тә калмагандыр инде... китәм... чеп-чеп-чеп-чеп-чеп...

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим... Йа Хода, менә бу көннәр дә килеп җитте... Нишлисең бит, үзебез теләгән язмыш, үзебез яшәгән тормыш... Ярабби Ходаем, тыныч кына синең изге дөньяңа китә алырмын микән. Балалар куа... Кумагыз, бәгырькәйләрем, үзем дә бик телим, тик Газраил генә озаклады. Әй балалар, балалар... Аңламыйбыз шул, вакытында... Яшәү мәгънәсен аңламыйбыз... Хәер, Марсила ахирәт, үзең ничек яшәдең соң?! Шулай ук дөнья кумадыңмы? Партия сафларын үтмәдеңме? Бар нәрсәгә ирешәм, дип, барысына да кул селтәп, ашкынып яшәп, үз җаныңа, рухыңа төкермәдеңмени? Шулай шул... Әй җан, җан... Балалар, бәгырь кисәкләрем, зинһар, җаныгыз турында, рухыгыз турында онытмагыз. Ашказаны азыгы турында гына уйлап, җан азыгын онытмагыз. (*Лилия нидер әйтмәкче була.*) Юк, юк, соңгы тапкыр сөйлим, тыңлый күрегез, зинһар өчен. Олыгайгач искә төшә ул, балалар, олыгайгач. Җаның бушап калгач, дөнья

малы күзгә күренми. Ник изгелек юлында йөрмәдем икән, ник тиен өчен чукындым икән, дигән уй үзәгемне өзә, балалар. Ашыкмагыз, балалар. Миңа күп калмады. Сез мине күрмисез. Хуш, хуш... мин гаепләмим. Шулай булырга тиештер дә. Болай үзе аяк астында комачау булмаска да тырышам да бит, нишлисең... Кирәкмәгән әйбер — гел күзгә чалынамдыр шул. Иншалла, күп түзәсе калмады инде... Теләгем шул... Үз җаныгызны онытмаска тырышыгыз... Дөнья китереп кыса инде ул, нишлисең... Соңыннан гына, картайгач кына үкенерлек булмасын, кошчыкларым... Тату яшәгез... Бер-берегезнең җанын аңлыйк, балалар... Менә күз алдына китереп карагыз... Чебиләр... Алар бит табигатьнең гөнаһсыз бөртекләре... Кешеләр дә шулай... Адәмнең җанын сыйпап, иркәләп торганда да таманга киләдер. «Түтәй, үл»,— диләр... Аңлыйм мин. Җаны буш булган, җансыз әби кемгә хаҗәт. Ачуланмагыз, балалар... Тату яшәгез... Матур булыгыз... Җаныгызны ялгыз калдырмагыз!..

Л и л и я. Уф Аллам, нишлим соң мин? Әби, түтәй, дим, ачуланма, ярсып киткәнмен. (*Бүрәнәгә утыра.*)

М а р с е л ь е з а. Зыян юк, зыян юк... китәм... чеп-чеп-чеп-чеп...

Х ы я л кайтып керә.

Х ы я л. Ни эшләп яталар болар? А-у...

Л и л и я. Монда мин...

Х ы я л. Уф, кыздыра, явар, ахрысы. Лилиям, нигә болай бик боек? Лилия, дим...

Л и л и я (*кул селтәп*). Әй...

Х ы я л. Нишләп беттегез сез? Елагансың, ни булды?

Л и л и я. Рәфидә...

Х ы я л. Нәрсә, Рәфидә?

Л и л и я. Чит илгә китәм, ди...

Х ы я л. Чү-чү, аңлатыбрак сөйлә.

Л и л и я. Нәрсәсен аңлатасың. Негрга кияүгә чыгып, Колумбиягә китәм, ди.

Х ы я л. Ничек? (*Көлә.*)

Л и л и я. Көлмә. Дөрес хәл шул, әнә тарткалашып чыгып китте негры янына.

Х ы я л. Туктале, тукта, ничек алай кинәт кенә...

Л и л и я. Күптән уйлап йөргән. Укыганда ук. Балабыз була, ди...

Х ы я л. Хәлләр...

Л и л и я. Минем монда сезнең кебек яшисем килми, ди. Коллар кебек, ди...

Х ы я л. Анысын дөрес әйткән. Акыллы бала шул.

Л и л и я. Сиңа ансат шул, тотасың да җибәрәсең, үзең үстермәгәч...

Х ы я л. Лилия, зинһар өчен, дим... Ничек җиңел булсын инде... Бер күр дә, югалт, имеш. Мин үзем сөйләшеп карармын әле.

Л и л и я. Мине тыңламаганны инде... Аннан син хәзер үзең дә китәсең...

Х ы я л. Мондый хәл булгач, китми дә торырга була...

Л и л и я. Юк, юк, эшеңнән бүленмә.

Х ы я л. Әллә куасың инде... (*Үпкәләгән булып кылана.*) Шаярам, Лилиям. Мин өч кенә көнлек ял алып кайткан идем. Менә хәзер сезне таптым, аңлаштык. Болай итәбез. Мин ялга кайтам да сине бөтенләйгә алып китәм.

Л и л и я. Хыял, ни диим... Тыңла әле...

Х ы я л. Әйе, Лилиям.

Л и л и я. Үзеңә әйтмәм, китkәч, хат аша хәбәр итәрмен, дигән идем дә... Хыял, мин синең белән китә алмыйм.

Х ы я л. Ничек китә алмыйсың?

Л и л и я. Шулай. Авырга алма. Картайдык та инде...

Х ы я л. Ни сөйлисең син, Лилиям? Уйла әле... Нинди картаю ди ул? Карт аю урманда гына була ул.

Л и л и я. Шаярма, мин чынлап сөйләшәм.

Х ы я л. Тукта әле, моны бит башка сыйдырып булмый, бу бит әллә нәрсә? Урыс әйтмешли, черт знает что?!

Л и л и я. Син хәзер китәрсең, һәм без бүтән...

Х ы я л. Тукта әле, Лилия...

Л и л и я. Бүлдермә, болай да көчкә генә сөйлим.

Х ы я л. Яхшы, яхшы, сөйлә.

Л и л и я. Мин бик күп уйладым. Күземә йокы кермәде. Безнең аралар өзелгән инде, саубуллашыйк, Хыялым.

Х ы я л. Берни дә аңламыйм. Ничә еллар бер-беребездән читтә газап чиккәннән соң очраштык. Инде бергә-бергә куанып, ялкынланып кына яшисе дигәндә, менә сиңа...

Л и л и я. Без бергә яши алмабыз, Хыялым. Бүлдермә, зинһар өчен. Әйе, мин гомерем буе сине көтеп яшәдем, сине бер күрү өчен әллә нәрсәләр бирердәй булдым. Минем өметемнең түбәсе син идең. Мин сиңа табынып яшәдем. Һәм менә... очраштык. Мин хәтта һуштан яздым.

Х ы я л. Мин сине бик тә аңлыйм. Мин синең шул өметләреңне тормышка ашырырга телим.

Л и л и я. Хәзер, Хыял, хәзер, фикеремне чуалтма. Очраштык... һәм кичә, сине күргәннән соң, мин сиңа кинәт суындым...

Х ы я л. Лилия, матурым, ул бит вакытлы нәрсә. Үзем дә шулай булдым. Ләкин, уйлавымча, ул үтәр, вакытлы хәл.

Л и л и я. Юк, Хыялым, вакытлы түгел. Мин күп уйладым инде... Тукта әле, нәрсә әйтмәкче идем соң? Хәзер, хәзер... Ә, әйе. Мин синең яшь чагыңдагы матур, саф образыңны ятарканмын. Син минем күңелгә шулай кереп калгансың. Мин сиңа нindidер идеалга, образга омтылган кебек омтылганмын. Ә хәзер ул юк. Син бүтән. Картайгансың, бөгелгәнсең, куркагракка әверелгәнсең диимме? Ә минем күңелемдә горур, сылу гәүдәле, баш имәс хыялым яши иде. Сине күргәч, ул да юкка чыкты, җимерелде...

Х ы я л. Лилия, зинһар өчен. Ярый, мин начар да ди, куркак та. Зинһар өчен, кире какма...

Л и л и я. Юк, Хыял, мөмкин түгел. Күңелем нидер сизенә... Барып чыкмаячак кебек...

Х ы я л. Лилия...

Л и л и я. Юк, юк, чынлап... ә бәлки, дип тә уйлап куям. Ләкин хәзер инде мин тәвәккәлләрлек хатын түгел. Эх, ичмасам, син кайтмаган булсаң, үлгәнче күңелемдә сакланган булыр идең. Өмет булып булса да. Ә хәзер ул да калмады.

Х ы я л. Лилиям, безнең бар да әйбәт булыр. Сиңа тормыш ваклыклары турында борчылырга туры килмәс. Китик, Лилия.

Л и л и я. Булмый, Хыял. Син хәзер минем йөрәгемдә юк, үлдең... Син минем өчен гап-гади бер кеше. Гап-гади бер кешегә ничек ышанып китим ди.

Х ы я л. Ә монда калып нәрсә бар? Кызың чит илгә китә. Берьялгызың.

Л и л и я. Нишләп берьялгызым. Минем эшем бар, дәрәҗәм, ике бүлмәле фатирым, дачам...

Х ы я л. Иртәгә үк теге адәм сине эштән куачак. Ә бу дачаларың, фатирларың минем капитал янында чүп, Лилиям. Миңа шул байлыкларга, үземә хуҗа кирәк, син кирәк. Ташлама мине!

Л и л и я. Кайгырма, кумас. Ул мине ярата, шуңа түзәчәк. Әгәр дә инде куса... Аннан без хәзер болай сөйләшеп торырга бала-чагалар түгел. Әби-бабай булып барабыз. Бетерик бу сүзне.

Х ы я л. Китмим, дисең инде... Ә Рәфидә, ул бит ятим кала...

Л и л и я. Калмас. Ятим буласын булган инде ул. Хәзер зур үсте. Китмим. Таянырга дөньям бар, оям, бүтәне дигәндәй... Кешедән ким түгел. Сине дә чакыра алмыйм, юк, юк.

Х ы я л (*кош читлеген алып*). Шушы кош кебек калуны кулайрак күрәсеңме?

Л и л и я. Бу аның үз читлеге, ә чит-ятка китсә, нәрсә буласын кем белә?

Х ы я л. Ләкин бит читлектә кош та сайрамый.

Читтә Шакир белән Шаһия күренеп алалар да качалар.

Л и л и я. Нишлисең бит, иялəшенгән инде...

Х ы я л. Китмим, дисең, алайса... Шушы редактор белән каласың. (*Портфелен ала.*) Ярый, сау бул, Лилиям. Мин соңрак тагын килермен әле.

Л и л и я. Юк, Хыялым, бүтән күрешмибез. Сау бул!

Х ы я л. Нишлисең?! (*Кочаклап үбә.*) Сау бул! (*Китә.*)

Л и л и я. Сау бул, Хыялым.

Ш а к и р (*йөгереп килеп*). Син аны кудың, кудың, Лилиям! Мең-мең рәхмәт сиңа! (*Лилияне кочаклап ала.*)

Л и л и я. Тукта әле, җибәр әле... Каян килеп чыктыгыз әле сез?

Ш а к и р. Шәһәрдән, билгеле. Лилиям, мин бик шат. Без бергә булырбыз.

Л и л и я. Зинһар өчен, калдыр әле мине.

Ш а к и р. Бетте, бетте, калдырам, ял ит. (*Кошка.*) Әй, кенәри, чут-чут, ник сайрамыйсың, сайра. Мә, кәнфит...

Л и л и я (*Шаһиягә*). Нигә алып килдең аны?

Ш а һ и я. Кая алып килү. Акайган, чаба. Тотып калып буламыни? Берәр нәрсә эшләп ташламасын дип килдем үзем дә.

Л и л и я. Ярый, килүең әйбәт булды әле.

Ш а һ и я. Ниләр булып беттегез соң сез? Куып җибәрдең?

Л и л и я. Сорама, берни дә сорама. Чәй әзерлә әле, иренмәсәң.

Ш а һ и я. Хәзер, ахирәт, хәзер. (*Самавыр алып килеп.*) Юкка кудың син аны, ахирәт, юкка. Бер дигән ирне. Миңа эләксә... Шундый асыл ирне ычкындыралар димени...

Ш а к и р  Н и г ъ м ә т о в и ч белән Ә х м ә т г ә р ә й керәләр.

Ә х м ә т г ә р ә й. Соң инде, Шакирҗан дус, талашмый гына алып булмый. О-о, Шаһия гүзәл дә биредә икән... Исәнмесез, саумысыз, тутый кошлар, әй лә, туташлар!

Л и л и я. Син кайтып китмәдеңмени әле, җизни?

Ә х м ә т г ә р ә й. Менә сиңа, куалар да. Соң, балдыз, кайтмадыңмы, дип, беренче «омик»тан соңардым. Икенчесенә Хыял дус килеп чыкты, ә менә хәзер Шакир дус... Син шаулама әле, балдыз. Җәмәгать, өстәл әзерләгез. Менә мин сезгә нинди тавыклар алып кайттым. Кызган, симез. Эх!

Ш а һ и я. Шакир Нигъмәтович акчасынамы?

Ә х м ә т г ә р ә й. Булса соң?! Акчадамыни хикмәт, әйе-

ме, Шакир дус? Ул бит аны пычагым да ала белми. Ә мин нинди шәпләрен алып кайттым. Әһә, чәй әзер икән, тик менә мәе дә булса...

Л и л и я. Җизни, дим...

Ә х м ә т г ә р ә й. Ә нәрсә? Шундый тавыкларны майлап та җибәрмәсәң, гөнаһ булыр. Йә инде, балдыз?

Ш а һ и я. Әхмәтгәрәй абзый, син Лилиягә кагылма әлегә, яме?

Ә х м ә т г ә р ә й. Ә нәрсә булган? Ни булды, балдыз? Каушама. Кичә генә әле ничек кош тоткан кебек идең. Ә бүген җебегәнсең. Юбилей дәвам итә.

Ш а к и р. Туктый беләсезме сез, юкмы? Ничә тапкыр әйтергә була, кагылмагыз, дип!

Ә х м ә т г ә р ә й. Ох-ах, защитник Родины. Бетте, бетте. Сегодня по три, но очень маленькие. А если бы те — вчера, сегодня по три, я бы...

Ш а к и р. Туктагыз дим...

Ә х м ә т г ә р ә й. Синең белән сөйләшмим бит, үзалдыма гына сөйләнәм.

Ш а һ и я. Ярый, булды, Әхмәтгәрәй абзый, шаярдык. Лилия, әйдә, чәй эчәргә.

Ә х м ә т г ә р ә й. Ниткән чәй эчү, тавык ашарга диген. Каяле, үзем ботарлап ташлыйм әле шуларны... Балдыз, синең теге нәрсәң кая микән?

Л и л и я. Нинди нәрсә тагын?

Ә х м ә т г ә р ә й. Соң шул инде, әби әйткән... брашкамы әле... Ха-ха-ха...

Ш а һ и я. Нәкъ үзе.

Л и л и я. Башымны катырма әле юк-бар белән.

Ш а к и р. Китегез инде, брашка эчеп утырып булмый инде...

Ә х м ә т г ә р ә й. Нигә булмасын? Кичә коньяк иде, бүген бал. Дөнья шулай инде ул, бер алдын — биш артын күрсәтә. Шаһия, бар алып кил әле...

Ш а һ и я. Каян?

Ә х м ә т г ә р ә й (*Шаһиянең колагына пышылдап*). Аңладыңмы?

Ш а һ и я. Ха-ха-ха, аңладым, хәзер. (*Кереп китә.*)

Ә х м ә т г ә р ә й. Безнең әби кайда соң әле, күренми?

Ш а һ и я (*чыгып*). Әби авыраеп тора. Менә! (*Банка белән бал бирә.*)

Л и л и я. Нишлисез инде сез, Шаһия?..

Ш а һ и я. Соң әнә бит, Әхмәтгәрәй абзый, ансыз булмый, ди.

Ә х м ә т г ә р ә й. Кәнишне. Эх, җәмәгать! Карагыз инде бу тавыкларны: заманында тырыша-тырыша үскәннәрдер

инде. Очарга да хыялланганнардыр. Тик тавыкның оча алмаганы һәркемгә мәгълүм. (*Ит ботарлап.*) Тавыкны бит ит өчен үстерәләр... Ә алар шуны аңламыйлар... Ә без аларны менә шулай тәмле кисәкләргә ботарлыйбыз... Ә алар берни эшли алмый... Аларның язмышы шул...

Шаһия. Чыннан да бик әпититле тавыклар. Каяле...

Шакир. Лилиям, сиңа ботымы, канатымы?

Шаһия. Ул очар кош — аңа канатын бир.

Әхмәтгәрәй. Сынык канатмы? Нәрсәгә ул?! Сынык канатка караганда, таза бот яхшырак. Мә, балдыз! (*Брашка сала.*) Җәмәгать, ашыкмагыз. Бот астына!

Шаһия. Астына тек астына...

Әхмәтгәрәй. Нәрсә, кичәге, ягъни өченче көнге бәйрәм хөрмәтенәме?

Лилия. Җитте дим, туйдым...

Шакир. Уйнамагыз кеше нервысында...

Әхмәтгәрәй. Если бы те — вчера, но у меня и сегодня нету пяти рублей. Ярый, алайса, болай гына... (*Эчә.*) Эх, тормышның тәмен белмисез...

Лилия. Нәрсә соң ул тормыш, җизни?

Әхмәтгәрәй. Нәрсә, дисеңме? Һе, болай тиз генә аңлатып булмый инде аны, балдыз... Ничек диим... Тормыш — мин ул! Менә мин тормышның ачысын да, төчесен дә күп күрдем, шатлыгын да азрак. Менә мин яшәгәндә аның тәмен белеп яшим кебек. Мин һәр мизгелдә аның ләззәтен тоям. Ачы булганда да ләззәт тоям. Әгәр берәр эшкә алынып, ләззәт тоймыйм икән, мин аны эшләмим генә. Сезнең шулай түгелмени?

Шаһия. Бик кызык әле бу.

Шакир. Без бит айнымыйча эчмибез. Хе-хе-хе. Кәнишне, сиңа ләззәт. Спиртлангач.

Әхмәтгәрәй (*ярсып*). Менә нәрсә, син, молокосос. Минем белән булышма. Мин күргәнне күреп, яшәп кара башта. Кул астында бәйле булган хатынны ирексезләп йөрү түгел ул. Тагын берәр сүз ишетсәм, үтеңне сытам.

Шакир. Ә-ә? Син... Син ни сөйлисең?

Әхмәтгәрәй. Ни ишетсәң, шуны. Ычкын моннан, исән чагыңда.

Шакир. Лилия, ни эшли ул?

Лилия. Әхмәтгәрәй абзый, сезгә күптән өегездә булырга вакыт түгелме?

Әхмәтгәрәй. Китәм, китәм, шашмагыз. Ләкин бел, Лилия, бу сволочь синең тырнагыңа да торырлык кеше түгел, алданма. Хушыгыз, бигайбә. Вчера мне жабу предложили, вот такую! (*Китә.*)

Шаһия. Юкка кешене үпкәләттек.

Ш а к и р. Китсен. Өстәлне күңелсезләп утырмасын. Ярый, җәмәгать, менә бераз гына тынычланып та калдык бугай. Килде-китте килмешәкләр таралышты. Йә, Лилиям, тынычландыңмы?

Л и л и я (*кинәт кычкырып*). Китегез!!!

Ш а к и р. Нишлисең, Лилия?

Л и л и я. Китегез дим, югал күз алдымнан...

Ш а һ и я. Чү, Лилия, чү, тынычлан.

Ш а к и р. Лилиям! Мин сине яратам бит. Син кичәге сүзләр өчен үпкәләгәнсеңдер... Гафу ит, Лилиям, кызган баштан булды ул... Мин сине кимсетергә теләмәгән идем... Гафу ит...

Л и л и я. Ой-ой-ой! Нишлим соң? Нинди ярату турында сөйлисез соң сез?! Иллегә җиткән хатында, синдә нинди ярату булуы мөмкин?! Кайчанга кадәрле без үзебезне алдап яшәрбез?! Үлгәнчеме? Нәрсә, бүтән хыялланыр нәрсәң калмадымыни!? Хәзер инде ярату белән шашасыңмы? Яшь чагыңда уйлыйсың калган.

Ш а к и р. Дөрес, Лилия, яшь чагында. Ләкин бит ул вакытта син очрамадың.

Л и л и я. Калдыр мине, буталма.

Ш а к и р. Ничек калдырыйм, Лилия. Ышан, безнең бар да яхшы булачак.

Л и л и я. Җитте! Булды, туйдым! Кит янымнан!

Ш а к и р. Куасың?.. Тагын куасың?.. Алай булгач, элегрәк ник ияләштердең?

Л и л и я. Шулай кирәк булган.

Ш а к и р. Кирәк булган... Миннән файдаландың, шуңа... Әй, ни сөйлим соң... ачуланма, Лилиям, ни сөйләгәнемне үзем дә белмим.

Л и л и я. Миңа барыбер... теләсә ни сөйлә, тик монда гына түгел... Туйдырдың. Калдырыгыз, зинһар өчен, мине...

Ш а к и р. Ярар, ку, ку. Ә беләсеңме, син үзеңнең ничтожество икәнлегеңне беләсеңме? Мин булмасам, син бит юк, ноль... Мин күтәрдем сине. Әйе, син хәзер миннән башка эшкә чумып яшим, димәкче буласың. Ә син беләсеңме, бу эшебезнең буш эш икәнлеген?.. Без бит ниндидер партия боссларының әмерен үтәүчеләр генә.

Ш а һ и я. Шакир Нигъмәтович, тынычланыгыз, артыкка китте.

Ш а к и р. Ю-у-ук! Артык түгел. Син шуны бөек эшкә санап саташасың. Үз-үзеңне алдап. Юк эш ул.

Л и л и я. Китегез моннан!

Ш а к и р. Ә менә мин сине шул бәләкәй өметеңнән дә мәхрүм итәчәкмен. Иртәгә үк син ул эштән, юк, редакциядән үк китәчәксең. Уйла, кызый, уйла.

Л и л и я (*елап*). Китегез дим... бүтән минем янда күренәсе булмагыз. Чукыныгыз редакциягез белән... (*Эчкә кереп китә.*)

Ш а к и р (*башын тотып*). Нишләдем мин?.. Нишләдем?.. Лилия, кичер мине... кичер. Эх җүләр! (*Тезләнә.*)

Ш а һ и я. Шакир Нигъмәтович, сез нәрсә? Шундый дәрәҗәле башыгыз белән тезләнәсез, үзегезне бетереп...

Ш а к и р. Эх, Шаһия, бар да бетте...

Ш а һ и я. Бетмәде, бетмәде, Шакир Нигъмәтович, башлана гына әле. Үзегезне шул картаеп беткән хатыннан мыскыл иттерәсез. Сез бит яшь әле, дәрәҗәле. Ул карт бит инде...

Ш а к и р. Мин яратам бугай аны, Шаһия...

Ш а һ и я. Нинди ярату ди ул. Әбине. Тынычлан, Шакир абый. Ул бит синнән көлә.

Ш а к и р. Көлә шул, көлә.

Ш а һ и я. Шулай булгач. Ул бит сине яратмый. Ярату гына түгел, күралмый.

Ш а к и р. Дөрес сөйлисең, эх, Шаһия, кызганычка каршы, дөрес сөйлисең.

Ш а һ и я (*аны кочаклап, юатып*). Борчылма, Шакир абый. Мин сине ташламам. Эх, Шакир абый, белмисең, аңламыйсың. Яратам бит мин сине! Яратам!

Ш а к и р. Нәрсә?

Ш а һ и я. Әйе, яратам. Күптәннән инде... Безгә редактор булып килгәннән бирле.

Ш а к и р. Ни сөйлисең син?

Ш а һ и я. Тыңла әле мине, Шакир абый. Бәлки, бу минем соңгы тапкырдыр. Әнә бит илле яшьтәге кеше нәрсә ди... Юк ул ярату, ди. Ә минеке бар, бар, бар! Соңга калып булса да яратышып калыйк!

Ш а к и р. Син чынлап сөйлисеңме, тиле кызый?..

Ш а һ и я. Чынлап, Шакир. Уйла әле. Ул бит сине мыскыл итте, ә мин сине сөярмен генә... тәмле ризыклар гына ашатырмын... мин ярата беләм. Мин бит әле яшь... ярый, ямьсез, дисәң... Мин матур булырга тырышырмын...

Ш а к и р. Җибәр әле мине, җибәр дим...

Ш а һ и я. Нәрсә дип шул карт хатынга ябыштыгыз, икәүләшеп. Нәрсәсе бар шуның? Китмә!

Ш а к и р. Кит әле моннан...

Ш а һ и я. Менә үзеңне аңламасалар, тыңламасалар, сиңа да читен бит. Мин дә шул ук хәлдә. Аңла инде мине... Мин бит сине яратам...

Ш а к и р. Ә мин сине яратмыйм, яратмыйм, аңлыйсыңмы?.. Күралмыйм! Кит дим, кит юлымнан!

Ш а һ и я. Үтерсәң дә китмим!

Ш а к и р. Кит дим, бака тәре, чирканчык... (*Алып ыргыта.*) Кит! (*Китә.*) Чукынышып бетегез үзегезнең бакчагызда!

Ш а һ и я (*ыңгырашып кына җырлый*).

Сандугачның балалары
Нигә тугыз булмаган.
Алар тугыз булыр иде,
Дөнья тигез булмаган.

Л и л и я чыга.

Л и л и я. Киттеме? Уф, көчкә! Нигә елыйсың? Йә, йә, елама, Шаһия, нишлисең бит...

Ш а һ и я. Лилия апа, нигә алай соң бу дөнья? Нигә алай? Нигә бер кешене бөтенесе дә ярата, ә берәүне беркем дә... Нигә мине беркем дә яратмый?

Л и л и я. Йә, йә, җитәр, яратырлар әле, син әле яшь...

Ш а һ и я. Нинди яшь, Лилия апа, кырыкта бит инде мин.

Л и л и я. Кырыкта түгел, утыз сигездә генә бит син... Бар да яхшы булыр.

Ш а һ и я. Эх, Лилия апа, шулай дип өметләнеп, үземне алдап яшимме? Батырларча хезмәт итеп, зур уңышларга ирештем диимме? Йә, ничек?..

Л и л и я. Белмим, Шаһия, үзем дә белмим. Менә иллегә җиттем, ә берни дә аңламыйм. Нигә яшибез без? Ни майтарабыз? Аңламыйм... Нәрсә булды соң бу?

Ш а һ и я. Мин синең алдыңда гаепле, Лилия апа...

Л и л и я. Кирәкми, мин ишеттем...

Ш а һ и я. Ачуланма инде, нишлим соң... Яраттым бугай мин ул кешене... Сезгә комачаулыйсым гына килмәде... Синең янга килүем дә аның белән очрашу өчен булгандыр, күрәсең. Сиздермәс өчен, гел артыгын кылана идем. Җиңел холыклы булып та күренгәнмендер...

Л и л и я. Юк, Шаһия, юкка борчылма... Бар, өйгә кереп бераз ятып тор, хәл ал. Бигрәк кыздыра, явар, ахрысы...

Ш а һ и я. Шулай итим булмаса. Син ачуланма инде...

Л и л и я. Нинди ачулану?! (*Кочаклап сөя.*) Бар да әйбәт... Бар, бераз ятып тор.

Шаһия өйгә керә.

Бар, бар... (*Кошка.*) Син дә сайрамыйсың? Нигә? Син дә өметеңне өздеңме? Нишләргә соң инде?!

Ш а һ и я йөгереп чыга.

Ш а һ и я. Лилия апа, Марсила әбигә начар!

Л и л и я. Ни булган?

Ш а һ и я. Сөйләшә дә алмый, селкенә дә... Паралич сыман, үлеп китмәсен...

Л и л и я. Йа Алла... Шаһия, бар, йөгер! Безнең күрше Анатолий Сафронович машиналы. Тиз генә чыксын. Арттан турыга гына чык.

Ш а һ и я. Барыр микән?

Л и л и я. Барыр, әйбәт кеше ул. Тизрәк инде...

Ш а һ и я. Йөгердем.

Л и л и я. Йа Аллам! Түтәй, түтәй! (*Өйгә кереп китә.*)

Р ә ф и д ә кайтып керә. Башын иеп, бүкәнгә барып утыра.

Ш а һ и я (*йөгереп кереп*). Лилия апа, булды. Әйдә, тизрәк! Арттан, турыдан гына алып чыгыгыз, диде. Әнә үзе дә.

Л и л и я. Тизрәк!

Шаһия Марсила әбине алып чыга.

Р ә ф и д ә. Әни, ни булды?

Л и л и я. Әбиеңә начар... Ә-ә-ә?.. Син! Син ничек биредә?

Р ә ф и д ә. Мин... ни...

Л и л и я. Тизрәк сөйлә, нәрсә син?

Р ә ф и д ә. Мин кайттым.

Л и л и я. Берни дә аңламыйм. Шаһия!

Ш а һ и я керә.

Ш а һ и я. Әйе, Лилия апа. Исәнме, Рәфидә.

Л и л и я. Шаһия җаным, монда әллә нәрсәләр килеп чыга әле. Син, зинһар өчен, үзең алып кит инде әбине. Мин үзем килеп җитәрмен.

Л и л и я. Уф Аллам, тагын ни булды?

Рәфидә елый.

Ни булды дим?

Р ә ф и д ә. Ул килмәде...

Л и л и я. Бөтенләймени?

Р ә ф и д ә. Әйе... Мин нишлим инде хәзер, әни?.. Ул алдакчы... ул оятсыз... негр калдыгы...

Л и л и я. Ярый, ярый, кызым, елап берни эшләп булмый. Түзәргә кирәк. Тормыш әле ул, ай-һай, күп алдар. Бик күп. Әллә ниткән хыяллар корырсың, бар да җимерелер, ә бәлки, барып та чыгар, кем белә. Түз, кызым, елама...

Р ә ф и д ә. Мин ничек яшим инде хәзер, әни?..

Л и л и я. Сабырлык кирәк, кызым. Язмышыңа язылган булгач... Яшәргә кирәк. Ничек итеп булса да. Ты-

нычландыңмы? Әйдә, чәй эчеп алыйк, булмаса. Аннан әбиең янына барырбыз... Картайган иде шул, ул да...

Рәфидә. Әйдә, әни.

Лилия. Бу нинди чебиләр?

Рәфидә. Әбинекедер. Көне буе эзләде, мескенем, әнә килеп тә чыктылар.

Лилия. Соңгарак калдылар шул. Ипи булса да бир алайса. Аннан чыгар әле шул кошчыкны читлектән. Ичмасам, ул ирекле булсын.

Рәфидә. Ярый, әнием.

Лилия. Көн дә бозылды. Нинди эссе иде, болыт каплады. Җил дә көчәя.

Рәфидә. Давыл булыр микән?

Лилия. Мөгаен.

*Лилия кисәк кенә көчәйгән җилгә кушылып, бөтен кирәкмәгән чүпчарны өзеп, җимереп ыргыта. Дөнья чистарып калгандай була. Бераз басып торгач, икесе дә елмаеп, кисәк кенә көлеп җибәрәләр.*

Эх, кызым минем, кошчыгым!

Рәфидә. Әнием! Әни, синең кошың читлегенә кире кайткан. Куам, чыкмый. Нишләтим?..

Лилия. Торсын, ияләнгән инде ул үз читлегенә. Давылдан да куркадыр...

Рәфидә. Ярый алайса. Иртәгә нишлибез, әни?

Лилия. Өйгә кайтырга кирәк. Әллә нәрсә әле бу дөнья...

Рәфидә. Бар да әйбәт булыр, әни. Өйгә дә кайтырбыз. Менә бакчабыз да гөрләп утыра. Фатирыбыз да бар. Кешедән ким түгел, яшәрбез...

Лилия. Яшәрбез... Әйдә, яңгырга эләккәнче, өйгә керик. Кара, бу чебиләр яңгырга эләксәләр, бетәләр бит... Кая киткәннәр соң? Чеп-чеп-чеп... Кызым, син читлектәге кошыңны сакла, мин чебиләрне табыйм. Чеп-чепчеп... Тавык булырлар... Ни әйтсәң дә, кош... очар... Алып кер өйгә әйберләрне...

*Көчле җилдән өй түрендәге агачның ботаклары сына. Һәм Ана белән кыз коеп яуган яңгыр астында калалар.*

Пәрдә.

# Иру...

*Ике пәрдәле драматик фараз-дастан*

КАТНАШАЛАР:

Бикә — 50 яшьләрдә.
Актаң — 14—15 яшьтә.
Роек — 17—19 яшьтә.
Сүндәй — 78 яшьтә.
Рүбәдә — 65—70 яшьләрдә.
Сәгати — 40 яшьтә.
Җадан — 50 яшьтә.
Чөнгут — 40 яшьтә.
Бимаж — 56 яшьтә.
Әсән.
Акмаз.
Кәрлә — яшьсез.
Хөҗәнди — яралы ир.
Хатын-кызлар, яугирләр һәм башкалар.

Вакыйга борынгы заманда, төрки кабиләләр арасында бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Томан таралган. Матур булып таң атып килә. Кошлар сайраша, тирә-якта моңлы тынлык. Табигать матурлыгын бозып, тирә-якта җимерелгән, таланган, пыскыган пейзаж җәйрәп ята. Ниндидер хатын-кызлар каралты-кураны рәтләп, уфтана-уфтана, эшләгән кыяфәттә селкенеп йөриләр.

Сәгати. Ошбу дөньяны без мәңге хәлгә кертәсебез юк... Сыңар ир калмады бит, бер ир...

Сүндәй. Ә без кем соң, алайса?

Сәгати. Һе, кем инде ул без, бабай?

Сүндәй. Әсән белән мин?!

Сәгати. Әй, бабай, бабай! Ир дигән җанвар ул ажгырып тора. Минем мәрхүм Хөҗәнди шикелле. Нindәй ир иде бит... (*Шыңшып ала.*)

Актаң. Йә инде, җиңги.

Сәгати. Ир шундый була ул. Сезнең эше... тфү! Бабай белән олан түгел...

Сүндәй. Йә, йә, килен, ир-ат белән тел озайтма, тилчә чыгар.

Бикә. Җитте, килен, сүз болгатыр чак түгел. Авыр вакыт. Эшкә барыбыз да!

Сәгати. Мин нәрсә... Ирләребез калмагач...

Рүбәдә. Иншалла, менә яудан исән калганнары кайтыр әле. Хода язган булса, иншалла... Синеке дә...

Сәгати. Кайтыр... Кайтырлар... Су дәрьясы иясе белән ант итеп әйтәм, иремне үтергән шул иблисләрнең үзем күзләрен тырмап чыгарыр идем...

Рүбәдә. Килен, ни сөйлисең? Ниткән тагын су ияләре? Алла диген, бер Хода диген. Тфү, тфү, әстәгъфирулла.

Сәгати. Әй, Алла инде, Алла...

Бикә. Килен, азма.

Еракта малай кычкырган тавыш ишетелә. Шомлы тынлык.

Бикә. Чү, шауламагыз... Кем тавышы?

Актаң. Әсән түгелме бу?

Бикә. Әсән углан тавышы шул... Ни булыр?

Рүбәдә. Йа Ходаем, берәр каза булмагае.

Сүндәй. Яу булмагае тагын... Теге кавем кире әйләнеп кайтмагае...

Актаң. Аллам, ярабби Ходаем, күрсәтә күрмә...

Әсән (*йөгереп керә, әлсерәгән*). Анай, анай!

Сүндәй. Нинди анай? Нә булды тагын? Миңа сөйлә әүвәл...

Актаң. Су эч, мә...

Әсән (*су эчеп*). Анай...

Сүндәй. Тагын анай, бабаңнан узып...

Бикә. Яле, бабакай, вакыты түгел... Соңыннан... Йә, сөйлә тизрәк, ни булды?

Әсән. Анай, анай...

Сәгати. Уф-ф, йә инде, сузма!

Әсән. Анда, анда...

Бикә. Нәрсә анда?

Әсән. Кеше...

Сүндәй. Берәү генәме?

Әсән. Анай... Анда... Хөҗәнди агай...

Бикә. Ә-ә?

Сәгати. Хө-хө... Хөҗәнди?!

Рүбәдә. Йа Ходаем...

Әсән. Ул, ул, сөйләшми, тормый...

Рүбәдә. Үтергәннәр, харап иткәннәр...

Б и к ә. Туктале, әби... Кайда, кай якта?
Ә с ә н. Әнә теге якта... Яр астында.

Бар да Әсән артыннан шул якка йөгерә. Әби ихата кырыенда кала.

Р ү б ә д ә. Йә Тәңрем, бер ир-егетебез дә исән түгел, ичмасам, йә Тәңрем... Ни гөнаһларыбыз өчен бу афәт? Ярабби бер Аллам, кичер, кичер безнең гөнаһларны. Гаебебез олугтыр, гөнаһларыбыз бихисаптыр, Ходаем, бу кадәрле күрмәс идек...

Хатыннар я р а л ы и р н е күтәреп керәләр. Бабай үзе дә көчкә сөйрәлеп, өйрәтеп килә.

С ү н д ә й. Җайлап, җайлап күтәрегез, хатын имгәкләре... Ул сезгә утын агачы мәллә!..
Р ү б ә д ә. Менә, менә бу урынга салыгыз. Ай, олан, олан...
Б и к ә. Җайлап. Исән, исән, ярабби... Су бирегез, су... кызым, Актаң...
С ә г а т и. Ай, Хөҗәнди... ни эшләткәннәр сине... ай, минем арысланым...
С ү н д ә й. Йә, үкермә кеше өстенә...
А к т а ң. Мә, су... (*Су эчереп карыйлар.*)
Р ү б ә д ә. Күзен ачты... Йа Ходаем, исән, исән...
Б и к ә. Хөҗәнди, олан... мине ишетәсеңме?
С ә г а т и. Мин, мин монда, тиңем.
Х ө җ ә н д и (*ыңгырашып*). Мин кайда?
Б и к ә. Өйдә син, ыруда. Безнең янда.
С ә г а т и. Мин сине тәрбия кылырмын. Мин сине әүвәлгедәй арыслан ир итәм. Тәрбия кылам, җанашым... Түз, газизем... (*Елый.*)
Х ө җ ә н д и. Анда, анда... (*Тагын коелып төшә.*)
Б и к ә. Нәрсә анда?
Х ө җ ә н д и (*көчкә генә сөйләшә*). Анда дошманнар чирүе, киләләр...
Р ү б ә д ә. Йә Тәңрем, киләләр, киләләр, ди...
Б и к ә. Син борчылмый гына ят, сакла үзеңне.
С ә г а т и. Нәселләре кыргырлары. Яшен Алласы суккырлары... Ни кылабыз?
Б и к ә. Чүегез әле, шауламагыз, күрмисезмени хәлен...
С ү н д ә й. Чү, шауламагыз!
С ә г а т и. Ни кылаек, Хөҗәнди?
Х ө җ ә н д и. Бикә, олуг бикә кайда?
Б и к ә (*аның янына узып*). Мин монда, монда, углан.
Х ө җ ә н д и. Бикә, тыңлап калыгыз карендәшегезне. Бәлки, соңгы сулышларымдыр...
С ә г а т и. Юк, юк!!!

Х ө җ ә н д и. Тукта, хатын.
С ү н д ә й. Булды, килен, тыел.
С ә г а т и. Өйрәтмәгезсәнә. Гел миңа бәйләнәләр.
Х ө җ ә н д и. Бүлдермә, хәлем юк.
Б и к ә. Тыңлыйм, углан, тыңлыйбыз.
Х ө җ ә н д и. Шул, олуг бикә. Ошбу вилаятьтә тынычлык бетте. Кая карама яу, чиру. Бәгъзе җиһанда кая карама кыралар, үтерәләр. Су...
С ә г а т и. Мә. (*Су бирә.*)
Х ө җ ә н д и. Шул...
Б и к ә. Тыңлыйм, углан...
Х ө җ ә н д и. Шулай... Мин сүнәм... Шыңшымагыз... Тыңлагыз каһарманны... соңгы сүзем. (*Пауза.*) Без нык тордык. Ләкин алар күп, бихисап ишле яу... Без беттек... кырылдык... Шул... Ыру башы бинең соңгы әманәтен тапшырам.
Б и к ә. Әллә?! Ул исән?
Х ө җ ә н д и. Юк, юк. Ул нык яраланды, шәһит киткәндә, әманәтен әйтеп калдырды.
Р ү б ә д ә. Йа Ходa...
Б и к ә. Соң? Без исән булганда, аның әманәтен бер карусыз үтәрбез...
С ү н д ә й. Һичшиксез, үтәрбез.
Х ө җ ә н д и. Шул... Баланы сакласын, диде, әүвәл угланны... Ыруны сакласыннар, дип әйтте, ыруны... Ничек кенә булса да... Ак сусар ыруын... Бернигә дә карамыйча... Ничек булса да... канны сакларга... Малайны, ди, соңгы өметне... Халыклар безнең ыру тирәсенә берләшсеннәр, ди... Ыруны югалтмагыз... Ни күрсәгез күрегез... Ыруны саклагыз... Ант эчегез, мин үлгәнче, ант эчегез...
С ә г а т и. Тыңлагыз инде, газапламагыз кешене... ант эчегез, ант...
Б и к ә. Әйе, әйе. Изгеләр рухы белән ант итәбез, олуг бием, сезнең изге шәһитегез хакына ыруны сакларбыз. Тынычлан, углан, бергәләп оешырбыз, синең берлә.
С ә г а т и. Без әле, картым, синең белән барын да саклабыз. Иманың камил булсын. (*Елмаеп.*) Ыруны да ишәйтербез. Беренче нисбәттә, син исән, исән.
Х ө җ ә н д и. Угылны, угланны... буынны, соңгы ир буынны...
Ә с ә н (*йөгереп керә*). Анда, анда...
Б и к ә. Ни, нәрсә? Әллә син?
Ә с ә н. Ю-ук, анда... кешеләр, күп кешеләр... Тузан өере анда, киләләр... Кораллы алар... атлы...
Х ө җ ә н д и. Бу алар... Яу, бу яу, чиру... куып җитteләр... Сакланыгыз... Алар мәрхәмәтсез...

Рүбәдә. Ай Аллам, ни эшлик, ни кылыйк?

Бикә. Ярсымагыз! Ни булса, шул була инде... Ягез, булышыгыз.

Ирне алып китмәкче булалар.

Хөҗәнди. Кирәкми. Мин беткән инде... Үзегез генә... алар мине эзләячәк... Мин алардан качтым. Үзегез генә... Угланны яшерегез... Угылны.

Бикә. Ярый, ярый, борчылма, бергәләп... (*Роекка.*) Кызым, Әсәнне яшер, йөгер!

Роек, Әсән китәләр.

Яле, булышыгыз!

Хөҗәндине икенче бүлмәгә яшерәләр. Җадан сугышчылары килеп керә.

Бимаж. Монда бар ыру башлары җыелган, монда керегез.

Чөнгут. Кузгалмаска. Ошбу тирмәдән беркемне чыгармаска. Бимаж, һәр почмакка шихнәләр куй, нык сакласыннар. Һәр адәмгә урынында калырга. Югыйсә... (*Бар да каушап туктап калалар.*) Бимаж, әйт алай башына, бар да әзер, диген. Әй, сез, олуг алай башын каршыларга әзерләнегез!

Җадан керә. Аңа Акмаз, Кәрлә һәм сакчылар ияргән.

Бимаж. Рәхим итегез, тәкъсир.

Җадан. Бары да биредәме, Чөнгут?

Чөнгут. Беркемне дә ычкындырмадык.

Җадан. Башла. Кәрлә, утыр яныма.

Кәрлә. Үлеп яраткан олуг кыланышыңа тотындыңмы, бөек яугир?

Җадан. Кыбырсыма, Кәрлә, әлегә синнән башка да күңелле. Шулаймы, Бимаж?

Бимаж. Нәкъ шулай, тәкъсир.

Җадан. Башла, Чөнгут.

Чөнгут. Хатыннар! Ошбу вилаятькә ирек китерүче, мәрхәмәт кылучы бөек яу килеп җитте. Олуг төмән кул астындагы бөек чирү сезгә бәхетле тормыш, чын ирек алып килде.

Җадан. Йә, йә, сузма, җәелмә ул кадәр. Юл көтә.

Чөнгут. Хуп.

Кәрлә. Әллә баш булу, сөрән салу ошап киттеме? Син булдыра алырдай шөгыль түгел ул, маташма, бичара...

Җадан көлә.

Бимаж. Бигрәк киң күңелле инде син, Кәрлә.

Кәрлә. Салпы якка салам кыстырма, яме. (*Бимажга күрсәтеп.*) Җадан, моннан сак бул, ошбу иң явызы...

Җадан. Булды, Кәрлә. Кәмит карар чак түгел, соңыннан. Вакыт тар.

Кәрлә. Вакыт тар, ә бүтәнгә җитәрлек...

Җадан. Ни әйтмәкче буласың?

Кәрлә. Менә, ир-егетләрне кырып, теләгәнегезгә ирештегез, «изге күңелле» бөек яугир! Карагыз, күрегез! Күпме чибәр хатыннар җыелган анда. Яугирләр көчкә тыелып торалар! Ай, рәхәтләнәсез, һай, азынасыз, вай, бөтен дала кыргыйлары азгынлыгын җиһанга чыгарасыз инде, ә?!

Җадан. Булды, Кәрлә, кылтайма. Урыныңны бел!

Кәрлә (*кыланып*). Ярлыка, о, бөек тәкъсир, кая инде ул безгә сезләрдәй яугирләр барында.

Чөнгут. Ха-ха-ха!

Бимаж. Җитте, диләр, Кәрлә явыз.

Җадан (*ачуы чыгып*). Җитте! Күп сөйләнәсең. Кәрлә булмасаң... Кит моннан. Кайда теге ир?

Бимаж. Шушы ыру хатыннары алып китте, хаким, күзәтеп бардым.

Җадан. Бездән дошман бәндә качып китте. Кайда ул?

Тынлык.

Кабатлап сорыйм, мондамы ул ир? Кем монда баш?!

Бикә (*алгарак чыгып*). Биредә бернинди дә качкын булмады...

Җадан. Син кем?

Бикә (*дәрәҗәсен белеп*). Мин — Нолымбикә, Ак сусар ыруы башы, би хатыны!

Җадан. Башка сүз дәшүче юкмы? (*Беркем дә дәшми.*) Кара аны, хатын, табылса, башың илә җавап бирәсең. Эзләргә! Бар җирне актарыгыз!

Эзлиләр.

Рүбәдә. Бөтен дөньябыз җимерелде, ирләребез кырылып бетте, тагын ни җитми сиңа, углан?

Чөнгут. Шым, кортка, ничек сөйләшәсең син? Ул явыз бәндә безнең өч иң яхшы яугирне үтереп качты. Үлем аңа, үлем...

Хатыннар шаулый башлыйлар.

Җадан. Чөнгут, бу нинди шау-шу? Тый!

Чөнгут. Булды. (*Берничә сакчыга.*) Шихнәләр,

тәртип булсын. Шауламагыз! Телләрегездән башыгыз белән бергә колак кагасыгыз килмәсә... тыегыз телләрегезне.

Җадан (*тыныч кына*). Шул, хатыннар. Сүзем шул: бәгъзе яуда без җиңдек. Яу шартлары буенча бар да безнеке. Монда без хуҗа. Әгәр берәр әмерне ошбу рәвештә бозучы, угрычы булса, җәза — үлем. Аң булыгыз, бездә тимер тәртип! Тимер тәртип булмаганда, җиңү юк!.. «Бөек яу» шартлары шуны таләп итә. Аңлат, Чөнгут.

Чөнгут. Баш өсте. Әгәр безнең әмерне...

Бимаж. Олуг каганның...

Чөнгут. Нәрсә?

Бимаж. Олуг юлбашчы әмерендер диюем.

Чөнгут. Ә-ә, әйе. Әгәр олуг юлбашчы әмерен бозучы булса, үлем! Аңладыгызмы?! Сез хәзер безнең коллар...

Сакчылар Хөҗәндине сөйрәп чыгаралар.

Ә-ә, менә кайда икән ул, тәкъсир.

Җадан. Әй, хатын.

Бикә ишетмәмешкә салыша.

Бимаж. Сиңа әйтәләр, кортка?

Сүндәй. Ул бикә.

Җадан. Сиңа әйтәм, бикә! Кара син аны, бикә?!

Бикә. Йә?! Мин?

Җадан. Син, син. Син нигә алдашасың? Ошбу эш өчен ни буласын беләсеңме?

Бикә. Ул качак түгел, ул минем карендәш.

Сәгати. Ул минем ирем. Ул качмады, ул иленә кайтты. Тимәгез, тимәгез аңа. (*Аны Бикә көчкә тыеп тора.*)

Чөнгут. Булды, хатын, юкса...

Җадан. Тимә, Чөнгут.

Бикә. Ул...

Җадан. Дәшмә! Синең белән соңыннан сөйләшү булыр. (*Хәлсез Хөҗәндигә эндәшеп.*) Йә, мәмлүк, ник үтердең минем баһадирларны?

Сәгати. Тәңре хакына, тимәгез. Күрәсез ич, аның хәле начар. Күп кан югалткан.

Бимаж. Кит, хатын! Безнең баһадирларның каны гына түгел, җаны да юк. У-у-х! Әйеме, тәкъсир?

Җадан. Алыгыз бу бәхри мәмлүкне.

Рүбәдә. Углан, углан?..

Бимаж. Ниткән углан булыйк ди без сиңа, кортка?

Сәгати. Тимәгез аңа!

Хөҗәндине читкә алып ташлыйлар.

Р ү б ә д ә. Углан түгел, бөек яугирләр, баһадирлар. Мәрхәмәт кылыгыз, калдырыгыз аны... Мине, менә мине алыгыз... мине үтерегез... Мине, Хода хакына...

Җ а д а н. Чөнгут, бу ни бу?

Ч ө н г у т (*сакчыларга*). Алып атыгыз шул карчыкны, үләксәне!

С ү н д ә й. Кортка, дәшмә, дәшмә.

Б и к ә. Яу башы! Хода хакына, ир бул!

Җ а д а н. Нәрсә?!

Б и м а ж. Син ничек?!

К ә р л ә. Булмый, булмый, өметләнмә.

Җ а д а н. Тик тор, Кәрлә. Сөйлә, бикә, сөйлә...

Б и к ә. Шул. Калдырыгыз аны. Ул ыруыбызда бердәнбер исән калган ир. Чын яугир булсаң, тимә...

Ч ө н г у т. Син, хатын, әмерне аңламыйсың, ахры... Камчыларга, җәзаларга боер, тәкъсир!

К ә р л ә. Әйдә, әйдә, күрсәт осталыгыңны.

Җ а д а н (*Кәрләгә*). Кит. Тимә, Чөнгут.

Б и к ә. Мәрхәмәтле бул, әгәр... Бердәнбер ир хакимебез...

Ч ө н г у т. Ир кирәк булган... Чибәрсең әлегә... Табылыр... ха-ха-ха. Шулаймы, яугирләр?

Җ а д а н. Кабаланма, Чөнгут.

Р ү б ә д ә. Мине, мине алыгыз... Калдырыгыз аны.

Ч ө н г у т. Кит, диделәр бит, кортка. Төнлә төшкә керсәң, котны алырсың... Мине алыгыз, имеш...

Җ а д а н. Булды.

Хөҗәндине сөйрәп алып китәләр.

Алыгыз.

С ә г а т и. Калдырыгыз, тимәгез. (*Егыла. Аны сакчылар тоткарлыйлар.*)

Җ а д а н. Тагын нинди ир заты бар?

С ү н д ә й. Мин.

Җ а д а н. Кем син?

С ү н д ә й. Ир.

Җ а д а н (*шаркылдап көлә*). Син ир? Бу ыру ирләре бик баһадир икән. Мәле, картлач (*аңа кылыч биреп*), шушы кылыч белән ор әле...

Карт кылычны селти алмый, егыла.

Ха-ха-ха! Сине ир дип танысаң, мин Алып батыр булам инде, алайса. Рәхмәт, картлач, көлдердең... Сине уздыра бу, ә, Кәрлә?

К ә р л ә. Уздырмый шул. Кылыч тотсам, мин, һичшиксез, эшкә кертер идем.

Б и м а ж. Әй, син, син ничек?

Җ а д а н. Сөйләнсен! Тагын нинди ир заты бар?

Б и к ә. Бүтән беркем дә, башка беркем дә юк.

Җ а д а н. Шым, хатын. Сиңа ышанмыйм. Син хәйләкәр. Тик аң бул, бу алдавың соңгы тапкыр булсын.

Б и м а ж. Ишеттегезме, соңгы тапкыр, хатыннар!

Җ а д а н. Тагын нинди ир заты бар дип сорадым?

А к т а ң. Бүтән беркем дә, би.

Җ а д а н. Бу нинди сылу бала?

Б и м а ж. Кыз-хатын, тәкъсир.

Җ а д а н. Күрәм. Яле, якынрак кил әле. О-о, бик күркәм, бик күркәм. Монда кышлыйсы булмаса, мин сине Каганга бүләккә алып китәр идем. Акмаз углан!

А к м а з. Әйе, атай.

Җ а д а н. Күр, нинди гүзәл Чәчкә. Ошыймы?

А к м а з. Юк!

Җ а д а н. Нигә?

А к м а з. Мин баһадир булам! Минем кызлар белән сөйләшергә вакыт юк!

Ч ө н г у т. Юләр олан. Чын баһадир катыннарның үзәген алып, ут чәчеп торырга тиеш.

Җ а д а н. Хе-хе, аңладыңмы?

А к м а з. Аңладым да...

Ч ө н г у т. Янә дә аңлар әле.

Җадан кулын күтәрә.

Б и м а ж. Шауламагыз! Олуг төмән сүз әйтә!

Җ а д а н. Күп сөйләнде, булды. Әмерем! Ошбу кояш чыгыштан алып, алдагы якты көннәр буенча бар да минем әмер белән генә үтәлергә тиеш. Әмердән башка бер гамәл дә кылмаска. Кем дә кем безнең ошбу әмерне бозса...

К ә р л ә. Үлем инде, үлем.

Б и м а ж. Кәрлә, җитте сиңа.

Җ а д а н. Бимаж! Монда баш булып син каласың.

Б и м а ж. Тәкъсир, әгәр Чөнгутны баш итсәк? Ул остарак та, аннан (*колагына*) ярата да баш булуны... тырышыр да... Ә мин ни (*күз кысып*), ярдәмче...

Җ а д а н. Бәлки. Чөнгут!

Ч ө н г у т. Тыңлыйм.

Б и м а ж (*аңа гына сөйли*). Мин алай белән юлны дәвам итәм. Тиз генә әйләнеп кайтып булмас. Башка вилаятьләрдә дә тәртип урнаштырасы бар. Аңлыйсыңдыр.

Ч ө н г у т. Әлбәттә.

Җ а д а н. Аңласаң, шул: монда баш булып син каласың. Бел: безгә монда озакка тукталасы була, монда кыш-

лыйбыз. Мин әйләнеп кайтканчы, тирмәләрне барларга, җәйләүләрдәге малларны җыярга, кыскасы — яугирләргә кыш чыгарга ошбу илдә мөмкинлекләр тудырырга кирәк. Кыз-хатыннарга үзегез урнаштырырсыз.

Чөнгут. Төшендем, бөек төмән.

Җадан. Бикәгә кагылмаска!

Чөнгут. Бөек алай башы! Мин сезгә шундый чибәрен әзерләп куярмын. Ә ул ничек кире, каршы торды. Асарга иде аны.

Җадан. Булды. Әйттем. Бикә кала. Мине каршылар.

Чөнгут. Аңлашылды.

Җадан. Чирүне җыярга. Юлга әзерләнсеннәр. Бимаж, син Чөнгутка ярдәмгә каласың.

Бимаж. Баш өсте, тәкъсир.

Кәрлә. Ә мин калмыйммы? Мин аларның канына күп тоз салыр идем.

Җадан. Юк, Кәрлә. Син минем белән. Акмаз углан, син каласың.

Акмаз. Атай! Мин калмыйм, минем яу чабасым килә.

Җадан. Юк. Мин әйттем. Чөнгут әнә хәзер синең агаң.

Акмаз. Чөнгут? Әйем...

Җадан (*хатыннарга күрсәтеп*). Менә сиңа яу. Сакла шуларны.

Акмаз. Мин кыз-хатыннарны сөймим. Минем орышасым килә, яуда.

Чөнгут. Әнә теге сылуга кара. (*Актаңга күрсәтә.*) Җүләр баш.

Акмаз. Әйем. (*Үпкәләп читкә китә.*)

Җадан. Малай, малай!

Акмаз (*чәчрәп*). Мин малай түгел, мин егет, мин ир-егет.

Чөнгут. Ир, егет. (*Көлешәләр.*)

Җадан. Булды, әйттем!.. Бу тагын нинди киреләнү. Йә? Ни дияргә тиеш яугир?

Акмаз. Баш өсте...

Җадан. Менә шулай, углан.

Чөнгут. Зарар юк, без аның белән бик тиз уртак тел табарбыз.

Җадан. Булды. Киттек. (*Чыгып китәләр.*)

Рүбәдә. Йа Ходаем, ниләр булып бетәрбез инде?

Сәгати. И-их, кулымда корал булса, ичмасам.

Сүндәй. Үзем мин аларны...

Бикә. Булды, карендәшләр, ярсымагыз, сабырлык кирәк әлегә.

Ч ө н г у т, Б и м а ж, А к м а з әйләнеп керәләр.

Ч ө н г у т. Ха, мин баш! Йә, ничек, Бимаж?

Б и м а ж. Сезгә бик килешә баш булу, тәкъсир.

Ч ө н г у т. Килешергә тиеш тә. Акмаз, урын китер.

А к м а з. Ничек мин?

Ч ө н г у т. Сиңа әйтәләр, ишетмисеңмени?

Б и м а ж. Ни эшлисең, син хәзер аның кул астындагы яугир.

Акмаз, теләр-теләмәс кенә, урын китерә.

Ч ө н г у т. Менә шулай. Хәзер мин боера башлыйм. Яле. Әй, хатыннар! Әмерем: минем баһадирларны урнаштырырга әзерләнегез. Без монда кыш чыгарга тиеш. Һәр хатын-кыз бәгъзе яугиргә карышмаска, аны чын күңелдән кабул итәргә тиеш.

С ү н д ә й. Мин ирек бирмим. Ирек бирмәм.

Ч ө н г у т. Синең сылубикәңә тимәбез, картлач. Бигрәк яшь, бигрәк сылу икән шул әле. (*Көлешәләр.*)

Ч ө н г у т. Бусын да аңладыгызмы?

Б и к ә. Без киңәшеп карарбыз.

Ч ө н г у т. Нәрсә? Ниткән киңәшү?! Бу әмер, хатын, аңлыйсыңмы? Әмер. Ярый, нигә сүз әрәм итеп торырга. Аңладыгызмы?

С ә г а т и. Юк! Аңламыйм да, аңларга да теләмим.

Ч ө н г у т. Нәрсә? Алыгыз аны.

Б и м а ж. Менә шулай! Ыграк аларны.

Б и к ә. Олуг яугир, ул уйламый сөйли. Яшь әле. Мәрхәмәт кылсагыз, без киңәшер идек.

Ч ө н г у т. Ниткән киңәшү. Әле дә төшенмәдегезме? Без ике сөйләшмибез. Монда хәзер мин хуҗа! Хәзер мин монда тәртип урнаштырам! Мин ике сөйләшмим! (*Сәгатигә күрсәтә.*) Алыгыз дидем. Ә юк, ул ямьсез. (*Роекка борылып.*) Менә монысын...

Сакчылар Роекны эләктереп алалар.

Б и к ә. Ни эшлисез сез?

Ч ө н г у т. Син нигә кысыласың, хатын?

Б и к ә. Ул минем кызым.

Ч ө н г у т. Булды. Монда кызлар бетте. Сез безнең коллар. Монда хәзер бары безнең хатыннар гына. Аңладыгызмы дим?!

С ә г а т и. Юк, дошман.

Ч ө н г у т. Нәрсә?!

Б и к ә. Сәгати, сабыр, кирәкми.

С ә г а т и. Нәрсә кирәкми?! Алар безнең юлбарыстай

ирләребезне, атайларны кырып бетерсеннәр дә, кирәкми. Син — ерткыч, син — явыз, син — дошман!

Чөнгут. Алыгыз бусын да. Камчыларга. Соңыннан яугирләргә ыргытырга.

Сәгатине алып китәләр.

Сәгати. Мин сезне барыбер үтерәм. Мин сезне...

Чөнгут. Без уен уйнамыйбыз. Бүлемгә кертеп чишендерегез шушы бичәне...

Бикә. Хода хакына, тимәгез аңа...

Чөнгут. Бетте!

Бимаж. Акмаз, ни карап торасың? Ку.

Акмаз. Якын килмә, бикә.

Чөнгут. Җебемә, малай. Әле күрәселәрең алда.

Бикә. Ул телсез, сөйләшә алмый, зинһар...

Бимаж. Бигрәк әйбәт, кычкыра алмас...

Акмаз. Бәлки, хаким, калдырырбыз?..

Чөнгут. Нәрсә? Синме яугир? Тфү! Жәлли. Ха-ха.

Бикә. Җибәрегез аны.

Бимаж. Кит, шундый кызыйга, сине... Сиңа да өлгерербез...

Чөнгут. Җитте, Бимаж... Аңа ярамый, кагылма.

Бимаж. Алайса, бусын үзем...

Чөнгут. Кит, кагылма. Соңгы тапкыр сорыйм: ни кылырга кирәген аңладыгызмы?

Сүндәй. Безнең хатыннарны яклаучы юк димәгез... Мин сезгә...

Чөнгут. Кит моннан, картлач. Алыгыз аны!

Бабайны алып китәләр.

Рүбәдә. Ай Аллам, ай Тәңрем, тимәгез аңа, тимәгез, ул бит карт кеше.

Чөнгут. Шым, кортка. Карт булса, телен тыйсын.

Бикә. Түз, түтәй, дәшмә. Сине дә кызганмаслар.

Чөнгут. Кызганмабыз. Тимер тәртип урнашмый торып, туктау юк. Инде аңладыгызмы?

Бикә. Ерткыч, мине ал, дошман, мине үтер!

Чөнгут. Хатын! Тый телеңне! (*Бикәгә нык итеп суга, Бикә аңсыз булып егыла.*) Күрсәтер идем мин сиңа мәхшәрне... Бугазыңны үзем каерып атар идем дә... Кит! Алып атыгыз моннан! Без әйләнеп кайтканчы, уйлашыгыз. Һәрбер яугир урнашкан булырга тиеш. Ә бу (*Бикәгә күрсәтеп*) Төмән башка өй әзерләсен. Акмаз! Син биредә сакка каласың. Без җәйләүдән маллар куып кайтабыз! Мин беттем. Кертегез тирмәгә чибәр кызны! (*Роекны сөйрәп кереп китәләр. Кычкыру, елау, ызгыш, шау-шу, талаш.*)

Ут сүнә. Сәхнәдә хатын-кызлар утыралар. Бер читтә Акмаз урнашкан.

Бикә. Менә шундый хәлләр.

Актаң. Тагын ниләр күрәсебез бар икән, әнкәй? Роекны да таба алмыйлар. Ни булгандыр?

Бикә. Суга төшкән кебек юк булды, балам.

Актаң. Йә инде, әнкәй.

Сәгати (*Акмазга*). Нәрсә чекерәйдең? Күңелегез туймадымыни әле?

Акмаз. Хатын! Әрепләшмә минем белән! Мин гаскәри!

Бикә. Йә, килен, ярсытма. Аның ни гаебе бар? Күрәсең ич, бала...

Акмаз. Хатын! Мин бала түгел, мин...

Бикә. Түгел, түгел, син — баһадир.

Рүбәдә керә.

Йә, бабай ничек анда?

Рүбәдә. Бетерделәр, бетерделәр...

Сәгати. Явызлар, мөртәтләр.

Бикә. Алар тукталмаячаклар...

Рүбәдә. Ни кылаек, бикә?

Бикә. Киңәшергә кирәк, хатыннар. Кызым!

Актаң. Әйе, әнкәй!

Бикә. Син бу угланны бераз сөйләштереп кара, без киңәш корып алаек.

Хатыннар китә башлыйлар. Акмаз аларны туктатмакчы була, Актаң аның юлын бүлә.

Акмаз. Хатыннар, кая китәсез? Таралмаска! Мин, алайса...

Бикә. Йә, йә, алай ачулы булма, сиңа килешми. Сезнекеләр кайтып та җитәр, ә без берни дә әзерләмәгән.

Акмаз. Шулай дисәң генә. Карагыз аны... Син ник калдың, хатын?

Актаң. Мин хатын түгел.

Акмаз. Миңа барыбер?

Актаң. Алай усал булып кыланма, син бит андый түгел.

Акмаз. Хатын! Әй, тфү, кызый! Кыздырма минем канымны, югыйсә... Мин гаскәри!

Актаң. Кичер, бөек сугышчы... Мин сине ярсытырга теләмәдем. (*Пауза.*) Ә кызсаң, син дә мине үтерер идеңме?

Акмаз. Мин кыз-хатын белән орышмыйм.

Актаң. Димәк, тимәс идең, димәк, син...

А к м а з. Булды, кызый! Мин сугышчы! Мин яу кырында гына алышам! Мин яуда җиңәм! Мин батыр булырга тиеш.

А к т а ң. Анда гына түгел, монда да батыр булырга яратасыз шул сез...

А к м а з. Кызый! Миңа кагылма. Җитте.

А к т а ң. Ярый, ярый, коелмассың. Монда булмасын. Яуда орышканда, син дошманыңны үтерәсең. Барыбер кан кою бит...

А к м а з. Анда намуслы орыш. Ул көчле булса — мин бетәм, мин алдырсам — ул. Гөнаһы юк.

А к т а ң. Ә ни өчен? Ансыз булмыйммы? Бәлки, ул берәрсенең синең кебек газиз улыдыр?! Менә минем атам кайтмады, абыйларым, җизнәләрем, беркем дә... Кайда алар, кайда?! Нигә алар үләргә тиеш?! Нигә алар?! (*Елый башлый.*) Нигә сезнекеләр түгел?! (*Онытылып өстенә килә.*)

А к м а з. Әй, әй, кызый. (*Аптырап кала.*) Син нәрсә... син... Йә инде... Мин каян белим. Яу бит... Бер башлангач, ни өчен орышканны шайтан үзе дә белә алмый торгандыр... Без җиңелсәк, без беткән булыр идек...

А к т а ң (*сулкылдап*). Без беркемгә тимәдек. Без тату яшәдек... Нәрсә калды хәзер, нәрсә? Ни эшлик? Бер иратыбыз калмады...

А к м а з. Беренче яуда җиңгәнегез өчен атайлар бик ярсыды. Шуңа бу юлы олуг яу белән килделәр. Бөтенесен кырып бетерәбез, дип. Үзегезнекеләргә әйт, алай бик карышмасыннар... Кызганмаячаклар...

А к т а ң. Кыргыйлар... Үтерүчеләр...

А к м а з. Җитте, кызый! Көч кемдә, шул дөрес... Берни кылып булмый... Түзегез! (*Актаң китә башлый.*) Син кая?

А к т а ң. Кит, кит...

А к м а з. Һай, кыз-хатын...

Каяндыр Ә с ә н  у г ы л йөгереп чыга.

Син кем, әй, тукта?!

Ә с ә н (*куркып кача*). Ә? Инәй, инәй!

Х а т ы н н а р йөгереп чыга.

Б и к ә. Олан! Йа Ходаем. Ник чыктың, ник?

Ә с ә н. Минем... (*Колагына пышылдый.*)

Б и к ә. Ник чыктың? Хәзер бит сине дә...

А к м а з. Үкермәгез! Хуш, хатын. Мин берни дә күрмәдем... Тик тизрәк...

Б и к ә. Рәхмәт, углан... Хәзер, рәхмәт...

Р ү б ә д ә. Ходай Тәгалә бу изгелегең өчен сиңа озын гомер бирсен...

А к м а з. Булды, хатыннар, бетсен!

Б и к ә. Бетте, бетте. Шым, ырудашлар. Актаң, бар, алып кит угланны.

Актаң белән Әсән китәләр. Акмаз тагын читкәрәк барып урнаша.

С ә г а т и. Бугазларын чәйнәп өзәр идем...

Б и к ә. Килен, булды!

С ә г а т и. Нәрсә булды? Менә бумы? Әллә... (*Камчы эзләрен күрсәтә*). Нәрсә? Күпме түзәргә?

Б и к ә. Кирәк, килен. Аларда көч. Түзәргә кирәк. Сезнең Кангл ыруы нинди көчле иде, алар да иелгән.

С ә г а т и. Булмас... ялган.

С ү н д ә й. Ялган... Ак шәһәрне җир белән тигезләгәннәр.

Р ү б ә д ә. Бишектәге оланнан алып, карт кешеләргә тиклем кырганнар. Кыз-хатыннарны да жәлләмәгәннәр, ди.

С ә г а т и. Ышанмыйм! Мин барыбер...

Б и к ә. Сабыр, Сәгати. Хәбәрләр дөрес. Ышанычлы кеше китерде...

С ә г а т и. Кем?

Б и к ә. Анысы мөһим түгел...

С ә г а т и. Нәрсә, безгә ышаныч юкмы?

Б и к ә. Кирегә сукалама, Сәгати. Ошбу хәбәрләр дөрес. Яу бик яман. Бар сахраны яндырып, кырып киләләр, ди. Әүвәл мине тыңлагыз.

С ү н д ә й. Ни әйтмәкче буласың? Хатын-кыз гакылына калгач, әй...

Б и к ә. Бабай, син тыныч булырга тырыш, сиңа бик йолкынырга ярамас...

Р ү б ә д ә. Утырыр инде, кирәкмәгән нисбәткә кысылып.

С ү н д ә й. Әй сәнә.

Б и к ә. Шул, карендәшләр, күнәргә кирәк.

С ә г а т и. Син нигә гел үзең хакимлек кыласың? Нигә гел баш буласың?

Б и к ә. Мин, бикә.

С ә г а т и. Булса, би юк инде.

Б и к ә. Оял, килен.

С ә г а т и. Нәрсә тагын?! Синең сүз дөрес түгел. Шул.

Б и к ә. Булды!

С ә г а т и. Ничек түзәсеңдер. Кызыңны хурладылар, олыларны кыйнадылар, карендәшләрне үтерделәр.

Б и к ә. Авыр, әйтмим. Канга тоз салырга тырышма.

Барыбыз өчен дә бердәнбер олуг бурыч бар: ыруны, нәселне саклап калырга кирәк. Ир-атны, угланны сакларга. Теләсә ни кычкырмагыз. Һәрбер ыру адәме — алтын бәһасе. Саклагыз үзегезне.

Сәгати. Шуларга баш иик, иман китерикме?

Рүбәдә. Йа Аллам, үзең ярдәм ит.

Бикә. Әлегә күнәргә, түзәргә кирәк булачак. Ни дисез?

Рүбәдә. Мин ни дияргә дә белмим, балам.

Сүндәй. Кит, килен, оят кирәк, ни йөз белән. Алар әллә нәрсәләр дияр. Үлгән ирләрегезгә, оланнарга хыянәт.

Сәгати. Үлсәм дә, аларга биреләсем юк. Мин аларны...

Бикә. Безне ике дә уйламый кырып бетерәчәкләр! Ыру бетә, нәсел югала. Ничек аңламыйсыз?.. Синең, минем, аларның сафлыгы, горурлыгы бер сукыр тиен тормый ошбу көндә! Күнәргә кирәк, вакытлы булса да.

Сәгати. Нәрсә, кызыңның сафлыгы да сукыр тиенме? (*Көлә.*)

Бикә. Барыбызның да...

Сәгати. Шә-ә-әп. Кызың бик куаныр инде. Юк, мин каршы.

Сүндәй. Соң, бетерсеннәр, үтерсеннәр! Шулардан чирканмыйча, сез, оятсызлар! Ирләрегез алдында, ата-бабалар йоласына төкереп. Акылга килегез, җир битләр?!

Рүбәдә. Ярабби, кызым, көн күзендә, ата-бабадан бирле күрелгәнме бу?

Сәгати. Шул шакшы атчабарларны якын китерсәмме? Чулмандай саф тәнемә... Мәңге.

Бикә (*ярсып, бик катгый итеп*). Булды! Ыру башы, хәләл ирем шәһит киткәннән соң, ыру иминлеге минем өстә. Сүзем: ыруны ничек тә исән-имин саклап калу өчен күнәргә боерам!

Сүндәй. Бикә?!

Сәгати. Син...

Бикә (*кисәк*). Кисмә сүзем! Әйтелде! Әзерләнергә. Түзәргә, ничек булса да сау калыгыз. Үзебез өчен түгел, кан өчен! Изге Ак сусар ыруы каны өчен! Ыруны саклау өчен!

Акмаз (*түземсезләнеп*). Булды, хатыннар, күп серләштегез.

Рүбәдә. Бетте, бетте, бәбкәм... Бигрәк акыллы балага охшагансың...

Китәләр.

А к м а з (*Бикәгә*). Мин сезгә тимәдем, тик әйт аларга, мин малай түгел, мин ир!

Б и к ә. Яхшы, углан, әй лә, яугир, азак алай сөйләшмәсләр.

Ут сүнә. М а л - т у а р тавышы. Чөнгут алае белән кайтып төшкән. Гомуми шау-шу. Ч ө н г у т керә.

Ч ө н г у т. Бимаж, Бимаж?!

Б и м а ж. Баш өсте, олуг яугир.

Ч ө н г у т (*кәефе килеп*). Хе-хе, баш өсте. Кая кадалдың? Җыйсыннар бу бөтен әтрәк-әләмне. Әмерем бар.

Б и м а ж. Хуш... Ә теге малайны?..

Ч ө н г у т. Акмазны? Ашыктырма, әлегә булмый. Соңрак.

Б и м а ж. Хуш, хуш, өлгерербез.

Ч ө н г у т. Җый барысын.

Б и м а ж. Баш өсте. (*Чыга.*)

А к м а з керә.

Ч ө н г у т. Ә-ә, синме?

А к м а з (*гаскәриләрчә*). Чакырдыгызмы, олуг яугир?

Ч ө н г у т. Оһо, син нинди! Йә, яугир, биредә тәртип булдымы?

А к м а з. Нәкъ шулай. Тик...

Ч ө н г у т. Нәрсә тик?

А к м а з. Кыз-хатыннар бик шыңшыды... Бабайның хәле бик начар, диләр... Бикәнең телсез кызы югалган... Тагын ма...

Ч ө н г у т. Тагын нәрсә?

А к м а з. Тагын... ни... Шул... Бар да әйбәт дияргә була.

Ч ө н г у т. Шыңшыйсылары алда әле.

Б и м а ж керә.

Б и м а ж. Бар да җыелды. Оһо, «бөек баһадир», хатыннар башлыгы да монда икән.

А к м а з (*камчысын селтәп*). Син, карачкы...

Б и м а ж. Син нимә, углан, мактап кына әйтүем. (*Чөнгут көлә, Бимаж аңа гына.*) Бу кадәр атасы булыр икән.

Ч ө н г у т. Кабаланма. Әйт, керсеннәр.

Х а т ы н - к ы з л а р керә.

Йә, ни ишетик? (*Беркем дә дәшми.*)

Б и м а ж. Сезгә әйтәләр, янә аңладыгызмы барын да?

Б и к ә (*алгарак чыгып*). Аңладык. Бездән ни кирәк?

Ч ө н г у т. Ни кирәк, ни кирәк. Янә дә кабатлыйм, алай башы Чөнгут нойон, сүзем: баһадирларны яхшылап урнаштырырга, аларның һәрбер әмерен карусыз тыңларга. Төшендегезме? Мин беттем.
С ә г а т и. Син...

Аның авызын Бикә каплап кала.

Б и м а ж. Нәрсә син? Җитмәдеме әллә? Хәзер...
Б и к ә. Юк, тәкъсир, күрәсез ич бер сүз дә дәшми.
Ч ө н г у т (*мыскыллап*). Ул барын да аңлаган, Бимаж. Күрәсең ич, сине дәшә, көчкә тотып торалар. Ха-ха-ха.
Б и м а ж. Мин әзер.
Ч ө н г у т. Хуп, яхшы. Менә шулай булырга тиеш. Бел, монда мин, бары мин генә баш!
Б и м а ж. Бары бөек Чөнгут яугир генә, төшендегезме?
А к м а з. Ничек? Ә атай?
Ч ө н г у т. Дәшмә, йолкыш бегич. Бел, туйдырды ул атаңның баш булуы. Янәсе, бөтен олуг яуга ул хуҗа, ул гына атаклы яу башы. Гарык! Менә без дә аннан ким түгел, ә, Бимаж?!
Б и м а ж. Нәкъ шулай, тәкъсир. (*Акмазга таба ымлап.*) Вакыт, хи-хи-хи.
Ч ө н г у т. Ә-ә, әйе. Шулай, Акмаз баһадир!
Б и м а ж. Бөек яугир.
Ч ө н г у т. Әйе, бөек яугир. Менә синең баһадирлыгыңны сынар чак җитте.
А к м а з (*онытып*). Чынлапмы?
Ч ө н г у т. Чынлап.
А к м а з. Мин әзер!
Ч ө н г у т. Кабаланма. Хәзер без, хатыннар, безнең карендәшлек, туганлыкны билгеләп, туй үткәрәбез. Олуг туй. Ха-ха-ха. Син... (*Актаңга күрсәтә.*)
А к т а ң (*куркып*). Минме?
Ч ө н г у т. Син, син. Чык бирегә.
Б и к ә. Нигә ул, нигә?
Ч ө н г у т. Кысылма, хатын! Тагын карышмакчы?
Б и м а ж. Акмаз яугир, яле!
А к м а з. Без сезне... (*Селтәнә.*)
Ч ө н г у т. Кирәкми. Чык әле мондарак. О-о, гүзәл!
А к т а ң. Әйе...
Б и к ә. Курыкма, балам, чык, чык, берни дә эшләтмәс.
Ч ө н г у т. Курыкма, курыкма. Киресенчә, олуг бәхет, шатлык бүләк итәм әле мин сиңа. Ха-ха-ха. Яшь кияүгә эләгәсең, бәхетең.
Б и м а ж. Мин дә әллә ни карт түгел инде анысы.
Ч ө н г у т. Дәшмә, Бимаж. Әмер шул, ыру халкы: олуг

туй ясыйбыз! Минем баш булу хөрмәтенә, туй! Шушы сылуны ошбу Акмаз яугиргә тапшырам! Сый әзерләргә. Сөҗү елга булып аксын! Баһадирлар, ял! Йә, Акмаз, күрсәт егетлегеңне!

Бимаж. Шә-әп!

Акмаз. Ничек? Мин теләмим. Минем баһадир гына буласым килә. Миңа кыз-хатын кирәкми. Мин...

Чөнгут. Бу ни, әмергә карышу?

Бимаж. Ни хәлгә җитте чиру. Алай башны тыңламыйлар.

Акмаз. Юк, мин карышмыйм, мин... Мин яу чаба алам, батырлык кыла... ә бу...

Актаң. Анам, мин куркам, әнкәй.

Бикә. Бөек би.

Чөнгут. Алай башы.

Бикә. Мәрхәмәт кыл, бөек алай башы! Ул бит әле бала гына... Бүтән...

Чөнгут. Бетте. Бүтәне кирәкми. Нәкъ менә шушысы, нәкъ менә синеке кирәк тә инде миңа. Үзеңә ярамый, ә бу бала, аңа ярый. (*Көлә.*) Ә күпме яшь булса, шулкадәр яхшырак ул, әйеме, Бимаж?!

Бимаж. Шулай, шулай.

Чөнгут. Нәрсә карап каттыгыз?! Туйга әзерләнегез. Бу көннәрдә күп яугирләр парланыр, уйлавымча.

Акмаз. Мин өйләнмим. Миңа кыз-хатын кирәкми. (*Китмәкче була.*)

Чөнгут. Кая? Беркая китмисең. Пешмәгән углан булсаң, карап тор, яугир нинди була ул. Бимаж, әзерлән!

Бимаж (*кыланып*). Минме?.. Әй, мин оялам бит.

Бикә. Бала бит ул, мыскыл итмәгез, зинһар.

Сәгати. Нәрсә, кызганычмы? Бая нәрсә дидең? Үзеңнеке булгач, кызганычмы? Әйдә, әйдә, күрсәт гыйбрәт, без дә белеп калыйк нишлисен.

Бикә. Кызым, рәнҗемә. (*Елый башлыйлар.*)

Чөнгут. Тик торыгыз, хатыннар. Алыгыз шул кызны. Тирмә әзерләгез. Ха-ха-ха!

Актаңны сакчылар аерып алалар.

Актаң. Анай, мин куркам, мин... коткарыгыз, зинһар өчен.

Чөнгут. Селкенмәскә. Хәзер кырып салырлар!

Актаң. Зинһар, мәрхәмәт кыл...

Акмаз (*кире борылып*). Хуш, мин риза. Тик бел, Чөнгут, атай килгәч, барын да беләчәк. Атай мәңге болай кыланмады.

Чөнгут. Телеңә салынма, малай актыгы. Мине

өйрәтмәкче тагын. Бимаж, нәрсә сузылдың, эшеңә тотын.

А к т а ң. Әнием.

Б и к ә. Балам, ни кылыйм?

А к м а з. Кузгалма. Чабам!

Б и м а ж. Мин нәрсә, мин...

Ч ө н г у т. Син, малай?!

А к м а з. Булды, Чөнгут! Мин сиңа ышандым, сантый. Хуш, мин разый. Бүтән буш сүз кирәкми. Аң бул, атай әйләнеп кайткач, аның хозурында каласың. Җавап бирерсең.

Б и м а ж. Мин нәрсә...

Ч ө н г у т. Җебемә, Бимаж! Атаңмы? Ха-ха-ха. Атаң кайтмаячак. Бетәчәк алар. Монда мин хуҗа. Мин баш! Бетте. Икесен дә тирмәгә бикләргә, сак куярга. Бел, чебеш, пешмәсәң, Бимаж түгел, яугирләр тотыначак эшкә. Ә аларны беләсең, алар алар инде... Күргәнең бар...

А к м а з. Ярый, өйрәтмә.

Ч ө н г у т. Малай?!

А к м а з. Сөйләнмә. Биклә үзеңнең тирмәңә.

Ч ө н г у т (*ярсып чыгып, төкрек чәчә-чәчә*). Алыгыз бу өшегәннәрне! Ә сез (*хатыннарга*) табын әзерләгез. Мин сезне... Мин әле сезгә...

Б и м а ж  с а к ч ы л а р белән Ә с ә н н е әләктереп килә.

Б и м а ж. Тәкъсир, менә кемне тоттык.

Ч ө н г у т. Бу кем тагын?

Б и м а ж. Малай, ир-ат. Яшергәннәр, корт чаккырлары.

Ч ө н г у т. Нәрсә тагын? Чабарга да вәссәлам. Кем яшергән, камчыларга, асарга!

Ә с ә н (*Чөнгутка кечкенә агач пычак белән кизәнеп*). Син ерткыч, син әшәке! Син минем этиләрне, абыйларны үтерүче! Мин сине үтерәм, агай, бел...

Ч ө н г у т (*аны тибәреп*). Бу ни бу? Ни сөйли бу үләксә?

Әсәрләнеп, Б и к ә йөгереп керә, тезләнә.

Б и к ә. Зинһар өчен, олуг яу башы, ярлыка угланны. Олан гына бит әле ул. Ни сөйләгәнен дә белми. Кил, улым.

Ә с ә н. Әни-и. (*Елый.*)

Ч ө н г у т. Бетте, хатын. Ир заты калырга тиеш түгел. Бимаж!

Б и м а ж. Әйе, тәкъсир.

Ч ө н г у т. Хәзер үк җәзаларга.

Б и к ә (*тезләнеп*). Ярлыка, үтермәгез баланы, аның гаебе юк. Мин яшердем, мин гаепле. Бердәнбер ир бала. Хода хакына...

Чөнгут. Кит моннан.

Б и к ә. Хет исән калсын.

Чөнгут. Кит, хатын. Ярый, Бимаж, богау салып, урдага озаттыр. Боларны суктырырга.

Бимаж. Үтәлер, тәкъсир.

Б и к ә. Рәхмәтләр яусын сезгә... Углан, углан! (*Егылып кала.*)

Чөнгут (*бөтенләй юләр кеше сымак ярсып, акаеп*). Яугирләр! Туй итәбез! Мин җиңдем! Бар дөнья минеке! Астын өскә әйләндерегез! Шанлы туй ясыйбыз! Ха-ха-ха! Йә, Бимаж, күңеллеме?! Шәп хөкемдармы мин?!

Бимаж (*елмаеп*). Шаккаткыч. Хәтта мин бу кадәр үк көтмәгән дә идем...

Ут сүнә.
Актаң белән Акмаз тирмәгә бикләнгән килеш. Икесе ике почмакта. Актаң куркып поскан, елый. Акмаз ни эшләргә дә белми басып тора. Аларның монда шактый озак утырганнары сизелә.

Акмаз. Мин сиңа тимим. (*Тимәгәнен аңлатып, бер кырыйга барып ята.*)

Актаң дәшми. Пауза.

Утырып ял ит... (*Пауза.*) Моннан тиз генә чыгармаслар, өметләнмә... Син миннән шүрләмә. Мин сиңа орынмам.

Актаң дәшми.

Күпме гомер басып торасың инде, бер сүз дәшсәң... Соң утыр инде, нәрсә котың очты. (*Актаң чәрелдәп куя да куркуыннан шапылдап утыра.*) Болай утырып ни? Әйт, берәр сүз?

Актаң кабат дәшми.

Аңла, мин кыз-хатыннарны сөймим, миңа кыз-хатын кирәкми, белдеңме?! Безнең яугирләр кыз-хатыннар белән әллә ниләр кылалар, беләм. Тик мин алай түгел. (*Пауза.*) Хе-хе, атай да орыша инде кайчак, әллә кемгә охшагансың син дип... (*Актаңга карап-карап тора да, төенчек чыгарып, ризык ала, ашый башлый. Бераздан Актаңның күз карашын сизеп, тыгылып калгандай була, борылып карый.*) Ашыйсың киләме? (*Актаң дәшми, күзләрен мөлдерәтеп карап кына тора.*) Мә, мә, монда минем җитәрлек... (*Актаң, куркып, тагы да читкәрәк китә.*) Мә инде, мә, ал, курыкма... (*Ризыкны урта тирәгәрәк куя*

*да, үзе читкәрәк китеп баса. Актаң озак кына кыймый тора да, кисәк кенә йөгереп килеп, ризыкны алып, читкә ташлана.*) Тәмлеме?.. Телеңне йотма тагын... Курыкма... Бәгъзе углан яуда гына алыша торган яугир дип әйттем бит инде. Бу ир сүзе, бел... Минем яуда гына баһадир буласым килә... Ошбу җебегән, елак кызыйга нә тиим?.. (*Пауза.*) Мин бит яугир, соңра алай башы буласы... Йә, сүрелдеңме инде?.. (*Аңа якынаймакчы була.*)

Актаң (*чырылдап*). Якын килмә!..

Акмаз. Килмим, килмим. Өркемә генә.. Көчкә... теле ачылды... Әллә өркүдән телсез калдымы дип торам... Һай, кыз-хатын... Бигрәк өркәк... Хуш, аша, аша, өркемә генә... Һай-вай! Кызганам мин сине... Үзең ниндәй матурсың, ә яклаучы бер ир — яугирегез юк... Начар бу, начар...

Актаң (*кыймый торганнан соң*). Эчәсем килә...

Акмаз. Менә анысы юк шул. Түзәргә туры килә. Йә, сүрелдеңме инде?

Актаң (*шүрләп*). Ә син миңа чынлап тимәссеңме?

Акмаз. Әйттем бит инде, һай бу кыз-хатынны.

Актаң. Ант эч.

Акмаз. Эчмәсәм? (*Аңа якыная.*)

Актаң (*чәрелдәп*). Килмә!

Акмаз. Ошбу җиһандагы дала кояшы белән ант эчеп әйтәм — орынмыйм ошбу хатынга, әй лә, кызыйга. (*Пауза.*)

Актаң. Барыбер, азрак читтәрәк тор, яме?..

Акмаз. Хуш, хуш. (*Пауза.*) Шулай су капкандай утырыйкмы? (*Актаң дәшми.*) Ай-һай, ошбу тирмәдә озак утырасы булыр... (*Пауза.*)

Актаң. Ни кылыйк?

Акмаз. Сүлә берәр ни?..

Актаң. Ни дияргә дә белмим шул...

Акмаз. Синең атың ни була?

Актаң. Актаң.

Акмаз. Актаң... Матур атама. Ә мин — Акмаз.

Актаң. Синең дә... (*Пауза.*)

Акмаз. Без ошбу вилаятькә килгәнче, сез ничек яшәдегез?

Актаң. Матур, бик күркәм яшәдек.

Акмаз. Ат чаптыгыз, яу чаптыгыз, калалар, ырулар алдыгыз, шулаймы?

Актаң. Ю-у-ук. Ат чаптык, тик яу түгел. Без иген иктек, мал көттек. Сез дә алай түгелме?

Акмаз. Безләрдә ул рәвештә түгел. Без күбрәк яу чабабыз.

Актаң. Адәмнәр кырасыз, ыруларны бетерәсезме?

А к м а з. Шулай язгандыр инде. Тик без ыруларны бетермибез, яуда гына. Югыйсә алар безне бетерәчәк...

А к т а ң. Соң, ир-ат беткәч, ыруг бетә бит инде... Барыбер сез ерткычлар...

А к м а з. Менә мин ерткычка охшаганмы?

А к т а ң. Юк та...

А к м а з. Шулай булгач. Безләрне яхшырак алышкан өчен, тәкрәрләү хак түгел. Яуда без җиңгәнгә без гаепләме? Без җиңелсәк — безне кырырлар иде, хакмы?

А к т а ң. Бәлки. Атай да сөйли иде... Әфрәнеҗ халыкларын, сәкалибә ыруын җиңеп кайттык, дип...

А к м а з. Менә бит... Без оста яугир булмасак, без бетәр идек... Безне беркем дә җиңә алмый!

А к т а ң. Кыланчык, бала.

А к м а з (*кызып китә*). Әй, кыз-хатын, тый телеңне! Мин ир, мин яугир! (*Актаң куркып, почмакка поса.*) Сөйләнмә алай, яме.

А к т а ң (*курка, курка*). Я-я-ярар...

А к м а з. Әрләмә, үзең бит...

А к т а ң. Юу-ук, үзем шул, ачуланма...

А к м а з. Ни өчен яу чапканны кайвакыт үзем дә аңламыйм мин. Менә үзем өчен булса, мин бөҗәкне дә үтермәс идем дә... Ә монда... Яугир булырга кирәк... Ансыз булмый, ышанасыңмы?

А к т а ң. Ышанам.

А к м а з. Хуп.

А к т а ң. Мине атам бик ярата иде...

А к м а з. Нишлисең бит хәзер... Алар бик батыр орыштылар. Атаем да сокланды...

А к т а ң. Ә син бөтенләй үзегезнекеләргә охшамагансың.

А к м а з. Алай димә. Халык арасында төрле кеше була. Әйбәтләре дә бик күп аларның... Тик эшләре шул булгач...

А к т а ң. Барыбер әшәкеләр. Беләсеңме, Кангл ыруындагы егеткә ярәшелгән идем мин, ә хәзер...

А к м а з. Ошбу көндә кайда инде ул?

А к т а ң. Аларның ыруы да бөтенләй кырылган.

А к м а з. Янә дә безме?

А к т а ң. Тагын кем булсын...

А к м а з. Мин үзем дә хәзер күп нәрсәне аңлый башладым кебек. Ошбу дошман дигән кешенең башка ыру кешесе түгел, нәкъ менә үз ыруында да булуы мөмкин икән. Вә илә чит ыру кешесе дә кан карендәш кебек дус була ала. Мин әүвәле сезнең халыкка гел дошманнар гына итеп карадым. Ә хәзер...

А к т а ң. Нәрсә хәзер?

А к м а з. Мин тоям, менә син миңа хәзер ничектер карендәшем кебек якын күренәсең. Әйтерсең без синең белән гел бергә ат чабып үскәнбез.

А к т а ң. Мин дә тынычланып калгандай булдым. Олуг орыштан соң беренче тапкыр үземне өркемичә, тыныч итеп тойдым. Бер карасаң, ошбу тирмәгә бикләүләре әйбәтрәк тә булып чыкты. Тыныч. (*Көлешәләр.*) Теге, сезнең кем әле?..

А к м а з. Чөнгут албасты.

А к т а ң. Шул Чөнгуттан да курыкмам шикелле.

А к м а з. Син чынлап та курыкма. Ошбу көннән сине хурларга ирек бирмәм.

А к т а ң. Ышанам да...

А к м а з. Бер уйласаң — син башка ыруныкы. Кан башка, гадәт башка, тик барыбер ниндидер якынлык тоям. Димәк, якынлык кан кардәшлектә генә түгел, ә башка бәйлектә дә булуы мөмкин икән. Бәлки, иң мөһиме, берберсеңне аңлау, тоюдыр, ә, бикәч? (*Актаң аңа аптырап карый, сикереп тора.*) Шаярам гына... Менә атай гына кайтсын, бар да биредә әйбәт булыр.

Ут сүнә.

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Баштагы мәйдан алды. Ж а д а н  б а һ а д и р әйләнеп кайткан. Ул урта тирмәгә урнашкан, янында ш и х н ә л ә р, Б и м а ж, А к м а з, К ә р л ә. Җадан бик ярсыгандай күренә.

Ж а д а н. Соң?

Б и м а ж. Мин кечкенә кеше...

Ж а д а н. Нә булды биредә, ни кылып беттегез, дип сорыйм мин сездән?! Кечкенә адәм... Кая хатын?

А к м а з. Ул биредә...

Б и к ә (*керә*). Ни йомыш?

Ж а д а н. Әле ишеткәннәр, биредә булган хәлләр хакмы?

Б и к ә. Хак би, әй, тәкъсир. Артыгы белән.

Ж а д а н. Артыгы белән. (*Бимажга.*) Ни әйтеп калдырдым мин сезләргә?! Ә-ә?! Нә әмер кушып?

Б и м а ж. Мин бу эштә бәләкәй кеше, тәкъсир. Бәгъзе тамашага фәкыйрегез комачауларга тырышып карады. Олуг төмән ачуланыр, дидем. Безләрне кем тыңласын? Ул бит Чөнгут, беләсез.

К ә р л ә. Без болай, без тегеләй иттек, көчәнә-көчәнә мәтәлеп үк киттек...

Җ а д а н. Кит, Кәрлә!

К ә р л ә. Әйттем мин сиңа, чамала, дидем...

Б и м а ж. Кәрлә, югал!

Җ а д а н. У-ух, нәләт яугырлары! Олуг «Яса» әмерләрен үтәүче калмадымы?! Үтәтермен! Башыгыздан колак кагарсыз!

Б и м а ж. Бөтенесенә бары ул...

А к м а з. Ул гына түгел, атай...

Җ а д а н. Атай! Син нә карап тордың? Баһадир булган, әмер тыңлый, тфү!

А к м а з. Атай?!

Җ а д а н. Нинди әмерне тыңларга, нә тыңламаска икәнне аерырга кирәк! Кая ул баш?!

А к м а з. Гаеп миндә, атай.

Җ а д а н. Кайда ул Чөнгут?!

Б и м а ж. Хәзер тотып китерергә тиешләр, олуг хаким.

Җ а д а н. Тагын ни?

Б и м а ж. Күп хатыннар карышты, шактыен җәзаларга туры килде. Шул эш барышында бер яугирне чәнечкәннәр, үзе исән, берни хәтерләми, сөҗү күп эчкән. Теге көчләнгән дигән кыз...

Җ а д а н. Нинди кыз?

Б и м а ж. Т-с-с, хи-хи... Бикә кызы. Шул көчләнгәч, алмашкан иде дә, суга төшеп үлгән...

Җ а д а н. Шуннан?

Б и м а ж. Бер ир табылды.

Җ а д а н. Ир? Нинди ир тагын?

Б и м а ж. Углан инде. Ул да моныкы. Полон итеп олыска озаттык. Теге качкан ирне чаптылар.

Җ а д а н. Беттеме?

Б и м а ж. Бетте кебек. Мин тырышып карадым да...

К ә р л ә. Ул би-ик каты тырышкан, тәкъсир, күбрәк үтерергә. Бу синең иң асыл күгәрченең, Җадан, ялгышма, аң бул!

Җ а д а н. Кит моннан, туйдырдың.

Ч ө н г у т н ы китерәләр.

Б и м а ж. Менә үзе дә...

Җ а д а н. Йә, ни ишетәек?

Ч ө н г у т. Мин берни төшенмим, ни булды?!

Җ а д а н. Нә кырдыгыз биредә дидем мин?!

Ч ө н г у т. Ни булсын, һәрчактагыча гына.

Б и м а ж. Ни рәвештә сөйләшәсең син?!

Җ а д а н. Хуш, сөйләсен. Шулай да булсын ди... Бу вилаятькә кем баш булмакчы иде, ә?!

Ч ө н г у т. Ничек инде? Ошбу вилаятькә бары сез генә баш. Кем баш була алсын тагын бәгъзе җирдә? Кызык...

А к м а з. Хәйләләмә, куркак!

Ч ө н г у т. Малай, син нә сөйлисең?! Син бик сәер угыл икән.

А к м а з. Син! Мин синең ише түгел! Мин яугир, белдеңме?!

Җ а д а н. Җитте! Җавап бир, Чөнгут?

Ч ө н г у т. Шул. Мин бары сезнең бөек әмерләр үтәлсен өчен тырыштым. Яңглышсам, белмим... бүтәнчә булдыра алмыймдыр... Мин көтүче түгел, мин яугир...

Җ а д а н. Угланны нә мыскылладың дип сорыйм мин синнән, минем нәселне?!

Ч ө н г у т. Хак түгел. Җебек икәнен күреп, чын яугир ясыйсым килгән иде дә...

А к м а з. Әй син?!

Җ а д а н. Булды, Акмаз. Син, Чөнгут, артыгын кылана башладың. Әмерем: Алайны Хулагу яугиргә тапшырып, алдагы көннәрдә алай атларына аткачы буласың. Олыска кайткач, сиңа Хан хөкеме булыр! Беттем! Төшендеңме?

Ч ө н г у т. Ярый... Җадан.

Җ а д а н. Алып китегез. Мин беттем. Таралыгыз! «Яса» әмерләрен бозган һәркемгә шушы корылык булачак! (*Акмазга.*) Син кал.

А к м а з. Әйе, атам?

Җ а д а н. Нигә мин төрле ят сүзләр ишетәм?!

А к м а з. Нинди, атай?

Җ а д а н. Ул кызый белән нә кылып йөрисең син?

А к м а з. Кайсы?

Җ а д а н. Кыланма минем белән!

А к м а з. Ә-ә, аны әйтәсеңме? Беләсеңме, атай, ул шундый әйбәт кыз...

Җ а д а н. Әйбәт. Менә ни: сезнең арада берәр ни булдымы?

А к м а з. Төшенмим?!

Җ а д а н. Якынлыкмы диим... Соң?

А к м а з. Нәрсә син, атай. Мин яугир. Ул миңа иптәш. Ул шундый күркәм кыз, беләсеңме...

Җ а д а н. Белмим, белергә дә теләмим! Бел, син яугир. Кыз-хатынга коры булырга кирәк. Якын бул да, ташла, кит. Бүтән якын барма. Бөтен бәла-казаң алардан булыр...

А к м а з. Атай, мин бала түгел!

Ж а д а н. Бүлмә сүзем! Бала син. Тыңла атаңны. Ябай кызлар белән уйнап, хихылдап йөрергә тиеш түгелсең. Син югары нәселдән, каның бөтенләй башка, аңладыңмы?

А к м а з. Ул бит миңа бер иптәш, дус кына, нигә атай?!

Ж а д а н. Җитте, угыл. Шул: гореф-гадәтне сакламау, уен аша әллә кая кереп китә дә ул. Ошбу җирдә син канны пычратырга тиеш түгел. Синең бичәң лаеклы ырудан булырга тиеш.

А к м а з. Мин...

Ж а д а н. Дәшмә. Тыңла, соңгы сүзем: әгәр тыңламасаң, олыска озаттырырмын. Богаулап. Бар.

А к м а з. Атай, мин...

Ж а д а н. Булды, бар, бар...

Авансцена яисә кеше күп йөрми торган аулак урын. Ч ө н г у т керә. Ул як-ягына карана да, ниндидер кош булып, тавыш биреп ала. Тагын кабатлый. Аңа җавап итеп ниндидер тавыш ишетелә.

Ч ө н г у т. Син кайда? (*Беркем дәшми.*) Кем монда?

Б и м а ж чыга.

Б и м а ж. Ш-ш-ш, шаулама...

Ч ө н г у т. Юктыр дип торам инде.

Б и м а ж. Шаулама, дим... Нәрсә кытаклыйсың?

Ч ө н г у т. Шаулама... Кая югалдың?

Б и м а ж. Кая, кая, кисәк китеп буламы? Яттылар, ычкындым. Кая теге?

Ч ө н г у т. Күренми әле.

Б и м а ж. Аңа ышанып та...

Ч ө н г у т. Сатмас, үче олы аның да. Минеке кебек... Син генә ул...

Б и м а ж. Нәрсә, мин?

Ч ө н г у т. Нәрсә, нәрсә? Аның ягына аудың.

Бимаж көлә.

Син нәрсә?

Б и м а ж. Ошбу уйны аңладың дип торам тагын.

Ч ө н г у т. Нинди уй?

Б и м а ж. Шаулама, дим. Ярар, башың эшләмәсә, тик кенә тор.

Ч ө н г у т. Юк, син...

Б и м а ж. Җүләр. Әгәр мине дә актарып чыгарсалар, нә файда? Әлегә мин аларның бөтен серләрен белеп торам.

Ч ө н г у т. Ә-ә?!

Б и м а ж. Бә-ә? Әллә минем нәфрәт олуг түгелме? Булды. Мин бәләкәй адәм. Син олуг башлык буласы. Анда хәлләр ничек?

Ч ө н г у т. Ничек, ничек? Аткачының, атлар башлыгының хәле ничек булсын. Начар.

Б и м а ж. Шыңшыма. Анда зыян кылу ягын кара.

Ч ө н г у т. Өйрәтмә, беләм ансын.

Б и м а ж. Кая соң теге?

Ч ө н г у т. Чү, кемдер килә.

Б и м а ж. Үзе түгел микән?

Сәгати керә.

Сөйлә, хатын.

С ә г а т и. У-у, күрә дә алмыйм инде үзегезне.

Ч ө н г у т. Әй син, хатын!

Б и м а ж. Ш-ш-ш, булды, Чөнгут. (*Йомшак кына.*) Син, хатын, ялгышма. Без киресенчә, алай башыннан үзгә буларак бәгъзе ыруга ярдәм итәргә телибез.

С ә г а т и. Йә, йә, бик күркәм күрәм мин сезне. Шул. Йомшак җәеп, катыга утыртырга маташмагыз! Миннән нә кирәк? Үзегезнекеләргә дошман булмасагыз күрсәтер идем мин сезгә...

Ч ө н г у т. Күрсәт соң...

С ә г а т и. Менә бит. Хәзер үк күралмыйсың син дә мине. Бөтен дөнья бер-берсенә дошман. Кем аңлата ала моны? Әллә ахырзаман шаукымымы?

Б и м а ж. Хатын, шаулама. Чөнгут, соңгы кисәтү.

Ч ө н г у т. Бетте бит инде.

Б и м а ж. Син бераз ялгышасың, хатын. Без ихлас, чын күңелдән. Без чын-чынлап ошбу вилаятьтә нык тәртип урнаштырмакчы булабыз. Болары соңла. Эшкә күчик: сезнең кемнәр бар?

С ә г а т и. Бар, ышанычлы хатыннар.

Б и м а ж. Шул. Әлегә элек сөйләшкәнчә зыян кыла торсыннар. Вакыт җиткәч, мин әйтермен. Мин әйткән яугирләргә якын бармаска. Корал җыелсын.

С ә г а т и. Белдек ансын.

Б и м а ж. Шар ярып йөрмәгез. Астан гына...

С ә г а т и. Булыр. Хәйләле, ай хәйләле үзең. Явыз да...

Б и м а ж. Бәгъзе синең хафа түгел, бар.

С ә г а т и. Үч аласы булмаса...

Ч ө н г у т. Бар, бар...

Сәгати китә.

Б и м а ж. Җитте дидем, Чөнгут.

Ч ө н г у т. Тукта әле. Ник син болай? Мин бит әле монда...

Б и м а ж. Җүләрләнмә. Шул янә дә син олуг алай башы булсын өчен тырышам да инде. Син бит безнең булачак

олуг каган. Тик әүвәле минем сүзне генә тыңла. Без ошбу вилаятьтә, олуг дала иясенә тапшырып, үзебезнең бөек олысны оештырабыз. Бел: кешеләр бер-берсен күрә алмаганда, бер башны икенчесенә алмаштыру берни тормый! Аң бул, мине тыңласаң — озак баш булырсың! Атла, шәйләмәсеннәр.

Ч ө н г у т. Төшендем, тәкъсир, әй, тфү, Бимаж. Килештек! (*Китә.*)

Б и м а ж. Өйрәнә... (*Чыгып китә.*)

Авансцена. Кич. А к т а ң йөгереп керә. Аның юлын А к м а з булә.

А к т а ң. Кит, җибәр.

А к м а з. Нә булды сиңа?

А к т а ң. Берни... ашыгам.

А к м а з. Йә инде... Нә ул кадәр ашыгасың?

А к т а ң. Эшем бар...

А к м а з. Күрмәгәнгә хәттин ашты, ә син ашыгасың...

А к т а ң. Мәрхәмәт кыл, ашыгам шул, эш күп...

А к м а з. Ә мин тоям, син качып йөрисең кебек...

А к т а ң. Менә инде... ник качыйм...

А к м а з. Ошбу фәкыйреңне күрсәң, угрыдай качып китәсең... Төшенмим шул кыланышны...

А к т а ң. Юк... нә... нә инде... һич алай түгел... Әүвәле вакыт юк... Аннан...

А к м а з. Нә аннан?

А к т а ң. Әнкәм дә инде...

А к м а з. Әнкәңә нә булган, хозурына төшенмим!

А к т а ң. Акмаз, янә дә безгә болай очрашмаска кирәк... Бетсен ошбу уен...

А к м а з. Сабырланчы... Нинди уен? Нигә күрешмәскә?

А к т а ң. Шулай инде... Читен миңа...

А к м а з. Вә ләкин берни төшенмим!.. Миңа нә кыен икәнен белсәң... Ошбу күрешүгә шундый кыяләндем. Бик иркә иде бәгъзе кавышу. Ә син юк та юк... Мин нә кылаем?

А к т а ң. Өзгәләмә бәгырьне, мәрхәмәт кыл... Кит син тизрәк бу тирәдән, шәйләмәсеннәр бергә...

А к м а з. Нигә шәйләмәсеннәр? Ошбу кавышу сиңа да, миңа да илтифат икән, нә качарга?! Әти дә котыра, син дә качасың. Мин нә кылыйм?

А к т а ң. Котыра?! Уф Аллам, китим мин...

А к м а з. Тукта?! Сиңа җиткерделәр мәллә?

А к т а ң. Нәрсәне?

А к м а з. Атайның ачуын!

А к т а ң. Әйе...

А к м а з. Һай, атай... Нә дип?

Актаң. Анам әйтте, ошбу көрешүне бетерегез, ди, илә...

Акмаз. Нә илә?

Актаң. Атасы сине бетерәчәк, ди...

Акмаз. Син ошбу сүзләргә карап миңа карамаска булдыңмы?

Актаң. Нә эшләем?

Акмаз. Их син, кызый...

Актаң. Нә эшлим? Егълап та карадым. Анай да егълады. Кызгандым. Атаең бик-бик ярсыган. Тагын бер күрсәм, полон итеп, олоска озаттырам дип әйтә ди.

Акмаз. Һай, атай, атай.

Актаң. Күрешмәек без янә, Акмаз... Хода хакына... Кыен булса да. Нә кыласың? Тәкъдиребез шулдыр... Яме, ачуланма...

Акмаз. Ю-у-ук, бу килеш калдырмыйм!

Актаң. Кызма, Акмаз. Үзеңә дә уңай булмас... Азак зыян кылырлар... Кирәкми...

Акмаз. Соң, Актаң, без нә язык кылдык? Ошбу тирәдә кемгә зыяныбыз тиде? Атайгамы? Сезнекеләргәме? Берни төшенмим...

Актаң. Нә кыласың. Гореф-гадәтләр шундыйдыр инде... Ярамыйдыр... Түзик.

Акмаз. Юк, Актаң. Әүвәле баһадир булам дип ябай әтәч булып йөргәнмен. Хәзер тоям — ир-егет каны керде. Ә яугир булу ул әтәчләнү, яуда кыру түгел, үз-үзеңне, мин-минлегеңне ачу, ялганнарыңны җиңү икән. Боларның барын да мин син илә күрешә башлагач аңладым. Хәтерлисеңме, тирмәдәге көнне башланды бәгъзе халәт. Шулай булгач, ничек мин синнән баш тартыйм? Ничек сине кире кагыйм? Син миңа ошбу вилаятьтәге бар кешедән дә якынрак.

Актаң. Аңлыйм да мин, Акмаз, сизәм... Янә дә Хода хакына, сабыр бул...

Акмаз. Хуш, синеңчә булсын. Без аларга белгертми генә очрашыйк.

Актаң. Акмаз?!

Акмаз. Булды, дәшмә! Ул ялган илә, күңелең салынмаган сүзең кирәкми. Тоям, күңелеңдә башка. Һәм ул — иң мөһиме. Әлегә шулай очрашыйк. Соңла күз күрер. Бәгъзе кыенлыкның нинди дә булса җаен табармын. Йә атамны күндерермен.

Актаң. Нигә?

Акмаз. Би кызын кәләшем итәргә.

Актаң. Алай сөйләшмә. Миңа кыен...

Акмаз. Кичер. (*Пауза.*) Беләсеңме, мин баштарак

яудан соң, сезнең кешеләргә гел дошман итеп карый идем.

Актаң. Мин дә сезгә...

Акмаз. Миңа дамы?

Актаң. Сиңа да...

Акмаз. Бу халәтне ничек аңлатырга да белмим. Чиктән тыш дошман күрә идем, ә хәзер — сөеп карыйм. Вә миңа бу хистән рәхәт, бик рәхәт. Мин бернинди кыенлык сизмим. Мин нинди иркен! Кешеләрне дошман күрмәү ничек рәхәт икән.

Актаң. Ә мин...

Акмаз. Нә син?

Актаң. Мин барыбер әшәкерәктер, Акмаз. Мин сезнең кавем кешеләрен барыбер якын итә алмам.

Акмаз. Нә кыласың? Без җәллад кыяфәтендә шул хәзер. Минемчә, барыбер кичерергә тырышырга кирәктер. Үч барыбер бәхет китермәс ошбу дөньяга. Ул кавем арасында да җүнле кешеләр бар, Актаң.

Актаң. Хәзер күрәм дә. Ләкин... Белмим... Торабара... Бәлки...

Акмаз. Ә сезнең үз кешеләрегез дә сәер.

Актаң. Ник?

Акмаз. Һе Алла, Алла дип, әллә ничек табыналар.

Актаң. Ә сездә алай түгелме?

Акмаз. Юк шул. Бездә гади генә. Бөек дала иясе, яисә башкасы дисең дә. Атай шуңа да ярсыгандыр әле ул... Сезнекеләр сәеррәк булганга.

Актаң. Ай, Акмаз. Мин куркам инде, нә әйтергә дә белмим.

Акмаз. Һәй, андамыни, табынудамыни хикмәт, әйеме? Беләсеңме, Актаң, килер, бәлки, шундый көннәр, кешеләр бер-берләренә дошманлыкларын онытып, ничек табынуларына карамастан, бер-берләренә изгелек кенә теләп яши башларлар.

Актаң. Изгелек... Белмим, минемчә, андый көннәр һичкайчан да тумас.

Акмаз. Юк, тиз генә диюем түгел. Бихисап күп, ишле еллар үткәч.

Актаң. Кем белә, кем белә...

Акмаз. Алары нә. Бу көндә мине генә читләмә. Әйт әле: менә минем хозурда ничек?

Актаң. Иялəндем инде...

Акмаз. Ә миңа синең белән...

Актаң (*сүзен бүлеп*). Сизәм, Акмаз.

Акмаз. Хуп. Алайса, һәр кич ошбу...

Актаң. Күрмәсеннәр генә инде...

А к м а з. Син разый...
А к м а з. Сау бул. (*Китә.*)
А к т а ң. Хуш. (*Икенче якка китә.*)

Алдагы сәхнә. Җ а д а н, К ә р л ә, Б и к ә керәләр. Җадан бик ярсулы.

Җ а д а н. Кайда Бимаж? Кайда?!

Б и к ә. Бәлки...

Җ а д а н. Ә сине, хатын, бу галәмәт өчен олуг җавап көтә! Кит күз алдымнан.

К ә р л ә. Азгын күңелең туймаган, азагыннан ким калган...

Җ а д а н. Кит, буталма, Кәрлә! Бимаж! Кайда бу эшлексез?!

Б и к ә. Минем нә гаеп? Үз оланым да юкка чыкты.

Җ а д а н. Берни белмим! Тик торганда булган эш түгел бу?! Тик шуны яхшы бел: башың илә җавап бирәсең углан өчен! Бөтен ыруың берлә!

Б и м а ж йөгереп керә.

Б и м а ж. Тәкъсир, тәкъсир, ошбу тирә-якны айкап чыктылар, беркем юк. Менә бу гына... (*Акмазның шлемын бирә.*)

Җ а д а н. Каян, каян алдың?

Б и м а ж. Елга буенда, яр өстендә.

Җ а д а н. М-м-мх! Суга ук атканнар микәнни? Этләр! Агым түбен актарырга!

Б и м а ж. Ай-һай, агымы нык, калды микән...

Б и к ә. Кызым, ай оланым...

Җ а д а н. Нә ыңгырашасың, Бикә? Җавабыңа әзерлән. Җәза, олуг җәза көтә ыруыгызны! Бимаж!

Б и м а ж. Баш өсте.

Җ а д а н. Су төбен актарсыннар. Ашыкма! Бөтен ыруны иләк аша үткәрергә, барча адәмне тикшерергә! Камчыларга явызларны, угланны табарга!

Б и м а ж. Белмим инде...

Җ а д а н. Җир астыннанмы, каянмы, белмим, угланны табарга, табарга, табарга!!!

Б и м а ж. Хуп, хаким... (*Китә.*)

К ә р л ә. Үзегез, ошбу этлеккә бары үзләрегез гаепле...

Җ а д а н. Ычкын, Кәрлә!

Кәрлә кача.

Бел, Бикә, мин сезләргә йомшак булдым. Әгәр олан табылмаса, ыруга көн булмаячак.

Ут сүнә. Шул ук мәйдан. Б и к ә ялгызы. Нидер кылып йөри. С ә г а т и керә.

С ә г а т и. Мәслихәтме, Бикә?

Б и к ә. Ә-ә, килен, әйдә, уз.

С ә г а т и. Юк, бик узып торып булмас, алай башы тирмәсенә...

Б и к ә. Хуш, ни йомыш, алайса?

С ә г а т и. Рүбәдә әби күрергә тели, аны озата килдем.

Б и к ә. Соң керсен, керсен, чит кавем түгел ләса...

С ә г а т и. Тәңре белә инде ансын, кем чит кавем, кем чит түгел. Бөтенесен болгаттылар.

Б и к ә. Син әллә ничек төртмәле сөйләшәсең әле, килен. Килешеп бетми.

С ә г а т и. Ярар инде, без кыйналган бәндәләргә...

Б и к ә. Дәш әбине.

Сәгати чыга.

Йа Аллам, тагын нә инде...

Р ү б ә д ә керә.

Р ү б ә д ә. Саумы, Бикә?

Б и к ә. Уз, уз, әйдә Рүбәдә әби.

С ә г а т и. Бик узып торып булмас, азак баскагың кайтып җитсә, име, әби...

Р ү б ә д ә. Ә-ә, әйе, кайтып кермәсен ул кавем.

Б и к ә. Борчылма, әби. Кайтмый алар тиз генә.

Р ү б ә д ә (*Сәгатигә карап*). Юк, чак кына булам да, ашыгам...

Б и к ә. Хозурыңда алайса, әби, тыңлыйм?

Р ү б ә д ә. Шул, Бикә, ялгыз калдым. Сүндәй бабаң да дөнья куйды бит инде...

С ә г а т и. Ошбу дошманнарны күралмый, үч аласы иде дия-дия китте, бичара...

Б и к ә. Беләм, килен. Кысылма. Җаны изгеләр берлә булсын, әбкәй. Бихисап ир-егетләребез баш салды ошбу арада. Үземнекеләр дә...

Р ү б ә д ә. Хак, килен, хак. Олуг кайгылар өелде түбәбезгә.

Б и к ә. Хуш, әби, тыңлыйм!..

Р ү б ә д ә. Шул инде, Бикә. Кыз-хатыннар бик сораган иделәр...

Б и к ә. Соң?

Р ү б ә д ә. Үзләре ошбу тирәгә килергә уңайсызланалар. Шул инде... Бик рәнҗибез, диләр, баш орып, тез чүгеп яшәгәнгә.

Б и к ә. Төшендем. Нә тели инде алар?

Р ү б ә д ә. Гореф-гадәтне онытып, бозып, кыргый дала кавемен түзеп яшәп ятабыз дип сөйлиләр. Бикә берни

кылмый, уйламый түзеп тора, бәгъзесе килешми, диләр. Нә булса да...

**Бикә.** Нә булса да?! Кылдылар бит инде нә булса да, карышып карадылар, нә булды?! Кырып салдылар.

**Сәгати.** Салсалар! Анавы — алар ирләре кеби горур килеш корбан булдылар. Алар сатылмадылар, кол булмадылар?!

**Бикә.** Килен, тик тор! Синең белән сүз юк! Соң нә эшләтим, нә эшләтим?! Мин дә бик теләр идем язмышымның болай булмавын. Тәкъдирнең ачы хакыйкате, үләсеңмени... Кырылып бетүдән нә файда? Тагын нә, әби?

**Рүбәдә.** Мин нә, кызым? Мин олыгайган кеше. Ошбу кабиләнең изге йолалары бар, алар бит...

**Бикә.** Әйт әле, әби, язык эшкә кайсы этәрде?

**Рүбәдә.** Кем дип, нә, юк...

**Бикә.** Әйт әле, әйт, әби...

**Сәгати.** Нә миңа карыйсың? Әйе, мин дә изге эшкә катыштым! Хатыннар да шул сүздә. Җитте! Күпме үч алмый түзәргә була! Син... Синең илә сүзең аркылы бу хәлгә калдык. Угланнар кирәк булган аңа...

**Бикә.** Әйтеп бетер, килен, эчеңдә калмасын. Углан булу сиңа да гыйззәтле булыр иде.

**Сәгати.** Әйтермен дә! Кирәкми миңа берни, үч кирәк! Сине тыңлап, Биеңне тыңлап яшәмәгән булсак, ошбу мәхшәр көннәр килмәгән булыр иде. Әллә кайчан атайны күтәреп, Биеңне төшереп баш буласы калган!

**Бикә.** Менә ничек сөйләшә башладың син. Менә нә икән сине...

**Сәгати.** Борчый шул! Безнең нәсел баш булса, мондай хәлләр булмый иде. Һич югы, горур булып, ыруг өчен каныбызны да жәлләми шәһит китә идек! Углан?! Тфү!

**Рүбәдә.** Балалар, угланнар...

**Бикә.** Җүләр хатын, үз каннары үсеп, үзләрен үк кырачаклар. Бел килен, угыл кемнән булса да, үскәч, кемгә каршы торуы көчлерәк урында тора. Кем гадәте, йоласы белән үссә — шул ыру баһадиры булачак. Ә алар безнең гадәттә үсәчәк!

**Сәгати.** Җитте! Өйрәтмә! Бикә өчен бу сүз ир-егетләребезне сатып, алай башы кочагына керер өчен генә кирәк булган!

Бикә аның яңагына орып җибәрә.

**Бикә.** Җитте! Соңгы сүзем: алга табан да ошбу рәвештә болгата торган булсаң, алай башы аша бастырырмын! Башка сүз булмасын! Барыгыз.

**Рүбәдә.** Мин нәрсә... Мин... гореф-гадәт...

С ә г а т и. Хуш, Бикә. Котылам дисәң — ялгышасың! Канга — кан, үчкә — үч, үлемгә — үлем! Бел, шушы көннән син минем дошманым!

Б и к ә. Булды! Эзең булмасын! (*Китә.*)

Р ү б ә д ә. Ай кызым, килешмәде...

С ә г а т и. Җебемә, әби. Бел, мин әйткәч, син үз тирмәгездәге яугирне агуларга тиешсең!

Р ү б ә д ә. Әйтәм бит, булдыра алмам мин...

С ә г а т и. Булдыр! Кара аны, булдырмаган һәркем — ыру дошманы!

Ут сүнә.

Мәйдан алды. Алда тезләнгән хәлдә Бикә утыра.

Б и к ә. Йа Ходам! Безем бердәнбер вә изге Аллабыз! Бөтен күңелем, бөтен барлыгым берлә сиңа табынам! Ярлыка безләрнең ошбу яман язмышы булып җыелган гөнаһларыбызны, калдырма безләрне ялгыз бу авыр тормышта! Бихисап күп еллар, йә бер Аллам, күбебез сине генә, бары тик ошбу җиһанда бер сине генә, Тәңребез, бердәнбер изге Ходабыз дип таныйлар, тәүбә итәләр, баш оралар! Арабызда булган потка табынучылар өчен ачы язмыш җибәрмә түбәбезгә, ярабби бер Ходам! Ошбу көндә бердәнбер түбәнчелек белән үтенеп ялваруым — Ходам, углан бир миңа! Би нәселенә, олуг нәселгә, ошбу ыруны яңадан күтәрү өчен, изге канны торгызыр өчен, ярабби бер Аллам, бир бичара Бикәңә бер углан! Барчасына түзәрмен: барча җәбер-золымнарга, кимсетүләргә, ыруымны мыскыллауга, бәйле булып ошбу залимнәр кул астында яшәүләргә, барчасына! Ничек кенә кимсетсәләр дә, күңелем түрендә, ихластан, сиңа, бары сиңа тугры калдым! Иманымны нә күрсәм дә, югалтмадым! Синең изге углың булган Бием әманәтен башкарам дип яшәвем фани җиһанда, бернигә карамый, ярабби бер Аллам! Беләсең, Ходам, барча диярлек карендәшләрем кырылып бара. Соңгы кызымны да үз хозурыңа алдың... Нә өчен Аллам?! Шушы шәһитләр бәрабәренә бир бер углан, йа Аллам! Бир Ходаем, бир бәгъзе кыйналган, орышылган, мәсхәрәләнгән тугры колыңа бер углан! Бир Ходаем! Бөтен барлыгым, иманым берлә сорыйм, йә бер Аллам!

Ут сүнә.

Бикә тирмәсе эче. Кич. Шактый гына вакытлар үткән, сулар аккан. Болганган су тынып, дулкыннар, вакытлыча булса да, басылып калганга охшаган. Җ а д а н белән К ә р л ә утыра, Б и к ә аларга сөҗү китерә. Китмәкче була.

Җ а д а н. Хуш, Бикә, үзең дә утыр әле... (*Бикә уты-*

*ра.*) Нә гелән читләшәсең? Әллә безем ошбу тәртипләр илә разый түгелме? (*Бикә дәшми.*) Инде халкың да тынычланды, басылды, имин илә яшәп ятабыз... Йә?

Кәрлә. Җүләр икән, әй лә, кызык икән син, Җадан.

Җадан. Дәшмә, Кәрлә. Сөҗү артыграк китте бугай сиңа.

Кәрлә. Миңа бервакытта да артык булмый, мин һәрчак чама беләм.

Җадан. Булды, Кәрлә. Йә, Бикә?

Бикә. Нә дәшим? Бар да әйбәт...

Җадан. Шулай да...

Бикә. Нигә куаныйм... Ошбу дөньям кырылгангамы?

Җадан. Булды, Бикә. Күп су акты ул хәлдән соңла. Сабырланырга вакыт.

Бикә. Вакыттыр, бик вакыттыр да...

Кәрлә (*көйләп*). Күңел ярасы — нык яра, аны онытып кара...

Җадан. Бүлмә сүзем, Кәрлә. Сөйләшеп бетерик. Бел, Бикә, миңа бу кыланышың хуш түгел.

Бикә. Нинди кыланыш?

Җадан. Авызыңа су капкандай дәшми йөрү. Минем дә углан югалды. Нә кыласың...

Бикә. Бер сүзем дә юк...

Җадан. Булды! Мин ир адәм! Һәм мин җиңдем! Ошбу олыста чакта миңа ачык бул! Без киткәч каралырсың. Үткән-беткән.

Бикә. Тырышырмын. Тик...

Җадан. Нә тик?

Бикә. Бел, алай башы, мин Бикә. Вә мин сиңа җария кебек яраша алмам. Ничек булдыра алсам, шул.

Җадан (*ачуы чыгып*). Бикә! Без дә сиңа кол булырга боермыйбыз! Бикә бул. Бигә нә рәвешле булсаң, миңа да ошбу рәвештә үк. Би нәселе булганга исән калдың да. Баскак ошбу кавемдә кара халык хозурында булсынмы?

Кәрлә. Ничек инде, олуг алай башы, кара халык белән сөҗү эчсен, булмаганны.

Җадан. Кыланма, Кәрлә. (*Бикәгә.*) Аны анык бел.

Бикә. Хуш, беләм.

Җадан. Башка миңа табан олуг Бигә караган кеби кара!

Бикә. Миңа да.

Җадан. Нә сиңа да?

Бикә. Бикәгә караган кебек.

Җадан. Ишеттеңме, Кәрлә, безләрдән хәзер ант эчтерә башларлар.

Кәрлә. Вә дөрес эшли.

Җ а д а н. Ә мин бәгъзе рәвештә карыйм?

Б и к ә. Ошбу ыру башы, Би нәселе югала.

Җ а д а н. Нә рәвешле карыйм дидем?

Б и к ә. Агач итеп.

Җ а д а н. Агач?! (*Көлә.*) Ишеттеңме, Кәрлә, агач? Нә рәвешле була ул?

Б и к ә. Нигез корый, мин берни кыла алмыйм.

Җ а д а н. Шул гынамы?

Б и к ә. Мин нә булса да кылырга тиеш, нигезне, нәселне сакларга, берни оешмый. Шашам бугай...

К ә р л ә. Алай түгел, Бикә. Син теләп кенә булмастыр, бар да Тәңре кулында йөрмештер.

Б и к ә. Иркенлек бир миңа, хаким.

Җ а д а н. Хуш. Нә турында гына хыялланып саташмый адәм башы, Кәрлә, ә?

К ә р л ә. Нәкъ шулай.

Б и к ә. Иркенлек...

Җ а д а н. Юк! Нәсел... Ыру каны... Тапкансың. Мин үзем дә белеп бетермим, кайсы ыруга якынрак бәгъзе хакимегез. Бер ыруда туганмын, бәгъзесендә үскәнмен, соңла башка берлә орышканмын, яугир булганмын. Ошбу ырулар гел орышып торганнар. Кемнең кем угланы булганны үзләре дә белеп бетерми.

К ә р л ә. Хәтта угланың да...

Җ а д а н. Кагылма угылга, Кәрлә, чабам.

Б и к ә. Миңа синең ыруың түгел, үз ыруым кирәк...

Җ а д а н. Шул, Бикә. Ошбу хакимеңә иң мөһиме яу! Яу уңышлы икән, мин яшим. Яу юк икән — мин үле кебек. Кайчак яудан мин үзем дә туям, ләкин ниндидер олуг бер көч мине яуга әйдәп тора, миңа дәрт, батырлык өсти. Минем яшәүнең бар шатлыгы булып, яу йөрү, ырулар алу тоела башлый. Мине инде син хыялланган нәсел саклау рәвешендәге вак сорау борчымый! Мин алардан югары! Мине бөегрәк көчләр йөртә! Вакландырма мине, Бикә! Җирәнәм мин ул караңгы тирмә почмагына кайтып калган гаилә сөаленнән.

Б и к ә. Син үтерттең барча ир халкыбызны! Соңгы угланны... Соңгы кызымның да башына явыз углың җитте.

Җ а д а н. Әй хатын! Кагылма угылга! Синең кызың ашады аның башын.

К ә р л ә. Йә, кузгатмагыз, күптәнге...

Б и к ә. Түзәр чамам калмады. Үтер, явыз! Куралмыйм!

Җ а д а н. Юк, Бикә, син ялгышасың. Яшисең килә синең, сине өмет яшәтә. Би нәселен, канын торгызам дигән олуг өмет яшәтә. О-о, ул өмет! Кемнәрне генә нә генә эшләтми ул?! Синең ул өметең безләргә булган

нәфрәттән дә көчлерәк. Сине шул яшәтә. У-у, ничек чәнчеп атар идең син мине, өметең булмаса. Ә мин ошбу өметеңне юкка чыгарам! Би нәселе калмаячак!

К ә р л ә. Һе, углыңнан теге чак олан булса да үтертер идеңме?

Җ а д а н. Кәрлә, кагылма дим угланга! Оланмы, түгелме — барчасы да кырылачак! Би нәселе бетәргә тиеш! Бу минем үчем!

Б и к ә. Явыздан да явыз икәнсең.

Җ а д а н. Бетте, Бикә. Ахыр сүзем: үзең исән яшәгәнгә рәхмәтле бул.

Б и к ә. Нигә ул миңа болай? Ал, кирәксә...

Җ а д а н. Күп сөйләнсәң, алырмын да...

Б и к ә. Кыралмыйм мин сине.

Җ а д а н. Кыеласың, хатын.

К ә р л ә. Җитте инде, сезләргә!

Җ а д а н. Оһо, минем Кәрлә дә кызып китте.

К ә р л ә. Көлмә, яугир. Ошбу дөньяның мәгънәсезлеге шундадыр инде: син көлдерергә уйласаң — егълыйлар, егълатыйм дисәң — көләләр.

Җ а д а н. Минем Кәрлүш акыл сата башлады. Бикә! Китмә, китмә, аның акыл сатуы, барыннан да кызыграк, көлдереп үтерәчәк хәзер. Хы-хы-хы.

К ә р л ә. Эх, Җадан. Олуг алай башы... Күпме җир йөрдек без синең белән, бихисап күп халыклар күрдек. Көләсең... Көл, көл...

Җ а д а н. Йә, йә, сөйлә, Кәрлә, көлмим.

К ә р л ә. Көлке шул. Нинди ыру саклау турында сүз бара биредә?! Нә рәвештә саклап булсын аны? Ошбу көннән кирегә табан достаннар берлә берничә йөз генә ел артка күз салыгыз: адәмнәр кайчандыр таш куышларда яшәсәләр, акрынлап кушыла барганнар. Гаиләләр тагын бер тирәгәрәк җыелган, кабиләләр оешкан. Ахыр чиктә ыруглар, халык төркемнәре — ниндидер тел, гадәт, әхлак берлә берләшкән, халык барлыкка килгән. Алга табан да ошбу гадәт дәвам итәчәк. Адәмнәр — теләсәләр-теләмәсәләр дә, орышыпмы, тату килешме, бер-берсенә якынаерга, берләшергә мәҗбүр булачаклар! Димәк, ошбу җиһанның төп тереге, мәгънәсе — берләшү. Барыбыз да җир балалары!

Җ а д а н. Юк, Кәрлә, ни эшләптер бу сүзең күңелле булмады. Әллә сөҗү җитеп бетмәгәнме? (*Сөҗү бирә. Кәрлә эчә.*)

К ә р л ә. Син бит, үзең дә олуг көч йөртә дисең. Бәгъзе берләшү дә ниндидер олуг көч тарафыннан башкарыладыр. Тик ошбу оешу үтерү, көч илә килмәсен иде.

Б и к ә. Хак. Көч илә ыруны һич берләштерә алмассың. Әгәр ачык йөз белән килсәләр...

Җ а д а н. Һе, ачык йөз. Кырып бетерерләр иде. Юк акылыгызны сатмагыз. Заманы шул. Үтереш-кырыш заманы... Укмаштыру кирәк икән, мин аңа кан аша ирешермен.

К ә р л ә. Ошбу уйны үзеңә җайлама. Бәгъзе囗эштә һәркем үзе хәл итә. Йә нәфрәтне җиң, йә хайван булып кал. Күп кирәкми бит, аз гына. Уйдырма дошманны үтерергә түгел, ә күңелдәге нәфрәтне.

Җ а д а н. Хайван?! Кәрлә, ошбу сүз өчен башка мәхлук булса, нә була?

К ә р л ә. Башы инде, хаким, башы киселә.

Җ а д а н. Соң?!

К ә р л ә. Кәрләң башсыз калса, хак уйны кем дәшер микән олуг хакимгә?!

Җ а д а н. Хак уй? Юк ул хаклы уй! Менә ул хак уй! (*Йодрык күрсәтә.*) Йә, йә, көлдер, Кәрлүк.

К ә р л ә. Көлегез, көл. Менә олуг хаким Бикә.

Җ а д а н. Бикә инде, Бикә...

К ә р л ә. Бикә синең илә нәсел сакламакчы. Нәрсә, ошбу нәфрәтегездән берәр уңай эш чыгар дип уйлыйсызмы?! Тыштан хәйләле, эчтән күралмаган гадәти күңелегездән берәр ялкын кабынып, ошбу эштән яңа тормыш барлыкка килер дип хыялланасызмы? Көтмәгез! Хыялланмагыз! Нәфрәттән беркайчан да, берни дә тумаячак! Нәфрәт нәфрәтне генә тудыра. Нәфрәт бәгъзе җиһанны җимерә, ул бары җимерә, җимерә генә! Нә аңламыйсыз?!

Җ а д а н. Барын да аңлыйбыз, Кәрлә. Бик күңелле, әйдә, әйдә!..

К ә р л ә. Хәер, болары беткән бәндәләр, тәкъдирегез шундый... Яңгыла тормыш көтмәгез! Берәвегез үтерүче, икенчегез үтерергә хыялланучы! Һәр икәвегез илә гөнаһлы кавем...

Б и к ә. Мин түгел, ул — хаким.

К ә р л ә. Хәйләләмә, олуг Бикә. Эчең нәфрәт тулы, үч тулы!

Җ а д а н. Менә, менә. Әйдәле, Кәрлә, әйдә. (*Сөҗү бирә.*) Мәле...

К ә р л ә (*тагын эчеп куеп*). Син ошбу кавемне мәңге кичермәячәксең. Син булдыра алырдай шөгыль түгел ул. Ниндәй олуг мәгънәсезлек ул — кичерә белмәү?! Юк бит, юк, үткәнне кире кайтарып булмый. Онытырга, яңа тормыш корып яши башларга кирәк. Ю-у-ук, кая ул?! Үч, бары тик олуг, изге үч! Бөек нәфрәт! Ай адәмнәр, әллә, чыннан да, шул нәфрәттән мәңге арынып булмас?!

ышанасы килми, бу чир безне мәңге хайван дәрәҗәсендә яшәтә торган афәт булып калыр микәнни?! Вә илә бит, кичерсәң — үзеңә дә савап, чит адәмгә дә файда. Бик гади бит ошбу мәсьәлә, хакимнәр. Белегез, нәфрәттән арына алмасак, яулар да мәңге бетмәс, ыру да ишәймәс. Ошбу җиһанда безне бары берең илә берең хөрмәт, туган тою гына чын адәм итә алыр, олуг әмирләр.

Җадан. Син нигәдер артыгын тыкылдый башладың, Кәрлә. Җитеп тормасмы?

Кәрлә. Нәрсә, тәкъсир, ошамыймы?

Җадан. Әллә нәрсә бутыйсың шунда.

Кәрлә. Килер берзаман ошбу көннәр. Адәмнәр юкбар өчен, ялтыравык өчен, корсак өчен берен илә берен таламаслар, кырмаслар. Киресенчә, аның кыешындагы һәркемгә уң булсын, хозур булсынны уйлап ярдәмләшергә тырышыр.

Җадан кычкырып көлә.

Вә ләкин ошбу хозурлыкның нә икәнен төшенмибез шул. Хакыйкать безләргә — ул тән саклау, гадәт саклау, байлык саклау, ачу илә үч саклау. Ә бит болар барысы да — чүп! Ошбу — чүп-чардан олы әгъза, менә монда, гелән-гелән чәнчеп искә төшерә торган камчы — җан бар, йөрәк бар! Төкерегез бар чүп-чарга, олуг хаким, фани дөнья малына. Ошбу чүп кала, йөрәк турында уйлагыз. (*Кисәк сынып китә.*)

Бикә. Нә булды?

Җадан. Йә, нә инде син, Кәрлә.

Кәрлә. Ә бит мин Кәрлә түгел, минем атым бар. Бәгъзе Кәрләгез, бәлки, сез тоймаганны да тоядыр. Бәлки, ошбу мыскыллар мине сезләрдән дә тирәнрәк яндырып төшәдер.

Бикә. Чү инде, Кә...

Кәрлә. Әйт, әйт, Кәрлә булсын. Атамадамыни хикмәт. Атамасы нә, бәгъзе адәм бу илә теге ыруданмы, ак илә кара кушылудан туганмы, андамы хикмәт?! Хикмәт бит тугач кем булуыңда. Адәмнәр кырачаксыңмы син, илә ошбу ыруыңны гына белеп, шуңа гына бикләнеп, башкаларга төкереп яшисеңме? Бит, әүвәле углан тугач, атам илә анам кем, яшелме яисә сарымы дип сорамый. Егълаганда да, барча олан да бертөрле тавыш илә егълый. Ул туу белән Тәңре кушуы буенча яшәргә тели, тырыша. Аңа барыбер — ошбу ата-ана акмы, карамы. Бәгъзе кабилә бу диндәме яисә башкадамы? Ахыр чиктә барыбер, барча табыну үзәге бер, бердәнбер олуг Алла! Ә хәзер, ошбу угланга иң мөһиме — ул тере җан иясе. Адәмнәр,

бары адәмнәр, азак, үскәндә, үзебезнең кирәкмәгән гореф-гадәт, чикләүләр белән, яңглышларыбызны көчләп өйрәтә-өйрәтә, аны яңглыш юлга кертәбез. Ошбу углан, безләремезнең мәгънәсез тәгълиматлары өчен яу чабарга, үтерүче булырга, ак-сары-кара тәнне, телләрне, берберләреннән аерырга мәҗбүр була. Күрсәк иде, аңласак иде, иң әүвәл — төрле төстәге, илә төрле телдәге кавемнәрдән элгәре, бөтен илләр дә йөрәкләрдән тора. Теге илә бу йөрәкне рәнҗетсәң дә, караныкымы ул, сарыныкымы, акныкымы — ул авырта, әрни. Ошбу вакытта без аңлар идек — нинди генә углан туса да, бәгъзе нинди генә халык булса да — аларның йөрәкләре бер төстә, каннары бер — алсу төстә!

Җадан. Җитте, Кәрлә. Күпкә китте синең... Йөрәк, йөрәк, такылдадың...

Бикә. Йә инде...

Җадан. Урынын белсен.

Бикә. Нә шуңа риза булып йөрисең син?

Кәрлә. Кемдер тиеш... кемдер... Адәмнәр үз түбәсеннән ары булганны кабул итмәгәч, кыланмый нә эшлисез?

Җадан. Җитте, бар, кит...

Кәрлә. Киттем... Менә бит... О-о, сез, олуг дөнья хакиме!

Җадан. Ычкын, Кәрлә! Син дә, Бикә... Ошбу тугрыда сүз катма, ыруың торсын дисәң... Бар.

Ут сүнә.
Яңадан мәйдан алды. Җадан, Бикә, Кәрлә күренәләр.

Бикә. Тагын кан кою, тагын, тагын.

Җадан. Олуг сабак булыр баш имәүчеләргә... Бел, Бикә, ошбу җиһанда һәрвакыт, кем көчле, шул җиңә.

Кәрлә. Дөрес... Кем көчле, шул җиңә. Вә ләкин таяк ике башлы. Кем көч бирә — шуңа көч килә.

Җадан. Шүрләмә, Кәрлә.

Бикә. Кайчан бетәр бу вәхшилек...

Бимаж (*керә*). Тәкъсир, соңгы төркемне дә кырдык. Беттеләр. Башкаларын полан алдылар.

Җадан. Чөнгут, Чөнгут явыз кайда?

Бимаж. Тыныч булыгыз. Башын үзем чабып өздем. Халык болгатуның нә икәнен белсен.

Җадан. Хуп. Качкын булмадымы?

Бимаж. Яугирләр юк. Берничә хатын гына. Алары берни кыла алмый.

Җадан. Яхшы булган. Башка фетнә күтәрергә җөһрәт итмәсләр. Кирәк бит, кул астындагы Чөнгут фетнә оештырып яткан...

Б и м а ж. Күп хатыннар, хаким. Яугирләрне дә алар болгатмады микән?

Б и к ә. Хатыннар аз, аз гына, нә сөйлисез?

Җ а д а н. Кысылма, хатын. Барчасына каты җәза булачак!

К ә р л ә. Башка нә булсын ди, безлә шомарган куллардан.

Җ а д а н. Бимаж! Фетнәчеләрне бастыруда яугирлегең өчен, ошбу тугрылыгың өчен сине Чөнгут урынына алай башы итеп билгелим!

К ә р л ә. Булды гына инде болай булгач...

Җ а д а н. Тик тор, Кәрлә...

Б и м а ж. Тәкъсир, мәңге онытмам, яхшы хезмәтле булырмын, алга табан да...

К ә р л ә. Күр, күр, кемдер килә анда. Тагын фетнә!

Җ а д а н. Нә сөйлисең син? Булмаганны каркылдама.

Б и м а ж. Чыннан да кемнәрдер килә. Тәкъсир, мин яугирләрне әзерли торыйм алайса?

Җ а д а н. Бар.

К ә р л ә. Бу бит, бу бит... Ошбу бит...

Б и к ә. Кызым... Кызым ич ул... Кызым... ай, исән, исән.

К ә р л ә. Акмаз углан, Акмаз...

Җ а д а н. Нәрсә?! Углан шул. Углан! Исән, исән!

Ерактан **А к т а ң** белән **А к м а з** килә, кулларында биләү.

Б и к ә. Йа Хода, соңгы өметем исән...

Җ а д а н. Углым, ышана алмыйм... булмас...

Акмаз белән Актаң артыннан **С ә г а т и** йөгергәне күренә.

Җ а д а н. Кара, кара, анда кем? Угыл, сак бул!

Сәгати, йөгереп килеп, Акмазга арттан хәнҗәр кадый. Качмакчы була, аны эләктереп алалар.

Җ а д а н. Улым, ай углым.

Акмазны күтәреп керәләр.

А к т а ң. Акмаз, Акмаз, җаным... Инде бит... инде... (*Елый.*)

Б и к ә. Кызым, син исән...

Җ а д а н. Аһ угыл, угыл... Ник тыңламадың... (*Сәгатигә күрсәтеп.*)Алыгыз ошбу хатынны, күземә күрсәтмәгез...

К ә р л ә. Әй дөнья! Әй адәмнәр! Кем көчле, шул җиңә... Вә ләкин кем көч кулланса — шуңа көч килә. Бик гади ләбаса...

Бимаж йөгереп килә.

Б и м а ж. Олуг хаким, анда яу килә, яу!

Җ а д а н. Ничек?!

Б и м а ж. Олуг яу! Сәкалибә ыруглары күтәрелеп чыккан бугай.

Б и к ә. Йа Ходаем, тагын.

Җ а д а н. Бимаж, яугирләр әзер булсын, орышка чыгабыз.

Б и м а ж. Баш өсте!

Җ а д а н (*Актаң янына килеп*). Бикә, угылны, бәләкәчне, минем канны сакла! Нә күрсәң күр, оланны сакла, беркемне китермә! Ошбу башың илә җавап бирәсең! Мин имин кайтмасам да, соңгы буынны сакла...

Б и к ә. Саклармын. Күз карамдай... Нәселне... Оланны... Каным бит ул минем...

Җ а д а н. Яугирләр! Яуга! Изге ыруны сакларга!

П ә р д ә.

…Бөтен дөнья театр,
Һәм без анда актерлар…

*Шекспир*

# …I am «the Theatre» actor…*

*Театр тормышыннан ике пәрдәле музыкаль хикәят*

КАТНАШАЛАР:

Сөмбел — 16—18 яшьтә.
Гайсә — 32—35 яшьтә.
Рәсүл — 35—40 яшьтә.
Әнзирә — 28—32 яшьтә.
Гарәфи — 50—55 яшьтә.
Альберт — 27—31 яшьтә.
Директор ханым — 45—50 яшьтә.
Режиссер — 50—55 яшьтә.
Хәсән — журналист — 35—40 яшьтә.
Гөлбостан — Гайсәнең туган апасы — 50—55 яшьтә.
Хаҗимулла — Гөлбостанның ахире — 60—65 яшьтә.
Сәлим — «завхоз» — 25—30 яшьтә.
Ата.
Ана.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәхнәдә: театр эчендә театр. Спектакль бара. Түрдә — «тирес» өеме. Гайсә, аңгы-миңге килеп, сәхнәдә йөри, башына куллары белән ябышкан, уфтана.

Гайсә. Бу ни бу? Кайда мин? Мунчадамы әллә? Әллә миңа ис тигәнме? О, юкә ботагы, ферштейн, димәк, мунча түгел. Ой, юкәдә икән чикләвек… Ну миндәге баш… Эшләми…

Альберт мүкәләп чыга, пычранып беткән.

Альберт. О-ой, борыным!

Гайсә аннан көлеп тора.

---

* Мин «театр» артисты.

Нигә ыржаясың? Кем соң сың син? Танавым берни сизми, таный алмыйм, кем соң сың син?

Г а й с ә. Кыланма, мин инде бу, мин. Җайла танавыңны. Минеке дә берни сизми, әллә ниткән куе ис кенә тулган кебек. Тыңкычлап тутырганнар диярсең... Борын тыгылган саен кеше танымый башласаң...

А л ь б е р т. Ә-ә, синмени әле бу... Мин тагын... Уф, борыным... Үләм... Менә әйт әле, кайда соң без? Ни-нәрсә иснәдек сың без? Ник бу кадәр танау ачыттырып-ачыттырып сызлый?

Гайсә «тирес» өеменә күрсәтә.

А л ь б е р т. Бумы? Кит әле, булмаганны. Әллә син шунда йокладыңмы?

Г а й с ә. Син әле башың белән күмелеп үк яткан идең.

А л ь б е р т. Фу, булмас. Тирестән генә болай борын бозылмас. Менә ич, бернинди әшәке ис сизмим. (*Барып иснәп карый.*)

Г а й с ә. Ташла әле шул танавыңны. Уйлашыйк, ничек бу тирес өеменә килеп түндек тә, ничек моннан котылырга? Син берәр ни хәтерлисеңме?

А л ь б е р т. Берни дә. Ниләр генә иснәдек тә, нидән генә болай ушсыз булдык соң без? (*Утырып елый башлый.*)

Г а й с ә. Минем балавыз сыгасым килми мәллә? Минем дә танау ачыта.

А л ь б е р т. Сиңа ни? Син аксөяк. Син бит калхуз завхозы малае. Сине юарлар да киптерерләр.

Г а й с ә. Җә инде, көнләшеп үләсең бугай. Тырыш әле син, үзең дә... әйдә, карап карыйк әле, бу өемдә тагын берәр тирес корты калмады микән?

А л ь б е р т. Ну, малай, синдәге Югары совет, чын Дума инде менә... Ф-фу, сөрт әле азрак битләреңне, кемгә-кемгә...

Г а й с ә. Үзеңне кара... Әйдә киттек, карыйбыз. (*Карыйлар.*)

А л ь б е р т. А-а-а-ай җен!

Г а й с ә. Ни булды? А-а-а-ай, суалчан түгел бу, аждаһа!

Ә н з и р ә пәйда була. Ул кулларында йөреп чыга. Аяклары — өстә. Үзе нидер мыгырдана. Итәкләре әйләнеп төшкән, каян карама салам асылынып тора.

Г а й с ә (*качкан җиреннән чыгып*). Бу ни бу?

А л ь б е р т. Белмим. Күргән-белгән галәмәт түгел.

Ә н з и р ә (*баштүбән торып*). Ниемә дип карап торасыз, әфәнделәр. Булышыгыз, пожалуйста.

Г а й с ә. Нинди нәмәрсә соң син?

А л ь б е р т. Кай төшең сөйләшә соң синең?

Ә н з и р ә. Менә монда, аста. Анда түгел инде, оятсызлар. Кыз кеше мин.

Г а й с ә. Бер дә алай булуга охшамагансың бит әле.

А л ь б е р т. Хәйләли. Бандит-мазар булмасын.

Ә н з и р ә. Түгел инде, түгел. Кыз мин, абзыкай, кыз.

Г а й с ә. Кем белеп бетергән инде сезне хәзер.

А л ь б е р т. Ник болай булдың соң син? Күтле-киреле?

Ә н з и р ә. Әллә ниткән истә сымак тоела.

А л ь б е р т. Карале, бу да ис диде түгелме?

Г а й с ә. Кара мунча кергән идең мәллә?

Ә н з и р ә. Юк ла. Ике егеткә берьюлы кияүгә чыккан идем, бәхетле булалмаммы дип. Качтылар. Балалары итәк тулып калды, шуларның арт сабакларын укытырга иде исәп. Танауга кисәк ис тулды. Шул ис кергәч, аякларым өскә күтәрелде дә китте. Нинди истер, белмим?

А л ь б е р т. Борын тишекләреңдәге саламны кой башта, ис, имеш.

Г а й с ә. Туктале, безне кыйнарга диме ул?

А л ь б е р т. Арт сабакны укытырга, ди.

Ә н з и р ә. Юк инде, юк, курыкмагыз. Кая сез булсын?! Алар чибәр иде, ак йөзле. Сезнең кебек негрлар түгел.

Г а й с ә. Туктале, тукта, иртән дисеңме?

Ә н з и р ә. Юк инде, төнлә үк килгән идем, шулай итеп йокларга да туры килде.

А л ь б е р т. Гырладым диегез, чучка баласы. Төне буе яңгырап торды.

Г а й с ә. Бутамале, ансы син идең лә анық.

Ә н з и р ә. Гафу итегез, ой, пардон, мин гырлай белмәем. Оялтмагыз, зинһар өчен.

Г а й с ә. Туктагыз әле, уйлашыйк. Төне буе диген ә... Тәк, башта без сине әйләндереп куйыйк әле...

Ә н з и р ә. Ән-н-ни-и!!! Кагыла күрмәгез, ату үләм.

А л ь б е р т. Ник?

Ә н з и р ә. Аягым өзелеп калыр сыман. Аягым белән танавым идарә иткән шикелле.

Г а й с ә. Ярар, әйдә җыен, итәк сүзен тыңлап торсаң.

Ә н з и р ә. Каравыл! Месье, мадам!!!

А л ь б е р т. Акырма, бер генә манчырмын.

Г а й с ә. Син аудар, мин тиз генә танавын актарып алам.

Аны акыртып егып, танавын чистартып алалар, ул елап утыра, егетләр киңәшәләр.

Г а р ә ф и күренә. Ул цилиндр кигән, кара фракта, трость тоткан. Аның җүләрме, акыллымы икәнен бер күрүгә аңлап бетереп булмый.

Г а р ә ф и. Һа, минем ахирләр җыелып беткән. Хәерле иртә, йокылар тәмле булдымы йомшак түшәктә. Гутен морген. Септембер, уктумбер. О-о, ляжанка.

А л ь б е р т. Бусы нинди иблис тагын?

Г а й с ә. Белмим, мондый җанварны да күргәнем юк.

Г а р ә ф и. Курыкмагыз, әфәнделәр, бәхетле итәм мин сезне. Тик иң әүвәл, әллә чыннан да мине танымыйсызмы?

Г а й с ә. Юк.

Г а р ә ф и. Син дәме?

А л ь б е р т. Юк.

Г а р ә ф и. Эшләр хөрти икән сезнең. Килегез әле монда.

Бар да җыелалар.

(*Әнзирәгә.*) Син дә кил. Фу-у, бусы бигрәк котсыз. Бик якын килмәгез, исегез чыдарлык түгел.

Г а й с ә. Йә, сөйлә.

Г а р ә ф и. Каты тотма, каты тотма. Әй, әгәр сез белсәгез, без кайларда гына булмадык. Хәер, каян беләсез, мәрткә киткәч.

Г а й с ә. Мәрткә киткәч?!

А л ь б е р т. Әни-и!

Г а р ә ф и. Сорап тора тагын. Ничек кенә әле. Өч ел буена. Ниләр генә кыланмадылар. Күпме кызның, күпме малның башына җиттегез. Хәзерге көндә сезнең өчәр хатыныгыз бар, алты-җиде балагыз. Хе-хе, ну, егетләр, дәрт бар икән үзегездә. Шулкадәр инде. Ул алимент өстенә алимент сезнең хәзер, бөтен милиция, бөтен КГБ эзли.

Г а й с ә. Кит әле, булмас.

Г а р ә ф и. Булмас сиңа. Мәрткә киткәч шулай инде, хәтерләп булмый. (*Икесенә генә шыпырт кына.*) Ә менә бусы икегезгә бер, иң соңгы, уртак хатыныгыз.

А л ь б е р т. Ә-ә? Шушы җенме?

Г а р ә ф и. Һәй, юып җиффәрсәң менә дигән әле ул!

Г а й с ә. Соң нишлик инде без алайса?

Г а р ә ф и. Әллә кайчан шулай диләр аны. Мине тыңласагыз, бар да шәп булыр.

Р ә с ү л керә. Ул борынгы греклар кебек, өстенә материя генә элгән.

Р ә с ү л. Ботка пеште, рәхим итегез.

Г а р ә ф и. Шулай, егетләр. Ботка да пеште, сез дә пештегез, шуңа күрә дә шушында бергәләп яши башларбыз. Ур-ра!.. Тормыш дәвам итә. (*Кисәк туктап калып.*) Ш-ш-ш, соңгы бер җыр...

Шәһәр чыгып уңга киттек, әй егетләр,
Сагындык сине калабыз, валлаһи, менә.
Шундый асыл егетләр без, апаем ла,
Ике аккош очып бара, шул вакытта... Их!
Кая барма, кая карама,
Бездәйне чәчеп үстермиләр.
Булсын әйдә, берәр рифма да —
Чит илләрдә лә үз күрмиләр.

Җыр бетә. Гарәфи артистлар белән таныштырырга тотына.

Г а р ә ф и. Хөрмәтле тамашачылар! Рөхсәт итегез, сезне артистларыбыз белән таныштырып китәргә! Безнең спектаклебез тәмам, тагын килегез, рәхим итегез!

Арткы пәрдә төшә. Төрле яктан сәхнәгә к е ш е л ә р чыга, премьера белән тәбрикләү башлана:

— Премьера белән!
— Гениально!
— Браво, бис!
— Афәрин!

Ут сүнә дә акрын гына грим бүлмәсендә кабына. Бер өстәлгә ниләрдер әзерләнеп каплап куелган. Бүлмәгә чишенә-чишенә Г а й с ә килеп керә. Ул бер җиңен асылындырган килеш, ашыга-ашыга өстәлне ачып карый. Бер шешәне алып ачмакчы була да, ишек артында шау-шу ишеткәч, тиз генә кире куя. Бүлмәгә Х ә с ә н үтә.

Х ә с ә н. Ну, Гайсә, ну, молодцы! (*Аны кочаклап котлый.*) Премьера белән сине! Булдырдыгыз! Шаккаттырдыгыз халыкны! Миннән күптин-күп, чуктин-чук рәхмәт. Беләсеңме, иң мөһиме синнән торды. Әгәр син шулай алып бармасаң...

Г а й с ә. Ничек инде, синең өчен... Мин тотынгач, понимаешь ли...

Х ә с ә н. Алла боерса, әле без синең белән, ә?! Әле минем планнар зурдан. Әле минем сиңа...

Г а й с ә (*өстәлгә күрсәтеп*). Алайса, шуның өчен...

Х ә с ә н. Тукта инде, җыелсыннар. Беләсең бит, мин вакланып тормыйм. Бөтенесе дә булса, күңеллерәк, хакмы?

Г а й с ә (*күңелсез генә*). Хак, хак...

Х ә с ә н. Ә калганнар кая соң әле?

Г а й с ә. Бер-берсен котлап туя алмый торганнардыр.

Х ә с ә н. Алай димә. Начар түгел бит. Бәйрәм бит...

Г а й с ә. Бәйрәм дә...

Х ә с ә н. Хәер, хатын-кызлар, главалар, кунак бүлмәсенә җыелырга булдылар. Аңлыйсыңмы, чит ил кунаклары да бар, ди, бүтәннәр дә... яхшы түгел, диләр...

Г а й с ә. Соң, әлбәттә, әлбәттә... Әгәр...

Х ә с ә н. Түз инде... Беләсеңме, сиңа гына әйтәм. (*Колагына.*) Минем тагын моннан да кызык бер әсәр бар...

Г а й с ә. Кит әле, кай арада өлгерәсең син?

Х ә с ә н. Һәй, килсә, ташып килә ул миңа. Менә кул, бармаклар язып өлгерә алмый.

Г а й с ә (*шешәгә тотынып*). Соң, моның өчен...

Х ә с ә н. Уйлавымча, син мине яклап эндәшерсең инде. (*Шешәне алып, кире куя.*) Әйдәп баручы актер син хәзер... Сүзең үтәр...

Г а й с ә. Ни диим, уйларбыз... (*Шешәне тартып ала да салып эчеп җибәрә.*)

Х ә с ә н. Алайса, мин сине күздә тотачакмын, име?..

Г а й с ә. Уйларбыз, дидем.

Х ә с ә н (*уйлап тора да, аңа өстәп сала*). Синең хәтле эшләгән кеше юк хәзерге көндә... Ә нинди рольләр... Мин бит карыйм, күрәм... Ник исем бирмиләрдер... Менә әйтәм әле...

Г а й с ә. Ансы ук кирәкмәс... болгатма, яме...

Х ә с ә н. Әйтәм. Ничек инде ул? Минем сүз үтә, беләсең... Дусларны якламыйча... Ярый, мин карап килим әле, ник килмиләр икән. А ту тегендә дә өлгерергә кирәк. Син, ни инде, ашыкма, яме...

Г а й с ә. Юк, юк, миңа булды...

Х ә с ә н. Җыелгач. Аракы — диңгез... Борчылма. Кара әле, сине анда берәү сораган иде. Дәшимме?

Г а й с ә. Кем тагын?

Х ә с ә н. Ну, чибәр үзе, яшь...

Г а й с ә. Сорап торасың, чибәр дә булгач... Бар инде, бар, торма.

Хәсән китә. Гайсә киемен алыштыра. Тагын бер рюмка салып ала...

Яшәргәме, әллә үләргәме, менә сорау нәрсәдә... (*Эчеп куя.*)

А л ь б е р т керә. Бик канәгать кыяфәтле күренсә дә, күңел түрендә ниндидер ризасызлыгы барлыгы сизелеп тора. Әллә акча җитенкерәми, әллә дәрәҗә җитеп бетми, әллә роль — әллә үзе шундыйрак.

А л ь б е р т. Ну, картлач, премьера белән что ли?! (*Кул суза.*)

Г а й с ә. Что ли, что ли... (*Кулын бирә.*)

А л ь б е р т. Автор иптәш кайда соң әле безнең?

Г а й с ә. Монда... Чыкты бугай.

А л ь б е р т (*чишенә-чишенә*). Ә бу нәрсә? Ул, хайван, нәрсә, безне монда гына сыйлап котылмакчы мәллә?

Г а й с ә. Белмим.

А л ь б е р т. Белмим, белмим... Нәрсә, шушы мыскыл-

лауга риза булмакчы буласыңмы? Безнең аркада күтәрелә, зараза, тагын сыйларга да иренә.

Гайсә. Миңа барыбер. Монда уңайрак та әле...

Альберт. Нәрсә уңай, нәрсә?

Гайсә. Тынычлап эчәргә була. Бер хуҗа да юк... Һәм...

Альберт. Сиңа инде шул булса... Аңла, безне хәзер кеше рәтенә дә кертми башладылар. Утызны узып кырык ягына чыктык. Бөтен җүнле рольләрдә без диярлек...

Гайсә. Җитте инде... Ташла әле.

Гарәфи керә.

Гарәфи (*чишенеп*). Ничек инде ул хуҗалар булмасын ди?! Ә? Ә мин кем? Понимаешь? Театрны ашатып торам...

Альберт. Әй, кит әле, син дә торма... Карачкы... Синсез ачка үләр идек...

Гарәфи. Җ-ә, җ-ә, мин булмасам... театрыгыз әллә кайчан таралып бетәр иде... (*Гайсәгә.*) Мә, тот. (*Кулын суза.*) Премьера белән...

Гайсә. Сезне дә...

Гарәфи. Ишеттеңме? (*Альбертка.*) Җүнле адәм, сез, дип дәшә белә... Аңлый, потому что...

Альберт. Бар әле, бар...

Гарәфи. Барырмын да мин... Ни, кая соң, кайда җыенабыз?..

Альберт. Кайда? Утыр урыныңда, син кемгә хаҗәт.

Гарәфи. Ничек? Безне банкетка дәшмиләрмени?

Альберт. Көтеп утыр.

Гарәфи. Ну-у, җәмәгать. Бу дирекциясен дә әйтер идем.

Гайсә. Барыбер түгелмени, кайда эчсәк тә...

Гарәфи. Мин, энем, беренчедән, гүпчем эчмим.

Альберт. Нәрсә? (*Көлә.*)

Гарәфи. Көлмәгез, пожалуйста. Икенчедән, бу ни бу? Гел безне санга сукмау? Гелән-гелән безне читтә калдыру?! Театрны ашатып торабыз, понимаешь ли... Ул режиссер белән директорын да әйтер идем, шуны да күрә белмиләр... Карале, нигә әле син берни дә дәшмисең?

Гайсә. Ни диим. Миңа барыбер...

Гарәфи. Ничек барыбер булсын... Туктале, тукта... Ә-ә, әллә син манчыган да инде... Чынлап та...

Гайсә. Манчыса... Сиңа ни...

Альберт. Ул өлгермәсә...

Гайсә. Шуннан... Хәл начар иде...

Г а р ә ф и. Ярар, ярар, барыбызда да була.

Х ә с ә н  С ө м б е л н е ияртеп керә. Ул әле бик яшь һәм саф күңелле кызга охшаган. Кулында чәчәкләр.

Х ә с ә н. О-о, мондагы чәчәк, мондагы гөлләр. Минем аркада үсепме-үсәсез, ә?

Г а р ә ф и. Үселде инде, үселде. Пенсиягә дә күп калмый.

А л ь б е р т. Әллә үзеңме безнең җилкәдә.

Х ә с ә н. Шаярам, егетләр. Бергә-бергә инде. Бар да җыелган, башласак та була.

Г а й с ә. Әйдә, башласаң башла инде.

Аны Альберт туктата.

А л ь б е р т. Нәрсә, башларга?

Х ә с ә н. Соң, мәҗлесне ачык дип белдерәм.

А л ь б е р т. Ә калганнар кайда?

Х ә с ә н. Кемнәр?

А л ь б е р т. Син башыңны җүләргә салма, яме...

Г а р ә ф и. Җегетләр, каты кылана күрмәгез берүк, каты кылана күрмәгез... Халыкны тәгәрәтерлек спектакль уйнадык...

Х ә с ә н. Ә-ә, син хатын-кызларны әйтәсеңме? Хәзер башлыйк та, аңлатам...

Г а й с ә. Җә, башласак башлыйк, җә таралыйк.

Х ә с ә н. Ә-ә, әйе, менә егетләр, танышыгыз, сезнең поклонница...

С ө м б е л. Юк, ни... Мин... Мин Гайсә янына гына идем...

Х ә с ә н. Димәк, Гайсәнең уйнавын ошаткансыз, димәк, безнең кунак...

С ө м б е л. Ошаттым дип...

Х ә с ә н. Узыгыз, уз...

Г а й с ә. Кергәч, үт инде, уз... Өйгә кил дигән идем түгелме мин?

Сөмбел Гайсәгә чәчәк бирә.

Рәхмәт...

Х ә с ә н. Менә хәзер башласак та була. Ә ни, Рәсүл кайда соң? Гайсә, дәшмисеңме?

А л ь б е р т. Әй, йөрмәсен әле.

Х ә с ә н. Белмим дә инде, миңа яхшы түгел.

А л ь б е р т. Ярар, бетмәс монда җыен — «ботка пеште»ләр. Бер җүнле роль уйнаганы юк, йөрмәсен безнең арада буталып...

Х ә с ә н. Белмим инде...

Г а р ә ф и. Ярар, килмәсә килмәс, керсә,— утырыр.

Альберт. Һе, керми ул.
Хәсән. Нигә?
Альберт. Горур, менә шундый.
Гайсә. Башлыйбызмы, юкмы?
Сөмбел (*Гайсәгә генә*). Ул минем ерак булса да туганым.
Гайсә. Кем?
Сөмбел. Рәсүл абый.
Гайсә. Шуннан ни?
Сөмбел. Әлегә берни дә түгел.
Хәсән. Әйдәгез, җәмәгать. (*Өстәл япмаларын ача.*)
Гарәфи. Охо, монда малай...
Хәсән. Бар да бар, егетләр, гөрлибез...
Гарәфи. Моны сыйладыңмы?
Хәсән. Авырыйм дигәч...
Гайсә. Санап бар, яме...

Эчеп куялар.

Хәсән. Егетләр, ашыкмагыз инде, берәр тост!
Гарәфи. Сыла.
Хәсән. Ни диим... Рәхмәт, егетләр. Халык нишли, ә? Егыла-егыла көлә. Аннан мәгънәсе — мәгънәсе ни тора! Мин тирәнгә салган мәгънәви аспектны, сверхзадачаны режиссер ничек куйган да, сез ничек итеп оста китереп чыгардыгыз, ә?! Рәхмәт, дуслар! Алла боерса, киләчәктә дә, шулай уңышлы итеп, халык күңелен күтәрерлек итеп иҗат итәргә язсын. Без бит иҗат кешеләре, егетләр! Әйдәгез, бөек иҗат өчен!
Альберт. Шәп әйттең, моның өчен күтәрми булмас.
Гарәфи. Сөйлисең бармы? (*Гайсәгә.*) Син ник дәшмисең?
Гайсә. Искиткеч. Әйдәгез, шуның өчен...
Хәсән. Тә-ә-әк, тагын кемгә сүз бирик?
Альберт. Үзем әйтим әле.
Гарәфи. Тукта әле, менә Гайсә әйтсен әле, син соңрак.
Хәсән. Әйе, әйе. Йә Гайсә, дускай?
Гайсә. Ни диим... Ну, әйбәт кенә спектакль эшләдек... Киләчәктә дә шулай уңышлы гына эшләргә язсын... Ну, халык яратсын диикме инде шунда... Ну, әйдәгез, булмаса...
Альберт. Юк, болай гына ярамый. Үзем өстим әле. (*Пауза.*) Менә без гел уйнарга язсын да, тегеләй-болай дибез. Менә мин ни дим: уйнарга да язсын, күрсеннәр дә, кадерне дә белә башласыннар. Инде театрны җигелеп диярлек тартабыз, шулай булгач, исемен дә бирсеннәр,

акчасын да арттырып торсыннар. Һәм, гомумән, театр ул, егетләр, киләчәктә безнең кулга каласы, дәрәҗәбезне белеп, кадеребезне белеп, өскә үрмәләгән саен нык басып калырга язсын. Әллә дөрес түгелме?

Г а р ә ф и. Сүзләрең алтын ла.

А л ь б е р т. Әйдәгез, шуның өчен!

Рюмкаларны күтәреп куялар.

Г а р ә ф и. Гомумән, искиткеч комедия оештырганбыз.

Х ә с ә н. Рәхмәт инде, егетләр.

А л ь б е р т. Син безгә генә ябыш. Безне, кара аны, онытма.

Х ә с ә н. Әле без сезнең белән... Ягез, бердәмлек өчен.

Тагын тост күтәрәләр.

Ә-ә, менә (*Сөмбелгә карап*) чын тамашачы фикерен дә ишетик әле.

С ө м б е л. Ни диим?

Г а й с ә. Ни уйлыйсың, шуны яр, оялма.

С ө м б е л. Тик сез ачуланмагыз, зинһар өчен, яме?

Г а р ә ф и. Ниткән ачу ди, яр да сал. Гайсә, тотынып утыр, сине бетерергә килгәндер бу кызый.

С ө м б е л. Нигә? Киресенчә, ул миңа ошады.

А л ь б е р т. Ние белән? Тиресе белән сөягеме?

Х ә с ә н. Туктале, тукта, шуннан?

С ө м б е л. Юк, уены белән дә түгел. Ниндидер моңы бар аның күңелендә.

А л ь б е р т. Ә безнең?

Г а р ә ф и. Безнең димә, минем диген, үзеңне генә сөйлә...

С ө м б е л. Сезне ошатып бетерә алмадым, ачуланмагыз...

А л ь б е р т. Нәрсә? (*Көлә.*) Ни сөйли ул? Тәнкыйтьчеләр, әле Мәскәүдән килгәннәре, мине ничек мактыйлар, беләсеңме? Һе, кыз-зый...

С ө м б е л. Гафу итегез...

Х ә с ә н. Ә әсәр, әсәр ничек? Шәпме?

С ө м б е л. Әйем, әйтмим.

Г а й с ә. Яр шуларга, яр, правду матку...

Х ә с ә н. Йә?

С ө м б е л. Әсәр бөтенләй ошамады. Кызык та кебек инде үзе... Юк, юк, ошамады... Ачуланмагыз...

А л ь б е р т. Эләктеме, сылыймы кызый. Аны Гайсә юри котыртып куйган, үзен мактатырга...

Г а й с ә. Әй син, барбос...

Г а р ә ф и. Егетләр, кызмагыз...

Х ә с ә н (*елмаерга тырышып*). Сез нәрсә инде, бу бит бик гади, җәмәгать... Син, ни, сеңлем, аңлап бетермәгәнсең... Монда беләсеңме, катлаулырак катламнар ята... Гади күз белән генә күреп бетерерлек түгел...

Г а й с ә. Хәсәнулла, юкны лыгырдап утырма, бар, алып кил әле...

Х ә с ә н. Кемне?

Г а й с ә. Кемне, кемне, аның кем икәнен беләсең бит.

Х ә с ә н. Соң әйтеп торам лабаса, анда чит ил кешеләре, үзе дә шунда...

Г а й с ә. Булса, кем әле ул шулкадәр?

Х ә с ә н. Кем әле түгел шул, режиссер әлегә. Аның алдында ничек ычкынсын инде ул?

А л ь б е р т. Шул себеркегә калмасаң. Һәй, кешеләр, өйләнеп тә җибәр тагын.

Г а й с ә. Синең эшең түгел, балда. (*Хәсәнгә.*) Бар, әйт, мин чакыра диген. Шулай дисәң, очып килер.

А л ь б е р т. Килер, син дип, шуннан очар... Тиле ди ул.

С ө м б е л. Бәлки, сезгә кайтыргадыр?

Г а й с ә. Нәрсә? Син дә мондамыни әле? Әйттеләр бит инде сиңа, өйгә килерсең дип, бар элдерт моннан...

Х ә с ә н. Җә, җә, кунакка кагылма. Хәзер, алайса, кадал инде... (*Чыгып китә.*)

Г а й с ә. Вот так, вот...

А л ь б е р т. Бар, бар, чакыр шул себеркене...

Г а й с ә. Карале, син...

Г а р ә ф и. Булды... Буеңа сеңдер бераз...

Г а й с ә. Нәрсә, артист булдың мәллә?

А л ь б е р т. Ә нәрсә, ошамаганмыни?

Г а й с ә. Охшаган, маймылның бер төшенә.

А л ь б е р т. Гарәфи абзый, тый әле шуны, юкса?..

Г а й с ә. Нәрсә, юкса? Кем дип беләсең син үзеңне?! Ну, ярар, мине дә булсын. Ну, менә нәрсә майтарып ятабыз без монда? Ә-ә, онытканмын икән, иҗат итәбез.

С ө м б е л. Гайсә абый, җитәр, ә? Урыны ул түгел.

Г а й с ә. Карале, кара моны? Син әле ычкынмадыңмыни? Ни дидем мин сиңа?! Марш!

Сөмбел елап чыгып йөгерә.

Г а р ә ф и. Сеңлем, сеңлем... Ну, Гайсә, сәгатең сукты бугай...

Г а й с ә. Кыланмагыз. Үзем беләм мин.

А л ь б е р т. Үзе белә ул!

Г а й с ә. Беләм шул. Синең ише генә түгел. Ни майтарам дип әтәчләнәсең соң син, идиот? Шул җен әвәләгән тозсыз кәмит күрсәтеп, мисез сарык кебек колагын асы-

лындырган мескен, мәхлук тамашачыга өч тиенлек әкият сатабызмы?! Синеңчә бөек театр шулмы?

Гарәфи. Ну, энем, ничек тә тырышабыз бит инде.

Гайсә. Нәр-р-сә-ә? Ә гомер үтеп бара, җүнле эш тә эшләгән дә юк. Ну, ни майтара ул безнең режиссерлар? Ну, менә ни? Ә бит режиссура ул профессия генә түгел, ә зур җаваплылык. Театрның рухи кыйбласын билгеләүче театрның «дәү әтисе» булырга тиеш ул режиссер. Ә болар, тфү! Менә ниегез бар театрыгызда ис китәрлек, ну, ни?

Альберт. Театрыбыз дип сөйләш, хәшәп.

Гарәфи. Сөйләсен, Альберт, сөйләсен. Ник, дөресен сөйли бит. Юк бит иҗат, малай, юк.

Гайсә. Театрыбыз булсын, чукын. Шушындый тозсыз спектакльләрдән, ыштан төшереп көлдерә торган комедияләребездән кала ни бар? Берни, берни, берниебез дә юк, юк, юк!!!

Альберт. Берне тондырсаң, туктар идең инде анысы.

Гарәфи. Син нәрсә инде, дөрес сүз өчен.

Гайсә. Нәрсә, тән сакчылары булдыңмы әллә?

Альберт. Карале, син, хет шунда әллә ничек чәйнә аларны, кылым да селкенми. Үзең күңелне болгатасың, шул гына.

Хәсән керә.

Хәсән. Булды, хәзер килә.

Гайсә. Менә (*Хәсәнгә*) бусы җыен тозсыз, болганчык сүз тезмәләре оештырып болгатучы...

Хәсән. Ни сөйли бу?

Гайсә. Слушай, язма син бүтән, беркайчан да, зинһар өчен, язма! Ну, уйнарлык түгел, кая, укырлык түгел бит ул чүп-чарны...

Хәсән. Син ычкына башладың мәллә? Хе-хе... Егет исереп киткән, җәмәгать. Әйдә, кайт әле син, әйдә кайтабыз.

Гайсә. Җибәр, кит әле моннан. Бар әнә тегендә барып ялагайлан... Һе-е. (*Мыскыллы чырай ясый.*)

Хәсән. Ни сөйлисең син... Көлдермә, яме...

Альберт. Нәрсә сөйләшеп торырга шуның белән. (*Гайсәне селтәп ташлый.*) Җиттеме?

Гайсә. О-о, көчле... да...

Хәсән. Син, чыннан да, сүзләреңне үлчәп сөйлә инде...

Гайсә. Үлчәргә кирәк икән шул... шул... шул...

Альберт. Сиңа алар рәтенә җитәргә әле, койрык чәнчеп, Кытайга чаклы җәяүләп чабарга кирәк. Койрыгыңны кыссаң, җүнлерәк булыр, име?

Г а й с ә. Ие, ие, ие шул.

Ә н з и р ә керә.

Г а й с ә. А-а, минем мәхәббәт...

Ә н з и р ә. Нихәл, егетләр. О-о, сезнең монда... Каты сезнең бәйрәм.

А л ь б е р т. Сезгә җиткереп булмас инде.

Г а й с ә. Киттек.

Ә н з и р ә. Кая? Беркая да бармыйм.

Г а й с ә. Киттек, дим.

Ә н з и р ә (*көлгән булып*). Карале, карагыз әле моны. Син миңа кем әле ул кадәр?

Г а й с ә. Беркем дә. Киттек.

Г а р ә ф и. Беләсеңме, Әнзирә, эш нидә. (*Колагына пышылдап.*) Исереп китте ул. Ул сиңа беркем дә түгел дә...

Ә н з и р ә (*аңа гына*). Ярый, алай булса, бераз котыртыйм әле... хи-хи.

Г а й с ә. Миңа син кирәк, хәзер үк, аңла...

Ә н з и р ә. Өзелеп яратам дисәң генә инде... Хе-хехе... Үтерә бу...

Г а й с ә. Әйдә, дим...

Ә н з и р ә. Мин дә көтәм...

Г а й с ә (*сынагандай булып*). Ну, әйе, да, да...

Ә н з и р ә. Нәрсә да, да?

Г а й с ә. Ну, яратам дим бит инде...

Ә н з и р ә. Көлдереп үтерә бу безне, җәмәгать. Ярар, әйдә өеңә кадәр озатып куйыйм... Без барыбыз да театрда бер-беребезне өзелеп яратабыз... Шулай бит, егетләр...

Г а р ә ф и. Шулай, шулай...

Ә н з и р ә. Киттек әйдә, сарыгым минем.

Ут сүнә.
Тар гына прожектор уты авансценаның уң як читенә, борынгы кәнәфидә утырган Р ә с ү л н е яктырта. Ул шулай ук борынгы киемнәрдән. Янындагы бер кешегә сөйләгәндәй, залга мөрәҗәгать итә.

Р ә с ү л. Театр прекрасен. Но прекрасен истинный театр, а не то, что мы имеем. А мы имеем что? Мы имеем страшно, грубо, пошло искаженный конгломерат подобия театра, тех времен, когда он был придуман для передачи высших мыслей, идей и великих утонченных чувств, тем помогая миру в усовершенствовании бытия и мышления. Вот что было заложено изначально театру, а не то, что мы имеем...

Ут сүнә. Рәсүл юк була.
Яктылык Гайсә бүлмәсен яктырта. Г а й с ә төш күреп ята. Ул ниндидер кысан, тәбәнәк бүлмәдә, караватта йоклап ята шикелле. Аның янында Ә н з и р ә дә йоклый. Ләкин ул башта күренми. Гаскәри булып киенгән

э т и с е керә. Гомумән, бар керүчеләр дә төрле чор гаскәриләре формасында. Ул, сак кына килеп, як-ягына каранып, Гайсәне уята башлый.

А т а. Улым, улым, тор тизрәк. Хәзер монда да килеп җитәләр.

Гайсә дәшми.

Улым, дим...

А н а керә. Ул да солдатча киенгән.

А н а. Шым, ай Аллам, уята инде баланы. Кагылма, дим, атасы, йокласын бер рәхәтләнеп... Менә болай итеп тирбәт, ичмасам, изрәсен азрак. Гел иркәләргә өлгерми калам, гел өлгереп җитеп булмый, алайса...

А т а. Уятма дип, нишлисең инде син, ә? Хәзер керәләр бит.

А н а. Керсәләр тагы. Бәлки күрмәсләр дә әле. Капла, менә болай итеп... (*Итәге белән каплый.*)

А т а. Күрмәсләр сиңа... Алармы күрмәс... (*Әнзирәне күреп алып.*) Абаусана, бусы кем? Уф Аллам...

А н а. Кем, кем? Хәзер шуны тикшереп торыр вакытмы соң?.. Капла...

Д и р е к т о р х а н ы м, р е ж и с с е р һәм башкалар керә. С ә л и м сул як почмактан аларны күзәтеп тора.

Д и р е к т о р х а н ы м (*режиссерга*). Тә-әк, сез монда уенны ничегрәк оештырырга икәнен уйлый торыгыз, ә калганнар — эзләргә.

А т а. Монда бит беркем дә юк.

А н а. Җөрерләр инде, юкны бушка аударып...

Р е ж и с с е р. Йөрербезме-юкмы, безгә монда эшләргә кушылган. Без башкармый кала алмыйбыз...

Д и р е к т о р х а н ы м. Дөрес. Сез кемнәр?!

Б а р ы с ы д а. Солдатлар! Гаскәриләр!

Д и р е к т о р х а н ы м. Дөр-рес! Шулай булгач, хезмәтегездә булыгыз!

Р е ж и с с е р (*караватны карап*). Ә бу нәрсә?

А н а. Карават ич, күзең чыккан мәллә?

Д и р е к т о р х а н ы м. Ә караватта кем?

А т а. Беркем дә юк бугай, әфәндем, әй ханым, әй туташ, туташ ла...

Г ө л б о с т а н. Абзыкай, кайда ул, аның бит 1 сәгать тә 32 минут инде менә ашаганы да юк, ә мин аңа пәрәмәчләр китердем. Кайнар...

Д и р е к т о р х а н ы м. Йә?

А т а. Мәгез инде, мәгез, карагыз! (*Апасына.*) Син дә.

Г ө л б о с т а н. Мин нәрсә, нәрсә мин? Тамагы тук булсын дип тырышам, һаман да мин бинават...

А н а. Юк дидек бит инде монда, вәт халык, әй...

Д и р е к т о р  х а н ы м (*юрганны ачып*). Әх-хә! Менәтерә!

А н а. Йоклый ул, йокласын. Соң, сезгә дә йокылы хәлендә әйбәтрәк бит...

Д и р е к т о р  х а н ы м. Юк, йоклар чагы үтте. Бүтән аңа бернинди йокы юк! Уят. Ә бусы кем?! Әһә, үзе генә дә түгел... Тәк, тәк...

Г а й с ә (*уянып*). Китегез әле, ни кирәк сезгә?

Ә н з и р ә. Мин гаепле түгел, мин үземчә әйбәт булсын дип тырыштым...

Р е ж и с с е р. Тик тор, синең белән сөйләшү башкача булыр...

Д и р е к т о р  х а н ы м. Беләбез, беләбез. Кара аны, ычкындыра күрмә, сөлек кебек ябыш.

Ә н з и р ә. Мин тотынгач инде.

Г а й с ә. Ни сөйлисез сез?

Р е ж и с с е р. Синең эшең түгел.

А т а. Улым, улым. Монда килеп эләккәч, тыңла гына инде. Монда карышырга ярамый. Мә, тизрәк форма ки...

Г а й с ә. Ниткән форма тагын?

Р е ж и с с е р. Форма гына түгел, саркофаг аның дөрес исеме...

Г а й с ә. Нәрсә, нәрсә?

Р е ж и с с е р. Саркофаг — табут инде, гади итеп әйткәндә. Ну, форманың, киемнең исеме.

Д и р е к т о р  х а н ы м. Безнең солдатларның киеме була инде, аңламаса аңламас икән. Бел! Форманы бозарга, формадан чыгарга ярамый! Категорически!!!

А т а. Боза күрмә инде.

А н а. Бер формага кергәч, җиңел ул.

А т а. Бер формага ияләшкәч шундый рәхәт була, чыгасы да килми.

Г ө л б о с т а н. Режим белән ашарга өйрәнгәч, тазарып та китәрсең, бәбкәм, ату гел сөяк, одни мослы.

Р е ж и с с е р. Шым, булды, җитте, без подсказки. Үзе белсен. Сабый бала түгел.

А н а. Каян белеп бетерсен инде ул барсын да. Хөрмәтле директор ханым, зинһар өчен, сорасын инде?

Д и р е к т о р  х а н ы м. Ярый, тик аз гына.

Читкәрәк китәләр. Сәлим аларга яхшы дип билге күрсәтә.

А н а. Сора, балам, тизрәк сорап кал.

Г ө л б о с т а н. Энем, мә, тыңлама беркемне дә, тамагыңны туйдыр иң элек. (*Ризык бирә.*)

Г а й с ә. Рәхмәт, апа. (*Капкалый башлый.*)

Ә н з и р ә. Миңа да, минем дә ашыйсым килә. (*Гайсә кулыннан йолкып алып ашый башлый, үзе шарык-шорык көлә.*)

Г ө л б о с т а н. Ник көләсең? Әрсез алабай. Әй, кыяфәт кешедәге... Үләм... Оятсыз... Капла, ичмасам, ботларыңны...

Г а й с ә. Ә нинди урын соң бу?

А т а. Театр бу, улым.

Г а й с ә. Ә сез монда ни эшлисез?

А н а. Хезмәт итәбез, улым, хезмәт.

Г а й с ә. Ничек? Нигә, соң бит сез, солдатлар?..

А т а. Гаскәриләр шул. Шуңа хезмәт тә итәбез...

Г а й с ә. Ничек инде? Үзе театр, үзе солдатлар?

Г ө л б о с т а н. Без театр гаскәриләре. Театрда хезмәт итәбез. Менә мин аларны ашатып-эчертеп торам. Бар да бик канәгать...

Г а й с ә. Туктагыз әле, мин берни дә аңламыйм. Бу җир ничектер бер дә театрга охшамаган... Әллә...

А т а. Ш-ш-ш. Дөрес, улым, бу төрмә. Тик без төрмә димибез.

А н а. Театр дигәч, бераз уйнарга ирек бирәләр.

Г ө л б о с т а н. Ашатырга да.

А т а. Без, башны юләргә салып, театр дигән булып уйнап йөрибез. Төрмә дисәк, безне тегеләр бөтенләй кысып, сытып бетерерләр иде...

А н а. Син дә театр дип кенә фараз кыл, яме, улым...

Г ө л б о с т а н. Ашавың да шулчак мул булыр...

Г а й с ә. Ничек инде? Бу бит әллә нәрсә? Диварлары кара, кысан, пычрак, сасы, ничек итеп алдашмыйм ди. Караны ак дияргәме? Юк, юк, әйтмәгез дә...

А т а. Тс-с-с, балам, кычкыра күрмә, ишетмәсеннәр. Кысан шул, түбәсе дә тәбәнәк, шуңа интегәбез дә...

А н а. Бик күтәрелеп булмый шул...

Д и р е к т о р   х а н ы м. Булды, күпме лыгырдарга була?! Молчать, спрашиваю я вас! Тезелергә! Смирно!

С ө м б е л кисәк яктыда пәйда була.

С ө м б е л. Зинһар, бирешә күрмә, Гайсә абый. (*Юк була.*)

Г а й с ә. Мин теләмим!

Р е ж и с с е р (*директорга карап*). Нәр-рсә-ә?!

А т а. Улым, улым, ярамый.

Д и р е к т о р   х а н ы м. Разговорчики в строю. Ярар. Синең белән икенче төрле сөйләшү булыр. Ә син?

Г а р ә ф и. Ханым, мин бөтен сөйләшкәннәрен ишетеп тордым, сөйлимме?

Директор ханым. Соңыннан. Бас. Кара аны, егет...

Гайсә. Мин сезгә егет түгел...

Ана. Уф, балам.

Директор ханым. Разговорчики. Кем соң син?!

Гайсә. Кеше! Адәм!

Директор ханым. Адәм?! (*Көләләр.*) Мәхлук син, менә бу, чүбек. Кеше, имеш. Ярый, без тагын килербез, ә син уйла... Гаскәр, смирно! Сәхнәгә, уйнарга! Ур-ра кычкырып, бегом марш! Айт-два, айт-два.

Режиссер. Төшкә кадәр канау казуны репетировать итәргә!

Бар да ур-ра кычкырып тарала. Ана белән Гайсә генә кала.

Ана. Йокла, улым, йокла син, үчти, үчти. (*Тирбәтә.*)

Ут сүнә.

Ут Гөлбостан апасы өендә, Гайсә бүлмәсендә яктыра. Гайсә йоклап ята. Аны Әнзирә уятмакчы булып маташа. Төшендә Гайсәне әнисе тирбәткән булса, ул өнендә Әнзирәгә әверелә.

Әнзирә. Йокла, бәбкәм, йокла син, үчти, үчти... (*Кисәк.*) Тор, имансыз. Кышкы аю кебек бурсып ятасың. (*Гайсәгә төртеп ала.*)

Гайсә (*сискәнеп китеп*). А-а-о-а, нәрсә, ни булды? Мин кайда?

Әнзирә. Тор, тизрәк, талыйлар, талыйлар.

Гайсә. Ә-ә? Кемне?.. Ә? Талыйлар?!

Әнзирә. Юк, юк, таламыйлар.

Гайсә. Ну-у, ни булды соң?

Әнзирә. Торырга вакыт.

Гайсә. Котны алып бетерәсез инде... (*Йокымсырап.*) Мин тагын бераз гына, яме... (*Төренеп ята.*)

Әнзирә. Карале моны... Апаң кайтса... Яратам дигән була әле, ә мин нинди кешеләрне ташлап китәм аның өчен?

Гайсә (*кисәк уянып китеп*). Нәрсә-ә-ә?

Әнзирә. Әйе, әйе, шакмакландырма бәбәгеңне, калдырдым да киттем, күзләре шараеп кына калды...

Гайсә (*торып утырып*). Рәхмәт әйттем бит инде аның өчен. Кая, бармы анда берәр нәрсә безнең бераз?

Әнзирә. Нәрсә тагын?

Гайсә. Кыланма...

Әнзирә. Юк, беткән.

Гайсә. Кыланма, дим. Баш ярыла.

Әнзирә. Башлана.

Гайсә. Шуңа да ярамагач, ниемә соң син миңа?..

Әнзирә. Кичә миннән башка тора алмый идең, бүген баш төзәттерергә генә ярыйммы?

Г а й с ә. Карале, ник килдең син монда?

Ә н з и р ә. Кылан, кылан, кыланып кал. Ә, Әнзирәбәгърем, синсез яши алмыйм дигәндә, мин кыланырмын, яме?!

Г а й с ә. Карале, нигә үпкәлисең? Ни эшләдем әле мин? Ну, ни калган сиңа монда?

Ә н з и р ә. Их, Гайсә...

Г а й с ә. Гайсә, Гайсә, утыз өч ел Гайсә инде... Кая, сал әле...

Ә н з и р ә. Синнән котылып булса. Мә, актыгы...

Г а й с ә. Булды, миңа шушы артыгы белән җиткән... (*Пауза.*)

Ә н з и р ә. Җиткән... Кеше көлдермә, ичмасам... Гайсә, чыннан да, тукта инде, кешечә яшәп кара, ичмасам... Миңа да...

Г а й с ә. Соң, кешечә... Ни кылырга кушасың инде син миңа?

Ә н з и р ә. Әрепләшмә, тарткалашма. Бүтәннәр ни кыла? Һич югы, әнә бөтенесенең дә бакчасы бар. Эшлиләр, ял итәләр, җимешен дә җыялар, эчеп тә йөрмиләр.

Г а й с ә. Кай вакытта?

Ә н з и р ә. Нәрсә, кай вакытта?

Г а й с ә. Җимешен җыялар?

Ә н з и р ә. Сөйләмә, сөйләмә, гел пуфылдап, көчкә күтәренеп кайталар.

Г а й с ә. Миңа да бакчалы бул димәкче инде алайса син?

Ә н з и р ә. Карасана, ә син кемнән артык?

Г а й с ә. Артык түгел, ким. Теләмим.

Ә н з и р ә. Ник? Әле үзең миңа бәйләнеп йөргән буласың.

Г а й с ә. Минме?

Ә н з и р ә. Ә кем тагы? Кичә кем сугыша-сугыша алып китте?

Г а й с ә (*бик гаҗәпләнеп, көзгегә күз салып*). Неужели мин?

Ә н з и р ә. Әйе, хәзер, менә үзем монда сөйрәлеп килеп җиттем, ди, көтеп утыр...

Г а й с ә. Әйтәм җирле...

Ә н з и р ә. Әйтеп-нитеп торасы юк... Ни караватың, ни бакчаң, ни казыгың... Алкаш.

Г а й с ә (*көйләп*). Квартиралылар, бакчалылар, акчалылар бик күп бит, дисәнә...

Ә н з и р ә. Дисәмсәнә...

Г а й с ә. Бакчасы, бакчасында мунчасы, йөгерә-йөгерә суын ташый, нечкә билле урысы...

Ә н з и р ә. Булсын. Шуларны да булдыра алмагач, ир ирмени?

Г а й с ә. Мин ир түгел...

Ә н з и р ә. Кем соң син?

Г а й с ә. Мин Актер! Айм, Акте!!!

Ә н з и р ә. Акты инде, акты, кичә ачык авыз булып агызганнарың өчен дә ни булып бетәр әле.

Г а й с ә. Әй! (*Кул селтәп.*) Нам татарам один..., что война, что сабантуй...

Ә н з и р ә. Сөйләшүләре шушының, тел бете, өтек.

Г а й с ә. Ну нәрсә, нәрсә инде хәзер. Мин дә бакчачы булыйммы?

Ә н з и р ә. Ник сорап торасың аны.

Г а й с ә. Теләмим. Актер эше түгел ул. Кем дигән сүз ул актер, беләсеңме? Актер, актер... Акт сүзеннән алынган булырга тиеш. Акт, димәк, бу фани дөньяга туып, артист булырга язган икән, димәк, ул Акт совершать итәргә тиеш. Вәт...

Ә н з и р ә (*көлеп*). Итеп торасың бит инде, акт ясап... һәм... начар ук димәс идем... (*Сырпалана.*) Әйдә...

Г а й с ә (*ялкынланып китеп*). Юк, юк, син борма. Туктале, чынлап та бит... Б-р-р, айнып киткәндәй булдым... Акт, Акт ул... Дөр-рес, нәкъ шулай... Кар-рале син, Акт сүзе нинди зур мәгънә ала...

Ә н з и р ә. Аның мәгънәсе болай да зур. Син көчәнеп мәдхия укымасаң да...

Г а й с ә. Туктале, дим. Акт, Акт... Дөрес шул. Без Акт совершать итәргә тиешбез! Без бакча корты булып, суалчан булып казынырга тиеш түгел, ә бөтен гомерне, бөтен җанны, бөтен канны шул бөек Актка, ягъни Акт — тер булуга бирергә тиешле! Әйе, әйе, Акты — Акт булса, ә икенче яртысы — тер, ягъни терьер, мөгаен, совершать итүче, башкаручы, актны эшләүче мәгънәсе бит! Менә нинди бөек мәгънә йөртәбез без үз исемебездә! Ә без? Бакча, имеш. Ниткән бакча, ниткән башка чүп-чар?! Ю-у-ук, бары тик Акт! Бөек Акт!

Ә н з и р ә. Шашма әле!

Г а й с ә. Бүлдермә! Әйе, Акт! Шушы фани дөньяның тигезсезлегенә, адәмнәрнең дөрес яши белмәүләренә каршы бөек протест, җан ачысы, дөрләп яну, якты юлны күрсәтү, бөек, якты, ялкынлы Акт! Менә нәрсә ул! Ә син, бәрәңге...

Ә н з и р ә. Җә, җә, син генә акыллы инде...

Г а й с ә. Аңладыңмы? Тә-әк, шуның өчен, каяле, тагын берне күтәрик әле...

Ә н з и р ә. Нәрсә?..

Г а й с ә. Туби оно, туби, ягъни быть или не быть, вот в чем вопрос? Менә ни ул! Янам, яле, сал әле тагын берне...

Ә н з и р ә. Җитте, репетициягә барасың бар.

Г а й с ә. Сал диләр, ниткән репетиция?! Бу бит, бу?!

Ә н з и р ә. Акт инде, акты... Шаулап акты... Болай булсаң, театрдан ук... (*Салып бирә.*)

Г а й с ә (*эчеп*). Татарлар эчеп үлделәр... Ник көләсең?

Ә н з и р ә. Елмаеп диген, дивана. Артистлар гына эчеп үлә, халыкта...

Г а й с ә (*елмаеп*). Әй лә икән, татарлар елмаеп үләләр... Койрыгыма да элмим...

Ә н з и р ә. Һәй, эчкәч сез барыгыз да...

Г а й с ә. Чыннан да, Әнзирә, күпме мескенләнеп, койрык болгап, куркып яшәргә була? Менә мин әле аларга барам да...

Ә н з и р ә. Ни эшлисең?

Г а й с ә. Әйтәм. Барын да ярып салам...

Ә н з и р ә. Әтәчләнмә. Тагын салыйм мәллә?

Г а й с ә. Ю-ук, җитте. Пока... Менә күрерсең. Күрсәтәм әле мин аларга кузкину мать!

Ә н з и р ә. Бөек акт. Галәмәт инде... Сәхнәгә чыгып, «танавыма тирес тулды», әллә башкасын әйтеп күрсәтимме?

Г а й с ә. Ташла әле, мин бит... Шаярдым ла бит мин... Аннан бу ни бу безнең белән, ә? Әйбәт кенә утырабыз да, театрында да, мәҗлесендә дә шулай, тотабыз да шул чукынган театр турында сөйләшергә керешәбез... Әллә чирме соң бу... Инде туйдырыпмы-туйдырган бит, ю-у-ук, тагын кирәк... Укыган чактагы минем маэстро әйтмешли, бер тоз ташын ялаган бозау башка яламый торалмыйммы?.. Җитте, булды.

Ишектә кыңгырау тавышы.

Ә н з и р ә. Апаң? Ач.

Г а й с ә. Бәлки.

С ө м б е л керә, аның кулында бәләкәй генә төргәк. Төргәк йөрәк рәсеме төшерелгән кәгазьгә төрелгән.

С ө м б е л. Исәнмесез. Ой, гафу итегез, мин ялгыш мәллә?

Ә н з и р ә. Сезгә кем кирәк?

Г а й с ә. Юк, юк, ялгыш түгел, нәкъ вакытында. Әнзирә апаң как рас китәргә кысталып тора иде...

Ә н з и р ә. Минме?

Г а й с ә. Син, син. Тормыш театрының чиле-пешле, тозсыз, мәгънәсез сәхнәсен уйнап бетердек... Уйныйбыз, уйныйбыз, уйныйбыз... Но, но, ханым... (*Шигырь укый башлый.*)

О, время! Все несется мимо,
Все мчится на крылах твоих;
Мелькают весны, медлять зимы,
Гоня к могиле всех живых...
Но, но заключительную сцену
И ты не в силах изменить:
Лишь тех, кто придет нам на смену —
Ты будешь мучить и казнить!*

О, о, әфәнделәр...

С ө м б е л (*кул чәбәкләп*). Сез, сез... Менә гафу итегез... Минемчә, минемчә, менә ул сез... Менә ул сезнең чын йөзегез... җаныгыз... чынбарлыгыгыз... Эх, менә шундый булып кала алсагыз икән...

Г а й с ә (*елмаеп*). Булмый шул, булмый, сеңелкәш...

Ә н з и р ә. Аңамы? Аңа тагын... (*Шаркылдап көлә.*)

Г а й с ә. Карале, «туташ», сез китәргә ашыга идегез түгелме?

Ә н з и р ә. Минме? Ә-ә, мин кире уйладым бугай.

С ө м б е л. Юк, юк, мин комачауласам... Мин озак тормыйм... Тик, тик, кызганыч билгеле, сезнең белән чын күңелдән сөйләшәсе килгән иде... Гел туры килми...

Г а й с ә. Хәзер, менә бу «туганны» гына озатыйм да...

Ә н з и р ә. Мин беркая да ашыкмыйм.

Г а й с ә. Әнзирә, кыздырма мине. Мин сиңа инде күптән әйттем...

С ө м б е л. Юк, бәйләнешмәгез аның белән. Сез, сез... Андый түгел... Соңыннан...

Ә н з и р ә. Андый түгел, әй кешеләр. Көлдереп үтерәләр болар.

Г а й с ә. Дөрес әйтәсез, чүп белән чүп булганчы.

С ө м б е л. Кичә дә мин сезгә, шул сезнең чын күңелегез турында әйтәсем килгән иде дә, аңлата алмадым. Көлделәр генә...

Ә н з и р ә. Бүген дә көлдерәсең.

Г а й с ә. Җиттеме сиңа, ә?

С ө м б е л. Көлсен. Мин... Миңа, миңа сезнең... Миңа сезнең шул саф күңелегез ошаган иде...

Ә н з и р ә (*бөтенләй ярылып*). Саф күңел... Уф, үләм! Төнлә күрсәләр иде аның сафлыгын. Ой, үтерәсез...

С ө м б е л. Юкка, апа, алай итәсез... Сез бит белмисез... Ул бит...

Ә н з и р ә. Нәрсә? Ми-ин, апа?! Минме, белмим? Әй, «сеңлем»...

---

* *Дж.Г.Байрон* шигыре.

Г а й с ә. Җитте, дим, кайтасы барын оныттың бугай. Бар әле, бар диләр...

Ә н з и р ә. Кагылма миңа...

С ө м б е л. Зинһар өчен, талашмагыз. Минем өчен кирәкми. Нишлисең, язмагандыр. Мин бары сезне туган көнегез белән генә котларга килгән идем.

Г а й с ә. Туган көн?!

С ө м б е л. Әйе, менә сезгә, бәләкәй генә инде, ачуланмагыз. (*Төргәк бирә.*)

Г а й с ә. Ничек туган көн?

С ө м б е л. Кичә бит үзегез әйттегез, туачак көнем диеп, килегез диеп...

Ә н з и р ә. Туачак көне? Утырткан ул сине, үскәнем, төп башына, катасы көнедер аның. (*Көлә.*)

С ө м б е л. Ничек?

Ә н з и р ә. Аның туачак көненә чаклы әле...

Г а й с ә. Туктыйсыңмы син... Карагыз әле...

С ө м б е л. Сөмбел.

Г а й с ә. Сөмбел, сеңлем, ни иде бит ул... Теге, сине бик күрәсем, очрашасым килгән иде... Китерәсем... Ничектер бик якын итеп күргән идем...

С ө м б е л. Ничек? Димәк, ялган?

Ә н з и р ә. Ялган инде, ялган, бар кайт өеңә, әниең сагынгандыр, коймак пешергәндер, манный боткасы. Ату бу иблис сине хәзер...

Г а й с ә. Җитте диләр. Сөмбел, чыннан да, якын күрәсем килгән иде...

С ө м б е л. Хушыгыз... (*Чыгып йөгерә.*)

Г а й с ә. Сөмбел, Сөмбел... (*Артыннан омтыла.*)

Ә н з и р ә (*аны тотып*). Кайтыр юлны гына бутамаслык, светофорны күрерлек...

Г а й с ә. Китә беләсеңме син, юкмы?

Ә н з и р ә. Китәрмен, эх, шундый итеп китәрмен, эзләп тә таба алмассың.

Ишек төбендә тавышлар ишетелә. Г ө л б о с т а н  Х а җ и м у л л а белән кайтып керә.

Г ө л б о с т а н. Әйдә, әйдә, уз, Хаҗимулла абзый. (*Төргәкләрен, сумкаларын урнаштырып.*) Уф, көчкә, кайтып та җиттек. Эт булгансыңдыр инде, име, Хаҗимулла абзый?

Х а җ и м у л л а. Түзәрлек, ир кеше ич мин. Әле безнең монда... Ухү-ху... Дәрт тә бар, дәрман да бар... Аллага шөкер...

Г ө л б о с т а н. Анысы бар инде, Хаҗимулла абзый, бар синдә... Сөйләп торасы да юк, күз генә тимәсен... Ходай Тәгалә үз ярдәменнән ташламасын.

Хаҗимулла. Алла, үзең дә җыйгансың малны.

Гөлбостан. Җыйган дип, Хаҗимулла абзый, кирәк бит. Менә дөгесе дә кирәк, мае да, җимеше дә... фруктысы да... Аннан, тагын бәяләр артырга тиеш, диләр бугай... Алдым инде... Тамагың тук булмаса, Хаҗимулла абзый, күңел башканы да күрми. Тамак тук булсын...

Хаҗимулла. Ансын дөрес әйтәсең, дөрес. Тәмле ашап алсаң, әллә ниләр кылып, майтарып ташлыйсы килә. Күңел ачыла. Намаз да җырлап кына бара.

Гөлбостан. Шулай булмыйча. Карының ач булса, уең гел шул хакта гына була да инде. Әле менә боларын (*ширпотреб төргәкләрен күрсәтеп*) саткалаган булам. Пенсия белән генә... Энем Гайсәгә дә әйтеп карыйм да, чыкмый. Соң, аларның да инде, тиен генә алалар... (*Гайсә белән Әнзирәне күреп ала.*) Бәтәч, энем, син дә өйдәмени? Хе-хе, а ту мин монда сөйләнәм дә сөйләнәм, кунак бар икәнен дә күрми торам.

Әнзирә. Исәнмесез, Гөлбостан апа.

Гөлбостан. Саумы, саумы, шөкер әле, бәбкәм. Нихәл энем, нигә бер дә кәефегез юк... Әллә ач тордыңмы? Нигә инде? Кичә син кайтсаң дип, пәрәмәчләр, өчпочмаклар пешереп, холодильникка өеп тутырып калдырган идем, җылытып ашар дип. Ашамадыңмы?

Гайсә. Өлгереп булмады.

Гөлбостан. Ә-әй, ач йөр инде. Менә, менәтерә, гел шулай ул, Хаҗимулла абзый, гел үзен карамый. Әллә берәр ни булдымы?

Гайсә. Юк ла...

Әнзирә. Мине ничек куып җибәргә белми, шуңа кәефе киткәндер.

Гөлбостан. Ниткән китү, нинди китү ди ул. Син бит инде үз кешебез. Бөтен ризыкларымны мактый-мактый ашый да беләсең. Юк, юк, әйдә. Хәзер менә барын да җылытам да... Ач йөриләр, вәт әй... Хаҗимулла абзый, онытып та торам икән, куй менә монда ул сумкаларны...

Хаҗимулла. Зыян юк ла... Зыян юк. Шөкер әле, муллык синдә...

Гөлбостан. Аллага шөкер, ярдәменнән ташламый. Ярдәм дигәннән, энем, акчаңны алгач, ризык алырга миңа биреп куярсың әле, запас алып куясым бар.

Гайсә. Кая инде тагын, монда бит...

Гөлбостан. Алай түгел: гомумән, син берни белмисең. Сорашып та торма. Ашаган белми, тураган белә, диләр шул... Бераз сатышсаң инде шунда...

Гайсә. Уф, әйттем бит инде...

Х а җ и м у л л а. Әллә карышып маташамы?

Г ө л б о с т а н. Юк ла, андый түгел ул. (*Гайсәне сөеп.*) Акыллы ул үзе. Менә ашавы гына начар... Чыгар, Аллаһы боерса, чыгар, базарына да чыгар...

Г а й с ә. Алу белән бирермен, апа. (*Төргәген сүтеп карый башлый.*)

Ә н з и р ә. Апа, булышыйм, алайса. (*Булыша башлый.*)

Г а й с ә. Уильям... (*Укый.*)

Кто снес бы плети и глумленье века,
Гнет сильного, насмешку гордеца,
Боль презренной любви, судей медливость,
Заносчивость властей и оскорбленья,
Чинимые безропотной заслуге...
Когда бы он сам мог дать себе рассчет
Простым кинжалом?!*

Г ө л б о с т а н. Ни дисең, энем?

Г а й с ә. Юк ла, китап бүләк иткәннәр иде, шуны укыйм.

Ә н з и р ә. Гамлет ук мәллә?

Г а й с ә. Әллә-мәллә...

Х а җ и м у л л а. Ашау дигәннән... Ашау аларның, яшьләрнең, мәйтәм...

Г а й с ә. Мин?! Яшь?..

Х а җ и м у л л а. Яшь әле, яшь, энем. Безнең белән чагыштырганда, сабый әле сез. Шуңа өлкәннәрне, акыллырак кешеләрне сабыр гына тыңлап, акыл алып яшәргә өйрәнегез...

Г ө л б о с т а н. Энем, тыңла абзаңны, бүлдермә. Абзаң зур гыйлемле, иманлы кеше, беләсең... Сөйлә, сөйлә, Хаҗимулла абзый.

Х а җ и м у л л а. Яшьләрнең иман дигән нәрсәләре юк, шуңа әпәтитләре дә начар. Намазны белмә, бер дога белмә, иманга килә белмә...

Г а й с ә. Нәрсә соң ул?

Х а җ и м у л л а. Нәрсә — нәрсә?

Г а й с ә. Ну, иман?

Х а җ и м у л л а. Иманмы? Иман... Иман инде ул.

Г ө л б о с т а н. Башын катырма дидем бит абзаңның, тыңла гына, өйрән бераз, акыл ал...

Х а җ и м у л л а. Әй Гөлбостан, аларга әйттең ни дә, әйтмәдең ни...

Г а й с ә. Соң, нәрсә булды инде, иман?..

Х а җ и м у л л а. Менә, менә бит... Әй Ходаем!

---

* *Шекспирның «Гамлет» трагедиясеннән.*

Г а й с ә. Үзегез дә белмисез мәллә?..

Г ө л б о с т а н. Энем!

Х а җ и м у л л а. Оялмый ул хәзерге яшьләр, оялтма да, телеңне дә әрәм итмә. Хәзер, аңлатам мин аңа: иман ул, энем, Аллаһы Тәгаләне уеңнан чыгармау, намазны калдырмау, догаларны дөрес уку була ул, беләсең килсә. Менә сез дә, бераз...

Ә н з и р ә. Мин андый түгел, абзый, аңа гына әйтегез.

Г ө л б о с т а н. Син акыллы бала анысы. Менә үзеңне базарга да алып чыгармын әле.

Ә н з и р ә. Бик рәхәтләнеп.

Х а җ и м у л л а. Мин сез дип, бөтен яшьләрне әйтәм дә инде...

Г ө л б о с т а н. Хаҗимулла абзый, аның бөтенесе дә алай ук җүнсез түгел дә инде. Гайсә энем дә алай начар түгел ул үзе. Бераз олыларны тыңлап кына бетерми.

Х а җ и м у л л а. Ай Алла, соң бит, мин дә бит, ул начар егет димим. Яшьләр, дим. Бары бераз иманга кил, дим. Ураза вакытында — ураза тот, дим, намаздан калмаска тырыш, дим, шунда тормышың да рәтләнер, дим...

Г а й с ә. Сезнең рәтләндемени?..

Х а җ и м у л л а. Рәтләндеме дип, соң, иман белән яшим, иншалла.

Г а й с ә. Син идеңме әле ул, абзый, теге заманда бик кызып коммунизм төзегән кеше? Әллә ялгышаммы шунда?..

Х а җ и м у л л а. Көлмә, көлмә син, энем. Ә нәрсә? Төзедек тә. Берсе икенчесенә комачауламый. Аллага шөкер, Хода юлыннан да тайпылмаганбыз.

Г а й с ә. Кыйблагыз бик күп икән шул...

Х а җ и м у л л а. Ничек күп?

Г а й с ә. Җил кайсы якка иссә, флюгер кебек, шул якка борыла...

Х а җ и м у л л а. Әй энем, сиңамы соң безне тикшерү.

Г ө л б о с т а н. Сүз ярыштырып утырма олы кеше белән.

Ә н з и р ә. Ул гел шулай, аптырамагыз.

Г а й с ә. Миңа ни... Минем туган апа артыннан йөрүең нәрсә дип атала инде... Олы кешегә барамы ансы?

Х а җ и м у л л а. Карале, кара моны, оялмый да.

Г ө л б о с т а н. Энем, шаярма. Хаҗимулла абзаң җитди кеше, тегеләй-болай гына йөрмидер...

Г а й с ә. Шул гомердән бирлеме?

Х а җ и м у л л а. Үзебез белербез без, иеме, Гөлбостан?

Г ө л б о с т а н. Ие, эке.

Ә н з и р ә. Җитәр сиңа.

Хаҗимулла. Иманга килергә кирәк сезгә, иманга.
Гайсә. Ярый, абзый, мин киләм, ди. Ә сез?
Хаҗимулла. Ничек инде мин?
Гайсә. Мин менә ничек иманга килим? Берни тикшереп тормыйчамы?
Хаҗимулла. Йа Ходა, Аллаһы Тәгаләне тикшереп ышанмакчы буласың мәллә?! Әстәгъфирулла, тәүбә!
Гайсә. Ә бәлки сез алдыйсыздыр.
Хаҗимулла. Көфер сүз сөйлисең, көфер, энем. Беләсең килсә, болар бар да акыллы итеп язылган изге китапта, күктән иңгән.
Гайсә. Яхшы, мин риза. Тик сез дә минем иманыма күз йомып табынырга тиеш булачаксыз.
Хаҗимулла. Нинди иманга?
Гайсә (*аракы салып*). Менә каплап куй шушы кырлыны да, аннан мин дә сезнең чын күңелдән сөйләвегезгә ышанам.
Хаҗимулла. Тфү, тфү, ләхәүлевәләкуәте. Ни сөйлисең син иблис токымы?! Мин сиңа иман, дим, ә син миңа шайтан ризыгын сузасың. Аллам сакласын. Тфү, тфү, тәүбә...
Гайсә. Шул шул, абзый. Сез минем тотып карап, тәмләп авыз итеп була торган иманымнан да баш тартасыз, күрә торып. Ә мин синең буш сүзеңә дә күз йомып инанырга тиеш. Дөрес, китапта бик акыллы язылгандыр да, тик сезнең буш, дәлилсез, чын йөрәктән сөйләнмәгән сүзегезгә ышанып, тезләнеп намаз укый башлыйммы? Бәлки, сез үзегез дә ялгышасыздыр, мин шәраб эчеп ялгышкан кебек? Минем шәраб эчүем сезгә ялгыш булып күренсә, сезнең, үзегез дә мәгънәсен аңламыйча, гадәт буенча гына, кеше тезләнә дип, тезләнеп дога укуыгыз мине дә ышандырмый. Бигайбә...
Хаҗимулла. Һай, ялгышасыз, олан, ялгышасыз.
Гөлбостан. Ярый, әйдә, юкны-бушка аударып утырмагыз. Өстәл янына. Тагын эчтеңме инде, энем...
Гайсә. Бераз каптым инде, апа...
Гөлбостан. Әй энем, энем, йә, ярар. Менә әйбәтләп ашасаң, хәлләнерсең.
Гайсә. Бик ашыйсы килеп тормый иде дә әле ансы...
Гөлбостан. Юк, юк, сөйләмә дә. Сиңа дип әзерлим, әллә мыскыл итәсең шунда...
Гайсә. Нәрсә инде син, туган апа, ашыйбыз билгеле. Менә Әнзирә дә...
Әнзирә. Минем белән булышма. Ике өчпочмакны сугып куйдым инде мин.
Гөлбостан. Әнзирә маладис ул, өметле бала.

Г а й с ә. Бала...

Х а җ и м у л л а. Без дә бик яратабыз синең ризыкларны. Кулларың алтын. Кая әле, бисмиллаһи рахман ирраһим. (*Ашый башлый.*)

Г ө л б о с т а н. Әйдә, энем, аша.

Ут сүнә.
Ут директор кабинеты һәм аның алдын яктырта. Р е ж и с с е р  э ф ә н д е белән Г а р ә ф и күренә.

Г а р ә ф и. Монда бик урыны да түгел дә...

Р е ж и с с е р. Ярар, әйдә, иртә таңнан кем йөрсен монда.

Г а р ә ф и. Директор ханым.

Р е ж и с с е р. Ханым... Юк ул.

Г а р ә ф и. Булмастамы әллә?

Р е ж и с с е р. Килергә тиеш. Шуннан? (*Директор кәнәфиенә кереп утыра.*)

Д и р е к т о р  х а н ы м керә.

Д и р е к т о р  х а н ы м. Хәерле көн, әфәнделәр.

Р е ж и с с е р. Сәлам.

Г а р ә ф и. Исәнмесез, директор ханым.

Р е ж и с с е р. Шуннан?

Д и р е к т о р  х а н ы м. Ни ялганлый тагын бу?

Р е ж и с с е р. Һаман да шул премьера хакында инде...

Д и р е к т о р  х а н ы м. Ул егеткә берәр чара кылырга кирәк, җитте!

Р е ж и с с е р. Кылыйк соң.

Д и р е к т о р  х а н ы м. Сезнең карамакта түгелме соң ул актерлар?

Р е ж и с с е р. Шулай да... Кеше язмышы... Бер үзең генә хәл итә торган эш түгел.

Д и р е к т о р  х а н ы м. Язмыш дип, күпме түзәргә телисең? Үзеңне жәлләп тормаган, бик яхшылап иләгән.

Р е ж и с с е р. Ул малай бик әтәчләнә башлаган.

Г а р ә ф и. Кем дип уйлый микән ул үзен...

Р е ж и с с е р. Тагын ниләрең бар?

Г а р ә ф и. Шул, сөйләгәнемчә, директор ханым белән сезне тетте-тетте дә, аннары Альберт белән сугышып...

Р е ж и с с е р. Сугышып?

Г а р ә ф и. Дөресрәге, ул сезне яклаган кебек чыкты... Шул, бәргәләштеләр дә, Әнзирәне алып кайтып китте...

Р е ж и с с е р. Әнзирә? Ялгышмыйсызмы?

Г а р ә ф и. Ничек ялгышыйм, ул инде. Күзләрем менә дигән әле, унга ун күрә. Алар күптән бит инде...

Р е ж и с с е р. Беттеме?

Г а р ә ф и. Бетте бугай. Мин анысы үз кеше, тугрылыклы, сата торган түгел...

Р е ж и с с е р. Ярый, бар, карарбыз.

Г а р ә ф и. Яңа спектакль куя башлыйсың икән...

Д и р е к т о р  х а н ы м. Белмәгәннәре юк.

Г а р ә ф и. Без белмәгән аз булыр, Бохарада таз булыр... хе-хе...

Д и р е к т о р  х а н ы м. Калдырмас, бар.

Р е ж и с с е р. Бар, бар, сине калдырмам.

Г а р ә ф и. Рәхмәт, бик зур рәхмәтләр. (*Китә.*)

Д и р е к т о р  х а н ы м. Юк кына әйбер өчен, ниндидер роль өчен, бер-берсен сатып тик йөри бу халык, аңламассың.

Р е ж и с с е р. Юк, ялгышасың. Юк әйбер түгел ул алар өчен. Роль аларның язмышы, гомер юлы, яшәеше, яшәү формасы. Бик мөһим элемент.

Д и р е к т о р  х а н ы м. Барыбер дә... (*Пауза.*)

Р е ж и с с е р. Ни эшлибез?

Д и р е к т о р  х а н ы м. Чакырттым әле мин аны.

Р е ж и с с е р. Чакыртуын чакырткан, ни эшләтәбез?..

Д и р е к т о р  х а н ы м. Тотарга да куарга! Бөтен дөньяны болгатып йөри.

Р е ж и с с е р. Булдыклы егет тә үзе...

Д и р е к т о р  х а н ы м. Булдыклы! Ә тәртип нишли? Алмаштырмас артист тумаган әле бу дөньяга.

Р е ж и с с е р. Шулай да... Тагын бер, соңгы тапкыр сынап карыйк та...

Д и р е к т о р  х а н ы м. Күпме була? Хет телен тыя белсә иде...

Р е ж и с с е р. Фатир чиратында торамы әле ул синең?

Д и р е к т о р  х а н ы м. Берәр бүлмә булмасмы дип, үзәккә үтте инде.

Р е ж и с с е р. Менә шул якларга баскалап алсак. Акчасын киметеп... Аннан карарбыз.

Ишек шакыйлар. Г а й с ә керә.

Г а й с ә. Чакырткансыз икән...

Д и р е к т о р  х а н ы м. Ник коелып төштең, геройлыгың кайда?..

Р е ж и с с е р. Нәрсә, гаебең бармы әллә?

Г а й с ә. Кем белеп бетергән инде...

Сәхнә алмашына. Гайсәнең уй-хыялы пәйда була. Барлык персонажлар да катнаша.

Р е ж и с с е р. Ә-ә, Гайсә әфәнде, әйдәгез, әйдә, узыгыз, сезне көтәбез.

Директор ханым. Гафу итегез инде, сезне вакытсыз борчыдык. Менә түргә рәхим итегез. (*Үз урынын бирә.*)

Гайсә. Ярый, килгәч, берничә минутымны алсагыз алырсыз.

Директор ханым. Зур рәхмәт инде, Гайсә Мөхәммәтҗанович.

Гарәфи. Катырак торыгыз сез аларга, Гайсә әфәнде... Катырак...

Гайсә. Тыңлыйм.

Сәлим. Башласыннармы, Гайсә әфәнде?

Гайсә. Башлагыз.

Режиссер. Эш менә нидә, Гайсә туган...

Сәлим. Нәрсә?

Режиссер. Гафу, Гайсә Мөхәммәтҗанович. Беләсезме, без Шекспирның «Гамлет» трагедиясен сәхнәләштермәкче булабыз. Сезнең олы ярдәмегездән башка һич тә мөмкин түгел.

Директор ханым. Сез театрыбызның иң сәләтле артисты.

Гарәфи. Безгәме инде сезгә җиту.

Директор ханым. Кем роле әле Гайсә әфәндегә, призракмы?

Сәлим. Молчать, я вас спрашиваю! Ничек җөрьәт иттең?!

Директор ханым. Гафу. Мин каян белеп бетерим инде. Мең кат гафу.

Гайсә. Прощаю.

Директор ханым. Рәхмәт.

Режиссер. Ничек инде Гайсә Мөхәммәтҗанович шәүлә булсын. Ул бары тик — Гамлет!

Бар да кул чаба, афәрин сүзләре ишетелә.

Альберт. Ур-ра, мин сезнең өчен чын күңелдән шат! Бу бит, бу бит!.. Дәрәҗә, дан, акча, канцу канцов — атказанган дигән исем! Браво!

Гөлбостан. Рөхсәт итсәгез, мондый җаваплы эшкә керешкәч, мин аның туклануын алгы планга куюыгызны сорар идем. Акчасын да арттырсагыз, кырын ятып рөлен өйрәнергә «мягкий» диван да алдырыр идем.

Директор ханым. Әлбәттә, әлбәттә.

Әнзирә. Иркәләп-назлап кына, шул диваннарда күңелләрен күреп, миннән дә олы ярдәмне кем күрсәтер, бәгъремә...

Режиссер. Кх-хм-м!

Директор ханым (*режиссерга*). Шулай кирәк. Әлбәттә, әлбәттә.

Хаҗимулла. Түбәтәеңне киеп, намазга чүк, олы эш алдыннан...

Хәсән. Чур! Тәрҗемәсен үзем ясыйм. Бер дигән җырлы комедия чыгачак. Егылып көләрләр.

Рәсүл. Ач тамагың, тыныч колагың, дускай.

Гарәфи. Син, бездарь, кысылма, яме. Без Гайсә Мөхәммәтҗанович белән үзебез дә бик беләбез ничек иҗат итәсен, име...

Сәлим. Булышыгыз, ярдәм итегез, чолгагыз.

Гайсә. Булды, җәмәгать. Моңарчы булышканыгыз өчен дә бик зур рәхмәт.

Сөмбел күренә.

Менә, менә минем бердәнбер булышчым. Ул бирде миңа бу китапны. (*Кул астына эләккән беренче әйберне алып, селтәнеп куа башлый.*) Китегез, таралыгыз, калдырыгыз мине!

Барысы да бергә. Ничек инде, туган, без сиңа ярдәм итәрбез. Ничек итеп инде син безсез яшәрсең, башка сыймый.

Режиссер. Мин булмагач, мезансценаларны бутап бетерәсең бит.

Директор ханым. Тәртипне кем карар, кем саклар?

Сәлим. Шым, җәмәгать. Чигенәбез, вакытлыча. (*Качалар.*)

Гайсә. Бу ни булды бу? Әй, юкка чыктылар. Менә могҗиза.

Сөмбел. Бу бик гади. Син курыкма гына алардан. Курыкмасаң, киртә дә калмый.

Гайсә. Димәк, мин ирекле?! (*Иркен итеп сулап куя.*)

Сөмбел. Син ирекле. Менә хәзер укысаң да була.

Гайсә. О-о, мин укыйм!

To be, or not to be,— that is the question:
Whether 'tis nobler in the mind to suffer
The slings and arrows of outrageous fortune,
Or to take arms against a sea of troubles.
And by opposing end them? — To die,— to sleep,—
No more; and by a sleep to say we end
The heart-ache, and the thousand natural shocks
That flesh is heir to,— 'tis a consummation
Devoutly to be wish'd. To die,— to sleep;—
To sleep! perchance to dream: — ay, there's the rub;
For who would bear the whips and scorns of time,
Th' oppressor's wrong, the proud man's contumely,

The pangs of disprized love, the law's delay,
The insolence of office, and the spurns
That patient merit of th' unworthy takes,
When he himself might his quietus make
With a bare bodkin?*

Качкан хезмәткәрләр аңа таба шуышалар.

Сөмбел. Саклан, Гайсә!

Сәлим. Чолгап алырга!

Директор ханым. Котылмакчы идеңме бездән?

Режиссер. Мезансценаларны, куелганны бозмый гына. Бары да үз хәлендә калырга тиеш.

Ут сүнә.
Кире элеккеге сәхнәгә кайталар.

Директор ханым. Нәрсә, мәрткә киттең мәллә?

Гайсә. Ә, нәрсә? Ә-ә, әйе, кем белеп бетергән инде...

Режиссер. Ә кем белергә тиеш соң?

Гайсә. Сез дип... Юкка чакыртмагансыздыр.

Режиссер. Ник бик кыюсыз гына?

Гайсә. Юк ла...

Режиссер. Ишеткән геройлыкларың белән чагыштырганда, син хәзер мулла мәчесе...

Гайсә. Ишеттерделәрдәмени инде...

Директор ханым. Ишеттермәсләр дип уйлаган

---

* *Шекспирның «Гамлет» трагедиясеннән.*
Яшәргәме, үләргәме,— менә нидә
Мәсьәлә. Йә кайсысы яхшырак соң:
Явыз язмыш укларына баш июме,
Әллә кулга корал тотып, бу җәфалар
Диңгезенә көрәш ачып, чик куюмы?
Үлү — йоклау. Артык һични. Барлык йөрәк
Газапларың, тәнең дучар булган мең-мең
Җәфаларың шул бер йокың белән бетте
Диеп уйлау — көтеп алган чик түгелме?
Үлү — йоклау; йоклау! — бәлки, төш күрүдер!
Шик тә шунда.
Шул булмаса, кем соң түзеп торыр иде
Замананың мыскылына, камчысына;
Башлыкларның изүенә; өстеннәрнең
Үз өстеңнән көлүенә, мәхәббәтең
Кире кагылу газабына; властьларның
Ятсызлыгы, гаделлекнең соңлавына;
Эш күрсәткән кешеләрнең җыен рәтсез
Кешеләрнең типкесендә йөрүенә;
Шул тормыштан үз-үзеңне пычак белән
Бер кадауда котылып булгач, нәрсә тота?

иденме? Сезнеңчә әйткәндә, мезансценалар бозылмый, уен төгәл бара. Ишеттерергә тиешләр дә...

Гайсә. Юк, бер сүзем дә юк...

Режиссер. Шулай итеп, мин бөтенләй бушмы?

Гайсә. Мин алай ук димәгән идем...

Директор ханым. Әллә дөрес җиткермәгәннәр димәкче буласыңмы?

Гайсә. Аллам сакласын, андый ук бәхетләр тәтемәс. Бары мин...

Режиссер (*кыза барып*). Нәрсә син?

Гайсә (*сак кына*). Җитдиерәк әсәрләр күрәсе килә дигән идем...

Директор ханым. Мескен песи. Ничек боргалый.

Режиссер. Сөйләнсен. Шулай да булсын ди. Әллә минем йөрәк авыртмый дип уйлыйсыңмы син, җыен чүпчарны куеп? Әллә минем Шекспир, Чеховны куясым килми дип уйлыйсыңмы? (*Тагын да ярсып.*) Кая ул әсәрләрне карар тамашачың? Кая алардагы интеллект?! Лыгырдарга бар да булдыра...

Гайсә. Мин...

Режиссер. Нәрсә?

Гайсә. Мин бары... Мин бары тик тамашачыны да тәрбияләргә кирәк, ни ашатсаң, шуңа ияләшә димәкче булган идем. Дөрес сөйләмәгән булсам, гафу итегез.

Директор ханым. Гафу итегез. Синеңчә, бу тамашачыны шул еллар буена режиссер әфәндең тәрбияләп бозган димәкче буласыңмы?

Гайсә. Юк ла, ничек инде мин?! Әзрәк кенә әйбәтрәк спектакльләр булса да...

Директор ханым. Ә хәзерге спектакльләр синеңчә начармы?

Гайсә. Юк та. Юк, чынлап, әйбәт тә алар. Тик гел комедия генә...

Режиссер. Ни эшлисең, тамашачыңа ыштан төшерү белән шамакайлану гына кирәк булгач. Менә нәрсә, егет, сиңа күп түздек...

Гайсә. Мин...

Директор ханым. Бүлдермә.

Режиссер. Менә шул, кадерле артист иптәш, алай бик җитди кеше булгач, үзеңә лаеклырак урын тап. Без сиңа андый бөек эшләр тәкъдим итә алмабыз, бигайбә. Әйеме, Директор ханым?

Директор ханым. Кая инде ул безгә.

Режиссер. «Блудный сын» булып сөйрәлеп йөрү бераз акыл кертә ул, телне дә тешләтә.

Гайсә (*ни кылырга белми, аптырап калып*). Зинһар...

Зинһар өчен, дим... Режиссер әфәнде... Салган баштан бит, исерелгән...

Директор ханым. Ә исерек булгач ярыймы?

Гайсә. Юк та... Алла хакына, директор ханым, премьера иде бит...

Директор ханым. Менә телеңне тыеп, авызыңны чамалап ачып сөйләшергә өйрәнгәч карарбыз, ярыймы? Ату, бездән начар кеше юк икән театрда.

Гайсә. Алай димәдем бит... Режиссер әфәнде... Зинһар өчен... Театрсыз яши алмыйм мин...

Режиссер. Татар акылы...

Гайсә. Барын да бетерәм, бернигә дә катышмыйм, зинһар, гафу итегез... Исереклек белән бит...

Режиссер. Тагын бер генә кабатланса, ю-у-ук, гайбәт кенә ишетелсә дә...

Гайсә. Ант менә, кабатланмас. Рәхмәт сезгә...

Режиссер. Йә, ни кылабыз алайса бу мәхлук белән?

Директор ханым. Акчасын кисәрбез...

Гайсә. Кисегез, кис.

Директор ханым. Фатир чиратын кичектерербез. (*Гайсә бөтенләй өнсез кала.*) Әгәр кабатланса...

Режиссер. Нигә дәшмисең?

Гайсә (*авыр гына*). Кабатланмас...

Режиссер. Ярый, бар. Соңгы шанс сиңа.

Гайсә кыйналган кеше сымак чыгып китә.

Директор ханым. Ничек этәләнә егетең...

Режиссер. Күп күрдек инде андый этәчләрне... Фуу!

Ишек шакыйлар.

Директор ханым. Кем анда тагын?

Хәсән керә.

Хәсән. Миңа сез кирәк идегез әле, режиссер әфәнде. Менә. (*Папка күрсәтә.*)

Режиссер. Әллә? Тагын язып аттыңмы? Мәкалә язуыңнан туктадың бугай инде син.

Хәсән. Анысына да өлгерәм.

Директор ханым. Менә ичмасам талант.

Режиссер. Юк, юк, минем вакыт юк әлегә, әнә башка кешегә укыт.

Хәсән. Сезнең белән әйбәт эшләп киткән идек тә, шуңа...

Режиссер. Юк, дидем. Беттеме?

Директор ханым. Ярый, ачуы чыкканда кыздырма кешене... Әйдә калдырыйк. (*Хәсәнне бүлмәдән алып чыга.*) Үзем җайлармын.

Хәсән. Нинди рәхмәтләр әйтергә дә белмим инде сезгә. Әсәр, беләсезме, бик әйбәт. Музыкаль комедия. Темасы өр-яңа. Су асты космосыннан инопланетяннар килү хакында...

Директор ханым. Ярар, ярар, укырбыз. Әйттем бит инде, булыр дип.

Хәсән. Үзе киреләнә бит әле.

Директор ханым. Кая барыр... Ә, туктале, элеккеләрен син үзең укып биргән идеңме әле?

Хәсән. Әйе.

Директор ханым. Алайса, өйгә килерсең, югалдың ату...

Хәсән. Бик рәхәтләнеп, бик куанып. Рәхмәт. (*Кулын үбә.*) Хушыгыз.

Директор ханым кереп китә.

Тфү! (*Төкерә дә иренен сөртеп куя.*) Кая барасың?.. Дөнья...

Кабинеттан Режиссер чыга, тәмәке кабыза. Үтеп баручы Әнзирәне күрә.

Режиссер. Әнзирә!

Әнзирә. Әйе...

Режиссер. Ашыгыч мәллә?..

Әнзирә. Ашыгыч дип...

Режиссер. Репетициягә иртә... Хәер, яшь кешене кем көтмәс, әйеме...

Әнзирә. Әйе, яшь кызларны кем көтмәс...

Режиссер. Син бозыла башладың әле, кызый.

Әнзирә. Кай төштән?

Режиссер. Сүз иясе белән йөрми...

Әнзирә. Тыңламагыз гайбәтне.

Режиссер. Синең белән миңа кагылгач... Тыңламый кая барасың?

Әнзирә. Ни диләр инде?

Режиссер. Хәйләләмә, яме. Минем кем икәнлекне оныта башладың бугай.

Әнзирә. Онытырсың бар...

Режиссер. Шулай булгач. Ни эшлисең син ул малай белән?

Әнзирә. Ниткән малай?

Режиссер. Йә ярый, чабата каертмый гына, яме... Нигә ул сиңа?

Ә н з и р ә. Кычкырма. Куркып яшәгән чаклар узган.

Р е ж и с с е р. Әйдә бозылышмыйк. Сиңа ничек караганымны беләсең.

Ә н з и р ә. Уф, тагын шул сүзләр.

Р е ж и с с е р. Шул булмыйча. Дөресе шул.

Ә н з и р ә. Ни эшлим мин ул дөреслек белән? Утызга җитеп барам.

Р е ж и с с е р. Шуннан?

Ә н з и р ә. Шул. Кемгә хаҗәт мин? Әйт менә, кемгә? Әллә безнең себерелгәнне белмиләр дип беләсеңме?

Р е ж и с с е р. Т-с-с-с.

Ә н з и р ә. Синнән куркып кына елмаялар, белмәгәнгә салыналар. Аларны да аңларга була. Театры шул булгач, деспотизмга корылгач, ни эшләсеннәр... Кемгә хаҗәт менә мин? Кем кияүгә ала мине? Әллә минем гаилә корасым, балалар үстерәсем килмиме? Әллә мин шуны булдыра алмаслыкмы? Әллә мин шул бәхеткә дә лаек түгелме? Ә, түгелме?!

Р е ж и с с е р. Кызма әле син! Кызма...

Ә н з и р ә. Өйләнән алай булгач менә миңа!

Р е ж и с с е р. Тукта әле, Әнзирә, дим. Тозсыз сүзләр сөйләмә әле. Мин ничә яшьтә дә, син ничәдә. Аннан бит минем хатыным, буйга җиткән балаларым барын да онытма.

Ә н з и р ә. Алай булгач, мине тикшереп, шымчылап йөрмәгез. Болай да... (*Пауза.*)

Р е ж и с с е р. Нәрсә, өйләнәм диме?

Ә н з и р ә. Ә нигә өйләнмәскә тиеш?

Р е ж и с с е р (*ярсып*). Мин синнән чынлап торып сорыйм. (*Пауза.*) Җавап бир!

Ә н з и р ә. Кычкырма, кара әле моны. Хатынымыни.

Р е ж и с с е р. Син миңа хатыннан да якынрак, беләсең. Җавап бир, дим.

Ә н з и р ә. Нигә өйләнсен ди. Үзем дә аңа әтәләнеп тормыйм әле. Бер иптәш инде шунда. Аннан... (*Елмая.*)

Р е ж и с с е р. Нәрсә, аннан?

Ә н з и р ә. Юк, болай гына... Бетерик, тик бел, мин дә болай гына яши алмыйм.

Р е ж и с с е р. Үзем табам мин сиңа әйбәт кияүне...

Ә н з и р ә. Кит әле... Каян чыга әле мондый изгелекләр.

Р е ж и с с е р. Андый өтеген дә түгел. Перспективалысын, яшен, булдыклысын.

Ә н з и р ә. Кемне тагын?

Р е ж и с с е р. Ансы минем эш.

Ә н з и р ә. Бик исләре китәр.

Р е ж и с с е р. Ә нигә? (*Аны кочып.*) Товар әлегә нича-

ва, чибәрлек бар, фигура во! Тик кара аны, акыллы булсаң гына... Кияүгә чыктым дип, мине онытсаң инде...

Әнзирә. Билен сындырма... Карарбыз. (*Китә.*)

Режиссер. Карарбыз. (*Икенче якка чыгып китә.*)

Директор кабинетына Сәлим керә. Ул үзен бик гади, тыныч тота. Тик шул ук вакытта аның, төбәп карамый гына, бөтен тирә-якны нык күздә тотканы чагыла.

Сәлим. Кеше бармы?

Директор ханым. Ә-ә, Сәлим, рәхим ит, утыр.

Сәлим (*баскан көе*). Утырып ук торып булмас.

Директор ханым. Әйе, тыңлыйм.

Сәлим. Син тыңламыйсың, ә мин тыңлыйм.

Директор ханым. Гафу ит, эш белән мавыгып.

Сәлим. Эш белән? Әкият сатмагыз! Кая эшегез?

Директор ханым. Мин...

Сәлим. Монда мин сөйли идем бугай. Әллә инде мине берни белми йөри дип уйлыйсызмы шунда?.. Нигә менә мин монда? Завхоз булу өченме?

Директор ханым (*пышылдап*). Ю-у-у-ук.

Сәлим. Шулай булгач... кыланышларыгыз буенча, ай, ялгышасыз, ялгышасыз, хөрмәтле директор. Сезгә күпне җиткерсәләр, безгә тагын да...

Директор ханым. Минем...

Сәлим. Шым... Тыңларга гына кирәк, аңлашыламы?

Директор ханым. Әйе.

Сәлим. Менә шулай: тәртип аксый, режим йомшара... Бәлки, миңа кирәкле җиргә шалтыратып карарга микән?..

Директор ханым. Туктагыз инде...

Сәлим. Бер режиссерны бөгә алмау, ул инде... Безгә, безгә хезмәт итәргә тиеш алар барсы да, аңлашыламы? Ә теге малай тотрыксыз, аны күптән очырырга дип әйткән идемме? Әгәр дә...

Директор ханым. Аңладым, бар да үз урынында булыр.

Сәлим. Бусы бетсен ди. Берсекөнгә миңа тулы отчет белән керерсең.

Директор ханым. Есть!

Сәлим. Ну, мин инде шалтыратмый торам. (*Чыгып китә.*)

Директор ханым. Рәхмәт инде сиңа. Барын да җайлармын... У-ф!

Ут сүнә.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Пәрдә ачылганда уң якта урнашкан Р ә с ү л г ә ут яктысы төшә.

Р ә с ү л. Ә беләсеңме, бүгенге көн сәнгатенең төп кимчелеге нәрсәдә? Сәнгать — тупикта. Кризиста. Н.Бердяев әйтмешли, «Кризис искусства». Без хәзер, мөгаен, төп мәгънәне, ягъни абсолютка омтылган тирәнлекне вакыйга линиясе буенча, сюжет буенча гына сөйрәргә тиеш түгелдер, ә бәлки, матдәгә, материягә трансмутататация хәлен ачып, материя аша үтәли үтә торган, барлыкны юк итеп, ә булмаганны, ягъни без юк дип уйлаган, әмма шулай да ничектер тоемлаган, сиземләгән чынбарлыкны, бәлки, безнең реаль дип уйлаган барлыктан да реальрәк булган чынбарлыкны ярып бирергә тырышу, үтәли үтү, җанны ачу эшенә тотынырга тиешбездер. Кыскасы,— быть или не быть?! Не быть, значит быть, быть бәлки, небытьтыр...

Ут сүнә.
Г а й с ә бүлмәсе яктыра. Ул бүләккә килгән китапны укый. Йөренә.

Г а й с ә. Яшәргәме, әллә үләргәме. Менә сорау нәрсәдә? (*Ишектә звонок.*) Керегез, кер, ишек ачык.

С ө м б е л керә.

С ө м б е л. Исәнмесез.

Г а й с ә. Үтегез, үт, мин сезне көттем.

С ө м б е л. Үтсәм дә инде...

Г а й с ә. Курыкмагыз, монда беркем дә юк... Бетте ул эшләр.

С ө м б е л. Чынлапмы?

Г а й с ә. Валлаһи менә. Туйдым.

С ө м б е л. Рәхмәт. Мине, зинһар өчен, бәйләнеп йөри бу дип уйлый күрмәгез, минем үземә дә уңайсыз...

Г а й с ә. Сез нәрсә инде... (*Пауза.*) Ә-ә, әйе, менә сезнең бүләкне укып йөри идем әле.

С ө м б е л. Ошыймы?

Г а й с ә. Бик. Дөрес, элек тә мин ул әсәрне яратып укый идем.

С ө м б е л. Шуны сәхнәгә куйса иделәр, име.

Г а й с ә. Ни сөйлисез сез...

С ө м б е л. Нигә?

Г а й с ә. Кем куйсын инде аны? Хәзер бит әнә Хәсәннәр заманасы... Кемгә хаҗәт ул хәзер? Замана...

С ө м б е л. Сезгә һәм... миңа...

Г а й с ә (*көлемсерәп*). Сезгә һәм миңа...

С ө м б е л. Һәм башка бик күпләргәдер... Дөнья өчен, әй лә, театр өчен чын-чынлап борчылган кешеләр аздыр дисезме?

Г а й с ә. Кем белә... Кем белә, Сөмбел... Күңел үзе бик җилкенә дә, җитди, йөрәк түреннән ташып чыккан әсәрләр тудырасы килә дә бит...

С ө м б е л. Берәрсе алынса икән, әйеме...

Г а й с ә. Булмас...

С ө м б е л. Дөнья болай гына бармас бит әле... Шекспир заманында кирәк булгач, бәлки, тагын берәр кирәк заманы җитәр...

Г а й с ә. Ай-һай, белмим... Ул заманга чаклы без яши алырбыз микән? Их Сөмбел, менә бүген, хәзер иҗат итәсе килә шул ул... булмый...

С ө м б е л. Алай өметне өзмәгез әле сез... Безнең дә хыяллар бар бит...

Г а й с ә. Мин сине актерлыкка укыйсың дип уйламадым да...

С ө м б е л. Мин яңарак кына әле...

Г а й с ә. Һәм ничек?.. Карап туймаслык...

С ө м б е л. Кирәкми андый сүзләр, яме... Алары бит иң мөһиме түгел, әйеме...

Г а й с ә. Барыбер, әйтеп бетерәм. Син минем янда булганда, миңа бик ни... рәхәт... Күңел тыныч... Бөтенесе дә әйбәт булып күренә башлый. Ярсып эшлисе, иҗат итәсе килә башлый... Кызык инде, әйеме?

С ө м б е л. Әйе. Мин килермен, әгәр...

Г а й с ә. Нәрсә, әгәр?

С ө м б е л. Килергә уңай мөмкинлекләр күбәйгән саен, мин дә ешрак килермен. Син ачуланма инде, яме...

Г а й с ә. Мөмкинлекләр азракмы? Вакытың юкмы?

С ө м б е л. Юк, аннан түгел. Беләсезме, ни, әнә теге апа булганда миңа әллә ничек уңайсыз...

Г а й с ә. Ант менә, ул бүтән килмәс...

С ө м б е л. Кирәкми, ант итмәгез, алдашмагыз, яхшы түгел. Килгәләр инде ул әлегә, нишлисең...

Г а й с ә. Гафу ит, мин киметермен, тырышырмын...

С ө м б е л. Аннан...

Г а й с ә. Әйе?!

С ө м б е л. Эчүегезне бетерә алсагыз иде сез. Сезгә бер дә килешми.

Г а й с ә. Эх Сөмбел! Эчәсем килми лә аны минем үземнең дә. Менә, аңлыйсыңмы, түзә алмыйм мин, чыдамым җитми! Шушы ялганга, шушы пычраклыкка, шушы формаль сәнгатькә! Түземем җитми дә ычкынам. Мин тырышырмын, мин киметермен, син китмә генә, яме,

Сөмбел. Зинһар, ялгыз калдырма мине! Минем бит монда беркемем дә юк! Бар да үз ягына гына тарта...

Сөмбел. Ышанам, ышанам мин сиңа, Гайсә. Ләкин син дә аңла, мин сине ялгыз калдырмаска бик телим дә, әмма ул гадәтләреӊ барында миңа синеӊ янда булу бик тә кыен, аңла, зинһар өчен...

Гайсә. Аңлыйм, Сөмбел, ышан, мин бөтен көчемне куярмын. Менә, менә, Сөмбел, мин бу пьесаны, беркем куярга теләмәсә дә, үзлегемнән өйрәнергә булдым. Ничек булдырсам, шулай башкарырмын. Мин тиеш! Тиеш бит, әйеме?

Сөмбел. Тиеш кенә түгел, син аны булдыра да аласың, Гайсә! Ышан үз-үзеңә. Сиңа бирелгән, Ходай Тәгаләдән зурлап бирелгән, югалтма гына. Мин сине шуңа, шул олуг сыйфатыӊ булганга ошаттым да инде. Аңла, җанашым, күктән иңгән ул сыйфатың калыкканда, бөтен бу кимчелекләр бөтенләе белән күмелеп кала. Ул чагында синнән дә матур, синнән дә акыллы, синнән дә горур, ягымлы адәми зат юк! Гел шулай булырга тырыш!

Гайсә. Булды гына, Сөмбелем! Син миңа ышан гына! Барына да барам, бөтенесен дә җиңәрмен, тик син генә кыйбламда якты йолдыз булып ян!..

Сөмбел. Янармын, Гайсә. Тик бел: бар да үзеңнән генә тора! Син җиңә алсаң, мин ташламам.

Ут сүнә. Ут кабынганда, Сөмбел белән Рәсүлне яктырта. Алар бернәрсәгә бәйле булмаган нindидер җирлектә торалар.

Рәсүл. Син ничек биредә?

Сөмбел. Гайсә абыйны күрергә килгән идем.

Рәсүл. Ә-ә...

Сөмбел. Нигә гаҗәпләнмәдең?

Рәсүл. Ишеткән идем, сине бик ошаткан дип.

Сөмбел. Хупламыйсыңмы?

Рәсүл. Нигә? Начар егет түгел ул үзе түгелен... Үзеңә ошагач...

Сөмбел. Аллага тапшырдык инде. Рәсүл абый, син дә сөйләшеп карасаң иде аның белән.

Рәсүл. Һе.

Сөмбел. Нигә?

Рәсүл. Әйтергә ансат, сөйләшеп кара. Мине бит монда беркем дә тулы акыллыга санамый...

Сөмбел. Анысы кагыйдә буларак... Шулай да...

Рәсүл. Белмим шул. Ул — егет, үз акылы үзендә дигәндәй...

Сөмбел. Барыбер, абый, бәлки? Тырышып кара инде, яме...

Р ә с ү л. Яхшы. Әгәр барып чыкса...

Ут сүнә. Ут яңадан грим бүлмәсен яктырта. Анда Г а й с ә белән Р ә с ү л утыра. Өстәлдә азрак шәрабы калган шешә тора. Гайсә бераз кызган.

Г а й с ә. Син бу исерек ник миңа бәйләнде дип борчылма. Бәйләнмим мин, сөйләшәсе килә минем.

Р ә с ү л. Сөйләшик соң.

Г а й с ә. Көлеп карамыйсың, димәк?

Р ә с ү л. Нигә көлим. Көләрлек берни дә юк.

Г а й с ә (*эчеп куеп*). У-у-ух. Китте. Менә әйт алайса миңа... Синеңчә актер кем ул?

Р ә с ү л. Кем дип... Тукта әле, син кисәк кенә, шундый олы темага...

Г а й с ә. Ю-у-ук, син боргалама. Көлмисең икән, сөйләш. Тик, тик... чын күңелдән булсын...

Р ә с ү л. Актер ул... Творец, иҗат итүче, шулаймы?

Г а й с ә. Шулай да булсын ди...

Р ә с ү л. Ничек инде булсын, бары шулай гына булырга тиеш. Алай булмаганга күрә, шундый спектакльләр дә инде бездә...

Г а й с ә. Актердан гына торса иде дә...

Р ә с ү л. Дөрес. Күбрәк куючыдан диик. Ләкин, ләкин бит без үзебез дә риза булып, авызыбызны салындырып, тиле кебек сикерешеп йөрибез.

Г а й с ә. Һе, риза булмый кала.

Р ә с ү л. Ә гомер? Гомер бит үтеп китә. Ай, тиз үтә ул.

Г а й с ә (*уфтанып*). Тиз үтә, ай, тиз үтә...

Р ә с ү л. Тукта әле, син нигә гел мине генә җөпләп утырасың?

Г а й с ә. Ашыкма. Сөйләвеңне бел. Әле башладың гына. Мин, бәлки, гүпчем синең позицияң белән риза түгелдер...

Р ә с ү л. Нидә туктадың әле?

Г а й с ә. Творецта. Мә, тот әле.

Р ә с ү л (*елмаеп*). Әйттем бит инде, мин ни гу-гу...

Г а й с ә. Әй син дә...

Р ә с ү л. Ярый, әйдә читкә китмик. Менә әйт әле, творец, ягъни иҗат итүче кем ул?

Г а й с ә. Творецмы? Йә әйтеп кара әле? Соң?

Р ә с ү л. Минемчә, творец — димәк, творить итүче, иң бөек дәрәҗә. Аннан да олы бөеклекнең булуы мөмкин түгел. Дәрәҗәле урын турында хыялланучы кешеләр бик нык ялгышалар. Ә бәлки, киләчәктә алар да нәкъ менә иҗатка борылырлар. Мөгаен, творчестводан, чын иҗат итүдән дә олуг дәрәҗә булмастыр. Ә бәлки, дәрәҗә яраткан кешеләрнең моны аңламаулары яхшырактыр да әле.

Чөнки иҗат итәсе килгән кешеләргә, әйтик, чын йөрәктән иҗат итәсе килгәннәргә комачаулый алмыйлар.

Г а й с ә. Нигә дип әле син гел творчество сүзен кыстырасың, иҗат кына димисең?

Р ә с ү л. Ә-ә, әйе, кызык сорау. Мин дә уйладым аны. Беләсеңме, иҗат итү сүзе ничектер ул мәгънәне биреп бетерми кебек. Ә творить итү, тудыру мәгънәсенә якын килеп бетә яза.

Г а й с ә. Син читкә китмисеңме, апаем?

Р ә с ү л. Юк, юк. (*Пауза.*) Хәер, бу теманы тыңлау ялыктыргыч инде ул. Күңеллерәк вакыйгалар, темпераментлырак темалар ишетәсе килә, әйеме?

Г а й с ә. Син сөйлә, сөйлә, сөйләвеңне бел. Акыл сатып күрсәтәсең килгәч, әгәр үзеңнән кемнедер ясыйсың икән...

Р ә с ү л. Ярый, ничек уйласаң да, уйла, миннән калмасын. Калганын вакыт күрсәтер.

Г а й с ә. Әйе, калганы минем эш.

Р ә с ү л. Дөрес, иҗат кешеләре арасында да иҗат итмәүчеләр бар.

Г а й с ә. Иҗат итүчесе син, ә иҗат итмәүчесе безме?

Р ә с ү л. Йә инде...

Г а й с ә. Бетте, бетте, май каптым.

Р ә с ү л. Сезме, синме, гомумән, тәгаен беркем дә димәдем бит әле. Игътибар беләнрәк карасаң, үзең дә күрәсең син аны. Мин үземне, гомумән, иҗат итәмнәр арасына әлегә кертә алмыйм.

Г а й с ә. Иҗат итә башлаганчы, пенсиягә чыгып китсәң?

Р ә с ү л. Шул шул менә. Без ничек карыйбыз: ялтыравыклы формаларга чорналган булса, җыр, бию, уен һәм башка. Һәм болар барсы да тамашалы булып, эчендә ниндидер шайтан да уйнап торса,— менә нинди яңалык; үзебез дә шаккаттык, халык та дивана кебек үлеп карый. Бүтән иҗат тармакларында да: язу, музыка, рәссамлыкта да шул ук хәл кабатлана. Бер үк формадан икенче формага ниндидер пүчтәк идеяләрне переливать итәләр. Ә бит үзәге шул ук кала. Литр суны кайсы, нинди формадагы савытка салсаң да, шул ук су булып кала. Билгеле, матур вазада матуррак күренә. Ләкин бит, матур ваза — бары ваза гына, ә башка сыекча түгел. Ә су шәрабка әйләнми.

Г а й с ә. Т-р-р, дускай, туктап тор. Дөрес әйттең, шәрабка әйләнми. Мин салып алыйм әле, бер формадан икенчесенә. (*Салып эчә.*) Сүлә.

Р ә с ү л. Без, шул, күп вакыт тышкы формага, ялты-

равыкка, матур вазага алданып, бу, шул ук булган суны шундый матур булды дип уйлыйбыз. Аңа сокланабыз, тел шартлатабыз. Ә бу — бары тик форма гына, иллюзия, мираж! Чын матурлыкны бары тик шул вазаны җәлләмичә, ватып яисә ватмыйча гына таркатып торып, үтәли пространство һәм вакыт аша үтеп, иң бөек булган тирәнлеккә, мәгънәгә барып җитеп, шуның аша эш кылганда гына чын иҗат барлыкка килә торгандыр.

Гайсә. Тукта, тукта, туктап тор әле син, иптәш, товарищ. (*Очкылык тотып алып.*) Нигә соң син алай булгач, болай күп белгәч, безнең вак формаларга исең китмәгәч, эшләп тә күрсәтмисең? Чиле-пешле актер булып йөрисең? Нигә шулай ук итеп, хакыйкатьне эзләгәндәй үк даһи актер мәгънәсенең төбенә төшеп, галәмәт зур артист булып йөрмисең? Ә?

Рәсүл. Нидән гыйбарәт соң ул синең даһилыгың?

Гайсә. Нидән дип, соң, менә танылган артист диик инде...

Рәсүл. Әгәр дә ул даһилык, ягъни әйтик, бик әйбәт артист дигәнебез, шушы без күзаллаган чынбарлыкка туган дөньяда, яшәеш формасында, бу форманың һәм материянең төрлелегенә, чуар буяуларын болгатуга хезмәт итеп, күпкырлап һәм болгандырып бер үк вакыйганы төрлечә коя икән, хәтта, әйтергә кирәк, ул бу эштә җитез һәм булдыклы, өстәвенә сөйкемле һәм кызыклы да икән, тик, әйе, әмма шул форма һәм материянең тирәнлегенә, беренчел төп сәбәбенә омтылмый икән, ә бары тик яңадан, көзгедәге чагылыш сыман, бер нәрсәне төрле төстә чагылдырып торуга кала икән, минемчә, бу чагылдыру буштан сайга алмашыну гына. Һәм сезнең бөек критикларыгыз шушы чагылдыруны, болгатуны даһилык дип кабул итәләр икән... Ярый, ярый, әйтик, кәсепченең осталыгы диик. Тик бу вакытлыча гына булачак.

Гайсә. Ягъни?

Рәсүл. Ягъни югары мастерлык критерийлары шул чүп чагылдыру, болгату белән генә чикләнгәндә... Аңлашыладыр бит?

Гайсә. Әйе. Ярар, сөйлә әйдә, ул кадәр (*тамагына чиртеп*) дигәч тә...

Рәсүл. Шул, бу чагылдыру урынына матдәнең үзлегенә, үзәгенә үтеп керү теләге, омтылышы туганга кадәр, ягъни, әйтик, исемнең, тереклекнең төзелешен, чын мәгънәсен аңларга теләк туганга кадәр, сәнгатьне иллюзияле бәяләү как таковой, һәм дөньяга, яшәешкә ялгыш бәя бирү дәвам итәчәк. Принципта, әгәр дә мин бик тырышып үз рухымны кысрыклап, көчләп, ягъни югары

хисләрне кытыршы формага кысалап, ягъни обособленный материягә, үземне шушы кысан формаларда чагылдыра алыр идем... Тик... нигә болар барсы да?..

Г а й с ә. Шулай бара бит инде... нишлисең.

Р ә с ү л. Без күник, шулай барсынмы?

Г а й с ә. Димәк, син үзеңне өстенрәк саныйсың? Югары куясың?

Р ә с ү л. Юк, син дөрес аңламадың. Минме яисә синме, теләсәк тә, үзебезне югары йә түбән куя алмыйбыз. Йә ярый, бусы бик тирән мәсьәлә. Бары тик минем төп хакыйкатьне генә аңлыйсым килә. Гомумән, барча җан иясенең дә төп шөгыле хакыйкатьне аңлауга омтылган булырга тиештер. Әгәр дә мин үзем дә шул нәрсәләрне аңлый алмыйм, тоймыйм, яисә аңларга да омтылмыйм икән, димәк, минем уен да сәхнәдә бушны бушка аударуга кайтып кала. Димәк, тамашачыга да безнең уен буш эш булып, ягъни ул да хакыйкатьне аңламаганда, үзе ялгышканда гына безнең «ялгыш» уен кирәк. Кем әйтмешли, вакытлыча гына. Ә бу «ялгыш» уенда мастер булу үзе үк ялгыш түгел микән?

Г а й с ә. Әйдә, әйдә, син алай «бөек» икәнсең, аңлат инде мин аңгырага, извольте. (*Пауза.*)

Р ә с ү л. Син алай усалланма әле, кирәкми, яме?.. Туйдырмадымыни әле шул юк-бар, бер-беребезгә төрттереп сөйләшү...

Г а й с ә. Ну инде, без бәләкәй кеше.

Р ә с ү л. Йә, йә, җитте, яме. Әйдә, гади генә булырга тырышып карыйк. Күреп торасың, өстен кую уемда да юк, кирәкми дә ул эшләр. Уйлавымча, алай кылану — иң зур бушлык, буш куыклык. Болар бары минем уйланулар гына. Рәхәтләнеп кабул итмәскә була. Әллә мин китимме?

Г а й с ә. Йә, бетте, бетте, йоттым телемне. Ну, шаярды дип уйла. Миңа ничектер сине тыңлавы җиңел әле, күңелле үк дисәм дә...

Р ә с ү л (*елмаеп куя. Ул бу халәтнең сәбәпләрен белә, бик белә кебек*). Менә шул...

Г а й с ә. Ник елмаясың...

Р ә с ү л. Болай гына. Анысы тагын да озынрак тарих.

Г а й с ә. У-у, юк, ул чагында кирәкми, елмай, чурт с ним.

Р ә с ү л. Шул менә, минемчә, чын иҗат барлыкка килсен өчен, формалардан башламыйча, киресенчә, иң югарыдан башларга кирәктер.

Г а й с ә. Пер-реведи.

Р ә с ү л. Ягъни Творец кем дигән сорауны тагын да

кабатласак, иң бөек Творецның иң югарыда икәнлеген, һәм аның дин теле белән әйткәндә, Аллаһы Тәгалә, философлар теленә күчсәк — абсолют, ягъни бөтен берләштерерлекне һәм берләштермәслекне дә берләштерүче, иң беренче, мәңгелек, беркайчан да бетмәүче, әйеме?

Г а й с ә. Әйе дә булсын ди...

Р ә с ү л. Димичә кая барасың.

Г а й с ә. И шуннан?

Р ә с ү л. Шуннан... шул, шул... Килеп чыга. Чынлап торып, бөтен дөньяны онытып тотынганда иҗат итү — югарыга якынаю булып чыгамы? Бу дөнья иҗат юлы белән яратылган. Библиядә Бог сотворил, диелгән. Сотворчествоның тамыры — творить, әйеме. Сотворчество — димәк, мөгаен, алдында Со — булгач, ниндидер иярченнәре, ярдәмчеләре белән Со-творил. Моннан үзеннән-үзе творчествоның иң бөек, иң олы дәрәҗә дигән гипотеза килеп чыга. Чөнки Аллаһы Тәгаләнең төп эше, яраткан эше — шул булган. Ярату дигәннән, безнеңчә, Коръәнчә — дөньяны яраткан була. Ярату сүзеннән, әйеме? Димәк, иҗат ул?..

Г а й с ә. Ярату...

Р ә с ү л. Дөрес... Биек баскычтагы ярату белән яралу, яратылу. Күпме биек булса, шулкадәр яхшырак. Шулай булгач, мондый дәрәҗәле эшкә тотыну безгә бик зур бурычлар йөкли. Хәер, творчество бездә генә түгел, гомумән, бөтен хезмәттәдәдер. Чөнки һәркем үзенчә омтылып иҗат итә ала. Хәтта балалар да уйнаганда онытылып әллә ниткән дөньялар әвәләп ташлыйлар. Моннан нинди рюземе, акциома килеп чыга инде?

Г а й с ә. Нинди дип... Нинди?

Р ә с ү л. Минемчә, кешенең эше генә түгел, бөтен гомере дә иҗат булырга тиеш. Безнең һәр сулышыбыз, һәр адымыбыз, йә иҗат була, йә...

Г а й с ә. Йә...

Р ә с ү л. Булмый каладыр инде. Мөгаен, безнең һәр сулышыбыз саен уңга да, сулга да авышмыйча, иҗат итеп, бары илаһи иҗат итеп алга үтә алуыбыз, шул сират күпере буйлап, миллиметрлап шуышуыбыздыр.

Г а й с ә. Тр-ру, туктап торыйк әле. Кызык, кызык. Син менә хәзер башка хезмәтләр дидең, әйеме?

Р ә с ү л. Әйе.

Г а й с ә. Ә менә син бакча мәсьәләсенә ничек карыйсың?

Р ә с ү л. Ниткән бакча?

Г а й с ә. Ник, бар бит инде бездә бакчалар, ягъни огородлар.

Р ә с ү л. Ә-ә, алар. Минемчә, әйбәт.

Г а й с ә. Ничек инде әйбәт?

Р ә с ү л. Дөрес, бөек профессионал, иҗат белән генә шөгыльләнергә тиеш. Ләкин бит аның бездә, тагын дип әйтик, бик күп ләкиннәре туа. Ләкин, мәсәлән, актерга гел тартырга йөк юк, ләкин тормышында бушлык бар һ.б.лар. Әлбәттә, күп нәрсәләр шәхеснең үзеннән тора. Ләкин... ләкин шул. Ә бакча мәсьәләсендә... Әгәр дә ул шәхескә профессионал гына түгел, ә бәлки, дөньяви күзаллавын күтәрү, шәхеснең интеллектуаль һәм рухи үсешенә, нечкәрүенә этәреш булып тора икән, хәтта бик кирәк дип саныйм...

Г а й с ә. Тормый бугай шул...

Р ә с ү л. Нәрсә тормый?

Г а й с ә. Этәреш булып.

Р ә с ү л. Шулай да күпмедер кешегә кирәкле эштер, дип уйлыйм. Дөнья бик чуар халыктан торган кебек, театрлар да бик чуар. Шулай да, минемчә, безгә бүтән туфрак бирелгән. Ничек диим: психология, рух өлкәсендә диимме... Дөрес, бакчаны эшкәртеп, матур уңыш, гөлләр үстерү дә бик лаеклы эш. Ләкин... Ләкин дип әйтик, әгәр дә безгә кыенрак, катлаулырак һәм җаваплырак туфракны эшкәртергә тапшырылган икән, тапшырылмаган очракта да, үзебез сайлап алганбыз икән шул шөгыльне, димәк, лаеклы рәвештә, кәмит алабутасы гына үстермичә, ә тирәнрәк, матуррак уңыш җыеп алырга тырышырга тиешле...

Г а й с ә. Да-а-а, мат-тур сөйлисең. Йә, йә... әйе, кайвакытта, бер уйласаң, кешенең буш вакыты күп кала. Ул ни эшләргә тиеш?.. Җир эшкәртү ул очракта, әйтик, сирәк очракта кемгәдер әйбәттер дә...

Р ә с ү л. Тик актерга микән? Уйны кая юнәлтсәң, шуннан уңыш аласыңдыр, әйеме?

Г а й с ә. Әйе дә булсын ди.

Р ә с ү л. Димәк, безнең бөтен уебыз җир эшкәртү белән тулган, тулмаса да, бөтен барлыгыбыз, хәрәкәтебез шуңа юнәлтелгән: ничек эшкәртергә, җиһазлар юнәлтергә, ә, әйе, акчасы... Димәк, тагын шул мескен башка проблемалар. Бу тагын бер иллюзия булып чыга түгелме? Үзенең һәм яшәешнең төп мәгънәсен анализлап, аңларга тырышырга багышланырга тиешле гомернең төп юлыннан, шул вак алданулар белән читкә каерылуы түгелме? Дөрес, хезмәт һәрвакытта яхшы әйбер. Ләкин әгәр син бүтән, нечкәрәк туфракта казынырга лаек яисә тиеш икән... Әллә юкмы?

Г а й с ә. Кем белә...

Р ә с ү л. Аннан бу сорау җиргә генә кайтып калмый. Без җиргә, бакча участогына диик, артыграк кагылып киттек. Бу бары тик хәзер безнең сөйләшү алдында бөтен иллюзияләрнең җыелма образы формасын алды, шуңа гына аңа артык бәйләндек дип уйлыйм.

Г а й с ә. Йә ярый, без анда кортлар. Ә үзең?

Р ә с ү л. Нәрсә мин? Минем үземчә казып карый алганым юк бит әле. Бәлки...

Г а й с ә. Үлгәнче булмас ул, бәлки...

Р ә с ү л. Бәлки. Адәмне барыбер өмет яшәтә. Ә бәлки...

Г а й с ә. Ә бәлки? Бәлки шул. Бәлки — яшәргәме, ә бәлки — үләргәме? Менә сорау нәмәдә! Ә бәлки, алай куела торган спектакльләр белән килешә алмагач, үзеңнең аерым карашың, оригиналь уйларың булгач, минемчә, синең үзеңә спектакльләр куеп карарга кирәктер?

Р ә с ү л. Һе... Синеңчә режиссура нәрсә ул?

Г а й с ә. Режиссура?

Р ә с ү л. Әйе. Режиссура, ул — профессия.

Г а й с ә. Ансы шулай.

Р ә с ү л. Шулай да, минем уйлавымча, һәркем үз профессиясе белән җиренә җиткереп шөгыльләнергә тиеш. Төбенә кадәр төшеп. Профессионально.

Г а й с ә. Ә-ә, үзең күреп торасың, ул эш бит бик сирәк килеп чыга. Шуңа күрә дә...

Р ә с ү л. Шуңасын шуңа, аннары үзеңне бөтенләй ак карга итеп калдырып, беркая да якын җибәрми башласалар...

Г а й с ә. Э-э, куркасың... Менә мине дә курку тота шул. Минем дә, синеке сымак ук булмаса да, әллә ниткән уйлар бар да бит... Куркыта. Роль бирмәсләр, торак урын булмас, театрдан ук куарлар һ.б. шуның ише кебекләр шүрләтә. Шулай да...

Р ә с ү л. Кем белә... Бәлки... Тик мин барыбер һәр эштә профессионал булырга тиеш, дип уйлыйм.

Г а й с ә. Ә нәрсә? Бит күпкырлы профессионаллар булган. Лионардо до Винчи кебекләрне исеңә төшер. Соң шул ук безнең Тинчурин.

Р ә с ү л. Бик мөмкин, бик мөмкин. Иң кыены — үзүзеңне ышандыру шул.

Г а й с ә. Йә, сөйләмә әле юкны. Әле ничектер мине дә кыстаган иделәр.

Р ә с ү л. Сине кыстарга тиешләр дә.

Г а й с ә. Нигә?

Р ә с ү л. Син шул «система» кылларын бик тырышып кылтыраткан һәм бик алга киткән шәхес.

Г а й с ә. Көлмә.

Р ә с ү л. Көлмим. Шулай икәнен хәзер үзең дә күрәсең. Шуңа сиңа ышаныч та зуррак. Системаны җимертмичә генә «лаеклы» спектакль куячагыңа ышаналар. Бу дөрес тә. Ә миңа, системага эшләп күрсәтмәгән мәхлукка, ничек итеп шундый «кадерле» иллюзия җимешен тапшырып боздырырга була?

Г а й с ә. Ә язгалап?

Р ә с ү л. Аз-маз.

Г а й с ә. Ник дөньяга чыгармыйсың? Беркем белми, понимаешь...

Р ә с ү л. Кит инде, бөтен кирәкмәгән җиргә кысылып йөрергә. Мин бит болай гына, үзем өчен...

Г а й с ә. Шулай да, ә бәлки?

Р ә с ү л. Бәлки, бәлки шул. Туктале (*көлеп*), син миннән болай итеп режиссер да, каләм корты да ясап бетерәсең.

Г а й с ә. Юк ла. Бары сине тыңлап-тыңлап тордым да, күңелгә, язучыдан да, режиссердан да, актердан да өстенрәк торган профессия бардыр кебек тоелып китте. Шул профессиягә якынайсаң — бу өч шөгыльне генә түгел, башкаларын да уңышлы гына башкарып булмыймы икән дигән уй керде. Әлбәттә, билгеле бер өлешчә кәсепне дә белгәндә...

Р ә с ү л. Бәлки, бәлки... (*Ул бу сөйләшүгә шат кебек. Нидер әйтмәкче була, ләкин әйтеп бетерми.*) Сиңа гәпләшү килешә икән...

Г а й с ә. Нигә?

Р ә с ү л. Үзгәреп киттең, җанланып.

Г а й с ә. Айнып диген. Әй, бардыр инде. Төрле чак була. Кайчак юк-бар сөйләшү ярсыта гына, кайчак...

Р ә с ү л. Сугыштыра дамы?

Г а й с ә. Син дә беләсеңмени?

Р ә с ү л. Азрак. Театрда эшлим бугай.

Г а й с ә. Булды инде... Үзем гаепле.

Р ә с ү л. Кем белә.

Г а й с ә. Туктале, тукта, кергән уемны чуалтма. (*Ул ничектер очынып, яктырып китә.*) Менә, менә, хәзер... Ә, әйе, менә әйтик пианист яисә виолончелист, булмаса, скрипач ди, әйеме...

Р ә с ү л. Соң?

Г а й с ә. Менә алар ниндидер бер танылу ноктасына җиткәндә, ә юк, танылу димик, бу тагын күңел кабул итми торган дәрәҗә соравына китереп тери. Әйтик, аның күңелендә, ягъни музыкантның, ул мөмкинлек салынган була. Бары тик без, кешеләр, ярый, ярый, шулай да булсын, белгечләр, аның мөмкинлекләрен көчләп, шы-

тып, асфальтны җимертеп чыккан яшел үсенте сымак, тишеп, бәреп чыкмыйча күрмиләр. Хәтта күрергә дә теләмиләр диик, әйе, әйе, елмайма, бу нәкъ шулай... Хәзер, хәзер... Мине туктатма гына... әйе, мөмкинлеге бәреп чыккач, то есть ул элек тә бар иде инде, аңлыйсыңдыр...

Р ә с ү л. Аңлыйм, аңлыйм...

Г а й с ә. Менә шуннан соң ул тыныч кына зур оркестрның дирижеры да була, инструментында да уйный, хәтта яхшы, гаҗәеп әсәрләр дә иҗат итә ала.

Р ә с ү л. Билгеле. Йә, шуннан?

Г а й с ә. Белмисеңме? Ник гел елмаясың...

Р ә с ү л. Белмим билгеле. Син сөйләгәнне, мин ничек белим...

Г а й с ә. Йә, йә, котыртма. Мин белгәнне син киптереп элгән. Ярар, әйдә... әйтеп бетерим әле...

Р ә с ү л. Билгеле, әйтеп бетер. Син начарлыкны уеңа да кертмә. Мин кызыксынып тыңлыйм.

Г а й с ә. Ышанам. Менә шул: әгәр музыкантларның иҗатында ниндидер югары бәйләнеш бар икән... Татарчасы ничек әле, вәт әй, шайтан алгыры...

Р ә с ү л. Ярый ла, анысы мөһим түгел, иң мөһиме — уең, фикерең...

Г а й с ә. Ансы шулай, шулаен да... Ничек әле... Йә ярый, шулай булып торсын әлегә... Димәк, безнең иҗатта да, музыка хәтле үк димәсәк тә, ниндидер музыкасы, югары ноктасы бар. Шуңа килеп терәлгән шәхес тә шулай ук музыкант шикелле берничә безнең шөгыльне бергә берләштереп башкара алырга тиештер. Ничектер ул философ булыпмы, дөньяны ниндидер берләштергән ноктадан күзәтепме, һәр шөгыльгә үз ачкычын таба алып, кешеләргә олы сүз әйтә ала һәм әйттерә алыр кебек. Әллә мин ялгышаммы? Әллә ниләр тыкылдап ташладым бугай...

Р ә с ү л. Нәрсә инде син? Дөрес, бик тә дөрес... Аларда нота булса, бездә сүз. Димәк, без сүзнең тирәнлеген аңлап, аннан да бигрәк югары нота — сүз өстеннән хакимлек итеп торган уйны аңлый, укый белергә тиешбез. Югары фикерләүгә ирешә алсак иде театр сәнгатендә.

Г а й с ә. Ф-ф-у-у. (*Башын чайкап куя, бераз шәраб йота.*) Бусы ярар, шулай да ди. Син үпкәли күрмә, мин чын күңелдән... Юкмы? А ту безнең халык бик тиз... Йә ярый, шулай булсын да. «Если колесо заворачивается вправо, то оно разворачивается влево, то есть развернувшись влево, оно должно завернуться вправо, по закону заворачивания вправо и разворачивания влево и наоборот» килеп чыга инде бу. Ягъни мәсәлән, сүз боткасы.

Бүлдермә, мин бүлдермәдем... Тыңла, иптәш, тыңла... Шулай, тыңлавы иң авыры ул... Инде, иптәш, менә нәрсә, сөйләнмик без, эшләп күрсәтик... Шаккатсын бөтә дөнья...

Р ә с ү л. Алай иҗат итеп күрсәтү өчен, әйтәм бит, күп нәрсәне җимерергә кирәк. Яисә җимертеп яңадан корырга. Ә шаккаттыру өчен, аллы-гөлле иттереп, бер исемнән икенчесенә каударып форма өлкәсендә генә кайнарга кирәк.

Г а й с ә. Ә сине форма өлкәсендә кайнау түбәнсетәме? Димәк, син монда эш өчен түгел, ә җылы урын булганга гына?

Р ә с ү л. Болагайланма инде. Сверхзадачаны бит форма эчендә генә сурәтләү өчен куялар һәм миннән зәңгәрле-кызыллы форма сорыйлар, ә тирәнлек түгел. Ике генә мөмкинлек бар: форма күп булса, тирәнлек югала, тирәнлек булса — форма саега. Димәк, мин алар сораган форманы тутырып бетереп бирә алмыйм. Менә инде алар бездән бүтәнне сорасалар...

Г а й с ә. Шулай инде... Хирровому танцору...

Р ә с ү л. Ни эшлисең. Сүз сүз шул. Ул төшенчәләрне аңлатып булмый, бары тоемлап кына буладыр.

Г а й с ә. Юк, син уйлый күрмә, бу көлә дип. Мин сине аңлыйм да кебек. Ә бит эшләргә дә кирәк... Кирәк шул... Нишлисең, бүтән төрле җирлеге булмагач...

Р ә с ү л. Бер сүзем дә юк... Бары тик, ни өчен мин шундый дигәнгә генә...

Г а й с ә. Шундый күп сүз... (*Тәмәке кабыза.*) Тартасыңмы?

Р ә с ү л. Юк.

Г а й с ә (*сәерсенеп*). Шулай да әллә ниндиерәк шул син... Сәер... Ә мин тартам әле. Булса, эчәр дә идем...

Р ә с ү л. Юк шул.

Г а й с ә. Әйтәм бит. Бу фани дөньяга тугач, кеше шикелле иттереп яшәргә кирәктер бит инде... Йә, ачуланма, үз-үземә генә сөйләнәм... Саташа башладым бугай инде...

Р ә с ү л. Ә, юк, менә монда нидер бар бугай...

Г а й с ә. Агу бирә күрмә тагын...

Р ә с ү л. Яшисе килә, ә?

Г а й с ә. Бераз... Бер тугач инде... Нәрсә дә булса үзгәрер шикелле...

Ут сүнә.

Театр сәхнәсе яктыртыла. Репетиция бара. Сәхнәдә Г а й с ә, А л ь б е р т, Ә н з и р ә, Г а р ә ф и, Р ә с ү л. Р е ж и с с е р алда утыра. Аның янында Х ә с ә н.

А л ь б е р т (*1 нче су төбендә яшәүче, Ташбашев*). Эх Килкимон, белми шул алар бөек хакыйкатьне.

Г а й с ә (*2 нче су төбендә яшәүче, Килкимон*). Белмиләр...

Г а р ә ф и (*3 нче су төбе адәме, Тюлкин*). Әйдәгез, дөньяларын болгатып, бутап бетерәбез...

К и л к и м о н. Нигә?

Т ю л к и н. Буталып бетеп, аннан, бәлки, дөрес юлны үзләре үк эзли башларлар иде, урыслар кебек.

Т а ш б а ш е в. Ю-у-ук, ярамас. Эх, әгәр дә алар хакыйкатьне белсәләр, шундый матур яшәрләр иде.

К и л к и м о н. Әйтмә.

Р е ж и с с е р. Давай, давай, тагын да мавыгыбрак. Башыгызга әллә нинди, кешелекне коткару идеяләре килә. Бу бит югары пилотаж...

Г а й с ә (*үзалдына*). Да пошел ты...

Р е ж и с с е р. Нәрсә, нәрсә?

Г а й с ә. Юк, болай гына.

Р е ж и с с е р. Тә-әк, дәвам итәбез. Онытмагыз, башыгызга бөек идея килде. Сез — юлбашчылар. 26 нчы Бакы комиссары...

Т ю л к и н. Әйдәгез алайса, берәр чибәррәк кызларын алдалап китерәбез дә...

К и л к и м о н. Нигә алдарга?

Т ю л к и н. Нигә?! Сезнең өчен кайгыртам. Су анасыннан туйган бит инде...

Т а ш б а ш е в. Кан алмашу соңыннан, дидем. Кем хәзер монда баш акула?

Т ю л к и н. Син инде хәзер, син.

Т а ш б а ш е в. Ярый алайса, бар, берәрсен алып кил, тик кара аны, шаярма. Ату су төбе космик тәлинкәсенә утыра алмассың.

Т ю л к и н. Кит инде, кайчан соң минем дөнья бутаганым бар? (*Китә.*)

К и л к и м о н. Их, иптәш Ташбашев, алар бөек яңарыш хакыйкатен белсәләр икән...

Т а ш б а ш е в. Әйтик микән?

К и л к и м о н. Әйтергә кирәк.

Г а р ә ф и Ә н з и р ә н е алып керә.

Т ю л к и н. Менә, егетләр.

Ә н з и р ә. Абау, сез кемнәр?

Т ю л к и н. Саумысез. Без — су төбе космосы бәндәләре.

Ә н з и р ә. Исәнмесез. Сез дә безнеңчә яшисезме?

Т а ш б а ш е в. Нәкъ шулай дияргә була. Тик без, су астыннан булгач, акыллырак җан ияләре. Шуңа әйбәтрәк тә яшибез. Сезне дә якты юлга чыгармакчы булабыз.

Ә н з и р ә. Татарча да беләсезме? Әллә сез татармы?

Т ю л к и н. Кушылма. Татарча гына түгел, чуашча да беләбез.

Ә н з и р ә. Ничек итеп якты юлга чыгарга соң? Бик чыгасы килә.

К и л к и м о н. Беләсезме, сезнең халык алга китүнең төп юлын белми.

Ә н з и р ә. Ә сез беләсезме?

Т а ш б а ш е в. Беләбез. Һәм сезне дә өйрәтергә телибез.

Т ю л к и н. Килкимон, башла.

К и л к и м о н (*колагына пышылдап*). Әгәр дә сез су төбендә кишер үстерергә өйрәнсәгез, галәмәт баеп, чиксез рәхәттә тату итеп яши башлаячаксыз.

Ә н з и р ә. Ой, аны ничек итеп су төбендә үстерергә ди? Ул бит анда һавасыз үсмәс?

Т а ш б а ш е в. Эш тә шунда шул. Сез аның су төбендә шәбрәк, әйтергә кирәк, миллион тапкыр шәбрәк үскәнен башыгызга да китермисез.

К и л к и м о н. Бу сезнең төп бәлагез.

Т ю л к и н. Булдырасыз, егетләр... Шәп.

Ә н з и р ә. Менә сиңа мә! Ә мин тагын, кияүгә чыгу төп бәхет дип торам...

Т а ш б а ш е в. Өлгерерсең.

Т ю л к и н. Бездән калмас.

К и л к и м о н. Егетләр, егетләр, дим, эш кала. Менә шул, сеңлем. Кишер бик бай үсемлек. Анда бөтен битаминнар да бар. Ә тозлы диңгез суында үскәч, ул акылга бик файдалы тәэсир итеп (*чигәсенә борып күрсәтә*), акылыгыз хәттин ашып...

Т а ш б а ш е в. Бер миллион тапкыр...

Т ю л к и н. Кыскасы, тәмам кеше буласыз...

Гайсә аптырап барып утыра.

Р е ж и с с е р. Гайсә, ни булды, ник туктадың?

Г а й с ә. Соң, болай булмый бит инде.

Р е ж и с с е р. Ничек булмый тагын?

Г а й с ә. Соң ничек итеп кеше шушы мәгънәсез текстны тыңлап утырсын ди.

Р е ж и с с е р. Ансы синең эш түгел.

Г а й с ә. Ансы шулай да, аңлыйсым килгән иде.

Г а р ә ф и (*аңа гына*). Дөрес, Гайсә, юк белән баш катыралар.

Р е ж и с с е р. Нәрсә аңлашылмый?

Г а й с ә. Гафу итегез, билгеле, әнә ул анда, сезнең янда чекерәеп утыра утыруын. Минемчә, ни язганын үзе дә аңламаган, пычагым да...

Х ә с ә н (*сикереп торып*). Син... Син... Ни сөйли ул, ә? Аңгыра сарык, аңлатып китәм: сүздә түгел монда хикмәт, идеядә! Идеянең бөеклегендә. Сүз кешелекне коткару турында бара, тишек баш. Образда бирелгән бар да, шуны да аңламасаң. Ни дип кенә укыталардыр. Сездә укыган бугай әле, җитмәсә...

Р е ж и с с е р. Ярый, булды, дәвам итәбез. Син (*Гайсәгә*), иптәш Килкимон, үзеңнең язмышың кыл өстендә икәнен онытып җибәрәсең бугай...

Г а й с ә. Мин нәрсә... Беләсем генә килгән иде... Гафу итегез...

А л ь б е р т. Гафу... Ә репетиция өзелә...

Р е ж и с с е р. Башладык. Сүз басымын дөрес ясагыз, хәшәпләр.

Дәвам итәләр.

Ә н з и р ә. Ур-ра, бездә яңарыш булачак! (*Пауза.*)

Р е ж и с с е р. Тфү! Ну, тагын нигә туктадыгыз? Кая су хезмәтчесе? Бер җөмләң бар, шуңа да соңарасың. Дәвам итегез.

Р ә с ү л керә.

Р ә с ү л. Устрица әзер, рәхим итегез.

Т ю л к и н. Әйдәгез, сезнең изге, олы кишерле киләчәк өчен бер җыр да, аннан безнең белән китәргә ризамы?

Ә н з и р ә. Сезнең беләнме? Ә анда шмотка бармы?

Т ю л к и н. Ни соң ул?

Ә н з и р ә. Ну, чүпрәк-чапрак инде!

Т ю л к и н. Море.

Ә н з и р ә. Ул чагында сезнең белән су төбенә генә түгел, күккә дә менә алам.

Т ю л к и н. Бар да безнеңчә. (*Шыпырт кына.*) Соңгы бер җыр...

Су төпләрен сукалаган чакта,
Коелып калды теш порошогым.
Олы кишер кебек кызарынам,
Күреп калсам оятсыз карашыңны.
Су төпләре бик уңдырышлы икән,
Сабаннарың булса төз генә.
Җыясы юк мукәләп тә уңыш —
Тончыкмасаң, иңләп йөз генә.
Су төпләрендә өй салырбыз,
Уя-уя кара балчыкны.
Күпме генә гайбәт чәчкән идек,
Алга киткән диеп дан чыкты.

Р е ж и с с е р. Булды, бүгенгә бетте. Альберт, калып тор әле.

А л ь б е р т. Әйе...

Р е ж и с с е р. Молодец. Көннән-көн әйбәтрәк.

А л ь б е р т. Тырышабыз инде, үзебезчә.

Р е ж и с с е р. Мин сиңа күптән күз салып йөрим. Аннан бик зур планнар да бар...

А л ь б е р т. Рәхмәт инде мине онытмагач. Бик тә эшлисе килә ансы...

Р е ж и с с е р. Истә тотарбыз. Аннан...

А л ь б е р т. Әйе...

Р е ж и с с е р. Синең Әнзирә белән мөгамәләгез ничегрәк?

А л ь б е р т (*ни дип әйтергә дә куркып*). Ничек дип, ярый инде, якын да түгел, ерак та димәс идем. Тик, тик мин аны бик хөрмәт итәм.

Р е ж и с с е р. Беләсеңме, старик, алдагы эш өчен сезгә якынайсагыз да начар булмас иде...

А л ь б е р т. Аңлап бетермәдем? Болай, эш буенча гынамы?

Р е ж и с с е р. Ә нигә эш буенча гына? Болай да...

А л ь б е р т. Китегез инде, ничек...

Р е ж и с с е р. Ашыкма. Курыкма, мин үзем әйтеп торам бит. Үзе дә сиңа әйбәт карый бугай. Әгәр эш әйбәт барса... Исем бирелгәнме әле сиңа?

А л ь б е р т. Кая инде ул безгә?..

Р е ж и с с е р. Ә фатирың ничек?

А л ь б е р т (*чынлап көлеп*). Әкият бу. Ну, тулай торак инде...

Р е ж и с с е р. Көлмә. Эшегез дә артыр, башкасы да... Миңа яхшы пар кирәк. Геройлар кирәк. Фактурагыз бар, тавыш һәм башкалар...

А л ь б е р т. Әллә ничегрәк әле бу...

Р е ж и с с е р. Рөхсәт дип торам бит... Бәлки, матур гаилә әрәм булып ятадыр... Шаярам...

А л ь б е р т. Мин тырышып карармын.

Р е ж и с с е р. Тырыш, тырыш. Тырышкан һәрчак уңышка ирешкән. Бар, уйла. (*Альберт китә.*) Театр, театр...

Ут сүнә. Ут яңадан авансценадан үтеп барган Г а й с ә г ә төшә. Аңа Г ө л б о с т а н апасы ияргән.

Г ө л б о с т а н. Энем, энем, дим. Ник өйгә кайтмый йөрисең? Ашамаган, эчмәгән килеш? Әйдә кайтабыз.

Г а й с ә. Соң, түтәй, әйттем бит инде, вакыт юк дип. Аннан теләмим дә әле мин.

Гөлбостан. Нәрсә теләмисең?

Гайсә. Ашыйсым килми. Аның кайгысы түгел дә әле миндә...

Гөлбостан. Кит инде, кит, шулай йөрмиләр инде, ашамый да... Менә Хөрмәтулла абзаң да сине гел кайгыртып тора...

Гайсә. Ансы нәрсә тагын?

Гөлбостан. Түбәтәй. Башына киеп куйсын, әллә ниткән зәхмәтләр кермәсен ди...

Гайсә. Менә хәзер, шул гына җитмәгән иде...

Гөлбостан (*еламсырап*). Теләсә нәрсәне кире как, тик аны алмасаң, мәңге бәхил түгел.

Гайсә. Уф Аллам, киям инде, киям.

Гөлбостан. Ә менә болары...

Гайсә. Ансы ни инде?

Гөлбостан. Юк, әллә ни түгел, бераз ашарга да... Ни, аннары...

Гайсә. Юк, кирәкми. Әйттем бит, ашыйсым кил-ми!

Гөлбостан. Карале әй, аласыңмы-юкмы? Мин мәрхүм әти-әниең алдында бурычлы, җаваплы кеше булып калдым. Карышма миңа.

Гайсә (*кычкырып*). Ки-рәк-ми!!! Берни дә кирәкми! Минем инде үземнең үләр чагым җитә, калдырыгыз мине, мин бала түгел. (*Чыгып йөгерә. Түбәтәе төшеп кала.*)

Гөлбостан. Иблис токымы! Хаҗимулла абзый дөрес әйтә шул. Әти-әнисе дә шул токым иде. Мәнсез! Кадал шунда. Аш белән атканга, таш белән атучы... (*Елый башлый.*)

Ут сүнә. Ут кабат янганда, Гайсә, аңа ияреп Әнзирә керә.

Гайсә. Йә, ни тагын?

Әнзирә. Нигә миннән качасың?

Гайсә. Эшем бар.

Әнзирә. Ой, ой, эшем кешеләре.

Гайсә. Ни йомыш, дим?

Әнзирә. Нәчәлник булдың мәллә? Бик коры сөйләшә башлагансың. (*Сырпаланып.*) Бу кадәр инде... Кызлар үзләре арттан чапкач шәптер инде ул...

Гайсә. Аңа түгел икәнен беләсең бит...

Әнзирә. Алайса (*ияген сыйпап*), бүген кич?

Гайсә. Юк!

Әнзирә. Карале моны, тыңлап бетер... Беркем дә булмый...

Гайсә. Юк, дим бит ич...

Әнзирә (*аны бүлдереп*). Бүлдермә. Карале, даманы

бүлдерә. Шулай итеп, беркем дә булмый, өстәл әзер була... Ә мин... көтәм...

Г а й с ә. Бул...

Әнзирә аның авызын каплый.

Ә н з и р ә. Дәшмә. Соңгы тапкыр. Мин аннары...

Г а й с ә. Нәрсә, аннары?

Ә н з и р ә (*елмаеп*). Ә менә анысын килгәч белерсең. (*Китә башлап.*) Кара аны, көтәм. (*Чыгып китә.*)

Гайсә ялгыз.

Г а й с ә. Уф... (*Кесәләрен әйләндерә, акча барлый.*)

Икенче яктан А л ь б е р т күренә.

А л ь б е р т. Карале, син монда Әнзирәне күрмәдеңме?

Г а й с ә. Ниемә ул миңа...

А л ь б е р т. Маташтырма. Чыннан да күренмәдеме?

Г а й с ә. Юк, дим бит.

А л ь б е р т. Карале, без бит синең белән дуслар бит, әйеме?

Г а й с ә (*аңа озак карап торып*). Ни йомыш?

А л ь б е р т. Сезнең аның белән ниләр булды?

Г а й с ә. Ничек, ниләр?

А л ь б е р т. Ну, бастыңмы син аны?

Г а й с ә. Беләсең киләме?

А л ь б е р т. Килә.

Г а й с ә. Болгаталармы?.. Болгата ул дөнья... Шуңа...

А л ь б е р т. Лыгырдамыйча гына! Булдымы?

Г а й с ә. Әй егет... 50 сум биреп тор, әйтәм.

А л ь б е р т. Әйтәсеңме?

Г а й с ә. Әйтәм. Вот те...

А л ь б е р т (*акча биреп*). Мә. Йә?

Г а й с ә. Ошамый ул миңа.

А л ь б е р т. Димәк, берни дә булмады?

Г а й с ә. Ничек теләсәң, шулай уйла.

А л ь б е р т. Син миңа болгатма, бир алайса акчаны.

Г а й с ә (*акчаны яшереп*). Юк, булмады, дидем бит инде...

А л ь б е р т. Шулай диләр аны. Тагын эчә башлыйсыңмы?

Г а й с ә. Берегезнең дә эше булмасын.

А л ь б е р т. Нинди рольләрең бар! Бөтен комедияләр синеке. Менә-менә исем бирергә тиешләр. Дәрәҗәң бар, фатирың булыр...

Г а й с ә. Әбиеңә сәлам әйт, яме, бар энем, бар... Кеше-

некенә һөҗҗерләнеп торма. Үзеңә кирәклене минем болай да тинтерәгән башкаема өймә... Ботыңны... өйрәт.

Китә.

Альберт. Дур-рак!

Ут сүнә.

Ут Гөлбостан түтәсе өендә яна. Анда Гайсә күренә. Кулында башланган шешә. Әллә җырлый, әллә үзалдына сөйләнә. Бер кулында бау. Түшәмдә элмәк ясарга җайлы урын эзләп йөри. Люстрага элмәк ясап, уйланып кала, аннан елмаеп куя. Аңа ничектер җиңел булып киткәндәй була. Утырып шәраб салып эчә, тын гына утырып тора. Аннан өстәлгә басып, элмәкне муенына элә, бераз уйлап тора да кисәк өстәлдән читкә тайпыла... Сөмбел йөгереп керә. Нидер сизенгән.

Сөмбел. Гайсә абый, Гайсә абый?! (*Аны асылынган килеш күреп.*) А-а-ай, ярдәм итегез, ярдәм! (*Чыгып чаба. Гөлбостан белән Хаҗимулла йөгереп керәләр.*) Ярдәм итегез! (*Өстәлгә басып, аз гына булса да, Гайсәне күтәреп тора башлый, аңа Хаҗимулла булыша. Гайсә йөткереп куя.*)

Хаҗимулла. Пычак, тизрәк.

Гөлбостан пычак суза. Гайсәне акрын гына күтәреп алалар.

Күзен ачты.

Гөлбостан. Исән, исән. Ай энем, болай ярыймы инде, япь-яшь килеш...

Хаҗимулла. Гомерен үтеп бетерми, әй яшьләр...

Сөмбел. Ярарыгыз инде, борчымагыз...

Ут сүнә.

Прожектор уң як почмакта, кәнәфидәге Рәсүлне ала.

Рәсүл. Яшәү, үлем...
Ни өчен соң бу... Гомер?..
Газап, китек күңел...
Йә яктырак яна факел,
Йә тоныклан, сүрел...
Үлем... Үлемме соң үлү,
Үлемме әллә терелү?!
Туу мәллә үлем,
Тәмуг, газап, тетелү?!
Газапланып гомерең буе
Тууыңа килү?!
Яшәү, үлем?..
Яшәүме соң бу?
Йә, әйтче, күгем...

Ут сүнә.

Сәхнә яктырганда, анда спектакль бара. Психбольницадагы күренеш. Сәхнәдә яңадан Гайсә, Альберт, Гарәфи, Рәсүл, Әнзирә (шәфкать туташы).

Әнзирә. Булды, яттык барыбыз да! На правый бочок! Әгәр берәр кыймылдау ишетсәм... Тихий час! (*Чыгып китә.*)

Бераз тынлык саклана. Гарәфи торып баса.

Гарәфи. Җәмәгать! Мин бөек режиссер — Станисловский! Хәзер үзегезгә бөек, музыкалы, трагедияле, драмалы хомедия куям! Тәк, тезелегез әле! (*Рәсүлгә.*) Ник сөйрәләсең, мисез тәре, великий булдың мәллә?! Бас тизрәк.

Альберт. Мин гатуф, господин режиссер. (*Кулын күтәрә.*)

Гарәфи. Сиңа ни?

Альберт. Мужнымы, мин йә директор, йә татарның иң кызык әртисте, шамакае — Хуҗа Насретдины булам?

Гарәфи. Мужны. Ә син ник берни сорамыйсың?

Рәсүл. Мин телсезне уйнармын.

Гарәфи. Юк, син тиле телсез булырсың, менә мондый. (*Күрсәтә.*) Ха-ха-ха. (*Үзара гына.*) Халык үләчәк, спектакль, во!

Гайсә. Миңа мужнымы?

Гарәфи. Син кем? Кем соң син Гайнетдин?

Гайсә. Минем ата маймылны уйныйсым килә.

Гарәфи. Бик олы дәрәҗә сорыйсың бит әле син, апаем.

Альберт. Җитмәгән аңа бетлесе генә. Ы-ы...

Гарәфи. Шым! Йә ярар, миннән булсын яхшылык. Бетле маймыл булырсың. (*Әнзирә йөгереп керә.*)

Әнзирә. Бу ни бу?! Ниткән тавыш? Дурдоммы бу конце концов, әллә Дума Советымы? Тәртип!

Гарәфи (*аның янына килеп*). Ш-ш-ш, шаулама. Без театр уйныйбыз. (*Күрсәтә.*)

Альберт. Комедия! Мин менә чып-чын шамакай! (*Кылана.*)

Гайсә. Ә мин, сөеклем, маймыл дәрәҗәсендә. (*Сикеренә, Әнзирәне капшап нидер эзләнеп ала.*) Әйдә, син дә маймыл бул.

Әнзирә. Кит әле... Ә син ник тик торасың?

Гарәфи. Глухонемойны уйный ул, тиле глухонемой.

Альберт. Үзе тиле, үзе глухонемой. Хи-хи-хи.

Гарәфи. Әйдә, син дә уйна. Син шундый хатын бул...

Әнзирә (*көлеп*). Нинди?

Г а й с ә. Шундый инде менә... (*Күрсәтә.*) Шундый...
Ә н з и р ә. Кит әле, оятсыз. Оялтасың.
А л ь б е р т. Оялтма инде кыз баланы, макака.
Ә н з и р ә. Йә булды, инде төш күрә башлыйбыз.
Г а р ә ф и. Зинһар өчен, бер генә минут?..
Ә н з и р ә. Нәрсә?
Г а р ә ф и. Соңгы бер җыр... Шимпанзе, башла.
Г а й с ә. Маймылларның була, әй төрлесе, без маймылның сарысы... (*Кисәк пижамасын умырып ташлап, ак күлмәктән калып.*)

Яшәргәме, әллә үләргәме?! Менә сорау
Нәрсәдә. Йә, кайсысы яхшырак соң —
Явыз язмыш укларына баш июме?!

Г а р ә ф и. Нишлисең, дивана, текстны бутама.
Г а й с ә. Әллә кулга корал тотып, бу җәфалар
Диңгезенә көрәш ачып, чик куюмы?
Ә н з и р ә. Туктале, Гайсә, син әллә нәрсә сөйлисең бит?
А л ь б е р т. Тузга язмаганны. Әллә белая горячка инде?
Г а й с ә. Үлү — йоклау. Артык һични... Барлык йөрәк
Газапларың, тәнең дучар булган мең-мең
Җәфаларың шул бер йокы белән бетте
Диеп уйлап-көтеп алган чик түгелме?
Р е ж и с с е р (*читтән*). Бетерде спектакльне.
Х ә с ә н. Нинди текстны боза бит, хайван.
Р е ж и с с е р (*артистларга ишарә ясап*). Туктатыгыз аны, туктат!
Р ә с ү л. Сак бул, Гайсә.
Г а р ә ф и (*режиссерга*). Хәзер. Әфәнделәр, әйдәгез! (*Аңа ташланалар.*)
Г а й с ә (*аларны селтәп ташлап*).

Шул булмаса, кем соң түзеп торыр иде
Замананың мыскылына, камчысына...
Башлыкларның изүенә; өстеннәрнең
Үз өстеннән көлүенә, мәхәббәтең
Кире кагу газабына, хакимнәрнең
Оятсызлыгы, гаделлекнең соңлавына...

Д и р е к т о р х а н ы м. Ни карап торасыз, басыгыз!
Р е ж и с с е р. Сөйрәгез аны сәхнәдән.
С ә л и м. Ну, ишкәнсез. Әгәр дә ычкындырсагыз...
Д и р е к т о р х а н ы м. Ычкынмас.
Р е ж и с с е р. Бөтен көчне тупларга кирәк. Дәшик барсын да.
Г а й с ә. Эш күрсәткән кешеләрнең, җыен рәтсез
Бәндәләрнең типкесендә йөрүенә!
Шул тормыштан үз-үзенә пычак белән
Бер кадауда котылып булгач, нәрсә тота?!

С ә л и м. Йомшак тоту, йомшаклык галәмәте. Ну!
Д и р е к т о р   х а н ы м. Әйдәгез!

Бар да Гайсәгә ташлана, камап алалар. Кем этә, кем сөйри. Ул карыша. Рәсүл аңа ярдәм итмәкче була, аны изеп китәләр.

С ә л и м. Ычкындырмагыз.
Д и р е к т о р   х а н ы м. Артка сөйрәгез.
Р е ж и с с е р. Бердәм фронт булып, мезансцена бозылмасын.
С ә л и м. Психикасына, нервысына басым ясагыз!
Г а й с ә. Ха-ха! Бирегез миңа музыка! Кая курайчылар?

Король ошатмады уенны, шәт,
Ошатмасын, аның шунысы да шәп!

Д и р е к т о р   х а н ы м (*Атасына, Анасына, Апасына, Хаҗимуллага, Әнзирәгә*). Марш, алга...
А т а. Улым, ни эшлисең син, шашма.
А н а. Акылыңа кил, улым.
Г ө л б о с т а н. Ашамый йөргәнгә инде бу. Әй энем, тамагы ачның акылы була димени инде. Тукта, энем, ашап-эчеп ал.
Г а й с ә (*кемгә сөйли, шуңа омтылып*).

Дөньяда кешенең иң төп теләге,
Әгәр бары ашау белән йокы булса,
Ул чагында нәрсә кеше?! Хайван гына...

Х а җ и м у л л а. Тезлән, намазга тезлән, имансыз бала, тәкъбир әйт!
Г а й с ә. Безне шулай үткән белән киләчәккә
Баш йөртерлек киң уй белән яратучы,
Мөгаен дә, бу акылны безнең башка
Тиккә ятып тутыксын дип бирмәгәндер?..

Ә н з и р ә. Юк белән бетермә хәлеңне, төн алда әле. Әйдә, әйдә.
Г а й с ә. Аh бу тәнем, артык каты булган тәнем,
Чык булып күтәрелсен иде эреп!
Ичмасам, шул мәңгелекнең кануны да
Үз-үзеңне үтерүне тыймасае!

С ә л и м. Җиңәсезме, юкмы аны!

Бөтенесе этә-этә, аны артка, калкурак җиргә, баганага алып барып териләр. Таяк табып, кулларын җәйдереп, аркылыга бәйлиләр. Ул ничектер алардан өстәрәк булып кала. Ә Рәсүл аның аяк астына һушсыз булып егыла.

Г а й с ә (*көчкә генә*). Фу, ваклык! Кузгал мием! Эшкә ябыш!

Каядыр тагын да биектә, ап-ак күлмәктә С ө м б е л пәйда була. Ул кулларын Гайсәгә таба сузган.

С ө м б е л. Мин яратам сине, сөеклем!

Г а й с ә. Мин дә, иркәм. Мине —

Алдаша дип уйлый күрмә.
Әйдә, әнә төче телләр коры көяз
Алларында елмайсыннар, каеш тезләр
Табышлырак, майлы җирдә сыгылсыннар.

(*Сөмбелгә.*)

Ишетәмсең?! Күңлем кеше аера белеп,
Сайлый белә башлаганнан бирле, җаным
Сиңа ятты!

А л ь б е р т. Җитте! (*Гайсәнең башына авыр әйбер белән суга.*)

Гайсә сискәнеп киткәндәй, баганасы белән бергә тетрәп куя. Аннан, барысыннан да аерылып, яп-якты утта, багана һәм аркылы таягы белән бергә, акрын гына өскә күтәрелә башлый. Бар да егылып кала. Кайтаваз булып, Гайсәнең тавышы ишетелә.

Г а й с ә. Ни теләдегез?! Тотарга мине?! Ха-ха-ха! Мине, чиксезлекне, Олуг галәмне, Ходам яраткан җанымны?! Да, сыймыйм мин, ишетәсезме, сыймыйм, сезнең тар, вак, ялган рамкаларыгызга! Мин ireклек телим! Мин мәңгелек телим! (*Югала.*)

О, если бы из юдоли
Как голубь в теплый мир гнезда.
Уйти, взлететь в простор небесный,
Забыв земное навсегда!
О-о, әфәнделәр!..

П ә р д ә.

# Кабан күле серләре

*Мәхәббәтле-сөюле, хәзинәле-байлыклы*
*ЦРУ күзәтүе астында юмористик-шоу-комедия*

КАТНАШАЛАР:

Сәгъди — инглиз телендә сөйләшә.
Кантри (*беренче пәрдәдә бик юан, соңыннан ябык*).
Нәрмин.
Макс — бәләкәй } ЦРУ агенты.
Чарли — озын. }
Аллыгөлия — мөдир.
Гөлсылу.
Нургали.
Сәрвәр.
Сәрхуш.
Кибет мөдире.
Кассир.
Беренче агент.
Икенче агент.
Өченче агент.
Дүртенче агент.
Автор.
Хезмәтче — Рейган.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәхнәдә (автор күзаллавы буенча) Җир шары торырга мөмкин. Ул бик зур. Аның бер ягында АКШ картасы белән флагы, икенчесендә СССР картасы һәм флагы, өченче ягында Болгар җире һәм яшел флаг булырга мөмкин. Шар кирәк күренештә, мөһим булган ягыннан ачылып, таралып китәргә мөмкин. Күренеш тәмамлангач, җыелып тагын шар була ала. Сәхнә ачылганда, шар әйләнеп тора. Сәхнәдә — Автор.

Автор. Алма бит ул, алма бит ул,
Алма бит ул түгәрәк.
Шул түгәрәк эчләрендә
Яшик, дуслар, бергәләп.

Хәерле кич, хөрмәтле тамашачылар. Без сезнең белән бүген озак та түгел, тиз дә түгел, нәкъ ике сәгать буе бер

тамаша карарбыз. Без татарчаны хәзер бик үк аңлап бетермибез, шуңа төгәлрәк, урысча әйтеп китәм, безнең тамаша — сатирик шоу-комедия дип атала. Кыскасы, ханымнар, әфәнделәр, мин сезне бер кызыклы тарих мизгеле белән таныштырып үтәм. Ә, әйе, мин бит әле сезне үзем белән таныштырмадым. Мин шушы тамашаның авторы. Барыгыз да белгәнчә, галимнәр әйтүе буенча, безнең җиребез алсу алма кебек түгәрәк, менә ул (*күрсәтә*), һәм ул әйләнә. Үзегез аңлыйсыз, дөнья әйләнгәч, ул бутала да, болгана да. Картлар әйтмешли, дөнья ул куласа, бер әйләнә, бер баса. Дөнья әйләнгәндә менә безнең татарларның да әллә кемнәр белән очрашуы, җирнең бүтән почмагындагы мөселман кардәшләре белән аралашуы мөмкин. Ярый, җәмәгать, күп сүз... кһм, кем әйтмешли, шулай инде. Мең кат ишеткәнче, бер тапкыр күрүең яхшы, ди. Әгәр инде бик ошатсагыз, икенче, өченче тапкыр килеп карарга да мөмкин. Ә хәзер рәхим итеп тамаша карагыз.

Җир шары АКШ турысыннан ачылып китә. Бай җиһазландырылган Көнбатыш фатиры. Камин, шәмнәр һәм башкалар булуы мөмкин. Креслоларда б е р  е г е т белән б е р  к ы з утыра. С ә г ъ д и йөренә.

С ә г ъ д и. Сез ни өчен җыелганны беләсезме?

К а н т р и. Ноу, юк.

Н ә р м и н. Нигә алай капылт кына чакырдың?

С ә г ъ д и. Эш менә нәрсәдә, әфәнделәр. Безнең илгә СССРдан, Татарстаннан бер татар язучысы килгән. Татар клубында чакта ул безне күреп калган. Туган апа аша ул безне күреп сөйләшәсе килүен белдергән.

К а н т р и. О, ес, кит әле, булмас.

Н ә р м и н. Кантри, бүлдермә. Йә, йә, Сәгъди.

С ә г ъ д и. Менә шул, ерак туган җиребездән килгән милләттәшебезне күреп, аның белән сөйләшү, аралашу һәрберебез өчен бик шатлыклы хәл дип уйлыйм.

Н ә р м и н. О' кей! Чынлапмы? Кайчан?

К а н т р и. Тизрәк күрәсе иде.

С ә г ъ д и. Дусларым, озак көтәсе булмас, ул менә-менә килеп керергә тиеш.

Х е з м ә т ч е. Әфәндем, анда сезне сорыйлар.

С ә г ъ д и. Чакырыгыз.

Х е з м ә т ч е. Баш өсте.

С ә г ъ д и. Менә килеп тә җитте.

А в т о р керә.

А в т о р. Хоу до юоу доу!..

С ә г ъ д и. Әссәламегаләйкем! Исәнмесез, саумысыз!

Н ә р м и н. Исәнмесез.

А в т о р. Саумысыз, туташ.

К а н т р и. Хуш киләсез, әфәндем!

С ә г ъ д и. Рәхим итеп утырыгыз. Сез инглизчә генә сөйләшәсезме?

А в т о р. Ә, юк, юк, сезнең алда уңайсыз хәлдә калмаска дип кенә бер-ике сүз өйрәнгән идем. Ә сез татар телен бездән дә яхшырак беләсез.

С ә г ъ д и. Алай ук түгел дә инде. Сезгә нәрсә, коктейльмы, әллә вискимы?

А в т о р. Юк, юк, борчылмагыз, мин биш кенә минут.

С ә г ъ д и. Сез безгә кадерле кунак. Геод бейце, алайса, мин анда кунак бүлмәсенә табын әзерләргә куштым. Эш турында сөйләшеп бетергәч, шунда чыгарбыз.

А в т о р. Юк, юк, мин чынлап әйтәм. Мин бик тиз генә.

С ә г ъ д и. Сез мине, билгеле, сорри, әй лә, гафу итегез, ләкин кире кагу файдасыз. Без сезне барыбер кунак итми җибәрмәячәкбез.

А в т о р. Ярый алайса.

Н ә р м и н. Еракта яшәүче кардәшеңне очратып сөйләшеп утыру үзе бер бәхет. Соңрак сез безгә татар иле турында сөйләрсез бит.

А в т о р. Әлбәттә, сөйләрмен.

К а н т р и. Сез ничек безгә килеп чыктыгыз. Сездән безгә «миссион» бик кыен, диләр бит?

А в т о р. Мин үзем театрда артист булып эшлим.

Н ә р м и н. О’ кей! Ничек, чын татар театрындамы?

А в т о р. Әйе.

К а н т р и. О, ес, бик кызык.

С ә г ъ д и. Сез безне бер йомыш, сөаль белән эзләгәнсез, диләр.

А в т о р. Әйе. Мин шул йомыш белән килгән идем инде.

С ә г ъ д и. Ес, ес, тыңлыйбыз.

А в т о р. Бер уйлаганда, бик сәер тоелыр. Мин театр өчен пьеса язарга уйладым. Башта бик әйбәт тема йөри иде.

К а н т р и. Бик кызыклымы?

А в т о р. Менә эш тә шунда шул. Минемчә, бик кызыклы, матур булырга тиеш. Ләкин мин әле яшь, яза белмәм дип куркам. Тәҗрибә юк. Шуңа менә минем сезнең ярдәмгә таянасым килә.

С ә г ъ д и. Кызык, без монда торып сезгә ничек ярдәм итә алабыз соң?

А в т о р. Мин болай уйлыйм. Мин сезгә башлангыч юлын күрсәтәм, ә аннан калганын үзегез дәвам итәсез.

С ә г ъ д и. Ес, нинди эш инде ул?

А в т о р. Хәзинә табу.

К а н т р и. Хәзинә! Менә бу эш, ичмасам!

С ә г ъ д и. Ничек итеп?

А в т о р. Мин сезгә хәзинә яшерелгән картаны һәм аның буенча байлыкларны табу юлын күрсәтәм. Ә калганын үзегез дәвам итәрсез. Ә мин сезнең юлны, эзләнүне күзәтеп, язып барам. Ахырда — сезгә сәяхәт һәм хәзинә, ә миңа пьеса килеп чыга.

С ә г ъ д и. Ес, кызыклы тәкъдим.

К а н т р и. Ноу, бераз куркынычрак.

С ә г ъ д и. Рид а риск, ноу! Һе! Ансыз гына сиңа. Ә бит хәзинә таба алсак, бөтен хыяллар тормышка ашачак. (*Авторга.*) Сезгә дә өлеш чыгарырбыз.

А в т о р. Юк, юк, миңа пьеса булса, шул җитә. Аңлагыз, бу минем өчен мөһим. Аның белән минем язмышым хәл ителә.

С ә г ъ д и. Аңлашыла, Геод! Без башлап карыйк. Дуслар, сез ризамы? Без өчәү булсак, сезгә читен булмасмы?

А в т о р. Юк, юк, күңеллерәк булыр сезгә дә.

Н ә р м и н. Ә ни өчен сез, «йоуист», безгә тукталдыгыз, Татарстанда да кешеләр күп бит.

А в т о р. Беләсезме, беренчедән, ул карта сездә яшерелгән, икенчедән, минемчә, сез тапсагыз, ул байлыклар тиешле юнәлештә файдаланылыр кебек. Аннан миңа пьеса өчен сезнең кебек чибәр кыз да бик кирәк.

Н ә р м и н. О-о, сенкевью.

С ә г ъ д и. Яхшы! Алайса, нидән башлыйбыз?!

А в т о р. Сез өчәү бик тырышып ул картаны эзлисез, һәм менә шушы өйдә өчәү очрашасыз.

С ә г ъ д и. О’ кей! Бик кызык бу. Ярый, дусларым. Барыгыз, әйләнеп килегез, ә мин сезне каршыларга әзерләнәм. (*Авторга.*) Уңышлар сезгә!

А в т о р. Сезгә дә. Мин читтән күзәтәм. Йа дуис йоу лук!

С ә г ъ д и. Кунак бүлмәсенә рәхим итегез.

Сәгъди ялгыз. Х е з м ә т ч е керә. Бик яхшы костюмнан.

Х е з м ә т ч е. Гафу итегез, Кантри җәнапләре килделәр.

С ә г ъ д и. О’ кей. Керсен, керсен (*Хезмәтчегә*) бер минутка, тагын бер туташ килергә тиеш, килгәч әйтерсез.

Х е з м ә т ч е. Баш өсте. (*Чыга.*)

С ә г ъ д и. Ни булды бу, бу кадәр көттергәннәре юк иде.

К а н т р и керә.

К а н т р и. Хелло, әссәламегаләйкем, дустым!

Сәгъди. Магаләйкем!..

Кантри. Ник алай бик коры... О, ес, кәефе юк кешеләрнең.

Сәгъди. Ярый, шаярма. Күпме көтәргә була? Соңга калганың юк иде бит әле?.. Җитмәсә, шундый эш алдыннан. Эшлеклерәк булырга кирәк, эшлеклерәк. Ни булды?

Кантри. Нинди шаяру? Шаярырлык түгел әле монда. Тукта әле, хәл алырга ирек бир. Керү белән ябышты...

Сәгъди. Ни булды, дим?

Кантри. Шул, әти аркасында инде. Биржада бер компанияне берничә миллионга утырткан. Берничә сәгатьтән шул ук акцияләр төшә башлаган. Әтигә банкротство яный...

Сәгъди. Кит әле, шуннан, шуннан?..

Кантри. Әти мине чакыртты. Кыскасы, дусларга чыктык, тегендә чаптык, монда чаптык. Файда юк.

Сәгъди. Нәрсә, әллә?..

Кантри. Ноу, алай бөтенләй үк янмадык. Яшәрлек калды. Атам үкерә.

Сәгъди. Үкермичә...

Кантри. Атамның исәбе, үзең беләсең, эш барып чыкса, татарларның берләшкән корпорациясен төзү иде. Ә ничек килеп чыкты?..

Сәгъди. Ес, начар килеп чыккан. Мин инде минем генә хәл мактанырлык түгел дип йөри идем.

Кантри. Сиңа нәрсә? Туган апаң белән икегезгә генә зур йорт, лавкаларың уңышлы гына эшләп тора.

Сәгъди. Эш анда гынамыни?! Гомер бушка уза. Иншалла, менә эшебез барып чыкса...

Кантри. Шәп булыр иде дә!

Сәгъди. Барып чыгарга тиеш. Барып чыкса, Россиядәге кардәшләр белән берләшеп, бизнесны тагын да көчәйтеп булыр иде. Аннан без монда яшибез!

Кантри. Ес, эх, эш барып чыкса, гомеребезгә җитәчәк.

Сәгъди. Алла боерса. Нәрминне көтик тә төп эшкә тотынырбыз. Рейган!

Хезмәтче керә.

Хезмәтче. Тыңлыйм, әфәндем! (*Чыга.*)

Сәгъди. Кантри, син нәрсә эчәсең?

Кантри. Минемчә, дустым, без башта Нәрминне көтик инде, ул ни дияр?!

Сәгъди. О' кей! Шулай итик, алайса.

Хезмәтче керә.

Хезмәтче. Гафу үтенәм, сезне анда туташ сораган иде.

Сәгъди. Менә Нәрмин дә килеп җитте. Чакырыгыз.

Хезмәтче. Баш өсте! (*Китә.*)

Нәрмин керә.

Нәрмин. Хелло! Егетләр, ачуланмагыз, тоткарландым.

Кантри. Нинди ачулану инде, синең кебек туташка...

Сәгъди. Тукта әле, Кантри.

Нәрмин. О, ес, Сәгъди ачулана.

Сәгъди. Менә нәрсә, дуслар, без дуслар. Бер-беребезне ярты сүздән аңлыйбыз.

Кантри. Беләбез бит.

Сәгъди. Ноу, бүлдермә. Эш шунда, без бик зур вә куркыныччлы эшкә тотынабыз. Вә ләкин сез бала-чагалар кебек шаярып йөрисез. Кабатлап әйтәм, бу уен эш түгел.

Нәрмин. Сорри, без бүтән алай итмәбез, без төзәлербез.

Сәгъди. Нәрмин!

Нәрмин. Бетте, бетте!

Сәгъди. Мин бөтенләй синең бару бармавыңны сөаль астына куям.

Кантри. Ничек инде?!

Сәгъди. Ярар, булды, эшкә керешик. Зур авырлык белән булса да, документлар, харита* минем кулга керделәр. Туган апаның да ярдәме зур булды. Карт үләр алдыннан сөйләшә алмый башлады. Туган апа көчкә йомшартып, харита урыны турында яздырып ала алды.

Кантри. О' кей, булдырган!

Сәгъди. Ашыкма. Документларны казып алганда, эзгә ЦРУ агентлары төшә язган, сак булырга кирәк.

Кантри. Ә, юк! Мин алай булгач катышмыйм.

Сәгъди. Каушама. Бары да әйбәт кенә узды.

Нәрмин. Кантри гел шулай инде ул. Бер нәрсә булса, калтырый башлый.

Кантри. Мыскыллама инде.

Сәгъди. Ес, алга таба китик. Хәзер безнең кирәкле кәгазьләр бар. (*Тартма чыгара.*) Менә алар!!!

Нәрмин. Фу, болар череп беткән бит.

Сәгъди. Черемичә, 500 ел җир астында ятып...

---

* *Харита* — карта.

К а н т р и. Моның белән эш чыгарып булмас.

С ә г ъ д и. Кыюрак, акыллырак эш итсәк, бар да булыр.

К а н т р и. Әй, юк. Мин куркам.

С ә г ъ д и. Калтырама инде. Бик кычкырмагыз, кем әйтмешли, диварларның да колагы бар.

К а н т р и. Ес, тс-с-с, Алла сакласын!

С ә г ъ д и. Тыңлагыз. Ә хәзер бергәләп уйлашабыз.

Н ә р м и н. Беренчедән, без анда ничек эләгәбез? Әгәр дә җәйгә Казанга татарлар җыелганда эләксәк?..

К а н т р и. Ой, бу бик куркыныч эш бит.

С ә г ъ д и. О' кей! Әйбәт фикер. Мин аны уйлаган идем. Бер начар ягы бар. Безне тикшерәчәкләр. Үзегез беләсез. «Кей Җ Би» бик яхшы эшли. Аннан безгә вакыт та күп кирәк.

К а н т р и. Ес, ул «Кей Җе Би»ны бик усал, диләр. Кешеләрне аягыннан асып та җәзалыйлар икән.

С ә г ъ д и. Менә, менә! Безгә бүтән юл сайларга кирәк. Анысын уйлашырбыз. Озаклап яшисе булачак.

Н ә р м и н. Тиз генә эшләнә торган эш түгел.

К а н т р и. Ә сагындыра башласа? Мин әнисез ничек яшәрмен? Анда, Себергә үк япсалар.

С ә г ъ д и. Беренчедән, Себергә япмыйлар, ә сөрәләр. Икенчедән, болай әнкәңне сагына торган булсаң...

К а н т р и. Ноу, мин болай гына.

Н ә р м и н. Шулай да нигә миңа әйтергә булдыгыз?

С ә г ъ д и. Сиңа да бер-икеләп аңлатмый булмас. Беренчедән, син безнең дус, икенчедән, анда, һичшиксез, кыз-хатын кирәк булачак. Өченчедән, син булганда, Кантри әни дип еламас. Һәм башкалар, гомумән, артык күп сораулар...

Н ә р м и н. Аңлашылды. Тик анда ничек итеп озаклап яши алырбыз?

К а н т р и. Әйе, минем анда бөтенләй озаклап ятасым килми.

С ә г ъ д и. Тиз эшне эшләп бетерә алсак, бәлки, тиз дә әйләнеп кайтырбыз. Минем озаклап маташасым килә мәллә?

К а н т р и. Һай, ярабби Ходаем.

С ә г ъ д и. Озак яшәргә туры килсә, мин менә нинди план тәкъдим итәм.

Н ә р м и н. Ес, я, я?

С ә г ъ д и. Без шунда яшәгән татарлар булып урнашабыз.

К а н т р и. Ничек?! Ә?

С ә г ъ д и. Тыңлап бетер. Хәзер безнең долларлар алар-

га су кебек кирәк. Берәр штатта, әй лә, районда диюем, паспортлар, документлар сатып алабыз, аңлашыламы?

Нәрмин. Ес, әйе...

Кантри. Ес, ес, ә баштан сыйпамаслар?

Сәгъди. Борчылма, әйбәт долларлар тасма сыйпарлар.

Нәрмин. Шуннан?

Сәгъди. Без авыл балалары булып, Казанда эшкә урнашабыз.

Кантри. Ничек? Ноу, мин эшли белмим.

Сәгъди. Өйрәнерсең.

Нәрмин. Ә мин?

Сәгъди. Сине укырга урнаштырырга була.

Нәрмин. О' кей! Әйбәт фикер. Чит телләр факультетына. Инглиз теленә. Во!

Сәгъди. Ноу, безнең төп кимчелегебез — без урыс телен белмибез. Сиңа анда күбрәк урысча укырга туры киләчәк.

Нәрмин. Нигә?

Кантри. Нәрсәгә ул урыс теле?

Сәгъди. Менә нәрсәгә: хәзер... менә бу ЦРУ информациясе... Әһә, менә: Татария Россиянең колониясе, күпчелек халкы татарлар. Бик хәерчеләр. Җире бай, ләкин ул байлыклар республикага эләкми. Тормышлары кыргыйларныкы шикелле. Телләрен оныта башлаганнар. Колония буларак, төп тел булып урыс теле урнаша бара.

Кантри. Ай Аллам, без бит анда өч көн дә тора алмыйбыз.

Нәрмин. Чыннан да, бик хөрти бит әле бу...

Сәгъди. Ноу, бу бит әле ЦРУ хәбәре генә. Менә бусы совет передатчиклары хәбәре.

Кантри. Йә, йә?

Сәгъди. Татарстан бик бай табигатьле, ямьле җир. Күпчелек урыслар яши, шуңа төп теле — урыс теле. Азчылык булган татарлар урыслар белән бик дуслар. Интернационализмның дөньядагы иң көчле чагылышын тапкан җир. Чөнки Россия Татарстанны бөтен кирәкле рухи һәм матди байлыклар белән тәэмин итеп тора. Татарлар бар нәрсәдән дә канәгать. Озакламый үз телләреннән ваз кичәргә йөриләр. Татар теле кирәк түгел дип, күптән түгел генә бөтен татар халкы демонстрациягә чыкты.

Кантри. О' кей, ЦРУга ышансаң. Кара ничек һәйбәт яшиләр бит, әй. Тизрәк барасы килеп китте.

Нәрмин. Кайсысына ышанырга инде?

Сәгъди. Ес, менә шул шул. Шуңа күрә безгә урыс телен дә өйрәнергә туры килә.

Кантри. Әйе, үз телләрен алмаштырмасалар, безгә

дә җайлы булган булыр иде. Без монда, Америкада була торып, ничек телебезне саклап калырга белмибез, ә алар...

Нәрмин. Ноу, соң, әйтелгән бит инде, кырылып беткәннәр дип.

Кантри. Ничек кырылып?

Нәрмин. Ничек булсын. Соң, безоннар ничек беткән?

Кантри. О, ес, суйганнар, димәк.

Сәгъди. Бардыр инде, баргач күрербез.

Нәрмин. Ә безнең инглиз акцентын нишләтәбез?

Сәгъди. Ес, бусы да бик мөһим. Мин болай кылыйк дим: анда безнең Финляндиядәге кебек мишәр дигән татарлар бар икән. Без үзебезне шуннан диярбез.

Кантри. О' кей! Ә кайда микән соң ул Мишәрстан?

Сәгъди. Чүпрәле дигән районы бар, ди. Мин белештем инде. Башкаласы Цильна дигән җир икән.

Кантри. Ес! Вәт нәрсәләр бар җиһанда?!

Нәрмин. Алар инглиз акценты белән сөйләшәләрме?

Сәгъди. Аннан да хәтәр, ди. Казан каласында аларның ярты сүзләрен дә аңламыйлар икән. Без хәтта берике инглиз сүзе кушсак та, мишәрләргә ярый дип, уздырып җибәрәчәкләр.

Нәрмин. Менә бусы әйбәт. Ә урысча начар белүне ничек каплыйбыз?

Сәгъди. Сере дә шунда шул. Андагы мишәрләрнең урысчасы да ипилек-тозлык кына икән.

Кантри. О' кей! Булды гына бу! Чукындырабыз болай булса...

Сәгъди. Ярый, төп эшне тиз генә бетерик тә, Рейганны чакырырмын.

Нәрмин. Нигә?

Кантри. Соң, мондый эшне билгеләп үтәргә кирәк.

Сәгъди. Изге эшкә керешәбез, Алла боерса.

Кантри. Амин!

Сәгъди. Аннары шуны яхшылап колагыгызга киртләп куегыз: артык долларлар һәм совет акчасын алмаска! Мин үзем сезне аз-азлап финанслап торырмын. Ни өчен диегез?

Кантри. Ни өчен?

Сәгъди. Шуның өчен, без андагы халыктан аерылып торырга тиеш түгел. Әйтергә кирәк, без начаррак та яшәргә тиеш әле. Хәерче кешене беркем дә чит илдән килгән дип уйламый. Шуңа күрә безнең акча запасы аз булачак. Кием дә искитмәле кирәкми. Шул документлар эшләү өчен долларлар алырбыз.

Кантри. Бик кыен булмасмы?

Сәгъди. Түзәргә туры килер.

Нәрмин. Ес, түзәбез аны. Соң, күз алдына китерегез, менә безнең тормыш. Алар да шулай яшәсә, яртылаш начар булганда да бер дигән яшәргә була.

Сәгъди. Амин.

Кантри. Амин.

Сәгъди. Шулай итеп безгә әзерләнергә бер атна вакыт җитәрме?

Кантри. Аз булмасмы?

Нәрмин. Җитәргә тиеш. Минем тизрәк анда барып җитәсем килә. Кан тарта микән?

Сәгъди. Ес, тартадыр. Бабаларыбыз туган җир бит. Минем үземнең дә күңелем җилкенә.

Кантри. Минем дә, менә кызык.

Сәгъди. Кара, кара моны. Бөтенләй үзгәрде. Әле генә бармыйм дигән идең түгелме?

Кантри (*әтәчләнеп*). Миндә болгар бабам каны уянды.

Сәгъди. Ярый алайса, бер атна әзерләнергә, уйларга. Иртәгә сезгә инглиз-урыс сүзлекләре тапшырырлар. Анысын да өйрәнә торыгыз. Ә мин «Ке. Же. Би.»-га сиздермичә, ничек анда эләгү җаен табарга тырышырмын.

Нәрмин. Бирсен Ходай!

Кантри. Ходай бирсә, Әмерикәдә безнең шикелле кеше булмас!

Нәрмин. Булмас!

Сәгъди. О' кей! Дуслар, эш барып чыкса, беренче эш итеп нишлим?

Кантри. Нишлисең?

Сәгъди. Өйләнәм! Бер матур гына саф мөселман кызын табам да өйләнәм!

Нәрмин. Яратмасаң дамы?

Сәгъди. Әлбәттә, мин аны яратачакмын, күңелем сизә.

Кантри. Кемне?

Сәгъди. Соң, шул кызны. Мин аны күрәм дә кебек. Минемчә, ул минем коткаручым булачак, минем мәхәббәтем.

Кантри. Картлач, син үзең акыллы гына егет, ә кайвакыт әллә нинди мәгънәсез сүзләр сөйләп куясың. Акыллы кеше өйләнә димени? Менә мин һичкайчан өйләнмәячәкмен. Гашыйк булсам да!

Нәрмин. Ноу, син алай димә әле, белеп булмый. Ә минемчә, сөю ул бернигә дә бәйле булырга тиеш түгел. Сөю ирекле булырга тиеш. Минемчә, язмышыңа язган булса, шайтанны да яратып була. Нәрсә диләр әле, күңелең төшсә бакага, күл яныннан китмәссеңме?

С ә г ъ д и. Дуслар, сез теләсә нәрсә әйтегез, мин өйләнәчәкмен.

К а н т р и. Үлсәм дә, өйләнмим! Атабыз дисәләр дә!

С ә г ъ д и. Ярый, тумаган тайның билен сындырмыйк, алдагы уңышлар өчен бер дога. (*Утыралар.*) Рейган!

Х е з м ә т ч е (*керeп*). Тыңлыйм, әфәндем!

С ә г ъ д и. Безгә мәтрүшкәле татар чәе һәм...

К а н т р и. Кыздырган каз...

С ә г ъ д и. Каз юк әлегә.

Н ә р м и н. Һәм сөт. Саф татарча, сөтләп эчик.

К а н т р и. Ес, оригинальс!

Х е з м ә т ч е. Баш өсте! (*Чыгып китә.*)

С ә г ъ д и. Әфәнделәр! Тост! (*Чәйле чәшкеләрне чәкештерәләр. Җырлыйлар.*)

Кабан күле буйларында
Камышлар үсә икән.
Туган якны сагынулар
Үзәкне өзә икән.

К у ш ы м т а:

Су өсләрен тибрәндереп,
Җилфердәп җилләр исә.
Хәзинә эзлибез дигән булып,
Кайтабыз туган илгә.

Бабаларны язмыш җиле
Еракларга тараткан.
Сагындыра туган җирләр,
Еракларда торсак та.

К у ш ы м т а.

Бабаларның олы рухын
Саклаучы оныклар без.
Безгә күчкән җан җылысын
Мәхәббәттә сакларбыз.

К у ш ы м т а.

Ут сүнә.
Авансцена.

И к е  Ц Р У  а г е н т ы  һәм Р е й г а н.

М а к с. Йә, булдымы?

Р е й г а н. Ә акча?

Ч а р л и. Син башта сөйлә.

Р е й г а н. Һе, җайлы гына, ярый мин киттем.

М а к с. Тукта, китмә!

Ч а р л и. Мә! (*Долларлар бирә.*)

Р е й г а н. Юк, юк!

М а к с. Мә тагын.

Р е й г а н. О' кей. Сүз башына җитеп торыр.

Ч а р л и. Сөйлә тизрәк!

Р е й г а н. Кыскасы, сәр, мин аларны бик яхшылап тыңлап тордым.

М а к с. Сузма!

Р е й г а н. Кыскасы, алар болай сөйләштеләр. Сүзне берсе башлады.

Ч а р л и. Кем?

Р е й г а н. Кыскасы, болай килеп чыкты.

М а к с. Син нәрсә, кыскасы да кыскасы...

Р е й г а н. Ничек инде, сөйлим бит. Кыскасы...

Ч а р л и. Уф, ярый, мә тагын! (*Акча бирә.*)

Р е й г а н. Әллә кайчан шуннан башласагыз. (*Тегеләрне читкә алып китеп, тиз-тиз сөйли башлый.*) Беренчесе — алар документларны, карталарны тапканнар.

М а к с. Шуннан, шуннан?

Р е й г а н. Бүлдермә, ату кыскартам.

М а к с. Ноу, бетте, бетте.

Р е й г а н. Икенчесе — алар бер атнадан юлга чыгарга җыеналар.

Ч а р л и. Бик тиз...

Р е й г а н. Аларга озакка сузарга ярамый.

М а к с. Ник?

Р е й г а н. Сезнең эзгә төшкәнегезне сизгәннәр.

М а к с. Ах, чурту-матр!

Р е й г а н. Ни дидең?

М а к с. Сиңа кагылмый. Урысча өйрәнә башладым. Ничек итеп бармакчы булалар?

Р е й г а н. Анысын белмим. Тик шунысын яхшы беләм, алар анда нindидер мишәрләр булып эшкә урнашмакчы булалар.

М а к с. Эшкә урнашырга?!

Ч а р л и. Димәк, озакка җыеналар.

Р е й г а н. Шулай булырга тиеш.

М а к с. Аларны анда ничек табарга?

Р е й г а н. Алар ни... башта нindидер Татарстан дигән җирнең, Чүпрәле дигән илнең Цильна дигән башкаласына юл тоталар.

Ч а р л и. О, ес, беләбез, беләбез, бу бит бөтен дөньяда танылган башкала.

Р е й г а н. Аннан алар Казан дигән шәһәргә юл алачаклар һәм эшкә урнашалар.

М а к с. О’ кей, ярый, аңлашылды. Кара аны, телеңне тешләп кенә йөр. Алар аеруча куркыныч җинаятьчеләр.

Р е й г а н. А, юк, мин берни дә белмим. (*Китә.*)

М а к с. Чарли! Әзерлек N 1. Марш! Бердән, безнең идарәгә яңа көчле япон аппараты кайткан. Ул бик тиз рәвештә татар телен өйрәтә икән. Анда СССРда татарлар республика төзеп, экономиканы бик нык күтәреп, АКШны узып китмәкче булалар, ди. Шуңа күрә «атакай» анда разведканы көчәйтү өстендә эшли. Тиз арада бөтен агентлар да татарча сөйләшә башлаячаклар. Без ул бөек, гүзәл телне өч көн эчендә өйрәнә алачакбыз. Алга, Чарли! Җиңү безнеке булачак!

(*Җыр.*)

Байлык эзләү татарларның
Гомердән килгән чире.
Безнең бурыч, агент Чарли,
Аларның серен белү.

К у ш ы м т а:

Деллу, деллу, деллу һай,
Була инде бу болай,
Алар кача, без тотабыз,
Алар отыла, без отабыз.

Эзләү, табу, тоту, белү
Бу безнең профессия.
Капшау, чоку, күрү, сизү —
Кирәк безгә, дидия.

К у ш ы м т а.

ЦРУның иң атаклы,
Иң уңган агентлары без.
Ни өчен дип сорасагыз,
Без бит татарча беләбез.

К у ш ы м т а.

Без эзләрбез, без табарбыз,
Без тотарбыз, без карарбыз.
Вәт күрерсез, без баербыз,
Вәт күрерсез, дидия.

К у ш ы м т а.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кызыллы-гөлле плакатлар белән тулган «шарашкино» конторасының кадрлар бүлеге. Карт кына, бик ябык гәүдәле, зур күзлек кигән карчык өстәл артында утыра.

Телефон шалтырый.

Аллыгөлия. Әллү! Әллү! (*Бик җитди.*) 5 нче трестның 27 нче төзү идарәсенең 36 нчы СМУның 13 нче участогы каршында төзелгән алдынгы хозрасчетный оешмасының кадрлар бүлеге начальнигы Майбәдәрова Аллыгөлия Бибихәсәновна үзе тыңлый. Ә-ә? Әллү! Бишенче трестның 27 нче төзү идарәсенең 36 нчы СМУының 13 нче участогы каршында төзелгән алдынгы хозрасчетный оешмасының кадрлар бүлеге начальнигы Майбәдәрова Аллыгөлия Бибихәсәновна шәхсән үзе тыңлый! Ә? Шту?! Шту, дим?.. Әллү! 5 нче трестның 27 нче управлениесенең... Ә? Нәчтә?.. Сөйләшә дә белми. Пошла ты, диде, ә кая икәнен әйтмәде... Һай, кешеләр, сөйләшә дә белмиләр. Менә эшләп кара инде син шундыйлар белән.

Ишек шакыйлар.

Да, да, керегез! Проходите!

Безнеңчә киенгән Сәгъди, Кантри, Нәрмин керәләр.

Сәгъди. Гафу итегез, без сезне бик «импертант» эшегездән бүлдек, ахрысы?

Аллыгөлия. Нәчтә?

Сәгъди. Мин әйтәм, гафу итегез, мин сезне бик мөһим эшегездән бүлдем, ахрысы?

Аллыгөлия. Нәчтә дисең?

Нәрмин. Ул әйтә, без сезне бик мөһим эшегездән бүлдем, ахрысы, ди.

Аллыгөлия. Ну нәчтә, дим, нәчтә?

Сәгъди (*пышылдап*). О, ес, аңламый, ахрысы.

Кантри. Беттек, каптык...

Сәгъди. Ноу, каушама.

Нәрмин. Нишлик соң?

Кантри. Инглизчә әйтеп карасак?

Сәгъди. Яхшы, сорри, айнфинк вет вуй сипорейтить йеу фрам вери импортент вуек?

Аллыгөлия. Нәчтә?

Кантри. Беттек. (*Качмакчы була. Аны Сәгъди белән Нәрмин кысып тоталар.*)

Нәрмин. Ә бәлки ишетмидер?

Сәгъди. Кычкырып карыйм алайса.

Аллыгөлия. Нәчтә дисең?

Сәгъди (*якын ук килеп колагына кычкыра*). Мин әйтәм, без сезне бик мөһим эшегездән бүлдек, ахрысы, сорри, гафу итегез.

Аллыгөлия. Ә-ә, күптән шулай диләр аны. Кәнишне, бүлдегез. Оекбаш бәйләп бетерәсем бар.

Сәгъди. Чыннан да, чукраграк бугай. Карале, Нәрмин. Вот даз оек, Нәрмин?

Нәрмин. Ноу, белмим.

Кантри. Берәр бомба-мазар булмасын.

Аллыгөлия. Нәчтә?

Сәгъди. О' кей! Аллага шөкер, чукрак икән. Мин инде каптык дип торам.

Аллыгөлия. Нәчтә?

Сәгъди (*Аллыгөлиянең колагыннан тотып*). Без бик ерак авылдан килгән идек, эшкә урнашырга.

Аллыгөлия. Акырма шулкадәр, чукрак түгел, Аллага шөкер. Сиксән икегә җитсәм дә.

Сәгъди. Нәчтә?

Аллыгөлия. Аллага шөкер, диюем.

Сәгъди. О, ес, шулай икән шул, бик яшь күренәсез, диюем.

Аллыгөлия. Нәчтә?

Сәгъди (*колагына*). Эшкә урнашырга иде.

Аллыгөлия. Ә-ә-ә, ник аны әйтми торасыз. Кайчаннан бирле торасыз, сүзегезне ишетеп, әй лә, тфү, аңлап булмый. Мишәр малайларымы әллә сез?

Кантри (*куанып*). Ес, ес, әйе, без мишәрләр, без мишәрләр.

Аллыгөлия. Әйтәм җирле цыкылдыйсыз, прәме чит илдән килгәннәр диярсең. Хи-хи-хи-хи! Цыкы-цыкы.

Кантри. Ю-ю-ук, без чит илдән түгел.

Аллыгөлия. Нәчтә?

Сәгъди (*Кантрига йодрык күрсәтеп*). Без Цүпрәле ягыннан, бик эшлисебез килә.

Аллыгөлия. Ә-ә-ә, аңладым, аңладым. Авыл малайларыдыр дип уйлаган идем инде аны. Шәһәрнекеләр эшләргә яратмый бит хәзер.

Кантри. Мин эшләргә атлыгып торам. Чыдап булмый.

Аллыгөлия. Нәчтә?

Сәгъди (*тагын йодрыгын селкеп*). Бик эшлисебез килә.

Аллыгөлия. Ә-ә-ә, аңладым. Ни эшли беләсез соң сез?

Сәгъди. Без бөтен төзү эшләрен эшли беләбез.

Аллыгөлия. Кит әле, кайдан өйрәндегез?

Сәгъди. Америкада.

Аллыгөлия. Хе-хе, шаян егет икәнсең, Америкада, хе-хе...

Сәгъди. Ноу, ноу, сорри, ни дим, хе-хе, әйе, мин бик шаян.

Аллыгөлия. Кызык егет әле син, үзең чибәр, гашыйк булып куймасам ярар. Хи-хи-хи...

Сәгъди. Менә анысы кирәкмәс иде. Әти (*елап*) бик нык каешлап, әйтеп җибәрде. Кара аны, малай, кызлар белән йөрмә, диде. Ноу, ноу!

Аллыгөлия. Ярар алайса. Ни, нигә бик төзүче буласыгыз килде соң әле?

Сәгъди. Ес, ес, ни бит, болай әле ул. Теге ни... Ә-ә, ес, әти кечкенәдән төзетеп, борып өйрәтте. (*Газета чыгарып, статья укый.*) Шуңа күрә балачактан, кечкенәдән төзүче булу каныбызга сеңде! Бу изге омтылышны тиз генә туктату мөмкин түгел! Чөнки без комсомоллар! Безнең өчен илебезнең изге, удар төзелешендә катнашу — иң зур теләгебез! Безне якты киләчәккә алып барган коммунистик төзелеш өчен бер нәрсәбезне дә кызганмабыз. (*Газетаны яшерә.*)

Аллыгөлия. Менә бит! (*Сәгъдине кочаклап үбә.*)

Сәгъди. Ә-ә, ни... миңа әти...

Аллыгөлия. Юк! Сез карагыз! Менә бит! Менә бит алар! Менә нинди комсомоллар! (*Тагын кочаклап үбә.*)

Сәгъди. Әти... ни, әйткән иде...

Кантри (*Нәрмингә*). Сәгъди үзенең мәхәббәтен тапты.

Аллыгөлия. Мин бик дулкынланам! Бу тарихи вакыйга! Ә бит күпме сөйлиләр, мөртәтләр! Сезнең эшегез дөрес түгел, сезнең эздән баручы булмас дип. Юк, бетмәгән әле алар, безнең эздән баручылар! Һәм алар... бетмәячәк! (*Тагын кочмакчы була, Сәгъди аның колагына үкерә.*)

Сәгъди. Безнең иң яраткан эшебез җир казу иде.

Аллыгөлия (*үкереп елап җибәрә*). Ай, мин нинди бәхетле! Без юкка яшәмәгәнбез! Бездән соң да үрнәк буын кала.

Нәрмин белән Кантри аптырап телсез калалар.

Аллыгөлия. Ә бит җир казу бик авыр эш бит, бирешмәссезме соң, иптәш комсомоллар?!

Кантри (*чыдаша алмыйча*). О, ес, мин экскаватор шикелле эшлим. Бу минем иң яраткан эшем.

Аллыгөлия. Нәчтә?

Сәгъди (*колагына*). Ул да җир казырга ярата.

Аллыгөлия (*Сәгъдинең иңенә суга, ул чүгеп куя*). Молодцы! Ил сезне мәңге онытмас! (*Сәгъди кулындагы газетаны күреп.*) Бу нинди газет, нигәдер бер дә язуын танымыйм. Комсомол эше буенчадыр инде.

Сәгъди. О, ес, бу... теге... Ә, әйе, камоланосомополомо буенча. Чит язу өйрәнәбез.

Аллыгөлия. Ай-вай! Менә ичмасам!

Сәгъди. Безгә тизрәк эшкә урнашып эшли башларга иде, туган илгә файда китерергә.

Аллыгөлия. Ә, әйе, без аны хәзер. (*Бер кочак төрле бланклар, кәгазьләр чыгара.*)

Кантри. Яшәү, торак мәсьәләсен сора.

Сәгъди. Безгә, кара авыл малайларына, берәр коттедж кирәк булыр инде.

Аллыгөлия. Булыр! Булыр. Ни, бик үк яхшы түгел инде ул.

Сәгъди. Без түзәрбез!!!

Аллыгөлия. Сокланам мин сезгә! Анда бераз караңгырак, тәрәзәсе бер генә, ни, теге яртылаш җиргә иңгән.

Сәгъди. Түзәрбез!!!

Аллыгөлия. Молодец! Анда бераз сулана да инде. За то тараканнар күп түгел, өч төре генә бар, диләр.

Сәгъди (*елардай булып*). Түзәрбез!!!

Аллыгөлия. Менә бит! Сез булганда, без, һичшиксез, якты киләчәгебезгә барып җитәрбез.

Сәгъди. Амин!

Аллыгөлия. Ни дидең?

Сәгъди. Амин...

Аллыгөлия. Менә анысы кирәкми. Комсомолга андый җыен юк-бар... что син.

Сәгъди. Гафу үтенәм, ханым.

Аллыгөлия. Тагын шаярасың, хе-хе-хе... Болай була: монда эшегез беткәч, 13 нче СМУга барасыз, анда документларны тутырасыз, аннан 27 нче төзү оешмасына, анда тутырырсыз, аннан 4 нче трестта да тутырырсыз. Ә хәзер менә боларны тутырыгыз! (*Бер кочак кәгазь бирә.*)

Ут сүнә. Музыка.

Аллыгөлия җыры:

Заманалар үзгәрде дип,
Тормыйм әле утырып.
Таптап безне китмәсеннәр,
Безнең тамыр нык торыр.

Бюрократлар дигән булып,
Җыен саен сүгәләр.

Миңа медаль бирерлек лә,
Эшләгәнне күрсәләр.

Кәгазь өеп, кәгазь җыеп,
Гөрләп үтте гомерләр.
Үлгәндә дә җиргә түгел,
Кәгазь өеп күмәрләр.

Безнең буын бик нык әле,
Безнең буын бирелмәс.
Күпме генә тырышса да,
Бюрократлар кимемәс.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кабан күле буе. Кашына-кашына, алҗыган, йончыган Сәгъди белән Кантри керәләр. Кантри бераз ябыгып та киткән. Алар артыннан Макс белән Чарли күзәтеп киләләр. Алар милиция формасыннан.

Кантри. Булды, җитте, түзәр чамам калмады. Кайтыйк инде. (*Елый башлый.*)

Сәгъди. Ничек кайтыйк инде. Эш бит әле барып чыкмады. (*Кашына.*) Түз инде, түз!

Кантри. Кая түзү?! Бер атна буе бөтен җирдә казынабыз, берни юк. Менә кулларны кара. Шундый идеме алар?! Гомергә көрәк тоту түгел, эш тә эшләгәнем юк иде. (*Кашына-кашына.*) Ябыгып беттем.

Сәгъди. Ноу, синең әле анда җитәрлек. (*Корсагына суга.*) Бу мәчтер дигәне бигрәк бәйләнчек кеше булды. Берничек качып булмый.

Кантри. Сөйләп торма. Анда көне буе җир казы, аннан үзебезнекен. Юк, булмый, мин барып бирелəм йә үләм. (*Китмәкче була.*)

Сәгъди. Син нәрсә?! КГБда аяктан асалар дип үзең сөйләдең.

Кантри. Әни! Әнине сагындым!

Сәгъди. Түз инде, түз. Менә Нәрмин килгәч, үзеңне юатыр.

Кантри. Карале, Сәгъди, ә бәлки, безгә эшкә бөтенләй йөрмәскәдер, ә? Бигрәкләр дә авыр бит. Бездә экскаватор казый, ә монда көрәк.

Сәгъди. Ноу, ярамый. Сизүләре бар. Аннан безгә торырга да урын кирәк бит әле. Мин бер кызыл борынлы абзый белән сөйләштем. Карале, монда барысы да диярлек кызыл борынлы икән. Ул әйтә, эшләмәгән кеше ашамый, ди. Эшләмәгән кешегә бездә «хана» ди. Ул ха-

насы нинди сүздер инде, белмим, ә эшләмичә ярамый. Бу сиңа Америка түгел, монда бар да тырышып эшли.

Кантри. Белмим инде, аягымны сузмасам, тырышам инде анысы.

Сәгъди. Ес, тырыш инде, тырыш.

Кантри. Җитмәсә, ахир, төнен дә йоклап булмый. Ул нәрсәдер кимерә тәнне. Менә әле дә шатыр-шытыр кашынам.

Сәгъди. Әйтмә инде. Үзем дә йөдәдем. Кашына-кашына бөтен тәнне яргалап бетердем бугай инде. Чир генә булмаса ярар иде.

Кантри. Ес! Берәр СПИД ише нәрсә булса, иленә әйләндереп кертмәсләр. Ул килеп чыкты берзаман «Кукарача». Берәүләре озын мыеклы, берәүләре соры, берәүләре йодрык кадәр. Таракан дигәннәре шулдыр инде. Тешлиләр дип котым чыкты.

Сәгъди. Ноу, курыкмасаң да була, мин комендanttан белештем инде. Алар иснәп кенә карый икән. Үзең тимәсәң, тими, ди. Әгәр тисәң, бөтен гаскәрен җыеп килә икән.

Кантри. Комендант дисеңме? Ес, уф Аллам, исемә төшермә. Беркөнне бүлмәдә бик юеш, киемнәр дымлана, киеп булмый дигән идем. Башта нindидер сүзләр белән урысча сүкте. Аннан, гафу ит, апа, дигәч, татарча җиффәрде. Аякларым калтырый башлады, беттем дип торам.

Сәгъди. Ес, анысы бар инде. Исеңдәме, теге экваторга баргандагы шикелле юеш. Бәлки, монда, чыннан да, климат башкадыр.

Кантри. Белмим, нәрсәдер, миңа бу климат үтергеч тәэсир итә.

Сәгъди. Түз инде, түз. Менә хәзер Нәрмин килсә, Кабан күлен тикшерә башлыйбыз.

Кантри. Ес. Түлке мин кермим. Мин йөзә белмим.

Сәгъди. Кермәссең. Сез кеше күрмәсен дип карап торырсыз.

Нәрмин керә.

Йә, хәлләрең ничек, Нәрмин?

Нәрмин. Начар. Тамак туймый. Студент ашханәсендә ашап эчем авырта башлады. Син дә инде, бөтен акчаларны җыеп куйдың да, рестораннарына кереп карар идек, ичмасам!..

Сәгъди. Ноу, ярамый! Без алай фыртланып, акча чәчеп йөри башласак, безнең эзгә хәзер төшәчәкләр. Доллар күрсәтсәң, бигрәк тә. Безгә бик сак булырга кирәк. Аңлыйсыздыр, әләксәк ни буласын.

Кантри. Ес, әһә!

Н ә р м и н. Аңлавын аңлыйбыз анысы. Ашарга берни юк бит. «Меат» урынына әллә нинди «ит» дигән әйбер бирәләр. (*Елап.*) Дуңгызныкын да ашап ташлаганмын ялгыш.

К а н т р и. Син нәрсә? Ничек ашый алдың?

С ә г ъ д и. Ярый, ярый, тынычлан. Монда чучка итеннән башка әйбер юк, әләксә әле. Түзегез.

К а н т р и. Ноу, нигә юк? Тоже бер кызыл танаулы абзый «кильки» маркалы итне бик мактап торганын ишеттем. Ул ниндидер борматуха дигән кыйммәтле шәраб белән бик яхшы үтә икән.

Н ә р м и н. Ниткән шәраб?.. Урыс теленнән бишенче икелемне алдым. Мөгаллим, надан мишәр, дип сүгә. (*Мышкылдый.*)

К а н т р и. Сүксә! (*Кашына.*) Сиңа рәхәт, сине төнлә беркем дә кимерми.

Н ә р м и н. Кимермәс. Ул общага дигән өйдә гел ниндидер дискотека дигән бик шау-шулы мәҗлес уздыралар икән. Безнең бүлмә янында гына. Җир казып алҗыгач, иртә ятам, һәр музыка такты саен ятагым сикереп куя. Аннан (*елмаеп җибәрә*) бик чибәр бер егет минем ишекне шыгырдата, нидер әйтмәкче була. Тик авызы гына селкенә, ә сүзе аңлашылмый. Менә болай! (*Селкетеп күрсәтә.*) Әллә бу чит илдән килгән микән, дип тә уйлап куйдым.

С ә г ъ д и. Ес, йә, йә?

Н ә р м и н. Шул инде. Аннан нигәдер аның күзләре иртән әйбәт була, ә кичкә шакмаклана. Күзләре әйбәт чакта, ул минем ишеккә якын да килми.

К а н т р и. Ничек шакмаклана?

Н ә р м и н. Ноу, ничек дип, менә болай, теге кубик-рубик шикелле була.

К а н т р и. Ә-ә-ә, акая диген.

Н ә р м и н. Юк, ноу, ноу, нишләп акайсын. Ул үзе миңа бик ошый. Менә сөйләшеп кенә булмый. Телен аңламыйм.

С ә г ъ д и. Син, Нәрмин, сөйләшмичә, киңәшмичә әллә кемнәрне ошатып йөрмә. Минем бабайдан ишеткәнем бар иде. Безнең болгар кызлары вә егетләре гашыйк итсәләр, нык гашыйк итәләр, яратсалар, үтереп яраталар, дип.

К а н т р и. Ноу, минем яшисем килә.

С ә г ъ д и. Менә шул шул... Яшисең килсә, аның яныннан китмәскә, гел эт кебек ияреп йөрергә кирәк, ди. Гашыйк булгач аерылып китсәң, бетәсең, ди. Шулай булгач, болай килешәбез: монда татарның кызлары да, егет-

ләре дә бик чибәр. Беркемгә дә гашыйк булмаска! Әнә Америкага кайткач, хет шунда президент кызына да, малаена да гашыйк булыгыз.

Нәрмин. Анда аның андый чибәрләре юк шул. Җитмәсә, саф мөселман, үзебезнең кешеләр.

Сәгъди. Нәрмин, дим! Син ни сөйлисең, ә? Ярамый. Бөтен эшне бозасың. Ярар, алга таба эш планы. Тирәякта кеше-кара юкмы?

Нәрмин белән Кантри каранып киләләр.

Нәрмин.<br>Кантри. } (*Икесе бергә*). Юк.

Сәгъди. Безнең казу эшләре әлегә файда китермәделәр. Мөгаен, яңа йортлар салганда, берәр йорт астында калгандыр. Без ул эшкә кире кайтырбыз. Ә хәзер безнең алда чал Кабан! Нишлибез?

Нәрмин. Чумарга кирәк.

Сәгъди. О' кей! Дөрес. Болай була: сез икегез ике якта каравыллап торасыз, ә мин тиешле урынга йөзеп кереп, төпкә чумып карыйм.

Кантри. Ноу, картлач, күпме казып та табалмадык, монда булыр микән? Бәлки, бу черегән харита дөрес күрсәтми торгандыр.

Сәгъди. Ес. Бәлки. Без башта Кабанны тикшерик, аннан Сөембикә манарасы астын карыйсы булыр, аннан...

Нәрмин. Нәрсә аннан?

Сәгъди. Бик чиста күрсәтелмәгән бер эз бар харитада, ярый, анысы соңыннан. Ягез, Аллага тапшырдык, эшкә. (*Водолаз маскасын кия.*) Ягез, сез урыннарыгызга!

Нәрмин белән Кантри ике якка кача, Сәгъди чыгып китә. Милиция формасыннан ике агент керә.

Макс. Әле генә шушында иделәр, кая югалдылар, ә?

Чарли. О, ес, болар оста эш йөртә, совет разведкасы мәктәбен бетергәннәр диярсең. Койрыкларын да тотып булмый.

Макс. Тизрәк боларның төбенә төшәргә кирәк, югыйсә мин аяк сузам.

Чарли. Син сөйлисеңме, минме, үземнең хәлем элеп киптергән тараканныкы кебек, кием аркылы гына күренми. Бөтен әйбер нindидер талонга, ди, берни бирмиләр. Син ул кильки белән ипинең, азрак булса да, сортларын алмаштыргалап тора алмыйсыңмы?

Макс. Нәрсә, ошамыймы? Хе-хе... Бу сиңа Никарагуа да, Панама да түгел, бушка банан ашап, кофе эчеп

ятарга. Себер, диләр моны. Юкка гына бөек кешеләрне монда сөрмәгәннәрдер инде...

Чарли. Ул квартира «хостессы», хуҗасы теге мадамны әйтәм... Беркөнне, син шундый чибәр, син мондый, син тегенди, дип, почмакка кысып маташа. Качмакчы булам, качып булмый. Куллары көрәк кадәр, үзе ат хәтле, ниндидер база дигән җирдә грузчик булып эшли икән.

Макс. Ес, ес, син нишләп тордың соң?

Чарли. Нишлим? Беттем, дидем дә кулларымны күтәрдем. Кипкән камбала кебек агентны капшаудан нинди файда?

Макс. Тукта әле, чү, әнә теге күлгә кереп киткәнен көймә белән монда алып чыгып киләләр, качыйк.

Гөлсылу Сәгъдине алып чыгып яткыра. Күкрәгенә баскалый, яңакларына чәбәкли. Сәгъди күзен ачкач, сүгә башлый. Үзе бик матур.

Гөлсылу. Сез нәрсә, гражданин, шундый яшь килеш. Беләсегез килсә, ул сезнең генә гомер түгел. Сезне үстергән, яратып яшәүче әти-әниегез хакында да уйларга кирәк. Кирәк бит, ә? Вәт кешеләр! Ну ярар, шикәр юк, ди, сабын юк, ди, башкасы юк, ди... Сабын булмаса, әнә Кабан күленә чумасың да чыгасың. Вахитов заводы анда барыбер порошок суы җибәрә. Иванушка дурачок кебек яшәреп тә чыгасың әле. Бераз яшеле сеңгән инде анысы йөзенә. Ничава, агарырсың. Вәт бит әй, юк өчен шундый чибәр егет әрәм булсын диген! Нәрсә? Нәрсә елмаеп карап торасың?

Сәгъди. О' кей! Сөйләгез, сөйләгез, туташ, зинһар өчен!

Гөлсылу. Кара, кара, үлә язган кеше хәзер мыскыл итеп тора. Туташ, имеш, зинһар өчен... Әйтермен дә, хәзер бездә демократия! Елмаеп торма, үзең уйлап кара.

Сәгъди. Ноу, ноу, сез мадмуазель, мине аңламадыгыз. Мин алар өчен түгел, мин югарырак...

Гөлсылу. Нәрсә? Тагын мыскыллыйсың, мин аны коткарам, ул, мадмуазель, имеш... Шуннан нәрсә, югарырак булсаң ни. Төшереп аттылармы?

Сәгъди. Төшереп дип...

Гөлсылу. Ярый, хәзер сезне кысалар да ди. Ярар, хәзер сиңа обкомда урын калмаган, ди. Ярый, башка халыктан бернинди дә өстенлегең булмас. Дачаларыңны, персональный машинаңны алырлар. Алсыннар, борчылма. Соң, җанашым, шуның өчен генә, обкомны тараталар дип кенә, суга ташланалармыни? Дөнья матур бит, кара! Менә күл буенда камышлар шаулап үсә, менә су чайкала. Кайдадыр моңлы көй яңгырый. Килә, яши, түзә... кеше. Ә син?! Ә үзең шундый сөйкемле, җитмәсә. Йә, аңладыңмы инде, яшәргә кирәк икәнен?

Сәгъди (*баш кагып елмая*). О' кей!.. Ой, ни...

Гөлсылу. Үзе гел шаяра. Шундый күркәм егет, үзе шаян, үзе... Ә үзе әллә ниләр уйлап чыгарган.

Сәгъди. Сез миңа карамагыз. Сез сөйләгез. Менә шулай минем баш очында гел сөйләп торыгыз. Сезнең тавышыгыз шундый ягымлы.

Гөлсылу. Әйе, бик матур итеп сөйләшә торган урын инде бу. Син дә тапкансың батар урын. Сасы Кабанга кергәнче, Иделгә төшсәң булмыймы? Хәер, анысы да... Йә, бераз хәл кердеме?

Сәгъди. Ес, керде. Сез шундый матур кыз, минем мондый матурлыкны күргәнем юк иде әле. АКШта да.

Гөлсылу. Ягез инде, ул кадәр үк түгелдер инде... Аккошлар күптән беткән шул Кабанда...

Сәгъди. Ә сез бирედә ни эшлисез? Кызык: шундый матур кыз, үзе шушында каңгырып йөри.

Гөлсылу. Ә мин кайда булырга тиеш соң? Мин биредә эшлим.

Сәгъди. Ноу... Сез... Сезнең урыныгыз кайдадыр югарыда. Сез аппартаментларда, флигельләрдә күбәләк кебек гөлдән гөлгә кунып, «мерседес»ларда тирә-якка елмаю таратып кына йөрергә тиешле.

Гөлсылу. Ю-ю-юук, сез төзәлә торган кеше түгел икән. Ә үзе шундый яшь. Соң, оныт инде ул обком хыялларыңны, башыңнан чыгарып ташла. Хәлегездән килсә, бөтенегез Көнбатышка китеп, шул машиналарда гына йөрер идегез. Әйтәм бит, дөнья искиткеч матур. Кара, күзеңне ач, егетем!

Сәгъди. Туташ, сез мине кем белән булса да бутыйсыз.

Гөлсылу. Менә, менә! Бу кеше танымау да шул тегеннән калган гадәтең. (*Мыскыллап.*) Гафу итегез, «туташ», мин сезне танымыйм. Хе!

Сәгъди. Сорри, гафу итегез, туташ, сез бик сөйкемле, ләкин бу гүзәллек сезгә мине ниндидер буш «обком» сүзе белән бутарга хокук бирми әле. Мин ул «вуест» турында хыялланмыйм, мин анда яшим, беләсегез килсә!

Гөлсылу. Ә-ә?!

Сәгъди. Ес, ес! Яшим! Һәм ул машиналар, флигельләр турында хыялланмыйм. Мин инде андый чүп-чардан туеп өлгердем.

Гөлсылу. Менә сиңа кирәк булса?! Әй Ходаем, нишләргә инде?.. Инде җанланды дигәндә генә,— здвиг по фазе...

Сәгъди. Нәрсә? Нәрсә дигән сүз ул, туташ?

Гөлсылу. Ничек, шуны да аңламыйсың? Уф Аллам,

чыннан да, харап буласың бит. Тукта әле, син ятып тор. Менә шулай.

Яткыра.

Сәгъди. Ноу, сез нишлисез, аңлатыгыз, зинһар өчен?

Гөлсылу. Хәзер, хәзер! Бер минут кына ятып торыгыз, мин «Скорый» чакырам.

Сәгъди. Ә анысы нәрсә?

Гөлсылу (*елардай булып*). Уф,ниләр генә эшлим. Тагын бер әйтегез әле, сез үзегезне, чыннан да, аннан дип уйлыйсызмы?

Сәгъди. Кайдан, туташ?

Гөлсылу. Соң, шуннан инде, тегеннән?..

Сәгъди. Кайдан, тегеннән?

Гөлсылу. Соң, теге яктан, АКШтан...

Сәгъди. Туташ, хатын-кызга тавыш күтәрү начар эш. Әмма Ходa шаһит, сез мине үзегез мәҗбүр иттегез. Тыңлагыз! Айм, американ татар! Дант мейк проблемс тьюми!

Гөлсылу (*ычкынган дип уйлап*). А-а-а-о-у-а! (*Китә башлый.*)

Сәгъди (*хатасын аңлап, аны туктата*). Ноу, сорри, гафу итегез, туташ, мин арттырыбрак җибәргәнмен, ахрысы. Ни... о, ес, без бүлмәдәш дустым белән инглиз телен өйрәнәбез, театр түгәрәгенә дә йөрибез. Минем үземне сынап кына карыйсым килгән иде.

Гөлсылу (*шыңшып*). Сез шаярасыз, эхе-эхе... Ә мин... Шундый эш белән шаяралар димени... Котымны алдыгыз, мин сине бик... ни, ни идем... Әллә ычкындымы икән дип котым чыкты... Йөрәгем ярыла дип торам... Эх син!

Сәгъди. Сорри, туташ, гафу. Мин бүтән беркайчан да сезне борчуга салмам. Гаеп миндә...

Гөлсылу. Телегез дә сәеррәк. Әллә чит тел өйрәнгәнгәме?

Сәгъди. Юк, юк. Мин бит мишәр малае, катырак җиффәрдем. Тагын бер гафу, туташ.

Гөлсылу. Сезнең мыеклы халыкның гел шул, акылыгыз гел соңга калып йөри.

Сәгъди. Ноу, юк, туташ, бездә бер дә алай түгел, ышаныгыз. Бездә андый дорфалык бөтенләй юк. Безнең семья бик тәрбияле.

Гөлсылу. Тәрбия?! Кайда соң ул хәзер тәрбия?..

Сәгъди. Бездә.

Гөлсылу. Бәлки, бәлки...

Сәгъди. Зинһар өчен, үтенеп сорыйм, туташ, шул «обком» сүзе белән генә мыскылламагыз. Йөрәгемә ярамый.

Г ө л с ы л у. Менә нидә икән хикмәт! Соң шулай ук авыр булдымыни аннан китүләре?

С ә г ъ д и. Хода хакына, туташ...

Г ө л с ы л у. Ярый, ярый. Тик миңа бүтән батмаска сүз бирегез. Яшәү шулкадәр күңелле! Дөнья матур! Бу тормышта бар да бар! Җаның ни тели, шуны ал да рәхәтләнеп яшә бу тормышта!

С ә г ъ д и. Ес, ноу, ничек диим, ни, теге... Әгәр мин тагын бер генә тапкыр кереп чыксам?..

Г ө л с ы л у. Нәрсә? Юк, сез берни дә аңламагансыз! Милиция белән өегезгә кайтарып куймый булмас.

С ә г ъ д и. Ноу, юк, юк, туташ, мин бит шаярдым гына.

Г ө л с ы л у. Уф! Нишләргә инде миңа сезнең белән?! Калдырсам, батарсыз, милиция чакырсам...

С ә г ъ д и. Ноу, юк, юк!..

Г ө л с ы л у. Ярамый. Үзем белән алмый булмый инде.

С ә г ъ д и. Ә, ни, туташ, болай бит әле ул...

Г ө л с ы л у. Нәрсә инде, тагын ни булды?

С ә г ъ д и. Ә-ә-ә, ни... О, ес, әгәр мин сезне үзем эзләп тапсам?.. Адресыгызны калдырыгыз да, ә? Соклануымны яшерә алмыйм, сез шундый чибәр, шундый ягымлы...

Г ө л с ы л у. Стоп! Юк инде, мине хәзер алай гына йомшарта, алдый алмассыз. Минем белән барасың. Ярар, минем башка бәла булгансың икән, сезне общагага түгел, чын авыл өенә алып кайтмый булмас. Мунча керерсез, ял итәрсез. Бу күлдән сеңгән яшеллек белән йөрмәссез бит. Ә безнең «изге чишмә» суын да татысагыз... Ярый, ул турыда соңыннан.

С ә г ъ д и. Юк, туташ, чын күңелемнән. Сез мине киналәмәгез. Сез миңа чыннан да хуш килдегез.

Г ө л с ы л у. Ярый, ярый, ышанам. Вакытны уздырмыйк. Юлга, иптәш, товарищ, бывший «обком» вәкиле.

С ә г ъ д и. Ноу, туташ, зинһар өчен...

Г ө л с ы л у. Бетте, бетте.

С ә г ъ д и (*җырлый*).

Гомер юлларымда башка бүтән,
Синдәй кызны эзләп табалмам.
Җиһандагы бар нәрсәне онытып,
Сиңа тартыла күңелем, багалмам.

К у ш ы м т а:

Күл буйлары дулкын-дулкын,
Чит-читләре камышлы.
Син гүзәлне очратканга,
Рәхмәт укыйм язмышка.

Гөлсылу (*җырлый*).

Күл буйларын бергәләшеп узыйк,
Күл буенда безнең очрашу.
Мәңгелеккә күңелемә кердең,
Мөмкин түгел икән хушлашу.

Кушымта:

Күл буйлары дулкын-дулкын,
Чит-читләре камышлы.
Егет асылын очратканга,
Рәхмәт укыйм язмышка.

Гөлсылу. Киттекме, әфәндем?
Сәгъди. Киттек, мадмуазель! (*Чыгып китәләр.*)

Нәрмин белән Кантри керәләр. Төп башына утыралар.

Кантри. Эзли ул, бар. Оу, ноу, кызлар эзләргә килгән ул, башка бернигә түгел. Әйтәм җирле, өйләнәм, ди.

Нәрмин. Йа Хода, күрәселәр бар икән әле...

Кантри (*мыскыллап*). Гашыйк булырга ярамый, югыйсә ул туташка тагыласың, аерыла алмыйсың, имеш!.. Менә тагылып китте инде, каештагы бульдог кебек. Тфү! Никләр генә килдем! Ник әнкәем-бәгырькәем янында гына калмадым. (*Елый.*) Эх, ес, җүләр балык мин, җүләр. Татар акылы төштән соң шул, американишен татары булса да.

Нәрмин (*башын сыйпап*). Йә инде, йә булды, елама, Кантри, елап берни эшләп булмый. Менә бу хәлдән ничек чыгарга?

Кантри. Ничек, ничек? Ес, беттек инде, каптык! Вөҗүдемә газап эстәп кенә килгәнмен. Себер сөргеннәрендә генә бетәр өчен яралган икән бу газиз башкайларым.

Нәрмин. Себер түгел, дустым, мәшһүр Казан каласы! Горур, хәятлы татарларыбызның башкаласы.

Кантри. Себер түгел... Себердән дә хәтәррәк... Мондый саз-күлне кайда күргәнең бар? Ә мондый хәрабәләрне? Исән-сау әйләнеп кайта алсак, Болгар хәрабәләрендә булдык диярбез инде...

Нәрмин. Кайтырбыз, Алла боерса.

Кантри. Кайтырсың бар. Бездәге зинданнарда да мондагыдан бер егерме тапкырга әйбәтрәк ашаталар. Тараканнар да юк. Калифорниягә кайтып, бер ел төрмәдә утыруың мең өлеш артык.

Нәрмин. О' кей! Анысы өчен кайгырма. Кайт кына, утыртуын утырырлар.

К а н т р и (*куркып*). Нигә?

Н ә р м и н. Әнә өченче көн Сәгъди әйтте бит, кемдер безнең арттан күзәтә дип. Сәгъди әйтә...

Ул арада и к е Ц Р У а г е н т ы аларның артына килеп баса.

М а к с. Сез кемнәр?!

Нәрмин белән Кантри алга капланып егылалар.

Ч а р л и. Документларыгыз?!

К а н т р и. Бе-бе-бе-без бе-бе-белмибез: без кем? Ке-е-ем соң без?

М а к с. Мин дә шуны сорыйм?!

Н ә р м и н. Бе-бе-без эшчеләр. Ә, ноу, ноу, мин эшче, ә ул, әй юк ла, ул эшче, ә мин с-с-студент.

М а к с. Сорри, әфәнделәр, без сезне куркыттык бугай, рәхим итеп торып утырыгыз.

Ч а р л и. Ес, ес, курыкмагыз.

К а н т р и (*яткан килеш*). Боларның да бик әшәке акцент, бездән дә каты мишәрләр, ахрысы.

Н ә р м и н. Алар сергач мишәрләредер, анда ди ул биниһая каты мишәрләр...

М а к с (*ишетеп калып*). Ноу, юк, юк, без Кырым татарлары.

Ч а р л и. Ес, әйе, сез бернидән дә курыкмагыз. Без үз кешеләр. Утырыгыз, сөйләшик. (*Нәрмин белән Кантрига утырырга булышалар.*)

Н ә р м и н. Рәхмәт сезгә, сәр.

К а н т р и. Сенквью! Без бик курыккан идек.

М а к с. Ни дип?

К а н т р и. Сезне Америкадан дип... (*Нәрмин аңа төртә.*) О, ес, ноу. Хе-хе-хе... Америкадагы кебек бандитлар дип... Безнең совет илендә бандитлар юк бит, шуңа бик аптырап калдык. Әйе.

Н ә р м и н. Әйе, шулай шул.

М а к с. Ноу, ес, ес, без бик нык саклыйбыз. Сезнең тынычлыкны саклау безнең бүгенге көндә иң мөһим бурыч!

К а н т р и. Бик зур рәхмәт!

Ч а р л и. Ә хәзер...

К а н т р и. Ә нәрсә? (*Куркып кала.*)

Ч а р л и. Ноу, курыкмагыз. Сез гафу итегез, шулай да без белергә тиешбез, сез кемнәр, ни эшләп йөрисез?

К а н т р и (*Нәрмингә*). Каптык, нишлибез?

Н ә р м и н. Ашыкма әле. (*Макска.*) Карагыз әле җәнабе, безнең бер юлдашыбыз бар иде.

Макс. Ес, без аны күрдек.

Нәрмин. О, ес, менә шуны бер әшәке кыз ияртеп алып китте. Без аны эзләп табарга тиешбез. Ул аңа бозым ясарга мөмкин. (*Максны ишарә белән үзе янына чакырып.*) Без моннан китә алмыйбыз.

Макс. Ноу, ни өчен?

Нәрмин. Менә монда (*инструментлар сумкасын күрсәтә*) бик кирәкле харита белән документлар, аларны сакларга кирәк. Чөнки (*пышылдап*) ЦРУдан агентлар аларны кулга төшерергә йөри, ди.

Макс. Китегез әле! (*Куана.*)

Нәрмин. Әйе! Сез закон саклау әһелләре буларак, шул хаританы саклый алырсызмы? Бу бик мөһим эш.

Макс. Нинди шик булырга мөмкин. Без һәрвакыт халыкка хезмәт итәбез.

Нәрмин. Алайса, без барып эзләп килик, ә сез без килгәнче саклап торыгыз.

Макс. О' кей, һәрвакыт әзер!

Нәрмин. Кантри, киттек.

Кантри. Ничек, кая?

Нәрмин. Алга табан, алга карап.

Макс. Хәерле юл, мадмуазель. (*Китәләр.*)

Чарли. Син нәрсә? Нигә җибәрдең аларны?

Макс (*сумканы селкеп*). Вуи хев ить о-ол нау! Зет ман из он аур хэнде! Бары да булды! Карта безнең кулда! Алар алдандылар! Менә ничек эшли ул ЦРУ!

Чарли. О, ес! Бик яхшы!

Макс. Сез милиция, сез безне саклагыз, имеш. Ха-ха-ха!..

Алар куанып биегәндә, арттан кара костюм, кара эшләпә кигән дүрт кеше чыгып баса.

Беренче кеше. Ребята, помогите нам, одно дело надо закрутить. Мы свои! (*КГБ удостоверениесен күрсәтә.*)

Макс. Ноу, ни дисез? Төшенмим?..

Икенче кеше. Чего, чего? Вы что, по-русски не понимаете?

Чарли (*Макска*). Кара әле, болар нинди телдә сөйләшәләр соң? Әллә инглизчә сөйләшеп карыйкмы соң?

Макс. Әйдә.

Икенче кеше. Что вы шепчетесь?

Макс. Веи, ар гуут фелоуз... Век хев, ногъ вон, эничең рок?..

Беренче кеше. Чего, чег-го? Мужики, они что то болтают, не по-нашему.

И к е н ч е  к е ш е. Проверить надо.
Б е р е н ч е  к е ш е. Ваши документы?
Ч а р л и. Ни, без, без тәти егетләр.
Б е р е н ч е  к е ш е. Ваши документы?
Ч а р л и. Капут... (*Кулларын күтәрә.*)
И к е н ч е  к е ш е. Самозванцы! Позорят легендарный мундир чекиста. А ну, проучить их, ребята!

Музыка астында кыйнап аталар. Макс белән Чарли кәкрәеп төшә.

Б е р е н ч е  к е ш е. Ну что, будем говорить?
М а к с. Без бит начарлык белән килмәдек Америкадан.
И к е н ч е  к е ш е. Человек не понимает. Ребята!

Тегеләрне тагын тукмап ташлыйлар.

Б е р е н ч е  к е ш е. Все! Время! Мы отказываем. Татаринов (*бер агентка*), вызови, оперативку, пусть заберут.
И к е н ч е  к е ш е. Не убегут?
Б е р е н ч е  к е ш е. Нет, они сейчас не в состоянии. (*Китәләр.*)

Бераздан Чарли азрак хәрәкәткә килә башлый.

Ч а р л и. Ой, ой, шеф, үтерәчәкләр безне монда. (*Макска торырга булыша.*)
М а к с. Ой, ычкындым дип торам. Ой-ой-ой, тимә, авырта.
Ч а р л и. Кайтып китик без моннан, Макс, исән чакта.
М а к с. Ноу! Син нәрсә? Атакай, эшне эшли алмасагыз, башыгызны ашыйм, юләрләр йортына яптырам дигәнне оныттыңмыни?
Ч а р л и. Эх шеф, монда бит юләрләр йортындагыдан да начаррак. Монда барысы да юләр бугай. Без нинди начарлык эшләдек соң? Үзебезне бик тәртипле тоттык. Хәтта теге икәү белән дә бик әдәпле сөйләштек.
М а к с. Юк, Чарли, монда эш бүтәндә. Мондагы халык бу форманы бик яратып ук бетерми бугай, безне шуңа тукмаганнардыр. Ә хәзер әйдә, Атакайга хәбәр ит, карта бездә диген.
Ч а р л и (*сәгатеннән антенна тартып чыгарып*). Америка! Америка! Прием! Казаннан хәбәр итәбез!

Ул арада Макс, сумканы актарып, аннан мастерок, бүтән төрле төзү эше коралларын чыгара.

М а к с. Оу, ноу! Дей лайть-туасть! Ах хайваннар, алдап киткәннәр.

Ч а р л и. Һай, бу дөньяда нигә дөреслек юк соң?! Нигә без генә җәфа чигәбез бу дөньяда?

М а к с. Ярар, берни эшләп булмый, безгә тагын аларны эзләргә кирәк булыр.

Ч а р л и. Йа Хода!..

М а к с. Безгә хәзер иң мөһиме, исән чакта бу киемнәрдән котылырга. Йә тагын кыйнап ташларлар. Тегеләр тагын килмәкче булып калдылар бугай. Тизрәк качарга кирәк. (*Чыгып китәләр.*)

Алҗыган Н ә р м и н белән К а н т р и керә.

К а н т р и. Уф, җитте, булды, үләм. Бөтен Казанны актардык, ә ул юк.

Н ә р м и н. Каян табасың инде аны мондый шәһәрдә. Үзебезгә кыймылдарга кирәк булыр. Югалышсак, берсекөнгә шушында ук, Казанча сәгать унбердә очрашабыз, диде бит.

К а н т р и. Үзебез генә?.. Мин куркам. Ул бүлмәгә кайтсаң, ул тараканы, ул коменданты, ул башкасы... Урамда да тынгы юк.

Н ә р м и н. Ярый, шыңшыма. Көн ярымга түзәргә кирәк.

К а н т р и. Ничек түзәргә? Бөтен акча анда. Җитмәсә, бүлмәдә кильки дә беткән чак.

Н ә р м и н. Минем дә юк. Син студент, үзеңне туттырырсың дип мине дә кысты.

К а н т р и. Бөтен акчаны үзенә алды да туташлар белән типтерә хәзер.

Н ә р м и н (*килүче Нургалине күреп*). Кантри, бар әле син, качып тор.

К а н т р и. Нәрсә, әллә милициями?

Н ә р м и н. Әйе.

К а н т р и. Ә-ә, ни, ярый, син үзең җайла инде, яме.

Н ә р м и н. Ес, ярар, бар кач тизрәк.

Кантри кача.
Н у р г а л и керә. Чайкала. Борыны кызыл, күзе шакмак.

Н ә р м и н. О, бу сез икәнсез. Мин нинди мәһабәт кеше килә дип торам. Исәнмесез!

Н у р г а л и. Ау-а-у-у-в-а-у-в-а...

Н ә р м и н. Сез бик оялчан икән. Ул кадәр оялмагыз, тартынмагыз.

Н у р г а л и. А-у-а-у-д-а-у-га.

Н ә р м и н. Ес, чын мәгәр, сөйләшик. Утырыгыз әле. Менә шулай. (*Нургали утыра.*) Минем бик күптәннән сезнең белән сөйләшәсем килеп йөри.

Н у р г а л и. А-у-у-а-у-д-а-у-а.

Н ә р м и н. Сез шундый гаҗәеп итеп тыңлый beләсез. Сезгә сөйләве дә күңелле. Беләсезме, сез ачулана күрмәгез. Шулай да сезнең иртән, күзләрегез шакмакланмаган чагыгыз әйбәтрәк. Ноу, мин сезне гаепләмим. Сез миңа болай да бик ошыйсыз. Безнең анда мондый егетләр бөтенләй юк.

Н у р г а л и. А-у-а-у-в-аг-уя!

Егылып китә, кесәсеннән яртылаш бушаган шешә төшә.

Н ә р м и н. Ах, сезгә начар! Хәзер, хәзер, айн момент! (*Торгызып утырта.*) Ах, мин белмәдем, сез авыру. Бу сезнең даруыгыз, әйеме? Мә, эчегез.

Н у р г а л и. А-у-у-га-у-в-у-а...

Стакан чыгара, аракы салмакчы була. Кулы калтыраганлыктан, сала алмый.

Н ә р м и н. Курыкмагыз! Калтырамагыз, ул әшәке түгел, менә эчеп җибәрегез дә даруны, сезгә җиңелрәк булып китәр.

Н у р г а л и. А-у-а-у-а-у-а. (*Тагын сала алмый.*)

Н ә р м и н. Гафу итегез, әгәр рөхсәт итсәгез, мин сезгә үзем салып бирәм. Ничә тамчы?

Н у р г а л и. А-у-а-у-а-у-х-у...

Н ә р м и н. Бик күп? Күп ярар микән? Ес, ярый салып карыйм. (*Аракы салып бирә, тамчылап.*)

Н у р г а л и (*эчә*). А-у-а-у-а-б-у. (*Тагын шактый гына салып эчеп куя.*) Ф-р-р-р! (*Фырлап башын чайкап кычкырып куя.*)

Н ә р м и н. Ах, сезнең кыланышларыгыз ничек гүзәл!

Н у р г а л и (*азрак рәтләнеп*). С-с-и-н-н к-е-е-ем?

Н ә р м и н. Мин Нәрмин. Таныш булыйк.

Н у р г а л и. Н-и-и-гә?

Н ә р м и н. Минем сезнең белән сөйләшәсем килә.

Н у р г а л и. Ни-и-гә?

Н ә р м и н. Миңа әйтү уңайсыз, шулай да... Сез миңа бик ошыйсыз.

Н у р г а л и. Һе, ошыйсыз... О-ошармын шул. Хе-хе-хе... Мин бик күп кешегә ошыйм. Гупчем, мин уа-уа-хуа!

Н ә р м и н. Ес, ес, сез бөтен кешегә ошыйсыз. Бу шәһәрдәге бөтен кешегә дә диярлек. Ә сезнең атыгыз ничек?

Н у р г а л и. Минем атым юк! Гупчем миңа бәйләнмә. Кит моннан! (*Очкылык тота башлый.*)

Н ә р м и н. Һе, сез шаян икәнсез. Ничек инде ул? Атсыз буламыни?

Н у р г а л и. Менә шул шул! (*Елап җибәрә.*) Атсыз булмый. Менә миңа тракторда эшлә, диләр, ә миңа ат кирәк.

Н ә р м и н. Ес, әйе шул, ат һәркемгә кирәк.

Н у р г а л и. Менә син дә минем яклы. Чөнки минем трактор бар, то есть, бар иде, ә атым юк! Атланып та йөри алмыйм. (*Кешнәп җибәрә.*)

Н ә р м и н. Искиткеч тавыш! Браво! Юк, сез мине аңламадыгыз. Мин сезнең үзегезнең атыгыз, ни инде... Менә минем атым Нәрмин.

Н у р г а л и. А-а, мин бик атаклы кеше!

Н ә р м и н. Мин дә шулайдыр дип уйлаган идем.

Н у р г а л и. Бу дөньяда Наполеон белән Сталиннан кала мин — Нургали!

Н ә р м и н. О, ес, нинди горур исем! Нургали! Нургали, әгәр дә мин сезгә ат табып бирсәм...

Н у р г а л и. Ә-ә, ат?! (*Үбеп ала.*)

Н ә р м и н (*егыла язып*). Сез... сез... мине үптегез?

Н у р г а л и. Ат, ат, ат!!! Димәк, мин атлы була алам?

Н ә р м и н. Әйе, Алла боерса.

Н у р г а л и. Ат, минем ат, ур-ра! Әйдәле, без моны юыйк.

Н ә р м и н. Ноу, ничек? Ул бит әле юк!

Н у р г а л и. Юләркәй, башта юалар, аннан алалар. Кара син аны, син бик яхшы кыз икәнсең, чукынмыш. Минем җанымны аңладың, сиңа да ат бик кадерле икән. Тыңла әле абзаңны.

(*Нургали җырлый.*)

Ат турында хыялланып,
Дәртләнеп йөргән чакта,
Майлы трактор тоттырдылар,
Качып котылдым чак-чак.

Тракторга утыргач ук,
Атны оныт, диделәр.
Бу безнең зур яңарыш,
Җырлап эшлә, диделәр.

Атлы, атлы, атлы, атлы,
Атлы булырмын әле.
Алсу йөзле чибәр белән
Тормыш корырбыз әле!

Н ә р м и н.

Дөнья гизеп йөри торгач,
Таптым бугай язмышның —
Миңа язган яманлыгын,
Миңа язган яхшысын.

Атка исем китми иде,
Хәзер атсыз торалмам.
Барлыгыңны белми идем,
Синсез нишлим, күзалмам?!

Атлы, атлы, атлы, атлы,
Атлы булырсың әле.
Мин сөямен, син дә сөйсәң,
Тормыш корырбыз әле.

Н у р г а л и. Әйдә киттек!

Н ә р м и н. О' кей! (*Кантри качкан якка карап алып.*) Әйдә алайса, мин синең белән җир читенә дә китә алам.

Чайкалган Нургалине култыклап, көчкә-көчкә чыгып китәләр. К а н т р и чыга. Ул бөтенләй бетешкән. Башын ике кулы белән тоткан.

К а н т р и. Ай-вай-вай-вай! Ай-вай-вай-вай! Бетте, бар да бетте!.. (*Башын тотып җиргә егыла.*)

М а к с белән Ч а р л и керәләр. Алар бик хәерче киенгәннәр.

М а к с. Менә берсен тоттык.

Ч а р л и. Ес, булды бу. Инде мин коры калдык дип уйлаган идем.

М а к с. Чарли, торгыз аны. Сорау алабыз хәзер. Алар белән йомшак сөйләшүдән файда юк икән. Каты булырга кирәк. Торгыз!

Ч а р л и (*Кантрины күтәрмәкче була, көче җитми*). Шеф, ул бик юан, күтәрерлек түгел. Бер бочка кильки ашаган диярсең. Булышыгыз, ә!

М а к с. Әйдә алайса.

Кантрины күтәрәләр. Ул яңадан коелып төшә. Тагын күтәрәләр. Тагын коелып төшә.

Чарли, без гаепле түгел, үзең күрәсең. Ул торырга теләми. Мин иң соңгы чиккә җиткәндә генә куллана торган чарага керешергә мәҗбүр.

Ч а р л и. Шеф, кирәкмәс, җәлләгез кешене.

М а к с. Юк, ул үзе гаепле. Кытыкла.

Ч а р л и. Баш өсте.

Кытыклый башлый. Кантри башта акырып, аннан бик көчле итеп көлә башлый, сикереп торып йөгереп йөри. Чарли аны куа. Тотып туктата. Кантри ике кулын күтәреп туктый.

М а к с. Тәк, тәк, иптәш жулик, бездән кача алмыйсың, килеп каптыңмы?

К а н т р и. Сез кем?

Макс. Танымаган буласыз? Яхшы. Танытырбыз. Чарли!

Чарли. Ес...

Макс. Кытыкла.

Кантри. Ноу, юк, кирәкми. Чынлап әйтәм, мин сезне белмим.

Макс. Белмисез? Ә менә монда безне буш сумка тоттырып алдап киткәнегезне оныттыңмыни?

Кантри. Димәк, сез милиция? Хе-хе-хе!.. Ноу, ә, бу нинди кыяфәт соң? Хе-хе-хе!..

Чарли. Көлә-ә-ә?

Макс. Көлмә, зинһар. Тәк, хәзер сорау алу башлана.

Кантри. Ес, рәхим итегез. Мин инде куркасын куркып бетердем. Эч авырта, ябыктым, баш әйләнә, тән кычыта...

Макс. Син читкә борма, сорауларга җавап бир!

Чарли. Кытыклыйм!

Кантри. О, мама мия, рәхим итегез, дидем бит...

Макс. Дусларың кайда? Карта кайда? Байлык кайда?

Кантри. Дусларның кайда икәнен белмим. Байлык? (*Кесәсен әйләндереп селки.*) Юк. Ә нинди харита?

Макс. Ноу, бorгаланма. Теге кызыкай әйткән, байлык эзләү картасы?..

Кантри. Ул кыз ни әйткәндер, белмим. Минем ул хаританы тотканым да юк.

Чарли. Күргәнем дә юк дисең инде алайса? Кытыклыйм!

Кантри. Әни! Әнигә әйтәм! Мин күргәнем юк димәдем, тотып караганым юк, дидем.

Макс. Алайса күрдең?

Кантри. Күрдем. Соң, күрүдән ни файда? Бернием юк. Дуслар ташлап качтылар.

Макс. Димәк, син дә безнең кебек бер мескен, мәхлук. Кызганыч, Чарли, тагын өметләр акланмады.

Чарли. Җибәрәбезмени?

Макс. Ноу, монысын эзләп тегеләре килеп чыкмасмы?

Кантри (*калган шешә белән стаканны күреп*). Кайгырмагыз, егетләр. Әйдәгез, кайгыларны юыйк.

Чарли. Әллә? Юктыр ич?!

Кантри. Ес, бар, бар! (*Шешәне ала.*)

Макс (*уйланып*). Эчәргәме, әллә эчмәскәме? Менә сорау нәрсәдә? Тагын урыс әйтмешли, «запой» китмәсме? Әй, беткән баш беткән, әйдә сал!

Кантри (*сала*). Мәгез, товарищи!

Макс (*эчә*). Кабарга берни дә юкмыни, әфәнделәр? Өч көн ашаган юк, исертер.

Ч а р л и. Исертсә, бу мәхшәрне бер кичтә булса да, онытып торырбыз.

М а к с. Ес, карап йөрсәң, акылдан шашарлык бит монда. Ярый әле, кара күзлек бар, ул ярдәм итә.

К а н т р и (*тагын салып*). Мәгез, әфәндем. (*Чарлига бирә.*)

Ч а р л и. Ах, урыс аракысы шәп шул!

К а н т р и. Ес, шәп, шәп!..

М а к с. Әйдәле үзең.

К а н т р и. Хәзер, хәзер. (*Аз гына сала.*) Сезнең исәнлеккә! (*Тегеләр күрмәгәндә, җилкә аша ыргыта.*) Ох, көчле!..

М а к с. Көчле шул. Яле, тагын берне сал әле.

К а н т р и. О' кей, мәле, әфәндем. (*Сала.*)

М а к с. Яшәсен Аме... ә, ноу, тостсыз да әйбәт үтә икән. (*Эчә.*) Ох! Яшисе килә бит, джентльменнар!

К а н т р и. Мәле, син дә яшәреп кит әле, әфәндем.

Ч а р л и. Каяле! (*Эчә.*) Охо, ес, дөнья түгәрәк, яшик дуслар бергәләп, татар әйтмешли.

М а к с. Ес, син шигырь дә яза башладың.

Ч а р л и. Ә син ни уйлаган идең. Ни өчен урыс белән татарда атлаган саен шагыйрь. Алар гел аракы эчәләр. Ә менә...

М а к с. Егетләр, ашарга берәр нәрсә дә булса...

К а н т р и (*куанып*). Мин хәзер алып киләм.

Ч а р л и. Ноу, син, син товарищ, качарсың.

К а н т р и. Ес, алайса бармыйм. Егетләр, берәрне тотыйк та җырлыйк әле. (*Эчәләр.*)

М а к с. Син... слушай, гомумән, яхшы е-е-е-гет икән үзең. Җырлыйбыз, Чарли.

Кирәкмәгән алтын эзләп,
Азапланганбыз күпме,
Урыс аракысы бик шәп,
Әллә эчкәнең юкмы?

Деллу, деллу, деллу, һай,
Була инде бу болай.
Эч тә исер, көл, тәгәрә,
Кайгы онытыла бугай.

Татарларның да кайбере
Яхшы егетләр икән.
Чын күңелдән кунак итеп,
Безне исертеп киткән.

Деллу, деллу, деллу, һай,
Була инде бу болай:

Бәхет хәзинәдә түгел,
Аракыда була бугай,
Деллу, деллу, деллу, һай...

Макс. О' кей, дускай, тагын сал әле.

Чарли. Сал, диләр! Э-э-э, кайда бу? Качкан!

Макс. Ах, тагын утырттылар. Ноу, шайтаныма олаксыннар. Мин бүген бәхетле, Чарли. Әйдә, җырлап кайтабыз.

Чарли. Әйдә, дустым... (*Җырлап чыгып китәләр.*)

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Яшелчә кибете эче. Кассада кассир утыра. Аның янына Сәрвәр чыга.

Сәрвәр. Ул бәрәңгене нишләтергә инде? Череп беткән.

Кассир. Нишләтәсең? Тутырыгыз бөтенесен бергә пакетларга да, бәйләп куегыз. Пакетта булгач алалар аны.

Сәрвәр. Пакетта дип, бигрәкләр дә начар бит инде. Кеше ашарга дип ала, ә без...

Кассир. Сеңлем, практикага килгәнсең икән, өйрән. Болай аңгыраеп йөрсәң, гомергә дә кибетче дәрәҗәсенә үсеп җитә алмассың.

Сәрвәр. Без бит үзебез әйбәтен генә сайлап алабыз. Әйбәтрәкләрен сайлап алыйк та...

Кассир. Әйбәтрәкләрен сайлап алыйк, имеш?! Әнә әйбәтрәген базарга яисә Америкага барып алсыннар.

Сәрвәр. Апа, черегәне барыбер списать ителәдер бит аның?

Кассир. Юк! Списывать ителми! Соң, җаным, ул техникумда нәрсәгә генә өйрәтәләр соң сезне? Списать иткәч, акчаны ничек эшләмәкче буласың?

Сәрвәр. Аннан акча эшләп буламыни?

Кассир. Вәт менә! Кемнәрне җибәрәләр бит! Укытып, стипендия түләгән булалар тагын аларга. Берни дә белмиләр. Соң, сатып бетергәнен списывать итәбез дә инде, аңладыңмы?

Сәрвәр. Бу — алдау була бит.

Кассир. Хочешь жить, умей вертиться, ди урыс. Безне алдыйлар ич әле, иң матур, иң бай илдә яшибез дип, без нигә алдамаска тиеш?

Сәрвәр. Мин алай булдыра алмыйм.

Кассир. Әй, нәрсә лыгырдап торам соң, вакыт әрәм итеп. Ана сөте белән кермәгәнне, тана сөте белән кермәс. Барыбер аңламыйсың. Ничава, эшли башлагач, оятың

качкач өйрәнерсең. Һәрнәрсәнең үз вакыты. Бар, хәзергә синең урының бәрәңге арасында, тагын бер тапкыр шуны аңлаттың.

К а н т р и килеп керә.

Менә кара, хәзер пакеты белән ала да китә. Алар иялашкәннәр инде. Берсе дә күктән төшмәгән. Бар, берничә пакет алып чыгып куй.

Сәрвәр китә. Кассир бизәнә башлый.

К а н т р и. Әссәләмегаләйкем!
К а с с и р. Чего? Җүнләп сөйли белмисең мәллә, ат чырай, нәрсә кирәк?
К а н т р и. Исәнмесез. Миңа...

Сәрвәр бәрәңге чыгара.

К а с с и р. Нәрсә сузасың селәгәй кебек, ни кирәген ал да сыпырт, күрәсең ич, эшне бүлдең. (*Бизәнә.*)
К а н т р и. Миңа бәрәңге кирәк иде. Килькигә кушып ашасаң, тәмле була, диләр. Сездә нинди сортлары бар? Арчылганын, туралганын күрсәтегез.
К а с с и р. Нәрсә?! Син нәрсә, ычкындың мәллә? Әллә психбольницадан качтыңмы, чучка танау... Мыскыл итеп тора тагын. Америкадан килгән диярсең. Арчылганын, туралганын аңа. Мә, тот! Сезне иркәли-иркәли, шушы хәлгә китереп җиткердек инде. Сөйләшүләренең дә рәтләре юк. Гел кибетчене мыскыллау уйлары.
К а н т р и. Зинһар, гафу итегез, мин сезне эшегездән бүлдерергә уйламаган идем.

Сәрвәр читтән аның сабырлыгына шаккатып карап тора.

Алайса, арчылмаганын, берничә сортын күреп булмасмы?
К а с с и р. Тагын мыскыллый. Булмас!!! Әнә пакетта, ал да ычкын. Милиция чакыртмас борын.
К а н т р и. Ноу, бетте, бетте, чакырта гына күрмәгез. Миңа ярый, ниндиләре булса да.
К а с с и р. Җитте! Каян килгән Америка татары. Гафу итегез, чакырта күрмәгез, имеш. Давай, давай, ал да күземә күренмә, бөтен нервамны чыгарды. (*Валидол каба.*)
К а н т р и (*бәрәңгене карап*). Бу ни?
К а с с и р. Нәрсә тагын? Нәрсә акайдың?
К а н т р и. Бу бәрәңгегә охшамаган.
К а с с и р. Нәрсәгә охшаган соң, әллә...
К а н т р и. Бу нindидер пычрак боткага охшаган. Гафу үтенәм, ләкин мин ботканы бик үк яратып бетермим.

К а с с и р. Һе, ну дает, яратып бетермим. Бу — бәрәңге, ал да ычкын!

К а н т р и. Миңа бүтән сорты алайса.

К а с с и р. Юк бүтән сорты!

К а н т р и (*елап*). Соң, җанашым, мин моны ашый алмыйм, яратмыйм.

К а с с и р. Яратмыйм, имеш. Яратмасаң, алмыйсың. Унике тиенгә сиңа... Хәзер унике тиенгә нәрсә алырсың. Американың колорадский жугы да килеп кунмый.

К а н т р и. Сез, зинһар өчен, аңлагыз, мин бик ач...

К а с с и р. Без үзебез дә бик ач, әнә эчем аркага ябышкан. (*Юан корсагына суга.*)

К а н т р и. Ноу, мин сорыйм, минем белән алай сөйләшмәскә! Сез (*Сәрвәргә*) күреп торасыз, мин шикаять бирергә мәҗбүр.

К а с с и р. Ә, ни, безнең книжка...

К а н т р и. Мин мәҗбүрмен.

Сәрвәр кереп китә. М ө д и р чыга. Ул тагын да юан.

М ө д и р. Ни булды? Нигә тавышланасыз?

К а с с и р. Ангелина Шәкуровна, менә бәйләнә. (*Күз кыса.*)

К а н т р и. Мин бәрәңге алмакчы идем...

М ө д и р. Ә-ә, бәрәңге, менә ич бәрәңге.

К а н т р и. Ноу, ничек диим, минем мондый бәрәңгене ашаганым юк шул. Иялләшмәгән көе эчемә ярамас дип куркам.

М ө д и р. Сәер. Без барыбыз да шушындый бәрәңге ашыйбыз. Менә минем үземә бик ошый. Ярар, алай булгач, сезнең өчен бүтәнен табарбыз. Сез нигә аны баштан ук әйтмәдегез?

К а н т р и. Мин әйткән идем.

М ө д и р (*елмайган булып*). Димәк, аңлатып әйтмәгән булгансыз. Хәзер алып чыгабыз без сезгә.

Кассир белән кереп китәләр. Ул арада С ә р в ә р әйбәт бәрәңгеләр алып чыга.

С ә р в ә р. Сез гафу итегез инде, бик күңелсез килеп чыкты. Менә болары ярармы?

К а н т р и. О' кей! Рәхмәт! Менә мондыен ашаганым бар. Сез бик ягымлы. Бу каладагы бер кешегә дә охшамагансыз.

С ә р в ә р. Сез дә. Мин, сез сөйләшкәндә, кассир апа өчен уңайсызланып тордым. Сез аңа ачуланмагыз инде. Аның тормышы авыр, ире эчкече, өч баласы...

Кантри. Ноу, нигә ачуланыйм, ул шундый ачык апа.

Сәрвәр. Сезнең сөйләшүегез шундый ягымлы. Минем гомердә алай сөйләшкән егетләрне күргәнем юк иде әле. Әйтерсең чит илдән килгәнсез.

Кантри. Юк, юк, мин моннан. Минем бик тә карыным ачкан иде.

Сәрвәр. Ашханәгә керергә акчагыз юкмы?

Кантри. Гафу, мин анда ашый алмыйм. Анда ашасам, нитә... эч китә...

Сәрвәр. Ой, әйтмәгез инде.

Кантри. Миңа шул хәзер кильки белән бәрәңге булса, мин әле яшим Алла боерса, ашказаным иләшәште инде.

Сәрвәр. Ничек? Сезнең кильки белән бәрәңгедән башка әйбер ашаганыгыз юкмы?

Кантри. Ике атна инде.

Сәрвәр. Сез бик яхшы кешегә охшагансыз. Әгәр авырсынмасагыз, менә бу адрес белән килегез. (*Адрес яза.*) Мин сезгә авылдан килгән каз белән шулпа пешерермен.

Кантри. Ә? Каз?! Шулпа?! Ән-и-и! (*Һуштан язып егыла.*)

Сәрвәр. Ни булды? Торыгыз, торыгыз. (*Нашатырь иснәтә.*) Сез бик ачуландыгыз бугай, мин сезне ошатканга күрә генә чакырган идем. Теләмәсәгез...

Кантри. Ноу, юк, бик телим. Тик шунысы гына кызык. Сез шундый сөйкемле кыз. Миңа, шундый килбәтсез кешегә, ачык чырай күрсәтәсез.

Сәрвәр. Юк, юк, үзегезне алай кимсетмәгез. Сезнең күңелегез искиткеч, мөгамәләгез яхшы.

Кантри. Рәхмәт сезгә, сез бу дөнья кешесе түгелдер, сез фәрештә.

Сәрвәр. Ой, исемегезне дә белмим, күпме сөйләшәбез...

Кантри. Ес, мин Кантри, ә сез?

Сәрвәр. Кантри! Нинди матур һәм ят исем. Мин — Сәрвәр. Ә сез кайдан?

Кантри. Сәрвәр! Гаҗәеп исем. Беләсезме, минем гомердә дә алдаганым юк, шуңа сезне дә алдыйсым килми. Беләсезме, мин сезгә чын дөресен каз ашаганда сөйләрмен. Ярый, хушыгыз.

Сәрвәр. Зинһар, ашыкмагыз. Черек бәрәңге арасыннан чыгып шушындый сөйкемле егет белән сөйләшүе үзе бер бәхет.

Кантри. Ни бит әле, мин бит...

Сәрвәр. Сез нидер әйтмәкче буласыз бугай. Әйтегез, әйт.

Кантри. Әй лә...
Сәрвәр. Әйтегез инде...
Кантри. Оялам.
Сәрвәр. Нәрсәдән?
Кантри. Кызлар белән сөйләшкәндә.
Сәрвәр. Миннән оялмагыз. Сез бик ягымлы, һәм сез ни, бик әйбәт. Ә, әйе, син кибеттә булганга ояласыңдыр. Ә кайда сиңа кызлар белән сөйләшүе җайлы?
Кантри. Ни, каз дип...
Сәрвәр. Ә-ә, каз ашагандамы? Булды гына, мин сезгә шундый каз пешерермен, м-м-мах!
Кантри. Ноу, туташ, шул сүзегез белән бөтен күңелемне иләсләндерәсез, зинһар өчен, җәллэгез! Сау булыгыз!
Сәрвәр. Ярый, Кантри, мин көтәрмен. Мин сезгә ышанам.
Кантри. Мин килермен. Кызык, гүя мин сезне гомер буе белгәнмен.
Сәрвәр. Миңа да шулай тоела. (*Җырлый.*)

Назлы җилләр сыйпап үтә
Чәчләреңнең көдрәсен.
Уйларымда гел син генә,
Төшләремә керәсең.

Кушымта:

Җан-җанашым, сине уйлыйм,
Ай җаным, дип уфтанам.
Сине көтеп күзем тала,
Синнән башка торалмам.

Кантри. (*Җырлый.*)

Ноу, ноу, ноу, җанашым,
Ес, ес, ес, торалмам.

Сәрвәр.

Кояш чыгып бер елмайса,
Син икән, ди хыялым.
Алсу йөзең тулып янса,
Куанып мин туялмыйм.

Кушымта:

Җан-җанашым, сине уйлыйм,
Ай җаным, дип уфтанам.
Сине көтеп күзем тала,
Синнән башка торалмам.

К а н т р и.

Ай, ай, ай, җанашым,
Вай-вай, вай, торалмам.

С ә р в ә р.

Күлдә үскән төнбоектай,
Син күлемдә атасың.
Әллә уйныйсың гынамы,
Әллә чын яратасың.

К у ш ы м т а:

Җан-җанашым, сине уйлыйм,
Ай җаным, дип уфтанам.
Сине көтеп күзем тала,
Синнән башка торалмам.

К а н т р и.

Син, син, син, җанашым,
Мин, мин, мин, торалмам!

М ө д и р белән к а с с и р чыга. Кантри бәрәңгесен сумкасына яшерә.

К а с с и р. Мә, тыгын. Үземә дигән бәрәңгене аласың, җир бит!

М ө д и р. Зәмзәмия, җитте! (*Елмаеп.*) Менә сез теләгән бәрәңге.

К а н т р и. Нәрсә? Аңламадым? Ә-ә-ә, бәрәңге. Ноу, юк, миңа бәрәңге кирәкми. Сез аны гел менә монда тотыгыз. (*Бәрәңге тартмасына күрсәтә.*) Хушыгыз!

С ә р в ә р. Сау бул, Кантри. Мин көтәрмен.

К а н т р и. Сау бул, Сәрвәр. Мин, һичшиксез, каз ашарга, әй лә, ноу, сезнең янга килермен.

Китә. Сәрвәр кереп китә.

К а с с и р. Әллә?

М ө д и р. Әллә-мәллә?! Шуны да юмалый алмагансың.

К а с с и р. Мин шулхәтле юмалап карадым, күнмәде.

М ө д и р. Ярар. Бу тегеннән булмасын. Бәрәңгене дә алмады. Бөтен дефицитны яшерергә кирәк. Черегән бәрәңгене аерсыннар, сак бул!

К а с с и р. Яхшы. Мин хәзер һәрберсенә елмаеп кына торачакмын. Үзем бәрәңге ашамасам ашамыйм...

М ө д и р. Черегә дә ярый инде безгә.

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәгъди. Йә, авторны күрә алмадыгызмы?

Кантри. Дөнья бетереп эзләдем, юк.

Нәрмин. Ул хәзер монда килеп җитәргә тиеш.

Кантри. Ничек?

Нәрмин. Шулай.

Сәгъди. Ноу, Кантри, тинтерәтмә аны, хатын-кызның мең төрле хәйләсе бар аның.

Нәрмин. Ес, шулай булмыйча.

Сәгъди. Безгә аны, һичшиксез, күрергә кирәк. Чөнки бутала башладык. Бөтенләй буталганчы, аның белән киңәшеп алырга иде.

Кантри. Бутала күрмик инде. Әни сагынып беткәндер инде. Үзем дә. (*Күзләре яшьләнә.*)

Сәгъди. Ноу, әле бит буталмаган. Менә әле баеп китәрсең.

Кантри. Белмим инде...

Нәрмин. Чү, әнә кемдер килә, качыгыз. (*Качалар.*)

Автор керә.

Автор. Исәнмесез, дуслар! Качмагыз, бу мин. Йә, ни хәлләрегез бар?

Сәгъди. Ә-ә-ә, сезмени. Саумысез. Хәлләр мактанырлык түгел анысы.

Автор. Ни булды?

Кантри. Карын ач, ашарга юк. Ул кильки ашыйашый кеше янына килеп булмый. Башта ник бездән качалар дигән идем, аннан аңладым. Сасып беткәнбез икән инде. Эх, бер туйганчы ашасам, алтыны да кирәкми.

Автор. Гафу итегез, дуслар, менә анысын эшләп булмый. Түзәргә кирәк, түзмәсәк, бар да җимерелә.

Нәрмин. Нәрсә җимерелә?

Автор. Пьесаның структурасы. Аннан хәзинә табу тагын да авыраячак.

Нәрмин. Аңлашыла. Алайса, менә бу урыс телен миңа тиз генә өйрәнгән итеп язып булмыймы? Икелене бигрәк күп куялар, орышалар, җитмәсә. Стипендия дә юк. Сәгъди дә кыса.

Автор. Анысы да ярамый шул. Ышаныгыз, мин сезнең өчен булдыра алган бөтен максималь мөмкинлекләрне тудырырга тырышам. Ләкин, үзегез күреп торасыз, безнең илнең мөмкинлекләре шулай гына. Ә миңа чынбарлыкны бозу зур гөнаһ. Тамашачыны алдарга ярамый. Бу — сәхнә законы.

Сәгъди. Ес, ярый, түзәрләр. Иң кыены шул, без хәзер,

сез әйткәндәй, структурада бутала башладык. Нәрмин әнә әллә ниткән шакмак күзле сакау егеткә гашыйк булды. Аны хәзер ничек айнытасың?

Н ә р м и н. Ноу, ярар, үзең кем артыннан чаптың соң? Бәйдәге эт кебек.

К а н т р и. Шауламагыз әле, монда минем язмыш хәл ителә.

С ә г ъ д и. Безнең язмыш.

А в т о р. Алга таба нишлик дигәннән, минемчә, Сәгъди сиңа Гөлсылу белән очрашып, изге чишмә буенда барын да аңлашырга кирәк.

Н ә р м и н. Менә әйттем бит, кеше сөйләгән була.

К а н т р и. Ес, гел аңа по блату, бөтен яхшы сәхнә.

А в т о р. Ялгышма, Кантри. Дөнья бит ул куласа, син дә уңарсың әле. Ярый, җәмәгать, тамашачыларның кадерле вакытын сузмагыз, дәвам итәргә кирәк. Әйдә, Сәгъди, Аллага тапшырдык,

С ә г ъ д и. О' кей! Ярый, дуслар, әйдәгез башлыйк. (*Чыгып китәләр.*)

Чишмә буендагы сәхнә. Авансценада ө ч д у с. Җырлыйлар.

Кабан күле буйларында
Өч дус йөри тинтерәп.
Тамак та ач, хәзинә юк,
Качыйк мәллә тизрәк?

Су өсләрен тибрәндереп
Чумдык Кабан төбенә.
Тыныч тормыш, әнкәй бәгырем,
Керә хәзер төшемә.

Казан каласы таш кала,
Өч дус өчен артык зур.
Эзләнмәгән җир калмады,
Ул хәзинә юктыр ул.

Су өсләре тынып калгач,
Манараларга мендек.
Байлык эзләп әллә нинди
Маҗараларга кердек.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

**Чишмә буе. Сихри матурлык, ямь булырга тиеш. Сандугач сайрый. Ерактан уфылдаган Сәгъди тавышы ишетелә. Сәгъди белән Гөлсылу керәләр.**

Гөлсылу. Түз инде, түз, егетем, ерак калмады, тагын бер чакрым гына.

Сәгъди. Ес, түзүен түзәм дә, атлавы авыр бит. Кара инде, ә? Көтмәгәндә сиңа бәла булдым бит.

Гөлсылу. Юкны сөйләмә. Бәла аяк астында йөри ди.

Сәгъди. Минме инде ул?

Гөлсылу. Юк инде. Соң бит ярдан төшкәндә генә каерылды түгелме соң аягың?

Сәгъди. Әйе, һич көтмәгәндә сиңа йөк булдым.

Гөлсылу. Юк, юк, нинди йөк ди! Кая, аягыңны карыйм әле.

Сәгъди. Ноу, ярый инде, туташ, үтәр.

Гөлсылу. Юк, хәзер үк кысып бәйләп куярга кирәк. Каяле. (*Аягын карый, бәйли башлый.*)

Сәгъди. Ой!

Гөлсылу. Авыртамы?

Сәгъди. Түзәрлек.

Гөлсылу (*бәйли-бәйли*). Сине калдырасы калган икән. Бездә ошадымы соң?

Сәгъди. Бик. Әниең шундый ачык, ягымлы ханым.

Гөлсылу. Ханым. Хи-хи-хи...

Сәгъди. Әйе. Ә ул мунчагызның рәхәтлеге. Искиткеч.

Гөлсылу. Әйтәм өч сәгать буе чыга алмый яттың.

Сәгъди. Ә ул чәйнең тәмлелеге. Во! Минем андый тәмле чәйне гомердә эчкәнем юк иде әле.

Гөлсылу. Индийский, высший сорт.

Сәгъди. Ноу, бездә индийскийның 99 сорты бар, барыбер алай тәмле түгел.

Гөлсылу. Тагын шаяртасыңмы? Каян килсен ди инде туксан тугыз төре. Әле бертөрлесен тапсаң да әйбәт. Казанда бер тартмасы өч сум тора.

Сәгъди. Юк, чын, ихластан әйтәм.

Гөлсылу. Сәгъди, кайчан син алдашудан туктыйсың, ә? Онытылып китәсеңме?

Сәгъди. Ә-ә, ес, онытылып китәм икән, хи-хи-хи!..

Гөлсылу. Ул шаяруларыңмы, алдашуларыңмы, шундый туйдыра башлады инде.

Сәгъди. Гафу, туташ!

Гөлсылу. Ярар, булды. Ә беләсеңме, чәйнең тәмлелегенең сере нәрсәдә?

Сәгъди. Нәрсәдә?

Г ө л с ы л у. Чәйгә суны без менә моннан, изге чишмәдән алабыз. Менә кара, нинди чиста, саф чишмә.

С ә г ъ д и. Шушында хәтле килепме?

Г ө л с ы л у. Килсә. Аның урынына чәе ничек тәмле.

С ә г ъ д и. Анысы дөрес, бик тәмле. Минем чын суын татып карыйсым килә.

Г ө л с ы л у. Әйдә алай булгач. (*Су эчерә.*)

С ә г ъ д и. О' кей! Ә-ә-әх! Ай-яй тәмле! Җаннар сихәтләнеп китте. Әйтерсең канатлар үсте. Ха-ха... Мин очам! Минем очасым килә!

Г ө л с ы л у. Чәү, чәү, мине калдырып китмә тагын.

С ә г ъ д и. Ноу, Гөлсылу алтыным! Мин синсез ничек очыйм, без бергә очабыз.

Г ө л с ы л у. Чынлапмы! Ур-ра! Без бергә очабыз.

Кулга-кул тотынып әйләнәләр. Сәгъди аяк авыртуын оныта.

С ә г ъ д и. Гөлсылу! Җаным! Мин киләчәк тормышымны синнән башка күз алдына да китерә алмыйм.

Г ө л с ы л у. Сәгъди, мин сиңа ышанам да ди, ләкин бит әле без бер-беребезне бик начар беләбез.

С ә г ъ д и. Ой-ой, ой, аягым! (*Егылган була.*)

Г ө л с ы л у. Һай Аллам, Сәгъди, ни булды?

Сәгъди һушсыз булып кылана.

Җаным, бәгырем, минем аркада гына харап буласың бит. Нишләргә?! (*Елардай булып.*) Зинһар, ачуланма, җанашым, мин синсез тора алмаячакмын. Мин мәңге синеке булырга тиеш. Синсез тормыш тормыш булмаячак. Мин моны, сине беренче күргәч үк, аңладым. Мин сине гомердә ташламам. Сүз бирәм. Ярабби Ходаем, терелт, зинһар өчен!

С ә г ъ д и (*торып, үзенә күрсәтеп*). Аллаһе Тәгалә синең үтенечне ишетте. Теләгең кабул булды. Мин терелдем. Мин яшәячәкмен!

Г ө л с ы л у (*бик оялып*). Ах!

С ә г ъ д и. Туташ, тагын бер кат кабатлагыз әле шул искиткеч сүзләрне, җанашыммы әле?

Г ө л с ы л у (*ярсып*). Кабатлыйм мин сиңа хәзер. (*Букет тотып куа башлый.*) Кабатлыйм. Кара син аны, ә, оятсыз! (*Үзе шат.*) Ничек оялмыйсыз, кыз баладан көләргә. (*Суга-суга.*) Кабатлыйммы?

С ә г ъ д и. Юк, юк, ноу, булды.

Г ө л с ы л у. Булмады әле, булмады. Менә сиңа, менә!

Суккан вакытта Сәгъди аны эләктереп ала, кисәк кенә суырып үбә. Озак кына шулай калалар. Акрын гына икесе дә сыгылып төшәләр.

С ә г ъ д и (*пышылдап*). Гөлсылу, матурым, тагын әйт инде шул сүзләрне.

Г ө л с ы л у (*көчкә генә иренен кыймылдатып*). Әй, оятсыз!

С ә г ъ д и. Матурым, гүзәлем, бәгырем! Мең-мең рәхмәт сиңа! Син мине сихерләдең, бөтен акылымны томаладың. Мин дөньяда үземне беләсеңме ничек итеп сизәм? Мин үземне иң бәхетле кеше итеп тоям, синнән кала.

Г ө л с ы л у (*пышылдап*). Нигә миннән кала?

С ә г ъ д и. Чөнки син миннән дә бәхетле, әйеме?

Г ө л с ы л у. Әйе. Ә? Әй хәерсез.

С ә г ъ д и. Ноу, зинһар, ачуланма, Гөлсылуым, син минем дөньяда иң сылуым. Миңа дөньяда синнән башка беркем дә, берни дә кирәкми.

Г ө л с ы л у. Чынлапмы?

С ә г ъ д и. Ес. Чын. Мин сине бүген үк урлап качар идем, ләкин...

Г ө л с ы л у (*хыялланып*). Нәрсә, ләкин...

С ә г ъ д и. Бу мөмкин түгел, чөнки...

Г ө л с ы л у. Ә-ә?! (*Бик аптырап кала.*)

С ә г ъ д и. Син борчылма, Гөл...

Г ө л с ы л у (*чыдаша алмыйча*). Мин... борчылам?! Юк инде. Син зур урындагы кеше булгач, чөнкимени? Бел, сиңа урлату дигән уй башымда да юк иде! Сау бул! (*Китә башлый.*)

С ә г ъ д и. Ой-ой-ой, үләм! Деат! Ой, аягым! (*Гөлсылу туктый.*)

Г ө л с ы л у. Мин сиңа ышанмыйм.

С ә г ъ д и. Мин үлдем. (*Ята.*)

Г ө л с ы л у. Барыбер ышанмыйм. (*Сәгъди селкенми, Гөлсылу якынрак килә.*) Ышанмыйм, дим! (*Сәгъди аның кулыннан эләктерә.*)

С ә г ъ д и. Гөлсылу! Җанашым, зинһар, миңа үпкәләмә. Сине мыскыллау минем уемда да юк иде.

Г ө л с ы л у (*тартылып*). Җибәрегез дим, әфәнде!

С ә г ъ д и. Ярарыгыз инде, мин гөнаһлы. Ес. Мин үз хатамны аңладым. Ярый, алай булгач, минем белән гомер буе бергә булырга сүз бирегез. Ул очракта мин сезнең аяк астыгызда туфрак булырга риза.

Г ө л с ы л у. Җибәрегез, мин сезгә ышанмыйм! Сез алдакчы!

С ә г ъ д и. Ноу, зинһар, ышаныгыз, бу юлы мин чын күңелемнән. Изге чишмә белән ант итәм.

Г ө л с ы л у. Изге чишмәгә кагылма. Син аңа лаек түгел. Ярый, соңгы тапкыр мин сиңа ышанам. Әгәр тагын алдашсаң...

С ә г ъ д и. Гомеремдә дә... Вәгъдәме?!

Г ө л с ы л у. Вәгъдә. (*Үбешәләр.*) Ләкин безгә загста язылышырга кирәк бит.

С ә г ъ д и. Нәрсә соң ул?

Г ө л с ы л у. Соң, шуны да белмисеңмени?

С ә г ъ д и. Бездә, Америкада, әй, ноу, хе-хе-хе, мишәрләрдә, андый нәрсәгә бик исебез китми. Шуңа белмимдер.

Г ө л с ы л у. Загссыз ярату буламыни?

С ә г ъ д и. Ярар, ярар, алай бик кирәк булгач, мин риза. (*Җырлый.*)

Бакчаларда чәчәк,
Һаваларда кошлар,
Казаннарда, гүзәл, син икән.
Күкләргә лә менәм,
Кабаннарга төшәм,
Сине генә сөям мин, иркәм.

Г ө л с ы л у.

Еракларда килеп,
Яратамын диеп,
Күңелемне алган син икән.
Сагынып сине көтәм,
Күңелемдә йөртәм,
Яши алмам синсез мин, иркәм.

Б е р г ә.

Бергә җитәкләшеп,
Куанышып яшик,
Яратудан олы бәхет юк икән.
Безнең кебек булу,
Бер-береңне сөю
Дөньяларда бүтән юк икән.

Г ө л с ы л у. Син минем иң акыллым, иң, иң, иң!

С ә г ъ д и. Син дә! Туташ, ә бу изге чишмә каян килеп чыккан?

Г ө л с ы л у. Бу чишмә урыны борынгы заманда безнең изге болгар бабаларыбызның кабер урыныннан ташып чыккан, диләр. Ул безнең халыкның яшәеш суы булып, киләчәге булып, изге рух биреп ташый, диләр.

С ә г ъ д и. Син әллә ниләр беләсең.

Г ө л с ы л у. Бу — бабалардан бабаларга күчеп калган риваять. Ярый, Сәгъди әфәнде, әйдәгез, безгә кузгалырга вакыт.

С ә г ъ д и. Хәзер, тагын бер генә изге чишмә суын йотыйм да... (*Су эчәләр.*) Мин монда дусларны да алып киләм, һичшиксез!.. Әйдә! Ой!

Г ө л с ы л у. Ни булды? Булышыйм! (*Кочаклашып китәләр.*)

Кабан буе сәхнәсе.
М а к с белән Ч а р л и керәләр.

Ч а р л и. Ой, ой, башым! Урыс аракысын бу кадәр каты дип белми идем.

М а к с. Сөйләмә! Үләм! Чыдарлык түгел. Әйтәм монда бөтен кеше кызыл борынлы.

Ч а р л и. Ноу, чукынсыннар ла! Үз кайгым кайгы. Макс, әйдә, исән чакта ычкыныйк бу илдән.

М а к с. Син нәрсә?! Психбольницага эләгәсең килә мәллә? Атакай ни диде?

Ч а р л и. Да, ул әйтсә, эшли инде.

М а к с. Шул шул, түз! Менә картаны тапсак, баш төзәтәбез.

Ч а р л и. Ой, күрәселәрем бар икән әле.

М а к с. Ш-ш-ш, кемдер килә. Тегеләр бүген монда очрашырга тиеш. Без аларны бүген, һичшиксез, капырачакбыз. Качыйк.

Ч а р л и. Ой, башым! (*Качалар.*)

К а н т р и керә. Ул бик шат. Гел елмая. Юләр кеше кыяфәтендә.

К а н т р и. Бу дөньяда яшәүләре бигрәк күңелле булып китте әле, ә казы нинди тәмле! Ник моңарчы мин бу Казан каласына килмәдем икән? Бигрәкләр дә матур шәһәргә ошап китте, үзе нинди бай шикелле. Нинди м-м-ах! Бәрәңге саталар. Кодрәтемнән килсә, мин монда гына яшәр идем. Тик шул начар гадәтем генә бетерә. Кызлар алдында телем бәйләнә. Үзалдыма сөйләнгәндә, сәгатьләр буе лыгырдыйм. Эх, шул гүзәл Сәрвәр белән рәхәтләнеп сөйләшеп утырсаң иде. Ә казы! М-м-м-а-х! Ә Сәрвәр үзе! Бәясез кыз! Искиткеч туташ!

Ул хыялланып утырганда, Н ә р м и н керә.

Н ә р м и н (*сүлпән*). Син нәрсә мыгырдап утырасың? Кильки ашап акылдан шаша башладың мәллә?

К а н т р и. Һелло, Нәрмин! Гүзәл Нәрмин! Исәнме-саумы! Ноу, шашмыйм, мин бик шат бүген. Ә, ес, шашам икән. Мин, чыннан да, акылдан шашам. (*Кылана.*)

Н ә р м и н. Син шат. Кайчан кайтып китәрбез инде моннан?

К а н т р и. Нигә китәргә? Монда бик яхшы итеп яшәргә була.

Н ә р м и н. Кемгә ничек бит?

К а н т р и. Сиңа ни булды, Нәрмин?

Н ә р м и н. Әй, сорама. Башым болганды. Сиңа гына ачылам, Сәгъдигә сөйләмә, сүгәр.

К а н т р и. Ноу, нигә сөйлим.

Н ә р м и н. Исеңдәме, бер егет минем ишегемне гел шакып йөри дигән идем.

К а н т р и. Теге шакмаклы күзлеме?

Н ә р м и н. Әйе, шул.

К а н т р и. Шуннан?

Н ә р м и н. Шуннан шул... Мин аңа бик каты гашыйк булдым бугай. Аннан башка яшәүне күз алдыма да китерә алмыйм. Ә ул миңа теге вакытта бер-ике сүз әйтте дә бүтән сөйләшми.

К а н т р и. Ник?

Н ә р м и н. Ник дип, авызын селкетә, ә сүзе аңлашылмый. Андый чакларда ул үзенең даруын эчә иде.

К а н т р и. Ноу, ул авырумыни?

Н ә р м и н. Шулай бугай.

К а н т р и. Сиңа бик сак булырга кирәк.

Н ә р м и н. Нинди сак булу. Кеше тилмерә, җәфалана, ә даруы юк. Талонга гына бирәләр диме шунда хәзер. Нинди илдер инде бу. Кеше үләргә мөмкин, ә даруны бирмиләр.

К а н т р и. Хәзер даруы бер дә юкмы?

Н ә р м и н. Юк шул. Мин гаҗиз булдым инде. Нишләргә дә белмим.

К а н т р и. Ә ул шул даруны гына яратамы?

Н ә р м и н. Әйе дияргә була. Ноу, тагын ул ат ярата икән.

К а н т р и. Нәрсә? Ат? Кызык?

Н ә р м и н. Кызык шул менә. Ат табам дигәч, аның күзләренә илаһи нур кергәндәй булды, бөтенләй үзгәрде. Минемчә, аты булса, ул үзгәрәчәк, сөйләшә башлаячак.

К а н т р и. Соң, ал да бир алайса.

Н ә р м и н. Ноу, ничек? Монда бит ашарыбызга да җитми акча.

К а н т р и. Хәзинә табылса инде...

Н ә р м и н. Шәп булыр иде. Белмим шул, ай-һай...

К а н т р и. Ярый, үзеңне ашама, Нәрмин. Берәр җае чыгар. Ашау дигәннән, мин бик каты кунак булдым бит әле.

Н ә р м и н. Кунак булдың? Ничек?

К а н т р и. Шулай. Күз алдына китер: каз шулпасы, аның артыннан кыздырылган алсу-көрән каз вә кетердәп торган бәрәңге! М-м-ах! Телеңне йотарсың!..

Н ә р м и н. Ес, начар булмаган. Чиста Американча килеп чыккан. Ничек булды соң?

К а н т р и. Ес! Чыккан гынамы соң? Ничек булды дисеңме? Мин бер чибәр кыз белән танышкан идем. Һәм ул мине кунак итте.

Н ә р м и н. Чибәр кыз?

К а н т р и. Әйе! Беләсеңме, нинди кыз?! Искиткеч! Үзе

шундый, үзе мондый, үзе... гупчем, нәкъ үзе инде. Ә күзләре! Тик шунысы гына гаҗәп, ничек итеп минем кебек килбәтсез кешегә каз ашата алды икән, ноу, әй лә, ошата алды икән ул?

Нәрмин. Алай ук түгел инде. Монда килгәч, ябыгып, зифаланып та киттең.

Кантри. Шулай дисеңме? Ә ул бәрәңгене ничә төрле генә итеп пешерми?! Телеңне йотарсың! М-мах!

Нәрмин. Тукта, Сәгъди килә түгелме? Кара, кара, йөзләрендә кояш уйный, алтын тапкан диярсең.

Кантри. Әйтмә. Кара әле, Нәрмин, теге кыз турында аңа әйтмә, бетерер.

Нәрмин. Син дә теге шакмак күзле егетне телгә ала күрмә.

Кантри. Ноу, без аңа үзебез бәйләнсәк, берни дә әйтә алмас.

Нәрмин. Яхшы... О' кей!

Сәгъди керә, ул бик шат.

Сәгъди. Һелло! Әссәламегаләйкем, дусларым.

Нәрмин. Синең кәефләр бик шәп күренә.

Сәгъди. Ес, зарланмыйм. Бу шәһәрдә шундый чиста, саф һава, сулап туя алмыйм.

Кантри. Бигрәк тә күле шәптер инде.

Сәгъди. Ес, начар түгел. Ник алай дисең, картлач?

Кантри. Юк, теге ни, күл суы башыңа китте бугай. Кыз артыннан киткәч, эзләп тә табып булмый.

Нәрмин. Үзе, беркемгә карамаска, дигән була бит әле.

Сәгъди. Хе-хе-хе... Ес, сез аны әйтәсезмени әле?

Кантри. Шуны.

Сәгъди. Ес, ул бик кызык килеп чыкты.

Нәрмин. Кызыктыр инде, кыз куенында яткач...

Сәгъди. Нәрмин, син ни сөйлисең? Ул бөтенләй башка туташ. Беләсезме, ул шундый чибәр, шундый ягымлы, шундый... Күзләреннән ниндидер илаһи нур сирпелә.

Кантри. Шакмаклы да түгелме тагын?

Сәгъди. Син нәрсә инде? Ә-ә, Нәрмин, ул шакмак күз бүтән бәйләнмәдеме? Тагын бәйләнсә, безгә әйт.

Нәрмин. Бәйләнми, кызганычка каршы.

Сәгъди. Нигә кызганычка каршы?

Кантри. Бәйләнмә әле аңа, бозык.

Сәгъди. Ноу, кем бозык? Менә син үзең кайда йөрдең микән?

Кантри. Алтын эзләп.

Сәгъди. Таптыңмы соң?

Кантри. Таптым. Алтыннан да зурысын.

Сәгъди. Нәрсә соң ул?

Кантри. Ә, белер идең бугай! Телеңне йотарсың, ммах!

Сәгъди. Ярый, дуслар, төп эшкә керешик, болай да ничә көн бушка узды.

Нәрмин. Бик бушка узганга охшамаган.

Сәгъди. Дөрес, Нәрмин. Әйтсәм әйтим инде, дуслар, мин...

Кантри. Нәрсә син?

Нәрмин. Таптыңмы?

Сәгъди. Әйе, таптым.

Кантри. Таптың?

Сәгъди. Таптым, дуслар! Котлагыз мине! Мин монда үземнең мәхәббәтемне таптым. Мин өйләнәм.

Кантри. Әй, җүнле сүз сүлиме дисәң? Акылың кайда соң синең?

Нәрмин. Таптым дип кеше куркыта тагын. Кем сине монда өйләндерсен?! Ә ничек кәләшеңне алып китмәкче буласың? Ә бәлки... син аны мыскыллап китмәкче буласыңдыр.

Кантри. Урламакчымы әллә? Ха-ха-ха!..

Сәгъди. Ес! Нәкъ үзе! Урлыйм! Башта мәчеткә барып никах укытабыз, аннан урлап алып чыгам.

Нәрмин. Мөмкин түгел.

Сәгъди. Белмим. Ничек булыр. Ләкин мин ансыз яши алмаячакмын.

Кантри. Ес, саргаеп үлә, хи-хи-хи!..

Нәрмин. Ярый. Ә хәзинә мәсьәләсе?

Сәгъди. Менә миңа ул хәзинә хәзер бигрәк тә кирәк. Хәзинә булмаса, аны алып чыгу турында уйларга да ярамый.

Кантри. Каян эзлибез инде хәзер, шеф.

Сәгъди. Минемчә, Сөембикә манарасы астына күрсәтелгән билге буенча (*картаны күрсәтеп*) казып карыйбыз.

Кантри. Әгәр булмаса?

Сәгъди. Булмаса, тагын бер юл кала.

Кантри. Казуын казырбыз, анысына инде өйрәндем. Тик менә теге кашыну мәсьәләсе...

Сәгъди. Әлегә түзәргә туры килә. Мин үзебезнең арттан күзәткәннәрен сизәм.

Нәрмин. Алар милициядән. Син киткәч, без аларны бер хәйләләп качтык инде.

Кантри. Оу, ноу. Алар миңа башка киемнән килеп бәйләнделәр. Мин аларны исертеп качтым.

Сәгъди. Ес, безгә бик сак булырга һәм ашыгырга кирәк.

Макс белән Чарли чыгалар.

Макс (*бармагын пистолет итеп төбәп*). Селкенмәскә! Сез кулга алындыгыз! Уф, башым!

Өчесе дә кулларын күтәреп калалар.

Сәгъди. Без ни, бе-ез төзүче комсомолецлар.
Кантри. Ә-ә-ә-й-е-е!
Нәрмин. Ес!
Макс. Шым бул! Кара син аларны, алдаша да башладылар. Гел алдашырга гына торалар. Татар халкын бу кадәр алдакчы дип башыма да китерми идем. Чарльз, тирә-якны карап кил. Селкенмәскә!

Чарли китә.

Кантри. Нишлибез? Каптык. Эх казы, эх бәрәңгесе...
Сәгъди. Ни мыгырдыйсың?
Нәрмин. Наркотик биреп йоклатып булмас микән?
Сәгъди. Ноу, ни сөйлисең? Каян табасың аны хәзер. Бу сиңа Америка түгел. Монда наркотикның нәрсә икәнен дә белмиләр бит. Казанда беркем дә кулланмый ди аны. Аларның хастаханәләрендә дә юк диләр әле аны.
Кантри. Ес! Таптым. Кичә алар аракы эчкән иделәр. Бүген аларның баш авырта.
Сәгъди. О' кей! Алдарга кирәк. Бәйләп калдырабыз аларны.
Кантри. Алдашмый гына булмасмы?
Сәгъди. Ноу, тәк! Иптәш, әй, иптәш... товарищ!
Макс. Ни кирәк?
Сәгъди. Без кичә бик нык бәйрәм иткән идек. Бүген баш авырта.
Макс. Ой, башым!
Сәгъди. Минем әнә тегендә бер таныш бар. Әгәр рөхсәт итсәгез (*кибеткә күрсәтеп*), мин тиз генә барып, берне алып килер идем. Баш чатный.
Макс. Булыр дисеңме?
Сәгъди. Ес, мин тотынгач, һичшиксез.
Макс. Үземнең дә баш иләсләнеп тора иде дә...
Сәгъди. Соң, әллә кайчан шулай димичә, яхшы кеше өчен берни дә кызганыч түгел. Хәзер без аны. Әйдә, дуслар.
Макс. Ноу, берегез генә.
Сәгъди. Ә-ә, алай булгач, булмый. Әгәр мин дә качсам. Мә, менә бу бауның очын тот. Ә мин икенче башын. Бау белән тартып алырсың. (*Бау чыгара.*) Мин кача алмам. Каяле, мин сезне тотып торыйм.
Макс. Ничек? Ә-ә, тотыгыз, тот, тик тизрәк кенә.

С ә г ъ д и. Хәзер без аны. Бик шатланып, сэр. Каяле, кулыгызны. (*Максның кулын артка каера.*) Кантри, Нәрмин бәйләгез.

Кантри белән Нәрмин Максны бәйли башлыйлар.

М а к с. Сез ни эшлисез?

С ә г ъ д и. Сине бәйлибез.

М а к с. Ноу, нигә?

С ә г ъ д и. Ычкынып, безне куып җитмәскә. (*Агачка бәйлиләр.*)

М а к с. Кызык. Мин ычкынсам, син алып килә алмыйсыңмы?

С ә г ъ д и. Ес, менә-менә, нәкъ өстенә бастың. Син шаулама, тик кенә тор, алайса, бөтен эшне бозасың.

М а к с. Яхшы. О' кей! Ә-ә, ы-ы! (*Өч дус кача.*) Сез кая?!

С ә г ъ д и. Сау бул, шеф!

М а к с. Ничек сау бул, ә минем баш, уф, баш! Чарли! Чарли!

Йөгереп Ч а р л и керә.

Ч а р л и. Ни булды, шеф?

М а к с. Чиш!

Ч а р л и. Нәрсә чишәргә?

М а к с. Мине чиш! Күрмисеңмени?

Ч а р л и. Ничек бәйләндең соң син үзеңнән-үзең. Ни өчен?

М а к с. Сөйләмә! Чиш! Бәйләнерсең үзеңнән-үзең, бар, бәйләп качтылар.

Ч а р л и. Ә син карап тордыңмы?

М а к с. Булышып тордым. Чиш, диләр!

Ч а р л и. Булышкансыңдыр. Булышмасаң, бу кадәр яхшы итеп бәйли алмаслар иде.

Макс ычкына.

М а к с. Качтылар, шайтаннар, җитмәсә, баш чатный. Нишлибез?

Ч а р л и. Үзең качырдың да. Ес, психбольницага туры юл инде. Уф, башка чыдап булмый.

М а к с. Берсе әнә теге бик күп кеше җыелып торган җирдән алып киләм дигән иде дә, алдады.

Ч а р л и. Нишләп җыелып торсыннар, чират ич ул. Монда шундый әйбер бар икән, кешеләр тезелешеп өелешсә, чират дип атала.

М а к с. Ноу, кит инде, килде-китте аракы өчен шулкадәр чират була димени инде?!

Ч а р л и. Була икән шул.

М а к с. Ярар, әйдә, үлеп булмый, барып бәхетне сынап карыйк.

Ч а р л и. Әйдә.

Китәләр.
Сәхнәгә С ә р х у ш чыга. Күз төбе кара янган, үзе бик шыксыз.

С ә р х у ш. Уф Алла, бляха-муха, ничек итеп баш төзәтергә? Кемне алдарга, ә? (*Кесәләрен әйләндерә.*) Бер тиен булсачы!.. Әй дөнья, дөнья, шайтан алгыры, голова кругом пошел. (*Җырлый.*)

Минем кебек асыл егет
Дөньяларда бер генә.
Көнләшәләр миннән барсы,
Арага да кертмиләр.

Алдый торгач, йөри торгач,
Аферист дип тактылар.
Мин котырткан, мин алдаган —
Бу дөньяда шактыйдыр.

Талантларым бик күп минем,
Кадеремне белмиләр.
Алдакчы дигән булалар,
Аферист дип йөриләр.

Яшәүләре ямьле була,
Бер тинтәкне алдасам.
Башларына тай типтереп,
Кесәләрен капшасам.

Җыр беткәндә, кулиса артыннан сәхнәгә һавадан башта М а к с, аннан Ч а р л и очып төшәләр. Сәрхуш кача. Макс белән Чарли озак кына тора алмый яталар.

М а к с. Уф, үләм! Ай, билем! Ай, башым! Ай! (*Арт ягын тота.*)

Ч а р л и. Ой, үләм! Ой, күзем, ой, башым, ой! (*Арт ягына ябыша.*)

М а к с. О' кей! Ну, бирделәр... Утырып та торып булмас, ахры, бер атна буе.

Ч а р л и. Ес, бу ни инде бу? Әллә Алла каргадымы соң безне? Нигә бу татар илендә безгә гел кире килеп тора?

М а к с. Атакай безне бетерәчәк. Әллә хәбәр итеп карыйсыңмы?

Ч а р л и. Ноу! Нәрсә дип? Арт якка бирделәр дипме? Җүләрләр йортыннан курыкмыйм әле. Менә хәзер ничек исән калырга?

Макс. Исән калсам, бүтән аракыга борылып та карамас идем. Бу урыс аракысы бигрәк яман икән.

Чарли. Ул әллә үзгәртеп корулары башлангач, шулай әшәке үзгәрде микән әллә, ә?

Макс. Менә әйткәнем булсын, әгәр исән калсам, бүтән эчмәс идем. Виски да капмас идем.

Чарли. Монда яшәп таблеткага гына калабыз, нинди виски инде ул тагын? Менә хәзер ничек табарга диген!

Сәрхуш чыга. Үзен бик тә зыялы, тәртипле тота.

Сәрхуш. Күрәм, егетләр бик ямансулыйлар. Күңелсез мәллә, әллә хәлләр авырмы?

Макс. Сез кем?

Сәрхуш. О-о-о, үзебезнең мөселман халкы икән әле. Таныш булыйк, Шәйхулла.

Чарли. Кем соң сез?

Сәрхуш. Ах, ах, ышанмыйлар. Ну, Шәйхулла түгел алайса, Миңнулла.

Макс. Ярый, шулай да булсын ди. Сезгә ни кирәк?

Сәрхуш. Егетләр, мин сезнең хәлне аңлыйм. Сезнең баш чатный.

Чарли. Каян белдең?!

Сәрхуш. Әй, үткән этап. Сез минем мондый шикарный чырайга карамагыз. Әйе, әйе, минем дә бар иде андый чаклар. Ну, хәзер мин бик культурный, интеллигентный кеше. Шулай да газапланган кешене мин аңлыйм. Ай, ничек аңлыйм. Кыскасы, сезнең баш чатный?..

Макс. Нәрсә тәкъдим итәсең?

Сәрхуш. Мин сезгә берне табып киләм. (*Тамак төбенә чиртә.*)

Макс. Берәү алып килде инде.

Сәрхуш. Сез нәрсә, дуслар. Мин андый егет түгел, мин бик чиста эшлим. Мин алып киләм.

Чарли. Чынлапмы?

Сәрхуш. Ну инде, син нәрсә? Валлаһи, валлаһи, билләһи! Истенный крест! Во! Әйткән сүз — аткан ук!

Макс. Тукта, ашыкма. Ничек эшләмәкче буласыз инде сез аны? Әнә анда борын тыгарлык түгел.

Сәрхуш. Анысы минем эш, минем точка бүтән. (*Күз кыса.*)

Макс. Бездән ни кирәк?

Сәрхуш. Инде шуны да белмәскә. Американнар әйтмешли, мани-мани!

Чарли. О, ес, ул бездә бар.

Макс. Мә! (*Долларлар бирә.*) Ничә доллар?

С ә р х у ш. Нәстә? (*Акчаны карап.*) Бу чүп-чарга монда нәрсә булсын. Сукыр тавык та бирмиләр аңа. Каян алдыгыз бу чүпне?

Ч а р л и. Өйдән (*Макс йодрык яный.*)... түгел...

М а к с. Ноу, ноу... без аны. О, ес... агач башыннан таптык.

С ә р х у ш. Ничек агач башыннан? Агач башында буламыни инде акча?

М а к с. Менә бу тинтәк агач башына «эш» белән менгән дә табып төште.

Ч а р л и. Ә-ә?

М а к с. Чарлига төртә.

Ч а р л и. О-о-ой, ес, ес, әйе!

С ә р х у ш. Ә безнеке сездә бер дә юкмы?

М а к с. Менә шушы гына. (*Унлыкны чыгара.*)

С ә р х у ш. Аз, анда үз бәясенә генә бирмиләр. Ике бәя түләргә кирәк. Кая, ярар алайса, тегеләрен дә бир. Бәлки, залогка ярап торыр.

Ч а р л и. Зинһар, коткара күрегез инде.

С ә р х у ш. Айн момент. Дусларны коткару минем өчен изге эш, намус кушуым, бурычым. (*Күзе яшьләнә.*) Мин ул эшкә бөтен гомеремне багышладым. (*Китә.*)

М а к с. Тиз килер микән? Бигрәк нечкә күңелле кеше икән. Андый кеше алдамас. Рәтләнсәм, валлаһи бүтән капмас идем.

Ч а р л и. Ес, яхшы кеше... һичшиксез, алып киләчәк.

С ә р х у ш к е р ә.

Булдымы?

С ә р х у ш. Мин тотынгач соң инде. (*Шешә чыгара.*)

М а к с. О' кей. Сал тизрәк.

Сәрхуш сала, башта үзе эчеп куя.

С ә р х у ш. Пробасы алынды. Зарарлы түгел. Менә хәзер эчәргә була. (*Тагын салып эчә.*) Менә хәзер сиңа салам. (*Макска бирә.*)

М а к с. О-о-ох, яшим икән!

Ч а р л и. Миңа да, миңа!

С ә р х у ш. Мәле, сиңа да. Мин бик юмарт кеше бит.

Ч а р л и. Ай-яй-яй, ес, булды бу.

С ә р х у ш (*үзенә тагын салып*). Ә хәзер, иптәшләр-товарищлар, мин бер тост әйтәм. Безнең гөрләп чәчәк атучы илебез, халкыбыз хакына тост!

М а к с. Әйт, дускай, әйт!

Ч а р л и. Тыңлыйбыз!

С ә р х у ш. Менә товарищлар, шундый хәлләр: без бер

аягыбыз белән социализмда, икенче аягыбыз белән коммунизмда торабыз.

Макс. Ноу, һе, кызык инде. Ничек ул, бер аяк монда, икенчесе тегендә?

Чарли. Ничек булсын инде, туңкаеп, билгеле...

Макс. Ес, һәм озак шулай туңкаеп торыргамы исәбегез?

Сәрхуш. Юк, товарищи, сез мине аңламадыгыз. Без зур уңышлар белән алга барабыз. Безнең киләчәгебез якты. (*Шешә аша карый.*) Әйе, бик якты! Бездә хәзер бөек үзгәрешләр бара, үзегез күреп торасыз! Без берничә е-е-елдан Американы узып китәчәкбез.

Макс. Чарли, берничә йөз елдан диме?

Чарли. Әйе, шеф, берничә йөз елдан, диде.

Сәрхуш. Безнең хәзер алдынгы кешеләребез, хөкүмәтебезнең иң акыллы кешеләре депутат булып баралар. Алар элеккегеләр шикелле хөкүмәтне, халыкны таламаячаклар! Алар яхшырак итеп... Ә, нәрсә? Шулай бит! Менә мин үзем дә кандидат булып китәм әле. Менә моны гына (*шешәне селкеп*) эчеп бетерәм дә... Мин туган илебезне үзгәртеп корачакмын! Хенде хох!

Макс. О' кей! Браво! Сез зур политик!

Чарли. Ес! Искиткеч! (*Күз яшен сөртә.*) Безнең илгә бер-ике шундый кеше булсачы. Ничек алга китәр идек!

Макс. Әйтмә инде!

Сәрхуш. Өйрәнегез, егетләр! Минем кебек акыл ияләре сирәк!

Салып эчә. Макс белән Чарли да күтәреп куялар.

Макс. Ой-ох, дөньяларда яшәүләре бигрәк рәхәт икән.

Чарли. А-ах, урыс аракысы шәп!

Сәрхуш. Менә мин, илнең иң акыллы кешеләреннән берәү, әрәм булып ятам. Мине күрмиләр! Әбәзәтелни депутат булам?! Вәт шунда күрсәтәм күрмәгәннәрен! Бөтен үчемне алам!

Чарли. Товарищи, әйдәгез җырлыйк.

Сәрхуш. Әйдәгез! (*Җырлыйлар.*)

Тотабыз дип йөри торгач,
Үзебезне тоттылар.
Кайберләре алдап китте,
Берәүләр ыргыттылар.

Деллу, деллу, деллу, һай,
Була инде бу болай:
Без эзлибез, тотылабыз,
Кыйналабыз, ычкынабыз.

Алтын таптык дигән чакта,
Буш сумка тоттыралар.
Йә башка сугып китәләр,
Йә үзләре сыптыралар.

Деллу, деллу, деллу, һай,
Була инде бу болай:
Татар алдый, ышанабыз,
Тотып калабыз бугай.

Елый-елый Нәрмин керә. Аның артыннан Нургали ияргән. Ул бу юлы аек, яхшы костюмнан, галстук таккан.

Нургали. Зинһар, гафу итегез, Нәрмин, мин сезне үпкәләтергә теләмәгән идем.

Нәрмин. Китегез, зинһар өчен. Калдырыгыз мине.

Нургали. Юк, юк, андый сүз сөйләмәгез. Мин сезне ничек калдырып китим, җитмәсә, шундый хәлдә?..

Нәрмин. Ах, юк өчен борчылмагыз. (*Елый.*)

Нургали. Ягез инде, ягез, җитәр. Сез мине аңламадыгыз бугай.

Нәрмин. Бик яхшы аңладым, хушыгыз!

Нургали. Нәрмин, зинһар өчен, бер айныганмын икән, тыңлап калыгыз. Бәлки бу соңгы тапкырдыр.

Нәрмин. Сез ни сөйлисез? Сезгә аек булу шундый килешә.

Нургали. Ә сез мине ташлап китмәкче буласыз. Атым булмаганга эчкәнне, янымда сез булмагач, мин эчепме-эчәчәкмен инде.

Нәрмин. Менә туктый алдыгыз бит әле, шуны дәвам гына итегез.

Нургали. Булмас дип куркам. Чөнки сез минем күңелгә изге өмет керттегез дә, мин бар нәрсәне, хәтта эчүне дә онытып сезгә табындым. Ә хәзер качасыз. Ах, мин нишләрмен?

Нәрмин. Сез ат хакында әйтәсезме?

Нургали. Әйе! Яңадан атлы булу хыялым тормышка аша гына дигәндә, кырт кына кирегә бордыгыз. Ах, мин нинди бәхетсез.

Нәрмин. Зинһар өчен, әфәндем. Миңа ачуланмагыз. Булдыра алмыйм мин әлегә, булдыра алмыйм. Хәзер генә ат таба алмыйм. Ләкин мин сезгә сүз бирдем бит.

Нургали. Миңа яки хәзер, югыйсә... Юк, бар да җимерелде. Сау бул, аек тормыш. Исәнме, яңадан исереклек!

Нәрмин. Юк, ноу, кирәкми!

Нургали. Сез миннән баш тартып бик дөрес эшли-

сез, туташ. Айный белмәгән бозык егеттән сезнең кебек чибәр, акыллы кыз бик еракта йөрергә тиеш.

Нәрмин. Ноу, юк! Алай сөйләмәгез, зинһар өчен. Миңа бу сүзләрне ишетү бик кыен.

Нургали. Миңа да җиңел түгел. Миңа синең белән җиңел, рәхәт иде. Шундый хыяллар туган иде башта.

Нәрмин. Сез борчылмагыз, бары да җайланыр, эчмәгез генә.

Нургали. Юк, минем бөтен кешегә ышанычым югалгач, сезгә генә ышана алган идем. Инде менә бар да бетте. Их, атлы да була алмадым, ичмасам! Ә сез, бүтән, тәртипле, итагатьле егеткә ат бүләк итәрсез.

Нәрмин. Ноу! Ничек аңлый алмыйсың?! Миңа бит сез генә ошыйсыз, мин сезне генә яратам! Әйтмәгәнне әйттерәсез!

Нургали. Менә бит, әллә кайчан шулай димичә! Шушы сүзләрне ишетү өчен кайчаннан бирле тырышам. Ачуланмагыз, зинһар өчен. Минем сезнең чын күңелегезне беләсем килгән иде.

Нәрмин. Ничек?! Сез шаярдыгыз?

Нургали. Юк, юк, мин чын күңелдән. Бөтен дөньясына ышанычым югалгач, мин сезгә дә ничектер шик белән карадым. Мәйтәм, ничек инде тотсын да ат бүләк итсен. Шуңа сезне тикшереп карадым. Хәзер мин сезгә үземә караганда да ныграк ышанам.

Нәрмин. Сез миннән көләсез. (*Китмәкче була.*)

Нургали. Гафу, зинһар өчен. Ә хәзер ачыктан-ачык сөйләшсәк тә була. Нәрмин, сез дә миңа бик ошыйсыз. Үзегез күреп торасыз, минем чирем бар, мин аннан котылмыйча ат белән генә бәхетле була алмаячакмын.

Нәрмин. Тыңлыйм, ес?..

Нургали. Мин дәваланырга уйлыйм, тик сез миңа ярдәм итегез. Сез янымда булганда, мин тау-ташлар күчерерлек көч сизәм үземдә.

Нәрмин. Нургали! Бу синме? Мин сине танымыйм.

Нургали. Бу мин, җанашым.

Нәрмин. Болай булгач, мин сине мәңге ташламам. Беләсеңме, изге чишмә дигән җир бар...

Нургали. Беләм. Аны белмәгән татар юктыр.

Нәрмин. О' кей! Бигрәк яхшы. Әйдә, без шунда очрашыйк. Барын да шунда хәл итәрбез. Дәвалануны да, атны да. Ризамы?

Нургали. Синең белән булгач риза!

Нәрмин. Хуш! Мин сине изге чишмә янында көтәрмен!

Нургали. Хуш!

Икесе ике якка китәләр.
Шул ук сәхнә. Ут янганда, сәхнәдә Сәгъди утыра.

Сәгъди. Нигә килмиләр инде? Соңга калабыз бит.

Кантри керә.

Кантри. Бик соңардыммы?

Сәгъди. Ноу, түзәргә була, картлач. Карале, син бигрәк ябыгып, сылуланып киттең, урлап качмасыннар тагын үзеңне болгар кызлары...

Кантри. Күз тидер тагы.

Сәгъди. Тфү! Тфү!

Кантри (*битен сөртеп*). Сенквью! Биткә төкермәсәң дә була.

Нәрмин керә.

Нәрмин. Уф, соңга калам дип, чабып үлә яздым.

Сәгъди. Бер дә үлгәнгә охшамагансың әле, бик шат күренәсең.

Нәрмин. Гел сезгә генә куанырга димәгән.

Сәгъди. Ярый, дуслар, эшкә тотыныйк. Безнең эшләр тагын да катлаулана. Сөембикә манарасы астыннан берни дә чыкмады.

Нәрмин. Ноу, ә бәлки, тирәнрәк булгандыр ул.

Кантри. Тирәнрәк сиңа?! Соң, кыйшайган манара казый торгач, урынына утырып, турайды бит инде, куллар калмады. Эштә булсак, урынына утырткан өчен премия бирерләр иде әле.

Сәгъди. Ес, анда эш барып чыкмады. Хет, изге эш эшләдек. Манараны урынына утырттык.

Нәрмин. Ничек басылып калмадык әле.

Кантри. Ходай коткарды, иншалла.

Сәгъди. Тагын бер һәм соңгы юл калды, дуслар.

Нәрмин. Нинди?

Сәгъди. Тыңлагыз. Мин менә бу эзне тикшереп карадым. (*Картаны күрсәтә.*) Кабан күленең читенә, сай җиренә, Болакка тоташкан турысына килеп чыктым. Ләкин без соңга калган булып чыктык.

Кантри. Ник?

Сәгъди. Әгәр без бер унбиш-егерме ел элек килгән булсак, өлгергән булыр идек тә...

Кантри. Әйе, егерме ел элек мин әле мич алдында күмер ашый идем.

Нәрмин. Берни эшләп булмыймыни?

Сәгъди. Белмим, байлык яшерелгән җиргә татарлар тиз арада театр төзеп куйганнар. Байлык шуның астында калган.

К а н т р и. Ай, өлгер дә инде бу татар халкы! Шул арада театр салып атканнар. Күз ачып йомганчы театр төзеп ыргытканнар. Культураны бу кадәр кайгырткан халык турында минем моңарчы ишеткәнем дә булмады.

Н ә р м и н. Әйтмә инде. Ә без нишлик соң?

С ә г ъ д и. Бер юл бар.

К а н т р и. Ес, әйт тизрәк!

С ә г ъ д и. Безгә ул театр эченә ничек булса да керергә, тиешле турысын табып казырга кирәк.

К а н т р и. Шартлатсак?

Н ә р м и н. Ноу, син нәрсә! Шундый матур, егерме ел буе төзегән театрны. Аннан аның артистлары да бик әйбәт, ди, яшәсеннәр. Билет алабыз да керәбез.

С ә г ъ д и. Ноу, ноу, ноу! Булмый!

Н ә р м и н. Нигә?

С ә г ъ д и. Анда билетлар өч-дүрт ай алдан сатылып бетә, ди. Ә без көтә алмыйбыз, вакыт кыса.

К а н т р и. О' кей! Таптым! Әгәр контролерларны, каравылчыларны сатып алсак?

С ә г ъ д и. Булмый.

К а н т р и. Ник? Акчага, җитмәсә, долларга сатылмаган кеше юк әле дөньяда.

С ә г ъ д и. Ноу, менә шул шул!.. Андагы контролерлар акчага түгел, алтынга да сатылмый, ди.

К а н т р и. Ничек алай микән?

С ә г ъ д и. Аларның баш режиссерлары җыен ышанычлы, тотнаклы кешеләрне генә җыя икән. Шуңа күрә безгә ничек булса да Камал театры эченә керергә кирәк. Кергәч, җае табылыр... Хәзергә ял итегез. Бүген кичкә театр янында очрашабыз. Озакларга ярамый. Ә инде аймылышсак, әйткәнемчә, изге чишмә янында очрашырбыз. Берәм-берәм генә таралышыйк. (*Китәләр.*)

Яшелчә кибете сәхнәсе. К а н т р и керә, кибеттә С ә р в ә р генә.

К а н т р и. Һелло! Әссәламегаләйкем!

С ә р в ә р. О-о-о, кем килгән безгә. Әйдә, рәхим ит! Мин сине сагынып беттем инде. Сиңа бик мөһим бер сүз әйтәсем бар.

К а н т р и. Гафу үтенәм, эшегездән бүлмим.

С ә р в ә р. Юк, юк, син нәрсә инде, хи-хи-хи, әллә бәрәңге кирәкме?

К а н т р и. Бәрәңге?

С ә р в ә р. Әйе, бәрәңге! Нинди сортын? Ә бәлки, арчыганындыр, әллә туралганын укмы?

К а н т р и. Сагындым дип, ни... каз бик тәмле булган иде...

Сәрвәр. Эх, әйе шул, каз бик тәмле иде. Кантри, җанашым, авылдан алып килгәч тагын бер пешерермен әле, яме?

Кантри. Ярар. Ә хәзер...

Сәрвәр. Нәрсә — хәзер?

Кантри. Ноу, каз ашыйсым килми икән.

Сәрвәр. Туйдыргандыр, каз тиз туйдыра бит ул.

Кантри. Ярый, мин китим инде...

Сәрвәр. Ничек, китәсезмени?

Кантри. Әйе.

Сәрвәр. Ашыкмагыз инде, сөйләшик.

Кантри. Без ни... мин дуслар белән идем.

Сәрвәр. Да, ә алар кайда?

Кантри. Алар киттеләр.

Сәрвәр. Кызганыч. Аларны күрә алмый калдым.

Кантри. Күрерсез әле, алар беркая да кача алмыйлар.

Сәрвәр. Ни өчен?

Кантри. Чөнки... ес, чөнки чик аша чыга алмаячаклар.

Сәрвәр. Чик аша?

Кантри. Ноу, юк, ни, теге...

Сәрвәр. Кантри, кошчыгым, син нидер яшерәсең кебек. Үзең мине алдамыйм, дидең. Син миннән нәрсә яшерәсең?

Кантри. Ес, мин ә-ә-ә-йтермен. Тик се-ез миңа ачуланмаска сүз бирегез.

Сәрвәр. Ничек сүз бирергә?

Кантри. Нindие, теге, ә-ә-әгәр м-м-мин бик ә-ә-әшәке кеше булып чыксам...

Сәрвәр. Аның булуы мөмкин түгел.

Кантри. Ноу, сез с-с-сүз бирегез. Сезне ачуландырасым килми.

Сәрвәр. Сүз бирәм. Мин болай да ачуланмас идем. Мин бөтенләй ачулана белмим. Өйрәнә алмый калганмын.

Кантри. О' кей. Тыңла, алайса, бәрәңге. Әй... лә... т-т-туташ, м-м-мин сезнең ил кешесе түгел.

Сәрвәр. Ничек? Син тегеннәнмени? Ничек алай була инде ул?

Кантри. Ес, тегеннән. Була икән шул.

Сәрвәр. Ә кайда сезнең тарелка?

Кантри. Тарелка? Н-н-ноу, без җамаяктан ашыйбыз. Безнең тарелка юк.

Сәрвәр. Ничек килдегез алайса?

Кантри. Очып.

Сәрвәр. Мин дә шуны сорыйм бит, кошчыгым. Нинди тарелкада очып килдегез, дим?

К а н т р и. Н-н-ноу, тарелкада түгел, самолетта очтык.

С ә р в ә р. Туктале, тукта, син гуманоид булмадыңмыни?

К а н т р и. Гу-гу, гуманоид? М-м-мин? Ноу, мин Америкадан. Мин Америка татары?

С ә р в ә р. Ничек? Сез Америкадан?

К а н т р и. Әйе, Америкадан.

С ә р в ә р. Сез — шпион?! Ах! (*Егыла башлый.*)

К а н т р и (*тотып калып*). С-с-сез нәрсә, т-т-туташ, м-м-мин шпион түгел, б-б-без болай гына.

С ә р в ә р (*аңына килеп*). Ә мин сиңа ышанып...

К а н т р и. Ышандыгыз, т-т-туташ... Мин алдакчы т-түгел...

С ә р в ә р. Ә мин җүләр, бер тәкъдим ясамакчы идем тагын.

К а н т р и. Ес, нинди?

С ә р в ә р. Бар да бетте, кире кайтармаслык булып җимерелде. Ай Ходаем, нигә мине шулкадәр бәхетсез итеп яраттың?

К а н т р и. Туташ, борчылмагыз. Мин гаепле, б-б-беләм, ләкин...

С ә р в ә р. Нәрсә, ләкин, нәрсә кошчыгым?! Син китеп барырсың, ә мин монда җылап утырырмын, әби булганчы.

К а н т р и. Нигә, туташ?..

С ә р в ә р. Нигә? Сине сагынып, сине юксынып! Каз пешереп...

К а н т р и. Кабатлагыз әле.

С ә р в ә р. Нәрсәне?

К а н т р и. Ка-ка-казны ка-ка-кабатлагыз...

С ә р в ә р. Каз пешереп?!

К а н т р и. Ә? Каз?! Исемә т-тө-төште, мин китә алмыйм икән.

С ә р в ә р. Ничек? Сез китмисез...

К а н т р и. Т-т-туташ, сез нинди т-т-тәкъдим ясамакчы булган идегез? К-к-кунаккамы?

С ә р в ә р. Мин... мин...

К а н т р и. Ес, ес!

С ә р в ә р. Мин... син... миңа...

К а н т р и. Әйтегез, туташ, мин көтәм.

С ә р в ә р. Син миңа өйләнәм дисәң, ни... бу... мин сиңа кияүгә чыгар идем димәкче идем.

К а н т р и. Ә-ә! Ой-ой, өйләнергә? М-м-миңа?!

С ә р в ә р. Әйе.

К а н т р и. М-м-мин бит ни...

С ә р в ә р. Шул шул! Ярый хушыгыз, әфәндем!

К а н т р и. Сәрвәр т-т-туташ, т-т-туктагыз, зинһар өчен. Ә-ә-ә, каз? Әй лә, гафу итегез. Күреп торасыз, минем эшләр катлаулы. Ничек килеп чыгасын белеп булмый.

С ә р в ә р. Ш-ш-шулай, бе-бе-белеп бе-бе-бетерәсез дә, к-к-каз ашап сы-сы-сызасыз.

К а н т р и. Ноу, туташ, ноу! Беләсезме, берсекөнгә сез изге чишмә янына килегез. Дусларым белән дә танышырсыз. Шунда барын да сөйләшербез, ризамы?

С ә р в ә р (*елап*). Р-р-риза...

К а н т р и. Ноу, еламагыз. Бар да әйбәт булыр. Мәхәббәт комедиясендә бар да әйбәт булып бетә ул. Түзегез азга гына. О' кей!

С ә р в ә р. Я-я-ярар, х-х-хуш, кошкаем!

К а н т р и. Хушыгыз, каз... әй, ноу, хе-хе, туташ! (*Китәләр.*)

Кабан күле сәхнәсе.
Сәхнәгә М а к с белән Ч а р л и чыгалар. Алар тагын да куырылганнар. Махмырдан ыңгырашып, ни эшләргә белми йөриләр. Чарли ярты минут саен тышка чыгып керә.

Ч а р л и. Уф, үләм бугай. Ай эчем, ай әҗәлем шушында булыр микәнни соң?! (*Эчен тотып йөгерep чыгып китә, аның ыңгырашканы ишетелә.*)

М а к с. Синең эчең нәрсә ул, менә минем баш. Ой, үләм. Ай, башым! Гомердә урыс аракысын эчмәс идем. Ярабби Ходаем, исән калсам, бүтән капмас идем. Аракыга якын да бармам, борылып та карамам.

Ч а р л и керә.

Ч а р л и. Ай, үләм бугай, бу кильки мине кабергә кертә. Макс, шеф, нишлим икән бу эч белән?

М а к с. Чөй кагып куй!

Ч а р л и. Мыскыл итәсең? Ит, ит... А, а-ах, ой, үләм! (*Эчен тотып чыгып йөгерә.*)

М а к с. Әллә чыннан да ычкына инде? Эч китүдән кеше үлә микәнни? Ноу, үз кайгым кайгы... Уф, башым... Нишлим икән, исән калсам... борылып та карамас идем шул яшел еланга.

Ч а р л и керә. Кулында аэрозоль.

Ч а р л и. Менә берәү калган.

М а к с. Нәрсә ул?

Ч а р л и. Оныттыңмыни? Соң шул инде, теге көнне депутат алып килгән әйбер. Ул аны коньяк «пыш-пыш» диде. Анысы нинди сүздер инде, белмим.

М а к с. Ә аның белән баш төзәтеп буламыни?

Чарли. Ес, кичә шуларны эчеп исереп беттек бит.
Макс. О' кей! Сал, әйдә, алайса тизрәк.
Чарли. Ноу, ашыкма, аны башта җайларга кирәк.
Макс. Тиз бул, алайса үләм...
Чарли (*«пыш-пыш»ны тишеп эчәргә әзерли*). Мә, шеф.
Макс (*эчә*). О-о-ох!
Чарли (*эчә*). Ой-ой-ой! Эчем, үләм! (*Чыгып йөгерә.*)
Макс. Үлә-ә-әм! Чарли, син нинди коньяк эчердең? Үләм! Чарли, бәхил бул! (*Егыла.*)
Чарли. Шеф, ой, бу коньяк нишләтә, үләбез бит. Шеф, әйдә бирелик. Күп булса, төрмә булыр. СССРда чит ил тоткыннары өчен шартлар да яхшырак, ди. Бирелик исән чакта.
Макс. Ой, янам. Бирелик дисеңме?
Чарли. Бирелик яхшы чакта. Җаным көчкә чыкмый тора.
Макс. Бар алайса, шалтырат.
Чарли. Кая? Атакайгамы?
Макс. Ноу, кая булсын, соң шул «02»гә инде. Монда да безнең ФРБдагы шикеллерәктер инде ул.
Чарли. Ес, ой эчем, ой Аллам, үләм! (*Эченә ябышып чыгып китә.*)
Макс (*аның артыннан*). Шалтыратып та кил берүк. Менә таптык үз башыбызга алтын. Атакай бетерер инде.

Чарли керә.

Чарли. Уф, эчем шартлый бугай инде.
Макс. Күрмәгәндәй сосасың бит шул кортлаган кильскине, кара икра диярсең. Киләләрме?
Чарли. Ес, хәзер килеп җитәргә тиешләр.
Макс (*чукына*). Йа Хода, үзең ярдәм ит.

Дүрт агент килеп керә.

Беренче агент. Урыныгыздан кузгалмаска! Кулларыгызны күтәрегез!
Икенче агент. Кайда ЦРУ агентлары?
Макс. М-м-менә, бе-бе-ез...
Беренче агент. Сез? Ха-ха-ха!
Икенче агент. Сез нәрсә, безнең белән шаярырга булдыгызмы?
Чарли. Ю-юу-ук, әфәнделәр.
Беренче агент. Әфәнделәр? Ха-ха-ха. Карале, болар теге ни мәллә? (*Чигәсенә бармагы белән борып күрсәтә.*) Ха-ха-ха!..

И к е н ч е  а г е н т. Син нәрсә (*Чарлига*) эчеңә ябыштың? Корал яшерәсеңме, ал кулларыңны!

М а к с. Ул кулларын ала алмый.

Б е р е н ч е  а г е н т. Нигә?

М а к с. Аның эче күпергән.

Б е р е н ч е  а г е н т. Эче күпергән?

Ч а р л и. Әһә! Ес! Гафу үтенәм, миңа чыгып керергә кирәк. (*Утырырга кирәген аңлата.*)

Б е р е н ч е  а г е н т. Ах, этләр! (*Өченче, дүртенче агентларга.*) Озата барырга!

Тантаналы музыка астында Чарли чыгып китә.

И к е н ч е  а г е н т. Сез нәрсә? Кемнәр белән шаярганыгызны беләсезме сез? Сез кемнәр?

М а к с. Бе-бе-без ЦРУ агентлары. Язып куегыз, без ирекле рәвештә бирелергә булдык. Үз теләгебез белән.

Б е р е н ч е  а г е н т. Карале, бу нинди агентлар булсын. Берсе күпергән, тыштан керми. Берсе чын Сәрхуш, күз төбендә нинди зур синяк. Борыны пешкән чөгендер кебек.

М а к с. Зинһар, ышаныгыз, без агентлар. Ышанмасагыз,— ой, май гадь вуи ал ЦРУ эйджентс. Белиевас, вуи суррент аурсельвс! Инде ышандыгызмы?

И к е н ч е  а г е н т. Бәлки, син әле Наполеон яисә Сталиндыр. (*Беренчесенә.*) Чын-чынлап ычкыну һәм шизофрения симптомнары. Күп эчүдән, алкоголизм җимеше. Бар, психбольницага шалтырат, көтсеннәр.

Б е р е н ч е  а г е н т. Яхшы! (*Китә.*)

И к е н ч е  а г е н т. Йә, егетләр. (*Макс белән Чарлига.*) Сез шулай итеп ЦРУ агентлары булдыгыз инде, ә?

Ч а р л и. Ес, нәкъ үзе, әфәндем.

И к е н ч е  а г е н т. Сезне, егетләр,ерактан килгән кунаклар буларак матур бүлмәләр, җылы каршылау көтә. Рәхим итегез.

М а к с. О' кей! Бик зур рәхмәт.

И к е н ч е  а г е н т. Иванов.

Ө ч е н ч е  а г е н т. Мин.

И к е н ч е  а г е н т. Психбольницага озатырга боларны!

Ө ч е н ч е  а г е н т. Есть! (*Макс белән Чарлига.*) Әйдәгез!

М а к с. Сенковью! Зур рәхмәт сезгә, әфәндем! (*Чарлига.*) Менә төрмәгә дә эләкмәдек.

И к е н ч е  а г е н т. Барыгыз, бар.

М а к с. Бер дога кылыйк инде.

Чарли белән Макс утыралар. Бәет көйлиләр.

Җүләрләр йортында ятак киштәсе,
Чарли белән Максның тавышын ишетәсез.
Хәзинә эзләп килдек без монда,
Ни күрде башлар байлык юлында...
Юләрләр йорты, кергәч, уң якта,
Тилмердек бу илдә агент булсак та.

*(Агентлар елап торалар.)*

Әнкәй бәгырем, каргады микән,
Агент булсын, дип, тилмерсен, диеп...
Коймак пешерәләр юләрләр йортында,
Газап эзләре минем сыртымда.
Әнкәй бәгырем мине каргады,
Башкайларымны саклый алмады.

Татарлар белән алышма икән,
Качкан вакытта калышма икән.

Себер җилләре үзәкне үзә,
Агент бәгыре ничек соң түзә?

Әнкәй бәгырем, сиңа сүз дәшәм,
Җүләр йортында түгәм күз яшем.

КГБ агентлары үкереп елап җибәрәләр.

Беренче агент. Месkennнәр!
Икенче агент. Сезнең өчен йөрәккәйләрем лә өзелә. Әйдәгез, марш!

Барысы да китәләр.
Изге чишмә буе. Нәрмин керә. Ул кызу-кызу йөренә, кемнедер көтә.

Нәрмин. Ярабби Ходаем, аек килеш кенә килсә ярар иде. Ул авторны да әйтер идем. Соң, эчми торган егет итеп язса, ни була?! Ноу, булмыйдыр.

Нургали керә, аз гына кызмача.

Нургали. Исәнмесез, саумысыз, кәҗә савасызмы сез?
Нәрмин. Исәнме, Нургали? Син тагын салгансың.
Нургали. Соң бу салумыни инде, җаным, кәеф күтәрү өчен генә. Менә сине сагынып саргая башладым да бераз (*чиртеп*) кәктем.
Нәрмин. Мин дә сагындым, эчмим бит.
Нургали. Нәрмин, мин хәзер валерианка тапкан песидәй синнән кала алмыйм. Син мине ташлама.

Нәрмин. Мин сине ташламам. Тик син мине тыңла гына.

Нургали. Сөйлә генә, аппагым.

Нәрмин. Теге юлы син дәваланам дигән идең, исеңдәме?

Нургали. Кәнишне. Ул бит минем бердәнбер аек көнем иде.

Нәрмин. Ес, димәк, син ул эшкә риза?

Нургали. Ике куллап. Үзем дә ул чирдән ничек котылырга белмим. Ярдәм ит, Нәрмин.

Нәрмин. Ярдәм итәрмен. Тик безнең дуслар белән эш кенә барып чыксын.

Нургали. Нинди дуслар? Нинди эш? Көнләштермә мине.

Нәрмин. Син ачуланма, озакламый барын да белерсең, яме. Әгәр бар да әйбәт булса, ат та булыр.

Нургали. Ат? Ур-ра! Син чынлап әйтәсеңме?

Нәрмин. Ес, чынлап.

Нургали. Әгәр мин сәламәтләнсәм, атлы булсам, әйбәт егеткә әйләнсәм, син минем белән бергә булырга ризамы?

Нәрмин. Ничек?

Нургали. Миңа якын булырга?

Нәрмин. Бары да синнән тора.

Нургали. Мин тырышырмын. Мин бик тырышырмын.

Нәрмин. Ә хәзер, безнекеләр килеп сөйләшкән арада, син качып тор. Мин сине үзем чакырырмын.

Нургали. Яхшы, аппагым.

Икесе бергә чыгып китәләр.

Кантри. Менә килеп тә җиттек. Беркем дә юк.

Сәрвәр. Нинди гүзәл җир. Чишмә чылтырап, җырлап ага. Бөтен дөнья яшеллеккә чумган. Бер уйласаң, нинди гүзәл җирдә яшибез инде.

Кантри. Тик сез аның кадерен генә белмисез.

Сәрвәр. Сез түгел, без диген.

Кантри. Ноу, ничек инде?!

Сәрвәр. Соң син дә хәзер безнеке бит, хи-хи-хи. Шулай да, Кантри, сез нинди эш белән йөрисез?

Кантри. Хәзер, ни... әйтермен.

Сәрвәр. Хәзер, ни, юк, әй. Синнән бүтән сүз дә чыкмый. Мине алдап кына йөрисеңдер әле. Америкада әллә ниткән кызларың бардыр.

Кантри. Ноу, сезнең казлар бик тәмле.

Сәрвәр. Каз булыр ул.

Кантри. Ә, булыр!
Сәрвәр. Әйе. Ә минем сүзгә җавап кайчан?
Кантри. Хәзер.
Сәрвәр. Тагын хәзер...
Кантри. Ни, Сәрвәр, син аз гына көт.
Сәрвәр. Яхшы, кара аны, казлар оча торган...
Кантри. Оу, ноу! Хәзер, хәзер. Тик син, мин дуслар белән сөйләшеп бетергәнче көтеп тор.
Сәрвәр. Озакка түгелдер дип уйлыйм. (*Китәләр.*)

Сәгъди керә. Ул бик дулкынланган.

Сәгъди. Әллә беркем дә юк инде. Һәрвакыттагы кебек, болар гел соңга калып йөрерләр. Хәзер мин әйтәсен ишетсәләр, күккә сикерәчәкләр.

Нәрмин керә.

Нәрмин. Хелло, Сәгъди. Син нәрсә кош тоткан малай кебек очынасың? Әллә гашыйк булдыңмы?
Сәгъди. Шаулама, Нәрмин. Анысы да бар, бүтәне дә...
Нәрмин. Әллә?!
Сәгъди. Ашыкма, Кантри кайда?
Нәрмин. Күрмәдем!

Кантри керә.

Кантри. Мин монда сезне көтә-көтә инде...
Нәрмин. Ноу, мин килгәндә берегез дә юк иде.
Сәгъди. Дуслар, талашмагыз, барыгызга да җитә.
Кантри. Нәрсә, әллә?
Сәгъди. Әйе, бар да булды.
Кантри. }
Нәрмин. } O' кей! Ур-ра!
Сәгъди. Бик шауламагыз!
Нәрмин. Сөйлә тизрәк!
Сәгъди. Чәү. Башта мин сезне беләсезме нәрсә белән таныштырам. Карагыз әле менә бу якка — гүзәллекме?
Нәрмин. Искиткеч!
Сәгъди. Менә шунда инде изге чишмә чылтырап ята. Суын татып карыйбызмы?
Кантри. O' кей!

Өчәүләп чишмә суы эчәләр.

Нәрмин. Оу, ноу! Нинди тәмле шифалы су! Сулышлар киңәеп китте.

К а н т р и. О-йе, менә бу, ичмасам, чишмә. Җан керде, аякта тагын да ныграк басып тора башладым.

С ә г ъ д и. Шул шул, менә нинди гүзәл ул безнең бабалар туган як! Яманлык кына түгел, гүзәллек тә бар. Сакларга гына кирәк! Бу чишмә суын эчкән кеше яшәреп, көрләнеп китә, җанда рух, моң арта. Тәндә болгар бабалары каны кайный башлый, ди. Туган якка кайтып, болгар рухын алдык без, дуслар! Ә эш болай булды: зур авырлык белән Камал театрына үтеп кердем.

К а н т р и. Ничек керә алдың?

С ә г ъ д и. Тс-с-с, шаулама! Бусы иң зур сер. Аның турында авыз ачып дусларга да сөйләргә ярамый. Чөнки иң авыры, иң катлаулысы анда керү булды.

К а н т р и. О' кей! Аңлашылды.

Н ә р м и н. Шуннан?

С ә г ъ д и. Шуннан шул, кергәч, японский, ну, теге аппарат белән хәзинә яткан турыны таптык, миңа пожарник булып йөрергә туры килде. Пожарник булгач тоткарламадылар.

К а н т р и. Шуннан, шуннан?

С ә г ъ д и. Хәзинә турысын тапкач...

К а н т р и. Әйе...

С ә г ъ д и. Турысын тапкач... Миңа тагын профессия үзгәртергә туры килде.

К а н т р и. Ник?

С ә г ъ д и. Чөнки идәнне ачып карарга кирәк иде, һәм мин, театр сазда булгач, бата, грунт составын тикшерергә кирәк дип, геодезист булдым.

Н ә р м и н. Алар шуңа ышандылармы?

С ә г ъ д и. Ышанмыйча. Алар үз театрларын бик яраталар. Шуңа аны саклау өчен җаннарын бирергә әзерләр. Берсүзсез тикшерергә риза булдылар.

К а н т р и. Ә ничек алып чыга алдың?

С ә г ъ д и. Ноу, ашыкма, әле бит тапмаган. Бер салырга ярата торган театр әһеле белән өч төн казыдык. Төшеп җиткәндә генә, үзем казып, хәзинәне яшердем.

Н ә р м и н. Яшердең?

С ә г ъ д и. Әйе. Театрның бутафор тартмаларына тутырып, яшереп куйдым. Алып чыгасы гына калды.

Н ә р м и н. Күпме?

С ә г ъ д и. Җитәрлек. Ләкин бу азы гына ди әле. Иң зур өлеше Кабан күленең үзәгендә. Хәзинәләр арасыннан шундый документ һәм харита чыкты. Бусы безгә киләчәктә эш.

К а н т р и. Ничек?

С ә г ъ д и. Анысы турында соңыннан. Ә хәзер куаныгыз.

Нәрмин. Әллә ничек булып калды әле. Менә мин хәзер шатланырга тиеш. Ә миңа бик моңсу булып калды.

Кантри. Миңа да. Чыннан да, уйласаң, без хәзер дөньяда иң бай кешеләр. Бар нәрсәгә төкереп яшәргә була. Күңелсез булып калды.

Сәгъди. Сез чынлап сөйлисезме, дуслар?

Нәрмин. Син ачуланма, Сәгъди, чыннан да шулай.

Сәгъди. Димәк, сез Штатларга кайтырга бик ашыкмыйсыз?

Кантри. Син үпкәләмә, Сәгъди, мин күңелемдәгеп яшерә алмыйм. Миңа бу җир бик ошый.

Сәгъди. Димәк...

Нәрмин. Ярар инде, син бик борчылма. Мәсәлән, миңа байлык күп кирәкми.

Кантри. Миңа да...

Сәгъди. Ноу! Ничек? Димәк, бөтен байлык диярлек миңа кала?

Нәрмин. Ничек телисең, шулай эшлә.

Сәгъди. Күрәм, дуслар, без эшләр белән генә түгел, уйлар белән дә чын дуслар икән. Тик менә сезнең бер ялгыш уегыз бар.

Кантри. Нинди?!

Сәгъди. Бу байлыкны җыйнап, тизрәк кайтып китү уе.

Нәрмин. Ничек, алайса...

Сәгъди. Әйе, дуслар. Мин сез бүтәнчә сөйләрсез дип курыккан идем. Хәзер мин шат. Әйтегез әле, бу җирләр, бу яклар, бу сулар сезгә ошыймы?

Кантри. Бик.

Нәрмин. Бу чишмә бөтенләй башымны әйләндерде. Гүя мин бөтенләй башка кеше. Искиткеч гүзәл як!

Сәгъди. Туган як. Димәк, сез монда яши алыр идегез?

Нәрмин. Син ни әйтмәкче буласың?

Сәгъди. Ноу, сез әйтегез, яши алыр идегезме?

Нәрмин. Бик шатланып, ләкин...

Сәгъди. Ноу, бернинди ләкинсез, менә нәрсә, дуслар, Казанда Татар иҗтимагый үзәге дигән оешма эшли. Мин аларга үземнең планнарымны сөйләдем.

Кантри. Нинди планнар?

Сәгъди. Минем үземә дә бу ил күңелемә хуш килә. Мин аларга татар мәдәниятен экономикасын күтәрүгә, гомумән, татар илен алга алып бару өчен корпорацияләр төзергә дип, бөтен хәзинәне тәкъдим иттем. Ә без (*Кантрига*), әгәр дә син теләсәң, билгеле, ул корпорациядә эшли алабыз. Безнең экономика өлкәсендә Америка, Ев-

ропа илләре тәҗрибәсе. Без милләтебезгә бик зур файда китерә алабыз.

Кантри. Ноу, мөмкин түгел.

Сәгъди. Нигә?

Кантри. Без чит ил кешеләре. Безне, шпионнар дип, кулга алачаклар.

Сәгъди. Алмаслар. Ул турыда да сүз булды. Безгә ирекле яшәү вә эшләү шартлары тудырылачак, диделәр.

Кантри. Алай булса, мин риза. Монда казлар да бик тәмле бәрәңге белән.

Нәрмин. Сезнең эшләр җайланды. Ләкин мин үз өлешемне бирә алмыйм.

Сәгъди. Ник?

Нәрмин. Ноу, мин үзем өчен түгел.

Кантри. Ни эшләмәкче буласың?

Нәрмин. Минем бер дустым бар иде, ул салырга ярата. Менә ул дәваланырга риза булды.

Сәгъди. Ес, шуннан.

Нәрмин. Мин аны гына дәваларга түгел, гомумән, татар халкын ул чирдән коткарырга өлеш кертмәкче булам.

Сәгъди. О' кей! Бигрәк әйбәт! Бик шәп, Нәрмин! Безгә хәзер аек акыллы, эшлекле кешеләр кирәк булачак. Бу бик изге эш! Бабалар сөйләве буенча безнең халык кайчандыр бөтенләй эчмәгән.

Нәрмин. Сез риза. Алайса, мин калам. Ноу, минем бер үтенечем бар.

Сәгъди. Нинди?

Нәрмин. Шул байлык хисабына бер ак ат алып булмасмы икән?

Сәгъди. Ничек, Кантри, алыйкмы?

Кантри. Ес, алыйк.

Нәрмин. Рәхмәт, дуслар.

Гөлсылу керә.

Гөлсылу. Исәнмесез?

Сәгъди. Саумы, Гөлем? Менә таныш булыгыз, дуслар! Бу минем кәләшем, бәхетем Гөлсылу.

Кантри. Кантри!

Нәрмин. Нәрмин!

Сәгъди. Гөлсылу! Менә миңа чын дөресен сөйләр чак җитте. Мин мишәр малае түгел, мин Америка татары.

Гөлсылу. Ә-ә?

Сәгъди. Әйе. Дөресен әйтергә ярамаганга, мин сине гел алдап йөрергә мәҗбүр идем. Инде хәзер бар да хәл ителде. Без байлык таптык. Без туган илдә калырга булдык.

Гөлсылу. Мин сиңа ышанмыйм.

Сәгъди. Ышан, бәгырем! Мин дөресен әйтәм һәм синең кулыңны сорыйм.

Гөлсылу. Юк, мин сиңа ышана алмыйм. Син миңа бик якын, ләкин мин синнән шикләнеп яшәргә теләмим.

Сәгъди. Мин бит синнән башка яши алмыйм.

Гөлсылу. Вакыт күрсәтер.

Кантри. Сәрвәр, син кайда?

Сәрвәр (*чыгып*). Мин мондау...

Кантри. Мин... ни... казлы... әй лә... мин риза.

Сәрвәр. Нәрсәгә риза?

Кантри. Мин... ни... бәйләргә... Сәрвәр белән... (*Муенын бармагы белән урап асып күрсәтә.*)

Сәрвәр. Кантри, кошчыгым! Тизрәк никах укытыйк.

Нәрмин. Нургали, а-у!

Нургали тавышы. А-у! (*Чыгып.*) Җаным, мин монда.

Нәрмин. Сиңа ак ат булачак! Син терелерсең. Мин бик шат.

Нургали. Нәрмин, аппагым!

Сәгъди. Күрәм, дуслар, сез муеннан гашыйклар һәм бу бик әйбәт. Дөньяда төрле хәл була. Менә мин өйләнәм дип шапырынган идем, барып чыкмады әлегә. Мәхәббәттә шапырынырга, алдашырга ярамый икән. Аның сиңа бик нык җәза бирүе бар. Без Гөлсылу белән аңлашырбыз.

Хастаханә пижамаларыннан ике агент керә.

Сәгъди. Сез кемнәр?

Макс. Без ЦРУ агентлары.

Кантри. Ә?! (*Качмакчы була, аны Сәрвәр кочаклап ала.*)

Чарли. Ес, без элеккеге агентлар. Ә хәзер без... (*Бармагы белән чигәсен борып күрсәтә.*)

Нәрмин. Ә-ә?!

Макс. Гафу итегез инде безне, без бүтән алай эшләмәбез.

Чарли. Ес, без бүтән татар эшенә гомердә дә кысылмабыз.

Макс. Америкалылар башы җитәрлек эш түгел икән.

Чарли. Без бүтән буталып йөрмәбез.

Макс. Әйе, без хәзер ышанычлы урында. (*Чигәсен бора.*)

Сәгъди. Ярый, без сезне бу юлы гафу итәбез. Карагыз аны, татарларны бүтән бутап йөрмәгез.

Кантри. Ес, кара син аларны...

Н ә р м и н. Спектакль бетә, туй җитте, Сәгъди, әйт соңгы сүзеңне.

С ә г ъ д и. Хәзер.

К а н т р и. Оу, ноу! Менә бу юлы Сәгъди сөйләми торсын әле. Җебегән ул. Өйләнә дә алмады. Үзем әйтәм тостны.

С ә г ъ д и. Ә-ә? Ну-ну?!

К а н т р и. Әфәнделәр, туташлар, шулай итеп безнең бөек операция азагына килеп җитте. Минем шуны әйтәсем килә. Үзегез күреп торасыз, дуслар, ничек килеп чыкты: без монда байлык, хәзинә эзләргә генә дип килгән идек. Әйе, анысын да таптык. Әмма без монда тагын да зуррак, тагын да кадерлерәк байлык — мәхәббәт, ярату таптык. Без җанга шифа бирә торган изге чишмә аша туган җиребезне, болгар бабаларыбызның рухын таптык. Кеше гомере бик кыска, дуслар. Шуңа күрә бу фани дөньяда үзеңнең мәхәббәтеңне табып, бәхетле тормыш корып, үзеңнән соң изге рух калдыру — дөньяның бөтен байлыкларыннан да бөектер! Менә нинди фикергә килдем мин, дуслар! Яшәсен ярату!

Н ә р м и н, Н у р г а л и (*бергә*). Яшәсен ярату!

С ә г ъ д и, Г ө л с ы л у (*бергә*). Яшәсен мәхәббәт!

(*Җырлыйлар.*)

Чәчкә аткан болын уртасында
Күбәләкләр нурга коена.
Яраталган, мәхәббәтле кеше генә
Иң бәхетле кебек тоела.

К у ш ы м т а:

Ал чәчәкләр елмаешып дәшә,
Сөю — бәхет, сөю — сәгадәт.
Кабатлыйлар чәчкәләрне кошлар,
Иң бөек хис — изге мәхәббәт.

Иң кыйммәтле, алтын асылташтан
Тере чәчкә мең-мең кыйммәтле.
Мәхәббәтне табу, ярсып яну
Ялкынлата безнең йөрәкне.

К у ш ы м т а.

Яшьлек үзе бәхет, үзе чәчәк,
Яшь чагында сөю — сәгадәт,
Гомереңгөрләп чәчкә атар,
Яшьлегеңдә булса мәхәббәт.

К у ш ы м т а.

С ә г ъ д и. Карагыз әле, әнә теге кеше автор түгелме?

А в т о р. Саумысез, дуслар!

С ә г ъ д и. Менә безнең эш бетте, сезгә ошады микән безнең кылган эшләр, белмим, ә безгә ошады.

К а н т р и. Бик!..

Н ә р м и н. Ярый, сез килеп чыктыгыз әле.

А в т о р. Белмим, дуслар, мин генә хәл итә торган эш түгел бит. Менә тамашачылар ни дияр? Әгәр аларга ошаса, димәк, бар да үз урынында. Ягез, кадерле тамашачылар, сезгә ошадымы?.. Рәхмәт! Кадерле тамашачылар! Мин сезгә бер серне чишмәкче булам. Сез карап утырган американлылар алар чын американлылар түгел бит. Бу минем хыялым. Минемчә, киләчәктә без, татарлар, дус булып, мул тормышта, саф мәхәббәт, аек акыл белән яшәрбез Алла боерса. Бу хәлнең бит тормышта булуы да мөмкин. Мөмкин түгел, ә тиеш. Бөтен бер халык җыелса, Кабан күле байлыгы барлыкка килмәсме? Уйлашыйк. Ә бүген тамашада катнашучы артистлар...

Аларга рәхмәт әйтик!

П ә р д ә.

# *Гинд кызы*

*Ике пәрдәле музыкаль комедия*

КАТНАШАЛАР:

Зәйтүнә.
Җәүдәт.
Габдрахман.
Кәбирә.
Мөхәммәтхан.
Мәмдүдә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Җәйге матур кич. Җәүдәт белән Зәйтүнә эскәмиядә утыралар. Җәүдәт телогрейкадан, майлы чалбардан, йөзләре буялып беткән. Авыл яшьләре, гөрләшә-гөрләшә, клубка кино карарга ашыгалар, арадан икесе бик каты итеп сүгенеп үтәләр...

Җәүдәт (*авыр сулап*). Зәйтүнә...

Зәйтүнә. Ә теге атнада булганы, беләсеңме, искиткеч булды. Аларны бикләп тоттылар. Егетен, урлап китеп, ябып куйдылар. Мин еладым да...

Җәүдәт (*күзләрен мөлдерәтеп*). Зәйтүнә...

Зәйтүнә. Ә ничек яраталар алар бер-берсен! Андый мәхәббәтне син белмисең дә. Ә андагы матурлык, моң, чисталык, сафлык...

Җәүдәт. Зәйтүнә...

Зәйтүнә. Мин ул матурлыкны сагынып көтеп алам. Бер атна бит инде, бер атна булганы юк! Тагын да булмаса, мин бетә идем. Түзә алмыйм...

Җәүдәт. Зәйтүнә...

Зәйтүнә. Ә егете нинди чибәр! Ул киенүе, җырлавы... Нигә алай икән ул аларда? Ә без...

Җәүдәт. Зәйтүнә...

Зәйтүнә. Тыңлыйм, гел сине генә тыңлап торам бит инде. Нигә без шулай яшәмибез икән? Матур итеп, яратышып, җыр җырлап? Нигә?

Җ ә ү д ә т. Зәйтүнә...

З ә й т ү н ә. Әле син сөйләп бетермәдеңмени? Бик күп сөйлисең син. Сүз сөйләмәскә кирәк, ә тормышка ашырырга кирәк... Бүген нинди булыр икән? Ой, бик көчле мәхәббәтлесе булса ярар иде. Беләсеңме, минем шул кинодан соң шундый яшисем килә башлый!

Җ ә ү д ә т. Зәйтүнә...

З ә й т ү н ә. Мин керәм, син нишлисең?

Җ ә ү д ә т. Зәйтүнә, мин бит яратмыйм...

З ә й т ү н ә. Кемне, минеме?

Җ ә ү д ә т. Һинд киносын. Шуңардан күңелем болгана башлый...

З ә й т ү н ә. Син нәрсә инде? Нигә алай?

Җ ә ү д ә т. Ачуланма. Валлаһи, карый алмыйм. Алдау бит ул, Зәйтүнәм. Әкият! Әкият киносы. Ә тормыш...

З ә й т ү н ә. Ә тормыш... Юк, син ялгышасың... Киресенчә, анда ул чын тормыш... ә бу (*китәр якка карап*) алайса каласың бу якта...

Җ ә ү д ә т. Китмә, Зәйтүнә.

З ә й т ү н ә. Нигә?

Җ ә ү д ә т. Яратам мин сине...

З ә й т ү н ә. Яратасың... Юк, Җәүдәт, ярату ул матур, гүзәл, чын күңелдән, әллә нинди булырга тиеш... Син бит шул ук Җәүдәт, икенче класстан бергә үскән Җәүдәт... Тегендә барсам да син, уң ягымда да син, сул ягымда да син...

Җ ә ү д ә т (*үпкәләп*). Зәйтүнә...

З ә й т ү н ә. Ярату ул — матурлыкка омтылудыр, име. Хуш.

Җ ә ү д ә т. Китмә!

З ә й т ү н ә. Бар, юынып чык азрак.

Җ ә ү д ә т. Мастерскойдан мин. Тракторымны ремонтладым. Эш эшләдем... (*Маңгаендагы миңенә, кызыл ноктага күрсәтеп.*) Ә бусы нәрсә?

З ә й т ү н ә. Миң, тамга. Күргәнең юкмыни? Матурмы?

Җ ә ү д ә т. Нәрсәгә ул?

З ә й т ү н ә. Кирәк. Аны безнекеләр тагып йөри...

Җ ә ү д ә т (*аңламыйча*). Безнекеләр?!

З ә й т ү н ә. Аңламыйсың син. Менә алкам. (*Борынындагысын күрсәтеп.*) Матурмы?

Җ ә ү д ә т. Юк...

З ә й т ү н ә. Ярый, соңга калам. Йә, нишлисең?

Җ ә ү д ә т (*елардай булып*). Зәй-тү-ү-нә?!

З ә й т ү н ә. Хуш! (*Клуб эченә кереп китә.*)

Җ ә ү д ә т (*үзенә-үзе урын таба алмый*). У-у, шул һинд киносын бетермәсәмме?! Бетермәсәмме?! Шул ике сери-

яле зараза гына керде арабызга! Трактор шавыдай, ничек көчле итеп, шаулап яратыша идек бит. (*Кесәсеннән шешә чыгара, эчмәкче була.*) Эх, шайтан алгыры, бензин икән лә бусы... (*Икенче шешә чыгара, башыннан гына эчеп куя.*) Ә-ә-эх! Бу да басмый, ичмасам, йөрәк ярсуын. Их, Зәйтүнә! Аңламыйсың җанымны?!

Мәмдүдә күренә. Ул олы гәүдәле, чибәрлеге чамалы булган кыз бала. Бөтен бите сипкел. Егетләрне шактый гына өркетеп тота торган кыз.

Мәмдүдә. Ни эшләп утырасың, Җәүдәт?

Җәүдәт. Балык тотып.

Мәмдүдә. Ха-ха-ха. Бигрәк шаян инде син, име, Җәүдәт... Синең янда бигрәк күңелле, име...

Җәүдәт. Син кино карамыйсыңмыни?

Мәмдүдә. Юк! Яратмыйм!

Җәүдәт. Нигә?

Мәмдүдә. Кызык түгел.

Җәүдәт. Алдашма.

Мәмдүдә. Валлаһи. Әллә ниткән Һиндстан экиятен карап утырырга. Үзебездә дә хәттин ашкан. Әкият бит ул, уйдырма! Менә бездәге кебек, бәрәңге комбайны кебек дөбердәтеп, сөякләрне шытырдатып кочу юк анда. (*Җәүдәтне кочаклап ала.*) Эх! Ха-ха!

Җәүдәт. Үтерәсең, җибәр.

Мәмдүдә. Шаярам. Нәрсәгә чыкканымны аңламыйсыңмы, Җәүдәт?

Җәүдәт. Эчәсеңме?

Мәмдүдә. Аңларга теләмисең... Җәүдәт! (*Ачуыннан эчеп куя.*) Тик утырганчы, озатып ташла мине теге очка?

Җәүдәт. Ә нәрсә?

Мәмдүдә. Озат әле, дим...

Җәүдәт. Юк...

Мәмдүдә. Әйдә алайса, тракторда кататься итәбез. Синекендәме, минекендәме?

Җәүдәт. Ә? Нәрсә?

Мәмдүдә. Чукракландыңмы әллә? Әйдә минекендә. Минеке зуррак, «К-700». Болын буйлап чаптырырбыз...

Җәүдәт. Тракторым ватык... Бар әле, үзең генә.

Мәмдүдә. Әллә нишләгәнсең әле син? Ни булган сиңа? Киемеңдә үзгәреш дисәң — киемең дә шул ук. Майлы чалбар. Каяле, өр әле, өр! Әллә бензин эчтеңме? Әллә шул чикерткә аркасындамы? Мин хәзер аның сыйракларын ботарлап... Әйт кенә!

Җәүдәт. Юк. Бар кайт инде, Мәмдүдә, тынычлан. Бүген сугышып йөрмә, яме.

Мәмдүдә. Куасың? Эх, Җәүдәтчик! Аңламадың...

Тракторда кататься итәргә теләсә кемне чакыралармы соң? (*Җырлап китә.*)

Чәйнәп-чәйнәп карадылар,
Йоталмадылар әле.

Җәүдәт. Ничава. Башына җитмәсәмме?! (*Бензинлы шешәне ала.*)

Мөхәммәтхан күренә.

Әй, аг-гай-эне, шырпың бармы?

Мөхәммәтхан. Әлегә бар. Ә нәрсә?

Җәүдәт. Биреп тор әле...

Мөхәммәтхан. Мә. (*Шырпысын бирә.*)

Җәүдәт. Бар кит инде.

Мөхәммәтхан. Ә шырпы?

Җәүдәт. Саранланма, бар. Бик саваплы эш башкарырга булыштың, бар. Ярый, бар ычкын инде!

Мөхәммәтхан. Урамда очраган һәр кешегә өләшә башласаң... Киттем, киттем. Фу, шулкадәр сосмасаң... (*Китә башлый.*)

Җәүдәт. Әй, тукта. Клуб кайсы якта әле монда?

Мөхәммәтхан. Кичә ә-ә-энә теге якта иде. Ә нәрсәгә ул сиңа?

Җәүдәт. Башына җитәм мин аның хәзер. (*Бензинлы шешәсен ача.*)

Мөхәммәтхан. Нишлисең син, юләр?

Җәүдәт. Яндырам, зар-разаны.

Мөхәммәтхан. Тукта әле, юләрләнмә!

Җәүдәт. Кара, син нигә миңа бәйләндең? Кем соң син ул кадәр?

Мөхәммәтхан. Йә, исермә инде шулкадәр. Бу мин бу, клуб мөдирегез, агартучыгыз — Мөхәммәт абзаң...

Җәүдәт. Кем?

Мөхәммәтхан. Мин инде, мин, клуб мөдире.

Җәүдәт. Ә-ә, синмени әле бу, койрыгы көйгән артист? Юк, клубның гаебе юк монда, син гаепле барысына да! (*Бугазыннан ала.*)

Мөхәммәтхан. Нишлисең, энекәш?

Җәүдәт. Син бит безнең арага керәсең! Яндырам мин сине... (*Өстенә бензин сибә.*) Син имансыз ташыйсың шул тозсыз, өч серияле һинд киносын... Әйдәле клубың янына. Барыбер яши белеп яшәмисең!.. (*Сөйрәп чыгып китә.*)

Зәйтүнә, аның артыннан Мәмдүдә күренә.

З ә й т ү н ә. Нәрсә инде тагын?
М ә м д ү д ә. Син аңладыңмы?
З ә й т ү н ә. Нәрсәне?
М ә м д ү д ә. Җәүдәткә кагылма!
З ә й т ү н ә. Нинди Җәүдәт?..
М ә м д ү д ә. Алдашма. Башын бутап, шаштырып бетергәнсең. Кара аны, кызый, мин андый эшләргә юл куймам. Менә күрәсеңме моны?
З ә й т ү н ә. Күрәм.
М ә м д ү д ә. Күрәсең шул: ике потлы герне 32 тапкыр күтәрә ул, сытып кына китерер.
З ә й т ү н ә. Сезгә миннән ни кирәк?
М ә м д ү д ә. Сезгә миннән ни кирәк? Ох, ох! Егылып үләрсең. Калдыр Җәүдәтне. Әнә чукынып кара шул индийский киноңны, әкиятеңне.
З ә й т ү н ә. Әкият түгел ул, матур тормыш, ялгышасыз сез...
М ә м д ү д ә. Йә, йә, кылтайма. Хәзер акылга утыртырмын.
З ә й т ү н ә. Нинди дорфа сез... Алай ярамый...
М ә м д ү д ә. Нәрсә? Әле син миңа, анаң хәтле апаңа акыл өйрәтәсеңме? (*Сугып җибәрә.*)

Зәйтүнә йөгерә.

Кара аны, Җәүдәткә якын киләсе булма, ул минеке булачак. Чикерткә! (*Җырлап китә.*)

М ө х ә м м ә т х а н, Җ ә ү д ә т пәйда булалар.

М ө х ә м м ә т х а н. Тиле икән син, агаем. Шуның өчен кеше яндыралармыни?
Җ ә ү д ә т. Эх, Мөхәммәтхан абый... Йөрәк яна бит! Ничек идек бит.
М ө х ә м м ә т х а н. Тынычлан. Болай ярсып кына үзеңә карата алмассың.
Җ ә ү д ә т. Тагын шул дүрт серияле индийский кино алып кайтсаң, бел, чыра пычагы белән акыртып суям мин сине.
М ө х ә м м ә т х а н. Йә инде, болагайланма. Әнә карале, мәхәббәтең үзе дә биргә таба килә түгелме?
Җ ә ү д ә т. Зәйтүнә...
З ә й т ү н ә. Нәкъ шулай булды... Зиртаны егетеннән аерырга теләделәр, аердылар... кызның яңагына суктылар, ә соңыннан кыз, түзә алмыйча, кыядан түбән ташланды... һәм үлде...
Җ ә ү д ә т. Кем үлде?

З ә й т ү н ә. Зирта — һинд кызы... Ул үлде... Юк! Кызның артыннан куып җитәргә дә, аны туктатырга, коткарырга кирәк!..

Җ ә ү д ә т. Ни булды сиңа, Зәйтүнә?..

З ә й т ү н ә. Иң дөрес юл! Хушыгыз!.. (*Йөгерә-йөгерә биек тауга таба ашыга.*)

Җ ә ү д ә т. Туктале, тукта, Зәйтүнә...

Җәүдәт һәм Мөхәммәтхан Зәйтүнә артыннан йөгерәләр. Ә бу вакытта Зәйтүнә тау кырыена килеп җитә, күзләре кемнедер эзли, шунда кызның аягы таеп китә, ул тау астына егылып төшә. Тынлык. Бераздан Җ ә ү д ә т һәм М ө х ә м м ә т х а н килеп җитәләр.

М ө х ә м м ә т х а н. Менә шушындарак ишетелде бугай тавышы.

Җ ә ү д ә т. Кайда соң ул?! (*Кычкыра.*) Зәй-әй-түнә! Зәйтүнә! (*Астан ыңгырашкан тавыш ишетелә.*) Зәйтүнә... ул анда! (*Тиз генә тау астына таба сикерә.*) Мөхәммәтхан абый, Зәйтүнә монда... Йа Аллам, ул егылып төшкән, мескенем, Зәйтүнәм... уян инде, Зәйтүнә! Нәрсә карап каттың, тиз бул врачны — Кәбирә апаны алып килегез! (*Кычкыра.*) Тизрәк! Ул үлә-ә-ә!

Мөхәммәт каушавыннан урынында тик басып тора.

М ө х ә м м ә т. Бу кадәр тамаша, бу кадәр шашу белән үзебез һинд киносына әйләнеп бетәбез бугай инде... (*Кычкыра.*) Кәбирә, Кәбирә!

Мөхәммәтхан китә. Җ ә ү д ә т кызны кулына күтәреп өскә алып менә. З ә й т ү н ә селкенми, эндәшми, бер-ике җирдә күлмәге ертылган, тәннәре сыдырылган, бернинди кан юк. Бу вакытта кызның әтисе — Г а б д р а х м а н, аннан авыл врачы К ә б и р ә күренә.

Җ ә ү д ә т. Зәйтүнә... Зәйтүнә, уян инде...

Г а б д р а х м а н. Кызым... Нәрсә булды аңа? Нишләттегез аны?!

Җ ә ү д ә т. Аңа беркем дә кагылмады... Ул үзе егылып төшкән...

Г а б д р а х м а н. Үзе?.. Колагыгызны, күрсәтермен мин сиңа — үзе!

К ә б и р ә (*кызны караганнан соң*). Болай әллә нәрсә беленми, ярасы да юк. Үзе бик курыккан... Тизрәк өенә алып кайтырга кирәк.

Җәүдәт кызны күтәрә һәм берничә адым ясый. Зәйтүнә кинәт һинд җырын җырлап җибәрә.

Г а б д р а х м а н (*артта килеш*). Ни булды бу? Кино бетмәдемени әле?

К ә б и р ә. Бу — Зәйтүнә...

Г а б д р а х м а н. Зәйтүнә?

К ә б и р ә. Әйе, кино күптән бетте инде.

Җ ә у д ә т. Юк... Кино бетмәде әле... Зәйтүнә, Зәйтүнә...

Зәйтүнәне өенә алып кайталар.

Ут сүнә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Председатель өе. Караватта З ә й т ү н ә ята, селкенми. Г а б д р а х м а н әрле-бирле йөри. М ө х ә м м ә т х а н һәм К ә б и р ә утырганнар.

Г а б д р а х м а н. Ике врач, бер Казан профессорын чакырттым. Берсе дә берни әйтә алмыйлар, төгәл диагноз куймыйлар... кызым, бәгърем...

К ә б и р ә. Ярый, мин өйгә кайтып, бераз йоклап алыйм. Кирәк булсам чакырыгыз.

Г а б д р а х м а н. Рәхмәт, Кәбирә, чакыртырмын. (*Кәбирә китә.*)

М ө х ә м м ә т х а н. Ярый, иптәш председатель, мин дә китим инде...

Г а б д р а х м а н. Тукта! Беркая да китмисең, иптәш завклуб.

М ө х ә м м ә т х а н. Бер генә сәгать йоклап алыйм инде, иптәш председатель?

Г а б д р а х м а н. Бер сәгать түгел, бер секунд та йоклатмыйм мин сине хәзер! Кызымны терелтмичә беркая да китмисең...

М ө х ә м м ә т х а н. Минем ни гаебем бар инде монда, иптәш председатель?

Г а б д р а х м а н. Дәшмә! Ничә тапкыр әйттем: алып кайтма шул «һинди-минди» киносын, дип. Колхозчылар иртән эшкә соңга калалар, кайберләре бөтенләй эшкә чыкмый. Һаман шул кино турында гына сөйләшәләр. Башка кинолар беткәнмени соң?!

М ө х ә м м ә т х а н. Бар. Ләкин ул тавышсыз, совет киноларына беркем дә килми. План үтәлми. Ә һинд киносына бөтенесе өерелеп килә. Авырулары да, аксаклары да, чукраклары да, сукырлары да килеп утыралар...

Г а б д р а х м а н. Әйе шул, кинога киләләр, ә эш вакытында йоклыйлар! Нигә, ни өчен дип сорыйм мин синнән, ә?!

М ө х ә м м ә т х а н. Белмим инде, иптәш председатель...

Г а б д р а х м а н. Белмисең? Ә нәрсә генә беләсең соң

син? Ике ел ярым культпросветта колхоз акчасын әрәм итеп нәрсәгә генә укыттым мин сине, иптәш завклуб? Менә нәрсә, әгәр кызымны терелтмәсәң, укыткан өчен тотылган алты йөз сиксән сум 23 тиенне дә түләтәм, кызымны имгәткән өчен, статья белән мәңгелеккә утыртам мин сине, иптәш подсудимый, бывший завклуб!

Мөхәммәтхан. Иптәш председатель!

Габдрахман. Дәшмә!.. Сохарины кибеттән талонсыз алырсың, мин кушты диярсең. Бер генә кило ал, аңладыңмы?.. Кәҗәңне колхоз исеменә күчерәм, өеңне сатам!

Мөхәммәтхан. Иптәш председатель, зинһар өчен...

Габдрахман. Теш пастасы, кружка, сөлге... сабының бармы?

Мөхәммәтхан. Юк...

Габдрахман. Мә, ал, миннән соңгы яхшылык... Мин хәзер управлениегә китәм, тиздән кайтам. Ә син уйла: йә кызым, йә бер кешелек камера... (*Ишекне тышкы яктан бикләп чыгып китә.*)

Мөхәммәтхан. Килеп каптым. Бөтенесенә дә мин гаепле... Нишләргә инде хәзер? Әгәр Зәйтүнә терелсә, гомердә дә күрсәтмәс идем шул һинд киносын!

Зәйтүнә кинәт урыныннан тора һәм һинд телендә җырлый башлый, үзе Мөхәммәтне күрми. Мөхәммәт куркуыннан ишеккә барып ябыша, тибенә-тибенә кычкыра башлый.

Мөхәммәтхан. Ко-о-открыгыз!.. Ул то-о-рды! Үтерә-ә-әләр...

Бу тавышка тәрәзәдән атылып Җәүдәт керә.

Җәүдәт. Нәрсә булды? Нишләтәсең син аны? Зәйтүнә...

Мөхәммәтхан. У-у-у-ул мине үтерә ба-а-а-ашлады, коткарыгыз...

Җәүдәт. Зәйтүнә, бәгырь кисәгем, тынычлан, мин синең яныңда. Ишетәсеңме мине, әйдә ят әле урыныңа... менә шулай.

Зәйтүнә урынына менеп ята.

Нәрсә генә эшлим соң, Зәйтүнәм?

Мөхәммәтхан тәрәзәдән чыга башлый. Аны Җәүдәт туктата.

Мөхәммәтхан. Җибәр, җибәр мине, минем утырасым килми, ач камера ишеген... сохари, кружка, сабын...

Җәүдәт. Нәрсә лыгырдыйсың син, ниткән камера, нинди кружка, сабын?

Мөхәммәтхан. Җәүдәт, коткар мине, юк, мине түгел — Зәйтүнәне, югыйсә миңа... (*Бармагы белән тимер читлек күрсәтә.*)

Җәүдәт. Тынычлан, ул йоклый, йә, хәзер уйлашыйк, Мөхәммәт абый...

Мөхәммәтхан. Җәүдәт, зинһар, уйлап тап берәр нәрсә... Башыма бернинди фикер килми... (*Уйлыйлар.*) Җәүдәт, ни...

Җәүдәт. Нәрсә?

Мөхәммәтхан. Әйт әле, бер кило сохари күпме тора икән ул?..

Җәүдәт. Белмим. (*Тагын уйлыйлар.*)

Җәүдәт (*кинәт*). Таптым!

Мөхәммәтхан. Свобода!!! Рәхмәт, Җәүдәт... ярый, мин киттем.

Җәүдәт. Тукта. Кая киттең?

Мөхәммәтхан. Тыңлыйм...

Җәүдәт. Теге һинд кинолентасы клубтамы?

Мөхәммәтхан. Әйе.

Җәүдәт. Алайса — киттек шунда...

Җәүдәт Зәйтүнәне күтәреп, тәрәзәдән чыга. Клубка китәләр. Клуб эче. Залда беркем юк. Зәйтүнәне беренче рәткә кертеп утырталар. Мөхәммәтхан аппаратын кабыза: экранда һинд киносы, җыр ишетелә. Экранда сурәтләр барлыкка килү белән, Зәйтүнә терелеп киткәндәй уянып китә. Елмая, шатлана, җырга кушыла. Читтән күзәтеп торучы Җәүдәт һәм Мөхәммәтхан шат күңелле Зәйтүнәне күреп елап җибәрәләр. Бу вакытта киноаппарат янып төшә, лента эреп, ябышып бетә. Зәйтүнә кабат сүрелә, элеккеге «авыру» халәтенә кайта.

Җәүдәт (*шатланып*). Аңладыңмы инде?

Мөхәммәтхан. Аңладым: аппарат янды... Беттем...

Җәүдәт. Бетмәдең. Күрдеңме, ул ничек терелеп киткәндәй булды?..

Мөхәммәтхан. Әйе, күрдем.

Җәүдәт. Димәк.

Мөхәммәтхан (*шатланып*). Димәк, безгә дә шундый...

Җәүдәт. Тс-с! Ишетмәсен. Әйдә киттек...

Кызны күтәреп алып чыгып китәләр.
Председатель өе. Зәйтүнә караватта ята.
Мөхәммәтхан, Җәүдәт, Кәбирә, Мәмдүдә утыралар.
Председатель әрле-бирле йөри.

Габдрахман. Эксперимент уңышлы үтүе сездән тора. Әгәр уңышлы үтәлмәсә, барыгызны да утыртам, Себер җибәрттерәм. Инде эксперимент шартларына килсәк: авылны буярга, бизәргә, чәчәкләр утыртырга һәм башкалар. Кыскасы, авылның яшен-картын һинд милли

киемнәренә кидертергә. Авыл халкын һиндча җырларга, биергә һәм минимум һинд телендә 32 сүз белергә тиеш. Хәзерге көннән алып сез «Кызыл маяк» колхозы кешеләре түгел, ә индуслар!..

Мәмдүдә. Кемнәр?

Габдрахман. Иблисләр... тфү, индуслар! Оештыру эшләрен иптәш завклубка йөклим.

Мөхәммәтхан. Иптәш председатель...

Габдрахман. Дәшмә! Тыңламасалар, миңа җиткерерсең!

Кәбирә. Менәтерәк?! Синме соң бу, Габдрахман?! Әллә кайчан кирәк иде ул. Дуңгыз абзарына әйләнеп беттек...

Мәмдүдә. Иптәш председатель, мин дә биергә тиешме?

Габдрахман. Син дә!

Мәмдүдә. Ә трактор?..

Габдрахман. Трактор да... Нинди трактор?

Мәмдүдә. «К-700»ны әйтәм.

Габдрахман. Бер атнага онытып торырсың.

Мәмдүдә (*еларга җитешеп*). Бу кадәр кансыз булырсыз икән, иптәш председатель...

Габдрахман. Мөхәммәтхан!

Мөхәммәтхан. Мин монда, иптәш председатель.

Габдрахман. Син Зәйтүнәнең тән сакчысы булырсың.

Мөхәммәтхан. Нигә?

Габдрахман. Кирәккә. Аңлашылдымы?

Мөхәммәтхан. Артыгы белән.

Мәмдүдә. Ә миңа?

Габдрахман. Ни җитми сиңа тагын?

Мәмдүдә. Тән сакчысы... Әнә Җәүдәт сакласын мине. Кочаклап кына йөртермен, беркемгә тидермәм... үзем дә кыерсытмам.

Җәүдәт. Зинһар, бирмәгез, иптәш председатель. Аның кай төшен саклыйсың? Кем тия алсын аңа?

Габдрахман. Ярар, карарбыз.

Кәбирә. Ну, маладис, Габдрахман кордаш, иң кирәкле эшкә — авылны ямьләндерү эшенә тотынгансың.

Габдрахман. Зав!

Мөхәммәтхан. Гав! Тәртип! Тавыш! Барыгыз да шаго-о-ом марш!

Бөек күчену башлана. Клуб мөдире анда-монда күрсәтмәләр бирә, шабыр тиргә баткан. Бар декорация үзгәрә, киемнәр алышына. Кемдер һинд биюен кабатлый, кайсыдыр җыр сүзләрен өйрәнә.

Мөхәммәтхан. Булдымы болары? Игътибар, игъ-

тибар! Уф, җәмәгать, монда карагыз әле, үтерәсез бит. Зинһар, тыңлагыз! Иптәш председатель...

Габдрахман. Бу нәрсә?! Ник тыңламыйсыз завклубны? Ягез, җыелыгыз әле! Җәүдәт, ник сөйрәләсең?

Җәүдәт. Өлгерә алмыйм...

Мөхәммәтхан. Исәнләшүне кабатлап алабызмы?

Мәмдүдә. Йөз кабатладык бит инде. Мин сиңа бәлүрин мәллә?

Кәбирә. Сыерымны ничек савам инде мин хәзер. Бу киемнәр белән танырмы икән?

Мәмдүдә. Трактордан төшми эшләр идем, иптәш председатель, китим мин, ә?

Габдрахман. Тавыш! Беркем дә китми. Зәйтүнә үзен нәкъ Индиядә кебек хис итәргә тиеш. Берәрегез генә ялгышып сиздереп карагыз, колаксыз калдырам!.. (*Мәмдүдәгә.*) Маңгаеңдагы кызыл тамгаң кайда?

Мәмдүдә (*үпкәләп*). Хәзер ябыштырам.

Габдрахман. Алга таба нәрсә, завклуб?

Мөхәммәтхан. Исемнәрне үзгәртү.

Габдрахман. Яле, тезелеп басыгыз.

Тезелеп басалар.

Мөхәммәтхан. Бераздан өйдән Зәйтүнәне алып чыгабыз. Аның исеме хәзер Зәйтүнә түгел, һиндча — Зирта була, әйеме. Җәүдәт, син шушы минуттан Джимми буласың...

Җәүдәт. Нинди Джими тагын? Син нәрсә?

Габдрахман. Җәүдәт, тавышланма.

Җәүдәт. Нигә ул үртәшә? Бирермен мин аңа, и-и-и-и...

Мөхәммәтхан. Мин үртәшмим. Һиндча шулай була ул. И-и-и, түгел, Джимми. Д, Д... аңгыра сарык.

Габдрахман. Аңладыңмы?

Җәүдәт. Аңладым.

Мөхәммәтхан. Мәмдүдә, син...

Мәмдүдә. Кара аны, Мөхәммәтхан абый.

Мөхәммәтхан. Син, Мәмдүдә, йомшак кына әйткәндә, Матху буласың.

Җәүдәт шаркылдап көлә.

Габдрахман. Җәүдәт, Джимми!

Җәүдәт. Кызык ич.

Мәмдүдә. Нәрсә? Яле, кабатлале, кәкре сыйрак...

Җәүдәт. Матху, ха-ха-ха, Матху, үләм...

Мәмдүдә. Минем Матху буласым килми. Йә Зита, йә Гита булсын.

Габдрахман. Булырмын мин сиңа, Матху, и бетте китте! Бик матур исем. Көлмәскә, дидем, колагыгызны... Дәвам ит.

Җәүдәт. Үзенә кушмаган.

Мәмдүдә. Нәчәлство үзен әбижать итсә...

Габдрахман. Дәшмә! Син ничек...

Мөхәммәтхан. Иптәш председатель, сез йомшак кына әйткәндә, Брахман буласыз. Мин сезнең рөхсәт белән Мутарелли булам. Кәбирә түти — Канзас...

Кәбирә. Нишләп кансыз булыйм ди инде мин... Черкине дә рәнҗеткәнем булмады. Зинһар...

Габдрахман (*Мөхәммәткә*). Беттеме?

Мөхәммәтхан. Бетте.

Габдрахман. Бетсә, хәзер Зәйтүнәне бирегә алып киләм...

Шул вакыт, һинд киемендә бии-бии, Зәйтүнә килеп чыга. Ул искиткеч матурайган, аны танырлык түгел. Барысы да каушап, Зәйтүнәгә карап катып калалар. Дәртле һинд биюе бөтен урамны ямьләндереп җибәрә.

Кәбирә. Әстәгъфирулла! Кем бу?..

Габдрахман. ...Минем кызым кайда?..

Җәүдәт. Мин кайда?

Мәмдүдә. Әнеккәем, тагын кино җибәрделәр...

Мөхәммәтхан. Су, су бирегез... (*Аңын җуеп җиргә ава.*)

Зәйтүнә-Зирта. Исәнмесез.

Брахман. Исәнме, кызым ... Зирта.

Зирта. Сез мине каян беләсез?

Брахман. Син мине танымыйсыңмы Зәй... Зирта?

Зирта. Тавышыгыз таныш, күргәнем дә бар кебек...

Брахман. Мин бит синең әтиең...

Зирта. Әтием... әһә, исемә төште... Бөек махарадж. Ә сез... (*Кәбирәгә*) минем әнием. Син миңа бәләкәй чакта күңелле, гүзәл тормыш турында сөйли торган идең, әнием...

Джимми (*Мутареллига*). Мескен, бернәрсә дә хәтерләми... Эх, Зәйтүнә...

Мутарелли. Бөтенләй беткән бит бу... Шариклары бушаган. Өйләнеп тә җибәрсәң әле...

Джимми. Юләр мәллә мин. Аллам сакласын.

Брахман. Ә бу безнең иң уңган тракторчыбыз, әй, ни, хе-хе, чәй комбайнында эшләүче «чибәребез» — Матху.

Зирта. Шулаймыни? Нинди матур исем, сезгә бик килешә... Мин сезне кайдадыр күргән кебек...

Матху. Минем дә күргәнем бар кебек... Хәзер сез

тагын да акыллырак күренәсез. Бигрәк әйбәт булган инде...

Зирта. Ә сез мине кайдан беләсез?

Матху. Беләм, белмәскә... көн саен күрәм...

Брахман (*аңа йодрык күрсәтеп*). Матхушка! (*Елмаеп.*) Ә менә бу безнең иң атаклы кешебез — Мутарелли, бай сәүдәгәр, тиздән Себергә барырга җыена...

Зирта. Мутарелли... Мутарелли! Әтием, үтенәм синнән: мин аңа кияүгә чыкмыйм, чыкмыйм, беркайчан да! (*Канзаска.*) Әнием, коткар мине!..

Канзас. Юк, юк, кызым, сине беркем дә аңа кияүгә бирергә җыенмый, тынычлан... (*Председательгә.*) Саташа, бәгырь кисәгем. Мөхәммәтне күрсәтмәскә кирәк Зәйтүнәгә.

Брахман (*Мутареллига*). Бар, читкәрәк барып тор. Соңыннан сөйләшербез әле синең белән! (*Зиртага.*) ... Зирта, менә бусы алдынгы трак... әй лә, ни, әйе, фил көтүчебез — Джимми.

Зирта. Джимми?! Джимми, кайттыңмы, сөеклем, мине сагынып кайттыңмы?! Әтием, әнием, ул кайтты...

Брахман. Әйе, әйе, кызым, ул бүген генә кайтты. (*Джиммига.*) Синең белән дә яхшылап сөйләшәсе булыр, Джимми!

Зирта. Джимми... (*Җәүдәтнең маңгаеннан үбә, Җәүдәт аңын җуеп җиргә егыла.*)

Брахман. Нәрсә булды аңа?.. Джимми, Джимми, тор әле... (*Битен чәбәкли, егет аңына килә.*)

Зирта. Джимми, нәрсә булды сиңа? Ник бер дә куанмыйсың?..

Джимми. Ни иде... ә-ә, минем бертуган сеңелем авырып тора иде, ул исемә килеп төшеп, башым әйләнеп китте...

Зирта. Авырый? Ә сеңелең ни исемле?

Джимми. З... З... Зәйтүнә... Сәламәт вакытта Зәйтүнәне бер егет яратып йөри иде...

Зирта. Ул кызның авыруы бик көчлеме? Терелә алырмы?

Джимми. Юк, юк, беркайчан да... Белмим.

Зирта. Борчылып барыбер ярдәм итеп булмый... Телисеңме, мин сиңа җырлап бирәм?

Джимми. Юк, юк, теләмим... (*Аңа Брахман төртә.*) Телим икән, бик...

Зирта. Рәхим итегез, сезнең өчен генә... (*Һинд җырын җырлый.*)

Алтынланып кояш уйный күк йөзендә,
Чәчкә аткан бар гөлләр дә җир йөзендә...
Бар галәмгә ямьнәр кергән бу көннәрдә...
Якты нурлар балкып тора һәрбер йөздә...

Кушымта:

Яктыда уйныймын,
Сафлыкта йөзәмен,
Җанымның очканын сизәмен...
Җан дуслар янымда,
Йолдызлар ягымда,
Галәмне иңлимен, гизәмен...

Күпме яшәп күрелмәгән бу яктылык...
Күпме йөреп сизелмәгән бу пакьлелек...
Мин бәхетле, тоям элек тоймаганны...
Мин бәхетле, яшим, яңып яшьнәгәндәй...

Якты нурлар синнән микән, әй тормыш...
Яшәү көче бирә кемнәр, әй язмыш...
Мин мәңгелек белән тоташ хәзер, йа Аллам...
Мәңге шулай яшә икән, сөйгән ярым...

Брахман (*күз яшьләрен сөртеп*). Бик матур җырлыйсың, кызым, рәхмәт.

Зирта. Ә хәзер.

Брахман. Әйе...

Зирта. Мине үземне генә калдырсагыз иде.

Брахман. Баш өсте.

Зирта. Джимми монда калсын.

Джимми. Мин? Юк, мин булдыра алмыйм, минем...

Брахман (*йодрык селки*). Булдырырсың. Хе-хе, булдыра, булдыра торган егет ул. Фил хәтле фил көтүе көткәнне, анысын гына... Ярый, киттек без. (*Джиммига.*) Кара аны, эшне бозсаң...

Канзас. Җәүдәт, берүк егыла күрмә...

Барысы да китәләр.

Джимми. Син... сез шундый матур...

Зирта. Син дә бик матур.

Джимми (*үз-үзенә*). Ай мескенем, мескенем, Зәйтүнәм, ни булган сиңа? Ничек ярата идем мин сине. Ә хәзер ничек качып китәргә белмим...

Зирта. Син ни сөйләнәсең?

Джимми. Ә-ә, ни, дога укыйм.

Зирта. Сез будда динендәме?

Д ж и м м и. Әйе, бутто бы динле шикелле.

З и р т а. Ни хакында дога укыйсыз, сер булмаса?

Д ж и м м и. Сезнең хакта.

З и р т а. Рәхмәт. Ләкин минем бар да әйбәт.

Д ж и м м и. Алайса, мин китим?

З и р т а. Юк, синең янда миңа бик рәхәт.

Д ж и м м и. Миңа да... (*Үз-үзенә.*) Йа Хода, нәрсә сөйлим мин?.. Китәргә кирәк, әллә кая кереп киткәнче, Алла сакласын...

З и р т а. Синең иреннәрең...

Д ж и м м и. Мин... мин... (*Куркып калып.*) Моңарчы үзем теләп йөреп, хәзер үзем үк карышам... Йа Хода. Мин бик ашыгам... Хушыгыз! (*Чыгып йөгерә.*)

З и р т а. Джимми, Джимми! (*Артыннан йөгерә.*)

Б р а х м а н белән М у т а р е л л и керәләр. Алар киемнәренә буталып беткәннәр, абыналар, сөртенәләр. Икесе дә алҗыганнар.

Б р а х м а н. Син, завклуб башың белән кайчан минем кызымның башын әйләндерергә өлгердең, ә?! Өйләнәсе килгән аның! Хәзер шулай итеп өйләндерәм мин сине!..

М у т а р е л л и. Иптәш председатель, сез нәрсә инде, мин кызыгызны күргәнем дә булмады, мин аны бөтенләй белмим. Нәрсә генә ишетмәссең ул юләр кыз авызыннан...

Б р а х м а н. Нәрсә дидең?

М у т а р е л л и. Мин әйтәм: җүләрләнә башладым, ахрысы, мин. Һич кенә аңлый алмыйм — әллә кино күрсәтәм, әллә төш күреп, миңгерәп йөрим. Иптәш председатель, чеметеп карагыз әле...

Б р а х м а н. Уф, үтерә бу кызый, нишләргә дә белгән юк. Башка бәла булды. Син дә...

М у т а р е л л и. Нәрсә мин?

Б р а х м а н. Шул тузга язмаган кино күрсәтеп... башка бәла ясадың. Ничек әйбәт кенә, тыныч яши идек бит... кызым...

М у т а р е л л и. Ни эшлибез инде хәзер?

Б р а х м а н. Нишлибез, нишлибез, мин синнән сорарга тиеш, иптәш завклуб?

М у т а р е л л и. Иптәш председатель, бер нәрсә әйтсәм, ачуланмассызмы?

Б р а х м а н. Әйт.

М у т а р е л л и. Теге егет кызга сагыз булып ябышты, мин әйтәм, Алла сакласын, бозылышып китмәсеннәр...

Б р а х м а н. Кара аны, кызым өчен башың белән җавап бирәсең...

Мутарелли. Алайса, аларны бик мавыктырмаска кирәк.

Брахман. Әлегә йөрсеннәр. Берни юк. Әгәр бик эчкә кереп китсәләр — аерырга кирәк...

Мутарелли. Ничек итеп?

Брахман. Үзең бел инде анысын. Гел өйрәт сине. Нәрсәгә укыттым мин сине? Колхоз акчасын туздырып...

Мутарелли. Көчләп җибәрдегез дә... Өйләнә дә алмый йөрим. Хөрмәт юк. Сыер сауган килеш кенә калган булсам, теләсә нинди кыз йөгереп килә иде. Дояр егетләрне ярataлар алар...

Брахман. Ярый, ярый, җылама... Кызымны гына терелт. Утынны өстәбрәк бирермен.

Мутарелли. Ярар, тырышырмын.

Брахман. Уттай эш өстендә кәфен, тфү, әстәгъфирулла-тәүбә — сари урап... Печән өстендә... Ну, акылына килсә! Ну, акылына килсә!..

Мутарелли. Чү, үзе килә!

Брахман. Киен тизрәк!

Мутарелли. Килеп җиту белән, бии башларга кирәк...

Бик кызу итеп бии башлыйлар. Зирта керә.

Брахман. Ни булды, Зирта?

Зирта. Джимми, Джимми мине ташлап китте.

Брахман. Ничек? Кара син аны маңка малайны, әй, гафу, индусны, мин аны!..

Мутарелли. Бер дә борчылмагыз, Зирта. Хәзер без аны...

Зирта. Бар да бетте! Ул мине ташлады... Ах! Минем яшәүнең мәгънәсе калмады! Мин кыядан... (*Йөгереп чыгып китә.*)

Брахман (*йөрәген тотып*). Кая? Тагын сикерергә? Бар, бар, тизрәк тап Җәүдәтне! Туктат кызымны!!!

Мутарелли кыз артыннан йөгерә.
Матху күренә.

Брахман. Матху, Матху, Мәмдүдә, дим... Нәрсә ташбака кебек атлыйсың. Атла тизрәк!

Матху. Тыңлыйм әфәндем?! (*Бик озак итеп баш ия, ритуал ясый.*)

Брахман. Чукынмале шул... Туйган. Кая карама индуслар. Берәр нормаль кеше калдымы бу дөньяда?!

Матху. Соң үзегез бит һиндиячә генә...

Брахман. Минем каршыда түгел, Зирта янында гына... аңгыра баш! Бар, тизрәк врачны монда чакырт!

М а т х у. Миңа врач кирәк түгел әлегә, иптәш председатель, Аллага шөкер.

Б р а х м а н. Сиңа түгел, миңа кирәк! Аңгыра бәрән...

М а т х у. Шулай диләр аны! (*Нидер сизенеп.*) Кәбирә апа... (*Ашыкмыйча чыгып китә.*)

Б р а х м а н. Уф, йөрәгем, тагын ниләр күрәсем бар икән?

М у т а р е л л и Д ж и м м и н ы алып керә.

Б р а х м а н. Ә синмени әле бу? Кил әле монда!

М у т а р е л л и. Менә карышкан була, тыңламый, иптәш председатель.

Б р а х м а н. Ни эшләдең син, ә? Бөтен эшне бозып йөрисең! Синең нәрсә, башка яшисең килмиме, ә?

Д ж и м м и. Ни эшләгән тагын? Берни эшләмәдем... Менә карагыз: бу чүпрәкләрегез дә урынында, алкам да борынымда...

М у т а р е л л и. Төтен җибәрә, иптәш председатель...

Б р а х м а н. Нигә ташлап киттең баланы?!

Д ж и м м и. Мин...

М у т а р е л л и. Колхоз ышанычының кадерен белмичә. Хөрәсән!

Д ж и м м и. Мин, ни, аның белән чак кына үбешми калдым... куркам мин аннан...

Б р а х м а н. Куркам? Эх син, егет кисәге! Ә мин тагын Зәйтүнәне... ялгышканмын...

Д ж и м м и. Иптәш председатель, мин...

Б р а х м а н. Бар, артыннан йөгер. Ату кыядан ташланмакчы иде.

Д ж и м м и. Юләрем, син нәрсә инде! (*Йөгереп чыгып китә.*)

М у т а р е л л и. Шул кыз артыннан шашып йөри иде бит...

Б р а х м а н. Бар, артларыннан калма.

М у т а р е л л и. Баш өсте, махарадж... (*Китә.*)

К а н з а с керә.

К а н з а с . Брахман, Брахман. Нәрсә булды, кая Зирта?

Б р а х м а н. Кәбирә, әйтмәле шул исемне...

К а н з а с . Тс-с! Зирта ишетмәсен...

Б р а х м а н. Зәйтүнә Җәүдәт белән...

К а н з а с . Нинди Зәйтүнә, Җәүдәт турында әйтәсең син?..

Б р а х м а н. Йә, Кәбирә, уян әле, бу мин — Габдрахман...

К а н з а с . Бәрәкалла, Габдрахман, танымый торам үзеңне.

Б р а х м а н. Кара, белмәгәндәй кылана. Бик чабып карадым да артыңнан, син генә күз салмадың.

К а н з а с . Әй булган икән шул яшь чаклар. Син өйләндең, кызың туды.

Б р а х м а н. Синең кияүгә чыкмаганыңны һич аңлый алмыйм мин, Кәбирә? Чибәр, алтын куллы кыз бит син...

К а н з а с . Мин бит сине...

Б р а х м а н. Чынлапмы?

К а н з а с . Әйе... Карале, Габдрахман, ничек ямьләндерден бит авылны. Нәкъ без яшь чактагы вакытка охшап калды. Яшьлек һинд киносы кебек үтте дә китте, име, Габдрахман?..

Б р а х м а н. Ә мин яшьлеккә кире кайткандай булдым, Кәбирә. Күрәсеңме, тирә-юньгә ямь керде, күңел сөенә, әйдә, кайтыйк без яшьлеккә... Кызым терелсә, сиңа хәзерге кебек, әнием дип эндәшер...

М а т х у керә.

М а т х у. Әһем-әһем!

Б р а х м а н. Син? Син ни эшләп йөрисең монда?

М а т х у. Нишләп йөрисең? Сезгә күңелле. Ә мин ни эшлим?

К а н з а с . Әллә берәр нәрсә булдымы?

Матху эндәшми.

Б р а х м а н. Берәрсен кыйнадыңмы әллә?

М а т х у. Кыйнарсың бар. Бөтенесе шундый итагатьле булып беттеләр. Авыз тутырып тәмле сүзләр кыстырып сөйләшергә беркем калмады, бөтенесе үзгәргән... сугышырсың монда...

Б р а х м а н. Тукта, туктале, кызмале син.

М а т х у. Тракторга утырып качыр идем — тракторымны яшергәннәр. Тормышның бөтен ямен алдыгыз!

Б р а х м а н. Төкер әле шул «К-700»ыңа! Күз сал әле тирә-ягыңа: нинди матурлык, ямь. Ничек шатлана бөтен кеше!

М а т х у. Нәрсә? Ни булды сезгә? Әллә сез дә теге, ни... әллә ниләр сөйлисез. Печән өсте, ә председатель...

М у т а р е л л и керә.

М у т а р е л л и (*Матхуга*). Менә син кайда икәнсең.

М а т х у. Менә тагын берсе... Йөрмә әле син дә буталып...

М у т а р е л л и. Брахман кушмаса, сукыр тиенгә кергән бар иде.

М а т х у. Әллә синең кирәгең бармы? Ник шунда...
М у т а р е л л и. Бу киемнәрне кигәч, син шундый матураеп киткәнсең...
М а т х у. Нәрсә? Син нигә мине мыскыл итәсең, ә?! Ипи шүрлегең кычытып торамы әллә?
М у т а р е л л и. Гел комбинезонда йөргәч, мужикка әйләнеп бара идең... Шул киемнәрдә генә кал син, Матху-ду-дә...
М а т х у. Калды ди, көтеп тор! Менә бу кәмитегез генә бетсен, бөтенләе белән мичкә ыргытып яндырам, исән калсам!
М у т а р е л л и. Берүк яндыра күрмә! Киемнәр клубныкы, гомер түләп бетерә алмассың! Әгәр бу күлмәкне һаман киеп йөрергә вәгъдә бирсәң, мин аларны сиңа бушка гына списать итәрмен, Матху-ду-дә... Йә, ризамы? (*Җырлый.*)

Һинд киеме үзеңә бирдерермен,
Һинд күлмәге генә киярсең...
Салдырырга теләсә берәрсе —
Мөхәммәтхан бирде диярсең!

К у ш ы м т а:

Мәмдү, Мәмдү, Мәмдүдә,
Йөрешләрең ямьле лә!
Матху, Матху, Мадхут-тай,
Безнең эшләр дә худта!

Клуб киемен списать иттерермен,
Матур кызкай гына булып кал...
Асыл, ефәк кенә кидерермен,
Кожанкаңны гына, зинһар, сал...

Син киярсең ефәк сариларың...
Мин киярмен ап-ак шаровар.
Син килерсең миңа кунак булып,
Мин куярмын сиңа самовар.

М а т х у. Тукта әле, син нигә миңа алай карадың? Йөрәгем авыртып китте. Слушай, башка миңа алай итеп карама, ике күзең янына тагын бер запасноен борып куярмын!
М у т а р е л л и. Мин риза...
М а т х у. Нәрсә риза?
М у т а р е л л и. Өч күзле булырга.
М а т х у. Туктыйсыңмы, юкмы, күпме көләргә була

ялгыз, ярдәмчесе булмаган, көчсез, мескен кыздан? Иптәш председатель, нәрсә ул мине шулай мыскыл итә?..

Б р а х м а н. Җитте сезгә! Югыйсә икегезне дә дуңгыз карарга куям.

З и р т а керә. Борчулы.

З и р т а. Коткарыгыз! Коткарыгыз, анда Джимми.

Б р а х м а н. Ни булды, Джимми?..

З и р т а. Мин... тау башында Джимминың маңгаеннан үбәргә теләгән идем, ул артка чигенде һәм таудан төшеп китте...

К а н з а с. Харап кына булган икән.

М а т х у (*Зиртага*). Кеше үтерүче, аны син төртеп төшердең! (*Елый.*)

Б р а х м а н. Кызым... Джимми... Уф... йөрәгем, врач, врач кайда...

М у т а р е л л и. Хәзер барыбызга да Себер...

З и р т а. Дөрес аңламадыгыз... Тизрәк Джиммины коткарырга кирәк!

М а т х у. Коткарырга? Ничек?

З и р т а. Аңа берни булмады...

К ә б и р ә. Кызым, җүнләп кенә сөйлә: Джиммига ни булган, хәзер кайда ул?

З и р т а. Агач тамырында...

М а т х у. Кайда?

З и р т а. Ыштаны белән агач тамырына эләгеп калды. Әле дә шунда асылынып тора.

Б р а х м а н. Тизрәк, тизрәк, тауга чабыгыз, тартып алыгыз... Уф, йөрәгем, врач, врач, Кәбирә, Кәбирә...

Барысы да тауга таба йөгерәләр.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Председатель өе. Б р а х м а н берүзе. Маңгае салкын чүпрәк белән уралган, тавышы беткән, көчкә чыга. Урамда кычкырган тавышлар ишетелә. Этләр өрә. М у т а р е л л и председатель өенә килеп керә дә ишекне бикләп куя.

М у т а р е л л и. Иптәш председатель, коткарыгыз, үтерәләр...

Б р а х м а н. Ни булды?

М у т а р е л л и. Карарга теләмиләр, берсе дә сүзсез совет киносын карарга теләми... Будкадан сөйрәп чыгардылар да тотындылар изәргә: «Давай һинд, давай һинд

киносын җибәр!» — дип газаплый башладылар. Этләр белән кудылар, көчкә котылдым үзләреннән, тагын аз гына тырышсалар, үтерәләр иде бит, хайваннар...

Б р а х м а н. Дөрес эшләгәнсең, бернинди һинд киносы! Алар үтермәсәләр, мин сине буып үтерәм, аңладыңмы, завклуб?..

М у т а р е л л и. Ике көн өйдән чыгарга куркып ятам. Һәр почмак саен күзәтүчеләр, шпионнар куйганнар, үтерәләр алар мине, иптәш председатель. Бер генә серия күрсәтик булмаса, эрвәлюция ясап клубны үз кулларына төшерә күрмәсеннәр дип куркам...

Б р а х м а н. Ничава, кызым гына терелсен, күрсәтермен мин аларга эрвәлюция, төслесен, киң экранлысын... Сөйлә, кызым кайда булды, кем белән күреште? Кем белән сөйләште? Йөзендә терелү әсәре күренәме, юкмы?

М у т а р е л л и. Зирта иртән Джимми белән очрашты...

Б р а х м а н. Шуннан?

М у т а р е л л и. Шуннан Джимми белән, аннан тагын Джимми белән, кичкырын тагын Джимми белән...

Б р а х м а н. Джимми... сәер...

М у т а р е л л и. Иң начары...

Б р а х м а н. Иң начары? Ни булды?!

М у т а р е л л и. Бая Зирта Джимми белән болынга, аннан әрәмәгә чаптылар.

Б р а х м а н. Нәрсә? Нишлиләр алар анда?!

М у т а р е л л и. Анысын берничек тә белә алмадым, үзләре бииләр, җырлыйлар, сикерәләр, тәгәриләр...

Б р а х м а н. Тәгәриләр?!

М у т а р е л л и. Әйе.

Б р а х м а н. Шуннан?

М у т а р е л л и. Шул.

Б р а х м а н. Нәрсә шул?..

М у т а р е л л и (*колагына*). Юк булдылар.

Б р а х м а н. Ничек?

М у т а р е л л и. Әрәмәгә кереп...

Б р а х м а н. Уф, йөрәгем, врач, врач... Чиктән аша башлады бу... Туктатырга кирәк, кичекмәстән. Шушы ук минутта!

М у т а р е л л и. Ничек итеп?

Б р а х м а н. Уйла. Ничек итеп? Син нәрсәгә монда алайса, шуны да белмәгәч...

М у т а р е л л и. Таптым!!!

Б р а х м а н. Ну?!

М у т а р е л л и. Таптым?

Б р а х м а н. Әйт тизрәк, Ходa бәндәсе.

М у т а р е л л и. Урларга кирәк!

Б р а х м а н. Ничек урларга?

М у т а р е л л и. Шулай. Капчыкка салыпмы, бәйләпме... Теләсә ничек. Әлек бездә кыз урлаган шикелле!

Б р а х м а н. Туктале, туктале. Син чынлапмы?

М у т а р е л л и. Ну да. Урларга да вәссәлам!

Б р а х м а н. Юк, бу сүзләрне син уйлап әйтәсеңме, әллә җавап кирәк булган өчен генәме, ә?!

М у т а р е л л и. Иптәш председатель, «а» диегез әле...

Б р а х м а н. А...

М у т а р е л л и. Дөрес. Сез, чыннан да, аңгы... Сез... а-а-аңлап бетермәдегез: мин әйтәм, егетен, то есть Джиммины урларга кирәк!..

Б р а х м а н. Джиммины?.. Ә нәрсә? Әйбәт фикер бу!

М у т а р е л л и. Матхуга кушсак? Көчле. Барыбер көчен кая куярга белми йөри. Тынычланыр бераз, кулына эш тә булыр.

Б р а х м а н. Маладис, индус иптәш! Тәк-тәк. Шә-ә-әп, егет урлыйлар! Ха-ха-ха! Шәп. Бар алып кил атаманыңны!

М у т а р е л л и. Хәзер без аны... (*Китә.*)

Б р а х м а н (*үзалдына*). Әй кызым, барысына да мин генә гаепле. Мин шул көнгә калдырдым да инде сине. Әнисез, ятим үсте. Ятимлекне сизмәсен дип, бөтен теләгән әйберен ашаттым, яраткан киемнәр генә кидертеп үстердем. Ә кызның күңеле бөтенләй икенче нәрсәдә булган икән: һинд киноларыннан матурлык, җылылык эзләгән. Ана җылылыгын шул кино гына алыштыра алса икән. Терелсәң, өйгә әни алып кайтырмын... Йә, Кәбирә, син ризамы? Миңа кияүгә чыгарга ризамы?.. Ә? (*Җырлый.*)

Таң аткан чагында,
Кичләрен тагын да,
Сагышлана күңел, моңлана...
Исләргә төшәсең,
Үзәкне өзәсең,
Күзләрем чарасыз дымлана...

Аерым аралар,
Йөрәкләр яралы,
Очрашалмый җаннар сызлана...
Кояш кире батмый,
Сулар үргә акмый,
Кабат кавышулар язмаган...

Үтә яшьлегем дә,
Вакыт агымында
Әйләнеп карыйм да уйланам...
Аерым аралар,

Йөрәкләр яралы,
Күрешә алмый җаннар сызлана...

Гомер узып бара,
Юлда эзләр кала,
Үкенүләр бәхет китерми...
Сагнып сине көтәм,
Кирәкми беркем бүтән,
Яшьлегемә урап кайтыйммы?

Аерым аралар,
Йөрәкләр яралы,
Кавышалмый җаннар сызлана...

Матху һәм Мутарелли керәләр.

Матху. Риза!

Брахман (*аны күрмичә*). Чынлапмы?

Матху. Валлаһи, билләһи.

Брахман. Алайса, үп мине...

Матху Брахманны үбәргә үрелә.

Мутарелли. Кһем-кһем! Кеше бар! Исәнмесез!

Брахман (*уңайсыз хәлгә калып*). Әстәгъфирулла! Кем бу? Кемне алып килдең син монда?!

Мутарелли. Менә алып килдем...

Матху. Алып килмәдең, чакырып килдең, аерма зур.

Мутарелли. Гафу, әфәндем, әй лә, туташ. Туташ дидем бит инде...

Матху. Шулай диген. А ту?!

Брахман. Күрәм килгәнегезне. Шуннан нәрсә?

Мутарелли. Соң, урлау?

Брахман. Нинди урлау?

Мутарелли. Үзебез урлыйбыз дип сөйләшкән идек бит?

Брахман. Ах да! Менә Матху туташ, сезгә мөһим йомыш чыгып тора. Бик җаваплы эш. Серне бик нык сакларга кирәк.

Матху. Могила, во! Тыным да чыкмас!

Брахман. Яхшы. Тыңла: Зиртага сиздермичә генә теге егетне сугарга кирәк...

Матху. Җәүдәтнеме?!

Брахман. Әйе, шуны.

Матху. Шәп! Их, асыл егет, кочагыма керәсең икән! (*Брахманны үбеп ала.*) Шундый итеп яшерермен, әнисе дә эзләп таба алмас, боерган булса...

Б р а х м а н. Кара аны, имгәтә күрмә, йомшаграк кылан. (*Китә.*)

М а т х у. Менә ичмасам бу эш!

М у т а р е л л и. Сиңа нәрсә булды? Күзләрең утлы күмердәй яна?

М а т х у. Янар да. Малы бит, малы нинди?

М у т а р е л л и. Алайса, мин бармыйм!

М а т х у. Бармам мин сиңа! Хәзер син миннән кала алмыйсың. Киттек!

Матху һәм Мутарелли китәләр.

К а н з а с (*ялгызы*). Авылыбыз бигрәк ямьләнде. Әллә үзем дә яшәрдем инде. Гел биеп-җырлап кына торасы килә. Хи-хи-хи. Әллә махарадж тәэсире инде. Тфү, тфү, ләхәүлә. Яхшыга гына булса ярар иде. Брахман шайтан, ниләр сөйләнә бит? Теленә тилчә чыккыры... Тфү, тфү, әйттем исә кайттым. Әллә ничек күңелле булып китте... (*Җырлый.*)

Б р а х м а н керә.

Инеш буйлары ак томан,
Ак уйлар уйлый сыман...
Аклык булып, пакьлек булып,
Ярату килер сыман...

К у ш ы м т а:
Кил син миңа, кил, сөйгәнем,
Чит үзәнне сайлама.
Кил син миңа, кил, соңлама,
Томан булып таралма.

Яр буенда ялгыз агач,
Томан җитми янына...
Җиһаннарда ялгыз калгач,
Тәү ярымны сагынам.

Ак томанда сафлык төсе,
Пакьлек, тынлык, назлылык.
Ак томандай урап алчы,
Ташлап китсен ялгызлык...

Б р а х м а н. Син нәрсә, кортка?

К а н з а с. Ник, җырлыйм ич, ошамый мәллә?

Б р а х м а н. Бик әйбәт анысы. Шундый матур итеп җырлыйсың. Кем булыр икән бу, дип аптырап килсәм, менә кем булып чыкты...

Тынлык.

Канзас. Кызың ни хәлләрдә?..

Брахман. И-и аның куануын күрсәң. Бөтенләй үзгәрде ул, танымаслык булып. Ул җырулар җырлый, ул бии, үзе куана. Кызым әллә киресенчә элек тулыр-тулмас булдымы икән ул, дип уйлап куям. Ул кадәр үзгәрмәс иде, дим. Үзем дә җиңеләеп калдым...

Матху һәм Мутарелли күренәләр. Матху кулында капчык.

Матху. Әнә алар! Чүкердәшеп утыралар, тутый кошлар...

Мутарелли. Сак бул. Зиртаны куркытма...

Матху капчыгын Брахман башына кидертә. Канзас куркып китә.

Матху. Ә-ә! Эләктеңме, принц...

Канзас. Каравыл, үтерәләр! Тимәгез аңа, җибәрегез аны...

Мутарелли. Кәбирә түти... Син нишләп йөрисең монда? Зирта кайда?

Канзас. Зирта Җәүдәт белән су буенда.

Мутарелли. Су буенда?.. Ә капчыкта кем алайса?..

Канзас. Председатель, тфү, Брахман ла!

Матху. Брахман?

Мутарелли. Брахман?! Сау булыгыз, хушыгыз. Мине монда беркем дә күрмәде. (*Качып китә.*)

Матху. Сатлык җан! Куркак. Аңламассың хәзер дөньясын. Күземә бөтенесе Джимми булып күренә башлады. Бу председатель аяк астында буталып йөрмәсә! Иптәш председатель, курыкмагыз, чыгыгыз капчыктан. Мин ул бандитны куып җибәрдем. Сезгә хәзер бернинди куркыныч янамый. Сез ирektә!

Брахман (*капчыктан башын чыгарып*). Нәрсә булды миңа? Бөтен дөньям караңгыга чумгандай булды... Матху, Матху, синмени әле бу? Бар тизрәк врачны чакырт, тиз бул!..

Матху. Иптәш председатель, менә врач сезнең алда. Ярый, мин китим, мөһим эшләрем көтә... (*Китә башлый.*)

Брахман. Туктале, Матху...

Матху. Тыңлыйм, иптәш председатель.

Брахман. Бөтен колхоз исеменнән зур рәхмәт сиңа, Матху.

Матху. Пажалысты!.. (*Китә.*)

Агач күпердә Зирта һәм Джимми басып торалар.

Д ж и м м и. Син кем, Зирта?

З и р т а. Зирта... һинд кызы...

Д ж и м м и. Һинд кызы?.. Тагын бер кат уйлап әйт әле: син кем?

З и р т а. Һинд кызы.

Д ж и м м и. Алайса, мин кем?

З и р т а. Син — Джимми.

Д ж и м м и. Ә Җәүдәт дигән исем сиңа танышмы, Зирта?

З и р т а. Җәүдәт... Җәүдәт... юк.

Д ж и м м и. Зирта, зинһар, тагын яхшылап уйлап кара...

З и р т а. Юк, юк, миңа ул исем таныш түгел.

Д ж и м м и. Алайса, тыңла, Зирта... (*Җырлый. Җыр Зәйтүнә һәм Җәүдәт арасындагы моңсу мәхәббәт турында.*)

Һиндстаннан болгарларга табан,
Кәрван бара салмак, тын гына...
Кәрван башы хикәят әйтә,
Бар да тып-тын, агыла моң гына...

Яшел сахра гөлләр эчләрендә,
Нурда йөзеп, таңда чыкланып
Яшәгәннәр ике асыл чәчкә,
Берсе сөеп, берсе моңланып...

Аңлаталмый алар мәхәббәтен,
Диңгез шавы, кошлар моңнары...
Газизләнеп шашып сөюеннән —
Егет ташып, ярсып җырлады.

Кыз сарылды сылу пальмаларга,
Аңлый алмый егет көюен...
Күк йөзендә гүя ут кабынды,
Егет кызны ярсып сөюдән.

Ялкын капты егет дөрләвеннән,
Кыз йөрәге утка күмелде...
Нурлар чәчте чибәр күз сирпүдән,
Егет күңеле нурга күмелде...

Өзлеп сөйгән егет Җәүдәт иде...
Дөрләп янган йөрәк — Зәйтүнә...
Бу — галәмнең көчле мәхәббәте,
Бу гыйшыкка җырлар әйтелә...

З и р т а (*күзләрендәге яшьләрен сөртеп*). Зәйтүнә һәм Җәүдәт... Никадәр көчле мәхәббәт, никадәр газап уты... Күңелем әллә нишләп китте. Күз алдындагы томан тарала барган кебек... Зәйтүнә... Җәүдәт... мин аларның икесен дә беләм кебек, тик кайдан, кайчан?.. Җәүдәт...

Д ж и м м и. Ә?

З и р т а. Юк, мин сиңа әйтмим. Мин болай гына... Бу җырыңны башка минем алда җырлыйсы булма, Джимми! (*Китә башлый.*)

Д ж и м м и. Син кая, Зирта?

З и р т а. Тауга. Миңа үземә генә калырга кирәк. Ә син беркая китмә, мине монда көтеп тор. Мин хәзер, бик тиз... (*Китә.*)

Зирта гадәти киемен кияргә өенә китә. Джимми күпердә кала.

Д ж и м м и. Нәрсә эшләдем мин. Йә ул таудан ташлана, йә ул аңына килеп барысын да исенә төшерә...

М а т х у күренә. Кулында аркан. Уйланып утырган Джиммины кинәт тотып ала, аркан белән бәйли, авызына чүпрәк тыга. Аркасына салып, авылга таба чаба.

М а т х у. Менә кайтып та җиттек. (*Мутареллины күрә.*) Яле, бәйлә шуны әнә теге пальмага. (*Икәүләшеп бәйлиләр.*)

М а т х у. Менә шулай. Түз, түз, җанкисәгем... (*Авызыннан чүпрәкне ала.*)

Д ж и м м и. Сез нишлисез, ә? Бу ни эш бу?!

М а т х у. Әй аны! Ничек моңлы бит аның, җанашымның тавышы. Сөйлә, сөйлә, аппагым...

Д ж и м м и. Ычкындырыгыз тизрәк!

М а т х у. Йә, йә, нервыларыңны сакла, багалмам.

Д ж и м м и. Җибәрегез, чишегез, дим. Зирта тауга таба китте...

М а т х у. Беләбез, беләбез, кадерлем. Аның белән бернәрсә дә булмас. Буласы булган инде. Исәннәр турында да уйларга кирәк.

М у т а р е л л и. Әллә җибәрикме?

М а т х у. Шүрләмә!

Д ж и м м и. Ни кирәк сиңа, ә, Матху? Нигә мине бәйләдегез?

М у т а р е л л и. Председатель кушканга.

М а т х у. Ә син кысылмый гына басып тор әле!

М у т а р е л л и. Гафу, башлыгым.

Д ж и м м и. Председатель... моны ничек аңларга, ә?

М а т х у. Аңлатам, җанкисәгем. Бүгенге көннән алып син Зиртаны мәңгегә онытырга тиеш. Аңладыңмы?!

Мутарелли. Бәлкем, ычкындырырбыз, ә?

Матху. Шыңшыма!

Мутарелли. Бетте, бетте.

Матху. Һәм тагын бер мөһим нәрсә, бел: мин сине яратам. Инде аңлап бетердеңме?

Джимми. Юк! Юк, аңларга да теләмим.

Матху. Аңламаганнарга тагын бер кабат кабатлыйм: мин сине я-ра-там...

Мутарелли. Ә мин?!

Матху. Ә син молчи, завклуб, понял!

Мутарелли. Поняла! (*Джиммины ычкындыра башлый.*)

Матху. Стоп! Тәртип бозма, завклуб, «абу» итәм бит.

Клуб мөдире туктый.

Мутарелли (*елар дәрәҗәгә җитеп*). Минем өйгә кайтасым килә...

Матху. Кайтырсың, ашың пешсә!

Джимми. Матху, бәгърем, ычкындыр инде, ә. Аннан мин сине тракторымда утыртып йөртермен.

Матху. Миңа өйләнсәң — ычкындырам. (*Джиммига сыена.*)

Джимми. А-а-а... Минем өйләнәсем килми. Яшь бит әле мин...

Матху. Борчылма, җанашым. Беркем дә өйләнәсе килеп өйләнми. Ходай Тәгалә үзе кушып, вакыты килеп җиткәндер.

Джимми. Әй, әй... Мин каршы, җибәр мине, Матху.

Мутарелли (*елап*). Менә ышан син хатын-кызга... Алдандым, алдандым...

Джимми. Бу бит уен гына иде, ә син нәрсәгә барып җиттең! Тукта, дим. А-а! Ни эшлисең син, ә?..

Матху. Кемгә уен, кемгә муен. Шундый чибәр ирең булса, ә? Һәм булачак та! (*Джиммины ирененнән үбә.*)

Мутарелли йөзе белән җиргә каплана.

Джимми. Зинһар, тыңла әле, Мәмдүдә.

Матху. Матху-у-у...

Джимми. Матху, аңла инде: бу бит уен. Мин сине яратмыйм.

Матху. Бәлки, мин сине өзелеп яратамдыр? Кара син аны, эгоист, оятсыз, уйламаган идем!

Джимми. Мин Зәйтүнәне яратам...

Матху. Зәйтүнәне?! Андый кыз дөньяда юк!

Джимми. Бар!

М а т х у. Юк, юк! Йә инде, бәгърем, Җәүдәтем, андый кыз юк диген инде...

Д ж и м м и. Бар. Андый кыз бар! Ул — һинд кызы! Ләкин ул безнең арада бу пычрак тормышта яшәрлек кыз түгел! Ул үзе сафлык, чисталык, гүзәллек фәрештәсе!..

М а т х у. Соң ул тулы кыз түгел, җиделе-сигезле, ничек аңламыйсың. Аның нәрсәсен яратасың. Ә мин сине күтәреп кенә йөртермен. Җүләр бит ул кыз...

Мутарелли Зирта янына китә.

Д ж и м м и. Җүләр түгел ул! Акыллы ул! Җанлы кыз ул! Без үзебез юләр! Матурлыкны яныбызда күрми яшибез...

М а т х у. Соң нәрсәсенә кызыктың шуның? Җырлавынамы? Биюенәме?

Д ж и м м и. Ә нәрсә?! Җырлавы да, бию дә әйбәт. Гомумән, аның өчен үләргә дә була.

М а т х у. Мин дә аннан ким түгел бит. Кара, менә кара. (*Джимми тирәсендә әйләнә-әйләнә һиндча җырлап бии.*)

Кимсетеп карыйсың син миңа,
Кимсетеп карама син миңа!..
Киммени инде соң мин сиңа,
Килмисең ник үзең син миңа?!

Синең тракторың «ДТ»,
Минем тракторым «К-700».
Тракторыңа утырт та
Килен итеп алып кайт!

Биимен, кай төшем килмәгән?
Миңамы моңнарны бирмәгән?!
Җимертеп эшлимен, эшләсәм,
Булдырыр идемме, пешмәсәм?!

Синең тракторың «тойота»,
Минем тракторым «кадиллак»,
Синең тракторың йоклата,
Кайтыйк минекендә калтырап...

Бергәләп кырларда эшләрбез!
Ярдан да егылып төшмәбез!
Яратып яшәрмен мәңгегә —
Зиртаны туйга да дәшмәбез!!!

Канатлар куярбыз тракторга,
Айларга очарбыз тракторда!
Кырларда таңнар да яктырак,
Кил инде, бәгърем, якынрак...

Йә, мин начармы?!

Д ж и м м и. Зинһар, аңла инде, Мәмдүдә бәгърем. Мин Зиртаны яратам, аны сөям. Кермә безнең арага.

М а т х у. Ярый, аңламадың. Бүтәнчә сөйләшми булмый...

Матху Джимминың авызына чүпрәк тыга, күтәреп чыгып китә. Бу вакытта З и р т а һәм М у т а р е л л и күренәләр. Икесе дә арыганнар.

М у т а р е л л и. Әле генә монда иделәр... Бәла-каза булмаса ярар иде... Зирта туташ, мин хәзер әтиеңне алып киләм. (*Китә.*)

З и р т а. Йөрәгем урыныннан купты... Нәрсә булды соң миңа? Менә хәзер нәрсәдер булачак...

Б р а х м а н, М у т а р е л л и керәләр.

Б р а х м а н. Кызым...

З и р т а. Әтием, миңа бик авыр...

Б р а х м а н. Ни булды, кызым? Әллә...

З и р т а. Әтием, мин кем?

Б р а х м а н. Син... син минем бердәнбер яраткан кызым.

З и р т а. Тагын?

Б р а х м а н. Тагын...

З и р т а. Джимми кайда?

М у т а р е л л и. Аны Матху урлап качты... мине үземне генә калдырды да сызды Джимми белән.

З и р т а. А-а-а, аны урлаганнар. Әти, зинһар, табыгыз аны.

Б р а х м а н. Яхшы, яхшы, тик тынычлан гына. (*Мутареллига.*) Эх, хөрәсәннәр, әрәмтамаклар!

Д ж и м м и н ы күтәреп, М а т х у керә.

М а т х у. Тракторның көпчәген тишеп киткәннәр. Югыйсә калдырмый идем мин аны монда, Брахман әфәнде!

Б р а х м а н.Төшер җиргә! Чиш бауларын, Матху...

Зирта, Джимми янына килеп, бауны бушатырга тели, Матху аны туктата.

М а т х у. Кит, кагылма. (*Җиргә бастыра.*)

З и р т а. Джимми, мин тауда...

Матху. Якын килмә дим, җүләр кызый!

Брахман. Җитте, күп остарма телеңә!

Мутарелли. Матху, бәгърем, мине бәйләрсең, яме...

Матху. Нәрсә?

Мутарелли. Минем әнә шул бауга бәйләнәсем килә... мине иркәләрсең...

Матху. Акылың алтын икән. Нәрсәгә миңа ике кияү? (*Джиммины баулардан арындыра.*)

Джимми. Зирта...

Зирта. Джимми... Мин сезгә бер нәрсә әйтергә телим...

Джимми. Дәшмә! Зирта, дәшмә, син бер нәрсә дә, беркемне дә исеңә төшермәдең. Син Зирта — һинд кызы...

Зирта. Син бит...

Джимми. Юк! Зинһар, дәшмә!

Матху. Булды, җитте. Син нигә минем иремә бәйләнәсең?

Джимми (*Матхуга*). Син туктыйсыңмы, юкмы? Тутыккан тимер йөрәк! (*Пауза.*)

Матху. Ярый алайса, туктыйм... Син, Зирта, минем кемлегемне беләсеңме? Мин — Мәмдүдә...

Джимми. Матху, акылыңа кил.

Брахман. Матху, кара аны...

Матху. Әйе, Мәмдүдә! Алдынгы тракторчы Мәмдүдә! Җир сөрәсе урынга, әкият уйнатып азаплыйлар!.. Әкият бу! Син күргәннәр барысы да әкият. Син тиле терелсен дип, бездән шамакай ясадылар.

Брахман. Кызым, ул саташа, ышанма аңа.

Матху. Саташам?! Ха-ха-ха!

Джимми. Матху, тукта, үтерәм бит!..

Брахман. Тукта, юләр кызый.

Матху. Мин түгел, әнә ул юләр. Мин оттым, ә син (*Зиртага*) оттырдың. Алдадылар сине, алдадылар. Менә бусы — Мөхәммәтхан — завклуб, һинд әкиятләре ташучы. Әтиең Брахман түгел, Габдрахман, «Кызыл маяк» колхозы председателе. Канзас — авыл врачы Кәбирә, ә инде монысы — Җәүдәт... Хәкимов...

Зирта. Җәүдәт?..

Матху. Әйе, Җәүдәт. Ә син...

Джимми. Әйтәсе булма. Үтерәм...

Матху (*Зиртага*). Ә син... Зәйтүнә, тиле авыл кызы... (*Пауза.*) Хәзер туктадым!

Брахман. Гафу ит безне балакай, шулайрак шул... Без сине...

Зирта. Эх сез... Берни дә аңламадыгыз... Сез... сез...

Джимми. Зәйтүнә, мин чын күңелдән. Зинһар, борчылма гына... Без сиңа ярдәм итәрбез...

З и р т а (*көлемсерәп*). Син?! Миңа ярдәм?.. Сез мине алдадыгыз... Киресенчә, сез үзегез ышана яздыгыз... Мин сезгә аңлата алырмын дип уйлаган идем, булмады... Шушы мәгънәсез тормыштан, пычраклыктан чыгарбыз, котылырбыз дип котыгыз чыкты... Карагыз әле яхшылабрак: әйбәт бит, матур бит, гүзәл бит, күңелле бит болай яшәве... җырлап, биеп, изгелеккә, сафлыкка омтылып, табынып... Һәркемнең күңелендә үз матурлыгы бар. Тапсын иде ул аны. Әти, Кәбирә түти, сез дә, Мәмдүдә һәм Мөхәммәтхан сез дә, Җәүдәт син дә... Ә мин... мин элеккеге тормышка кайта алмам инде... Хушыгыз!.. (*Йөгереп чыгып китә.*)

Д ж и м м и. Зәйтүнә!

Б р а х м а н. Ну, Мәмдүдә! Себер китәсең, бел, сохариеңне әзерлә.

М у т а р е л л и. Бар, йөгер, Җәүдәт. Ярдан сикерәчәк хәзер. Ничек булса да, тотып калырга өлгерергә тырыш!

Д ж и м м и. Зәйтүнә! (*Артыннан йөгерә.*)

Берзаман тау башында З и р т а пәйда була.

Б р а х м а н. Кызым, алтыным, зинһар, алай итмә. Тукта!

К а н з а с. Кызым, балакаем, ашыкма. Без сине аңларга тырышырбыз. Кичер безне!

М у т а р е л л и. Зирта, зинһар өчен, сикермә инде. Минем Себер китәсем килми!

М а т х у. Эхе, уйлап бирә ул сезне. Минем кебек акыллы булса, тыңлар иде дә...

Ул арада Зирта аларга бер күз сала да ярдан түбән сикерә.

М у т а р е л л и. Беттем! Бетерде башымны кызый...

Б р а х м а н. Кызым-м-м...

К а н з а с. Балам-м-м...

М а т х у. Кара, кыю икән. Тәки сикерде.

Б р а х м а н. Әй кызым. Мин генә җиттем синең башка. Әтиең ата була белмәгәч... Кичер, кызым. Барысына да мин гаепле. Сине аңламавыбызны да, аңларга тырышмавыбызны да, чукынышып шушы пычрак тормышта тыпырчынып, тырмашып, пычракка батып яшәвебезне дә кичер. Эх, элегрәк аңлаган булсак иде сине?! Рәнҗемә, балам...

К а н з а с. Зәйтүнә, балакай. Нинди гүзәл кыз идең?! Нинди акыллы идең, итагатьле идең. Мөгамәләң ничек әйбәт иде кешеләргә. Әнием дип дәшә идең бит инде... Зинһар, кичер, гафу ит мине.

М у т а р е л л и. Зирта. Миңа да син үз кызым кебек идең бит... (*Үкерә.*) А-а-а-у-у-ы-ы... Мин алып кайткан киноларны ничек ярата идең... Ник болай иттең? Мин сиңа гел һинд киносы гына күрсәтеп торыр идем!

З и р т а керә. Алар аны күрмиләр.

М а т х у. Себердә күрсәтерсең әнә...

К а н з а с. Мәмдүдә, җитте сиңа, эндәшмәгәч тә...

М у т а р е л л и (*Матхуга*). Син генә гаепле барысына да... Син... Минем хисләремне аңлаган булсаң... Эх син...

Б р а х м а н. Үкермәгез әле.

К а н з а с. Шушындый вакытта.

Барысы да тезләнеп үксергә керешә. Аптырап, Матху да чүгә. Арттан З и р т а боларның кыланышларына шаккатып карап тора.

З и р т а. Сез... сез... ни эшлисез? Анда... анда...

Барысы да куркып калалар. Кем кая кача башлый. Брахман аптырап кала.

Б р а х м а н. Се-се-сез ке-ке-кем?

З и р т а. Анда... анда...

М у т а р е л л и. Кем син ди-ди-диделәр?

З и р т а. Мин Зирта... Кызың бит әткәй...

М у т а р е л л и. Ләхәүләвәләкуаәте...

Б р а х м а н. Врач кирәк... Врач...

М а т х у. Бу Зәйтүнә өрәге! Минем гаеп юк... Мин ни...

К а н з а с. Врачың монда, җаным...

З и р т а. Әйе, әтием, врач кирәк... анда...

Б р а х м а н. Кызым, син исән!

К а н з а с. Аллага шөкер. Балакаем!

М у т а р е л л и. Уф, Ходай Тәгалә бар икән әле. Беттем дип торам...

М а т х у. Җен саклыйдыр бу кызны.

З и р т а. Зинһар, бер тапкыр булса да, мине тыңлагыз инде...

Б р а х м а н. Әйе, әйе, кызым, рәхәтләнеп сөйлә!

З и р т а (*елап*). Анда, яр астында Джимми. Мин...

М а т х у. Джимми? Ни булган аңа?

З и р т а. Ул... ул... Сөйләшми... Берни дә әйтми...

М а т х у. Ачуын китереп бетерделәр дә малайның...

З и р т а. Ул... ул... Мин... аның... мин... аңа... аның өстенә төштем... ул хушсыз... а-а-а-а... Мин аны харап иттем... Сөйгәнемнең үзем башын ашадым... а-а-а-а...

К а н з а с. Тынычлан, кызым, тынычлан.

М а т х у. Бетергән егетне, имансыз. Син юри аның өстенә төшкәнсең. (*Елый.*) А-а-а-а-а... Тол калдым... а-а-а...

Б р а х м а н. Үкермәле. Барыгыз, тизрәк алып менегез, бар...

М у т а р е л л и. Борчылма, Матху бәгърем, мин барында... Мин сине ташламам... Әйдә...

Д ж и м м и н ы яр астыннан күтәреп алып меналәр. Канзас аның пульсларын тикшерә. Зирта белән Матху үкереп елыйлар.

З и р т а. Зинһар, кичер мине, җаным. Мин гаепле барсына да. Мин алып кердем сезне бу сихри дөньяга. Аңлата алырмын дип уйлаган идем, булмады. Кичер мине...

М а т х у. Җаным! Мин сине шушы исәр кыз шаукымыннан саклап кала алмадым, кичер мине.

Д ж и м м и, кисәк кенә сикереп торып, һинд җыры җырлый башлый. Барысы да аптырап кала. Зиртаның йөзенә акрынлап елмаю иңә, яктыра. Ул, Джимми җырлаганда, акрын гына арткы планга күчә, аннан юкка чыга.

М а т х у. Ул терелде... син...

Д ж и м м и. Гафу, сез кем?

М а т х у. Мин кем? Бу бит мин, синең хәләл җефетең, Мәмдүдә...

Д ж и м м и. Мин сезне белмим, гафу итегез...

Б р а х м а н. Бу без бит, Җәүдәт энем, авылдашларың.

М у т а р е л л и. Бу да ычкынды, ахрысы... Нәкъ пар күгәрченнәр... Ә миңа ни эшләргә? Мин кемнән ким?! Матху бәгърем, күр!

Мутарелли, кисәк кенә торып, тау башына йөгерә, ярдан сикермәкче була. Куркып кала, талпынып-талпынып карый, бәргәләнә, ни кылырга белми тора. Аптырагач, җиргә ятып, һиндча җырлап, бәргәләнә башлый.

М а т х у. Тукта-а-а! Син ни эшлисең? Бердәнбер асыл ир-егет калдың, харап итмә үзеңне. Мин кемгә калам?

М у т а р е л л и. Юк! Мин горур булып... сикердем! (*Йөгереп килеп Матхуның кулларына сикерә. Аның кочагында кала.*)

Б р а х м а н. Ай кызым, кызым... Менә сиңа кызым. Менә сиңа һинд кызы! (*Тау башына таба атлый. Кисәк кенә йөрәген тотып иелә.*) Уф, йөрәгем... Врач кайда... врач...

К а н з а с. Мин янында, Брахманым. Мин һәрчак синең белән...

Б р а х м а н. Ризамы?

К а н з а с (*бик оялып*). Риза.

Кисәк кенә бик дәртле музыка башлана. Зирта йөгереп чыгып бии башлый. Бик дәртле, җитез бию. Бераздан ул Джимми белән Зирта арасында җырлы-биюле диалогка әйләнә. Ул көчәйгәннән-көчәя бара. Бөтенесе аптырашта кала. Бию азагында Джимми белән Зирта тау башына йөгерәләр. Башкалар бу көтелмәгән хәлдән катып калалар. Зирта белән Джимми йөгереп менгән уңайдан таудан сикерәләр. Һәм, һич көтмәгәндә, аска төшмичә, өскә, күккә күтәреләләр. Ут сүнә. Экранда шул ук музыка дәвам итә. Анда һинд киносы бара. Зәңгәр күкне иңләп, ике аккош очып йөри...

П ә р д ә.

## *Сагынырсың әле син дә бер...*

*Ике пәрдәле моңсу мәхәббәт хатирәсе*

КАТНАШАЛАР:

Психолог.
Наилә.
Кәрим.
Гөлсинә.
Ләйсән.
Саймә.
Альберт.
Азат.
Илсөяр.
Рәшит.

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Авансцена яисә юл чаты. Каядыр җил улаганы, яңгыр яуганы ишетелә. Бик шыксыз, ямьсез, салкын, яңгырлы көзге кич (*төн*). Арлыбирле йөреп җылынырга теләгән, өстенә кара плащ кигән, башын целлофан кисәге белән каплап, калтыранган бер егет күренә. Ул шактый озак торган, салкын үзәгенә үткән, егет кеше булганга гына еламый. Шул арада каяндыр фара уты йөзеп кереп, машина тавышы үтеп китә. Егет кул күтәрә, йөгереп карый, кычкыра. Ләкин машина туктамый. Егет, гаҗиз булып, кире урынына кайта. Ачыргаланып кычкырган кыз тавышы ишетелә. Бик еракта. Егет тагын сикергәләп, йөренеп ала. Аптырагач, юлдагы олы ташка барып утыра. Бөтенләй төренеп. Сәхнәгә, әчке күлмәктән генә, туңып, зәңгәрләнеп беткән бер кыз керә. Ул зифа буйлы, йөзгә чибәр, озын чәчләре суланып, укмашып асылынган, бөтен җиреннән су ага, үзе дер-дер калтырый. Ул бермәлне туктап тора. Килергәме-килмәскәме дип шактый торгач, башка чыгар юл тапмагач, егеткә таба атлый. Акрын гына янына ук килеп җитә. Сүз әйтергә телен әйләндерә алмагач, туңуы үзәгенә үткән, акрын гына кулы белән егеткә тиеп ала. Егет сизми. Кыз бераз кыймый торгач, катырак кагыла. Егет сискәнеп китә, ләкин селкенми. Башын акрын гына борып карый да, сикереп торам дигәндә, бу көтелмәгән күренештән мәтәлеп үк китә. Бер мизгел бер-берсенә ка-

рашып торалар. Кыз сулкылдый. Сөйләшә алмаганга, тагын кулларын сузып, егеткә табан атлый...

Кәрим (*куркып*). Әй, син нәрсә... (*Артка чигенә.*)

Кыз сүз дә әйтә алмый, аңа таба атлый-атлый, тагын да каты сулкылдый, дер-дер калтырый.

Тукта, диләр!

Кыз туктый. Бер-берсенә эндәшмичә карашып торалар. Кызның яшьләнгән матур йөзе, күзләре, үзе егеткә охшаганы күренеп тора. Ләкин ул хатын-кызның шәрә килеш үзенә таба килүеннән шүрләп калган.

Син нишлисең... ә?.. Кем син?.. Нишләп... (*ишарә белән аңа күрсәтеп*) болай йөрисең?

Кыз аңа табан атламакчы була.

Аяк атлыйсы булма!

Кәрим кулындагы бәләкәй сумкасы белән кизәнә. Кыз каты сулкылдап, соңгы өметен өзеп, таш өстенә барып каплана. Үкси. Егет аңа якын ук килә. Кулы белән кагыла. Кыз игътибар итми. Кәрим плащын кыз җилкәсенә сала. Кыз башын бора. Бер мизгел икесе дә калтыраудан туктап, бер-берсенә карашып торалар.

Ал, ал, курыкма!

Кәрим йөри башлый, кыз да торып йөри. Икесе ике якта. Йөри торгач, җылылык чыганагы эзләп, үзләре дә сизмәстән, аркалары белән бер-берсенә терәләләр. Сискәнеп, кинәт кенә борылалар.

Шулай җылырак булыр... Эләктереп куй...

Кыз, башын селкеп, ризалык белдерә.

Болай да салкын шул. Мин плащны киим. Ә сез минем алга кереп утырыгыз. Курыкмагыз, зинһар өчен... (*Плащка үреләп. Кыз, кисәк кенә плащны аңа ата да читкә китеп баса.*) Сез мине дөрес аңламадыгыз. Икебезнең дә сәламәтлекне саклап калырга телим. Кияүгә чыгасыгыз бардыр әле... (*Кыз, кисәк борылып, усалланып аңа карый.*) Алай усал карамагыз. Ярый, алай булгач, икебез дә калтырап үлик инде шушында. Аңлатып торырга вакытым юк, соңгы җаным чыгып бара... Синеке дә шулайдыр дип уйлыйм, начаррак булмаса...

Кәрим, кыз янына барып, плащны җилкәсенә сала, аны үзенә тартмакчы була. Кыз, плащны кире очырып, урынында басып кала.

О-о-о, горур басып үлүгә ни җитә?! Яхшы, мин риза. Мондый чибәр кыз янында басып торып түгел, аяк астында ятып үлсәң дә, зур бәхет... Җитмәсә, шәрә кыз белән. (*Кыз усал карап куя.*) Зинһар, алай карама. Мин синең ала сыерыңны суеп ашамадым. Тыңла: мин сиңа бары яхшылык телим, ә син аңламыйсың. Гомеремдә бер тапкыр адәм затына булышырга теләдем, анда да барып чыкмады. (*Пауза.*) Аңла, монда безнең егет белән кыз булуыбызның бер сәбәбе дә юк. Бары — борьба за выживание... Аңла да минем сүземне тыңла.

Килеп кызның кулыннан тота, кыз кулын йолкып ала.

Өшеп үлү бүтән төргә караганда рәхәтрәк микәнни?.. Хәер, бер дә рәхәткә охшамаган... Әй, ник сөйләнеп торам соң әле!

Кызны очыртып күтәреп ала да бөтереп ташка, үз алдына утырта. Кыз бераз талпынып ала да, көче булмаганлыктан, туктап кала.

Менә бит, акыллы кеше сүзен тыңлагач, эчкә җылы керде, әйеме? Син миннән курыкма, мин кызларны кыерсытмыйм. Бигрәк тә мондый чибәрләрне. Йә инде, алай ямьсез карама. Киресенчә, башта мин әле үзем синнән курыктым. Беттем мәйтәм, өшегән егетнең башын ашый бу җен кызы. (*Кыз сулкылдый.*) Йә, йә, елап, хәлне җиңеләйтеп булмас... Гел сулкылдап тору кыз кешегә дә килешеп бетми. Йә инде... Менә шулай. Кул белән генә сөртеп куйыйм, яулык сыгарлыктыр. (*Кызның күз төбендә синяк күреп.*) О-хо, бу нәстә? Да, сиңа бик уңай килмәгән бу юл... Зинһар, елый күрмә... Ни булды, ник син болай?

Гөлсинә (*сулкылдап*). Мин... мин...

Кәрим. Әйт, кыюрак бул.

Гөлсинә. Мине... таладылар... Мине... (*Үксеп җибәрә.*) Мыскыл иттеләр...

Кәрим. Нәрсә?!

Гөлсинә. Бернәрсәмне калдырмадылар... Шулхәтле... Шулхәтле мыскылламасалар... җитмәсә, кыйнадылар...

Кәрим. Да-а-а...

Гөлсинә. «Проклятые бабы» дип, сүгә-сүгә типкәләделәр, азрак жәлләмиләр дә... үзләре шундый яшьләр... (*Үкси.*)

К э р и м. Шешенеп беткәнсең, зинһар өчен, тукта инде елаудан.

Г ө л с и н ә. Нишлим инде мин хәзер... Ничек кайтып керим? Ничек яшим?..

К э р и м. Йә, йә, болай елап та ерак китеп булмас. Бетеренмә шулхәтле... Кайда алар?

Г ө л с и н ә. Белмим... Мин күзне ачканда, юк иделәр. Алар машина белән...

К э р и м. Дөньяда төрле хәл була, түз... Хәзер безгә ничек тә кайтып җитәргә кирәк... Аннан карарбыз. Ләкин син үз-үзеңне артык өзгәләмәскә сүз бир, яме. Берәр җае чыкмый калмас. Җан биргәнгә, җүн бирермен дигән, ди. Сүз бирәсеңме?

Кыз, башын селкеп, ризалык белдерә.

Менә шулай. Үзең акыллы да икәнсең әле. Аллага шөкер, дөньяда шәфкатьле кешеләр дә җитәрлек. Каян кайтып килеш соң синең?

Г ө л с и н ә. Туйдан. Алар мине юлда утырттылар. Юл буе әшәкелек әйтеп килделәр. Үзләре исерек. Калдырыгыз мине дигән... (*Тагын үкси.*)

К э р и м. Йә, йә бетерешмә... (*Сүз таба алмый.*) Их, бер машина! Әһә, бер ут күренә.

Ут үтеп китә. Кәрим артыннан йөгереп карый.

Мин каршына чыгыйм әле, яме. (*Тукталып.*) Их, каһәр! (*Тагын бергә утыралар.*) Сез кая кайтасыз?

Г ө л с и н ә. Казанга.

К э р и м. Беләм. Төгәлрәк, дидем...

Г ө л с и н ә. Совет районына...

К э р и м. Ә-ә, тулай тораккамыни?..

Г ө л с и н ә. Юк, мин Гвардейская урамында, әни белән...

К э р и м. Кире як икән...

Г ө л с и н ә. Нишләп?.. Безгә йөрү бик җайлы.

К э р и м. Юк, озатып куярга диюем. (*Кыз кырт борылгач.*) Шаярам гына... Мин сине Казан урамы буйлап болай җибәрә алмамдыр дип уйлыйм... Минем бәлагә юлыккан кешене ташлап китә торган гадәтем юк.

Г ө л с и н ә. Рәхмәт! Ләкин мин сездән берни дә сорамадым.

К ә р и м. Юк инде, җанашым, мин бу юлы үтенеп тормыйм, файдасы юк! Әһә, менә бу бик якты ут, димәк, безнеке булачак! Ничәнче йорт та, ничәнче фатир әле... Әй, нәгыйн, әйе, бергә кайтасы бит әле. (*Кул болгап алга чыга*). Әй-әй-һәй! Тукта! Тукта! Булды, йөгердек! (*Торып йөгерәләр.*)

Ут сүнә.

Психолог кабинеты. Ул сәхнә кырында бер өстәл, берничә урындык һәм берәр элемент белән билгеләнергә мөмкин.

П с и х о л о г. Әйе, әйе, мин тыңлыйм...

Г ө л с и н ә. Ни дип тукталдым соң әле... Зинһар, гафу итегез...

П с и х о л о г. Зыян юк, үзегезне иркен тотыгыз. Мин тыңлыйм дигәч, сез кисәк сөйли башладыгыз... Әгәр тагы да теләгегез булса, дәвам итегез, тартынмагыз... Белегез, безгә сезнең белән ачыктан-ачык булу кирәк... Әгәр ачылып бетә алмасагыз, минем сезгә ярдәм итә алмавым бар...

Г ө л с и н ә. Зинһар, гафу итегез, мин үзем дә сизмәстән шул вакыйганы сөйли башлаганмын...

П с и х о л о г. Сез аны сөйләргә теләмәгән идегезме?

Г ө л с и н ә. Юк, доктор, алай түгел. Мин, чыннан да, автомат рәвештә сөйләп киткәнмен... Хәтта үзем дә аңламыйм, нигә аннан башлаганмындыр...

П с и х о л о г. Ә үзегезне бушангандай итеп сизмисезме?

Г ө л с и н ә. Бар бугай шул... Беләсезме, мин аны бушану димәс идем: ничектер ачылу диимме? Әйе, ачылу... ачылып киткәндәй булдым.

П с и х о л о г. Бу бик әйбәт хәл... Гомумән, иң кыены да шул аның: минем янга киңәш сорап килгән кешеләрнең чын күңелдән ачылып китә алмавы...

Г ө л с и н ә. Чыннан да, ниндидер җиңеллек тә сизәм кебек... Аз гына... Бик аз...

П с и х о л о г. Яхшы, яхшы. Менә сез уйлап карагыз әле. Ничек дисез: бу вакыйгадан башлавыгызны, ул вакытта булган хәлдән, кичерештән башланып киткәндер дип уйлап сөйләмәдегезме?

Г ө л с и н ә. Сез стресстан соң дисезме?

П с и х о л о г. Әйе...

Г ө л с и н ә. Белмим. Юктыр дип уйлыйм. Ул стрессны, вакыт үтү белән, мин бөтенләй диярлек онытып.

Һәм ул соңрак та мине артык борчымады. Чөнки тормышым аңа бәйле рәвештә дәвам итмәде. Шулай да...

П с и х о л о г. Алайса, әйдәгез, болай килешәбез: сез шулай иркен итеп, баш миегез ни сөйлисе килсә, аңа комачауламыйча, теләгән вакыйганы сөйләтсен. Ә мин сезне кирәкле җирләрдә туктатып сораштырырмын. Килештекме?

Г ө л с и н ә. Яхшы. Мин тырышып карыйм.

П с и х о л о г. Юк. Берничек тә тырышырга тырышмагыз. Бары тик иркен, ирекле рәвештә генә. Хәтта беразонытылып та. Менә баштагы кебек. Сез мине аңлыйсызмы?

Г ө л с и н ә. Әйе бугай...

П с и х о л о г. Алайса, дәвам итегез, мин тыңлыйм...

**Ут сүнә дә Гөлсинәләр фатирында кабына. Анда туган көн бәйрәме азагына якынлашкан. Күп кеше таралган. Бер-ике «якын» дуслар гына калган. Ишек төбендә, тышкы яктан К ә р и м белән Н а и л ә күренә.**

Н а и л ә. Кая алып килдең син мине, аңламыйм.

К ә р и м. Менә булды дияргә була, килеп җиттек.

Н а и л ә. Кая?

К ә р и м. Хәзер аңлатам. Әйдә, керик...

Н а и л ә. Кая? Ю-у-ук, ничек итеп, кая кергәнеңне белмичә керәсең ди?

К ә р и м. Начар кешеләр түгел ул. Бары ни, теге, ну, бүген монда туган көн.

Н а и л ә. Туган көн? Кемнеке?

К ә р и м. Кемнеке, кемнеке. Ярый, анысы бик мөһим түгел. Әйдә, керик, болай да соңга калып беттек инде... Бу вакытта кеше дә тарала башлый.

Н а и л ә. Соң алай булгач, бигрәк әйбәт, кереп тә тормыйк.

К ә р и м. Юк, мин нык ышандырдым.

Н а и л ә. Үзең бит. Башта ук шулай аңлаткан булсаң, соңга да калмас идек. А ту, бер җиргә алып барам...

К ә р и м. Ярый, ярый әйдә! (*Звонокка басмакчы була, аның кулын Наилә тотып кала.*) Нәрсә?

Н а и л ә. Кәрим, алтыным, ә бәлки, чыннан да, кермәбез... Соң да...

К ә р и м. Ничек? Монда хәтле килеп...

Н а и л ә. Син кереп котлап чык, мин монда көтеп торам.

Кәрим. Бигрәк кызык инде син. Әй, минем куркак куяным. Әйдә курыкма. Мин бит ышандырдым, яхшы түгел. Ничек синсез керим инде мин. Без бит гел бергә...

Наилә. Анысы шулай. Шулай да әллә ничек, уңайсыз шул, бер белмәгән кешеләр...

Кәрим. Булды. Сөйләштек, килештек алайса: тиз генә котлыйбыз да китәбез. Ризамы?

Наилә. Риза.

Кәрим аны үбеп ала.

Кәрим. Акыллым да инде...

Алардан ут алына, бүлмә эче яктыра.

Рәшит. Господа! Әфәнделәр, туташлар! Игътибар! Соңгы тост!

Саймә. Ходаем, ничәнче соңгысы инде. Меңенчесеме?

Гөлсинә. Әни, син нәрсә инде!

Саймә. Әни дә әни. Вакыт күпме инде хәзер?! (*Кухняга кереп китә.*)

Рәшит. Ялгышасыз, Саймә апа, меңенчесе түгел. Унҗиденче генә прощальный тост...

Бар да көлешә.

Азат. Шулай итеп, җәмәгать...

Гөлсинә (*Илсөяргә*). Тәки килмәде...

Илсөяр. Алдакчы ул синең, шул гына. Әллә кемдер әле, бер урам ышпанасыдыр. Син дә инде... Әллә кемнәрне чакырасың...

Гөлсинә. Юк, әллә кем түгел ул... Андыйга охшамаган, мин аны беләм.

Илсөяр. Каян беләсең? Бер-ике күргән дә, кешене белә, имеш. Анысы да шәрә килеш.

Гөлсинә. Илсөяр!

Илсөяр. Бетте, бетте, шаярам.

Азат. Кем турында сез шулай кич буена гәп куертасыз, ә? Без дә белик әле. Нинди кеше микән ул, алай бик әйбәт... М-м?

Илсөяр. Күпне белсәң, тиз картаерсың...

Азат. Күпне күрсәң, тиз сукыраерсың дисеңме?

Илсөяр. Өстенә бастың. Сак бул.

Азат. Ох, ох. Ярар кирәкми. Мин менә Гөлсинәкә-

емне белсәм, аның янында булсам, шул җиткән. Шулаймы кошчыгым?..

Г ө л с и н ә. Шулай, шулай... Йә, ятма инде өскә, авыр син... Йә инде... кыланма...

Р ә ш и т. Җәмәгать, эчәбезме без, юкмы? (*Көчкә башын күтәрә.*) Юл астына.

И л с ө я р (*рюмкасын тартып алып*). Синең юл астына гына түгел, әллә нәрсә астына да булган инде. Ярый, Гөлсинә, без китик.

Р ә ш и т. Өлешеңә тигән көмешкәңне бирмиләр, кая монда демократия?

Ишектә кыңгырау тавышы.

И л с ө я р. Звонок. Кызык, бу вакытта кем булыр?

Р ә ш и т. Рэкет, мафия. Минем малайлар. Менә алар хәзер, мине эчертмәгән өчен, сезне кыздырып ашыйлар. Ә сине, Илсөяр бәгърем, даже борычлап.

А з а т. Ачмагыз, ачма, бу вакытта...

С а й м ә. Күршеләрдер, ачыгыз.

Г ө л с и н ә. Илсөяр... Һай Аллам, ачыгыз тизрәк.

А з а т. Кирәкми, Гөлсинә.

Г ө л с и н ә. Ачыгыз, дим!

И л с ө я р. Хәзер, хәзер. (*Ачарга китә.*)

Р ә ш и т. Кунак килде. Ну, Илсөяр чукынмыш, барыбер салам бит. Ходай үзебезнеке, бирә дә куя...

И л с ө я р, К ә р и м, Н а и л ә керәләр.

К ә р и м. Исәнмесез.

Г ө л с и н ә. Исәнмесез. Менә бит, сезне көтә-көтә...

К ә р и м. Шулай килеп чыкты инде, ачуланмагыз...

Г ө л с и н ә. Юк, юк, инде килмисез дип тора идек.

К ә р и м. Без тиз генә. Ышандыргач, котлап чыгыйк, дидек.

Г ө л с и н ә. Юк, юк, нинди тиз.

Р ә ш и т. Нинди тиз, нинди киту!.. Бәйрәм дәвам итә! Әйдәле кунак... (*Аракы сала, аны Илсөяр тартып ала.*) Ну, син нәрсә инде... Күпме көттем мин бу кунакны...

И л с ө я р. Җитте сиңа. Дуңгыз булырга димәгән.

Р ә ш и т. Бүре арасында бүре бул, дигәннәр. Дуңгыз арасында дуңгыз булмыйча...

И л с ө я р. Ярый, булды. Нәрсә, ахирәт, авыз ачып торабызмы?

Азат. Әйе, таныштыр булмаса. Үзең танысаң...

Гөлсинә. Ә, әйе, карале, каттым да калдым. Таныш булыгыз. Кәрим.

Азат. Азат. Ә бу матур кызны кем дип белик?

Кәрим. Наилә.

Наилә. Исәнмесез...

Рәшит. Сеңлем, бер дә тартынма. Бик шәп кешеләр без. Аеруча мин... (*Сөртенеп китә.*)

Илсөяр. Утыр инде...

Рәшит. Утыр инде түгел, утырыгыз инде, кунаклар.

Гөлсинә. Ә, әйе, карале... Кәрим, әйдә, узыгыз...

Азат. Наилә туташ, рәхим итегез.

Наилә. Юк, юк, без хәзер китәбез, борчылмагыз.

Кәрим. Әйе, без... (*Гөлсинәгә сыңар роза чәчәге биреп.*) Менә бу, сиңа... туган көнең белән.

Наилә шаккатып карап тора.

Без озакка түгел...

Гөлсинә. Рәхмәт... Кәрим, китмә, зинһар...

Кәрим (*Наиләгә карап*). Белмим инде...

Наилә. Кәрим...

Илсөяр Рәшиткә төртеп ала.

Рәшит. Ә, әйе, Гөлсинә, син берни дә эшли белмисең икән, кошчыгым... (*Наиләне култыклап.*) Каяле туташ, рәхим итеп... Ә син, мужик кеше, үзең дә утырырга тиеш, прошу.

Кәрим, акрын гына, Наилә янына утыра.

Ә хәзер, дәвам итәбез, и все... (*Шешә алып.*) Кара син аларны, мошенниклар, Рәшит абыйларын изге эштән мәхрүм итмәкче булалар...

Гөлсинә. Дөрес, Рәшит, әйдә оештыр! Утырышыгыз, дусларым.

Азат. Гөлсинә, китәргә җыенган идек түгелме соң?

Гөлсинә. Нинди киту, бернинди киту булырга мөмкин түгел, шулаймы, Рәшит абый?

Рәшит. Так точно, иптәш Гитлер.

Илсөяр. Кыз-зык, шайтан алсын, гулять тек гулять.

Саймә кухнядан чыга.

Саймә. Йа Алла, тагын җәелгәннәр. Китәргә җыенган идегез түгелме соң?..

Кәрим торып баса.

Гөлсинә. Утыр. (*Әнисен читкә алып китеп.*) Әни, син нәрсә инде?

Саймә. Нәрсә, нәрсә? Соң оят кирәк азрак, чик-чаманы белергә кирәк. Бу кадәр булырлар икән...

Гөлсинә. Йә инде, шаулама. Бу ул, әни...

Саймә. Кем инде тагын?

Гөлсинә. Шул инде, мине коткарган, алып кайткан.

Саймә. Кайтса, төн уртасында килергә димәгән... Ә тегесе...

Гөлсинә. Анысын үзем дә белмим, аның белән...

Саймә. Йөрерләр инде, өелешеп...

Гөлсинә. Әни?!

Саймә. Чукыныгызсана.

Гөлсинә. Әни, ярар, ярсыма, җитте. Сатулашканчы берәр ризык чыгарсаң, яхшырак булыр иде.

Саймә. Чыгар... Әйтерсең монда Әндрәй казнасы бар...

Гөлсинә. Бүтән туган көн дип авыз ачсаммы?

Саймә. Үз ишләрең түгел, менә нәрсәне аңламыйсың, бала. Ә бусы (*Кәримгә ымлап*) нинди калхуз йолкышы. Үзең дә инде... Тфү!

Гөлсинә. Без генә әйбәт.

Саймә. Әй, тормасана. Туйдым мин бу исерекләрне хөрмәтләп. Мә (*алъяпкычын биреп*), үзегез карагыз. Мин Гаффә апаларында булам. Карагыз аны, артыгын котырмагыз.

Гөлсинә. Бар, бар, бала-чага түгел. Белермен. Борчылма.

Саймә китә.

Гөлсинә. Йә нәрсә, Рәшит дус, мине көтәсезме?

Рәшит. Көтәбез дип, ни, мин ни инде...

Илсөяр. Көтә, көтми... Китте инде Рәшит абзаң, әллә кайчан алга табан...

Рәшит. Соң, Гөлсинәкәй, үзең дә инде, пнимаешь ли, хуҗабикә башың белән читкә китеп йөрисең. Пнимаешь ли, кунаклар бит, ниткән... сусаганский...

Илсөяр. Ну, имансыз да инде...

Наилә. Бар да бар, борчылмагыз.

Гөлсинә. Ә-ә, син һәрвакыттагыча дөрес, Рәшит дустым, сусауны басарга кирәк... Әйдәгез әле...

Р ә ш и т. Менә бит. Акыллы кыз дип, юкка гына мактамыйм мин Гөлсинәне.

А з а т. Рәшит, Рәшит! Җәмәгать, бик җәелергә ярамый. Вакыт та соң, аннары...

Г ө л с и н ә. Ярар, Азатулла, артык итагатьле булып китмә, ярыймы... акыллым...

Р ә ш и т. Эе!

К ә р и м. Чыннан да, без котлыйбыз гына...

Р ә ш и т. Энем, кунак булсаң, тыйнак бул. Тот әле уң кулыңа... юк, уң, уң кулың...

К ә р и м. Мин сулагай...

Р ә ш и т. Сулагай. О-о, алайса, кәнишне, сулга... Менә шулай... Син дә, сеңлем.

К ә р и м. Ул тотмый...

Р ә ш и т. Кара, кара икегезгә бер тел мәллә сезнең... Каяле сеңлем, телеңне күрсәт әле...

Наилә елмая.

Әнә ич теле. Ярамый туган, ярамый, үзе сөйләсен. Кеше, телсез икән бу кызый, дияр.

Н а и л ә. Мин чыннан да...

Р ә ш и т. Бернинди уйнап та даже юк. Андый сүзең булса, лучше телеңне яшер. Бу ризыкка тел кирәкми, авызың гына чәпелдәп торсын.

И л с ө я р. Ну, лыгырдык та инде үзең, суытып бетерә, градусын очырып.

Г ө л с и н ә. Әйе, әйдәгез, дуслар...

Р ә ш и т. Стоп! Кара син аларны! Мине генә тыярга димәгән, мин дә тыям! Ә тост кая? Котлау кайда?

А з а т. Соң, көне буе котладык бит инде...

Р ә ш и т. Апаем, кысылма. Син болай да күп сөйләдең. Кунак, сүлә.

К ә р и м. Ни диим, мин бит ни, котлаган идем.

Р ә ш и т. Шашма, туган, коры котлау була димени. Юешләп, пичәтен сугып күрсәт!

И л с ө я р. Молодец, Рәшит, синнән дә җүнле сүз чыгар икән.

Р ә ш и т. А как же!

К ә р и м (*басып*). Нәрсә диим, Гөлсинә... Гомер юлың гел үзең кебек нурлы, чибәр булып балкып торсын, гел хәзерге кебек тугры дусларың ташламасын, мәхәббәтең

каршыңа чыгып бассын, гел шулай яшь, матур булып — 17 яшьтә кал!

Гөлсинә. Рәхмәт.

Наилә. Котлыйм, мин дә...

Рәшит (*Кәримгә*). Тукта, кузгалма! Селкенә күрмә! Селкенмәгән килеш карап калыйк! Җәмәгать, шагыйрь, шагыйрь ич бу... Менә өйрән, Азат... Ә-ә, сеңлем, алай котламыйлар, күтәреп бетер, төбенә кадәр... Вә-әт.

Илсөяр. Да-а, бик якын иткән кеше генә котлый аладыр болай...

Азат. Ничә көн буе ятладыгыз...

Кәрим. Нәрсәне?..

Гөлсинә (*читкә борып*). Минем адресны ди... (*Азатка.*) Ул аны күптән белә иде инде шул...

Азат. Шулайга охшаган шул...

Илсөяр. Кунаклар, әйдә җитешегез әле. Гөлсинәдә хәзер табын кайгысы юк, аның кунаклары...

Гөлсинә. Әйе, әйе, әйдәгез, җитешегез. Мин хәзер... (*Кухняга кереп китә.*)

Рәшит. Йә, Азат, хәзер тагын синең чират.

Азат. Нәрсәгә?

Рәшит. Тост.

Азат. Кит әле моннан!

Илсөяр. Азат, син нәрсә?

Азат. Бүген көне буе мактыйм бит инде ул кызны.

Рәшит. Димәк, аз.

Азат. Әй!..

Рәшит. Әйтмәсәң, исем китә. Әллә минем телем юкмы? Менә! Сеңлем, ничек минем телем?

Наилә көлә.

Илсөяр. Бер-ике кило бар. Беразын кисеп алып, кыздырмый булмас, артык күп лыгырдый.

Рәшит. Рәхим ит. (*Илсөярнең битен ялап ала.*) Ха-ха-ха. Шулай итеп, тост! Гөлсинә, син кайда?

Гөлсинә. Әйе киләм.

Рәшит. Менә табыныбызны нурландырып, бәйрәмне ямьләндереп, озын төнне кыскартып кунаклар килде. Күренеп тора, алар Гөлсинәне хөрмәт итәләр. Шулай бит, сеңлем?

Наилә. Әйе дисәм инде, мин аны бөтенләй белмим дә әле...

А з а т. Кызык. (*Аңа бик игътибар белән карый.*)

К ә р и м. Әйе, дөресрәге, Гөлсинәне мин якыннанрак беләм. (*Наиләгә карап ала.*)

И л с ө я р (*Рәшиткә пышылдап*). Брудершафт.

Р ә ш и т (*аңламыйча*). Нәрсә дисең?

И л с ө я р. Колак, дим. Әнә калхуз базарында колак саталар, ди. (*Ишарә белән аңлата.*)

Р ә ш и т. Ә-ә, шулай диләр аны. Үзе әйтә белми дә. Шулай булгач, тост! Ты мене уважаешь, я тебе уважаю, дарагуй, значит, мы уважаемые люди. (*Гөлсинәне Кәрим янына этәреп китерә.*) Хөрмәтләшегез инде!..

Г ө л с и н ә. Ничек?

Р ә ш и т. Брудершафт, җәмәгать.

И л с ө я р. Ну баш та инде синдә.

Р ә ш и т. Һе, мин ич ул.

А з а т. Йә, күрик инде кәмитне...

Г ө л с и н ә. Ә нәрсә? Әллә булдыралмас дисеңме? Әйдәле, Кәрим (*Эчәләр, үбешәләр.*)

Р ә ш и т. Молодцы.

И л с ө я р. Булдырдыгыз.

А з а т (*Кәримгә*). Син гади генә егет түгел икәнсең, брат.

К ә р и м. Чыннан да, күңелле икән монда сезнең.

А з а т. Бик...

Н а и л ә (*Кәримгә генә*). Котладык, китик инде.

К ә р и м. Күңелле ич...

Н а и л ә. Сүзеңдә шулай торасыңмы?

К ә р и м. Нинди сүздә?

Н а и л ә. Котлыйбыз да китәбез, дидең.

К ә р и м. Соң болай ярамый бит инде. Бик сәер килеп чыга.

Н а и л ә. Кочаклашып үбешкәч бер дә сәер түгелме?

К ә р и м. Әллә көнләшәсең инде? Ха-ха-ха. Син нәрсә инде, җанашым. Уен гына бит ул. Кунак — хуҗаның ишәге.

Н а и л ә. Ярый, ярый, кал, ишәк булып кала күрмә.

К ә р и м. Борчылма. Азрактан кузгалырбыз.

Г ө л с и н ә (*Илсөярне читкә алып*). Илсөяр, нишлим икән инде.

И л с ө я р. Нишлисең ди, үбештегез бит инде, җитте. Ә ул ничава, высший сорт.

Г ө л с и н ә. Ничава гынамы?

И л с ө я р. Да, мин дә кире какмас идем.

Г ө л с и н ә. Оятсызланма!

И л с ө я р. Син оятсызланасың бит.

Г ө л с и н ә. Ничек?

И л с ө я р. Кызы була торып, арасына бәреп керәсең.

Г ө л с и н ә. Куй әле шул шаяруларыңны. Нишлим микән соң?

И л с ө я р. Таптым! Биибез.

Г ө л с и н ә. Аңламадым.

И л с ө я р. Хәзер, Рәшит, Рәшитулла, сөеклем, мәхәббәтем?!

Р ә ш и т. Нәрсә, тост кирәк мәллә?

И л с ө я р. Туймадыңмыни әле. Синең һаман шул булыр. (*Шешәне алып куя.*) Анысы соңыннан...

Р ә ш и т. Ну, нәрсә инде, нәрсә?

И л с ө я р. Ал баяныңны, кишер борыным, уйна бию көеңне, биисе килә.

А з а т. Сез нәрсә инде, җәмәгать, төн уртасында.

И л с ө я р. Борчылма, стеналар калын, таш йорт. Кунаклар биемәделәр бит әле.

Р ә ш и т. Кәнишне. Бас, кызым, Әпипә, әй лә, Наилә. (*Уйный.*)

Бию.

Г ө л с и н ә. Шуннан нәрсә?

И л с ө я р. Бигрәк хәйләсез икән син, башың бер дә эшләми. Хәзер «белый танец» игълан итәбез дә вәссәлам!

Г ө л с и н ә. Биегәндә генә сөйләшеп өлгерә алмыйм.

И л с ө я р. Ах, ах, тиз генә син, ә. Бәлки, сиңа хәзер үк тупылдап торган бала да кирәктер. Башта биегез. Аннан күз күрер. Бәлки, җайлап үз бүлмәңә чакырырсың.

А з а т. Нәрсә серләшәләр болар һаман?

И л с ө я р. Менә сине үтереп мактыйбыз. Искиткеч эшәп биисең...

А з а т. Чынмы, Гөлсинә?

Г ө л с и н ә. Чын инде, чын.

А з а т. Гөлсинә, ни булды сиңа?

И л с ө я р. Алҗыган кеше, нәрсә бәйләнәсең аңа.

А з а т. Матур кыз?

И л с ө я р. Әйе?

А з а т. Сезнең белән сөйләшмиләр.

И л с ө я р. Мерси. (*Китә.*)

А з а т. Ә бәлки брудершафттан баш әйләнгәндер?

Г ө л с и н ә. Шулай булса, ни булган? М-м?

А з а т. Тукта әле, нәрсә булды сиңа?

Г ө л с и н ә. Берни дә. Бәйләнмәле...

А з а т. Сок-мазар биримме, йә...

Г ө л с и н ә. Кирәкми! Бәйләнмә, дим...

А з а т. Бәйләнмим бит. (*Пауза.*) Кем икәнен әйт инде, һич югы...

Г ө л с и н ә. Кемне?

А з а т. Аны. Бажайның?

Г ө л с и н ә. Сиңа нәрсәгә ул? Тукталe, син нәрсәгә мине тикшерәсең әле?

А з а т. Тикшермим. Но...

Г ө л с и н ә. Кирәкми...

А з а т. Юк, ярар, мин сиңа беркем дә түгел ди... Бергә булган чаклар өчен булса да, үземне кемгә алмаштырасыларын белеп калыйм.

Г ө л с и н ә. Нәрсә? Хыяллан күбрәк. Ярый, бар әле, күңелне болгатма, читтәрәк йөр.

А з а т. Ярый, мин ул малайны...

Г ө л с и н ә. Азат, кара, әгәр аның бер чәче селкенсә?..

А з а т. Нәрсә, селкенсә?

Г ө л с и н ә. Шул, син мине беләсең...

А з а т. Карарбыз.

И л с ө я р. Җәмәгать! Игътибар! Көне буе сикереп, чүт онытмаганбыз. Белый танец. Дамы приглашают кавалеров!

А з а т. Татарчасы — кызлар үзләре ябышалар дип атала.

Р ә ш и т. Кара, син шаяра да беләсең икән.

И л с ө я р (*Гөлсинәгә*). Нәрсә карап каттың, бар, эләктер тизрәк, кызы аңгыраеп торганда.

Г ө л с и н ә. Тиз генә. Азатны читкә алып кит әле, калмый...

И л с ө я р. Азат! Азатчик! Көне буе синең белән бергә хыялландым, рәхим ит. Гөлсинә, зинһар, рөхсәт ит...

Г ө л с и н ә. Нишлим, якын дуска жәлләп булмый. (*Үзе Кәрим каршына китә.*)

Р ә ш и т. Үземә дә җитә, дуслардан да жәлләмим дисеңме?

И л с ө я р. Шулайрак була.

А з а т. Әллә миңа күзең төште? Рәшитеңне нишләтәсең?

И л с ө я р. Үлеп. Әй, Рәшит ул. (*Тамак төбенә чиртә.*)

Р ә ш и т. Но-но, көнләшмим, ләкин кисәтәм...

Г ө л с и н ә. Сине чакырырга мөмкинме?

К ә р и м. Сез дигәндә, аяк идәндә! (*Бии башлыйлар.*)

Г ө л с и н ә. Кунак кыз үпкәләмәсме соң?

К ә р и м. Хуҗабикәнең үзе белән биегәч, түзәр инде. Аннан ул андый түгел, бик әйбәт кыз.

Г ө л с и н ә. Шулай ук бик әйбәтмени?

К ә р и м. Әйе.

Г ө л с и н ә. Алайса аңлашыла...

К ә р и м. Нәрсә?

Г ө л с и н ә. Нигә соңга калганыгыз. Димәк, җибәрәсе килмәде. Әйбәт кыз, ә үзе егеткә ияреп йөри...

К ә р и м. Гөлсинә, син нәрсә? Бары минем белән килде. Ул монда нәрсә буласын да белмәде.

Г ө л с и н ә. Кара, кара, ничек карап тора... Ярата инде ул сине, ә?

К ә р и м. Ярый, бетерик әле ул турыда, яме?

Г ө л с и н ә. Гафу ит. Эх сине... Минем синең үзеңә генә әйтәсе сүзем бар иде.

К ә р и м. Әйе, тыңлыйм.

Г ө л с и н ә. Юк, монда әйтә алмыйм. Әйдә, минем бүлмәгә генә.

К ә р и м. Нигә? Монда гына да була.

Г ө л с и н ә. Юк, дим бит. Мин булдыра алмыйм. Әйдә инде...

К ә р и м. Яхшы түгел...

Г ө л с и н ә. Аңардан куркасыңмы? У-у, чекерәйгән. (*Кәримгә.*) Җегет диген инде моны...

К ә р и м. Нигә куркыйм. Гөлсинә, дим, син аны белмисең, тел тидермә.

Г ө л с и н ә. Ярар, ярар. Алланың кашка тәкәсе?! Сүз дә әйттерми. Мине тыңласаң, тидермәм.

К ә р и м. Әйдә инде, әйдә.

Г ө л с и н ә. Менә шулай. Менә ничек әйбәт була бит. (*Кочаклап диярлек алып кереп китә.*)

А з а т. Охо, бүлмәгә дә кереп киттеләр.

И л с ө я р. Кара, миңа кара әле, әллә кемнәрне күзәтәсең. Кыз үпкәли.

А з а т. Гафу... Просто, Гөлсинәнең кыланышы.

И л с ө я р. Ә син күрмә.

А з а т. Чукынсынсана. Проститутка...

И л с ө я р. Чү, чү...

Бүлмәдән Гөлсинәнең шаркылдап көлгән тавышы ишетелә. Наилә түзә алмый, тиз-тиз җыена башлый.

Р ә ш и т (*уйнаудан туктап*). Сеңлем, син кая?

Наилә эндәшми.

Тукта инде, егетеңне чакырыйм.
Н а и л ә (*елардай булып*). Кирәкми!
А з а т. Туктагыз, хәзер соң бит инде.

Наилә җавап бирми, үкси-үкси чыгып йөгерә.

И л с ө я р. Азат, бар йөгер, зинһар, харап булыр кыз бала.

А з а т. Ничек? Нигә мин?

И л с ө я р. Бар инде, бар, аңгыраеп торма. Таба алмассың аннан.

А з а т. Ә, әйе шул. (*Киемен алып чаба.*)

Р ә ш и т. Кәрим, Кәрим, анаңны...

И л с ө я р. Нәрсә кычкырасың, дурак.

Г ө л с и н ә (*чыгып*). Нәрсә шулкадәр кычкырасың?

К ә р и м (*аның артыннан чыга*). Ә? Нәрсә?

Р ә ш и т. Кәбестә. Кызың — утю-тю!

Г ө л с и н ә. Булса соң. Кеше китте дип елап булмый инде, әйеме, Кәрим?

К ә р и м. Ничек? (*Тиз-тиз киенә башлый.*)

И л с ө я р. Аны озата киттеләр инде, бер дигән асыл егетләр.

Р ә ш и т. Асыл егет...

К ә р и м. Барыбер...

Г ө л с и н ә. Кәрим!

К ә р и м. Нәрсә, нәрсә, ашыгам.

Г ө л с и н ә. Китмә.

К ә р и м. Ничек инде?

Г ө л с и н ә. Калдырма мине.

К ә р и м. Ачуланма, Гөлсинә, күреп торасың, болай да җүләр хәлендә калдым. Кешене рәнҗеттем.

Г ө л с и н ә. Зинһар өчен... Китмә... (*Елый башлый.*) Мин...

К ә р и м (*кире борылып*). Йә, йә, син нәрсә... ну нәрсә инде?.. Ярый, пока...

Г ө л с и н ә. Илсөяр, коткар.

Илсөяр йөгереп барып ишекне бикли, Кәримне чыгармаска тырыша.

И л с ө я р. Син нәрсә, күрмисең мәллә?

К ә р и м. Күрәм, җибәр, соңга калам.

И л с ө я р. Күрәм. Кеше ярсып бетте, син ташлап китмәкче... икенчесен дә бетермәкче буласыңмы... җибәрмим, үтерсәң үтер...

К ә р и м. Нишлисез соң сез. Әллә бөтенегез дә ычкына башладыгызмы? Җибәр, дим, ул анда берьялгызы төн уртасында...

И л с ө я р. Аның артыннан чаптылар инде... борчылма...

Г ө л с и н ә (*чынлап, ярсып елый*). Китмә, ташлама мине... Мин синнән башка. Мин... мин... мин... Ки-и-итмә-ә... (*Буыла.*)

Р ә ш и т. Дела...

И л с ө я р. Ай Ходаем, харап итте кызны.

К ә р и м (*Гөлсинә янына килеп*). Йә, йә... тынычлан... ярамый бит инде... Йә инде, ярсытма үзеңне...

Р ә ш и т. Да...

И л с ө я р (*Рәшиткә*). Әйдәле, безгә теге бүлмәгә керергә кирәк икән бит.

Р ә ш и т (*аптырап*). Нәрсәгә? Ни калган анда? Туктале, карале.

Илсөяр аны төрткәләп алып кереп китә.

Г ө л с и н ә. Зинһар, ташлама... Мин сине һәр көнне көтеп яшәдем... Зинһар, китмә... Зинһар, ташлама... зинһар...

К ә р и м. Йә, булды, булды, калам. Беркая да китмим.

Ут сүнә. П с и х о л о г кабинеты яктыра.

П с и х о л о г. Искә төшәр юләр яшьлегең...

Г ө л с и н ә. Доктор, доктор. Тагын ни эшли ала идем соң мин...

П с и х о л о г. Сабырлык, сабырлык кирәк.

Г ө л с и н ә. Сез дә шулай дип уйлыйсызмы... Минме, мин дипме...

П с и х о л о г. Мин әлегә беркем дә дип уйламыйм. Бары тик бер җыр искә төште... Әй яшьлек...

Ут сүнә.

Ут янганда шул ук сәхнә. С а й м ә апа каядыр җыенып йөри.

С а й м ә. Тәки мин киткәнче кайтып җитмәде... Бетте, бүтән көтәр чама калмады... Китәргә кирәк...

И л с ө я р керә.

Син икәнсең, Илсөяр, саумы! Теге кыз дип торам...

И л с ө я р. Саумысез, Саймә апа, Гөлсинә өйдә юкмыни?

С а й м ә. Юк шул әле. Менә үзем дә көтәм, кайтып җитми... Соңга калдырып бетерде инде. Йә, нәрсә каккан казык кебек катып калдың, уз.

И л с ө я р. Рәхмәт. Ярар инде, китәсегез дә булгач кереп тормыйм.

С а й м ә. Кер, кер, нинди китү. Апа мунчага килерсең дигән иде. Үпкәләп ята, һич барып чыгар хәл юк, шул дөнья мәшәкате белән... Тагын соңга калып бетәм инде...

И л с ө я р. Шуңа тоткарламыйм диюем...

С а й м ә (*киенеп*). Алайса, без болай итик: мин китим... тукта, ашыкма, тыңлап бетер, һай бу яшьләрне... Ә син Гөлсинәне көтеп кал. Колагына киртләп куярга кушты диген, акыллы гына булсын.

И л с ө я р (*чишенеп*). Нигә алай дисез?

С а й м ә. Әйтмәссең. Беркөнне чүп түгәргә дип чыксам, ни күрим, подъезд төбендә теге йолкыш белән тора.

И л с ө я р. Нинди йолкыш?

С а й м ә. Шул инде, теге, төн уртасында туган көненә әсәреп кергән иде бит. Беләсең инде син аны...

И л с ө я р. Нигәдер бер дә хәтерләмим.

С а й м ә. Хәтерләмәсәң, бигрәк тә яхшы. Бер очырып чыгарган идем инде. Оялмыйча: «Гөлсинә өйдәме?» — диеп килгән. Хәчтерүш. Авызын чабатадай җәеп, маляр булып эшлим, дип тора. Очлы үкчәле туфли белән бәргәләп чыгарган идем, тагын торалар. Соң, Илсөяр, җанкисәгем, менә үзең әйт: Гөлсинәгә тиңме инде шул йолкыш, йә?

И л с ө я р. Юк инде, юк, кисеп ташлаган тырнагына да тормый.

С а й м ә. Менә син аңлыйсың, ә теге кызый юк. Акыллы кыз шул син.

И л с ө я р. Акыллы дип, Саймә апа, ярылып ята бит инде. Гөлсинә кем дә, ул кем?

С а й м ә. Тфү! Әйтмә ичмасам. Искә төшсә, күңелем болгана башлый. Карале, Илсөяр. Син инде Гөлсинәнең якын дусты: алай-болай бик нитеп йөрмиләрме?

И л с ө я р. Ничек?

С а й м ә. Соң инде, бик еш күрешмиләрме дип әйтүем.

И л с ө я р. Юк, Саймә апа, алай бик еш күргән юк. Шул, мин югында гына булмаса...

С а й м ә. Ярый, ярый. Шуны әйтүем, минәйтәм, азрак

син дә әйткәләп җибәрсәң, бераз уйланыр иде. Колагына эл әле, яме. Сиңа тиң түгел диеп, шунда...

Илсөяр. Ярый, Саймә апа, ярый.

Саймә. Үзең беләсең, Альберт кайтырга да күп калмады. Яхшы түгел.

Илсөяр. Яхшы, Саймә апа.

Саймә. Мин кузгалыйм. Ә син үз өеңдәге кебек бул. Чәй куеп җибәр, ял ит. Хәзер кайтыр. Ярый, хуш.

Илсөяр. Ярый, Саймә апа, сау бул. Шәпләп чабын. Вәт йолкышлар, ә? Подъезд төбендә үбешмәсәләр?! Оятсызлар, ха-ха-ха! Яле, нинди тәмлүшкәләре бар микән? (*Кухняга кереп китә.*)

Урам якта Кәрим белән Гөлсинә пәйда булалар.

Кәрим. Әллә кермим генәме?

Гөлсинә. Әни әллә кайчан киткән булырга тиеш. Мунчага барасы бар дигән иде, апаларга.

Кәрим. Белмим инде, яхшы түгел. Туфли үкчәсен әле дә оныта алмыйм.

Гөлсинә (*катгый*). Ярый, булды! Мин әйттем, тыңла! (*Йомшарып.*) Син инде мине тыңламый да башладыңмыни, матурым?

Кәрим. Әйдә, кереп карыйк.

Гөлсинә. Менә шулай. (*Ишекне ачып керәләр.*)

Илсөяр (*үзе күренмичә, Саймә апа булып кычкыра*). Кемнәр йөри анда буталып?!

Гөлсинә б,елән Кәрим бер мәлгә туктап калалар. Аннан Кәрим атылган ук кебек ишеккә ташлана, чыгып сыза. Гөлсинә ни кылырга белми аптырап кала.

Илсөяр. Ха-ха-ха! Котлары очты! Ну, куркак икән ул синең, малай...

Гөлсинә. Котны алды. Әни дип торам. Әллә кайларга очыргансыңдыр инде син аны. Син нәрсә? Того что ли?

Илсөяр. Мин бит шаярдым гына.

Гөлсинә. Шаярдым. Йә ярый, эзләп керим. (*Чыга.*)

Илсөяр. Әллә чынлап торып сөйләшәләр инде? (*Көлә.*) Бала-чага төсле кача-поса йөрмәсәләр, хе...

Гөлсинә (*Кәримне алып керә*). Юк инде, әни, юк. Әнә ич Илсөяр ыржаеп тора. У-у-у.

Илсөяр. Син, Кәримулла, ГТО нормасы үтәргә әзерләнәсең мәллә? Бег с препятствиями. Хи-хи-хи!

Кәрим. Уф, котны алдың. Бетте баш дип торам. Гади каршылык булса ярар иде, бигрәк нык бит, теща...

Илсөяр. Кит инде, тещаның да күңелен таба алмагач. Булачак әбиеңнең җаен табарга өйрәтимме?

Кәрим. Тыңлыйм.

Илсөяр. Менә мин теща, ди, әйеме.

Кәрим. Әйе.

Илсөяр. Менә син кайтып керәсең, ди. Кил мондарак. Менә шулай итеп, бик ягымлы елмаеп, күзләренә кара да... Шулай, шулай, башта менә бу як битеннән үбеп ал. Ну, үп инде! (*Кәрим үбә. Үпкән саен Илсөяр дәртләнә.*) Ә хәзер бу ягыннан, әһә... Ә хәзер менә болай... (*Ирененнән озак итеп суырып үбә.*) Вот-т, ә аннан инде тещаң, минем шикелле әйбәт кеше булса, кәнишне, менә болай иттерә. (*Кәримне чытырдатып коча да үбә-үбә диванга ега, торгызмый.*)

Кәрим (*көлеп*). Туктале, җайсыз бит...

Гөлсинә. Кәрим, җитте.

Илсөяр. Ә, нәрсә?

Гөлсинә. Илсөяр!

Илсөяр. Әйттем исә кайттым. Миңа нәрсә... Кияүгә әнә... школа кирәк... Кара аны, Кәрим, оныта башласаң, үземә килерсең, тагын да шәбрәк итеп өйрәтермен, бүтәнрәгенә дә... Ха-ха-ха...

Гөлсинә. Син туктый белмәссең. Уф, ардырды. (*Эчкә үтәләр.*)

Илсөяр. Ну, иреннәрең татлы икән, Кәрим. (*Пышылдап.*) Тагын кабатларбыз, яме.

Гөлсинә. Илсөяр!

Илсөяр (*бала булып*). Мин бик тәти кыз. Эке.

Гөлсинә. Кәрим, Кәримчик?!

Кәрим. Әйе, Гөлсинәм.

Гөлсинә. Кәрим, бар, чәй куеп җибәр әле, яме. Бар әйбер дә шунда, кухняда.

Кәрим. Хе-хе, көләсең мәллә?

Гөлсинә. Нигә?

Кәрим. Ике җиләктәй хатын-кыз барында, мужик кеше чәй куя, өстәл әзерли димени?!

Гөлсинә. Кәрим, ну ярар инде, җанашым, бәгърем минем, тыңла инде...

К ә р и м. Юк, юк, әйтмәгез дә. Әле берәр ирләр эше кушсагыз, ике дә уйлап тормас идем.

Г ө л с и н ә (*кинәт кызып*). Кәрим! Күпме әйтергә була! Әйткәннәр икән, эшлә! Гел кирегә генә сукаларга булсын. Күрмисеңмени, безнең сөйләшәсе бар.

К ә р и м. Соң, әллә кайчан шулай диләр аны... (*Кухняга китә.*)

И л с ө я р. Ох син... Каты тотасың син моны, сынмасын...

Г ө л с и н ә. Кит әле, чынлапмы? Сизми калам шунда. Үпкәләмәде микән инде?.. (*Артыннан чыкмакчы була.*)

И л с ө я р. Тукта, син нәрсә инде... Бигрәк әйбәт... Киресенчә, сине хуплавым, молодчина... Бер ычкындырсаң ул бозау холкын... Минем кулда булса, бүтәнчә...

Г ө л с и н ә. Җитте сиңа, Илсөяр. Дус дигәч тә...

И л с ө я р. Ә ни булган?

Г ө л с и н ә. Булмаган. Бүтән аңа кагыласы булма...

И л с ө я р. Ә үзең, теге вакытта?..

Г ө л с и н ә. Кайсы вакытта?

И л с ө я р. Туган көндә.

Г ө л с и н ә. Ни эшләгән туган көндә?

И л с ө я р. Кызыннан аерып алып, үзеңә ябештерден.

Г ө л с и н ә. Илсөяр, оял, җитте.

И л с ө я р. Оял, оял, ә кызы җылап чыгып китте.

Г ө л с и н ә. Илсөяр, кадалма йөрәккә. Болай да... Әйттем, бүтән аңа кагыласы булма.

И л с ө я р. Куркасыңмы?

Г ө л с и н ә. Ул үзе дә миңа бик кадерле... Ә сиңа бит берничә көнгә...

И л с ө я р. Нишлим соң, ошагач... Курыкма, исән-сау кулыңа тапшырырмын.

Г ө л с и н ә. Ну, Илсөяр, булды. Ничек Рәшитең түзә синең? Берәр ирне тыныч уздырып җибәрәсеңме соң син?

И л с ө я р. Ярар, ярар, башың яшь әле... Күрербез. Ә Рәшит нәрсә? Безнең — ирекле мәхәббәт. Бел, ычкындырсаң асыл егетне, үзем кармакка эләктерәм.

Г ө л с и н ә. Булды, дим. (*Пауза.*) Син безне аңлап бетермисең. Их, белсәң иде, миңа аның янында ничек рәхәт икәнен. Карале, бәхетле кеше нинди кыяфәттә була микән ул?

И л с ө я р. Хи-и, тач, нәкъ син инде. Бераз борының-

ны да юып җибәрсәң... Мыегының мае сыланып, тузан җыелганмы?

Г ө л с и н ә. Йә, йә, көлмә.

И л с ө я р. Көлсә. Әнә әниең кайтып җитсә, бәхет кошың бик тиз кыйраклар, кытаклап очып китәр. Миңа да...

Г ө л с и н ә. Нәрсә, сиңа да?

И л с ө я р. Күз-колак бул, ди. (*Колагын борып.*) Колагына киртләп куй, ди. Ни-ни.

Г ө л с и н ә. Нәрсә ни-ни?

И л с ө я р. Акыллы булсын, ди, әйт әле, шул кызыймызыйга, ди. Җыен әтрәк-әләм белән мәтәшмәсен, ди.

Г ө л с и н ә. Әнинең шул булыр инде аның. Аңа генерал кияү кирәк. Ә мин нишлим аның белән...

И л с ө я р. Мин дә шуны сүлим бит: эт өрер, бүре йөрер, ди. (*Пауза.*) Әллә сразу миңа гына калдырасыңмы?

Г ө л с и н ә. Илсөяр, җитте инде сиңа.

И л с ө я р. Б-р-р-р! Кеше тәшсә тәшсен, мин тәшмим.

Г ө л с и н ә. Беләсеңме нишләргә булдым?

И л с ө я р. Нишләргә?

Г ө л с и н ә. Аңа чыгарга!

И л с ө я р. Утю-тю. Ә әниең?

Г ө л с и н ә. Белсә, үтерә.

И л с ө я р. Ә ничек итеп алайса?

Г ө л с и н ә. Белмим. Бәлки, аңа әйтми торырбыз.

И л с ө я р. Ә бу нәрсә ди?

Г ө л с и н ә. Ул белми әле...

И л с ө я р. Ничек?

Г ө л с и н ә. Шулай. Сөйләшмәгән әле. Аның да күңелендә бар бугай...

И л с ө я р. Кыз-зык... Синең башны бөтенләй әйләндергән, ахрысы, бу малай... Ярар әйдә, хәерлегә булсын, мин пас алайса. Ничек соң, әйбәтме?

Г ө л с и н ә. Оятсызланма.

И л с ө я р. Соң инде, яхшы булмаса, чыкмас идең. Сине өйрәтәсе юк... Хи-хи. Ә Альбертың ни эшли. Үзе чит илдә, үзе капиталлы, үзе солидный...

Г ө л с и н ә. Ниткән Альберт ди хәзер. Хет шунда бөтен дөньясы бушап калмый. (*Хыялый елмаеп.*) Бары тик Кәримем булса...

И л с ө я р. Йә, йә, син ни... ычкына күрмә тагын... «фазаңны» сакла... Шулай инде... Асылынсаң, асылын агачның асылына... Т-с-с, тыңлап тормасын...

Г ө л с и н ә. Юк, андый гадәте юк аның. Туктале, янына чыгыйм, үпкәләтмим тагын җанашымны. (*Китә.*)

И л с ө я р. Пычак була... җанашым, хе, дела...

Г ө л с и н ә (*кухнядан кычкырып*). Монда чыгасыңмы, синең янда эчәбезме?

И л с ө я р. Әйдә монда. Җенем сөйми шул кысан кухняларны... Карале, Гуль...

Гөлсинә кухнядан подноста чашкалар, чәйнек күтәреп чыга.

Г ө л с и н ә. Нәрсә?

К ә р и м. Булышыйммы?

Г ө л с и н ә. Юк, юк. Үзем. Ял ит.

И л с ө я р. Булышсын. Ир кеше хатын-кызга гел булышырга тиеш.

Г ө л с и н ә (*чәй салып*). Нәрсә әйтмәкче идең?

И л с ө я р. Юк, болай гына. Кызык булып китте: кухня да кухня. Безнеңчә нәрсә була микән ул?

Г ө л с и н ә. Теләсә нәрсә булсын, өстәле генә мул булсын.

К ә р и м. Чыннан да, кухня, кухня. Кухарка дип алсаң — пешекче була. Пешекче бүлмәсе. (*Чәй эчәләр.*)

И л с ө я р. Кит инде. Эшләт башыңны.

К ә р и м. Ничек микән?

Г ө л с и н ә. Әйдә, аптыратма кешене. Әнә чәегезне эчегез. Ә син... (*Кәримгә сиздермичә генә Илсөяргә, китсәң дә була, дигән ишарә ясый.*)

И л с ө я р. Әхә-хә, мәхәхә! Ярый, ярый, кумасаң да, китәм. Чәй эчәргә дә ирек бирми. Терәлгән икән...

К ә р и м (*аңламыйча*). Кем куа? Ни сөйлисең?

Г ө л с и н ә. Күләгә белән сөйләшә. Илсөярне белмисеңмени?

К ә р и м. Ә-ә.

И л с ө я р. Эке. Күләгә. Ишек ачасы калмаган аны. Рәхәтләнеп сыйланып яткан булыр идем.

Г ө л с и н ә. Ярар, күп телеңә салынма, бүтән чакны лыгырдарсың. Җил тегермәне. Бер кузгалса, туктатып булмый.

К ә р и м. Таптым!

И л с ө я р. Нәрсәне?

К ә р и м. Таптым. Аш өе, аш бүлмәсе була ул.

И л с ө я р. Син ни турында?

К ә р и м. Соң, кухня соң?! Аш өе?! Аш бүлмәсе!

И л с ө я р. Фу, ни шаккатыра дисәм. Мин инде ул турыда оныттым да...

Г ө л с и н ә. Шулай була бугай шул... (*Илсөяргә ышереп кенә йодрык күрсәтә.*)

И л с ө я р. Аш өе инде, аш өе! Ашым аш булмады дип, шушы очракта әйтә торганнардыр... Дустың булса, шундый булсын, ярын икегә бүләрлек... Китим әле мин, озакладым...

К ә р и м. Кая? Әле утырдык кына бит...

И л с ө я р. Рәхмәт инде. Гөлсинәң, җимешең-фруктың чәчәк ата башлады. Бик, бик бигрәкләр ашыгасым бар икән минем, бик-бик ашыгыч эшем бар икән.

Г ө л с и н ә. И-и ахирәт, ул кадәр ашыкмасаң иде. Утырырга иде...

И л с ө я р. Утырттың инде... Булмас, булмас, Галиулла, балалар да йокламаган, кытыгым да бик килә дигәндәй... Кая, Кәрим, тагын бер бик тәмләп пәп итим дә... (*Кәримгә үрелә.*)

Г ө л с и н ә (*аны этәреп*). Бар, бар, узынма!

И л с ө я р. Ярый инде. Менә Кәрим, шундый саран дусларың булмасын. Сау булып торыгыз. (*Китә.*)

Г ө л с и н ә. Килгәлә. Без өйдә югында.

К ә р и м. Бигрәк кызык инде бу Илсөяр. Ут капкандай тик торганда сикерде дә чапты. Хе...

Г ө л с и н ә. Әйтмә. Ашыгыч эше бардыр инде, алай капылт чыгып чапмас иде. (*Кәримне кочып.*) Көчкә... Менә хәзер без үзебез генә... Хәзер мин сине... (*Шашып коча, үбә башлый.*)

К ә р и м. Синең белән шундый рәхәт. Гел икәүдән-икәү генә калып торсак икән без, име.

Г ө л с и н ә. Мин сине шуңа юри аулакка алып кайттым да инде. (*Үбешәләр.*)

К ә р и м (*пышылдап*). Синең сюрприз шушымыни инде ул?

Г ө л с и н ә. Әһә. Кич тә безнеке. (*Колагына пышылдый.*) Төн дә...

Икесе дә кочаклашып тәгәриләр, көлешәләр.

К ә р и м. Гөлсинә.

Г ө л с и н ә. Әйе, алтыным?

К ә р и м. Син ачуланма. Ләкин, зинһар өчен, кеше

барында булса да, син миңа алай кычкырып команда бирмәскә тырыш, яме. Югыйсә...

Г ө л с и н ә (*аның авызын каплап*). Булды, булды, оныт аны, бүтән дәшмә... Мин гаепле... Матурым, бүтән алай булмам, яме... Кызып китәм дә...

К ә р и м. Бетте. О-ныт-тым... Кап та куп.

Г ө л с и н ә. Сукыр Якуп! (*Дәшмичә, авызларын йомып утыралар. Үбешәләр. Кәрим түзә алмый, кытыкланып көлеп җибәрә.*) Әһә, син беренче! Яле, кем өй түбәсенә?

К ә р и м (*көлеп*). Сезнекенә!

Г ө л с и н ә. Безнекенә үкмени?! Алайса менә. (*Куышалар. Диванга егылып, шаярып сугышалар. Икесе дә арып, әлсерәп туктыйлар.*) Сиңа хәзер җәза бирергә кирәк.

К ә р и м. Мин әзер. Мондый чибәр кыз кулыннан шәһид китүе дә зур бәхет.

Г ө л с и н ә (*җитдиләнеп*). Менә нәрсә...

К ә р и м. Әйе, йөрәк маем?..

Г ө л с и н ә. Беләсеңме...

К ә р и м. Не знай Балтач, без Чепия яклары.

Г ө л с и н ә. Юк, мин чынлап әле бу юлы. Тыңлале.

К ә р и м. Әйе. Колаклар локатор, үзем...

Г ө л с и н ә (*иркәләп*). Мин сиңа хәзер бер-ике әйбер әйтәм, син риза буласың. Килештекме?

К ә р и м. Уйлап карарбыз.

Г ө л с и н ә. Ә юк. Син уйламыйча гына. Син бит җиңелдең. Шулай булгач, синнән должок...

К ә р и м. Х-м-м, кызык. (*Бераздан.*) Әйдә, шайтан алгыры, кая кереп, кая китмәгән. Синең өчен барына да риза.

Г ө л с и н ә (*аны үбеп алып*). Бәгърем дә инде... Мин дә синең хакка гына әйтәм... Хәтерлисеңме микән, теге юлы син бер сүз башлаган идең...

К ә р и м. Нинди сүз?

Г ө л с и н ә. Соң теге вакытта... Мин уйлармын дигән идем...

К ә р и м. Син нәрсәне әйтәсең, әллә...

Г ө л с и н ә. Әйе инде, әйе...

К ә р и м. Өйләнү турындамы?

Г ө л с и н ә. Әйе. Мин уйладым инде...

К ә р и м. Ә-ә, ха-ха-ха. Шаярып бит ул...

Г ө л с и н ә. Ә мин...

К ә р и м. Әйе...

Г ө л с и н ә. Чынлап.

К ә р и м. Тукта, тукта, син менә хәзер дисеңме?

Г ө л с и н ә. Әйе, җаным.

К ә р и м. Туктале, ни бит, Гөлкәем, безгә болай да бик әйбәт бит әле. (*Коча.*)

Г ө л с и н ә. Син? Каршы? Ә мин...

К ә р и м. Юк инде... Ни инде... Юк, мин һич тә каршы түгел дә, ну бераз нитик диюем, ашыкмыйк...

Г ө л с и н ә. Аңлашыла.

К ә р и м. Нәрсә?

Г ө л с и н ә. Минем белән булган хәлләр тынгы бирмиме әллә?

К ә р и м. Син ни сөйлисең, Гөлсинә? Булмаганны. Ул бит бәхетсезлек. Һәркем белән булуы бар... Ашыкмыйк, бер-беребезне якынрак белик диюем...

Г ө л с и н ә. Тагын нәрсәсен беләсе бар инде... Мин болай да бөтенләем белән синеке... Миңа синең янда шулкадәр әйбәт.

К ә р и м. Миңа да шулай да бит, җанашым... Әни дигән кеше дә бар бит әле... Ы-ы-ы, шул шул...

Г ө л с и н ә. Син мине аңламадың.

К ә р и м. Юк инде, алай түгел ул...

Г ө л с и н ә. Аңлашылды... (*Юри шат кәефле булып.*) Ярый, бетте, ул хакта бүтән бер сүз дә...

К ә р и м. Туктале...

Г ө л с и н ә. Юк, юк, ул хакта авыз да ачма.

К ә р и м. Җүләрем. Мин бит үзем дә бик телим.

Г ө л с и н ә (*ясалма көлеп*). Ә мин теләмим. Ха-ха-ха.

К ә р и м. Нигә ул кадәр ашыгырга гына дигән идем. Ризамы?

Г ө л с и н ә. Юк.

К ә р и м. Йә инде, ачуланма. Ризамы?

Г ө л с и н ә. Юк, дидем.

К ә р и м. Ой Аллам, мин бит ашыкмыйк кына, дидем. (*Кочаклап Гөлсинәне кыса башлый.*) Ризамы миңа чыгарга?

Г ө л с и н ә. Юк, юк, юк! (*Бик каты кыскач, түзалмаган кыяфәттә.*) Ри-и-и-за. Үтерә яздың бит.

К ә р и м. Карышмассың.

Г ө л с и н ә. Минем тагын бер үтенечем бар иде.

К ә р и м. Әйе, соң?

Г ө л с и н ә. Син тагын кирегә сукаларсың. Әй, әйтмим.

К ә р и м. Әйтәсең.

Г ө л с и н ә. Юк, сорама да...

К ә р и м. Йә инде, йә, әйт, җанымны кыйма. Әйтү белән риза булам.

Г ө л с и н ә. Юк, юк, юк.

К ә р и м. Әйт дим тизрәк, мин барына да риза.

Г ө л с и н ә. Без синең укуың турында сөйләшкән идек...

К ә р и м. Ә-ә, тагын шул.

Г ө л с и н ә. Менә бит.

К ә р и м. Соң, теләмим мин анда укырга, күңел тартмый.

Г ө л с и н ә. Кызма әле...

К ә р и м. Гел шуны кыстырасың бит, җанашым. Ошамый ул эш миңа, күңелем кабул итми. Соң кара инде бераз — нинди торгаш инде мин йә. Үз эшем менә дигән.

Г ө л с и н ә. Нәкъ инде. Буяучы, маляр. Башыңа буяу исеннән минингит булгач аңларсың да...

К ә р и м. Булсын. Аннан мин гади буяучы да түгел...

Г ө л с и н ә. Галәмәт инде... бизәк төшерүче... Би-и-ик зур начальник...

К ә р и м. Көлмә. Миңа ошый. Бөтен кеше начальник булмый.

Г ө л с и н ә. Беләсеңме (*иркәләнеп*), сәүдә өлкәсендә ир кешегә өскә күтәрелүе дә бик җайлы... Рәхәтләнеп яшәргә дә була. Ә?

К ә р и м. Юк.

Г ө л с и н ә. Юк дигән була. Укый алмыйм, башым җитми диген инде. Юк, теләмим дигән була.

К ә р и м. Һәй, теләсәмме?

Г ө л с и н ә (*юри котыртып*). Ну, теләсәң ни?

К ә р и м. Мин анда эх тә итми укый алам.

Г ө л с и н ә. Тел белән.

К ә р и м. Йә ярый, матурым, сүз көрәштермик. Үзем карармын әле. Миңа, мәсәлән, бөтенләй башкасы ошый...

Г ө л с и н ә. Ниндие?

К ә р и м. Рәссамнар әзерли торганы. (*Пауза.*)

Г ө л с и н ә (*сырпаланып*). Кәрим, Кәримчик, син бигрәк акыллы инде, әйеме...

К ә р и м (*көлеп*). Сырпаланма, җанашым, юкка. Юк, юк.

Г ө л с и н ә. Ярар, ярар. Онытып тор. Ул турыда бер бик яхшылап сөйләшербез әле. (*Пышылдап.*) Икенче җирдә.

К ә р и м. Аңлап бетермәдем?

Г ө л с и н ә. Аңларсың. Тормыш — ананңны ормыш, ди. Сиңа алдау кирәкми, син мине генә тыңла, яме.

К ә р и м. Ә безнең эшкә әниең нәрсә ди инде?

Г ө л с и н ә. Үтерәчәк. Ул миңа бик бай, бик дәрәҗәле кияү әзерләмәкче иде...

К ә р и м. Нишлибез соң?

Г ө л с и н ә. Үзебезнекен эшлибез. (*Кочаклый.*) Әни сүзен тыңласаң — рәхәте юк, рәхәте булса — урыс әйтмешли (*авыр сулап*), и хочется, и колется, и мамка не велит... (*Көлешәләр.*) Җае чыгар әле...

К ә р и м. Шулай итеп, никах!

Г ө л с и н ә. Хәзер алай димиләр аны. Ни хак!

К ә р и м. Эх! Эштән, тулай торактан бүлмә дә биреп куйсалар. Ну, яшәп җиффәрер идек, ә?

Г ө л с и н ә. Хәзер. Йөгердем тулай торакка. Аллам сакласын.

К ә р и м. Нигә? Кечкенә булмый ул. Ну, ким дигәндә, 8 квадраттыр, 12 лесе әләксә, мечта, тәгәрәп йөрербез.

Г ө л с и н ә. Беркайчан. Өч бүлмәле фатирыбыз була торып. Юкка башың катырма, җае чыгар. Мин көтәм.

К ә р и м. Нәрсәне?

Г ө л с и н ә. Сине?

К ә р и м. Куптән көтәсеңме, җанашым?

Г ө л с и н ә (*кочаклап*). Бөтен гомерем буе көттем мин сине, шаша-шаша, ярсый-ярсый, елый-елый. Язмышым минем, бәхетем минем!

Ут сүнә. Психолог сәхнәсе яктыра.

П с и х о л о г. Йөгереп килеп кочкан иттереп, күрсәтер йокыңда төшләрең.

Г ө л с и н ә. Доктор, доктор, сез нәрсә инде!..

П с и х о л о г. Юк, юк, тормыш шул бу...

Г ө л с и н ә. Нинди мәгънәдә, доктор?

П с и х о л о г. Сез артык дулкынланмагыз...

Г ө л с и н ә. Ничек алай дип әйтә аласыз сез, доктор?!

П с и х о л о г. Зинһар өчен, борчылмагыз гына. Сез мине дөрес аңламадыгыз. Күпләрнең язмышы, кызганычка каршы, күпләрнең...

Г ө л с и н ә. Гафу, доктор, ярдәм генә итегез...

Авансцена. Мендельсон маршы яңгырый. Сәхнә кырындагы ишектән

ак туй күлмәге кигән Г ө л с и н ә һәм К ә р и м чыгалар. Алар янында — бәйрәмчә киенгән И л с ө я р белән Р ә ш и т.

И л с ө я р. Йә, ахирәт, бер үбим әле, чын күңелдән тәбрик итәм.

Р ә ш и т. Ну, баҗай, чын ихластан, тот бишне! (*Кәримнең кулын кыса.*)

И л с ө я р. Ниткән баҗай?

Р ә ш и т. Кара, кара, әсәрде. Юк инде, сине генә өзелеп сөям. Соң сез шулкадәр ахирәтләр булгач, туганнар дияргә була бит. Без кем булабыз соң?

К ә р и м. Баҗай!

Р ә ш и т. Шулай шул. Йә, баҗай, бармы җай?

К ә р и м. Булыр, баҗай.

Р ә ш и т. Котлыйм, Гөлсинә балдыз, чып-чын күңелдән! Күптин-күп, чуктин-чук бәхетле булыгыз.

И л с ө я р. Котлыйм, Кәрим. Кара аны: кызның Казандагы берен алдың, бәхетле итмәсәң?!

К ә р и м. Итәм. (*Гөлсинәгә.*) Акыллым, син бәхетлеме?

Г ө л с и н ә. Бик, бик! (*Күзләре яшьләнә.*) Чиксез!

И л с ө я р. Йә инде, ахирәт.

Г ө л с и н ә. Күңелем тулып китте.

И л с ө я р. Хәзер бушатабыз аны. Рәшитулла, ал әле шуннан бер шампанны.

Р ә ш и т. Әллә кайчан миңа эш кушмыйча. Интегәм эшем булмаса. Айн момент. (*Шампан ача. Сала.*)

И л с ө я р. Йә, Рәшитхан, селкет телеңне, башка вакытта туктатып булмый.

Р ә ш и т. Яхшы. Кадерле яшьләр! Сезне менә шушы бик матур Илсөяр апагыз белән, ихлас күңелдән законлы никахыгыз белән тәбрик итәбез. Матур гаилә корып, менә шушы шампан суыдай кайнап, көнен дә, төнен дә...

И л с ө я р. Йә, йә арттырма...

Р ә ш и т. Әйе, кайнап, дистә-дистә бала-чагаларыгыз янызыгызда чабып йөреп, телеграмм баганалары чаклы үсеп, сезгә биниһая күп шатлык, бәхетләр китерсеннәр. Амин!

И л с ө я р. Бәхетле булыгыз!

Р ә ш и т. Горько!

И л с ө я р. Монда инде...

Р ә ш и т. Булсын. Ачы! Маттиети! (*Яшьләр үбешәләр.*) Менәтерә пичәте сугылды.

Г ө л с и н ә. Ой, күз яше белән тушым юылды, күзем.

И л с ө я р. Ышкыма инде.

Г ө л с и н ә. Барыбер буялды.

Р ә ш и т. Ничава. Алай гына мулла кызында да була ул. Кара йөзле килен... Ха-ха-ха.

К ә р и м. Әйдә, тизрәк кайтыйк та юарсың. Машина да көтеп тора.

Р ә ш и т. Ә өстәл?

К ә р и м. Анысы күптән.

Р ә ш и т. Шулай диген. Ату бармыйдыр идем.

И л с ө я р. Әй хөрәсән, сөйләнеп тора тагын. Минем аркада гына йөргәнен белми... Ә Саймә апа килмәдеме?

К ә р и м. Килә алмады шул... Әйдәгез. (*Китәләр.*)

Гөлсинәләр фатиры. Шул ук бүлмә. С а й м ә, Г ө л с и н ә һәм К ә р и м кайтып керәләр. Кәрим ишек төбеннән узмый.

С а й м ә. Әйдә, әйдәгез. Әнисен артыннан йөрттерә бит.

Г ө л с и н ә (*эчкә үтеп*). А-а-х, мин өйдә. (*Әнисен кочаклап.*) Ой, әни, ничек рәхәт монда, син хәтта күз алдына да китерә алмыйсың! Ә сине ничек сагындым.

С а й м ә. Сагынгансыңдыр шул... Бик сагынганга, ярты ел буе өйгә кайтмый йөрисең. Килеп тә карамыйсың.

Г ө л с и н ә. Ярар инде, әни, искене казымыйк. Ярты ел түгел, ай ярым гына диярлек... Ой, ничек рәхәт миңа... Бүтән беркая да китмим, әни, теләсәң ни эшлә.

С а й м ә. Китмим. Чыкты да китте, болын чаклы өйне ташлап. (*Еламсырый.*) Мине мыскыл итеп... Күршеләрдән оят... Куып чыгарган, диләр...

Г ө л с и н ә (*елмаеп*). Соң, әни, шулай булып чыкты да бит. Куып чыгардың, өчәрләтеп, ха-ха-ха... Әнә Кәримнең әле дә коты очып тора.

Кәрим елмаерга тырыша.

С а й м ә (*тавышын күтәрә төшеп*). Чыгарса... Кычкырса... (*Мышкылдый.*) Мин нәрсә кычкырмам... Әни кеше кычкыра инде ул... Кызы исәр булгач...

Г ө л с и н ә. Йә, йә, әни, артыгы китә башлады...

С а й м ә. Гарьлек... Гарьләнәм... Әни кычкыра дип, бердәнбер кызың ташлап чыгып китсен инде... Кем белән диген...

Г ө л с и н ә. Әни, дим!

С а й м ә. Йә, үтегез, нәрсә икәүләшеп катып калдыгыз... Кунакка килмәгән...

Г ө л с и н ә. Рәхмәт, әни... Әнием дә инде ул минем, акыллым.

С а й м ә (*үртәп*). Рәхмәт... кайтып киту юк, әни килеп алырга тиеш... оятсыз...

Г ө л с и н ә. Йә инде, әни, булган беткән. Кызың киткән...

С а й м ә. Остарма, әйдә узыгыз, чәй эчәрбез. Эсселәтте.

Г ө л с и н ә. Хәзер, әни, куеп җибәрәм. (*Кухняга китә.*)

С а й м ә (*Кәримгә*). Йә, үги бала кебек торма ишек төбендә... Уз. Кем әле исемең?

К ә р и м. Кәрим.

С а й м ә. Уз әйдә, Кәрим.

К ә р и м (*бик дәртле кыяфәткә кереп*). Һәй, әнкәй, бер дә кайгырмагыз, тормыш булгач, төрле хәл була. Әле без гөрләшеп яшәрбез. Мин әле сезне өрмәгән җиргә дә утыртмам. Кияү булса, кияү булсын, әйеме?

Г ө л с и н ә (*кухнядан*). Ә әни?! Кара киявең нинди?!

С а й м ә. Карыйсың инде, карамый нишлисең, алма кебек кызның башын ашагач...

Г ө л с и н ә (*кухнядан*). Әни-и!

С а й м ә (*Кәримне читкәрәк алып*). Менә нәрсә, сөйләшеп куйыйк әле: әйтмәле шул әни сүзен, яме.

К ә р и м. Нигә, әни? Ой, гафу.

С а й м ә. Шулай булып торсын әле... Тагын кем диләр әле кыз әнисен?

К ә р и м. Әби, диләр, ләкин...

С а й м ә. Нәрсә ләкин?

К ә р и м. Ничек итеп сезгә әби дим?! Сез шундый яшь күренәсез...

С а й м ә. Рәхмәт... Барыбер әйтмә...

К ә р и м. Ярар. Сез ни әйтсәгез, шул булыр.

С а й м ә. Саймә апа гына диярсең.

К ә р и м. Яхшы, яхшы. Сез ни әйтсәгез дә, мин риза.

Г ө л с и н ә (*чыгып*). О-о, инде серләшә дә башлаганнар. Серләр килешә сезнең, ә?

С а й м ә. Килешмичә... Алайса сөйләштек.

К ә р и м. Яхшы, Саймә апа.

Г ө л с и н ә (*Кәримне кочаклап*). Саймә апа түгел, әни! Әйт әле: ә-ә-ни-и... Яле.

С а й м ә. Ялыктырма кешене, өйрәнер әле.

Г ө л с и н ә. Кара, берәүләр кадерле кияүләрен яклый ук башладылар. Менә әни, ә син әйткән буласың. Әле

киявеңнән башка тора да алмый башларсың. Кара син аларны, шул арада серләшә дә башладылар...

С а й м ә. Йә, әйдәгез, чәйгә...

Г ө л с и н ә. Кая әле, әни, куйдым гына бит. (*Кәримгә.*) Кәрим, аппагым.

К ә р и м. Әйе, Гөлем.

Г ө л с и н ә (*әнисенә сыенып*). Әни бик җитди сәбәпләр аркасында безнең туйда була алмады. Син хәзер тиз генә кибеткә барып кил, яме, авырсынмасаң...

С а й м ә. Юк, юк, юк, нинди әйбер ул тагын, ниткән туй, берни дә сөйләмәгез дә, кирәкми дә...

Г ө л с и н ә. Әни, каршы килмә. Алай ярамый! Туйда да булмадың, хәзер дә! Үпкәләтмә юк өчен. Ни әйтсәң дә, мин синең бердәнбер кызың...

С а й м ә (*йомшарып*). Мин бит каршы түгел... Мәшәкатьләнмәгез генә димәкче идем...

Г ө л с и н ә. Менә акча, озак йөрмә, яме, матурым.

К ә р и м. Мин хәзер, тиз генә. Ә-ә, ничәне...

Гөлсинә ике бармагын күрсәтә.

Йөгердем.

Г ө л с и н ә (*әнисен кочаклап*). Әнием! Ничек рәхәт бездә.

С а й м ә. Р-рәхәт. Нишлибез инде без хәзер?

Г ө л с и н ә. Ничек нишлибез?

С а й м ә. Шушы гыйбад белән бергә яшибезме? Каккан казыгы да юк бит аның. Әй бала, бала. Бирдең син миңа, авыртмас башка тимер тарак...

Г ө л с и н ә (*йомшак елмаеп*). Йә инде, әни. Бик әйбәт ул. Син әле белмисең генә. Җитмәсә, сәүдә эшенә укыячак...

С а й м ә. Каян килеп?

Г ө л с и н ә. Укыр, укыр. Керттем инде. (*Көлеп.*) Казыгы да булыр... Бар да әйбәт булыр.

С а й м ә. Булыр. Күргәне дә чиктән ашкан. Нахал...

Г ө л с и н ә. Кәримме? Ха-ха-ха! Нахал. Аңа тагын. Чебенне дә рәнҗетә алмый бит ул. Юк, әни, ул исkиткеч.

С а й м ә. Нишлисең бит... түзәргә тырышырмын... бер бәхетең булмаса...

Г ө л с и н ә. Синме бәхетсез... Син нәрсә, әни. Ашыкма, әле без сине шундый итеп бәхетле итәрбез. (*Пышылдап.*) Бер бәләкәчне апкайтып тоттырсак.

С а й м ә. Иттердең инде... Шунысы гына җитмәгән тагы.

Г ө л с и н ә. Ә нәрсә? Менә кара әле моны! (*Корсагын тоттыра, көлә.*)

С а й м ә. Үртәмәсәнә мине. Тик минем алда, кочыш-мочышларыгызны бетерегез, укшыта.

Г ө л с и н ә (*елмаеп*). Ой, әни, онытылып китәбез, зинһар!

Ишектә кыңгырау тавышы.

Әһә, кайтып та җитте. Бигрәк җитез дә инде... Хәзер! (*Ишеккә китә.*)

Саймә эчке бүлмәгә уза. Тышкы ишектән А л ь б е р т керә.

А л ь б е р т. Хау-ду-ю-ду!

Г ө л с и н ә. Ба-а, Альберт! (*Кочагына ташлана.*) Ба-а, Альберт, күпме җәйләр, күпме... Ба-а-а... Син дә бер кайтырсың икән, күрше...

А л ь б е р т. Гулечка! Матурым! Син ничек матурайгансың. Танырлык та түгел...

Г ө л с и н ә. Менә сиңа мә? Көтелмәгән кунак!.. (*Әнисенә.*) Әни, әни, чык әле, кем кергән безгә? Нинди кунак бар монда! Кругом маде ин импорт!

С а й м ә (*чыга*). Нәрсә шаулыйсың тагын, ни булды? (*Альбертны күреп.*) Менә сиңа мә? Альберт түгелме соң бу?! Ә-әй, танырлык та түгел. Чибәрләнгән, тазарган. Яле, яле, күрешик әле. (*Кочаклашып күрешәләр.*) Әй, менә вакыт үтә дә китә шул. Күпме әле?

А л ь б е р т. 3 ел, 4 ай, 17 көн.

Г ө л с и н ә. Ничә сәгать?

А л ь б е р т. Нәкъ вакытында, өйдә туры килдегез. Инде өйдә генә булсалар ярар иде, дип килгән идем.

С а й м ә. Кап-кара булгансың.

Г ө л с и н ә. Негр.

А л ь б е р т. Нишлисең. Негрлар арасында бит.

С а й м ә. Кайда идең әле син, улым?

А л ь б е р т. Африкада. Мозамбик дигән илдә.

С а й м ә. 3 ел. Баеп беткәнсеңдер инде.

А л ь б е р т (*муенынnан сызып*). Сүз юк. Анысын бер сөйләрмен әле.

С а й м ә. Әниең бик мактый иде инде, улым булган,

дип. Әй, карале, ишек төбендә торабыз, әйдәле, Альберт, уз әле, уз.

Г ө л с и н ә. Әйдәле, әйдә.

А л ь б е р т. Рәхмәт. Башта менә боларны хуҗаларына тапшырыйм әле. (*Төргәк, коробкалар ала.*) Менә, Саймә апа, менә болары сезгә!

С а й м ә (*нишләргә белмичә*). Ай, кит, улым, бигрәк уңайсыз, шулкадәр әйбер.

А л ь б е р т. Юк, юк, Саймә апа, алмасагыз үпкәлим... Сез минем өчен бик кадерле кеше...

С а й м ә (*алып*). Рәхмәт инде, бигрәк зурлагансың.

А л ь б е р т. Бер дә уңайсызланмагыз, минем өчен пүчтәк ул. То ли еще будет, Алла боерса. (*Гөлсинәгә төргәкләр биреп.*) Ә менә болары, Гөлсинәкәй-чибәркәй, сиңа... ал, ал... нигә куркып калдың... ал...

Г ө л с и н ә. Әллә ничек, Альберт, миңа синнән берни дә кирәкми иде...

А л ь б е р т. Үпкәләтәсең, Гөлсинә, обижаешь...

С а й м ә. Ал инде, ал, кеше сине хөрмәтләп...

Г ө л с и н ә. Рәхмәт инде, Альберт... (*Төргәкләрне тиз генә алып куя.*)

А л ь б е р т. Эх Гөлсинә, белсәң иде, мин сезне ничек сагынып кайттым!

С а й м ә. Әйдәле, кияү, әй лә, хе-хе, гафу, Альберт улым, уз әле, бер сөйләшеп, чөкердәшеп чәйләр эчик әле.

Г ө л с и н ә. Әни...

С а й м ә. Чукынмас, әйдәле...

Альберт чит ил шешәсе чыгара.

О-о, бусы нәмәрсә соң моның?

А л ь б е р т. А-а, бу виски исемле шунда.

С а й м ә. Биски. Һе, исеме дә бармыни әле. (*Гөлсинәгә.*) Бар, син, бар, чәеңне әзерлә.

А л ь б е р т. Йә, Саймә апа, ничек яшәп ятасыз? Нинди яңалыклар бар?

Г ө л с и н ә (*кухнядан атылып чыгып*). Бездә нинди яңалык булсын инде ул, синдәдер инде ул яңалык. Әллә нинди илләрдә булып кайткан кешедә...

А л ь б е р т. Анысы бар. Яңалыклар, кызыклар җитәрлек. Иркенләп сөйләргә кирәк, бүтән вакыт. Хәзер инде без гел бергә.

Саймә. Сагынгансыңдыр барыбер, әйеме?

Альберт. Сагындырмыйча. Туган якта (*Гөлсинә ягына ымлап*) шушындый кешеләрең калганда, ничек сагынмыйсың.

Саймә (*авыр сулап*). Шулай инде...

Альберт. Ә ул ничек матурайган. Саймә апа, ачулансагыз ачуланыгыз, сүксәгез сүгегез, Гөлсинәне бүтән үземнән калдырмыйм. Мал җитәрлек. Әле мин сезне, әле мин сезне, күмәм әле...

Саймә. Әй, Альберт улым, әй Аллам...

Ишектә кыңгырау тавышы.

Альберт. Кеше бар, Гөлсинә. Мактап йөри икән, кем булыр?

Гөлсинә. Барам.

Кәрим керә.

Кәрим. Менә мин дә. Тизме?

Гөлсинә (*үбеп*). Тиз, бәгъерем!

Саймә. Йа Ходаем.

Гөлсинә. Әйдә уз. Бездә кунак бар.

Кәрим. Бигрәк әйбәт. Күңеллерәк булыр. Мактап йөри, димәк. Исәнмесез. Кәрим.

Альберт. Приветик. Альберт.

Гөлсинә. Безнең күрше. Бик әйбәт егет. Беләсеңме, ул каян кайтты?

Кәрим. Чувашстаннанмы?

Гөлсинә (*көлеп*). Юк инде.

Альберт (*горурланып*). Африкадан. Өч ел.

Кәрим. О-о, гүзәл тропик илләр күреп кайткан икән алайса. Эх, ничек кызыгам мин сезгә.

Альберт. Әле сез яшь, булыр әле, тормыш бит ул...

Кәрим. Бирсен Ходай.

Гөлсинә. Ул безгә шундый бүләкләр алып кайткан. Менә! Шаккаткыч! Ул шулкадәр юмарт. Син әле аның белән дус булырсың.

Альберт. Дус булырсың дисең, Гөлсинә, ә иптәшең кем булуын әйтмисең?..

Гөлсинә. Исемен беләсең инде. Ә үзе ул минем ирем була, Альберт.

Альберт. Ирең? Ничек?

Г ө л с и н ә (*Кәримне кочаклап елмая*). Ирем, законлы ирем, Альберт, зинһар өчен, җүләр сорау бирә күрмә, яме...

А л ь б е р т (*аңышмыйча*). Ирең? Ничек? Мин аңлый алмыйм?!

К ә р и м. Ха-ха-ха! Бөтенләй аптырады кеше. Сезнең анда, Африкада, өйләнү дигән нәрсә бөтенләй юктыр, шуңадыр... ха-ха-ха... аңламый...

А л ь б е р т. Ах, ире... (*Нишләргә белми тора.*) Әйе шул, Африкада туйлар юк... юк шул...

К ә р и м (*күз яшьләрен сөртеп*). Һе, ярый, ярый, каушамагыз. Әйдәгез кухняга, хәзер без сезгә туй күрсәтәбез.

Г ө л с и н ә. Альберт, әйдә, чыннан да.

А л ь б е р т. Юк! (*Кисәк борылып чыгып китә.*)

К ә р и м. Һе-һе, бик кызык кеше. Туйны онытткан...

С а й м ә. Әй, тормасана чукынып, кеткелдәп!

Ут сүнә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Психолог кабинеты.

П с и х о л о г. Шулай итеп, сез кияүгә чыктыгыз һәм сезнең «беренче мәхәббәт» кайтып төште.

Г ө л с и н ә. Ничек диим... Алай ук түгел инде ул үзе... Ярәшелгән булганбызмы инде шунда... Юк, минем теләк белән түгел, формально... Ниндидер вазифа шикеллерәк...

П с и х о л о г. Сезнең баш әйләнгән чак... Һәм шул вакытта көтелмәгән удар...

Г ө л с и н ә. Юк, алай ук та түгел... ничек диим... Миңа озак вакытлар Кәримнән башка кеше күземә күренмәде дә...

П с и х о л о г. Беләсезме... Минемчә, сез шулай мавыккан вакытта, кисәк борылыш килеп чыгуның да сезгә бик көчле тәэсир ясавы мөмкин.

Г ө л с и н ә. Бардыр инде... Мин тынычлык таба алмыйм... Күңел тынычлыгы... Бар да әйбәт тә кебек... Бар әйберем дә бар...

П с и х о л о г. Катлаулы очрак... Өзелгән җеп күпме нечкә булса, шулкадәр ялгавы авыр. Ә сезнең очрак...

Г ө л с и н ә. Сез мине аңлап бетермисез. Бу әле башы гына...

П с и х о л о г. Юк, юк, минем сүзләргә игътибар итмәгез. Мин тыңлыйм.

Авансцена. Кич. Г ө л с и н ә белән А л ь б е р т күренә.

А л ь б е р т. Йә инде, ул кадәр кызулама.

Г ө л с и н ә. Болай да бик соңга калдым. Ашыгырга кирәк.

А л ь б е р т. Куркасыңмы?

Г ө л с и н ә. Нишләп куркыйм.

А л ь б е р т. Син инде болай да аңардан бозау ясап бетергәнсең...

Г ө л с и н ә. Бозау түгел ул.

А л ь б е р т. Түгел... Булмаса болай йөри алыр идеңме?

Г ө л с и н ә. Туйдыңмыни?

А л ь б е р т. Нигә алай дисең?

Г ө л с и н ә. Куасың бит.

А л ь б е р т. Юләрем. Ташлап китүеңә ачуым чыга. Тагын аның янына кайтасың.

Г ө л с и н ә. Тимә син аңа, калдыр аны, яме. Кайткан саен йөзне ертып алдашу туйдырды. Читен миңа болай.

А л ь б е р т. Туйдым диген инде.

Г ө л с и н ә. Бардыр инде.

А л ь б е р т. Әллә чынлап та.

Г ө л с и н ә. Бетерик без бу эшне.

А л ь б е р т. Мин сине берсекөнгә көтәм.

Г ө л с и н ә. Юк, Альберт, арыдым мин. Болай булдыра алмыйм. Ирекле булсам икән...

А л ь б е р т. Әйтерсең аңа мин гаепле...

Г ө л с и н ә. Үзем, барысына да үзем гаепле... Ярый, пока.

А л ь б е р т. Туктале, син нәрсә инде...

Г ө л с и н ә. Калдырып тор әле син мине... Бүтән килмим...

А л ь б е р т. Җүләрләнмә... син генә намуслы инде...

Г ө л с и н ә. Пока. (*Китә.*)

А л ь б е р т. Мин сине берсекөнгә көтәм.

Ут сүнә.

Гөлсинәләр бүлмәсе. Тышта шау-шу ишетелә. Бүлмәгә 4—5 яшьләрдә-ге бала күтәргән Кәрим килеп керә. Алар кышкы киемнән, карга батканнар, кызарынганнар, йөзләре шат, чыркылдашалар.

Кәрим. Менә кайтып та җиттек. Син бик көчле икән, кызый. Кирәкне бирдең!

Кыз көлә-көлә Кәримнең аягыннан кочып тарта башлый, ата кеше егылып киткән була. Алла, бирелә̀м, бирелә̀м. Бүтән сиңа карышмаска сүз бирәм...

Ләйсән. Эх эти, шул эш белән бакчага барасы булмасын иде ул, әйеме? Син дә арыйсың, мине әйткән дә юк инде... Без гел икәү уйнап кына йөрер идек...

Кәрим. Яшәргә акча да кирәк булып куя бит, кызым.

Ләйсән. Шул акчаны берәрсе гел безгә китереп торсын иде. Әй, әни алып кайтсын, син минем белән уйна гел.

Кәрим. Нигә гел минем белән генә, ә? Бергә-бергә диген.

Ләйсән. Әй, әни уйный белми ул. Болай әйбәт инде ул үзе, име, эти.

Кәрим. Кәнишне. Бик әйбәт бугай ул үзе. Синең кебек...

Ләйсән. Минем хәтле үк түгелдер инде анысы... Мин сиңа да охшаган, әнигә дә, әбигә дә, бабайга да, песигә дә... (*Көлешәләр.*)

Кәрим. Йә, бүген нишлибез инде без, дружок?

Ләйсән. Дружок түгел — кызым! Җайлы гына, менә әйт әле — кы-ы-зы-ы-ым!

Кәрим. Кызым!

Ләйсән. Вәт. Мине ат-ат итеп уйнатырсың, аннан... рәсем яса, аннан әкият укы, аннан (*шыпырт кына колагына*) камфит бирерсең инде, яме, эти, пажалысты...

Кәрим. Ха-ха-ха. Ну хитрый да инде үзең... Ярар, гафу итәрбез. Ә хәзер, үрә кат! Мине тыңла... Син марш бүлмәгә, уйнарга! Ә мин әниең кайтканчы кухняда берәр нәрсә әмәлли торам. Ясномы?

Ләйсән. Жасно, жасно! Тик озак түгел. Әти, мин уенчыклар алам да синең янга чыгам, яме? (*Әтисе карышмакчы була.*) Ну, пап, ну, уж син мине аңламыйсың да...

Кәрим. Ярар, ярар. Түлке акыллы булсаң гына...

Л ә й с ә н (*куанып*). Мин бик тә акыллы булам. Әти, әбием әзерләгәндер әле, нигә гел син, әйдә, уйныйбыз.

К ә р и м. Әбиең өйдә юк, кызым, Аллага шөкер.

Л ә й с ә н. Ә кайда?

К ә р и м. Кунакта.

Л ә й с ә н. Мине алмаган да, һе.

К ә р и м. Бакчага кем йөри аннары. Ул бит тиз кайтмый.

Л ә й с ә н. Ну уж, гел шул садик.

К ә р и м. Ярый, әйдә тизрәк эшкә керешик. Әниең кайтса, баштан сыйпамас. (*Чыгып китә.*)

Ут сүнә. Ут янганда, бүлмәгә Г ө л с и н ә кереп килә.

Г ө л с и н ә. А-у, өйдәме сез? Ау, дим? (*Сәхнә уртасында басып көтеп тора.*)

Л ә й с ә н (*йөгереп чыгып*). Әни, әни кайтты! Әти, әтием! Пап, пап, хатының кайтты.

К ә р и м. У-у, нинди кешеләр. Көттереп кенә йөриләр. Кая булдык диярсез микән бу юлы?

Г ө л с и н ә. Ой, ташлале шул... Берни сөйләшәсем килми... эт кебек арыдым. Өсне салырга булыш, ичмасам... Сагынып көтеп торалармы дисәң... Кая булдың...

К ә р и м. Ярар, ярар, бормаланма! (*Чишенергә булыша.*) Сиңа сүз әйтеп буламыни? Син бит безнең... Без генә ул, әйеме, кызым?

Л ә й с ә н. Без без инде ул, әти.

К ә р и м. Әниең аңламый шул безнең шундый икәнне.

Г ө л с и н ә. Әй, тормасана кан корытып...

К ә р и м. Кан корытып? Чылатып җибәрик алайса...

Г ө л с и н ә. Йә, кылтаймале...

К ә р и м. Кая булдың диләр сиңа? Сәгать уникенче, кызың йокламаган, сине көтеп утыра. Мин гаепле, җитмәсә...

Г ө л с и н ә. Туктыйсыңмы, юкмы? Уйнап йөрдем мәллә? Эшем муеннан. Юк-бар кешеләр белән эшләмим...

К ә р и м. Соң шуны әйбәтләп әйтеп булмый мәллә. Мин бит...

Г ө л с и н ә. Булды, җитте!

Л ә й с ә н. Талашмагыз әле, пажалысты. Көн саен, көн саен.

К ә р и м. Барыбер син дигәнчә кала инде, күпме талашсаң да...

Г ө л с и н ә. Йә, йә, бүлсәймә, әллә кая бармадым, җыелыш булды. Мине тагы күтәрергә тиешләр. Син генә ул...

К ә р и м. Әйттем мин сиңа, торгаш түгел мин дип, тыңламадың. Җенем сөйми шуны...

Г ө л с и н ә. Ни булды тагын?..

К ә р и м. Тагын азрак җитеп бетми.

Г ө л с и н ә (*башына сугып*). Менә монда җитеп бетмидер ул, анда түгел. Җәфа, җәфа булдың башыма...

К ә р и м. Үзең гаепле... тыңламадың сүземне... ярый, ташлале... җырып чыгармын... Чәй эчәсеңме?

Г ө л с и н ә. Әзермени?

К ә р и м. Так точно. (*Гөлсинәнең битеннән үбеп ала.*)

Г ө л с и н ә. Бу нәрсә инде тагын? Ничә тапкыр әйтергә була, селәгәеңне агызып, минем битемә кагылма дип! Ул артистлануыңның бер чиге булырмы, юкмы? Ансыз гына булмыйдыр...

К ә р и м. Мин бит...

Г ө л с и н ә. Син инде, син, бары да син. Әй кызым, бу атаң белән... (*Кыз дәшми.*) Йә, нәрсә карап каттың?

К ә р и м. Нәрсә диим? Ашарга әзер ханым-солтаным, үзегез керәсезме, күтәреп кертимме, әллә алып чыгып сыйлыймы?

Г ө л с и н ә. Җиттеме дим, юкмы? Күпме җанны ашарга була? Маймыл. Арып кайтасың...

К ә р и м.. Э-э-эх! Тырышасың, тырышасың яхшырак булсын дип... (*Кухняга китә.*)

Г ө л с и н ә. Яхшырак булсын өчен, яхшы итеп эшеңне эшләргә кирәк.

Л ә й с ә н (*ни эшләргә белми торганнан соң*). Әни! Без әти белән шундый итеп уйнадык. Карда тәгәрәдек. Әти Кыш бабай кебек, мин Кар кызы кебек ап-ак булдык. Әтинең борыны менә болай, кып-кызыл булды. (*Көлә, кухнядан чыккан әтисе дә, аңа кушылып, кызын сөеп китә.*)

Г ө л с и н ә. Каяле... Ай Аллам, баланы бетерә язган. Карга аунат инде... Каяле, маңгаеңны? Температура... Кай төшең авырта? Тагын минем башка бәла ясаган икән...

Л ә й с ә н. Бер төшем дә авыртмый, әни. Әйдә әти янына.

Г ө л с и н ә. Кара, монысы да мине өйрәтә. Бик остарсаң, почмакка бастырырга да күп сорамам...

Л ә й с ә н. Мин бүтән алай итмәм, бастырма, әни, пажалысты...

К ә р и м. Бар да әзер, әйдәгез өстәл янына...

Л ә й с ә н. Әти, утырт, утырт. (*Кәримнең җилкәсенә утыра.*)

Ут сүнә.

Психолог кабинеты яктыра.

П с и х о л о г. Мин болай, үзем өчен генә... Ничек дидегез әле... озак вакыт башка ир заты күзгә чалынмады дидегезме?

Г ө л с и н ә. Әйе.

П с и х о л о г. Ә аннан...

Г ө л с и н ә. Аннан, аннан...

Ут сүнә.

Йокы бүлмәсе яктыра. Г ө л с и н ә чишенә, йокларга әзерләнә. К ә р и м килеп керә. Сокланып карап тора.

К ә р и м. Бигрәк матур инде син. Чишенгәндә карап туя алмыйм.

Г ө л с и н ә. Шулаймыни? Кара, кара, карарга гына рөхсәт... Карале, ябышмале, дим...

К ә р и м. Сине шулай күрсәм, үземне тыя алмыйм. Тәнемдә каным кайнап, ташый башлый. (*Хатынын кысып коча.*)

Г ө л с и н ә (*көлеп*). Туктале, дим, ашыкма... Аякларыңны юдыңмы? Бөтен урын-җирне пычратып бетерәсең.

К ә р и м. Менә тагын, син өйрәткәннән бирле ул мөһим процедураны башкармый калганым бармы? Син нәрсә кисәк кенә? Йә инде, җаным, бәгърем...

Г ө л с и н ә. Ярый, ярый, мин бит каршы түгел, тик һәрнәрсәнең үз вакыты бар...

К ә р и м. Нәкъ менә вакыты инде...

Г ө л с и н ә. Арыгандыр дип тору юк...

К ә р и м (*пышылдап*). Ял иттерермен...

Г ө л с и н ә. Тукта инде! Минем белән сөйләшәсең дә килмиме?

К ә р и м. Килә матурым, килә. Ничек түзеп торыйм. Әнә бит син нинди...

Г ө л с и н ә (*көлеп, пышылдап*). Нинди?

К ә р и м (*тагын да авыр сулап*). Матур...

Г ө л с и н ә. Матур әйбер күп була инде ул... Барын да ботарларга димәгән...

К ә р и м. Әй, тагын... (*Кире борылып ята.*)

Пауза.

Г ө л с и н ә. Синең белән күптән ачыктан-ачык сөйләшәсе килеп йөри иде...

К ә р и м. Сөйләш соң...

Г ө л с и н ә. О-о! Нигә ул кадәр коры?

К ә р и м. Соң бит, Гөлсинә...

Г ө л с и н ә. Бүлдермә!

К ә р и м. Бүлдерсәң-бүлдермәсәң дә, сүзнең ни турында булачагын чамалыйм инде...

Г ө л с и н ә. Хәтта?! Бик кызык. Үсә башладың бит син, әй.

К ә р и м. Әйдә мыскылламыйча гына.

Г ө л с и н ә. Ник, чынлап. Үселде, үселде инде синең соңгы вакытта.

К ә р и м. Булды, дим.

Г ө л с и н ә. Ой, гафу итегез. Пордон, месье! Почмак саен рәсем ясап, агач юнып йөргәнче, институт бетер диюемнең файдасын күрәсең бит хәзер. Акыл керә башлаган бит сиңа... Үскәнсең син, үскәнсең...

К ә р и м. Җитте инде сиңа... Шундый матур мизгелнең тәмен бозасың. Һәрвакыт шул хәл. Матур гына да сөйләшеп була бит.

Г ө л с и н ә. Синең беләнме? Ничек итеп? Минем кем икәнлегемне, кайда эшләгәнемне аңлыйсыңмыни соң син? Сиңа матур сөйләшү... Сиңа менә әнә шул кирәк... бары шул... Ә-ә, син анысын бик яхшы беләсең...

К ә р и м. Оятсыз син. Мин бүтән мәгънәдә әйтәм. Бу бары тышкы як, физиология... Ә күңел...

Г ө л с и н ә. Бүтән мәгънә? Физиология? О-о, хомо сапенс... Мине дә узып китә башлагансың син, ә...

К ә р и м. Кая инде ул безгә... Ярый, күңел калсын ди шул килеш... белмим, мине түбәнсетеп сиңа ни файдадыр... Ә бит бары да чагыштырмача...

Г ө л с и н ә. Чагыштырмача?.. Азрак лаек булырга тырышырга кирәк.

К ә р и м. Кемгә?

Г ө л с и н ә. Мәсәлән, миңа.

К ә р и м. Шуңа кайтып калдымыни инде хәзер без-

нең бер-беребезгә булган мөнәсәбәт? Ә бит синең миннән күзеңне ала алмаган, кочагыма керүгә эрегән чакларың бар иде. Хәзер нишләптер...

Г ө л с и н ә. Тагын башлады... Яратам да диген инде...

К ә р и м. Эх Гөлсинә. Нәрсәсе начар аның?

Г ө л с и н ә. Әйтеп бетер. Ә синең андый чакларың юк идеме? Гомер бара... Тормыш диләр аны бәбкәччәем, әби әйтмешли. Бары да үзгәрә.

К ә р и м. Әйе, үзгәрә. (*Кызып китеп.*) Бар иде... Хәзер дә ул миндә юкка чыкмады. Шуңа масаясың да. Ни кылсаң да, мин сине гафу итәчәкмен. Һәм минем сиңа шулай бәйле булуым сиңа теләсә ничек кыланырга ирек бирә. Белеп торам, болай калдырырга ярамаганын да, шулай да... Чөнки, чөнки... Миңа синең янда булу үзе бер бәхет...

Г ө л с и н ә. Елап җибәрмә тагын. Һе, син мине гафу итәсең? Ха-ха-ха. Ә-ә, минем соңга калуларым...

К ә р и м. Юк инде... (*Гаҗизләнеп.*) Ярар, вакыты җиткәч, син дә берәр нәрсә аңларсың әле... Тик соң булыр.

Г ө л с и н ә. Нәрсә соң булыр?

К ә р и м. Мин сиңа сукмыйм, Гамил абзый әйтмешли, син үзең маңгаеңбелән минем йодрыкка килеп бәрелерсең.

Г ө л с и н ә. Тагын нәрсә? Һе-һе. Карале, сиңа кеше көлдерергә, артистлыкка китәргә кирәк булган... Көлдермә, зинһар өчен...

К ә р и м. Көл, көл.

Г ө л с и н ә. Җә, булды. Ну-ка, бөтен дөньяңны оныттырыйммы? Ха-ха-ха. (*Иркәли башлый.*) Оныта башладыңмы?.. Менә шулай... оныта башладыңмы, җанашым...

К ә р и м (*йомшап китә*). Җаным, бәгърем! Миңа ачуланма. Ни сөйләгәнемне дә белми башлыйм, дивана инде мин шулай...

Г ө л с и н ә. Күптән шулай диләр аны... Ату, мин дә мин... Йә, йә, булды, йә азынып китәрсең... җитте, дим бит инде... Юк, анысы... Тукта, дим. Менә нәрсә? Туйдырды бу уен миңа. Туры гына сөйләшик әле.

К ә р и м. Нишлисең... Сөйләшик...

Г ө л с и н ә. Син үзең барын да сизеп торам дисең...

К ә р и м. Шуннан?

Г ө л с и н ә. Шуннан шул... Сизеп торгач... Ну,

күрәсеңдер... безгә бергә яшәве авыр бит. Син мине аңламыйсың, тырышмыйсың да, бәлки тырышсаң да аңламассың.

Кәрим. Сиңа шулай тоела гына ул.

Гөлсинә. Туктале, бутамале. Минемчә, без тормышны башлаганда ук уйлап бетермәгәнбез. Без икебез ике дөньяда яши торган кешеләр. Минем үз әйләнәм, синең үзеңнеке. Мин этә-төртә институтка кертмәгән булсам, буяуга катып йөри идең бит.

Кәрим. Йөрсә соң. Син гел шул якны гына карадың да инде... Минем хыялым бар иде...

Гөлсинә. Хыял... Хыялый бит ул дурак дигән сүз...

Кәрим. Булсын. Дураклар да кирәк диләр бу дөньяга.

Гөлсинә. Ә-ә. Ә миңа нәрсәгә ул дурак? Нәрсә алып кайта ул миңа? Ә-ә, шул шул. Хыял. Искә төшермәле шул... Болай да почмак саен аунаган рәсемнәрең косасын китерә...

Кәрим. Ни булган?

Гөлсинә. Җитте, җитте, сөйләмә, күңелем болгана, фу... Картина Репина «Не ждали».

Кәрим. Ә көзге яңгырлы кичтә... Син бөтенләй башка идең... җаным шунда сиңа ябышып калгандай булды... Син дә бит миңа... йә әйт әле?

Гөлсинә. Бәлки... Күптән булган хәл бит инде.

Кәрим (*куанып*). Билгеле, син дә... Шулай булмаса — әниең, туганнарың сүзенә карамыйча ничек миңа чыктың.

Гөлсинә. Яшь чак, юләр чак.

Кәрим. Әйе, институт бетергән генә идең, яшь идең шул әле.

Гөлсинә. Уф, менә шул плоский шаяруларың да нервыма ярамый. Ничек мин сиңа түзеп яшим, шаккатам.

Кәрим. Әниеңә.

Гөлсинә. Нәрсә, әнигә?

Кәрим. Мин әниеңә дә түзәм әле.

Гөлсинә. Кагылма әнигә.

Кәрим. Бу юлы да аңлаша алмадык... Нишлисең... Барыбер без якын идек... Уйлале син шуны азрак... Хис турында. Минемчә, иң мөһиме — кеше җаны. Җаның сай булса, интеллигент булуның да, сәүдәгәр булуның да һәм башка бик күп булуларның бәясе — сукыр бер тиен!

Гөлсинә. Җитте! Туйдым. Тагын шул китап сүзлә-

реңне сөйләргә тотындың. Ничек туймыйсың?.. Бар, яшәп кара җан саклап.

Кәрим. Кычкыр, кычкыр, җиңеләеп китәрсең. Әмма шуны бел: җаның бушап калса, хисләр сүнеп бетсә, синең ише генә түгел, миллионер булсаң да, министр булсаң да — көннән-көн үзеңә көч киләчәк, тирә-якның салкын ваемсызлыгы һавасы суырып алынган буш вакуум шикелле җаныңны шытырдатып кысып китерәчәк.

Гөлсинә. Җитте! Минем җанымда синең эшең булмасын. Надоел! Ненавижу! (*Кәрим аны тынычландырмакчы була.*) Кит, дим, минем янымнан! Кагыласы булма!

Кәрим. Ярый, теләсәң нишлә. Мин кызым янына чыгам. Һәрнәрсәнең чиге була.

Ут сүнә.

Психолог кабинеты яктыра.

Психолог. Тик булмас кайтарып яшьлекне,—
Язмышны беркем дә боралмый...

Гөлсинә. Сез ни турында, доктор?

Психолог. Юк, юк, уйланам гына...

Гөлсинә. Зинһар, доктор, калдырмагыз гына, мин барына да риза...

Психолог. Ничек диим, ул кешенең кайтуы сезгә комачау ясамадымы?

Гөлсинә. Ничек инде? Юк, юк, алай әшәкелек эшләмәде. Хәер, алай дип бетереп әйтеп тә булмый.

Психолог. Бәлки, бөтен сәбәбе шунда ук ятадыр? Бәлки, сез аны ныграк ошаткан булгансыздыр...

Гөлсинә. Ныграк дисезме? Белмим, доктор, нәрсә дияргә дә белмим...

Психолог. Ә сез дәвам итеп карагыз... Тагын берәр шундый сезгә тәэсир итәрдәй вакыйга булмадымы? Йә, мин сезне тыңлыйм...

Шул ук бүлмә. Караватта Альберт йоклап ята. Кухнядан Гөлсинә чыга.

Гөлсинә. Тор, тор аю. Сеньор, торыгыз.

Альберт. Уф, бәйләнмәле.

Гөлсинә (*аны иркәләп*). Торырга кирәк. Озак ятарга ярамый.

Альберт. Фу, төнлә дә йоклап булмады, иртән дә

ирек бирмиләр. Нәрсә соң бу? Кайда соң монда сервис? Сизмим.

Гөлсинә. Ох-ох, күнеккән берәүләр югары сервиска. Ох-ох... Әле кай арада кеше рәтенә чыктыгыз соң сез, иптәш...

Альберт. Без күптән инде. Мине анда беләләр.

Гөлсинә. Шулаймыни. Ә-ә, ярый инде безгә...

Альберт. Кәрим белән дә...

Гөлсинә. Альберт, син инде...

Альберт. Шаярам.

Гөлсинә. Чынлап, торырга кирәк. Кайтып җитүе бар.

Альберт. Кем?!

Гөлсинә. Әни-и.

Альберт. Ә-ә. Ирең мәллә дип торам.

Гөлсинә. Юк. Әйттем бит инде, ул тиз генә кайтмый. Әйдә, тор.

Альберт. Биш кенә минут. (*Капланып ята. Гөлсинә аны кытыклый.*) Ярар инде... Саймә апа белән безнең дуслык бар, бер дә борчылма.

Гөлсинә. Кара, кара... Йә инде, барыбер яхшы түгел.

Альберт. Ярый. Менә хәзер урында гына кофе эчеп алам да торам...

Гөлсинә. Нинди кофе?

Альберт (*үбеп*). Син китергән.

Гөлсинә. Өстәлдә.

Альберт. Монда китер.

Гөлсинә. Хәзер менә, йөгердем. Оста. Бик әйбәтләп торып эчәрсең.

Альберт. Ә мин әйтәм, ятып... Коньяк белән, җитмәсә!

Гөлсинә. Нәфес синдә... Нахал...

Альберт. Алайса, авырсынмасагыз, минем сумканы гына алып биргез әле, зинһар өчен, үтенеп сорыйм. (*Аягыннан үбеп ала.*)

Гөлсинә. Болай сорагач... (*Сумканы бирә.*)

Альберт (*бер бәләкәй тартма алып*). Туташ, ачыгыз әле шул тартманы, әгәр сезгә авыр булмаса, ату минем хәлем җитми.

Гөлсинә (*тартманы ачып*). Ах! Бу нәрсә?

Альберт. Беренчедән, бу сиңа. Икенчедән — бу йөзек.

Г ө л с и н ә. Бриллиант. Чынмы?

А л ь б е р т. Син мине кемгә саныйсың?!

Г ө л с и н ә. Гафу ит. Ой Альберт, бу бик зур бүләк бит. Мин мондый әйбергә лаек та түгелмендер...

А л ь б е р т (*пышылдап*). Булмасаң, булырсың, бары да алда...

Г ө л с и н ә. Ой рәхмәт... (*Үбеп ала.*) Миңа мондый бүләк биргән кеше дә юк әле...

А л ь б е р т. Ирең соң?

Г ө л с и н ә. Эке, көт аннан. Гомеремдә бер тапкыр бүләк бирде, анысы да сыңар роза.

А л ь б е р т. Ә кофе мәсьәләсе ничек анда?

Г ө л с и н ә. Кофе? Ә-ә, ко-о-фе! Хәзер, хәзер, мин аны бик тиз генә. Коньяк беләнме?

А л ь б е р т. Коньяк белән? Ярар инде, алай бик кыстагач.

Г ө л с и н ә. Әлбәттә! (*Үбеп китә.*) Хәйләкәр төлке...

А л ь б е р т. Эшем шул.

Гөлсинә поднос белән кофе чыгара.

Менә бит, тырышкач була.

Г ө л с и н ә. Синең өчен инде. Үләргә дә була.

А л ь б е р т. Эх тәмле. Булдыргансың. Гомумән, син гаҗәеп кеше! (*Колагына нидер пышылдый.*)

Г ө л с и н ә. Оятсыз! (*Иркәләп кенә суга.*)

А л ь б е р т. Ә ирең белән хәлләр ничек инде сезнең?

Г ө л с и н ә. Ну, Альберт, ничә тапкыр кабатларга була, җитте. Искә төшермә шуны.

А л ь б е р т. Шулай да?

Г ө л с и н ә. Йә инде...

А л ь б е р т. Юк, мин бернинди әшәкелексез. Бик кызык бит. Мине ташлап кияүгә чыгарлык булгач. Башыма сыеп бетми, бары шул.

Г ө л с и н ә. Ярар инде, Альберт. (*Иркәләп.*) Булган булган инде. Яшь чак, ялгышканмындыр...

А л ь б е р т. Ялгышсаң да, аңлый алмыйм. Нигә? Нигә аңа? Мин бит сиңа бөтен дөньяны бүләк итәм, ни теләсәң, шуны алып бирәм дип киткән идем. Ә син... Мине бары шул гына борчый, әллә ни түгел... Шулай да менә алдашмый гына әйт әле: ничек хәзер сезнең мөгамәләгез?

Г ө л с и н ә. Хәзерме, элекме?

А л ь б е р т. Хәзер дә, элек тә. Тик, зинһар, алдама...

Г ө л с и н ә. Ярый алайса, тотынып утыр. Чын күңелдән әйткәндә, теге вакытларда мин аның янында булганда бөтенләй шаша идем. Әйе, әйе, туры мәгънәсендә. Калдырыйк әле, яхшы түгел...

А л ь б е р т. Юк, юк, әйтеп бетер. Ә хәзер?

Г ө л с и н ә. Ә хәзер? Хәзер бүтәнчәрәк... Дөрес, үзе ул минем өчен үлеп тора, мин дә дошман түгел... Әйтәм бит, эш анда гына түгел...

А л ь б е р т. Ә нәрсәдә?

Г ө л с и н ә. Торырга кирәк, менә нәрсәдә! (*Юрганын йолкып ата.*) Тор әле, тор әле...

А л ь б е р т. Читкә борма. Эш нәрсәдә инде?

Г ө л с и н ә. Беләсеңме, ул уңмаган. Гап-гади — неудачник! Мин инде аны укытып та карадым, эшкә дә урнаштырдым, кыстап та карадым, сөеп тә, өскә үрмәләсен дип, юк.

А л ь б е р т. Хм-м.

Г ө л с и н ә. Бервакыт чак кына эшеннән үк... Әй, нәрсә сөйләп торырга. Ул — уңмаган. Неудачник. Ә неудачникларны, үзең беләсең, хатын-кызлар яратмыйлар. Ә мин кем?

А л ь б е р т. Ха-ха-ты-ын кы-ыз!

Г ө л с и н ә. Дө-өрес. Шуңа да миңа чын ир кирәк.

А л ь б е р т. Ә бәлки, аңа башка шөгыль кирәктер?

Г ө л с и н ә. Юк инде, юк. Килде-китте рәсемнәреннән дә туйган. Әй, калдыр әле шуны.

А л ь б е р т. Шулай итеп, син мине «удачник» булганым өчен генә үзеңә якынайттың, яратканга түгел?

Г ө л с и н ә. Альберт, син нәрсә инде?!

А л ь б е р т. Ә бит Кәрим карап торырга килде-китте ир түгел. Хм-м.

Г ө л с и н ә. Туктат инде. Минем башны да бутап бетердең... Ул һәм син — җир белән күк арасы. Син син инде ул, ә ул?.. (*Ишектә кыңгырау тавышы.*) Әни кайтты. Тор тизрәк. Мин ачмый торам. Киен. (*Альберт тиз генә торып киенә.*) Хәзер, хәзер, кем анда... Кач ванныйга. Ә-ә, әни синмени...

Саймә керә.

С а й м ә. Басам, басам, әллә үлеп беткәннәрме дип торам. Син нәрсә, чукракландыңмы әллә? Ходаем, шушы вакытка тиклем йоклап ятасыңмы? Күпме ишек төбе саклатты...

Уянып, Л ә й с ә н чыга.

А л ь б е р т (*чыгып*). Исәнмесез, Саймә апа.

С а й м ә (*бөтенләй үзгәреп*). Ә-ә, син дә биредәмени, Альберт. Исәнме-саумы.

А л ь б е р т. Әйбәт кенә әле, Саймә апа.

С а й м ә. Кай арада килеп җиттең иртә таңнан, берәр яры җыендыгыз мәллә?

Л ә й с ә н. Альберт абый иртүк килмәде, ул төнлә белән үк килде. Вот. Син әби берни дә белмисең икән...

Г ө л с и н ә. Бар әле, бар, кая чыктың, ят урыныңа... Ни сөйлисең син булмаганны... (*Алып кереп китә.*)

А л ь б е р т. Берни дә аңламадым.

Г ө л с и н ә (*чыгып*). Кара син аны, молокосос.

С а й м ә. Һе-һе, ни сөйләгәнен дә белми әле ул, ачуланмагыз аны. Бала бит әле... Һе-хе, шулай кызыклары булып куя инде аның. Сез яшьләр, үзегез беләсездер, безгә карамагыз... Безгә ни, шул кунактан кунакка, чәйләр эчеп...

А л ь б е р т. Индийский.

С а й м ә. Эләксә.

А л ь б е р т. Эләгер. (*Колагына пышылдый.*) Үзем.

С а й м ә. Ай рәхмәт.

Г ө л с и н ә. Нәрсә серләшәләр болар, ә?

А л ь б е р т. Үзебез беләбез.

Г ө л с и н ә. Серләр килешә сезнең.

С а й м ә. Ничек кенә килештерер идек әле. Эх, киявем генә була алмады. Синең аркаңда. Күпме әйттем, күпме тукыдым.

А л ь б е р т. Гөлсинәне дә гаепләп бетереп булмый инде.

С а й м ә. Тыңламады, тыңламады чукынып, үз башына. Әнә хәзер азаплана шул имгәк белән. Ни эше, ни акчасы, ни... Эх, үзең кияү була алмадың. Улым шикелле күрә идем...

А л ь б е р т. Бәлки, соң да түгелдер әле.

С а й м ә. Сиңа, синең кебек егеткә беркайчан да соң түгел.

А л ь б е р т. Ярый, Саймә апа, мин китим инде.

С а й м ә. Менә сиңа кирәксә, китәсең дәмени? Тәмләп чәй дә эчмәдек бит әле. Юк, юк, әйдәле...

Г ө л с и н ә. Юк, әни, ул ашыга.

С а й м ә. Ә син кысылма. Башың яшь әле...

А л ь б е р т. Ачуланмагыз, Саймә апа, чыннан да ашыгам. Бер бәләкәй йомыш белән генә кергән идем.

С а й м ә. Ярый алайса, озакка югалма.Ату югалдың. Теге мөртәткә игътибар итмә, курыкма бер дә... Мин аны... Ходаем, таракан булып керде инде безнең дөньяга... Гөлсинә әйтмәдеме?

Г ө л с и н ә. Нәрсәне?

С а й м ә. Әйтер ул. Шимбә көнне бездә бәләкәй генә мәҗлес була, кил.

А л ь б е р т. Нинди мәҗлес?

Г ө л с и н ә. Әй, чүп... Мине азрак күтәргән иделәр, шуңа.

А л ь б е р т. Әйтми, Саймә апа. Менә нәрсә дисең инде моны? Хөрмәт итми, димәк.

С а й м ә. Итәр, итәр. Итмәм мин аңа. Ярый, кил, яме, вакытың булса.

А л ь б е р т. Һичшиксез, киләм. Теге әйбер дә булыр, олавы белән. (*Чыгып китә.*)

С а й м ә (*Гөлсинәгә ябыша*). Син нәрсә? Килеп керү белән Альберт бар дип әйтә белмисең мәллә? Оятка калдыра яздың шундый кеше алдында.

Г ө л с и н ә. Кем уйлаган сине бакыра башлар дип.

С а й м ә. Анаңны беренче күрәсең мәллә?

Г ө л с и н ә. Анысы бар инде.

С а й м ә. Нәрсә?

Г ө л с и н ә. Юк, үз шөгылеңне яхшы беләсең диюем.

С а й м ә. Нинди шөгыль тагын?

Г ө л с и н ә. Кычкыруыңны.

С а й м ә. Кычкырырмын мин сиңа! Йа Хода, урынын да җыймаган, өйләгә кадәр йоклап яталар.

Л ә й с ә н чыга.

Л ә й с ә н. Әби, ну җитте инде, пажалысты, кычкырышмагыз. Көн дә талаш, көн дә кычкырыш, прям как дети.

С а й м ә. Ах, эт кызы, сиңа нәрсә калган? Кара син аның кысылып торуын. Бет. Кычкырышмагыз, имеш. Атаң сыңары, атаң калдыгы. Атаңа охшамасаң, бераз юнең булыр иде синең, хөрәсән. (*Ләйсәнгә суга. Ләйсән елый.*)

Г ө л с и н ә. Җитте инде, әни, тимә балага. Ул сиңа уенчык түгел, дәшмәгәч тә!

С а й м ә. Җыештырыгыз урыннарыгызны! (*Урыннарны таратып ташлый.*)

Ут сүнә.

Психолог кабинеты яктыра.

Психолог. Сагынырсың әле син дә бер,—
Иңгәчтен йөзеңә күзләрең...

Гөлсинә. Әйе, доктор, әйе...

Психолог. Юк, уйланам гына. Ничек диим, сез хәзер тынычлык таба алмыйсыз, нидер җитми кебек? (Сәхнәне кисеп үтә.) Олы юлның тузанын ла...

Гөлсинәләр фатиры яктыра. Анда әле генә шау-шулы мәҗлес үткән, кунаклар таралган. Өстәл янында Гөлсинә, Кәрим, Альберт утыралар. Саймә кухня белән ике арада йөри. Кәрим шактый исергән, башы күкрәгенә салына башлаган.

Гөлсинә. Менә үзебез генә дә калдык... Уф...

Альберт (*Кәрим ягына ымлап*). Үзебез генә түгел шул...

Гөлсинә. Аның шул булыр инде. Соңгы вакытта бигрәк тә...

Кәрим (*башын күтәреп, җырлап җибәрә*). Олы юлның тузанын ла...

Саймә (*кухнядан чыгып*). Башлады инде... Сәгате җитте. Акырма шулкадәр.

Альберт. Да җырласын инде. Күңелен бушатсын. Әйеме, баҗай?

Кәрим. Ниткән баҗай? М-м?

Альберт. Ю-у-ук, болай гына. Ә чынына килгәндә, бу дөньяда без ирләр барыбыз да бер-беребезгә баҗайлардыр да әле. Ха-ха-ха!

Кәрим. Кемнән көләсең?

Альберт. Да үземнән көләм, үземнән. Җырла, җырла син...

Гөлсинә. Котыртма инде шуны, болай да...

Альберт. Котырсын. Мине дә заманында бик шәп итеп котырткан иделәр.

Кәрим. Дөрес, туган, котырсын. Тыңлама хатын-кыз сүзен.

Альберт. Бер дә курыкма, маймыл кебек котыр. Ха-ха-ха. Африка.

Кәрим (*көчкә торып басып*). Африка? Ә-ә, Африка! Син бит әле — Африка. Ну көлдереп үтерә яздың бит син мине, Африка. Өйләнүнең ни икәнен белми. Африка.

Альберт. Инде мин тырыша торгач өйрәндем. Менә син онытып барасың бугай, шулаймы?

К ә р и м. Ә-ә! Ну да, шулай бугай. Хәзер мин — Африка. Ха-ха-ха.

Г ө л с и н ә. Альберт, тукта, алай кирәкми. Тимә аңа.

А л ь б е р т. Мин тиям? Күр, киресенчә, аның үзенә күңеллерәк.

К ә р и м. Бик тә... (*Шапылдап утыра да җырлый башлый.*)

Олы юлның тузанын ла...
Үзем күрдем тузганын шул...
Белми калдым, сизми калдым,
Яшь гомернең узганын...

Г ө л с и н ә. Кәрим, җитте инде, тынычлан, зинһар...

К ә р и м. Кит әле, бар моннан...

С а й м ә. Башлана... Әй Ходаем, бу кадәрләр дә бирсә бирә икән кешегә...

К ә р и м. Әби! Шып-шугы!

С а й м ә. Нәрсә? Нәрсә дидең?

К ә р и м. Курыкма... Марича гына ул... Күп шаулама дигән сүз.

А л ь б е р т. Ха-ха-ха. Шып-шугы. Һе-һе. Көлдермә, зинһар, артист...

К ә р и м. Көл, көл, сиңа көләргә кирәк, сиңа көлү килешә... «Кайда микән яшь чагым, дип...»

С а й м ә. Җитте, диләр! Күршеләр йоклый. Үкереп утыра монда. Үз өендәмени.

Г ө л с и н ә. Кәрим, булды, дуракланма.

К ә р и м. Ә? Нәчтә дисең? Ишетмим!

Г ө л с и н ә (*Кәримнең колак төбенә тастымал белән кундырып*). Җитте сиңа!..

А л ь б е р т. Чү, чү, Гөлсинә, син нәрсә? Берни дә эшләмәде бит әле ул, чү.

С а й м ә. Шуннан китә инде аның кияү, әй лә, Альберт. Безне генә мыскылларга булсын...

К ә р и м (*көчле тавыш белән*).

Кайда микән яшь чагым, дип,
Шул юллардан эзләдем...

Г ө л с и н ә. Акырма, Кәрим, зинһар өчен...

С а й м ә. Гел шулай исереп акая...

К ә р и м. Алдашма, бабулька, булька, буль-буль... Гомеремдә беренче тапкыр дияргә була. У-у, ничек матур карый, сытып үтерер иде, хәленнән килсә. Беренче тап-

кыр, кызганычка каршы. Болай йөрсәм, сез мине инде әллә кайчан, тегендә үк.

А л ь б е р т. Ярар, булды бугай, Кәрим...

К ә р и м. Эх, белмисең, аңламыйсың монда яшәүләрнең ничек рәхәт икәнен. (*Аның җилкәсенә кулын салып.*) Беләсеңме, мин бит монда беркем дә түгел. Мин монда — бушлык, артык кашык. Бу йорт өчен мин үлсәм, мең мәртәбә файдалырак.

С а й м ә. Оятсыз, ни сөйли бит. Әле сине үтергәнче. Мине картаймас борын кабергә тыгасың әле син. Артык кашык, имеш. Умырганда бер дә артык дип тормыйсың, чамасын белми тыгасың... Ашау өчен туган нәмәрсә, үгез...

К ә р и м. Менә, менә, Альберт... баҗа диденңме әле.

А л ь б е р т. Карале, нигә алайса син алай интегәсең. Азапланма, төкер син аларга. Чукынсыннар.

К ә р и м. Шулай дисеңме?

А л ь б е р т. Шулай дим. Аларга да...

Г ө л с и н ә. Альберт...

К ә р и м. Булмый шул алай җиңел генә, булмый. Ә син, беләсеңме, син, беләсеңме, минем кызым нинди әйбәт! Ул, ул... ул, ул инде ул!

А л ь б е р т. Беләм, беләм.

К ә р и м. Белсәң — менә шул шул.

Г ө л с и н ә (*ягымлырак тонга күчеп*). Кәрим, матурым, яле, әйдәле, кереп ятыйк әле.

К ә р и м. Ә-ә, гөлкәем, синмени әле бу. Менә баҗа (*Гөлсинәне кочаклап*), хатын да әйбәт минем, чукынмыш. Үзе матур да... ничек аңа тыныч кына карыйсың ди...

Г ө л с и н ә. Фу, җүләрләнмә әле...

К ә р и м. Кит моннан.

А л ь б е р т. Хатын да әйбәт, әбиең дә... Что-то син үзең ниерәк бугай.

К ә р и м. Эй, торма әле, үзең син ниерәк.

А л ь б е р т. Но, но.

С а й м ә. Әле ул сиңа да җитешә... Әле...

К ә р и м. Әби! Әй, гафу, Саймә апа, маричага күчтермә әле, укшытасың, бар әле...

С а й м ә. Нәрсә? Шакшы тәре! Без алып кайтып чистартмасак, кеше арасында йөрерлегең дә юк иде бит синең. Карале, мөртәт, нәрсә ди бит.

Г ө л с и н ә. Җитте, Кәрим, минем сабырлыкны сынама.

К ә р и м. Нәрсә җитте? Нигә гел миңа җитә ул, сезгә түгел! Нигә мин бер дә чыгырдан чыкмыйм? Ә-ә-ә, шул шул...

С а й м ә. Чыгырдан чыкмакчы була тагын. Хәерче тәресе! Син дуңгыз баласына алма кебек кызымны бирдем.

К ә р и м. Бирмәдең, алдым. Зур аерма.

С а й м ә. Бер дигән гринадурдай егетләр артында калды. Сихерләп бәхетсез иттең. Бер рәхәт яшәткәнең юк. Коры сөяккә калдырдың!

К ә р и м. Коры сөяк. Һе-һе.

С а й м ә. Ыржайма. Тагын монда чыгырдан чыкмакчы була. Чыгармын мин синә. Өтермәндә яшибезмени, тормыш тормыш түгел... Алма кебек кызымны...

К ә р и м. Нәрсә? Алма кебек «кызыңны»? Алма кебек кыз. Тавыкларга сөйләгез, яме. Ярый, мин дуңгыз, ди. Беләсеңме, мин алмасам, синең кызыңа борылып та караучы юк иде бит. Мин коткардым аны гайбәттән, мин. Чөнки ул минем өчен...

Г ө л с и н ә. Кәрим, җитте...

А л ь б е р т. Ник алмаслар икән мондый чибәрне?

К ә р и м. Сиңа кирәк что ли? Рәхим ит.

Г ө л с и н ә. Кәрим, оял азрак.

К ә р и м. Миңа оялырга? Сезгә кирәк ул азрак булса да оялырга. Булды. Чыгырдан чыгар чак җитте.

С а й м ә. Син туганда ук чыгырдан ычкынган инде.

К ә р и м. Ычкынса. Беләсең килсә, кызың теге вакытта ук инде... Йөрдең шунда, әллә ниткән министр тещасы булырдай булып... Беркемгә кирәге юк иде...

Г ө л с и н ә. Оятсыз, ни сөйли.

С а й м ә. Аның ояты качкан инде.

А л ь б е р т. Әй син, бераз чамалап...

К ә р и м. Өркетмә мине. Андый туннар тузган инде... Эх, Гөлсинә. Күпме җанымны багышладым мин сиңа. Бернәрсәмне җәлләмәдем. Бары бөтен барлыгым белән синеке генә буласым килде. Ни дисәң дә, риза булырга тырыштым. Аңлый алмадың мине...

С а й м ә. Кузгалды... Саескан сайравы...

К ә р и м. Шып-шугы! Ә сиңа, теща, бөтен яклап ярарга тырыштым. Дурак мин! Сүз дә юк, дөрес әйтәсез. Дурак булганмын, хәзер аңладым...

С а й м ә. Дурактан сорама, тора-бара үзе әйтер... Шулай икән шул.

Г ө л с и н ә (*ычкынып*). Бирдең? Син, син пешмәгән аркасында шушы көнгә калдым мин. Күпме гомер син тинтәк белән бушка узды бит! Җан, җан, дип, бәгырь итемне ашадың. Нишлим мин синең ул җаның белән. Нәрсәгә салып кыздырыйм. Уңмаган! Ни эшең, ни үзең, йөрисең шунда сөйрәлеп. Нәрсә алып кайтып биргәнең булды? Ул акчаң нәрсәгә җитә? Нинди бүләк алдың миңа?

К ә р и м. Мин үзем сиңа бүләк, тагын нинди бүләк кирәк сиңа?

С а й м ә. Оялмый да.

Г ө л с и н ә. Бүләк. Муеныма кара таш, менә нинди бүләк син миңа. Үз гомереңдә бер биргән чәчәгең дә сыңар гына иде бит, акча җәлләп.

К ә р и м. Җүләр син.

Г ө л с и н ә. Әнә ул миңа беркем дә түгел дияргә була. Ә аның миңа бүләк итмәгән нәрсәсе калмады.

К ә р и м. Кем нәрсә бүләк итә бит. Кем юк-барны, чүп-чарны, кем иң бөеген, иң кадерлесен...

С а й м ә. Иң кадерлесен. Хәерче мин, булдыра алмыйм дими... Син андый әйберләрне үлгәндә дә ала алмыйсың, хөрәсән...

А л ь б е р т. Йә, мине калдырып торыгыз әле...

Г ө л с и н ә. Пешмәгән тек пешмәгән инде. Каян минем юлыма очрап тордың. Язмышың шундый бәхетсез булгач...

К ә р и м. Язмыш инде, язмыш...

Г ө л с и н ә. Котыртып торма, эт җан, чукынып кына китсәң ярар иде...

С а й м ә. Кешене тәки сабырыннан чыгарды. У-у! Югал күз алдымнан. Безнең өйне пычратудан башканы белмисең. Өең дә юк бит синең, килмешәк. Берәү булса, әллә кайчан фатир алган булыр иде инде.

Г ө л с и н ә. Алыр, аңа тагын. Безне талый гына белә бит ул, эшли белми.

К ә р и м (*кычкырып*). Җитте! Туктагыз!

С а й м ә. Башланды! Белая горячка! Кычкырма, мин сине кая озатырга белермен!

К ә р и м. Җитте. Туктамасагыз, үтерәм.

С а й м ә. Үтерә, үтерәчәк бу.

Г ө л с и н ә. Рәхмәтең шулдыр.

А л ь б е р т. Җитте, чибәр егет, артыкка китте.

К э р и м. Кит моннан, сине дә бетерәм!

А л ь б е р т. Нәрсә? Яле кабатлале. (*Кәримгә килә. Кәрим аны сугып ега. Ләйсән йокысыннан торып чыгып, аларны карап тора.*)

К э р и м. Китегез!

С а й м ә. Куа да башлады. Хуҗа.

Саймә белән Гөлсинә Кәримнең кулларына ябышалар.

Г ө л с и н ә. Китәрбез менә. Без сине хәзер...

Альберт торып, Кәримнең эченә тибә. Кәрим бөгелеп төшә. Л ә й с ә н йөгереп чыга.

Л ә й с ә н. Ә-ә-ти-и! Сугышмагыз, сугышмагыз! Прошу...

Альберт Кәримне типкәли.

А л ь б е р т. Кара син аны, миңа кычкыра.

Л ә й с ә н. Әти! Тимәгез әтигә! Тимәгез, тимә. (*Барып Альбертка ябыша.*)

А л ь б е р т. Әй, бар, йөрмә әле аяк астында. (*Ләйсәнне аягы белән этеп җибәрә. Ләйсән егыла, ярсып елый.*)

Л ә й с ә н. Әти-и-и!

Г ө л с и н ә. Кызым.

Ут сүнә. П с и х о л о г сәхнә аркылы үтә.

П с и х о л о г. Кайда микән яшь чагым, дип,
Шул юллардан эзләдем.

Авансцена. Л ә й с ә н н е иңнәренә утырткан К ә р и м керә.

К э р и м. Йә җылама инде, кич белән кайтасың бит.

Л ә й с ә н. Садикка барасым килми. Әти, кич белән син аласыңмы мине? (*Кәрим дәшми.*) Пап, дим, син аласыңмы садиктан?

К э р и м. Белмим әле, мин бүген бик соңга калырмын.

Л ә й с ә н. Юк, бүген син ал, яме?! Бүген синең белән генә кайтасым килә. (*Кәрим дәшми.*) Пап, дим, ну инде... Бүген әллә нинди көн, име? Минем сине беркая да җибәрәсем килми... (*Синяк күреп.*) Авыртамы, пап?

К э р и м. Юк, кызым, юк, авыртмый.

Л ә й с ә н. Хәзер тазартам мин аны. Өф! Ө-ө-ф! Беттеме?

К ә р и м. Бетте. Ярый, кызым, әйдә тизрәк булыйк, соңга калабыз.

Л ә й с ә н. Мин сине бик-бик көтеп калам. (*Чыгып китәләр.*)

Шул ук бүлмә. Бүлмәдә К ә р и м үзе генә. Уртада бер чемодан тора. Г ө л с и н ә кайтып керә.

Г ө л с и н ә. Ай-яй, салкын тышта. Син кайттыңдамыни инде? (*Кәрим дәшми.*) Ник эндәшмисең? Ә? Ни булды тагын?

К ә р и м. Мин китәм...

Г ө л с и н ә. Кая? Командировкага мәллә?

К ә р и м. Юк, бөтенләйгә. (*Пауза.*)

Г ө л с и н ә. Минем белән сөйләшмәдең дә...

К ә р и м. Нәрсәсен сөйләшеп торасың тагын... Куанычыңны гына тышка чыгара күрмә.

Г ө л с и н ә. Нинди булмаган сүз сөйлисең, нишләп куаныйм ди.

Пауза.

К ә р и м. Кызны садиктан алмадым, белми калсын, җылар...

Г ө л с и н ә. Тукта әле.

К ә р и м. Ачкыч өстәлдә, чәй кайнаган... Тагын нәрсә?

Пауза.

Г ө л с и н ә. Син миңа ачуланма... теге көнге өчен... Син үзең гаепле...

К ә р и м. Үзем. Кирәкми. Исерелгән... Милициягә барып җавап биреп кайттым, борчылмагыз...

Г ө л с и н ә. Ни дип?

К ә р и м. Тынычлыкта калдырам, курыкмасыннар дип.

Г ө л с и н ә. Әнигә дә үпкәләмә. Үзең бит, сезне үтерәм үк дия башладың.

К ә р и м. Үзем, үзем... барысына да...

Пауза.

Г ө л с и н ә. Үзең күреп торасың, безнең бергә яшәүнең мәгънәсе юк.

К ә р и м. Кирәк түгел...

Г ө л с и н ә. Син әле үзеңә тиң яр табарсың... Миңа үпкәләмә...

К ә р и м. Кирәкми, дим... (*Пауза.*) Әгәр мин баланы соңрак алам дисәм?

Г ө л с и н ә. Юк! Ул турыда авызыңны да ачма...

К ә р и м. Ярый, күп сүз — чүп сүз...

Г ө л с и н ә. Килеп чыккала...

К ә р и м. Һе. (*Пауза.*) Китим әле мин. Сагынырсың әле син дә бер...

Җыр яңгырый. Кәрим чыгып китә. Гөлсинә ни эшләргә белми басып кала.

(*Җыр.*)

Сагынырсың әле син дә бер,
Искә төшәр юләр яшьлегең...
Йөгереп килеп кочкан иттереп,
Күрсәтер йокыңда төшләрең.

Сагынырсың әле син дә бер,
Иңгәчтен йөзеңә күзләрең.
Сагыштан агарган чәчләрем
Күзеңнән китерер яшьләрең...

Сагынырсың әле син дә бер,
Тере җан сагынмый торалмый...
Тик булмас кайтарып яшьлекне,
Язмышны беркем дә боралмый...

Ут сүнә.
Яңадан шул ук бүлмә яктыра. С а й м ә белән А л ь б е р т каядыр китәргә җыенып йөриләр. Г ө л с и н ә булыша, әзерли.

Г ө л с и н ә. Йә, булдыгызмы инде, юкмы? Күпме җыенырга була. Китсәгез китә алмадыгыз, төш вакыты җитә бит инде...

С а й м ә. Хәзер, хәзер. Кияү, син әзерме?

А л ь б е р т. Мин күптән инде.

С а й м ә. Уңган да инде... (*Сөеп ала.*) Бар яктан да килгән.

Г ө л с и н ә. Артык мактама, йә азынып китәр.

А л ь б е р т. Кызый, әни белән безнең араны бутама. (*Үбеп ала.*)

Г ө л с и н ә. Әйттем бит инде яратмыйм дип.

А л ь б е р т. Минеме?

Г ө л с и н ә. Юк инде, лач-лоч үбешкәнне.

С а й м ә. Иртә таңнан карахтерыңны күрсәтә башлама, яме. Кияү син дип үлеп тора.

Г ө л с и н ә. Ярар. (*Уенга бора.*) Әйдә, күп сөйләшмәгез, әзер булсагыз, марш, сызыгыз тизрәк.

С а й м ә. Китәрбез. Барын да әзерләп куй. Җиләк күп булачак.

Г ө л с и н ә. Барыгыз инде, бар, өйрәтмә генә. (*Альбертка.*) Озак йөрмә! Әнине илтеп кую белән, как штык, монда бул!

С а й м ә. Кая барасың тагын? Көн-төн кияүне куасың. Түзгән машинага рәхмәт.

Г ө л с и н ә. Без анысын үзебез белербез, име, Альберт.

А л ь б е р т. Ес, ес, мисс. (*Тагын үбә.*) Мин бик тиз әйләнәм. (*Чыгып китәләр.*)

Гөлсинә өй җыештырырга тотына. Ишектә кыңгырау тавышы.

Г ө л с и н ә. Ходаем, китсәләр китә алмадылар инде, кире керәләр. Тагын лачкылдый башлар. (*Ишек ача, аннан Кәрим килеп керә. Кулында зур курчак.*) Син?..

К ә р и м. Исәнме... (*Пауза.*)

Г ө л с и н ә. Исәнме. (*Пауза.*) Әйдә, уз...

К ә р и м. Юк, мин азга гына...

Г ө л с и н ә (*үзе дә аңламыйча, кисәк җанланып*). Юк, юк, нинди тиз?! Тиз генә китмисең... Яме... Нигәдер мин сине бик көттем... Дәшмә... тыңла гына... а ту мин әйтә алмам... Күңелем сизенгән иде аны, нәкъ менә бүген килерсең кебек тоелган иде... Кәрим, Кәримем минем...

К ә р и м (*аннан читләшеп*). Ярый, Гөлсинә, кыланмыйк әле, яме. Мин болай да ул кыланышлардан...

Г ө л с и н ә. Сүк мине, сүк, Кәрим... Күңелеңне бушат. Мин сине ихластан тыңлыйм... Ышан миңа... Мин чын күңелдән...

К ә р и м. Үпкәләмә, мин сиңа ышана алмыйм... Бәгырь өзелгән.

Г ө л с и н ә. Ышанма, ышанма, китмә генә. Ой, ни сөйлим... Юк, ышан син... Ой, мин сине ничек сагынганмын... Ничек сагынганмын мин сине... Хәтерлисеңме, теге вакыттагы шикелле... Йә инде, кочакла инде мине, йә инде... менә шулай... Ой, ничек рәхәт миңа...

К ә р и м (*үзен көчкә тыеп*). Булды, Гөлсинә... Мин дә тимердән түгел...

Г ө л с и н ә. Тимердән булмыйча. Ярты елга бер килеп чыга алмадың... Бөтен җаным газапланды... Уф, азрак тынычландым... Бу нәрсә булды минем белән, мәйтәм, бер кәефем юк, ашкынам... Инде тынычландым...

К ә р и м. Кирәкми, Гөлсинә, кирәкми. Нигә болар барысы да? Син мине яңадан җебетеп, соңыннан миннән бер рәхәтләнеп көләсең киләме?

Г ө л с и н ә. Юк, юк! Алай димә! Алай димә! Дәшмә.

К ә р и м. Булды, җитте, кирәкми бүтән алай.

Г ө л с и н ә. Йә, йә, тынычлан. Бер яхшылап коч инде мине. Йә инде... Менә шулай... ныграк... Шулай... шулай... Ах... (*Ишектә кыңгырау тавышы.*)

Г ө л с и н ә (*елмаеп*). Өреп тутыргандай булдым. Рәхәт. Мин ачыйммы?

К ә р и м. Әйе, әйе, тиз.

Г ө л с и н ә. Хәзер. (*Ишек ача.*)

А л ь б е р т керә.

А л ь б е р т. Менә мин дә. Как штык! Мин әзер. О-о, кунак бар икән. Нихәл?

К ә р и м. Әйбәт.

Г ө л с и н ә. Менә Кәрим, ни...

А л ь б е р т. Син кая югалдың, күзгә-башка күренмисең?

К ә р и м. Мин...

А л ь б е р т. Ә-ә, ни, карале, Гөлсинә, ул бит әле безнең туйда булмады. Ох, старик, беләсеңме, нинди туй отгрохотали. Ха-ха-ха. Ярты шәһәр бәйрәм итте. Әйдәле, ул да безне котласын әле.

К ә р и м. Нинди туй?

А л ь б е р т. Нинди? Ха-ха, белми. Соң Гөлсинә белән безнең туй.

К ә р и м. Н-н-и-и-чек а-л-а-ай?

А л ь б е р т. Ну, Африка! Ха-ха-ха. Син чыннан да Африкада адашып йөргәнсең бугай. Ха-ха-ха. Теге юлы миңа бик кызыгып калган идең. Әйт әле, әйт, кайда йөрдең?

К ә р и м (*аңламыйча*). Ә? Нәрсәне?

А л ь б е р т. Һе-һе, беткән бу бөтенләй, Африкада йөреп, маймыл булып. Хи-хи-хи. Туй, беләсеңме? Туй! Шундый нәрсә ул... Хәзер без сиңа аңлатабыз... Гөлсинә, син өстәл

әзерләле тиз генә... Тик, брат, өстәл артында гына, ә төнгесен ни-ни... анысын үзең күзалла... Ха-ха-ха.

Кәрим. Туй... димәк, бу... димәк, син...

Альберт. Әйе инде, әйе. Гөлсинә, аңлат әле шуңа, миннән бүтән булмый... ой, үләм хәзер...

Гөлсинә. Әйе, Кәрим, ул минем ирем була...

Кәрим. Аңлашыла...

Альберт. Көчкә. Әйдәле, дускай, әй баҗай, баҗай, ха-ха-ха, өстәл янына. Туй итәбез.

Кәрим. Юк! Гафу итегез борчыганга, мин кызымны гына күрергә дип килгән идем...

Гөлсинә. Йә инде, ашыкма инде, Кәрим...

Кәрим. Юк, юк, кыстап азапланмагыз. Гөлсинә, миңа Ләйсәнне күрергә иде...

Гөлсинә. Беләсеңме, Кәрим...

Альберт. Ә Ләйсәнне без бик шәп җиргә урнаштырдык. Рәхәткә чумды бала.

Кәрим. Кайда Ләйсән?!

Гөлсинә. Аңа анда бик яхшы, бер дә борчылма, Кәрим.

Альберт. Ул хәтта монда кайтудан да баш тарта кайчак. Мин теге көнне һич алып кайта алмадым. Кайтмыйм, ди, и все. Хәтта шундый усал итеп карады...

Кәрим. Ләйсән кайда?!

Гөлсинә. Беләсеңме, Кәрим. Ул бик әйбәт интернатта.

Кәрим. Интернатта?!

Гөлсинә. Ә һәр ял саен ул монда кайта. Ул бик әйбәт интернат. Ниндидер махсус диме. Альберт көчкә генә урнаштырды. Ярый ул булды әле...

Альберт. Пүчтәк ул, ерунда безнең өчен...

Гөлсинә. Кәрим, мин аны алып кайтырмын, кил син, бүтән вакытта кил.

Альберт. Әйе, без аны жәлләмибез. Рәхәтләнеп килеп карап кит. Баланы атасы белән очраштырмыйча. Тик кыерсытма гына... Яле, әйдәле, безне бер котлале, яме... Әйдәгез әле өстәл янына...

Кәрим. Юк, юк, рәхмәт. Бәхетле булыгыз! Хушыгыз!

Альберт. Ха-ха-ха. Ну комик! Көлдереп үтерә язды. Син нәрсә аннан куркып калдың? Бөтенләй коелып төштең... Мин барында бернидән дә, беркемнән дә курыкма. Э-эх! (*Гөлсинәне күтәреп ала.*) Ха-ха-ха! Минеке!

К ә р и м (*кисәк тезләренә чүгеп, бөгелеп төшә*). Ниткән дөнья соң бу?!

Ут сүнә.

Шул ук бүлмә. Г ө л с и н ә Л ә й с ә н н е киендереп йөри.

Г ө л с и н ә. Каранма инде як-ягыңа, тык кулыңны, соңга калабыз.

Л ә й с ә н. Әнием! Минем анда барасым килми.

Г ө л с и н ә. Сөйләнеп торма. Синнән сорап торырлар менә хәзер.

Л ә й с ә н. Әни, әни, дим?

Г ө л с и н ә. Киен тизрәк. Син дә нервыга тиеп торасың.

А л ь б е р т (*эчке бүлмәдән чыга*). Сүкмә, әйбәт кыз ул. Әйбәтме син? (*Ләйсән дәшми.*) Ә мин әйбәтме? Мин сиңа әле, беләсеңме, нәрсә алып бирәм?.. (*Ләйсән дәшми.*)

Г ө л с и н ә. Әле син мондамыни?

А л ь б е р т (*игътибар итмичә, Ләйсәнгә*). Мине яратасыңмы?

Л ә й с ә н. Юк. (*Пауза.*)

Г ө л с и н ә. Китмәдеңмени дидем мин?

А л ь б е р т (*ишетмәгәнгә салынып*). Нигә яратмыйсың?

Л ә й с ә н. Син майлы.

Г ө л с и н ә. Син ни сөйлисең, ә? (*Ләйсәнгә суга.*)

А л ь б е р т. Әйтсен, бала бит.

Г ө л с и н ә. Салпы якка салам кыстырып торма. Ник монда син дип сорадым?

А л ь б е р т. Әйдә шуның белән генә бетерик әле, Гөлем.

Г ө л с и н ә. Кагылма миңа. Мин болай да бик әйбәт ишетәм.

А л ь б е р т. Кагылмыйм, кагылмыйм. Алайса, бетте?

Г ө л с и н ә. Юк. Сөйләштек, булды.

А л ь б е р т. Йә инде... гаепле булсам, кичер...

Г ө л с и н ә. Ой, нишлисең син, ә... Булды, җитте...

А л ь б е р т. Ни гаебем бар соң алайса, аңламыйм.

Г ө л с и н ә. Үтерәсең син мине... Да... бер гаебең дә юк синең... Аңлаттым бит инде... Ничә сәгать...

А л ь б е р т. Шул тикле җансыз булма инде... Бераз сабыр итеп кара... Мин дә тырышам...

Г ө л с и н ә. Ой Аллам! Мин бит сине тамчы да гаепләмим, үзем гаепле мин, ачуланма гына... Булмый, булмый, бары шул.

Альберт. Нәрсә булмый?

Гөлсинә. Бергә булып булмый. Минем түзәр чамам калмады. Сиңа түгел, үземә. Шуңа сине күрә дә алмыйм. Кочаклау түгел, чыраеңны да... Ничек аңламыйсың. Бөтен яклап сиздерергә тырыштым бит инде...

Альберт. Тырыштың анысы, үзәгемә үтте инде...

Гөлсинә. Шулай булгач, бетте, бар кит. Бер елга якын торып карадык бит инде.

Альберт. Тагын азрак...

Гөлсинә. Тагын бер көнгә калсаң, мин бетәм. Чыгам да асылынам. Зинһар, берни сорама. Кит кенә. Кеше бул инде. Ир бул, зинһар өчен.

Альберт. Симердең шул... Симергән эт шулай хуҗасына ташлана инде ул.

Гөлсинә. Зинһар, Альберт, әшәкеләнмик. Син бит андый түгел.

Альберт. Юхаланма. Җүнле кеше төсмени сезгә. Әнә шул Кәрим ишеләр төс тә инде сезгә... Әниеңне әйтер идем, дура...

Гөлсинә. Альберт, юкка көчәнәсең. Бер кылым да селкенми. Җүнле килеш кенә кит инде.

Ләйсән. Кит инде, бар... Күпме әйтергә була, һы.

Альберт. Кара, кара, бусы да... тик тор!

Ләйсән. Әнием!

Гөлсинә. Тимә балага.

Ләйсән. Мин сине яратмыйм... Мин әтиемне ярата-ам. Минем әти кайда... ник кайтмый ул?

Альберт. Синең атаң акыллы булган шул ул. Мондый елан янына кеше кайтамы? Кайтмый, кәнишне. Ну, акыллы егет булган икән Кәрим, кадерен генә белмәгәнбез...

Ләйсән. Әни, әти кайтмыймы?

Гөлсинә. Тыңлама кызым шуны.

Ләйсән. Син әшәке...

Альберт. Кит аннан, белми идем. Менә миннән башка әйбәтләп яшәп карагыз.

Ләйсән. Әни, әнием җаным, зинһар, илтмә мине шул интернатка, пажалысты... илтмә.

Гөлсинә. Кызым! Алтыным, бердәнберем минем! Илтмим кызым, илтмим, борчылма. Ярый әле, син бар. Елама, кызым. Мин сине беркемгә дә бирмим.

Ләйсән. Әни, әнием! (*Пауза.*)

А л ь б е р т. Гөлсинә, ачуланма, кызып киткәнмен.

Г ө л с и н ә. Кирәкми.

А л ь б е р т. Алайса, мир.

Г ө л с и н ә. Уф. Юк! Барын да әйтеп бетерденме?

А л ь б е р т. Гафу.

Г ө л с и н ә. Без киттек алайса, син кал. Кеше бул, Альберт, кит син җыенып без югында. Ә мин сине гомерем буе аның өчен хөрмәт итәрмен. Бары да юкка. Мин бүтәнчә булдыра алмыйм, аңла.

А л ь б е р т. Да-а-а.

Г ө л с и н ә. Йөзегең шунда, өстәлдә.

А л ь б е р т. Кит инде...

Г ө л с и н ә. Ярый, хуш. Тыңла инде мине, зинһар, соңгы тапкыр. Әйдә, кызым. (*Чыгып китәләр.*)

Ут сүнә.
Психолог кабинеты яктыра.

П с и х о л о г. Да-а...

Г ө л с и н ә. Менә шундый хәлләр...

П с и х о л о г. Күптәнме инде үзегез генә?

Г ө л с и н ә. Ике елдан артык...

П с и х о л о г. Язмыш... Үкенәсезме?

Г ө л с и н ә. Бер яктан караганда, үкенмим дә... Чөнки кайвакыт уйланып утырам да... Нинди бай, җанлы тормыш... Авыр булса да. Икенче яктан — нигә минем башка гына барысы да, Ходаем, дим...

П с и х о л о г. Хәзер сезнең кризис...

Г ө л с и н ә. Ничек аңларга?

П с и х о л о г. Тынычлык таба алмыйсыз... Нидер җитми кебек... Башкалар...

Г ө л с и н ә. Алары да бар. Нәрсәдер җитми дә кебек, дөрес... Йокы бик начар, доктор. Гел саташулы. Иң борчыганы — уй. Аннан арынып булмый. Әллә ниләр килә башка.

П с и х о л о г. Күптәнме?

Г ө л с и н ә. Элек алай ук түгел иде. Ә хәзер бер нәрсәдән ямь тапмыйм. Эшемнең дә кызыгы юк. Гел уйланып, боегып йөрим.

П с и х о л о г. Ә ирегезне шул китүдән күрмәдегезме?

Г ө л с и н ә. Кайсысын?

П с и х о л о г. Беренчесен, әлбәттә.

Гөлсинә. Юк. Ул кая китәсен әйтмәде... Эзсез югалды. Ниндидер үкенеч булып калды...

Психолог. Аның белән кызыксынучы да булмадымы?

Гөлсинә. Юк. Ә-ә, һе-һе! (*Елмаеп.*) Илсөяр дустым адресын бер сораган иде. Ошаткан булган, күрәсең...

Психолог. Адресын белмәвегез начар...

Гөлсинә. Аның ни катнашы бар? Аңламыйм. Ул бит борчылмый, ә минем тынычлыгым юк?!

Психолог. Юк, болай гына. Язмыш бит. Бәлки, әйбәт рәссам булып киткәндер. Бәлки, бер ишетелеп тә куяр...

Гөлсинә. Һе, ул минем төшемә дә шулай, гаепле елмаеп, гел рәсем ясап керә.

Психолог. Төшкә керәме?

Гөлсинә. Кергәли шул...

Психолог. Сезгә аны ул кадәр кулга алмаска иде.

Гөлсинә. Ничек?

Психолог. Кошны читлеккә япсаң, боега... Ул ректә генә моңлы сайрый... Гел иреккә омтыла. Ирексез җәнлеккә, хискә караганда, ирек кадерлерәк була башлый.

Гөлсинә. Бардыр инде. Кире кайта торган юл булса. Булган беткән инде. Менә хәзер...

Психолог. Хәзер?.. Ә кызыгыз ни ди?..

Ләйсән (*арткы планда пәйда булып.*) Мин әтиемне яратам! Минем әтием кайда? Ник кайтмый ул? (*Гөлсинәнең хәле начарая.*)

Психолог. Сезгә ни булды? Агарындыгыз. Мәгез су...

Гөлсинә. Берни дә юк, хәзер үтә ул, хәзер... (*Су эчә.*)

Психолог (*барып тәрәзәне ача*). Бирегә килегез, азрак һава алыгыз. (*Гөлсинәне тәрәзә янына алып килә.*) Торыгыз, тор, ашыкмагыз... (*Үзе урынына утыра.*)

Психолог кабинетына Кәрим йөгереп керә. Ул бик ашыккан. Йөгереп килгән кешегә охшый.

Кәрим. Исәнмесез, доктор. Зинһар, ярдәм итегез!

Психолог. Йә, йә, ул кадәр ашыкмыйча. Тәртибе белән генә.

Кәрим. Миңа ашыкмый булмый. Минм түзәр чамам калмады. Зинһар, ярдәм итегез!

П с и х о л о г. Сез бөтенләй ярсыгансыз. Тынычланыгыз. Мә, су йотыгыз. (*Кәрим су эчә.*) Тыңлыйм.

К ә р и м. Беләсезме, доктор, минем яраткан хатыным, гаиләм бар иде.

П с и х о л о г. Шуннан?

К ә р и м. Мин җүләр баш аларны ташлап чыгып киттем. Җүләр мин, доктор. Шундый әйбәт хатынымны ташладым.

П с и х о л о г. Ягез инде, тыныч кына сөйләргә тырышыгыз.

К ә р и м. Ничек тыныч. Минем йокым йокы түгел. Гел борчылам, саташып уянам. Күңелемә бер дә тынычлык таба алмыйм. Гел ул күз алдымда. Иң авыры — уй. Баш бер дә уйсыз тормый. Гел алар турында уйлыйм.

П с и х о л о г. Сабыррак булыгыз, зинһар.

К ә р и м. Булмый. Булдыра алмыйм. Мин гаепле алар каршында. Нишләргә миңа?

П с и х о л о г. Башта сезгә тынычланырга кирәк. Аннан...

К ә р и м. Нәрсә аннан? Мин алардан башка, сөекле хатынымнан, кызымнан башка яши алмыйм, үләм мин хәзер. Ә сез, тынычлан, дисез... Миңа тизрәк алар белән кушылырга кирәк, зинһар, ярдәм итегез. Киңәш бирегез.

П с и х о л о г. Ярар, ярар, ашыкмагыз гына.

К ә р и м. Мин бик гаепле! Ничек миңа аның янына барып керергә?! Ничек күзенә карарга? Киңәш бирегез! Кайда ул хәзер. (*Кычкыра.*) Гөлсинә! Гөлем!

П с и х о л о г. Сез нишлисез? Кычкырмагыз! (*Кәрим юкка чыга.*)

Г ө л с и н ә. Кәрим!

П с и х о л о г. Сез нәрсә?

Г ө л с и н ә. Әле генә монда булган кеше кайда?

П с и х о л о г. Нинди кеше?

Г ө л с и н ә. Әле генә монда кереп, сезнең белән сөйләште?

П с и х о л о г. Минем белән беркем дә сөйләшмәде.

Г ө л с и н ә. Ой, алдашмагыз инде. Әле генә монда кереп, сездән минем ирем Кәрим, Кәримем киңәш сорады. Зинһар, яшермәгез, доктор, ул бит минем ирем. Кәримем бит ул!

П с и х о л о г. Зинһар, тынычланыгыз, монда беркем дә булмады.

Гөлсинә. Алдашмагыз. Сез мине юри алдыйсыз. Ул монда кереп сездән киңәш сорады! Мине, яраткан хатынын ничек табарга икән, дип сорады! Бик сагындым, диде, күрәсем килә, бергә торасым килә, диде! Сез аны кая яшердегез?! Әйтегез! (*Елый.*) Әйт! Миңа Кәрим кирәк!

Психолог. Зинһар өчен, дим. Сез...

Гөлсинә. Юатмагыз мине... Минем аңа бер генә соравым бар... Бер генә сүз... Кая ул?! Кая? (*Залга кычкыра.*) Кайда син?!

**Гөлсинә авансцена уртасына йөгереп чыга. Арткы пәрдәне өзеп төшерә. Ул ефәк томан төсле тарала, юкка чыга. Сәхнәдәге бөтен җиһазны егып, бар нәрсәне чәчеп ташлый. Нидер чәлпәрәмә килеп ватыла. Каядыр шыбырдап яңгыр ява башлый.**

Пәрдә.

# Эчтәлек

Кереш урынына . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Упкын өстендә уен... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Юбилей . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
Ыру... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
I am «the Theatre» actor... . . . . . . . . . . . . . . 146
Кабан күле серләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 206
Һинд кызы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 281
Сагынырсың әле син дә бер... . . . . . . . . . . . . . 316

Литературно-художественное издание

Гафур Каюмов
*(Каюмов Гафур Шакурович)*

*Игра над бездной*

(на татарском языке)

Мөхәррирләре *Х.К.Ибраһимов, Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *В.Е.Булатов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Г.Г.Гарифуллина, Р.В.Сабирҗанов*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 3.06.2003. Форматы 84×108 1/32.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 20,16 + форз. 0,21. Шартлы-буяу оттиск 21,42.
Нәшер-хисап табагы 21,33 + форз. 0,36.
Тиражы 2000. Заказ Я-101.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.